ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исем.
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**Р. Ф. ХАРРАСОВА**

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ НИГЕЗЛӘРЕ

Казан
2017

УДК 821.512.145:82.09
ББК 833(2Рос=Тат)
Х20

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

**Фәнни редактор –**
филология фәннәре докторы **Ә.М. Закирҗанов**

**Рецензентлар:**
филология фәннәре докторы **В.З. Гарифуллин,**
филология фәннәре докторы **А.Г. Әхмәдуллин**

**Харрасова Р.Ф.**
**Х20** **Әдәби тәнкыйть нигезләре** / Р.Ф. Харрасова. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – 312 б.
ISBN 978-5-93091-239-5

Китап әдәби тәнкыйть өлкәсендәге фәнни эзләнүләр теориясе, методологиясе, әдәби тәнкыйтьнең гомуми һәм универсаль закончалыклары, жанр формалары белән таныштыра. Ул югары уку йортларында, гыйльми тикшеренү институтларында «Әдәби тәнкыйть» фәнен үзләштерүче студентлар һәм аспирантлар өчен уку әсбабы сыйфатында хәзерләнде. Хезмәт шулай ук журналистлар, мөхәррирләр, мәктәп укытучылары, язучылар өчен дә файдалы булыр.

УДК 821.512.145:82.09
ББК 83.3(2Рос=Тат)

**ISBN 978-5-93091-239-5**

© Харрасова Р.Ф., 2017;
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2017

# КЕРЕШ

*Прозада да, поэзиядә дә, драматургиядә дә
очраклы кешеләр аз түгел.
Очраклы кешегә тәнкыйтькә керү
әдәбиятның башка өлкәләренә керүгә караганда да
җиңелрәк.*
Б. И. Бурсов

Әдәби тәнкыйть тарихы Рәсәй югары уку йортларының филология факультетларында белем алучылар тарафыннан күптән укытыла һәм әдәбиятка кагылышлы фәннәрнең йомгаклаучы курсларыннан санала, әмма тәнкыйтьнең теоретик нигезләрен өйрәтү, жанр формаларын үзләштерү озак вакыт игътибардан читтә калып килде. Кулыгыздагы китап татар гуманитар белем бирү системасында калган кайбер бушлыкларны тутыру юнәлешендәге игелекле бер эш булыр дип өметләнәбез.

«Әдәби тәнкыйть нигезләре» бу төр хезмәткә аеруча ихтыяҗ туган чорда – Казан дәүләт университетында әдәби тәнкыйтьчеләр һәм мөхәррирләр әзерләнә башлагач – язылган, 2005 елда шул уку йортының әдәбият кафедрасында тикшерү үткән, хупланган һәм, 2006 ел башында ук басмага хәзерләнеп бетсә дә, басылмыйча калган иде. Аннан соң шактый ел узды, әдәби тәнкыйть теориясенә нисбәтле яңа дәреслекләр, методик ярдәмлекләр дөнья күрде, әмма алар арасында татарча уку әсбаплары һаман да юк. Шул ук вакытта татар әдәбият белемендә тәнкыйтьнең теге яки бу проблемаларын яктырткан яңа хезмәтләр барлыкка килүен дә әйтергә кирәк. Тәнкыйть фәнендәге заманга бәйле үсеш-үзгәрешләрне күздә тотып, «Әдәби тәнкыйть нигезләре» китабыбызны, аз булса да өстәмәләр, төзәтмәләр кертеп, укучы игътибарына тәкъдим итәргә карар кылынды.

«Әдәби тәнкыйть нигезләре»нең инде яңа заман фәне биеклекләреннән торып язылган дәвамы булыр дип фаразлана, чөнки

ызандаш фәннәрдә дә өйрәнелүче һәм үзара якын торган, бер ояга берләшерлек кайбер проблемалар аннан читтә калды. Боларның тәүгесе – әдәби коммуникация, ягъни нәфис текстны уку һәм эчтәлекне аңлау; форманы, стиль үзенчәлекләрен кабул итү; язучы иҗатына интерпретация; автор һәм тәнкыйтьче мөнәсәбәте; әдәби тәнкыйтьтә автор образы кебек мәсьәләләр. Икенчесе – әдәби әсәрне өйрәнү методлары. Аларга системалы, комплекслы, биографик җирлектәге, тарихи-мәдәни, чагыштырма-тарихи тикшерү ысуллары; компаративистик, социологик, герменевтик, формаль, структур методлар керә. «Әдәби тәнкыйть нигезләре»ндә, әлбәттә, эчтәлекне (әсәр нигезенә салынган принципларны һәм идеяләрне) һәм форманы (әлеге идеяләрне чагылдыру калыпларын, юлларын) ачу, ягъни формаль характердагы элементларны (стиль, жанр, композиция, сөйләм һ.б), эчтәлеккә мөнәсәбәтлеләрне (сәнгати идея, тема, фабула, конфликт, характерлар һ.б.) яисә икесенә дә караган якларны (сюжет) ачыклау юллары да өйрәнелергә тиеш. Болардан тыш, нәфис текст берәмлегенә әдәби төр һәм жанр ноктасыннан якын килүнең дә тәнкыйтьче белергә тиеш үзенчәлекләре бар.

Әдәби тәнкыйть гуманитар фәннәр укытучының иҗтимагый эшчәнлеге һәм булган белемнәрен күрсәтү мәйданы булып тора. Теләсә кайсы укытучы билгеле бер темага үзеннән көтелгән югарылыктагы тәнкыйть материалын яза белергә, һич югы тар аудиториянең – укучыларының игътибарын сәнгать таләпләренә җавап биргән әсәрләргә юнәлтә алырга тиеш. Шәхеснең матур әдәбиятны анализлау осталыгы югары уку йортында алган профессиональ күнекмәләрен, белем дәрәҗәсен чагылдыра. Махсус курс мөстәкыйль, иҗади, фәнни фикер йөртүче филологлар тәрбияләүне күздә тота, шунлыктан теоретик сәгатьләр янәшәсендә гамәли дәресләр дә уздырыла.

«Әдәби тәнкыйть нигезләре»н белү бигрәк тә киләчәктә фән юлыннан китүне сайлаганнар – яшь галимнәр, аспирантлар өчен мөһим. Филологик факультетларның белем бирү программаларына аны укыту кертелмәгән шартларда аспирантурада ул, һичшиксез, тирәннән укытылырга, гамәли ныгытылырга, ә мөгаллим күзәтүе астында башкарылган хезмәтләр вакытлы матбугатта апробация узарга тиеш.

Әдәби тәнкыйть теориясе яисә нигезләре дип аталган курс фәнгә керүне, тәнкыйть язмаларын башкару өчен кирәкле дәрәҗәдә теоретик материал узуны һәм кабатлауны күздә тота,

«Әдәби тәнкыйть буенча практикум» исә мөстәкыйль рәвештә тәнкыйди хезмәтләрне анализларга, аларның эчтәлеген ачып бирергә, сәнгатьчә үзенчәлекләрен күрсәтергә, төрләрен билгеләргә өйрәтә; әдәбият тарихы, әдәбият һәм әдәби тәнкыйть теориясе, хәтта башка фәннәр, әйтик, тел гыйлеме тармаклары буенча алган теоретик белемнәрне дә гамәлдә сынау мөмкинлеге тудыра.

Әдәбият белеменең тәнкыйть юнәлешендә эшчәнлек күрсәтү – мәктәп укытучысын, китапханәчене, журналистны, әдәбиятчыны үстерә, күзаллауларын киңәйтә, гыйльми тикшерүгә сәләтен, язу куәтен, сөйләм күнекмәләрен камилләштерә, шунлыктан «Әдәби тәнкыйть нигезләре» яшь филологлар узарга тиеш мөһим курсларның берсе булып тора.

Кечкенә күләмле мәкаләләр, хәбәрләр иҗат итми торып, бер генә кеше дә камил зур фәнни хезмәтләр башкара алмый. Студентларның да, аспирантларның да әдәби, фәнни сөйләме вакытлы матбугатка әзерләгән кечкенә күләмдәге язмалар аша камилләшә барырга тиеш. Махсус семинар вакытында алар әдәби редакцияләү эшенә күнектерелә.

Әдәби тәнкыйть теориясен үзләштерүчеләрдән түбәндәге белем, сыйфат һәм күнекмәләргә ия булу таләп ителә:

– аерым бер каләм иясенең әсәрләрен, теге яки бу нәфис текстны өйрәнгәндә һәм яктыртканда, мөмкин кадәр объективлыкка омтылу; әдип иҗатына комплекслы якын килү; заманчалыкны, әдәбиятның актуаль проблемаларын күздә тоту; теоретик белемнәрне үзләштерү һәм аларга таяну; тәнкыйтьче этикасы нормаларын саклау кирәклеген аңлау;

– әдәби тәнкыйтьнең жанр формаларын, аларның сыйфатламаларын, кулланылу мөмкинлекләрен белү; иҗат психологиясе, әдәбият теориясе һ.б. фәннәрнең сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләрен, әдәби процесска кагылышлы теоретик мәгълүматларын үзләштерү;

– әдәби тәнкыйтьнең кече формаларында (аннотация, аерым бер әсәргә рецензия) иркен иҗат итү.

# 1. ФӘН БУЛАРАК ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ ҺӘМ АНЫҢ ТӨП НИГЕЗЛӘРЕ

*Әдәби тәнкыйтьнең яшәве дәвамында...*
*аның нәрсә икәнлеге хакында бәхәсләр бара.*
*Фәнме, әллә сәнгатьме?*
П. Басинский

## 1.1. Әдәби тәнкыйтьнең предметы һәм бурычлары

Әдәбият, чынбарлыкны хәрәкәттә, үсештә сурәтләп, кешеләрдә шул тормыш хакында карашлар формалаштыра, аларның холкын тәрбияли, җәмгыятькә һәрьяктан камил кеше әзерләүдә булыша. Бу вакытта ул башка сәнгать төрләренең, әдәбиятны өйрәнү объекты иткән фәннәрнең ярдәменә таяна. Иҗатны, әдәби барышны алга әйдәүче, аның үсеш юлларын билгеләүче, фаразлаучы көчләрнең берсе, әһәмиятлесе булган тәнкыйть, үз чиратында, гаделлек принципларын тормышка ашыруда зур эш башкарган сәнгатькә хезмәт итә, кешене идея һәм әхлак ягыннан тәрбияләү процессына актив йогынты ясый, һәм аның максат-бурычлары әдәбият алдына куелган максат-бурычларга барып тоташа.

*Әдәби тәнкыйть иҗатчының эзләнүләрен дәвам итә, тулыландыра, фикерләренә төзәтмә кертә, аңа теоретик планда ярдәмгә килә.* Язучының дөньяга карашлары, аның әдәби һәм тәнкыйди хезмәтләрен янәшә куйганда, тагын да ачыграк, дөресрәк күзаллана. Каләм ияләренең, нәфис иҗат белән генә канәгатьләнмичә, башкалар язганны, әдәби барышны анализлаган хезмәтләр бастыруы аларда әдәбиятка, тормышка һәм җәмгыятькә бәйле фикерләрне халыкка җиткерү теләгенең көчле икәнлеген күрсәтә. Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Г. Ибраһимов кебек талант ияләре мирасында әдәби тәнкыйтьнең зур урын алуы юкка түгел. Теләсә кайсы әдәбият белгече әдип һәм шагыйрьләрнең нәфис иҗатын өйрәнүне бары тик аларның тәнкыйть язмаларын анализлау белән берлектә генә башкара.

Акыл эшчәнлегенең уникаль күренеше булган әдәби тәнкыйть яралгылары әдәбият белән бер үк вакытта барлыкка килсә дә һәм аның өйрәнү объекты баштан ук ачык булса да, фән сыйфатында шактый соң формалаша. Аның үзенә ызандаш гыйлемнәрне ачыклавы, алар белән кайбер вазифаларны бүлешүе һәм гыйльми өлкә буларак күзаллануы күпмедер вакыт сорый.

Әдәби тәнкыйть *әдәбият теориясе, әдәбият тарихы* кебек фәннәр янәшәсендә тора, шулар ярдәмендә аерым системага әйләнгән *әдәбият белеменең* бер өлешен тәшкил итә. Әдәбият тарихы һәм теориясе табышларына таянса да, тәнкыйть, заман әдәби барышын яктыртканлыктан, әлеге өлкәләрдән дә алдарак торган кебек кабул ителә, һәм ул сүз сәнгатенең генә түгел, теоретик фикернең дә үсешенә уңай тәэсир ясый.

Башка фәннәрнең әдәбият белеменә ярдәм итүче тармакларыннан яисә әдәбият тарихының, теориясенең юнәлешләреннән саналган *архивчылык, музейчылык, китапханәчелек, палеография, текстология, герменевтика, әдәби риторика, әдәби анализ методологиясе, хронология, әдәбият белеменең һәм тәнкыйтенең тарихы кебек бик күп,* төрле пландагы һәм шул ук вакытта үзара нык кисешкән фәннәр – әдәби тәнкыйть теориясе белән ызандаш өлкәләр. Кайберләренең, гомумән, фәнме, мөстәкыйль фәнме яисә кайсыдыр фәннең тармагымы икәнлеге шулай ук еш кына бәхәскә алына, һәм һәрберсенең теоретик нигезләрен ачыклауны максат иткән китаплар да языла тора.

Әдәби тәнкыйтькә теләсә кайсы фән өчен табигый *таләпләр* куела:

– мәгълүмати тыгызлык;

– гыйльми төшенчәләрнең аңлаешлылыгы, тәгаенлеге, гомумкабул ителгәнчә кулланышы, үзара бәйләнгәнлеге;

– теориянең тирәнлеге, объектны өйрәнүдә корал рәвешендә файдаланылуы, бары тик үзмаксат кына булып калмавы, предметтан киңрәк сфераларга чыгуы (әйтик, әдәбиятны – тормыш, аерым бер әсәрне – әдәби процесс, тарих, җәмгыятьтәге хәлләр, көнкүреш, сәясәт, мәдәни һәм икътисади барыш, тәгаен фәннәр үсеше белән бәйләү);

– төшенчәләрнең, категорияләрнең, кануннарның иерархик баскыч ясавы;

– яңа күренеш һәм фактларны гомумиләштерүгә хәзерлеге, мөмкинлекләре;

– кабул ителгән кагыйдәләрнең, белемнәрнең идеологиядән өстен булуы, фактларга гына буйсынуы һәм башкалар.

*Тәнкыйть әдәби әсәргә, анда чагылган тормыш күренешләренә бәя бирүне максат итә; әдәбият тарихыннан аермалы буларак, бүгенге көндә әдәби хәрәкәттә барган үзгәрешләрне, үзенчәлекләрне аңлата.* Әдәби тәнкыйтьне шулай ук нәфис текстлар белән эш иткән әдәбият тарихыннан традицион рәвештә вакыт принцибыннан чыгып аерып куйган бу билгеләмә күпмедер шартлы, чөнки сүз сәнгате барышын, күренешләрне яисә иҗатны яктыртканда, аның белән шөгыльләнүче үзеннән алдагы чорларга, һичшиксез, мөрәҗәгать итә. Тәнкыйть спецификасын аңлау өчен, аның предметы белән генә чикләнергә ярамый, танып-белү формасын, әдәби фактларны бәяләү, интерпретацияләү характерын да исәпкә алырга кирәк. Кайбер галимнәр узгандагы әдәби әсәрләрне заман яктылыгыннан торып яңадан ачуны да әдәби тәнкыйтькә кертеп карауны яклый.

Әдәби тәнкыйтьнең аны иҗат сыйфатында теркәүче махсус формалары бар. Алар авторларның стиленә, осталыгына, алга куйган максатларына, аудитория ихтыяҗына, милли традицияләргә, тәнкыйтьнең, аңа урын биргән вакытлы матбугатның, телевидение-радио челтәренең үсеш дәрәҗәсенә, шулай ук башка сәбәпләргә дә бәйле. Әдәби тәнкыйтькә һәм нәфис текст, һәм фәнни хезмәтләр язу методлары көчле тәэсир ясый, авторлар үзләренә кадәр иҗат ителгән әсәрләр йогынтысыннан беркайчан да тулаем азат була алмый. Әнә шулай итеп, нәфис әдәбият тәэсиренә бәйле рәвештә, *классицистик, сентименталистик, романтик, реалистик тәнкыйть* төрләре барлыкка килә. Ә инде каләм иясе, үз анализында алга куйган принциптан чыгып, әдәби күренешләрнең иҗтимагый яңгырашына, актуальлегенә игътибар иткән *публицистик* яисә аларны гомумфәлсәфи һәм гомумэтик проблемалар яктылыгында яктырткан *фәлсәфи*, әсәрнең сәнгати эшләнешен бәяләүгә һәм идея эчтәлеген ачуга басым ясаган *филологик тәнкыйть*не аерып куярга мөмкин.

Иҗатның махсуслашкан сферасы саналган әдәби тәнкыйть үзендә фән, сәнгать, публицистика кебек төрле интеллектуаль-эстетик эшчәнлек сыйфатламаларын берләштерә, сөйләмнән башка яши алмый. Тәнкыйтьне сәнгать белән – иҗадилык, ягъни авторның үз карашларын чагылдыруы, төрле сәнгати чаралардан файдалануы якынайта, ә фәнни эзләнүчәнлеге, башкаларны төрле белемнәр белән коралландыру рухы, объективлыкка омтылышы, фактларга нигезләнүе, төшенчәләр системасына иялеге аны фән

янәшәсенә куя. Тәнкыйтьнең актуальлеге, бер үк жанр формаларыннан файдалануы аны публицистика белән охшаш итә. Шул ук вакытта тәнкыйтьче, журналисттан аермалы буларак, һәрвакыт гыйльми тикшеренүче сыйфатында чыгыш ясый, бигрәк тә күләмле формаларда укучыны мәгълүмат белән коралландыруны алгы планга чыгармый.

Әдәби тәнкыйть предметын калыплаштыручы берәмлекләр рәтендә нәфис әсәрне, тупланманы, әдәби контекстларны, әйтик, аерым бер иҗатны, әдәби барышны, тормышны яисә күренешне, жанрларны һәм башкаларны атарга мөмкин. Алар исә төрле күләм, зурлык һәм вакыт аралыкларын били. Әлеге берәмлекләрне тикшерү, укучыга аңлатып бирү өчен, билгеле бер төшенчәләр белән кораллану, өйрәнүнең заманына күрә актуаль мәсьәләләрен аерып чыгару кирәк. Тәнкыйть белән шөгыльләнүче, бүгенге әдәби барышны һәм хәтта үткәндәге мирасны анализлаганда, үз эшенә өр-яңа бер хезмәт дип якын килергә тиеш. Моның өчен ул:

– үткәндәге традицияләргә нигезләнгән, заман карашлары, шәхси фикерләре белән баетылган, уйлап сайланылган күзаллаулар системасы булдыра;

– бүгенге әдәбиятны уңай идеаллар яктылыгыннан торып кабул итә, анализлый, бәяли, укучыга җиткерә;

– әдәбиятны, әдәби тәнкыйтьнең үзен – шәхесне тәрбияләүче чара, ә шәхесне тәрбияләүнең иҗтимагый бурыч икәнлеген аңлап эш йөртә;

– һәрбер нәфис әсәрнең милләт тарихында кабатланмаслыгын, мәдәниятнең шундый кечкенә барлык берәмлекләрдән оешуын истән чыгармый; димәк, үз халкының мәдәнияте югары үсештә булсын өчен, аны калыплаштырган иҗат берәмлекләренең сәнгати камиллеген кайгырта һәм бары тик чын сәнгать әсәрләрен генә пропагандалый.

Гомумән алганда*, әдәби тәнкыйть норматив-бәяләү, дидактик-тәрбияләү, коммуникатив функцияләр башкара.*

Әдәби тәнкыйть – *иҗтимагый күренеш*. Тәнкыйди хезмәтләр, сәнгать әсәрләре кебек үк, кешегә рухи кичерешләр китерүче *матди продукция* санала. Әдәби тәнкыйть социаль тирәлектә генә яши ала, җәмгыятькә, аның һәрбер әгъзасына турыдан-туры яисә ниндилеге өчен үзе дә җаваплы әдәби барыш, әсәрләр аша йогынты ясый: *иҗатны психологик һәм идеологик кабул итүгә хәзерли, эстетик күзаллаулар булдыра, иҗтимагый аңны формалаштыруда*

*катнаша.* Димәк, ул – функцияләрен бер үк вакытта матбугат, радио-телевидение, сәхнә сәнгате, бүгенге көндә инде интернет аша да гамәлгә ашыручы *иҗтимагый институт* та.

Әдәби тәнкыйтьнең үсеш тизлеге, дәрәҗәсе социаль-тарихи шартларга бәйле. Гасырлар дәвамында аның функцияләре, күтәргән проблемалары, жанр формалары, эчтәлеге, тәнкыйди рухы күзгә ташланырлык үзгәрешләр кичергән, хезмәт иткән аудиториясе дә төрле булган. Шул ук вакытта әдәби тәнкыйть җәмгыятьтә тәрбияви эшчәнлекне барлык чорларда да ике юнәлештә башкарган: бер яктан – публиканы, икенче яктан, сәнгатькәрләрне үстергән, үзгәрткән. Аның уңышлары тәнкыйтьченең хезмәт итәргә алынган өлкәсенең табигатен, кирәклеген аңлау дәрәҗәсенә барып тоташкан.

Тәнкыйди язмалар нәфис-фәнни формаларда дөнья күргәнгә, аны әдәби иҗатның да бер төре саныйлар. Язучыларның иҗтимагый берлекләрендә тәнкыйтьчеләрнең махсус остаханәсе бар. Иҗади оешма каршында ул юнәлештәге секцияләрне ачу тәнкыйтьчеләрнең әдәби барышка турыдан-туры тәэсир итүе һәм берлекләрнең иҗатчы – тәнкыйтьче арасындагы бәйләнешләрне ныгыту максатына да бәйле.

## 1.2. Әдәби тәнкыйть – иҗтимагый күренеш

Кеше табигатенә хас функцияләрнең берсе – мәдәният, чөнки аның яшәешен дин, сәнгать, гуманитар һәм төгәл фәннәр, сәясәт һәм башка юнәлешләрдәге эшчәнлектән башка күз алдына да китерү мөмкин түгел. Билгеле бер мәдәнияткә ия булу шәхеснең, халыкның, илнең әлеге өлкәләрдә алга китеш дәрәҗәсен чагылдыра.

Әгәр без мәдәниятнең бер өлешен тәшкил иткән тәнкыйтьне фән дип саныйбыз икән, иң элек фәннең эчтәлеген ачыклап узарга тиешбез, ә ул, үз чиратында, аның иҗтимагый күренеш икәнлегенә алып чыгачак. «Кеше» энциклопедиясендә теләсә кайсы гыйльми эшчәнлекнең иҗтимагый функция икәнлеге шушы рәвешчә ассызыклана: «Фән ул – кешенең хезмәт бүленеше вакытында аерылып чыккан һәм белем алуга юнәлтелгән билгеле бер эшчәнлеге»[1] (тәрж.– авт.)[2].

---

[1] Волков Ю.Г., Поликарпов В.С. Человек: энциклопедический словарь. М.: Гардарики, 1999. С. 179.

[2] Искәрмә: чит телләрдән алынган цитаталарның барысы да китап авторы тарафыннан татарчалаштырылганлыктан, алга таба бер урында да махсус күрсәтелмәде.

Әдәби барышны, чорны тәнкыйтьтән башка күзаллап булмый. XX гасыр башында, аларның үзара тыгыз бәйләнешен ассызыклап, М. Укмасый, гомуми әдәбият эчендә тәнкыйть булмаса, Аурупада күпсанлы әдәбиятлар барлыкка килмәс һәм зур казанышка ирешмәс иде, дигән фикерне әйтә[1].

Тәнкыйтьнең чишмә башы антик заманнарга ук барып тоташа. Тәнкыйть төшенчәсенә тәңгәл мәгънәдәге критика (kritike) термины Европа әдәбият белеменә грек теленнән килеп керә һәм киң мәгънәсендә фикер йөртү (хөкем) сәнгатен аңлата. Тәнкыйть итү тормышның төрле күренешләренә карата була ала, кешенең, җәмгыятьнең бәя бирүгә сәләтен, хаталардан саклануга һәм үсешкә омтылышын чагылдыра.

Кешелек тарихы иҗтимагый формацияләр баскычы рәвешендә оеша, һәр формация үз мәнфәгатьләрен кайгырткан, аерым бер хокук-бурычларга, мөмкинлекләргә ия сыйныфлардан, социаль төркемнәрдән тора. Махсус функциональ институтлар һәм хезмәт бүленеше барлыкка килү җәмгыятьнең алга таба үсешен тәшкил итә, аның әгъзаларына төрле рольләр йөкли һәм статуслар бирә. Социаль структура, төркемнәрнең үзара мөнәсәбәте тарих дәвамында зур үзгәрешләр кичерә. Галимнәр, кешенең җәмгыятьтәге урынын алмаштыра алуы хакында табигатенә хас интегральлектән чыгып фикер йөртә – аны ике яссылыкка ия дип саный. Ачыклабрак әйткәндә, кешенең иҗтимагый җан иясе сыйфатында бик нык детерминацияләнүе социаль системаны программалаштыручы социокод белән билгеләнә, ә табигатеннән килгән потенциалы аңа җәмгыятьтәге очраклы-фаразый мөмкинлекләрне тормышка ашырырга булыша.

Социаль структура үзгәрешләре хакында сүз йөрткәндә, социаль дифференциация төшенчәсеннән тыш, социаль стратификация гыйбарәсенә дә мөрәҗәгать итәләр: әгъзалары статусларын җиңел үзгәртә ала торган структураларны – ачык, авырлык белән үзгәртә ала торганнарын ябык структуралар дип йөртәләр.

Бүгенге җәмгыятьләрдә теләсә кайсы кеше, акылы һәм язу маһирлыгы булганда, әдиплек дәрәҗәсенә ирешә яисә гыйльми эшчәнлек юлыннан китә ала. Дөнья әдәбиятлары уздырган карашлардагы, әдәби әсәрләрнең идея эчтәлегендәге чуарлык аларны

[1] Укмасый М. Интикад // Йолдыз. 1911. 7 июль.

тудыручыларның төрле социаль чыгышка ия булулары, төрле иҗтимагый системаларга хезмәт итүләре белән дә билгеләнә.

Илебез тарихына мөрәҗәгать итик. Инкыйлабка кадәр татарларда әдипләр һәм галимнәр, нигездә, руханилар катламыннан, чагыштырмача бай тормышлы кешеләр арасыннан чыккан. Совет системасында алар зыялылар гаиләсеннән генә түгел, крестьяннар, эшчеләр катламыннан да фән өлкәсенә узганнар, чөнки һәркемнең бушлай югары белем алу мөмкинлеге барлыкка килгән. Ул заманнарда әдәби эшчәнлек белән шөгыльләнүчеләр арасында эшчеләр, мөгаллимнәр, милиция хезмәткәрләре һәм башка профессия вәкилләре еш очраган.

Күпчелек халыклар, милләтләр үз илләренең, ватаннарының ачык структуралы булуын тели, аерым кешенең бер социаль катламнан икенчесенә күчә алуын җәмгыятьтә хөкем сөргән демократия чагылышы дип бәяли. Шул ук вакытта җир йөзендә һаман да ябык төзелешле җәмгыятьләр бар. Әйтик, озак гасырлар дәвамында касталар системасы яшәп килгән Һиндстан кебек илләрдә очраклы-фаразый иҗтимагый мөмкинлекләр бик шартлы һәм чикле булып кала бирә.

Социаль төркемнәрнең барлыкка килүе хакында һәр заман философлары уйланган. Мәсәлән, Карл Маркс һәм аның тарафдарлары капитализм шартларында мәнфәгатьләре бер-берсенекенә туры килмәгән изүче һәм изелүче сыйныфлар булу тора-бара социаль бүленешкә китерә, ике арадарак торган һәм төрле катламнардан аерылып чыккан зыялылар теге яисә бу сыйныфка хезмәт итә дип санаган.

Соңрак Макс Вебер социаль градациягә икътисади хәл, хакимлек кыла алу-алмау, иҗтимагый дәрәҗә-статус китерә дигән фикер белдергән, аларның бер-берсе белән бәйлелеген, шул ук вакытта һәрвакыт янәшә йөрмәвен дә күрсәткән. Фән һәм әдәбият белән шөгыльләнүчеләр тарих дәвамында әлеге мөмкинлекләргә төрлечә ия, билгеле. Әйтик, феодаль җәмгыятьләрдә, икътисади һәм башка ихтыяҗларын канәгатьләндерү йөзеннән, күп кенә галим һәм шагыйрьләр сарай әһелләренә хезмәт иткән. Шул ук вакытта ханнар, патшалар, феодаллар үзләре дә иҗат һәм фән белән шөгыльләнгән, чөнки әлеге өлкәләрнең үсешендә хаким сыйныфларның да мәнфәгатьләре чагылган, бу төр эшчәнлек хакимне халыкта уңай яктан таныту чарасы да булып торган.

Социалистик система таркатылганнан соңгы яшәешебез СССРда ил идеологиясен ныгытырга хезмәт итәргә тиешле дип

каралган каләм ияләренең социаль статусы шактый югары булганны раслады. Шул ук вакытта аларның иҗатта һәм шуны бәяләгән фәндә шәхси фикерләре кырыс цензура күзлеге аша уздырыла, еш кына кысыла, хакимият алып барган идеология кысаларынан читкә чыга алмый, шуңа яраклаштырыла иде.

Галимнәрнең бер өлеше Үзгәртеп корулардан соңгы Рәсәй җәмгыяте югары, урта, нигез, түбән катламнарга һәм тормыш төбенә бүленә дигән караштa тора. Хакимлек итүче өске катламда әдәби һәм гыйльми элита булырга мөмкин, шулай да зыялыларның күпчелеге – нигез, бер өлеше аннан югарырак торган урта катламга карый, ди. Фәнгә хезмәт итүчеләр, төрле иҗтимагый статуска, капиталга, хакимлеккә ия икән, иҗтимагый тормышны яктырткан әдәбиятка да аермалы якын киләчәк дигән сүз.

Рәсәйдәге социаль төркемнәрнең башкача бүленешләрендә зыялылар, нигездә, урта катламга керә, икътисади-сәяси элитада әдәбиятчылар юк, ә инде дәүләт бюрократиясен тәшкил иткән югары катламда сәнгатькәрләрнең саны бармак белән санарлык. Милли телдә иҗат иткән, милли фәнгә хезмәт куйган язучы һәм галимнәрнең социаль статусы, икътисади хәле Рәсәйнең төп халкыныкыннан күпкә аермалы дип уйларга кирәк. Бу күренешләр җәмгыятьнең рухи тормышына, әдәбият, аны яктырткан фәннәр үсешенә һәм аларның эчтәлегенә дә тәэсир итә.

Рәсми игълан ителгән генә түгел, ә чын мәгънәсендәге демократия шартларында галим һәм язучылар ия булган дәрәҗә эшчәнлекләренең чагыштырмача иреклелеген һәм әдәбиятның, аны чагылдырган гуманитар фәннәрнең күпмедер объективлыгын тәэмин итешә, әмма бер генә җәмгыятьтә дә иҗатның тулы бәйсезлеге була алмый. Хәтта теоретик язмалар да хакимлек иткән идеологиягә, теге яки бу социаль катламнарга, әдәбиятчы караган тар төркемнәргә, ягъни кайсының да булса мәнфәгатьләрен, бурыч-максатларын тормышка ашыруга теге яки бу күләмдә хезмәт итә.

Тәнкыйтьтә авторның һөнәре, эш урыны, белеме, гаилә хәле, килеп чыгышы, җенесе белән билгеләнгән социаль дәрәҗәсе шулай ук чагылмый калмый. Әлеге статусның гыйльми хезмәт белән шөгыльләнүчеләрнең матурлык һәм ямьсезлек, түбәнлек һәм югарылык, көлке һәм фаҗига кебек эстетик категорияләр, әдәби нормалар, традицияләр һәм новаторлык, сәнгатьлелек үлчәмнәре, талант дәрәҗәсе, әдәбиятның миллилеге, күтәргән проблемаларының актуальлеге турында карашларын билгеләүдә роле, һичшиксез, зур.

Фән аша җәмгыятькә социаль, сыйнфый мәнфәгатьләрне яисә алардан өстен торган, гомумкешелек идеалларын яктырткан карашлар аңлы да, аңсыз рәвештә дә, ачыктан-ачык та, яшерен дә, өстән-өстән дә, тирәнннән уйланылып та уздырылырга мөмкин. Әдәби-фәнни мәдәният материаль элементлардан башка була алмый. Уку заллары, китапханәләр, матбугат, төрле чаралар уздыру өчен биналар һәм башкалар аны тудыруда турыдан-туры катнаша. Әлеге мәдәнияттә рухи катлам да бар. Аның төп өлешен, әлбәттә, сәнгати-эстетик аң тәшкил итә. Шактый гына мөстәкыйль һәм үзенчәлекле фәнне мәдәни кыйммәт итеп карау шулай ук аны җәмгыять белән бәйләү мөмкинлеге бирә.

Нәфис әсәрне яктырткан тәнкыйтьнең иҗтимагый күренеш булуы матур әдәбият башкарган функцияләргә турыдан-туры бәйле. Без боларга иҗтимагый (җәмгыятьнең йөзен, социаль төркемнәре арасындагы мөнәсәбәтләрне яктырту...), тәрбияви (билгеле бер әхлак нормаларын уздыру), эстетик (эстетик зәвык, матурлык тойгысы тәрбияләү…) бурычларны кертәбез. Әдәби тәнкыйть асылда һәр әдәби берәмлекнең әлеге вазифаларны ничек үтәве турында фикер йөртә.

Матур әдәбият иҗтимагый күренеш икән, аны ачып биргән фән дә иҗтимагый күренеш саналырга хаклы. Сәнгать әсәрләре кешедә яшәү идеалы тудыруны максат итә, ул идеал исә – җәмгыятьнең һәр баскычында төрле. Әдәби әсәрдән әлеге идеалны табып, гомумиләштереп, китап укучыга әйтеп биргән әдәби тәнкыйть бервакытта да җәмгыятьтә хөкем сөргән карашлардан азат була алмый. Ул публиканың психологик, идеологик, этик, эстетик аңына тәэсир ясый, шул ук вакытта үзе дә аңа бәйле кала.

Халык әдәбиятны һәм аны бәяләгән тәнкыйтьне илнең, милләтләрнең алга таба үсешенә, бигрәк тә мәдәниятенә хезмәт итәргә тиеш дип саный, аның язганнарын шул ноктадан бәяли. Хакимият фәнни-әдәби эшчәнлек өчен төрле дәрәҗәдәге бүләкләр булдыра һәм аларны дәгъвалаучыларга билгеле бер таләпләр куя.

Әдәби әсәр – тәрбия чарасы гына түгел, идеологик көрәш коралы да. Моны аңлаган хаким сыйныф аны һәрвакыт үз кулында тотарга тырыша. Кайбер бүгенге сәясәтчеләр, тарихчылар, философлар тарафыннан Рәсәйдә монархия вакытында ук фикер иреге иде, соңгы тамырдан үзгәртеп кору елларында ул тәмам демократик илгә әйләнде, анда һәртөрле карашларга урын бар, дип югары пафослы белдерүләр ясалса да, әдип, бигрәк тә аның милли телдә

язучысы, аз санлы халыкларның фидакарь каләм ияләре яшерен цензураны тоеп иҗат итә, теге яки бу фикерләре китап турында башында идея туудан ук интуитив рәвештә редакцияләнә башлый.

Иң элек язучы үзен эчке курку белән фикердә чикли, аннан башкарган караламасын төзәтергә, үзгәртергә тотына. Бераздан инде тәмам хәзер кебек китапның да акка күчермәләрен вакытлы матбугат редакторлары аркылыга-буйлыга сүтә. Соңрак әлеге китапка «эчке рецензия» язылырга һәм ул бәяләүче тарафыннан кире кагылырга да мөмкин. Әгәр рецензияче, яшәп килгән идеологиягә каршы фикерләр тапмаса, дәүләт серләрен ачкан юллар күрмәсә, эчтәлеге өчен җитәкчелектән куркып калмаса һәм, бу кулъязманы бастырырга ярый, дигән мөһер сукса, аны матбугат хезмәткәре чын-чынлап эшкәртә башлый.

Дөрес, хәзергә шәхси нәшриятларда чыгучы китапларның эчтәлеге – чагыштырмача автор ирегендә, чөнки әлеге оешмалар хезмәтеннән файдаланучылар – күбесенчә акчалы кешеләр, басмаханәләрнең алга таба яшәү-яшәмәве алардан да тора. Ә инде химаягә яисә химаячеләр теләге буенча китап чыгаручылар шулай ук еш кына үзләренә матди ярдәм сузучыларга бәйлелеккә төшә: алар теләгәнне, алар теләгәнчә яза. Димәк, җәмгыятьтә, аның законнарына буйсынып яшәгән каләм иясенең, шул исәптән тәнкыйтьченең дә, тулы бәйсезлеге турында сүз дә була алмый.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, әдипне һәм галимне байлар колы, хаким сыйныфларның боерыгын үтәүче генә икән дип санарга ярамый, ул барыбер дә халыкның иң алдынгы өлешен билгели, каләм ияләренең иң асыллары, үз милләте мәнфәгатьләрен кайгыртып, зинданнарга бара, көрәшкә күтәрелә. Иҗтимагый хәлләрдән канәгать булмаган шәхесләр аңлы рәвештә әдәбиятны идарәгә якынайтылмаган, үзе гадел дип санаган социаль төркемнәр кулындагы корал итә. Шулай булгач, хакимият, партияләр генә түгел, тәнкыйтьче дә, нәфис әсәр аша чагылдырылган иҗтимагый карашларны ачып күрсәтеп, әдипкә төрле күрсәтмәләр биреп, тәнкыйтьне идеологик факторга әйләндерә.

Әдәби тәнкыйтьнең сәяси көрәштә корал икәнлеге үз тарихи фактларыбыз, әйтик, СССРдагы бик күп чараларның резолюцияләре белән дәлилләнә. Аеруча КПСС съездларында, аның Үзәк Комитеты пленумнарында тәнкыйтькә кагылышлы мәсьәләләр көн кадагына куеп тикшерелде. Аларда чыгарылган типик карарларның берсен үрнәккә китереп узыйк: «Тәнкыйтьнең бурычы – заман

сәнгати барышының күренешләрен, тенденцияләрен һәм закончалыкларын тирән анализлау, партиянең ленинчыл принципларын һәм халыкчанлыкны ныгытуга һәрьяклы ярдәм итү, совет сәнгатенең югары идея-эстетик биеклеге өчен көрәшү, буржуаз идеологиягә каршы эзлекле чыгыш ясау. Әдәби-сәнгати тәнкыйть рәссамның идея күзаллаулары киңәюгә һәм осталыгы камилләшүгә булышлык итәргә бурычлы. Марксистик-ленинчыл эстетика традицияләрен үстергәндә, совет әдәби-сәнгати тәнкыйте төгәл идея бәяләмәләрен, социаль анализ тирәнлеген эстетик таләпчәнлек, талантка, нәтиҗәле иҗади эзләнүләргә сакчыл караш белән бәйләп алып барырга тиеш»[1].

Тәнкыйть әдәбиятка заманча һәм алдынгы карашларның үтеп керүенә булышырга яисә мәңгелек эстетик кыйммәтләр турында гына сүз йөртергә дә мөмкин. Бу тәнкыйтьченең дөньяны күзаллауларына, иҗтимагый-тарихи барышны аңлавына, шул барышта каләм иясенә нинди роль йөкләвенә, әдәбиятның кайсы функцияләренә өстенлек бирүенә һәм башка сәбәпләргә бәйле.

Тәнкыйтьне идеологик корал итүне тискәре бер күренеш сыйфатында гына санарга ярамый, асыл әдәбият гасырлар аша исән-имин чыккан гуманистик идеяләр сагында торган кебек, аны өйрәнүче фән дә кешелекле кыйммәтләрне якларга, аларны нәфис иҗатның умыртка баганасы итәргә омтыла. Тәнкыйть әсәрнең фикри эчтәлегеннән читләшсә, аны матурлык хисе тәрбияләүче сәнгать дип кенә караса, үзенең яшәү потенциалын югалта. Әдәбиятның эстетик функциясенә өстенлек бирүчеләргә каршы төшеп, без, ахыр чиктә шул ук матурлык төшенчәсенең мәгънә чикләрен киңәйтә – төрле халыклар, илләр, социаль төркемнәр, җәмгыять әгъзаларының үзара мөнәсәбәтләрендәге матурлыкны да аның эченә кертә алабыз. Тәнкыйди характердагы хезмәтләр язганда, әдәбият функцияләренең үзара тыгыз керешкәнлеген истә тотарга кирәк.

Тәнкыйтьче, әсәрне анализлаганда, аның ни дәрәҗәдә тормыш чынбарлыгын дөреслеккә туры китереп чагылдыруы турындагы сорауга җавап эзли, моны шулай ук җәмгыятьнең иҗтимагый аңыннан бәйсез башкару мөмкин түгел.

---

[1] О литературно-художественной критике: Постановление ЦК КПСС от 21 января 1972 года // КПСС в резолюциях и решениях съездов, конференций и пленумов ЦК. М., 1978. Т.11. С. 31.

## 1.3. Әдәби тәнкыйтьнең фәнни нигезе

Кеше эшчәнлегендәге кайсыдыр юнәлешнең фәнме, юкмы икәнлеген күрсәтү өчен, иң элек фән төшенчәсенең үзенә билгеләмә бирик: «Фән – күпаспектлы, киңкырлы һәм катлаулы төзелгән феномен: ул соц. институт та, гыйлем җитештерүче билгеле бер эшчәнлек тә, әлеге специфик эшчәнлеккә тормышка ашарга рөхсәт итүче традиция дә булып күзаллана.

...Гыйльми эшчәнлек һәм гыйльми традицияләр үсеше процессында яңа белем тупланып һәм дөньяны күзаллауларның элеграк барлыкка килгәннәре үзгәреп кенә калмый, фәннең бөтен компонентлары да – ул өйрәнгән объектлар, тикшерүнең чара һәм методлары, фәнни коммуникация үзенчәлекләре, гыйльми хезмәтнең бүленеш һәм кооперация формалары һәм башкалар да – үзгәреш кичерә»[1].

Югарыдагы билгеләмәдән гыйльми өлкәләрнең, юнәлешләрнең артуы, объектларның дифференциацияләнүе фәннең үз табигатеннән – ачык система булуыннан килгәнлек аңлашыла.

Фәннәр, бигрәк тә гуманитар тармаклар турында сүз йөрткәндә, аның объекты, субъекты, танып белү чараларының үзара бәйлелеген күз уңыннан ычкындырмыйлар. Предметы әдәбият булган тәнкыйтьнең максаты – әдәби күренешкә үз вакытында бәя бирү, сәнгати әсәр исә – шул күренешләрнең төп берәмлеге. Әдәбият тарихы матур әдәбиятны хронологик тәртиптә тикшерә. Димәк, тәнкыйть әдәбият тарихыннан алдарак баручы фән булып чыга, аның нәтиҗәләренә башка бик күп гыйлемнәр, шул исәптән җәмгыять тарихы, социология, философия, психология, культурология дә таяна, әмма соңгылары әдәбиятны башкачарак планда өйрәнә.

Тәнкыйтьне фән буларак тирән ачкан махсус теоретик хезмәтләрнең татарчасы юклыктан, уку әсбабыбызда, традиция буенча, рус телендәге сүзлекләргә, дәреслекләргә еш мөрәҗәгать итәрбез. И.А. Елисеев, Л.Г. Поляковалар төзегән белешмәдә тәнкыйть төшенчәсенә шушындый билгеләмә бирелә: «Әдәби тәнкыйть – әдәби иҗат төре, әдәби әсәрләргә, анда чагылган тормыш күренешләренә заман күзлегеннән бәяләмә. Тәнкыйть – сүтү, хөкем йөртү сәнгате. Ә. т. хәзерге әдәби барыштагы хәлләрне яктырта, агымдагы журнал һәм китап продукциясен күзәтә. Ә. т.-нең, образлары,

---

[1] Волков Ю. Г., Поликарпов В. С. Человек: энциклопедический словарь. С. 179.

идеяләре, язучыларның иҗат максатлары буенча якын яисә капма-каршы әсәрләрне янәшә куеп, төрле жанрдагы әсәрләрне, яки төрле сәнгатьләрне, я булмаса төрле тарихи чорларны үзара чагыштырып, тәгаен бер әсәр чикләреннән чыгу, шуның белән анда турыдан-туры яктыртылмаган сорауларны да иңләү, үз заманының идея тормышында актив позиция алу мөмкинлеге бар»[1].

Бу билгеләмәдә әдәби тәнкыйть иҗтимагый күренеш һәм иҗат төре сыйфатында ачылса да, аның мөстәкыйль фән яисә бер өлкәнең үзенчәлекле тармагы булуы күренми. Гыйльми күзлектән бәяләмә аңа «әдәбият белеме» төшенчәсе эчендә бирелә. Терминны шулай яктырту традиция буларак килә. Мәсәлән, махсус энциклопедияләрдә әлеге төшенчә әдәбият белеме категорияләре эчендә карала, әдәби тәнкыйтьнең фәннәр тарихында урыны төгәл билгеләнә. Ул, бер яктан, әдәбиятны, аның асылын, килеп чыгышын өйрәнүче мөстәкыйль фән дип атала һәм әдәбият белеменең тармагы дип күрсәтелә, икенче яктан, аның әсәрләргә, анда чагылган тормыш күренешләренә бәя бирүче иҗат төре икәнлеге һәм тәнкыйтьне фән буларак тануның гомумкүренеш түгеллеге әйтелә[2].

Әдәбият энциклопедиясендә дә тәнкыйтьнең иҗат һәм әдәбият турындагы фәннәр ызанында торучы, әдәби барышка актив тәэсир итүче өлкә икәнлеге язылган[3]. Димәк, аны тарихка һәм теориягә таянган әдәби анализ принципларын яктырткан фән буларак та, әлеге принциплар нигезендә башкарылган һәм сәнгатилек белән аерылып торган иҗат сыйфатында да карарга мөмкин. Бу урында әдәби тәнкыйтькә нисбәтле саф теоретик хезмәтләр барлыгын аның фәнни өлкә дә икәнлегенә дәлил рәвешендә билгеләп узарга кирәк.

Кайбер белешмәлекләрдә галимнәр гомумкабул ителгән билгеләмәләрне кабатлау белән генә канәгатьләнмиләр, инде алтмышынчы елларда ук үзенчәлеклерәк аңлатмалар да очрый: «Әдәби тәнкыйть – нәфис-сүз текстларын сүз сәнгатен һәм тормышның күптөсле чынбарлыгын бәйләүче мәнфәгатьләр, дулкынланулар, кызыгулар, шикләнүләр белән бер җепкә тезелгән хирыслы интуитив-интеллектуаль уку»[4].

---

[1] Елисеев А.И., Полякова Л.Г. Словарь литературоведческих терминов. Ростов н./ Д.: Феникс, 2002. С.92.

[2] БСЭ. 3-е изд. М.: Сов. энцикл., 1973. Т. 14. С. 1550.

[3] ЛЭ. М.: Сов. энцикл., 1981. С. 169.

[4] Григорьев А. Литературная критика. М.: Худ. лит., 1967. С. 114.

Тәнкыйтьне мөстәкыйль фән дип карау-карамау мәсьәләсе әле дә бәхәсләр уята. Дөрес, мөстәкыйль фән дип санамаучылар да, бары тик әдәби публицистика дип исәпләүчеләр дә, әдәбият белеменең бер тармагы рәвешендә караучылар да аның әдәбиятны фәнни һәм теоретик нигездә үстерүче хезмәт яисә гыйльми-идеологик эшчәнлек булуын билгелиләр, димәк, асылда шулай ук фәннилеген таныйлар. Әлеге гамәлләр тәнкыйтьнең максат-бурычларына җавап бирә дә. Кайберәүләр аның аеруча «кыйммәти-юнәлгәнлекле» эшчәнлек икәнлеген ассызыклый.

Безнеңчә, әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнүнең технологиясен, предметын, максат-бурычларын, асыл сыйфатларын, фәнни-методик нигезләрен формалаштырып, үсеш тарихын чагылдырып була икән, мөстәкыйль фән дип карау бәхәс уятырга тиеш түгел. Бу рәвешчә хөкем йөртү әдәби тәнкыйтьнең киңмәйданлы һәм киңпланлы әдәбият белеменең аерым тармагы сыйфатында яшәвенә каршы төшми. Ахыр чиктә кайсыдыр фәннең төрле өлкәләргә хезмәт итә алуы әлеге өлкәләрнең үзләренең дә ызандаш булуыннан яисә синкретик характерыннан килә.

Бу уңайдан шуны да өстәргә кирәк: киләчәктә безгә бүген билгеле булган һәр фәннең күп кенә тармаклары барлыкка киләчәк, һәм алар мөстәкыйль рәвештә дә яши алачаклар, яшәп китәчәкләр дә. Инде хәзер үк әлеге барыш ачыктан-ачык күзәтелә. Мәсәлән, фәлсәфә фәненнән, үз тикшеренү предметын ачык билгеләп, культурология, ягъни мәдәният белеме аерылып чыкты. Шул ук философия һәм социология эчендә барлыкка килгән яралгылардан конфликтология формалашты, аның аерым төшенчәләре, күренешләре, әлеге күренешләрне классификацияләү алымнары әдәбият гыйлемен дә үстереп, тирәнәйтеп җибәрде.

Әдәбият белеме эчендә әкренләп калыплашкан әдәбият теориясе, текстология яисә төрле фәннәрдән үзенә төшенчә, эш алымнары алган иҗат лабораториясе һәм башкалар яңа фәннәр мөстәкыйльләшүнең даимилегенә ачык мисал булып тора.

Тәнкыйтьтә фәннилек һәм әдәбилек турында бәхәсләшү дә урынлы. Теге яисә бу язмада алар төрле дәрәҗәдә чагыла. Тәнкыйтькә хас әлеге сыйфатлар аның белән шөгыльләнүченең эш алымнарына, иҗадилык һәм фәннилек потенциалына, һөнәренә һәм тагын бик күп сәбәпләргә бәйле. Гомумән алганда, әдәби тәнкыйтьнең төп мөһим формаларында фәннилек, төгәллек өстенлек итәргә тиеш.

Художестволылык ул хәтта әдәбият тарихында да зур урын алып тора, әмма фәнни җирлекне басып китми.

Укучылар көндәлек матбугат аша галимнәр язган һәм сәнгатилек ягыннан артык тартып тормаган тәнкыйть мәкаләләре белән һәрвакыт очраша, әмма бигрәк тә язучылар каләменнән төшкән лирик-публицистик характердагы язмалар алай да күбрәк. Бу татарларда фән белән турыдан-туры шөгыльләнүчеләрнең азлыгыннан килә. Кызганыч ки, әлегә, субъектка бәйле рәвештә, аерым бер жанр формаларына ныграк өстенлек бирелә, тәнкыйтьнең барлык мөмкинлекләре дә эшкә җигелми.

Әдәби тәнкыйть дигән гыйбарәнең тууы – тәнкыйть хезмәтләрендә әдәбилекне тану дигән сүз. Шул ук вакытта болай язу традиция буларак килә, югыйсә, электән гадәткә әверелсә, әдәби-фәнни тәнкыйть терминын да куллана алыр идек. Материалда кайсы сыйфатларның өстенлек алуына бәйле һәм шартлы рәвештә, кирәк очракларда әдәби яисә фәнни тәнкыйтьне аерып чыгарырга мөмкин, әлбәттә; тик шунысын онытмыйк: кулланылыштагы әдәби тәнкыйть гыйбарәсендә *әдәбиятка кагылышлы* мәгънәсе алда тора. Моны, әдәби тәнкыйть әлеге өлкәне аңлатучы төп төшенчәгә әверелгәнче, еш очраган гыйбарәләр ярдәмендә исбатлап була. Электә, мәсәлән, әдәби әсәрне, барышны бәяләүче, ачучы хезмәтләрне ачыклау өчен, «*әдәбиятка гаид*» (кагылышлы) сүзтезмәсеннән актив файдаланганнар. Әдәбият белемендәге тәнкыйть термины хурлауны, җитешсезлекләрен табуны аңлатмыйча, фәнни нигезлелекне күздә тотканлыктан, аның алдына әдәби сыйфатламасын өстәү язылган хезмәтләрнең ике яклы асылын төгәлрәк аңларга ярдәм итә сыман.

В. Гюгоның һәм башка бөек шәхесләрнең, фән ул – без, сәнгать ул – мин, дип әйтүеннән чыксаң, чын мәгънәсендәге әдәби тәнкыйть шулай да фәнгә якынрак торадыр кебек, чөнки ул иҗтимагый фикерне, заман хөкемен алга куеп эш йөртә, бик күпләр уйлап тапкан фәнни принципларга таяна, алардан башка яши алмый. Әдәбият исә бернинди теоретик белеме булмаган кеше тарафыннан да, эстетик тоем, табигый талант ярдәмендә иҗат ителә ала; каләм иясе, заманга бик нык бәйлелегенә карамастан, шәхси карашларын беренче планга куя, кайвакыт әлеге карашлар хакимлек иткән идеологияне чагылдырмый, хәтта аңа каршы да килә. Әдипнең язганнары аша гаять тә үзенчәлекле фикерләр уздыруы киләчәк чорларның авазы я шәхеснең үз заманында хөкем сөргән идеалларга, җәмгыятьнең яшәү нор-

маларына протесты булып тора, шунлыктан ул үзе дә, каләменнән төшкән әсәрләре дә илдәге иҗтимагый процессларның катализаторына әверелә.

Әдәби тәнкыйтьне билгеле бер белемнәр системасы дип күзаллаганда, аны аерым фән сыйфатында тануга якын торабыз. Тәнкыйтьне мөстәкыйль гыйльми өлкә дип бәяләү, шуның сыйфатында чагылдыру ихтыяҗы җитмешенче-сиксәненче еллардан аеруча көчәя. «Основы литературной критики» (Пособие по факультативному курсу для студентов филологического факультета / коллектив авторов. Ростов-на-Дону: Изд-ство ГПИ, 1975), «Вопросы истории литературной критики» (Сборник статей / редкол.: М.М. Владимиров, А.С. Дмитриев, И.К. Киреева и др. Тюмень: Изд-ство ТГУ, 1977), «Литературно-художественная критика» (Баранов В.И., Бочаров А.Г., Суровцев Ю.И. М.: Высшая школа, 1982. 206 с.), «Проблемы развития литературной критики» (Сборник статей / ред.: В.В. Ефимов, Б.Л. Милявский. Душанбе, Изд-ство ТГУ. 1984) кебек күпсанлы китапларның язылуы, әдәби тәнкыйть нигезләренең һәм әдәби тәнкыйть тарихының югары уку йортларында укытылуы әнә шул хакта сөйли.

Һәр яңа унъеллык тәнкыйть фәненә нисбәтле китаплар санын арттыра тора. Яңа гасырга кергәндә, әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эзләнүләр тагын җанланып китте, шул юнәлештә кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре дә якланды. Араларыннан, кызыклы эшләрнең берсе итеп, В.А. Найданованың әдәби тәнкыйть жанрларын классификацияләү проблемасына да күз ташлаган хезмәтен атап узарга[1]. Шул ук вакытта әдәби тәнкыйть фәне, аның теориясе тулы бер система буларак эшләнеп бетмәгән әле.

Моңа кадәр басылган әдәби тәнкыйтькә кагылышлы дәреслекләр күпчелек очракта аның тарихын чагылдыра, ә әдәби тәнкыйтьнең үзен теге яки бу яссылыкта махсус бүлекләрдә генә ача – ул фән буларак тасвирлана, аның тикшерү объектлары, жанрлары, принциплары билгеләнә. Кайвакыт авторлар дәреслек максатын әдәби тәнкыйть тарихын язу дип күрсәтә, әмма тәнкыйть теориясенең андый төр хезмәттә читләп узарга да мөмкин проблемаларына да туктала. Әдәби тәнкыйть һәм аның тарихын бергә өйрәтүне күздә тотып язылган хезмәтләргә мисал итеп, Казан

[1] Найданова В.А. Становление и развитие жанров в литературной критике Бурятии XX века. Улан-Удэ, 2014. 174 с.

галиме В.Н. Крыловның «Теория и история литературной критики» (2011) китабын китерергә мөмкин.

Кыскасы, «Әдәби тәнкыйть тарихы», «Әдәби тәнкыйть нигезләре» кебек өлкәләрнең бер-берсенә нык керешүе, барлык галимнәр күзаллавында да мөстәкыйльләшеп җитмәве күренә. Югары уку йортларында махсус белгечлекләр арта барган заманда әдәбият белеменә, аның бер тармагы булган тәнкыйтькә мөнәсәбәтле хезмәтләрне бергә туплау, анализлау, заман күзлегеннән бәяләү, системалаштыру ихтыяҗы көчлелеген дә билгеләп узарга кирәк.

Әдәби тәнкыйтьне фән буларак эшләү аның предметын ачык күзаллауга ярдәм итеп кенә калмаячак, әдәбият белеменә яисә журналистикага нисбәтле аерым тармакларның дифференциацияләнү күренешен дә көчәйтәчәк, бик күп предметларның өйрәнү объектын саналган әдәби һәм мәдәни күренешләрне аңлаудан килгән берлекне дә ныгытачак. Әдәби тәнкыйтьне фән сыйфатында формалаштыру, өйрәнү әдәби берәмлек булган сәнгать әсәрләрен үз вакытында системалы, комплекслы анализлау мөмкинлекләрен үстерәчәк; гыйльми өлкәгә яңа аяк баскан яшь белгечне сайлаган юнәлешенең асылына төшендерәчәк; аңа әдәбият белеме, әдәбият теориясе фәне эчендә махсус өйрәтелми торган бик күп нәрсәләрне – беренче чиратта, тәнкыйтьнең жанр формаларын – үзләштерергә ярдәм итәчәк.

Әле 1976 елда М.Г. Зельдович әдәби тәнкыйтькә бәйле теоретик-методологик проблемалар күтәргән монографиясендә түбәндәге сүзләрне язган: «Кайчандыр Карлейль „тәгаенлеккә сусын“-ны сәнгатьнең мәңгелек нигезе дип атаган. Әмма, бу төшенчәнең эмпирик түгел, нәкъ менә фәлсәфи мәгънәсендәге тәгаенлеккә ия булуның һәрчак төрле юлларын һәм чараларын табып, аңа фән дә үзенчә бик нык омтыла. Әдәбият белеменең хәзерге биеклеге, башка үзенчәлекләре белән беррәттән, тикшерүнең специфик предметын һәм специфик методын куәтләндерелгән эзләү белән игътибарга лаеклы. Спецификлыкның тәгаенлеге, тәгаенлекнең үзенең дә тарихи һәм методологик үзенчәлекле һәм үзгәрүчән икәнлеген раслап, катгый рәвештә кануни хокукларын яулый.

Әдәби тәнкыйтьнең тарихы һәм теориясе, гомумән әйткәндә, чыгарма булып тормый»[1].

---

[1] Зельдович М. Г. Уроки критической классики. Вопросы теории и методологии критики. Очерки. Х.: Вища школа, 1976. С. 3.

Формаль караганда, әдәби тәнкыйть иҗатка заманча якын килә, ә әдәбият тарихы аны тарихи ракурста өйрәнә кебек, асылда исә *тарихилык* һәм *заманчалык* принциплары ике фәнгә дә хас.

## 1.4. Әдәби тәнкыйтьнең публицистик нигезе

Әдәби тәнкыйтьнең киң публикага адреслануы, сәнгать әсәрләрен яратучыларны яисә аның белән шөгыльләнүчеләрне, гуманитар эчтәлекле һөнәр ияләрен күздә тотып иҗат ителүе аның публицистик нигезләрен билгели, теленә, язылу рәвешенә тәэсир итә, жанрларын формалаштыруда бер сәбәп булып тора. Тәнкыйди хезмәтләр белән танышкан укучы язучы һәм тәнкыйтьче арасында барган диалогның ихтыярый тыңлаучысы, сүз көрәштерүләренең казые сыйфатындарак яши, ул хәтта әңгәмәгә, кызыклы барган бәхәсләргә кушылып та китәргә мөмкин.

Әдәби тәнкыйть берьюлы каләм иясен дә, ул җитештергән продукция ярдәмендә эстетик ләззәт алган, билгеле бер яшәү нормаларын ныгыткан яисә кире каккан, иҗтимагый тормыш турында карашларын киңәйткән публиканы да тәрбияли. Бердән, күзаллауларына, зәвыгына төзәтмәләр кертә, анда югары сәнгать таләпләренә туры килгән әдәби әсәрләрне сайлау ориентирларын булдыра; икенчедән, иҗади хезмәтнең күпләр күрмәгән асыл якларын таба, укучы шикләнгән мәсьәләләргә ачыклык кертә, аңлап бетермәгән нәрсәләрне ныклап төшендерә; өченчедән, публиканы заманга хас фәнни фикерләр белән коралландыра.

Әгәр тәнкыйть булмаса, мәктәпне, югары уку йортын тәмамлаганнан соң филологик юнәлештә мөстәкыйль формада үз белемен күтәрмәгән укучы элек үзләштергән белемнәрен дә өлешчә онытыр һәм яңалары белән коралланмас иде. Әдәби тәнкыйтькә дә үзендә урын биргән вакытлы матбугат массаларны үзара якынайтуда, күренешләрне аңлы кабул итүне бер биеклектә тотуда искиткеч зур роль уйный.

Вакытлы матбугат әдәбиятка, тәнкыйтькә оперативлык мөмкинлеге тудыра, аларны бастырып, үз абруен арттыра, укучылар аудиториясен киңәйтә, сәнгать өлкәләренең үзара якынаюына булыша. Әдәби тәнкыйтьнең, беренче чиратта, нәкъ менә вакытлы матбугат аша дөнья күрүе аның формаларына, эчтәлегенә тәэсир ясый, публицистик нигезен ныгыта. Без еш кына газета-журнал битләрендә укылган мәкаләнең фәнни хезмәтләрдә үзгәртелгәнлеген күрәбез: аның әдәбилеге кимегән, фәннилеге көчәйгән, болар

турыдан-туры гомуми стильдә, интонациядә, аһәң һәм яңгыраашта чагылыш таба. Еллар узгач, әдәби тәнкыйть буенча тупланмаларга урнаштырылган хезмәтләр бигрәк тә үзгәрә. Шул вакытта ул сыналу уза, тулыландырыла, фикере тирәнәйтелә, һәм еш кына зур фәнни хезмәткә әйләнә. Мәсәлән, Ф. Мусин, Ф. Миңнуллин, Ф. Галимуллин, Р. Мостафин, А. Әхмәдуллин, Ә. Закирҗанов кебек тәнкыйтьчеләрнең язмалары турында шуны әйтергә мөмкин.

Тәнкыйди хезмәтләрдә бирелгән анализ тирәнлеген автор һәм адресат билгеле икән, без аның белән шөгыльләнүчеләрне дә, вакытлы матбугатны алдыручыларның кемлеген дә ачыкларга тиешбез. Әйтик, әдәби тәнкыйть әдәбиятчылар һәм журналистлар тарафыннан махсус өйрәнелә һәм ике белгечлекне, фәнне бәйләп торучы дисциплина булып тора. Аның белән укытучылар һәм җитәрлек белеме, әдәби күренешләргә тоемы булган, кызыксынуы көчле гади укучы да шөгыльләнә. Аларның барысыннан да фикер сөрешендәге эзлеклелек, объективлык таләп ителсә дә, фәнни белемгә ия авторларның язмалары вакытлы матбугатта чыгыш ясаучы башкаларга үрнәк булырга тиеш.

Әдәбиятка кагылышлы хезмәтләр татар вакытлы матбугатында үзәк материаллар сыйфатында урын ала. Күпчелек органнар үзләрен иҗтимагый-нәфис журнал яисә газета дип игълан итәләр яисә асыллары белән әлеге билгеләмәгә җавап бирәләр һәм шул сәбәпле эчтәлектә бер-берсен шактый гына кабатлыйлар да. Әдәби тәнкыйтьнең актуаль яңгырашлылыгы бүгеге көндә милли рухына, иҗтимагый тормыш белән тыгыз бәйләнешенә барып тоташа.

Хөкүмәт сәясәтен ачыктан-ачык һәм үткен бәяләргә курыккан публицист, әдәбиятны анализлаганда, төрле алымнардан файдаланып, тормыш-яшәешкә бәйле үз карашларын да уздыра ала. Ул, язучының кайбер кыю фикерләрен калкытып, әдәби әсәрләрне милли хәрәкәт катализаторы, халыкның аңын уятучы бер чара буларак кулланырга мөмкин. «Казан утлары» 2004–2005 елларда уздырган «Безнең заман герое» дип аталган һәм тәнкыйть мәкаләләреннән торган дискуссия моның шулай икәнлеген исбатлады. Бәхәс барышында дөнья күргән барлык мәкаләләрнең, һәм инде Рафикъ Шәрәфиев, Айдар Хәлимнәр тарафыннан язылганнарының бигрәк тә, умыртка баганасы булып, милләтне сайлау идеясе тора иде.

Әдәби тәнкыйтьнең генә түгел, әдәбият гыйлеменең барлык тармакларының бүгенге концепциясе әлеге бурычны чагылдыра. Бу

уңайдан Флүн Мусин «Казан утлары» журналында махсус мәкалә дә бастырды. Күренекле галим анда түбәндәге фикерләрне яза:

«“XX йөз татар әдәбияты” дип аталган феноменаль әдәби процессны чын булганынча белергә теләгәндә, иң әүвәл процессны фәнни яңартып өйрәнү концепциясен эшләргә кирәк.

...Бу дәвердә татар дөньясында әдәбиятка йөкләнгән вазифа гаять зур. Эш шунда: XIX гасыр урталарыннан татарлар арасында күзәтелә башлаган милли үзаң уяну һәм үсү хәрәкәте халык тормышында иҗтимагый-рухи яңарыш башлануга китерә. Ә әдәбият шушы процессны әйдәп баручы көчкә әверелә.

...Күпгасырлык әдәби тарихыбызда гына түгел, гомумән, бөтен хәятыбызда үзгә бер урын тоткан XX йөз татар әдәбиятын яңартып өйрәнүнең асыл максаты – интеграция процесслары бермә-бер көчәйгән бер дәвердә әдәбиятыбызның милләт яшәешен һәм язмышын чагылдыру белән бәйләнгән үз йөзен һәм үз юлын тулырак та, тирәнрәк тә ачуга кайтып кала. Шул нигездә узган гасыр әдәбиятыбызның төрле иҗтимагый-сәяси шартларда да үзенең бөтенлеген саклап кала алуы ачыкланачак. Монысы исә әдәбиятны татар дөньясының бердәмлеге өчен хәзерге көрәштә җитди коралга әвереләдерә»[1].

Димәк ки, әдәби тәнкыйтьнең иҗтимагый бурычы әдәбият үз алдына куйган максатлар белән билгеләнә, сәяси катаклизмнар чорында аның шул төр функциясе тагын да үстерелә. Бу исә, үз чиратында, фәнни-әдәби хезмәтләрнең публицистик аһәңнәрне мулданрак алуына, киң публикага юнәлтелгән булуына китерә.

Татар укучысында милли юнәлгәнлекле тәнкыйтькә ихтыяҗ зур. Аның алдынгы катламы әдәби тәнкыйтьнең максатчан рәвештә халыкта миллилекнең һәр ягына уңай мөнәсәбәттәге әдәбиятка зәвык тәрбияләвенә, шулар аша аның эстетик һәм милли аңының үсүенә өметләнә. Алай гына да түгел, рухи бозыклык чәчәк аткан, аңа каршы торучы чараларның көчен югалта барган чорда әдәбият саф әхлак сагында торучы утлы, үткен һәм үтемле, тәэсирле сүз булып кала.

Әдәби тәнкыйть эчендә милли-иҗтимагый мәсьәләләр күтәрүнең озын тарихы бар. Дидро, Лессинг, Толстой, Белинский һәм башкалар кечкенә рецензияләр язу белән генә канәгатьләнмәгәннәр,

---

[1] Мусин Ф. Әдәбият тарихын яңача өйрәнү // Казан утлары. 2005. 7 сан. Б. 147, 157.

нигездә, проблемалы очерклар, күләмле аналитик мәкаләләр бастырганнар; әдәбият үсеше милли барыштан, халык яшәешеннән бервакытта да аерып каралмаган. Фәннәр бик нык үсеп киткән, үзара аерымлана барган чорда гына бары тик әдәбиятның, нинди дә булса каләм иясенең үсешен күздә тоткан, аны иҗтимагый җирлектән аерып алган саф фәнни мәкаләләр иҗат ителә башлый.

Узган чордан әдәби тәнкыйть мәкаләләрен, китапларын, теоретик хезмәтләрне барласак, без аларның атамаларының ук иҗтимагый-сәяси яңгырашлылыгын күрербез: «Литература и революция» (Л. Троцкий, 1923)[1]; «Октябрьская революция и творческие принципы социалистической литературы» (М. Храпченко), «О партийности критики» (Ю. Кузьменко), «Народное и национальное» (Г. Ломидзе)[2]; «Советская литература в борьбе за коммунизм» (Г. Марков)[3] һәм һ.б. Инкыйлабтан соң дөнья күргән кайбер әдәби тәнкыйди басмалар да шул хакта сөйли: «Литература и марксизм» (1928—1931), «Книга и пролетарская революция» (1932—1940).

Тәнкыйтьнең, әдәбиятның, аңлы яисә аңсыз рәвештә, теге яки бу төркемнәргә, партиягә, иҗтимагый-сәяси системаларга, идеологиягә хезмәт итүе бәхәссез. Шуны аңлаган коммунистлар, башкаларга караганда да ныграк, аның белән һәрдаим күзәтчелек итәргә омтыла. Тәнкыйтьченең гуманистик идеяләрне, шуларны уздырган әдәбиятны алга сөрүе гражданлык бурычы дип карала. 1932 елда М. Горький бөтен халык исеменнән Көнбатыш әдипләргә: «Мәдәният осталары, сез кем белән барасыз?» – дигән сорау белән мөрәҗәгать итә[4]. Еллар узгач, шушы сорауга Е. Стояновская түбәндәгечә җавап бирә: «Аларның, Бөек Октябрь җиңүеннән башлап, эре социаль тетрәнүләргә, дәвернең аеруча мөһим вакыйгаларына һәм проблемаларына кайтаваз рәвешендә туган публицистикасы фрагментларыннан сүз рәссамының заман чынбарлыгы белән турыдан-туры аралашуының нәтиҗәләрен үзенә бер төрле күзәтү оеша.

---

[1] Троцкий Л. Литература и революция (печатается по изд. 1923 г.). М.: Издательство политической литературы, 1991. 400 с.

[2] Русская советская литературная критика (1956–1983): хрестоматия: сост.: Л.Ф. Ершов, В.П. Муромский. М.: Просвещение, 1984. С. 109–112; 129–133; 117–120.

[3] Марков Г. Советская литература в борьбе за коммунизм и ее задачи в свете решений XXVI съезда КПСС // Вопр. лит. 1981. № 8. С.13–48.

[4] Горький М. С кем вы, мастера культуры?: сост.: Е. Стояновской. М.: Худ. лит., 1985. С. 8–28 .

...Узган һәм бүгенге көннәр рәссамының гражданлык темпераменты, гражданлык намусы бу сорауга җавап бирә. Эстафета иртәгесе көнгә тапшырыла»[1]. Е. Стояновская фикеренчә, дөньяның мәдәният осталары тарихи аренада тынычлыкны, гуманизмны, социаль алгарышны яклап көрәшергә тиеш.

Шунысын да искә алыйк: борынгырак чорларда фәлсәфи-иҗтимагый хезмәтләр дә әдәби иҗат дәрәҗәсендә каралган, үз вакытында бәяләр алган, аларның эчтәлегенә мөнәсәбәттә генә түгел, әдәби-публицистик яңгырашы, стиле хакында да бәхәсләр барган. Мәсәлән, Ник. Михайловский киң публикага юнәлтелгән мәкаләләрендә җитешсезлекләр күргән Бердяевка каршы «Литература и жизнь» исемле хезмәт яза. Әлеге статьядан вакытлы матбугатта басылган әсәрләрнең стиленә бәйле кайбер юлларны китерик:

«Формага килгәндә, Бердяев әф. әйтүенчә, канәгатьсезлек аеруча ул миндә хәтта кирәгеннән тыш тапкан «лирика»га карый. Мин моны дөрес дип уйламыйм, Гофштетер әф. дә, мәсәлән, «Литературное приложение к Торгово-промышленной газете»да киресенчә миндә «теләсә кайсы пафос чит стиль» һәм «салкын, баканыкы диярлек акыл темпераменты» тапкан иде. Бар кешегә дә ярап булмый, хәзер мин, тормыш тәҗрибәсе һәм ул алып килгән уйланулар басымы астында, форма ягыннан гына түгел, эчтәлек ягыннан да алай әйтмәс идем»[2].

Әдәби тәнкыйтьне галим, әдип, журналист һәм укучы язарга мөмкин. Авторына бәйле рәвештә, материалларның стиле, фәннилеге, публицистиклык дәрәҗәсе нык аерылып торачак. Әле бит язучылык белән гыйльми эшчәнлекне янәшә алып баручылар да бар. Әлбәттә, андыйлар тәнкыйтьнең һәрбер калыбында җиңел эш итә, үзләрен төрле сыйфатларда күрсәтү мөмкинлегенә ия.

Татарстан Язучылар берлеге оештырган «Әдәби ел» йомгакларында бер күренеш күзгә ташлана: әдипләрнең афоризмнарга бай, урыны белән иронияле, урыны белән көлкеле чыгышлары зур игътибарга алына, зал җанлана, үзара бәхәскә керешеп китә. Кайбер докладлардагы шаян сүз артында тирән фикер торырга, юмор-

---

[1] Стояновская Е. От составителя // С кем вы, мастера культуры? С. 4, 7.

[2] Михайловский Ник. Литература и жизнь // Субъективизм и индивидуализм в общественной философии. Н. А. Бердяев. М.: Канон+, 1999. С. 315.

сатира элементлары ярдәмендә, чыгыш ясаучы теге яки бу әсәрнең җитешсезлекләрен чагылдырырга, аерым язучыларны иҗади осталык дәрәҗәсенә бәйле чеметкәләп узарга да мөмкин, тик кайвакыт теге яки бу «хисап» шаян сүз кушылган «санау»га да кайтып кала. Танылган зур язучыларның әдәбиятка тоемы көчлерәк, эчке бәяләмәсе гаделрәк булса да, кайберләре зур аудитория каршында еш кына объектив сүздән кача, каләмдәшләре белән яхшы мөнәсәбәт сакларга тырыша. Кызганыч ки, галимнәр тарафыннан җитдирәк, әмма бер тондарак ясалган докладларны күпләр, кызыксыз дип санап, теләмичә генә тыңлый я, гомумән, тыңламый. Ә бит әнә шул тыштан төссез тоелган докладларда, урыны белән кирәксез теорияләштерү күзәтелсә дә, мәгънәле сүз күбрәк яңгырый.

Әйе, фәннилектән ерак торган «шома сүз» һәр төр публика каршында үзен акламый. Кем алдында гына доклад укырга хәзерләнсәң дә, җөмләләреңне образлы итеп корганда, чама хисен югалтмаска, булган белемнәреңне тагын бар кат яңартырга һәм фикереңне дәлилле итәргә, әдәбиятны аңлауда тоемчанлыгыңа гына таянмаска кирәк. Төрле көлдергеч репликалардан торган чыгышың сине халык каршында, акыллы шәхестән, әдәбиятчыдан битәр, тамашачы, уенчы итәр; әйткәнеңә тирән мәгънәләр яшерелгәндә дә, публика сине җитди кабул итмәскә мөмкин. Фикерләребезне татар тәнкыйтенең бүгенге барышыннан мисаллар белән дәлилләп узарга да була.

«Казан утлары»ның 2005 ел, 7 санында Рөстәм Зариповның «Төрле-төрле уйласак та» дигән язмасы чыккан иде. Автор аерым бер урыннарда, бик хаклы һәм нигезле рәвештә, Айдар Хәлимгә каршы төшә, аның Гаяз Исхакый язган «Ул әле өйләнмәгән иде» хикәясен дөрес аңламавын әсәрнең төп мотивын объектив билгеләү юлы белән ача, әмма үзе дә А. Хәлим тәнкыйтенә хас чатаклыклардан арына алмый. Гомумән, аның күпчелек тәнкыйть язмалары үтә субъективлык белән аерылып тора. Ул бу очракта, А. Хәлимнең «Сез беләмсез кая барганны?» мәкаләсендә танылган прозаигыбызның Кандалыйны Пушкиннан өстен куйганына эче пошып, «Сәхипҗамал» поэмасыннан натуралистик тасвирларны китерә һәм, берничә өзеккә таянып, шушы нәтиҗәне чыгара: «Гел шушы рухта язылган поэмалардан алынган әлеге юллар бу агайның Пушкиннан ни дәрәҗәдә югарылыгын күрсәтергә җитеп торыр дип уйлыйм»[1].

[1] Зарипов Р. Төрле-төрле уйласак та // Казан утлары. 2005. 7 сан. 143, 144 б.

Р. Зариповның татар әдәбияты тарихында мәртәбәле урынга ирешкән Г. Кандалыйны – мулланы һәм үз чорының танылган шәхесен «агай» дип түбәнсетегә омтылуы аны тәнкыйтьче буларак бизәми. Икенчедән, әдәбиятчы лирик мин тарафыннан даими «өркетүләр»нең поэманың структур берәмлеге, ә сөйләменә ямьсез сүзләрне кертүенең мәгърифәтче шагыйрьнең гүзәл кызны һәм аның янәшәсендә укучыны да сискәндерү, куркыту һәм реаль чынбарлыкка күзен ачтыру максатыннан кулланган әдәби алым булуын искә алмый. Шагыйрьнең бигрәк тә гүзәллек-ямьсезлек һәм башка капма-каршы эчтәлеккә ия эстетик категорияләр белән эш итүен, моның өчен заманына күрә үзенчәлеклерәк әдәби образлардан, тасвирлардан, гыйбарәләрдән, тел-сурәтләү чараларыннан файдалануын аңлаудан ерак тора. Г. Кандалый иҗатында, гүзәллекне – матурлыкка, белемлелекне – наданлыкка, тәрбиялелекне – тупаслыкка кискен каршы куйган очракларда төшенчәләрнең дә шуларны чагылдыручы лексик кырларга караганнары активлаша.

Р. Зариповның әдәбият тарихыннан, теоретик хезмәтләрдән хәбәрсезлеге күренә. Ул, бердән, купшы әдәбият, бигрәк тә поэзия фонында танылган мулла тарафыннан язылган кыю шигырьләрнең әдәби барышка ничек тәэсир итүен, шагыйрьнең гади халыкны үз әсәрләре аша әдәбиятка якынайтуын аңламый. Икенчедән, рус әдәбият тарихында Пушкинның Кандалыйдан да «уздырган», хәтта порнография дип аталырга тиешле шигырьләре барлыгын белми. Рус шагыйре бозык әхлакны тәм табып тасвирлаган, интим мөнәсәбәтләрне тупас чагылдырган әсәрләр язу гадәтеннән бары тик өйләнгәч кенә, анда да хатынын ярату хакына үзен мәҗбүр итеп кенә туктата. Аның әлеге гадәттән тыш бозык эчтәлеккә ия шигырьләре Үзгәртеп кору еллары башында зур тиражлар белән халыкта таралуын да онытмаска кирәк.

Гыйльми нәтиҗәләр чыгарганда, шушы рәвешчә, автор мирасыннан аерым бер өзекләр генә китереп, зур гомумиләштерүләр ясау матур күренеш түгел. Галимме, тәнкыйтьчеме Кандалый һәм Пушкинны үзара нәкъ менә иң яхшы әсәрләре нигезендә генә шагыйрьлек дәрәҗәсе буенча чагыштыра ала. Шул ук вакытта, әдәби-фәнни күзлектән караганда, төрле стильдә иҗат итүче каләм ияләрен янәшә кую бик үк дөрес тә булмас. Иң отышлысы – рус шагыйрен дә, татарныкын да үз әдәбиятларын үстерүгә керткән өлеш ноктасыннан бәяләүдер.

Хәтта дөнья әдәбияты кысаларында да үз урынын тапкан Пушкин, ничек кенә яхшы язмасын, талантының яктысы Кандалыйныкын баса алмый. Безнең өчен татар шагыйренең үз халкының поэзиясен үстерүгә куйган көче тагын да зуррак, чөнки каләме замандашларыныкыннан кискен аерылып тора. Чагыштыра белергә кирәк: Пушкинны тудыруда катнашкан рус әдәбиятының үсеш дәрәҗәсе, тормышчанлыгы нинди дә, Г. Кандалый иҗат мәйданына килгәндә, милли шигъриятебезнең төп сыйфатлары нинди?! Җир белән күк арасы. Татар шагыйре аерым бер кысаларда үскән поэзиябезне киңкатлам халыкка бик нык якынайткан, заманчалаштырган, тематик һәм жанр формалары планында киңәйткән, актуаль яңгырашлы иткән, чын мәгънәсендә «татарнкыкы»на әверелдергән, киләчәк буын шагыйрьләре өчен этәрелеш платформасы тудырган.

Әлбәттә, төрле социаль чыгышлы, төрлечә көн иткән каләм ияләре мирасында натуралистик элементларның сәбәбен, күләмен күрсәтергә яисә берсенең натуралистик пландагы шигъриятен – икенчесенең порнографик әсәрләренә каршы куярга мөмкин. Ул чагында бу төр әсәрләр дөньяга килүнең шартлары, максатлары охшаш түгеллекне аңлатып үтәргә кирәк. Чагыштыруларның, янәшә куюларның төрләләре бар, әмма әлеге алымнар иҗатның үзенә нигезләнеп, аның асыл сыйфатларыннан чыгып сайланырга тиеш.

Җәмәгатьчелек журналист, публицист алдына язмаларында объективлыкка омтылу бурычы куя. Танылган тәнкыйтьче, рус милләтенең хадиме Г.В. Плеханов үз чорында ук тәнкыйтьнең публицистик сыйфатламасын объективлык, фәннилек төшенчәләре белән тыгыз бәйләнештә караган: «…объектив тәнкыйть /…/ чын мәгънәсендә фәннилектән генә публицистик булып чыга да»[1]. Г.В. Плеханов, хезмәтнең авторы кемлеккә карамастан, укучыда тормыш фактына мөнәсәбәттә ялгыш фикер тудырмаска тиеш, дигән карашны яклый. Димәк, әдәби тәнкыйтьтә беркемгә дә, хәтта башлап язучыга да, талант иясенә дә ташламалар ясалмый.

Укучылар турында сүз йөрткәндә, әдәби, гыйльми публика дип аерып күрсәтү бар. Адресатның әлегечә тәгаенләнүе шулай ук тәнкыйть мәкаләләренә үз эзен сала. Галимнәргә юнәлтелгән тәнкыйтьтә, әйтик, фәнни журналларда басылган язмаларда купшы сүзләрдән файдалану урынсыз булыр иде. Хезмәт авторлары, беренче чиратта, сәнгатьнең мәңгелек кануннары, аерым бер әсәрнең

[1] Плеханов Г.В. Избранные философские произведения: в 5 томах. М., 1958. Т. 5. С. 186.

шуларга җавап бирү-бирмәү мәсьәләсе, әдәбиятта моңарчы булмаган күренешләрне ачуга игътибар итәчәк. Кулланылган цитаталарга астөшермәләр биреләчәк, мәсьәләне өйрәнү тарихы да яктыртылырга, фәнни бурыч һәм максатлар куелырга, методологик нигез ассызыкланырга мөмкин.

Мәкалә киңкатлам укучылар алдыра торган «Чаян» журналында басыла икән, аның эчтәлеге сатирик-юмористик характерда һәм әсәрдә сурәтләгәннәрдән көлү, нәрсәнедер кире кагу рәвешендә булса отышлы. Бу очракта күзгә ташланырлык фәннилек мәҗбүри түгел, әмма фикернең нигезлелеге күренеп торса, тәнкыйтьченең нәрсәне сатира угына һәм ни өчен алганы ачык аңлашылса яхшы. Димәк, сатирик-юмористик рухтагы вакытлы матбугатта әнә шуңа күрә, нигездә, фельетон яисә башка кече формалар өстенлек итә. Дөрес, бу төр басмаларда да җитди, аналитик пландагы язмалар басылырга мөмкин, әмма андый күренеш гадәтилектән бер чыгарма рәвешендә генә очраштыра. Әгәр шаян-тәнкыйди рухтагы газета һәм журнал әдәби әсәрләрне аналитик бәяләүне үзенең даими бурычы итеп ала икән, әлеге хезмәтләрдә анализга сайланган әдәби берәмлекнең җитешсезлекләре калкуландырыла, һичьюгы асмәгънәдә укучыга җиткерелә һәм тәнкыйтьләнә.

Әдәби тәнкыйть – жанрларга бай өлкә. Тәнкыйтьнең адресаты иҗатчы булганда, стильнең, жанрларның теләсә кайсын сайларга мөмкин. Әдәбият белән шөгыльләнгән һәм филологик белемгә ия кеше язмаларны гади, югары белемсез укучы күзелегеннән дә, галимнекеннән дә чыгып укый. Тәнкыйть әдипкә турыдан-туры адресланса, элегрәк еш кына өйрәтү рәвешендә язылган. Хәзерге заманда мондый тон үзен акламый. Публицистның үз фикеренә нигезле, башка әдәби мисаллар ярдәмендә ышандыруы, дидактизмнан качуы, укучыны уйлануга этәрүе кирәк.

Вакытлы матбугаттагы «ачык хат»лар интернет челтәренә күчә бара, шунлыктан сан ягыннан арта. Форумнарда язылган фикерләр, шулай ук адресатлы хатлар сакланмаска да мөмкин, әмма алар публикада теге яки бу мәсьәләгә карата кызыксыну уята, укучыны үзара сөйләшүгә тартып кертә. Тәнкыйтьче, кемгәдер атап, махсус мөрәҗәгать рәвешендә мәкалә язса да, адресат сыйфатында зур публиканы күздә тота, югыйсә хатны почта аша гына юллаган булыр иде. Икенче төрле әйткәндә, «ачык хат» авторы, формаль караганда, иҗатчыга әйтелгән фикерен бөтен кешенең ишетүен тели, ә аның үзен массалар эчендә күрә.

Каләм иясенә – әдәби иҗаты турында хезмәттәшләре, иҗатташлары, галимнәр, гади укучы ни уйлый – белеп тору кирәк, әмма талантлы шәхесләр хәтта бик гадел тоелган кебек тәнкыйтьне дә авыр күтәрә. Сүзнең үлчәнгәнлеге, шәхси мөнәсәбәтләргә нигезләнмәве, кешенең яшерен серләрен актыртмавы, эчке дөньясына тыкшыну кебек кабул ителмәве... Бу шартларны тагын да дәвам итеп булыр иде. Әнә шундый кысалардагы тәнкыйть сүзе автор рухи дөньясының матурлыгы, күңеленең рыясызлыгы турында сөйли.

Рәссам башкалар тарафыннан әйтелгән киңәшләрдә, күрсәтелгән җитешсезлекләрдә һәрвакыт үзенә теләктәшлек хисе, ярдәм итү теләге тоярга тиеш. Кайвакыт каты тәнкыйть әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлаучыны гына өркетеп калмый, хәтта инде танылган язучының да кулыннан каләмен төшерә. Тәнкыйтьче талант алдында җаваплылыкны тоеп эш итсә, һичшиксез, җәмгыять каршында үз бурычын үти. Талант фаҗигасе турында күп язалар. Аны үстерергә дә, үтерергә дә була, диләр, ә бит бу эшләр нәкъ менә иҗатка карата объектив я субъектив якын килүдән башлана.

Теге яки бу әсәрләрне урынсыз, дәлилсез хурлау авторына зур рухи зыян салган, иҗатын сүлпәнләндергән кебек, кешене тиешеннән тыш мактау да боза, хәтта аңа артыграк та зарар китерә. Бердән, ул, ни язсам да, яхшы чыга, мин камиллекнең иң югары ноктасына ирештем инде, дип алдана. Икенчедән, тәнкыйть андый-мондый гына җитешсезлекләрне күрергә сәләтсез икән, алга таба да шушылай яза алуым җитәр, дигән фикергә килергә мөмкин. Бигрәк тә зур урыннарда эшләгән шагыйрьләр, әдипләр, иҗатларына объектив тәнкыйть юклык аркасында, язганнарының җитешсез якларын белмичә, хәтта дөньядан китәләр. Инде киләчәк буын да, әлеге әдипләрнең мирасы хакында үзләреннән элгәреләр фикеренә генә таянып язса, бигрәк тә танылган галимнәрнең гадел булмаган бәясенә каршы төшәргә батырчылык итмәсә, иҗат хакында дөреслек беркайчан да торгызылмаячак.

Тарихта, вакытлар узгач, теләсә кайсы хакыйкатьнең җиңәсенә ышану хата булса да, аңа – өметләнергә, ә тәнкыйтьчеләргә әдәбиятның объектив елъязмасын калдыру өчен көрәшергә кирәк. Гаделлек сагында һәрвакыт талантлы шәхесләр тора. Шундыйларга бай XX гасыр башы тәнкыйтендә объективлыкка омтылыш гаять тә көчле. Алтмышынчы – җитмешенче еллар да – татар әдәбиятының зур иҗатчыларга бай вакыты, һәм шуңа күрә дә нәкъ бу чор-

да тәнкыйтьнең нык үсеп китүе, бәхәсләргә юл куелу – табигый күренеш. Хәтта шул килеш тә, безгә калса, алтмышынчы еллар шигъриятенең дә дөрес бәясен алып бетерә алганы юк, ә инде илленче еллар ахыры шигърияте, гомумән, яңадан бәяләнергә тиешле. Без шигъри үсешкә нигезнең илленче еллар ахырында Роберт Әхмәтҗановлар буыны тарафыннан салынуын күрергә теләмибез, һич югы бәяләп бетермибез шикелле. Ул исә нәкъ менә илленче елларның икенче яртысындагы «җепшеклек чоры» белән бәйле.

Соңгы вакытта рус галимнәре алтмышынчы еллар уртасыннан иҗат ирегенең яңадан кысыла башлавын билгелиләр. Бу рус иленең бер өлешенә әйләнгән татар дөньясында да шулай. Алтмышынчы еллар ахырыннан әдәби мәйданда бер кызык хәл күзәтелә. Сәясәттәге чигенеш, бер яктан, шигъриятебезнең ирекен тоткарлый, икенче яктан, поэтик жанрлар әле инерция белән үсүен дәвам да итә, ә инде партия тарафыннан күзәтүнең көчәйтелүе нәфис текстларның асмәгънәлелеген үстереп җибәрә.

Сәнгать барышындгы хәлләр иҗтимагый барыштагы хәлләргә бик аваздаш. Әдәбият, укучысы һәм дөнья күрү мәйданы булса, ирексезлектә дә үсә, сүз иреге алгач, фикри тирәнлеге тагын да көчәя. Көрәшче язучы, әлеге ирекне югалта калса, сулышын бусалар, барыбер киләчәккә өмет белән каравын дәвам итә, әдәбиятның гаделлек рухын төрле юллар белән яшәтергә омтыла, рухи ныгый, халыкка хезмәт мәйданыннан китми. Ирекле әдәбиятның тәмен бер татыган милләт тә аннан һаман да кыю фикер көтә, каләм ияләренә әйдәманы итеп карый. Шул ук вакытта әдәбиятның озак вакытлы басым астына керүе, язучыларны аннан читләштерергә омтылыш ахыр чиктә сүз сәнгатенең сүнүенә, юкка чыгуына да китерергә мөмкин.

Хөкүмәтнең иҗатчы, гомумән шәхес ирекен рәсми рәвештә игълан итеп тә, асылда аңа каршы төрле киртәләр тудыруы шулай ук әдәби барышка зыянлы йогынты ясый. Каләм иясе яза ала да кебек, бастыру мөмкинлеге юк, халык арасында сөйли дә кебек, әмма еш кына объектив чыгышлары өчен җавапка тартыла. Бу төр идарәчелек вакытында фикернең акыллысы, саллысы телерадиоязмалардан кыскартыла яисә шуның аркасында тапшыру эфирга чыгарылмый. Халыкка үз сүзен ишеттерә алмау, язганнарын бастырмау аркасында, талантның кулыннан каләме төшә. Туксанынчы елларда иркен сулыш ала башлаган вакытлы матбугат, татар әдәбияты бүгенге көндә әнә шундый полосага килеп керде. Соңгы елларда А. Хәлим, З. Зәйнуллин һәм башкаларның хезмәтләренә карата

кузгатылган хөкем эшләре – тора-бара сүз ирегенең бөтенләй юкка чыгачагыннан беренче хәбәрләрдер.

Дөрес, туксанынчы елларда да ничәмә-ничә вакытлы басмалар, шәхси басмаханәләр була торып та, каләм ияләре егәрле сүзен кирәк кадәрле, кирәк дәрәҗәдә һәм киңкатлау массаларның иҗтимагый аңында ныгытырлык әйтмәде, тормышның һәр ягына, шул исәптән милләт язмышына, аның сакланышын кайгырткан әдәбият-сәнгатенә кагылышлы чын дөрес фикер татарның алдынгы, укымышлы катламына гына хас иде. Шулай да өлешчә ирек алган шартларда әйдәман каләм ияләре милләтнең аерым бер өлешен үз артыннан ияртә, зур иҗтимагый хәрәкәткә тартып кертә алды, тик, сүз һәм көрәш иреге кысыла башлау белән, аны ишетерлек аудитория тарайды, халык массалары иҗтимагый-сәяси мәйданнан читкә китте.

Хәтта туксанынчы елларда да тәнкыйтьчеләр, заман мөмкинлекләреннән файдаланып, махсус органнарын булдыра алмады. Андый тәкъдим белән чыккан иҗатчылар Татарстан Язучылар берлегендә дә яклау тапмады. Ә бит тәнкыйтьнең махсус органы булу-булмау – әйткәнебезчә, нәкъ менә аның ireген, үсеш дәрәҗәсен чагылдыручы бер факт, объективлыгын билгеләүче шарт. Татар әдәби тәнкыйтенең торган саен йомшый баруы, объективлыктан читләшүе аның алдына куелган киртәләр, гадел тәнкыйтькә мәйдан булмау, сүз ирегенең төрлечә кысылуы һәм тәнкыйтьчеләрнең сакчыллыгы, аларда гасырлар дәвамында ныгыган курку хисе белән турыдан-туры бәйле.

Гомумән алганда, гаделлек проблемасы бөтен совет чоры әдәби тәнкыйтенә хас булган, һәм аның хәзер дә көн кадагыннан алып атылганы юк. Алай гына да түгел, капитализм ныгыган, әдәбият аерым бер партия күзәтүеннән чыккан шартларда иҗатны бәяләүдә кай төр гаделсезлекләр арта гына төште. Мәсәлән, әдәби әйләнешкә камил язылган күпсанлы кече күләмле эпик әсәрләрнең кертелмәве, күзәтүләрдә сүз сәнгате үсешен чагылдыру өчен мөһим прозаны иңли алмау; кайбер галимнәрнең әдәби төрләрне, нигездә, азсанлы авторлар иҗаты аша чагылдыруы; драматургиянең күзгә күренеп йомшавына игътибар итмәскә, һәр куелган әсәрне күкләргә чөеп мактарга тырышу; поэзияне поэма үсешен үзәккә куеп бәяләү омтылышы, аны анализлаганда, бер әйләнешкә кергән шагыйрьләр иҗаты белән чикләнүләр, танылган иҗатчыларга тәнкыйть сүзен әйтүдән качулар, язганнарын еш кына тиешеннән арт-

тырып мактаулар һәм башка күренешләр әдәбият турында дөрес карашлар формалаштырырга мөмкинлек бирми.

Еллар узганнан соң, әдәби мираска әйләнеп карап, яңадан анализлау гадәти бер күренешкә әйләнсә, гаделлек әкренләп торгызыла. Әйтик, узган гасырда бөтен публика төрле бәхәсләрнең шаһиты булган. Аннан соң әдәбият үзгәрде, әдәбият теориясе өлкәсендә дә алга китешләр зур. Тәнкыйтьче киңкатлам укучыга яңа язылган әсәрләргә бәя бирүче кебегрәк аңлашылса да, ул яңа әдәбият җирлегендә дә, билгеле бер аралыктагы әдәби барышны тикшерүне максат итеп тә, узган чорларга кайтырга тиеш. Публиканы да электән килгән бәхәсләргә тартып кертү бик кызык. Рус тәнкыйте әнә шул рәвешчә үсә, массалар игътибарын үзенә җәлеп итеп тора.

Әдәбиятка бәйле һәм гел борчып торган мәсьәләләр җитәрлек. Әдәби әсәрләрне анализлау белән шөгыльләнүче, әйтик, бүгенге көн әдәбият теориясе ирешкән биеклекләрдән торып, алтмышынчы елларда иҗат ителгән әсәрләргә бәйле рәвештә, сюжетсыз, вакыйгага нигезләнмәгән әсәрләр поэма жанрына дәгъвалый аламы, кебек сорауларга җавап эзли ала. Р. Фәйзуллинның «Гадиләргә гимн», «Көрәшчеләр» калыбында язылган әсәрләрнең татар шигъриятендә дә, башка халыкларныкында элек һәм хәзер дә булып та, күп очракта поэма дип аталмавы турында уйланырга мөмкин. Әгәр, бу формада эпик башлангыч төп шартлардан санала икән, аталган әсәрләрнең күләмле публицистик шигырь буларак кына бәяләнергә хаклылыгын белдерергә тиеш кебек. Ә инде, әлеге поэмаларда хис сюжеты бар, дип каты каршы торучыларга, ул хис үсеш-үзгәрешләренең теләсә кайсы, хәтта бер-ике строфалы шигырьдә дә күзәтелә алуын, хис күчешләренең нәкъ менә кече күләмле поэтик әсәрләрне аеруча кызыклы итүен курыкмыйча әйтә алырга да тиеш шикелле.

Гомумән, татар әдәбияты, бигрәк тә аның бүгенгесе бик начар өйрәнелгән, әсәрләр аз күләмдә әйләнешкә кертелгән, бәяләнгән, нәкъ менә шушы күренешләр вакытлы матбугатта бәхәсләр кабынмауга, әдәбиятка мөнәсәбәтле проблемалар күтәрелмәүгә китерә. Татар әдәбият белемендә теге яки бу әсәр кемдер тарафыннан үтәүдә ничек бәяләнсә, гадәттә күпчелек очракта ул бәя үзгәрми яшәвен дәвам итә, фикер төрлелегенә урын бирелми.

Бүгенге көндә гап-гади күренгән хакыйкатьләрне яза алырлык тәнкыйтьчеләрнең юклыгы да зур проблема булып кала. Әгәр нинди дә булса бер иҗатка куйган таләпне икенчесенә дә куймыйбыз икән, теоретик тәгълиматның кирәге дә бетә. Формаль билге генә

булмаган эчтәлеккә – вакыйга юклыгына күз йомабыз һәм акларлык юллар эзлибез икән, башкалар иҗатына да шулай якын килик, ул чагында андый поэмалар теләсә кайсы авторда диярлек табылачак.

Кыскасы, бигрәк тә поэзия тәнкыйте мәйданы зур эзләнүләргә әзер, яңадан бәяләүләрдән куркып калмаслык, актив әйләнештә йөрмәгән яисә хаксызга әдәби тәнкыйть күзлегеннән читтә калган авторларны әдәби әйләнешкә кертерлек намуслы тәнкыйтьчеләр – көчле каләмле публицистлар көтә.

Әдәбиятны бәяләүдә субъективлыкның өстенлек итүе бик күп ямьсез күренешләргә нигез бирә. Бер яктан, талантлы әдипләрне читтә яисә арткырак планга калдырып, алардан талантсызраклар төрле бүләкләр ала. Икенчедән, иҗат мәйданында тиз һәм лаексыз рәвештә пьедесталга күтәрелүчеләр башка талантларга комачаулый, аларга күрсәтмәләр бирә башлый. Тәнкыйтьченең бер бурычы – урынсыз кагылган-сугылганнарны яклау, махсус рәвештә «күрелмәгәннәрне» табып, публикага тәкъдим итү дә. Бу сыйфатлар татар тәнкыйтенең алтмышынчы елларында шактый көчле иде.

И. Золотусский «Очная ставка с памятью» китабында болай ди: «Тәнкыйтьнең бәласе – элитарлык, диләр. Мин, тәнкыйтьнең бәласе – конформизм, дип уйлыйм.

…Тәнкыйди статья автор зәвыгының һәм әдәби сәләтенең феномены гына түгел, ә башкарган эше дә. Без янәшәбездә һәр җирдә кул астындагы кешенең башлыгын ничек мактаганын, җавапсыз пупкиннарны[1] ничек «урнаштырганнарын», әдәбиятта эшләр ничек эшләнгәнне, ә хакыйкать өчен көрәш бармаганны күрәбез. Алтмышынчы еллар тәнкыйтендә риторикачылык, бәлки, хәтта сектачылык күп иде, әмма ул үзе чын күңелдән ышанган идеяләргә тугрылык принцибында нык торды.

Кайбер тәнкыйтьче кем туры килсә шуны мактый, кирәкле кешеләргә хезмәт күрсәтә һәм кайчан да булса әлеге кешеләргә бар хакыйкатьне күзләренә карап әйтермен дип уйлый. Әмма юк, мондый хәл булмый. Кыюлык, конформизм кебек үк, безнең эштә – гадәт диярлек»[2].

---

[1]Аноним яисә җәмгыятьтә билгесез кешеләрне атау өчен кулланылучы экземплификант исем; үзенә кирәгеннән тыш ышанган, үзен югары бәяләгән, чынлыкта интеллекты түбән шәхес, каләм иясе тибы.

[2] Золотусский И. П. Вместо послесловия // Очная ставка с памятью. М.: Современник, 1983. С. 285–286.

Кызганыч ки, кайвакыт тәнкыйтьчеләрнең әдәбиятны аңлауга хәзерлеге язучының әдәби тоемы, хәзерлеге белән ярыша алмый, ул хәтта алдынгы карашлы, белемле публиканыкы дәрәҗәсендә дә булмаска мөмкин. Тар карашлы, кеше фикерен җиңел һәм дөрес аңлауга сәләтсез авторлар, үз язмалары белән, укучы аңына буталчыклык кертәләр, әдәби әсәр турында киң җәмәгатьчелектә ялгыш фикер тудыралар. Кыскасы, иҗат берәмлеген аңларлык – тоемың, белемең һәм телгә осталыгың булмый торып, тәнкыйди материал язу өчен, кулыңа каләм алу да – этикасызлыкка тиң.

Әдәби осталыкны күзаллавың тар икән, сүз остасына акыл сату – көлке гамәл. Иҗаттан профессиональлек таләп итүче үзенең дә язмасын укучы хөкеменә тапшырачагын онытып җибәрергә тиеш түгел. Аннотация язабызмы, күләмле рецензияме, иҗат портреты тудырабызмы яисә әсәрнең кайсыдыр ягын анализларга, аңа бәйле проблема күтәрергә алынабызмы,текстны тулаем һәм җентекле укырга мәҗбүрбез. Алай гына да түгел, әлеге әсәр, объект сыйфатында сайланган иҗат хакында башыбызда тулы күзаллау булдырырга тиешбез. Ә инде тикшерү алымнарының кайсынадыр ныграк тукталу, әсәрнең бер ягын аерып алып тирәнрәк өйрәнү, аны ниндидер яссылыкта гына ачу яисә язмада да тулы анализ бирү – шәхси эшебез.

Эчтәлек һәм форма берлегендә шулай ук публицистик осталык та чагыла ала. Бу язмага исем сайланышында ук күренә. Кайвакыт зур проблема күтәргәнлеге атамасында ук чагылыш тапкан мәкаләне кулга алып укырга керешәсең, ә эчтәлек аңа җавап бирми, автор тирәнгә узмый. Шулай да була: кайбер язмаларның исемнәре автор күтәргән проблемаларны, җиткергән фикерләрне тарайта.

Әдәби публика һәр сүзеңне игътибарга алсын дисәң, аның язмаңнан көткән өметен аклау турында онытмау кирәк. Әгәр тирән, төгәл фикер әйтергә көчеңнән килми икән, көт, уйлан, күпмедер вакыт әсәргә бәйле карашларыңны җыйнап йөр, үзең өчен ачыкланып бетмәгәннәреннән арын, кеше сүзенә колак сал, әмма, шәхси стилеңне һәм ышанган фикерләреңне саклаган хәлдә, газета калыбына, заман теленә, укучы ихтыяҗына җавап бирә торган тәнкыйть иҗат итәргә тырыш.

Кыскасы, тәнкыйтьтә публицистлык һәм фәннилек мөнәсәбәте мәкалә язылган шартларга, авторга, юлланган адресатка, язма урын алган вакытлы матбугат органына бәйле. Һәм әдәби тәнкыйтьнең әлеге ике сыйфаты һәрвакыт үзара тыгыз үрелеп, вакыты белән берсе икенчесенә үз урынын биреп яши.

## 1.5. Әдәби тәнкыйтьтә объективлык һәм субъективлык мөнәсәбәте

Без алдагы бүлекчәләрдә әдәби тәнкыйтьне ике төрле аңлау барлыгын күрсәттек, сүзлекләрдән шуны раслаган билгеләмәләр дә китердек. Шул ук вакытта, сәнгатилеген таныганда да, тәнкыйтьне нәфис әдәбият яисә иҗат дип санау белән килешеп бетмибез; тотып торучы төп жанр формалары фәнгә якынрак торганга, үзен дә, беренче чиратта, фән дип тануны яклыйбыз. Әдәби тәнкыйтьне гыйльми карашларны фәнни-сәнгати чагылдыручы өлкә дип әйтергә дә булыр иде. Шушы җөмлә андагы объективлык һәм субъективлык мөнәсәбәтен дә, тәнкыйть хезмәтләрендә беренчесенең алдарак баруын, өстенлек итүен дә ачык күрсәтә.

Әдәби тәнкыйть белән билгеле бер фәнни хәзерлеге булган публицист, социолог, тарихчы, мәдәниятчы һәм хәтта гади укучы да шөгыльләнә икән, аңа этәргеч көч булып хезмәтне башкаручының эстетик кабул итүе, кичерүе яисә шуны массаларда күреп алуы, әсәрне үзе укып, аерым бер нәтиҗәләргә килүе тора. Алар да, тәнкыйтьче-филологлар да әдәби берәмлекнең иҗтимагый мәгънәсенә, эстетик кыйммәтенә зур әһәмият бирә, сәнгатькә бу рәвешчә якын килүнең нигезендә фәлсәфи-эстетик фикерләүләрдәге уртаклык ята.

Укучыдагы кичерешләр дөньясының байлыгы аның табигате белән генә түгел, әсәрне кабул итүгә хәзерлеге – әдәби тәҗрибәсе, белеме, яшәгән тирәлеге һәм хәтта физик сәламәтлеге белән дә бәйле. Тәнкыйть мәкаләсендә сәнгатьтән алган тәэсирләрне алгы урынга куючылар әдәби тәнкыйтьне, беренче чиратта, нәфис иҗат дип саный, хисләр йогынтысында язылганлыктан, андый төр хезмәтләрдә образлы фикер өстенлек итә дип уйлый.

Әсәрне кабул итү, аңлау бар, шул аңлауны фәнни, фәннилектән шактый ерак торган тел белән чагылдыру бар. Бүгенге татар әдәби тәнкыйтенә фәнни нигезләү, логика, актуальлек, барыннан да бигрәк җитешсезлекләрне атаганда тәгаенлек җитми, дип даими рәвештә гаеп ташлау асылда каләм ияләренең һәм укучының иҗатка бәядә объективлыкны һәр нәрсәдән алга куюын күрсәтә, ә инде аңа ирешү – икенче бер мәсьәлә, киләчәктә аермачык хәл ителергә тиешле зур проблема булып тора.

Карашлар чуарлыгына урын бирү гыйльми хакыйкатьнең төрлелегә дигән сүз түгел, бу хәл бары тик демократик җәмгыятьнең яшәү принципларын һәм аның фән өлкәсенә дә кагылуын чагылды-

ра, анда шәхесләр культын булдырмауга хезмәт итә. Икенче яктан, нәкъ менә карашлар төрлелеге яшәгәндә генә, объектив нәтиҗәләргә киленә, әкренләп чын хакыйкать ачыла, тулы булмаган хакыйкатьләр капма-каршы тоелган кебек карашлар ярдәмендә дә тулыландырыла. Әлбәттә, әсәр турында фикер йөртү бары тик шәхси генә була ала, әмма шәхсилек үзе дә гомумилектән үсеп чыга: һәр кеше үзенә кадәр тупланган гыйлемнәргә таянып эш йөртә, кайсыдыр карашларны кире кага, кайсындыр кабул итә һәм үстерә.

Әдәби тәнкыйтьнең сәнгатилеге, әйткәнебезчә, аның белән башлыча талантлар шөгыльләнүеннән килә, ә аларны һәрвакыт сүзнең үтемлелеге, массаларга барып җитү дәрәҗәсе борчый. Шул ук вакытта тәнкыйтьченең сәнгатьче булуы һич тә мәҗбүри түгел. Әдәби тәнкыйть белән даими шөгыльләнү еш кына кешенең үзен дә иҗатка алгысыта башлый, һәм ул әдәби әсәрләр язу эшенә керешә.

Әдәбиятны үстерергә алынган тәнкыйтьтә объективлык – беренче шарт, ә субъективлык – котылгысыз бер хәл. Кешенең – белем дәрәҗәсенә, тәнкыйть әсәренең – адресатына, язылу максатына, шартларына, вакытына бәйле рәвештә, анда объективлык һәм субъективлык мөнәсәбәте төрле якка үзгәрә. Субъективлыкның артуы, хезмәтнең метафоралылык дәрәҗәсе – аны әдәби иҗатка якынайтучы сәбәпләрдән. Кайвакыт катнаш функциональ стильдә язылган мәкаләләрнең әдәбияткамы, фәнгәме якын торганлыгын әйтү дә кыен.

Киң аудиториягә адресланган газета-журналларда укылышсыз фәнни тел, бихисап терминнар аша күптөрле информация җиткергән хезмәтләр басылгалый. Андый язмалар массаларга аңлаешсыз. Дөрес, күп нәрсәдән хәбәрдар, гыйльми фикерне кабул итәргә хәзерлекле укучыда алар да кызыксыну уятырга һәм бу төркем тарафыннан югары бәяләнергә мөмкин. Шул ук вакытта бәхәссездер ки: бу төр хезмәтләр тәнкыйть алдында торган функцияләрне йомшаграк башкарачак. Әлбәттә, андый язмалар да, асмәгънә аша тирән фикер җиткергән мәкаләләр дә кирәк, чөнки тәнкыйть төрле булырга тиеш. Әйтик, тәнкыйтьченең сатира-юмор ярдәмендә яисә «юллар арасында» әйтелгән сүзе ассоциатив фикерләве югары каләм ияләренә көчле тәэсир ясый һәм шуның белән – аларны иҗатчы буларак тәрбияли. Бу төр тәнкыйть сүз ирегe тыелган шартларда объектив кала алуның, фикер уздыруның үзенчәлекле юлларын күрсәтә, беррәттән әдәбиятны да үстерә ала.

Әдәби тәнкыйть материаллары һәрвакыт ике планлы. Беренчедән, алар хисси интонациягә ия (моңа экспрессив тел чаралары,

әсәрдән туган кичерешләрне җиткерү һ.б.лар белән ирешелә), икенчедән, кыйммәти нигезле (хезмәт авторы әсәрнең иҗтимагый-эстетик мәгънәсен ача). Бу ике як аларның фәннилеген күрсәтә яисә сәнгатькә якынайта, шулай ук субъективлык һәм объективлык мөнәсәбәтен дә билгели. Вакытлы матбугатта көн күргән хезмәтнең әдәбилек дәрәҗәсе шул чор публицистикасының сәнгатилек дәрәҗәсен дә турыдан-туры чагылдыра.

Ике гасыр чигендә фәндә объективлык һәм субъективлык мәсьәләсенә игътибар артты, эстетика буенча хезмәтләрдә аның тәнкыйтьтә чагылышына махсус мәкаләләр дә бирелә. Ю. Борев, тәнкыйтьтә объективлык-субъективлык – тәнкыйди анализ методологиясенә караган үзәк проблемаларның берсенә әверелгән үзара мөнәсәбәтләр ул, дип белдерә һәм: «Әдәби тәнкыйтьтә ике капма-каршы һәм бердәй хата тенденцияләр ачыкланды: объектив һәм субъектив башлангычларны абсолютлаштыру. Объектив башлангычны абсолютлаштыру, нәфис текстта һәрвакыт сәнгати мәгънәне аңлауның төгәл программасы бирелә, дигәннән чыгып эш итә. Бу төр якын килү буенча, тәнкыйди анализ автор тудырган һәм текстта теркәгән сәнгати эчтәлекне ачарга тиеш»,– ди. Аныңча, тәнкыйтьнең объективлыгын абсолютлаштырганда, әсәр мәгънәсен даими дип тануга таяныла һәм, текстны өйрәнүнең математик дәрәҗәдә дөрес, төгәл алымнарын эшләү мөмкинлеге бар, дигән ялган ышаныч тудырыла. Галим бу вакытта тәнкыйди хөкемнең гуманитар характеры һәм әлеге хөкемдә шәрехләүченең шәхси башлангычына нисбәтле роль игътибардан читтә калганны да әйтә[1].

Әдәбият белемендә «әсәрне заманча уку» дигән гыйбарә бар. Һәр чор кешесе сәнгать әсәрләрен теләсә-теләмәсә дә үзенчә аңлый, заман үлчәүләренә куеп карый. Ә менә тарихтан, әдәби үсештән хәбәрдары, һичшиксез, аңа, беренче чиратта, узган чорлар җимеше дип якын киләчәк, автор әйтергә теләгәнчә аңларга тырышачак, шуннан соң гына иҗат ителгән вакыттагы иҗтимагый, сәяси, әхлакка бәйле һ.б. карашларның һаман да искермәгәнлеген, куелган проблемаларның актуальлеген билгеләячәк, яңа заман белән бәйләп караячак.

Әсәргә автор салган мәгънәне табарга тырышып укымау нәкъ менә объективлыктан ерагайта торган сәбәп булып тора да. Әдә-

[1] Борев Ю.Б. Эстетика. Теория литературы: энциклопедический словарь терминов. М.: Астрель, 2003. С. 278.

би әсәрне махсус рәвештә заманга яраштырып һәм үзеңә файдалы итеп укудан сакланырга кирәк. Аны аңлауда бу моментлар болай да үзен сиздерәчәк. Дөрес, һәр заман укучысы танышкан әсәре хакында, бүгенге көндә ул безгә нинди гыйбрәт бирә ала, дип уйланырга тиеш. Укытучы, галим, аның нинди шартларда, нинди максатларда язылганлыгыннан хәбәрдарлыктан, әсәргә салынган эчтәлекне ныграк төшенә һәм шул төшенгәнен шәкертләренә дә ирештерә. Бер үк вакытта аларның заман яшьләренең әлеге иҗат берәмлеген ничек кабул итүләре белән кызыксынуы, төрле буын кешеләренең аңлауларындагы аермаларны белүе кирәк.

Тәнкыйтьчегә килгәндә, ул үз чорында язылган матур әдәбиятны бәяли, димәк, ул аның мәгънәсенә автор аңлавындагыча төшенә ала. Әгәр ул теге яки бу әсәр хакында объектив бәя биреп калдыра икән, киләчәк буыннар, беренче чиратта, аның әйткәннәренә таяначак; мөгаллимнәр, әсәрне заманча аңлау хакында сөйләгәндә, ул язган хезмәтләрне китерәчәк һәм тәнкыйтьче карашын бүгенге укучы бәяләмәсенә янәшә куеп караячак.

Әдәби әсәрне тикшерүнең объектив нәтиҗәләр чыгарырга ярдәм итүче универсаль кагыйдәләрен эшләргә мөмкин. Алар бар, нәкъ менә әдәбиятның гуманитар өлкә икәнлеген истә тотып башкарылганнар да. Аларны танымаска мөмкин түгел. Әлбәттә, хакыйкать һәрвакыт, бигрәк тә заманга бәйле рәвештә, шартлы. Дөньяны аңлау, кешенең фикер үсеше бер тирәдә генә таптанып тормый. Бу урында төгәл фәннәрдәге гасырлар дәвамында халыкка хезмәт иткән законнарның да бервакыт кире кагылуын, ә Җир өчен гадел дип табылганнарының Галәм кануниятен чагылдырмавын әйтергә һәм абсолют хакыйкатькә ирешүнең, гомумән алганда, бер генә өлкәдә дә әлегә мөмкин булмавын өстәргә кирәк. Ю. Борев та, объективлык абсолютлаштырылганда, тәнкыйди фикер сөрешенең үзгәрүчәнлеге һәм тарихи шартлылыгы исәпкә алынмый, ди. Кыскасы, объективлыкка ирешү бүген дә тәнкыйтьче омтылган биеклек булып тора, ә дәрәҗәсе шул ук тәнкыйтьче һәм җәмгыять карашларындагы субъективлык күләме белән бәйле.

Кайбер әсәрләрнең, эчтәлегеннән чыгып кына, кайчан язылганлыгын билгеләү кыен. Мәсәлән, урман күренешен тасвирлаган парчаныкын яисә табигатьнең нәҗесләнмәгән, ярлыланмаган хәлдә гасырлар дәвамында торган башка бер урынын, шунда көн иткән тереклекне тасвирлаган хикәянекен. Дөрес, узган чорларда иҗат ителгән бу төр әсәрләрнең язылу вакытын тел үзенчәлекләренә таянып

билгеләргә була, әмма бик үк төгәл түгел, елларын зур аралыкларда күрсәтеп кенә.

Хикәя егетнең кызга мәхәббәт хисләрен җиткерүче монолог рәвешендә дип фаразлыйк. Бүгенге яшьләр арасында моннан утыз-илле ел электәгечә дә мәхәббәт аңлатучылар шулай ук әле очрыйдыр. Берпланлы, беркүзәнәкле мондый әсәрләр күп түгел, әмма бар. Шул ук вакытта тормыш детальләрен бик аз керткән кечкенә күләмдәге, лирик эчтәлектәге прозадан да заманны тою кыен булмаска мөмкин. Моның өчен текстта кайчак нәкъ менә шул чорга гына хас ниндидер предмет аталу да җитә.

Вакыйгаларга нигезләнгән әдәбиятта заман күпчелек очракта ачык аңлашылып тора. Кешенең күңел дөньясын, хисләрен тасвирлаган, традицион образлар белән генә эш иткән, прозаик детальләштерүдән качкан шигърият белән хәл башкачарак. Геройлар сөйләменә нигезләнгән драма әсәрләренең алдына да кайвакыт, вакыйга шул-шул җирдә һәм шул-шул елларда бара дип, хронотопны төгәл билгеләп куялар.

Укучы яшәгән чорны чагылдырмавы, вакыйгаларның үткән белән бәйлелеге ачык күренгән һәм заманга күчереп аңлау кыен әсәрләр бар. Әйтик, грекларның мифик карашларга нигезләнгән трагедияләрен, гыйльмилек дәрәҗәсе түбән яисә искергән карашларга таянып иҗат ителгән фәнни фантастиканы, корольләр тормышын яктырткан Шекспир драматургиясен, үзенчәлекле материалга корылган В. Гюго әсәрләрен бүгенге көн әдәбияты сыйфатында кабул итеп булмый, ә барыбер укучыларның аерым бер өлеше аларны ярата. Төп сәбәбе: әлеге әсәрләрдә тасвирланган үзара мөнәсәбәтләрне заманга бәйле һәм бәйсез дә аңлау кыен түгел, чөнки кеше холкы, хисләре асылда үзгәрми. Галимнәрнең әйтүенә караганда, кеше тукымы ясалу материалы булган маймылларның генокоды белән бүгенге инсанныкы арасында аерма юк дәрәҗәсендә, нибары бер процентка якын. Шулай булгач, аның тарихи хәтере, аң-белеме үссә үскән, ә холык сыйфатлары, физиологиясе бер дәрәҗәдәрәк калган.

Тарих та, әдәбият та Явызлык һәм Яхшылык көрәшеннән торган кебек, шул көрәш тарафдарлары да гасырлар дәвамында яшәп калган характер чагылышларына ия. Инсан яшәгән тирәлек, аның аралашу даирәсе үзгәрүчәнлеккә карамастан, ул корган мөнәсәбәтләрнең асылы һәр заманда бер төслерәк. Бүгенге кешенең үз-үзен тотышы гасыр башындагы әдәптән нык аерылса да, ул кылган

гамәлләр һаман да бер үк исемнәр белән атала. Кеше ярата, көнләшә, алдаша, урлаша, гыйлем туплый...

Язучы әйтергә телгәнчәдән битәр, ул әйтә алганча аңлау – әдәби әсәрне укуда идеалдыр. Үз чорыңнан әсәрдә тасвирланганнарга аваздаш хәлләр эзләү – шәхси эшең, ә әдәби берәмлекне дөрес аңлавың – аңлауга хәзерлек дәрәҗәң дигән сүз ул. Язучы фикеренә төшенүгә сәләтсезлегеңне заманча уку дип атау – көлке бер хәлдер, аны танымаска тырышудыр.

Әсәрләрне аңлы рәвештә «заманча уку»га мөнәсәбәт бүгенге публикада шулай ук төрлечә. «Яңача аңланган» әсәрләр сәхнәдә куела тора, шулай да алар күп вакыт тамашачының да, әдәби җәмәгатьчелекнең дә тискәре бәяләмәсен ала. Яшь режиссерлар тарафыннан сәхнәләштерелгән кайбер пьесалар зәвыклы, белемле тамашачы күңелендә ризасызлык хисе тудыра. Милли хискә ия кеше үз тарихының бозылып күрсәтелүен, традицион әхлакның тамырына балта чабуны кабул итми, ул башка халыкларга да тәкъдим ителгән спектакльләрнең алар күңелендә үз тарихына, үткәненә, халкына карата хата караш тәрбияләвеннән курка. Бу шулай булырга тиеш тә, ахыр чиктә сәнгатькәрләр автор каршында да этик җаваплы бит.

Соңгы гасыр башында Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында Н. Исәнбәтнең фольклор мотивларына нигезләнгән «Җирән чичән»е сәхнәләштерелгән иде. Тәүге куелышларының берсендә шундый күренеш күзәтелде: тамаша барышындагы мәзәк хәлләрдән гади тамашачы шаркылдап көлгән бер вакытта кайбер танылган зыялылар сытык чырай белән залдан чыгып китте. Сәбәбе – сәхнәдә акыллылык белән аерылып торырга, тапкырлыгы сүздә генә түгел, рольне башкару рәвешендә дә чагылырга тиешле чичән балаганчы, шут, тилемсә, бер ахмак кебек уйналды. Дөрес, Җирән чичән дошманнарыннан көлә дә, аларны җиңә дә, әмма моның уйлап эшләнгән хәйлә, акллылык нәтиҗәсе икәнлеге кычкырып тормый, алар очраклы хәлләр кебек кенә кабул ителә. Әлеге рольне башкаручы артистның нәкъ менә туктаусыз, урынлы-урынсыз, махсус рәвештә тамашачыга күрсәтеп, аның каршысына ук килеп, ияк кашуы, сакал тырмалавы, күз ялтыратуы, баш боргалавы, кыланчык нечкә, хатыннарныкы сыман тавышы һәм башка сыйфатлары, эш-хәрәкәтләре сәхнәдәге геройны гадәти бер тилемсәгә ошатып калдырды, артист исә тамашачының шуннан көлүеннән үтә канәгать кебек күренде.

Тәнәфестә, эчтән пьесаның сәхнәләштерелү рәвеше өчен Нәкый Исәнбәт алдында кыенсыну кичереп утырганда, буклет тарата башладылар. Анда, яңа заман режиссерларының әсәргә шушы рәвешчә якын килергә мөмкинлеген фаразлаган авторның киләчәк буыннарны пьесаны гадәти бер тамаша, көлке итеп куюдан сакланырга чакыруы язылган булып чыкты. Әлеге спектакль бөтен илләрне «гизеп йөри», иң зур чараларда читтән килгән кунакларга күрсәтелә, зыялылар утырган залларда, юбилей кичәләрендә аннан өзекләр еш куела, уен алкышларга да күмелә, әмма әсәрнең тирән мәгънәсенә игътибар иттерерлек сәхнәләштерелмәве күңелне һаман борчып тора. Ә гади тамашачының кайсы да булса төп геройда көнчыгыш фольклорындагы акыл иясе җете ачылырга тиешлек турында уйлана микән?.. Андыйлар да очрамый калмас. Тамаша даими барган елларда, җитешсезлекләрен күрсәтеп, рецензия яз әле, дип мөрәҗәгать итүчеләр булды. Кызык, шулай үтенүчеләр арасында мәктәп укытучылары күбрәк һәм хәтта сәхнәгә мөнәсәбәтле, авторга якын кешеләр дә бар иде.

Пьесаларның «үзенчәлекле» куелышы хакында, сирәк булса да, матбугат та язгалый. 2005 елның июнендә Төрки халыкларның VIII халыкара фестивалендә Уфадагы «Нур» театры артистлары чыгышыннан соң басылган язмаларның берсеннән, тәрҗемә итми генә, өзек китерик: «...Р. Фахруллина, И. Ганиева и Ф. Валеева буквально разорвали мое сердце. И вовсе не мастерством перевоплощения или психологического переживания, что часто выглядит «бредовым позорищем» в эпоху «симулякров третьего уровня». Они ели землю из цветочного горшка, обнажали друг другу грудь, жевали и глотали бумагу, играя всем известных Ирину, Ольгу и Машу в пьесе Зайкаускаса по мотивам «Трех сестер» Чехова. В унизительном публичном самоистязании они дошли до реально ощутимой боли, спазмов и озноба.

Хочу задать вопрос: существует ли какой-то другой выход в нашей ситуации, напоминающий античную, когда «классика существует как набор мифов, а режиссер каждый раз по-новому эти мифы пересказывает» (А. Железцов)? Ведь объемы интерпретаций уже такие, что вписаться в них уже невозможно, можно строить только область отрицательных значений семиосферы любого произведения. (Что, кстати, совершил Р. Загидуллин в постановке «На дне» с образом Барона, сделав его инфернальным «инопланетянином», хотя в тексте Горького – четкие указания на невозможность полного уничтожения следов аристократизма).

...Поиск равновесия между Чеховским ритмом и дыханием сегодняшнего дня не прост»[1].

Мәкаләдән шул аңлашыла: әңгәмәдәшләр әдәби әсәрне сәхнәдә яңача «уку»га тулаем каршы түгел, аның мөмкин булган юлларын эзлиләр, әлеге тамашаның «Мәгънәсезлек өчен» призын алуы белән дә килешеп бетмиләр. Шул ук вакытта бу әңгәмә авторның, тамашачының, әдәбиятны яхшы аңлаучыларның «яңача алымнарга» карата бер үк мөнәсәбәттә тормавын күрсәтә, режиссерларның һәм башкаларның да классик язучылар каршысында, милләт алдында этик җаваплылык мәсьәләләрен дә калкуландыра.

Әдәби әсәрнең яңача укылышы автор рөхсәте белән башкарылганда, чама сакланганда, кызыклы гына тамашалар туган очраклар байтак. Алай да теләсә кайсы чорны автор язганча аңларга тырышу дөресрәк булыр, чөнки әсәрнең яңалыгы вакыйга яңалыгында түгел – аңа салынган фикер яңгырашында, күтәрелгән проблемаларының актуальлегендә, алар исә заманнан заманга, чишелмичә, төсмерләрен генә үзгәртеп күчә бара.

Ю. Борев яңача укуның элекке укуларга каршы килмәвен, һәркайсының үзенчә дөреслеген әйтә. Ул хәтта бер үк вакытта яшәгән кешеләрнең дә төрлечә укырга хаклылыгын ассызыклый, әсәргә бу төр мөнәсәбәт рецептив этикага туры килә, ди. Гомумән алганда, дөрес тоелган фикерләр әйтсә дә, Ю. Борев заман укучысының автор каршында әхлакый җаваплылыгын бәяләп бетерми шикелле.

Әдәби әсәрне аңлауда субъективлыкка, индивидуальлеккә чиксез урын калдыру әсәрне махсус «бозып аңлауларга», субъективлыкны абсолютлаштыруга китерә. Алдарак без моның шулай икәнлеген күрсәттек тә. Әдәби тәнкыйтьнең нигезләрен салучылардан булган В.Г. Белинский шәхсилеккә урын калдырылган тәнкыйтьне дөньяны үзеннән генә башлана дип санаучы кешенең томаналыгы дип атаган[2], тәнкыйтьнең гомуми закончалыкларына таянуны, шәхси хисләрне читкә куеп торуны яклаган. Чыннан да, әсәр турында аның үзендә булмаган фикерләр чыгару тәнкыйтьченең белемсезлеген, тоемсызлыгын, зәвыксызлыгын, талымсызлыгын я булмаса ниндидер бер мәкерле максатларга хезмәт итүен

[1] Зайнуллина Г. Бег: беседа с искусствоведом Р. Султановой // Звезда Поволжья. 2005. 7–13 июля.

[2] Белинский В.Г. Полн. собр. соч.: в 13-и т. М.: Изд-ство АН СССР, 1955. Т. 6. С. 270.

сөйли. Дөрес, Ю. Борев үзе дә рецептив эстетикада чик концепцияләр дә яшәвен күрә һәм урыны белән аларга каршы да төшә.

Тәнкыйтьче шулай ук – укучы, ул әдәби фактка үз тәҗрибәсеннән һәм аңлау сәләтеннән чыгып якын килә. Субъектив аңлауның кешенең физик һәм рухи халәтенә, яшенә, психологик-шәхси үзенчәлекләренә, заманга бәйлесенә әдәби тәнкыйтьтә һәрвакыт урын кала. Бу күренешнең котылгысызлыгы белән килешкән хәлдә дә, тәнкыйть язмаларында әдәби әсәрне аңлатканда, чама хисен югалтмаска, иҗатка аек күз белән карарга тырышырга кирәк. Чама хисе, гомумән, сәнгатьнең барлык төрләренә һәм аларны яктырткан фәннәргә хас булырга тиеш. Әгәр ул югалса, матурлык, чынбарлык тамырына балта чабыла, әдәби тәнкыйть, мәсәлән, иҗатны алга җибәрүче, җәмгыятьне киләчәккә илтүче юллар күрсәтүче булудан туктый.

Теләсә кайсы социаль төркемнәр заман белән бергә үзгәрә бара. Гасыр эчендә, әйтик, руханиларның, мөгаллимнәрнең, крестьянның психологиясе бик үзгәргән. Әгәр XIX гасыр прозасындагы мулла, мөдәррис образларына заманабыз дин әһелләрен аңлау, хәзер башкарган функцияләрен белү ракурсыннан якын килсәк, аларны аз гына да ача алмабыз. Бүгенге руханилар, иҗтимагый тормышта, милли хәрәкәттә тоткан урыннары, сәяси-иҗтимагый карашлары, башкарган эшләре, хәтта дингә, хатын-кызның җәмгыятьтәге роленә һәм тагын бик күп нәрсәләргә мөнәсәбәтләре белән, бер гасыр элек яисә тагын да алдарак яшәгән шул социаль катламнан нык аерыла. Һәм бу, һичшиксез, әдәбиятта да чагыла.

Заман агымына иярү, дошман сыйныфларны сөймичә, алар язганнарга начар бер әйбер итеп карау үз вакытында вульгар социологизмга китергән, аерым бер социаль катлам вәкилләренең әдәби әсәрләрендәге уңай якларга күз йомдырган. Яңа шартларда без моны булдырмый кала алабыз, әмма тәнкыйтьчеләрнең үзләренең дә мөстәкыйль фикерле шәхес, төрле социаль чыгышка ия икәнлеген онытырга ярамый. Әле бит алар, аңлы рәвештә чор шаукымына һәм хаким даирәләр йогынтысына бирелеп кенә түгел, аңсыз да хата позициясен укучыга көчләп тагарга, фактларны бозып аңлатырга мөмкин. Бары тик фәннилек, фикер йөртүдә нигезләнгәнлек, тәгаен методологик принципларга таяну гына тәнкыйтьтә субъективлыкка урынны киметә.

Торгынлык елларында шулай ук кайбер тәнкыйтьчеләр, курку, идеологиягә буйсыну хисен алга куеп, шулай ук үзләреннән көтелгәнне язды, иң күркәм әсәрләргә дә тиешсез, эчтәлеккә туры кил-

мәгән ярлыклар такты. Бу чорда да хакимияткә оппозициядә тора дип фаразланган яисә чынлыкта да шулай булган әдипләр иҗатына алдан ук «советка каршы» фикерләр эзләп якын килүләр күзәтелде. Иң аянычлысы: вакытлы матбугат кубарган шау-шулар, аерым тәнкыйть язмалары кайвакыт каләм ияләренең мөһаҗирлеккә китеп баруына сәбәпче булды. Дөрес, татар әдәбияты тарихында, руслардагы кебек, узган гасырның икенче яртысында эмиграция дулкыннары күзәтелмәде, чөнки милли әдәбиятларга хезмәт итүчеләр аеруча көчле контрольгә алынган, рус әдипләренә караганда да ныграк куркытылган һәм бик сакланып иҗат итәләр иде.

Талантлы язылган әсәрләргә субъектив якын килеп, теге яки бу максатлардан чыгып, авторыннан кирәкмәгәнне – әдәби бөтенлеккә, образ логикасына зыян салырлык элементлар кертүне, совет идеологиясенә чиктән тыш яраклаштыруны, теге яки бу геройларны идеаллаштыруны, коммунист җитәкчеләрне уңай күрсәтүне һәм башка эш-хәлләрне таләп итеп язуга мисаллар үткәнебездә дә җитәрлек. Тәнкыйтьнең гаепләүле сүзе еш кына, әйтик, А. Гыйләҗев, Ә. Еники кебек талантлы, каләме кыю авторларга төште дә.

«Кайбер әдәбият белгечләре аскы агымы куәтлерәк булган «Берәү» повестена ныграк игътибар итеп, аның өске агымда яткан мәгънәсен социалистик реализм кысаларында карадылар. Аяз Гыйләҗевне тәкәббер герой иҗат итүдә, иҗтимагый-политик активлык җитенкерәмәгән шәхес образын тудыруда гаепләделәр. Исхакның гамәлләре коммунизм төзүче совет кешесенең әхлакый кодексына туры килми дигән белдерүләр дә ишетелде. Әйтик, филология фәннәре кандидаты Рафаэль Мостафин бер мәкаләсендә[1] әдипне чынбарлыкны артык каралтып күрсәтүдә гаепләде»[2], – дип яза Ә. Сәхәпов.

Р. Мостафинның «Берәү» әсәренең герое Сәлихнең тискәре персонаж булуында образ логикасы юклык күрүе гаҗәпләндерә, чөнки аның барлык эш-хәрәкәтләре нәкъ киресен сөйли. Элекке колхоз рәисе Сәлих колхоз икмәген дә урлый, атып, каравылчы Нурулланы да яралый, башка начарлыклар да кыла. Ул гомер бакый имансыз, кешелексез булган. Совет әдәби тәнкыйте автордан бу төр тискәре геройларны буржуаз тормыш калдыклары, чит ил пропагандасына

[1] Мостафин Р.Ә. «Берәү» повесте һәм аның тәккәбер герое // Алга барышлый: тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Б. 63–66.

[2] Сәхәпов Ә. Кырыс чынбарлык. Казан: Мирас, 1995. Б. 26.

бирелүчеләр рәвешендәрәк аңлатуларны, кискен тәнкыйть итүне һәм автордан ачыктан-ачык, ул – чын совет кешесе түгел, социалистик илдә алар яшәргә хокуксыз, андыйлар инде чынлыкта аз, кебек нәтиҗәләр чыгаруны таләп итте. Бу таләп исә, үз чиратында, әдәбиятны примитивлаштыруга, бертөслелеккә, объектив эчтәлеккә ия булмауга алып килә иде.

Р. Мостафин әлеге дә баягы «„Берәү“ повесте һәм аның тәкәббер герое» мәкаләсендә: «Без бу образның логикасын, характерының умыртка сөяген, аны хәрәкәткә китерә торган пружинасын аңламыйбыз. Район вәкиле, карьерист Тазюков образы турында да шуны әйтергә кирәк»[1], – дип белдерә. Тәнкыйтьченең шушы рәвешчә белдерүләрендә әдәбиятның совет җитәкчеләрен бары тик уңай планда гына тасвирлавын, аларны тарихны алга таба – коммунистик җиңүләргә алып баручылар сыйфатында яклавы чагылыш таба. Р. Мөхәммәдиевнең төп герой Исхакны «иҗтимагый-политик активлык җитенкерәмәүдә»[2] гаепләве шулай ук норматив тәнкыйть кысаларында язарга тырышудан килә иде дип саныйбыз.

Инде Яңа заманда А. Гыйләҗевнең һәр әсәреннән системага каршы көрәшүчене эзләргә алынган Ә. Сәхәпов үзе дә бәяләмәләрдә чикне онытып җибәрә шикелле. Башта «…көчле система тарафыннан ихтыяр көче сындырылган кеше тиз генә көрәшче була алмый. Аяз Гыйләҗев үзалдына андый көрәшче образын тудыру бурычын да куймый. Ул бүгенге чынбарлык белән ризалашмаган герой белән, аның язмышын төрләндерә алган чор образын бергә бәйләп иҗат иткән һәм шәхеснең рухи азатлыгы чикләнгән шартларны күрсәткән»,– дип белдерсә дә, ахыр чиктә: «Әдәбият белгече, алай эшләмә, системага тимә дип тукып торганда, Аяз Гыйләҗев киресенчә, куана-куана, көч-куәте Тазюковларда, Гыйльми Салихларында булган социалистик тәгълиматны Исхак кулы белән җимертмәкче була», – дигән нәтиҗә ясый.

А. Гыйләҗевның «Берәү» повестенда системаның үзе белән ныклап көрәшергә алынган каһарманнар турында сөйләү артык, әлеге әсәрдә мондый зур гомумиләштерүләр ясарга дәлилләр җитеп бетми, анда аерым җирлектәге конфликтлар калку чагылыш таба. Бу укучы өчен вакытына күрә мөһимрәк тә. Әдип гадел

[1] Мостафин Р.Ә. «Берәү» повесте һәм аның тәккәбер герое Б. 63–66.
[2] Мөхәммәдиев Р.С. Күңелдәге эзләр // Якутлар табыладыр вакыт белән: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Б. 141.

булырга, кешеләре тигез, туганнарча һәм бер-берсен кайгыртып яшәргә тиешле дип корылган, күпләр шуны сакларга гомерен биргән дәүләттә дә көнчелләр, караклар, уртак малга кул сузучылар, шәхсилек чире белән авыручылар барлыгын тасвирлый.

Автор «Берәү»дә тормыштагы, ил белән җитәкчелек итүдәге тискәре күренешләргә каршы торучыларның образларын тудырмый түгел, тудыра. Алардан, чор таләп иткәнчә, колхозның яшь белгечләренә, үзен халыкка уңай яктан күрсәткән яңа рәискә игътибар зуррак бирелгән. А. Гыйләҗев башкаларны да алар кебек гадел булырга, гомерләрен, көчләрен кызганмыйча, совет илен төзешкән карт-карчыкларны якларга һәм башка изге гамәлләргә чакыра. Ул шулай ук өлкән буынга лаеклы алмаш калдыру-тәрбияләү проблемалары, авыл кешеләре тормышын җиңеләйтү кирәклеге хакында сөйли. Аның герое Исхак сугышның чын адәмнәрне юкка чыгаруы, бигрәк тә авыл җирендә җаваплы эшләрне үз җилкәләренә күтәрерлек ир-атларның аз калуы, сөйгән ярларның, ихлас дусларның берәү генә булуы турында уйлана.

Әсәр атамасының мәгънәсе үтә киң. «Берәү» төшенчәсе һәр геройга карата кулланыла ала, чөнки образлар монда бер-берсен кабатламый, үзенчәрәк уйлый, үзенчәрәк яши, һәрберсе – кемнеңдер, кемнәрнеңдер бердәнбере. Төп герой Исхак кына түгел, тискәре пландагы җитәкчеләргә каршы куелган колхоз рәисе Хөсәен дә – әнә шул «берәү»ләр төркемендә. Шунысы да бар: Исхак кайчандыр үзен гашыйк иткән һәм гүзәллектә, дуслыкта «бер» генә тоелган Саниягә охшаш кызны барыбер очрата. Ә бит Сания исеменең мәгънәсе икенче дигәнне аңлата... Төп герой бер Санияне югалта, икенчесен таба. Тормыш дәвам итә, «берәү»ләр урынына я янәшәсенә икенчеләр килә, охшашрак фикер йөртүчеләр әкренләп ишәя. Әсәрнең ахыры бик якты төсләрдә тәмамлана. Инде Исхак авылда, үзенә якын кешеләр арасында, ата-бабалар көткән матур тормышны алга таба да төзер өчен яшәп калыр кебек тоемлана.

Төбенә төшеп караганда, «Берәү» повесте совет чорында да тәнкыйть ителерлек әсәр түгел. А. Гыйләҗев анда тормышның, бигрәк тә авылдагы яшәешнең барлык күңелсез якларын ачса да, боларны юкка чыгарга тиеш, чыгачак күренешләр итеп күрсәтә. Әдип Явызлык һәм Яхшылык көрәшенең мәңгелек тарихын аерым бер вакыт аралыгында сурәтли. Ул әлеге көрәштә яхшы кешеләрнең җиңәчәгенә өмет утын сүрелдерми. А. Гыйләҗев Исхакны, төрле рухи чигенешләр ясый-ясый, авылның киләчәген кайгыртучыларның

берсе булырга тиешлеген чын-чынлап аңлауга алып килә. Әгәр автор тормыштагы тискәре күренешләрне киметебрәк тасвирласа, җитәкчеләр арасыннан да тискәре образлар тапмаса, аны совет тәнкыйте хәтта кирәгеннән тыш мактарга да мөмкин иде.

А. Гыйләҗев, югарыдан ярдәмгә җибәрелеп, асылда зыян гына салып йөргән Мөнир Тазюковны, социалистик тәгълимат тарафдары булудан битәр, белмәгән эшләренә тыкшынуы, авылда тәртип оештыруны өстән төшкән боерыкларны анализламыйча, берсүсез, акылсыз рәвештә үтәтүдә күрүе, җирле идарәнең уйлап эшләгән адымнарына каршы төшүләре, кешеләр арасында, бәхәсле моментларда үзен соң дәрәҗәдә ахмак тотышы өчен гаепли. Әсәр 1958 ел вакыйга-күренешләрен сурәтләүдән башлана, язылу датасы исә 1959 дип билгеләнгән. Бу вакытта шәхес культы, аның кырыс тәртипләре партия тарафыннан көчле тәнкыйтькә алына. Шулай булгач, повестьта да ил җитәкчелеге яңгыраткан кайбер тәнкыйди рухтагы карашлар да чагылыш таба.

Ә. Сәхәпов А. Гыйләҗев әсәрләренә әйтелгән һәр язманы авторының теге яки бу геройның тоталитаризмга каршы көрәшкәнлеген тану-танымавыннан, күрү-күрмәвеннән килеп бәяли һәм шулай ук тәнкыйтьне бер кысага куып кертергә омтыла. «Адәм баласының мәхәббәт, эшкә бирелгәнлек, мал-мөлкәт туплау, мул тормышта яшәргә омтылу кебек табигый инстинктларын санга сукмаган тоталитар система тәгълиматы яссылыгында Мирвәли образын аңларга тырышу тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиевнең «Күңелдәге эзләр»[1] мәкаләсендә дә сизелә. Аерым алганда, Ринат Мөхәммәдиев Миргалинең фаҗигасен шәхсән үзеннән күрә»,– дип белдерә ул һәм тәнкыйтьченең түбәндәге сүзләренә күчә: «Шәхси милекчелек психологиясендә тәрбияләнеп, мин-минлеге чамадан тыш зур булган Мирвәли әтисе җыйган мал-мөлкәтнең, колхозлашу чорында авылдашлары белән уртакка бүленүеннән куркып, барын юкка чыгара, яндыра. Моның белән генә колхоз зур югалту күрми, әлбәттә, ә Мирвәлинең үзе өчен ул кыйммәткә төшә. Авылдашларыннан, үскән җиреннән аерыла, кешеләргә булган ышанычын, кешелеклелек хисләрен югалта. Үзсүзлелек, усаллык, нәфрәт һәм мәкер белән тулы гомер уздырган кешенең язмышы ничек һәм ни дәрәҗәдә ямьсез һәм мәгънәсез рәвештә тәмамлана икән – Мирвәлинең соңгы

[1] Мөхәммәдиев Р.С. Күңелдәге эзләр. Б. 142–143.

көннәре һәм шул көннәрдә аның башыннан узганнар моңа табигый һәм ышандыргыч дәлил булып тора».

Р. Мөхәммәдиевтән китерелгән өзек повесть белән яхшы таныш укучыларның зур күпчелегендә бәхәс уятмыйдыр дип уйлыйм. Автор язган әсәр һәм тудырган фикер – бер нәрсә, аннан икенчене күрергә теләү – башка. Тәнкыйтьче әдәби берәмлеккә, заманга һәм чор идеологиясенә бәйле генә түгел, ә, беренче чиратта, әсәрнең эчтәлегеннән чыгып якын килергә тиеш.

Ә. Сәхәпов: «…тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиев тә, тәнкыйтьче Мансур Вәлиев кебек үк, Мирвәлине гаепләү, аның фаҗигасен шәхси җирлеккә генә кайтарып калдырырга тырышу юлыннан киткән һәм Аяз Гыйләҗевнең Мирвәли образы аша халыкны икегә аерган, җәмгыятьне капма-каршы лагерьга бүлгән тәгълиматны гаепләргә омтылуны күрә алмаган. Мирвәлинең ачуы, усаллыгы, кешеләргә карата түгел, ә бәлки аларны кол хәленә төшергән, сүзсез буйсынырга мәҗбүр иткән аяусыз һәм вәхши системага, җәберзолым һәм фаҗигаләр тудыручы дәвергә юнәлдерелгән»,– дигән зур гомумиләштерүләр ясый.

А. Гыйләҗев, кыю сүзле зур талант иясе буларак, норматив тәнкыйть таләпләреннән читкә чыгып язса да, реаль чынбарлыктагы җитешсезлекләрне һәркем тотып алырлык тасвирласа да, совет иленә, социалистик системага каршы булмады. Бу хакта аның укучылар белән очрашуларда үзенең дә әйткәне бар. Әгәр, Ә. Сәхәпов күзаллаганча, чыннан да, А. Гыйләҗев үз әсәрләрендә инде илленче-алтмышынчы елларда ук совет системасы белән шулкадәр ачыктан-ачык көрәшкән икән, ул иҗат иткән китапларның берсе дә дөнья күрмәс, ә үзе яңадан сәяси яктан зарарлы әдип буларак хөкемгә тартылыр иде.

Әдипнең кайбер әсәрләрендә идеалда күзалланган социалистик-коммунистик яшәеш белән чынбарлыктагы тормышның бер булмаганлыгын күрсәтүе системаны җимерү өчен түгел, ә камилләштерү өчен икәнлеге ап-ачык. Болай язу исә «шәхес культы» тәнкыйтьләнүгә кайтаваз булып тора һәм 1956 елгы үзгәрешләрдән соң инде мөмкин иде.

Торгынлык чорында татар әдипләре, социалистик системага «ят» образларны тудырганда, аларның шәхси милекчелеген, гомуми тәртипләргә буйсынмавын кире какты. Язучылар шулай ук башкалар чит күргән, тормышта җиңүләргә шанссыз, үзен хокуксыз яисә хокукларында чикләнгән дип санаган кешеләргә, ягъни

аутсайдерларга җәмгыятьтә яшәү авырлыгын, артык «шәхсилек»-нең драмага, фаҗигагә китерүен сөйләде, әмма әлеге геройлар ярдәмендә, системаның тамырына балта сукты дип булмый.

Тоталитар система шартларында яшәүче әдипләр, гомумән, тәнкыйтьнең субъективлыгыннан да, аны шундый иткән хакимияттән дә сагаеп яза, кайвакыт кыю сәяси эчтәлектәге әсәрләрен бастырырга җөрьәт тә итми. Сталин репрессияләре турындагы китаплардан И. Салаховның «Тайгак кичү» («Колыма хикәяләре») фаҗига-хроникасын исебезгә төшерик. «Шәхес культын фаш итүгә зур өлеш керткән Н.С. Хрущев властьтан читләштерелгәч исә, әдипнең языла башлаган әсәре ярты юлда тукталып кала, җир астына күмелә. Чөнки Хрущевтан соң сталинизм дәверенә тәнкыйтьчел караш рәсми төстә тыела башлый»[1], – ди Л. Минһаҗева, әлеге хезмәткә мөнәсәбәттә фикер йөртеп. Ә бит, авторның истәлекләреннән күренгәнчә, «Тайгак кичү» исеме белән язылып беткәннән соң да, әсәр озак еллар басылмый: «Мин аларны, төпләтеп, берсен – Казанга, икенчесен – Уфага, …ә инде өченче нөсхәсен, кат-кат төреп, тимер әрҗәгә салып, җир астына күмеп куйдым»[2].

1977 елда И. Салаховның «Тайгак кичү» китабын чит илдә чыгару мөмкинлеге дә туа, әмма ул аның башта үзебездә һәм татарча дөнья күрүен тели[3]. Шул ук вакытта моның бер хәйләкәр сылтау гына икәнлеге, авторның, алай эшләгәндә, үзеннән яңадан «халык дошманы» ясауларыннан курыккан булуы да бар.

Кайчандыр И. Салахов «Колыма хикәяләре»н, хакимият тыйган очракта юк ителүеннән куркып, җиргә күмгән кебек хәлләр бүгенге көндә юктыр, әмма бу тыелган темалар бетте яисә әдип, ничек тели, шулай яза дигән сүз түгел. Тәнкыйтьнең гаделсезлегеннән, аның белән хәзер тагын да остарак, яшеренрәк идарә итүче хаким төркемнәрдән сагаю әдипне һаман да бик күп темаларны күтәрүдән, аңлаганча ук язудан һәм проблемаларның чишелешен теләгәнчә яктыртудан тыеп килә. Алга таба сүз иреге нык киселгән шартларда «җиргә күмелгән әсәрләр» булачакны да фаразлау мөмкин.

Әдәби әсәр еллар узгач та бер үк төсле бәяләнсен, әдибе моңа кадәр ирешкән мәртәбәсен югалтмасын өчен, шәрехләүнең тотрык-

---

[1] Минһаҗева Л. Ибраһим Салахов (тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Матбугат йорты, 1999. Б. 71.

[2] Салахов И. Киләчәк буыннар белсен // Соц. Татарстан. 1988. 4 декабрь.

[3] Минһаҗева Л. Ибраһим Салахов (тормышы һәм эшчәнлеге). Б. 73.

лылык факторлары үзгәрешсез калырга тиеш. Ю. Борев төзегән энциклопедик сүзлектә әдәби әсәрне интерпретацияләүдә тотрыклылык шартлары бик ачык тәгаенләнә. Болар: текстның үз эчендәге әдәби концепция, эчке кичерешләр, эстетик юнәлгәнлек программасы һәм текстның реаль социаль феноменга – аны сәнгатьчә әсәргә әверелдерүче социаль-мәдәни контекстка караганлыгы[1].

Әдипләр югарыда күрсәтелгән пунктларны күздә тотып эш итсә, әсәрләре гасырлар дәвамында адресатлары тарафыннан нәкъ авторы теләгәнчә аңлашыла ала. Бәяләүчеләр исә гыйльми тикшерү объектларына шул ук яссылыклардан һәм объектив якын килергә тиеш. Менә ни өчен каләм ияләребезнең, әйтик, роман-повестьларында, поэтик текстларында фикерләрен милләт алгарышына хезмәт иттерүне күздә тотып уздырганнары, тормыш материалына үз халкының фәлсәфи-эстетик, иҗтимагый-сәяси күзаллауларыннан якын килгәннәре һәм югары кимәлдә иҗат иткәннәре киләчәк буыннар күңелендә дә яши, теге яки бу әсәрләре озак гомерләр дәвамында милләттәшләребез тарафыннан югары бәяләнә, тарихи-әдәби сәхифәләрдән сызып атылмый.

Тәнкыйтьченең объективлыгы һәм субъективлыгы хакында бәхәсләр кайвакыт сайлап алынган материал аркасында туа. Әдәбиятның үзендә дә шул ук хәл. Әйтик, язучы аерым бер социаль катлам вәкиле тормышын гына чагылдырырга теләгән ди. Моның өчен кече күләмле жанр формалары алынса, вакыйгалар барган заман тулы чагылыш таба алмый, ә инде повесть-роман сайланса, язучы чынбарлыкны тулырак чагылдыру мөмкинлегенә ия. Г. Исхакыйның яшь чагында язылган «Тәгаллемдә сәгадәт...» хикәясе белән каләме камилләшкәч иҗат иткән «Мулла бабай» романын искә төшерик. Икесе дә асылда каһарманның муллалыкка үсү юлын чагылдыра. Ә тирәнлек, тулылык дәрәҗәсендә нинди аерма! Тәнкыйтьче дә, проблемаларны никадәр киңрәк алса һәм тулырак ачса, шуның кадәр объективрак күренәчәк.

Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Тәнкыйть еш кына авторның материал сайлауга хокукын танымый, аннан аеруча күләмле прозада киңлек, масштаблылык таләп итә. Хәер, ул аңа шулай ук хокуклы. Язучы үзе исә хәтта романда да заманны тулы яктыртуны зарурият санамаска мөмкин. Моны XX гасыр ахырында дөнья

---

[1] Борев Ю.Б. Эстетика // Теория литературы: энциклопедический словарь терминов. С. 278.

күргән «юка» романнар белән расларга булыр иде. Алар татар әдәбиятында да бар. Мәсәлән, Флүс Латыйфи үтә кече күләмле һәм шактый гади сюжет сызыклы, шул ук вакытта тирән мәгънәле, «хыянәт» төшенчәсен төрле яссылыкларда ачкан һәм хаклы рәвештә шулай аталган әсәрендә, хәтта үзәккә куелган сәүдәгәрләр тормышын да тулы тасвирлый, тарихи чорны масштаблы тудыра, дип әйтеп булмый. Бу, бәлки, Ф. Латыйфиның аны максат итмәвенә, ә, бәлки, узган заманга караган материалны начар белүенә, җитәрлек тупламавына бәйледер.

Гомумән алганда, кече күләмле тарихи романнарда документларга аз таяну, маҗаралылыкка яисә көтелмәгән сюжет борылышларына күп урын бирү аны әкиятирәк рухтагы повестьларга, «көнчыгыш хикәят»ләренә тартым итә башлый. Флүс Латыйфиның «Хыянәт»е белән дә эш шулайрак тора, һәм ул, жанр сыйфатламаларыннан чыгып фикер йөрткәндә, романныкына түгел, ә повесть таләпләренә җавап бирә дип уйлыйбыз. Әгәр язучы үз әсәренең жанрын төгәл билгеләсә, бу урында сүз дә башкачарак барыр иде.

Кызганыч ки, еш кына әсәрнең жанрын редакторлар билгели һәм авторның әлеге проблеманы чишүдәге хокукын чикли. Бу фикерне без әдибә буларак һәм ачы иҗат тәҗрибәсенә таянып, моңа кадәр язылган әсәрләрнең кайберләре, сюжет таләпләреннән чыкканда, повесть дип саналырга тиешлеккә карамастан, укучыга хикәя дип тәкъдим ителгәнгә әйтәбез.

Инде гасыр башы прозасын искә төшерик. Гали Рәхимнең «Идел»ендә зыялылар ялы, алардагы романтик рухият укучы күзалларлык яктыртыла, һәм нәкъ менә сайланган материал аркасында ул үз чорында да еш кына тәнкыйтькә очрый, совет чорында басылмый. Тәнкыйтьчеләр киңәшенә ияреп, башка катламнар тормышыннан алынган эш-хәлләрне повестька кертү аның сәнгатьчә каймасына, яңгырашына зур зыян салыр иде. Хәтта ки әсәрдә тасвирланган зыялыларның көндәлек хәятыннан икенче төр күренешләр өстәү дә аннан алыначак эстетик ләззәтне киметәчәк, чөнки ул соң дәрәҗәдә бөтен оешкан.

Тәнкыйтьче, әсәр тормыш чынбарлыгын мөмкин кадәр тулы чагылдырырга тиеш, дигән принцип белән эш йөртеп, кискен боерыклар бирүне гадәт итсә, тыштан караганда, объективлык тарафдарыдай күренер, ә асылда берьяклы хөкемдар, әсәрнең нинди максаттан язылганлыгын, шул максатка хезмәт иткән чималны, идея-тематикасын аңламаучы булыр. Сайланган материал ачылма-

ганда, ул җитәрлек дәрәҗәдә – проблема күтәрерлек һәм чишәрлек файдаланылмаганда исә, укучыда чынбарлык күренешләренә бәйле объектив фикерләр формалашмаска яисә әдәбиятта заман күренешләре табигый чагылмаска мөмкин. Бу очракта тәнкыйтьченең әдәбиятта тормыш материалын тулыканлы яктыртуны проблема дәрәҗәсенә күтәреп язуы – намус эше булып тора.

Әдәби тәнкыйть гыйлеме, үзе белән шөгыльләнүчегә шундый тәкъдимнәр ясаса яисә таләпләр куйса да, алар һәрвакытта да үтәлми – кеше үз күзаллауларының колы булып кала. Бигрәк тә инде аңына сеңгән, заман идеологиясе белән ныгытылган карашлардан арыну авыр. Әдип яисә шагыйрь өчен үтә гади тоелган хакыйкатьләрне дә кайчак тәнкыйтьченең генә түгел, иҗатташларының да аңлый алмавы, бер яктан – кешеләрнең фикерләү дәрәҗәсендәге, икенче яктан, әдәбиятка якын килү принципларындагы, күзаллауларындагы аермаларга килеп тоташа.

Сәнгатькәрдән үзе иҗат иткән әсәрдә реаль чынбарлыктагыча тулылык таләп итүчеләр дә, артык детальләштерүне көтүчеләр дә юк түгел. Тәнкыйть белән шөгыльләнүченең тормыш тулылыгы белән әдәби әсәр тулылыгын аера алмавы – аның фаҗигасе, тоемсызлыгы, иҗатның, гомумән, ни икәнен белмәве. Андыйлар чынбарлыктан материалның сәнгатьчә әһәмиятлесе генә сайлап алынганны аңламый. Каләм иясенең шәхси әдәби иҗеге дә барлыгын онытмаска кирәк. Кемдер кызыклы детальләрне әсәргә мулданрак кертә, кемдер хисләргә күбрәк урын бирә, кемдер шартлы сызыклар белән генә картина язган рәссам кебек эш итә. Әдип тә стиленең колы булып калгалый, хәтта кирәк чакта да аны үзгәртә алмаска мөмкин. Каләм иясеннән булдыра алмаганны яисә теләмәгәнне таләп итү дә урынсыз.

Үзгәртеп кору елларында китап продукциясе шактый төрләнде, әмма әдәби тәнкыйть һаман да бу төрлелеккә күнегә алмый, ул, әйтерсең, аннан куркып калды. Тәнкыйтьче, кыю һәм иманлы булганда гына, язучы яшәгән чорда ук аның бихисап җитешсезлекләргә ия, милләтнең әдәби зәвыгына, аннан да бигрәк үзаңына, күзаллауларына, киләчәктәге язмышына зыян салырлык әсәре хакында объектив фикерен әйтә ала. Гүзәл Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» (Зулейха открывает глаза.–2015) әсәре дөнья күргәннән соң басылган күпсанлы тәнкыйть мәкаләләре моның шулай икәнлеген ачык күрсәтте. Бары тик милләтпәрвәр шәхесләр һәм үзләре дә чын мәгънәсендә югары сәнгать әсәре тудырган, бигрәк тә иҗтимагый-тарихи темада актив эшләгән зур талантлар, шул

темага язылган әсәрләрне ныклап өйрәнгән галимнәр әлеге әсәрне көчле тәнкыйть утына алды. Алар арасында Р. Батулла, В. Имамов, М. Хабетдинова, Р. Рахман һәм башкалар бар иде.

Матбугатта, төрле әңгәмәләр вакытында кискенрәк яңгыраган фикерләр дә ишетелде. Әсәрнең төзелешеннән, стиль күчешләреннән чыгып, В. Имамов хәтта Гүзәл Яхинаның авторлыгын да кире какты, ә үзен милләтен сатучы дип атады. Тәнкыйтьче укучы игътибарын шулай ук әдибәнең тарихны белмәвенә, фантазиягә урын бирүенә юнәлтте[1]. В. Имамов «Мәдәни җомга» газетасының 2016 ел, 4 февраль санында «Тешкә тигән Зөләйха» мәкаләсендә түбәндәгеләрне язып чыкты: «Гомумән, Яхина ханым әкиятләр язарга үтә һәвәс. Аның романында үз гомерендә кулына тәүге тапкыр мылтык алган Зөләйха беренче ядрәсе белән үк аюны атып үтерә. Икенче тапкырында санаулы секундлар эчендә алты явыз бүрене юк итеп өлгерә ул». Автор үз мәкаләсендә, бик хаклы рәвештә, әсәрнең тормыш чынлыгыннан ерак торуын күрсәтә һәм югарыдагы өзектә дә фикерен әсәрдән китерелгән аерым күренешләр аша дәлилли.

Филология фәннәре кандидаты, КФУ доценты Миләүшә Хабетдинова әсәргә шактый тулы анализ бирде һәм шулай ук тискәре нәтиҗәләргә килде – вакыйгалар барган чорда татарларның мәҗүсилек йолаларын тотмавын, шуларны тасвирлаган Гүзәл Яхинаның, гомумән, татар тормышын белмәвен язып чыкты. XXI гасырның иң талантлы яшь каләм ияләреннән булган Рүзәл Мөхәммәтшин да: «Автор татар тормышын да, татар традицияләрен дә белми һәм тоймый»,– дигән фикер әйтте[2].

Рус тәнкыйтьчеләре әсәрнең сәнгатьчә эшләнешендәге кимчелекләрен күрсәтсәләр дә, гомумән алганда, эчтәлек ноктасыннан романны югары бәяләде, чөнки алар өчен анда татарның ничек тасвирлануы, автор объективсызлыгы аркасында йөрәге җәрәхәтләнүе мөһим түгел иде. Татар язучылары шулай ук романның сәнгати эшләнешенә караган җитешсезлекләрне дә билгеләгән бер чакта аны тәрҗемә итүче Флера Тарханова исә: «Талантлы язылган»,– дип белдерде[3]. Алга таба тәнкыйть инде игътибарын күпсанлы тәрҗемә кы-

[1] Вахит Имамов о романе «Зулейха открывает глаза»: «У женщины для этого не хватит ума» // Бизнес-онлайн, 2016. 31 января. https://www.business-gazeta.ru/article/300676.

[2] Шунда ук.

[3] Шунда ук.

тыршылыкларын ачуга юнәлтте. Шулай итеп, көчле пиар аркасында һәм зәвыксызрак киңкатлам укучы ихтыяҗын күздә тотканлыктан, аның яклавын тапканлыктан, зур тираж белән басылган «Зөләйха күзләрен ача» романы сәнгатьчә эшләнеше ноктасыннан ике тапкыр зур тәнкыйть кичерде. Аның тирәсендә татар вакытлы матбугатында башланган бәхәс рәсәйкүләмгә әверелде.

Шунысы начардыр: роман чыгудан матди табыш алган җитәкчеләр, сәхнәләштерүчеләр, тәрҗемә итүчеләр, сатучылар һәм башкалар халыкка аны һәрдаим уңай пропагандалады, ахыр чиктә ул Татарстанда да, дөньяда да югары рейтинглы китаплар исемлегенә керде[1]. «Зөләйха күзләрен ача» XXI гасырда чыккан китаплар арасында татар тормышын иң бозып күрсәткәне, җитмәсә, сәнгати ноктадан кайтышы да булуына карамастан, киң мәйдан яулады, ахыр чиктә укучының дөньяны, узганны субъектив күзаллауларын формалаштыруда, зәвыгын түбәнәйтүдә бик зур роль уйнады. Татар басма сүз тарихында, публикага тәрбияви-эстетик зыян салу ноктасыннан караганда, Г. Гобәйнең атеистик тәрбия проблемаларына багышланган «Коръән серләре» (1967) исемле күләмле публицистик хезмәте дә аның белән ярыша алмый иде, чөнки ул чын мәгънәсендә иманлы кешеләрне дененнән яздыра алмады.

«Зөләйха күзләрен ача»га мөнәсәбәтле бәхәснең озак вакытлар дәвам итүе киңкатлам укучылардагы фикерләрнең капма-каршылыгы аркасында иде. Бигрәк тә татарның урыслашуын яклаганнар, урыслашканнар, урыслаша башлаганнар, уртакул кимәлдә язучылар, әдәбиятны хакимияттә утыручыларга ярарга тырышып тәнкыйть итүчеләр яисә мактаучылар, күрәләтә торып, татар тормышын дөрес аңлатмаган, кайбер тискәре геройларын, чынлыкка хилафлык күрсәтеп, теге яки бу социаль төркемнең типик вәкиле итеп тасвирлаган, татарда үз милләтенә нәфрәт уятуны алга куйган, урыслаштыру коесына су койган әсәрне яклау юлына басты. Чыннан да, әдәби тәнкыйть – галимнең дә милләткәме, әллә үзенә яисә тар даирә мәнфәгатьләренәме хезмәт иткәнлеген күрсәтеп тора һәм аның әхлагын сынау мәйданыдыр. Шуны да онытмыйк: нәкъ менә язучы исән чакта әсәрләре хакында тәнкыйть сүзләре җиткерү әдәби бәхәсләргә, ә ул исә, үз чиратында, хакыйкатькә юл ача. Вакытлы матбугатта басылган мәкаләләрнең, эфирда

[1] Татарстан китап нәшрияты директоры иң күп сатылган китапларны атады // Безнең Чирмешән. 2017. 28 сентябрь.

яңгыраган чыгышларның полемик характер алуы укучыда әсәрнең үзе белән танышу теләге уята.

Гомумән алганда, объективлык белән субъективлык – диалектик күренешнең ике ягы, әдәби әсәрне бәяләгәндә чама хисен югалтмау аларның чагыштырма нисбәтен уңышлы көйли. Сәнгатьтә бар нәрсә чама белән булганда гына, гүзәл әсәрләр туган кебек, тәнкыйтьтә дә читкә тайпылышлар кабул ителми.

Нәфис текстны субъектив бәяләүгә һәм төрлечәрәк аңлауга китерүче берничә шарт-сәбәп бар. Болар: тарихи чорның сәнгать тәҗрибәсе; тәнкыйтьченең шәхсилеге һәм теге яки бу рецептив төркемгә каравы; әдәби әсәрне укыганда, анализлаганда кичергән психологик халәте һәм әсәрне тикшерү-өйрәнү чаралары, методлары. Тәнкыйди анализның камил эшләнгән бөтен методологик системасы оешканда, әдәбиятчының аны куллануга, әсәрне аңлауга шәхси мөмкинлекләре зур һәм төп максаты әдәбиятны, әдипләрне үстерүгә хезмәт итү булганда исә, каләме чорны объективлык дәрәҗәсе белән канәгатьләндерерлек хезмәтләр язачак.

## 1.6. Әдәби тәнкыйтьнең объектлары

Сүз ярдәмендә иҗат ителгән теләсә кайсы *нәфис текст*, нинди эстетик югарылыкка ия булуына карамастан, тәнкыйтьче тикшерүенә куелырга тиеш, чөнки аның алдында әдәби мәйданны чүп-чардан арындыру, югары пробалы сәнгать әсәрләренең классика статусы алуына булышу, түбән зәвыклы халык массаларын яисә примитив интеллектлы укучыны күздә тотып язылган, киң таралучан «базар» әдәбиятын дәреслекләргә кертерлек, югары уку йортларында укытырлык сәнгати мирастан аеру бурычы тора. Гади укучының күпчелеге китапта, вакытлы матбугатта урын алган әдәби әсәр инде сайлау узган һәм яхшы дип ышана, әнә шуңа күрә публиканың нинди зәвыкка ия булуы өчен, беренче чиратта, сәнгати камил булмаган текстларны басмага чыгарган редакторлар җаваплы. Озак вакытлар яхшы әсәр укымаган кеше чиле-пешле текстларга күнегә, аларга хирыслыгы арта.

Массалардагы әдәби зәвыкның түбәнлеге өчен җаваплы икенче төркем – тәнкыйтьчеләр. Алар тарафыннан газета-журналларга күренекле әдипләрнең иң яхшы әсәрләренә генә түгел, башлап язучыларның чиле-пешле хезмәтләренә дә уңай бәяләмәле мәкаләләр җибәрелә. Дөрес, уртакул әсәрләр күбрәк күзәтү характерындагы язмаларда чагылыш таба, башка текстлар янәшәсендә саналып

үтелә. Болай эшләгәндә дә, укучыда дөрес әдәби ориентирлар калыплашмый.

Исеме дан алган иҗатчыларның буш әйберләрен мактау, хәтта аерым очракларда әдәби шедевр сыйфатында күрсәтү соңгы заман тәнкыйтенең котылгысыз чиренә әверелде. Инде киңкатлам укучыда моңарчы макталып кына килгән каләм ияләре гел яхшы әсәр генә яза дигән хата фикер бик нык урнашты. Бүгенге тәнкыйтьче әнә шундый зарарлы күренешләргә каршы торырга, каләм ияләре арасыннан үзенә фикердәшләр тупларга һәм аларны әдәбиятны сафландыру эшенә тартырга тиеш.

Тәнкыйтьченең бер вазифасы – кәгазьгә басылган түбән эшләнешле әсәрне генә түгел, югары кимәлдә язылганын да күреп алып, популяр-фәнни тел белән әлеге дә баягы сәнгатилек дәрәҗәсен аңлатып бирү. Һәр әсәр – тулы анализга, ә һәр автор, килешәме ул аның белән – юкмы, үз иҗатына лаек бәя алырга хокуклы. Әдәбият мәйданына яңа аяк басучыларның иҗатын тәфсилле чагылдырган мәкаләләр башка тәүге тапкыр каләм тирбәтүчеләргә дә гыйбрәтле сабак бирәчәк.

Язучыларның әдәби ел йомгакларында, объектив һәм субъектив сәбәпләр аркасында, төп журналларда, нәшриятларда дөнья күргән әдәбиятка гына күзәтү ясала. Китап базарына чыгарылган һәр продукция, коммерция нигезендә һәм аеруча Казаннан читтә бастырылган китаплар үз вакытында бәясен алмый кала. Тәнкыйтьчеләр яшь каләм тибрәтүчеләрнең дә әдәби зәвыгын үстерүдә төп рольне уйнауларын онытып җибәрә.

Тәнкыйтьче иясеннән дә озынрак гомергә хаклы әсәрләрне, дөрес бәяләп яисә эчке тоемы аркасында, анализ объекты итеп ала икән, шәхси язмасының да озак яшәренә, киләчәк галимнәре искә алуына өметләнә торгандыр, чөнки тәнкыйть мәкаләләре аерым иҗат буенча күләмле фәнни хезмәтләр язылганда әйләнешкә керә, алардан өзекләр китерелә, үзләре исә еш кына күптомлыкларда да урын ала.

Кайбер тәнкыйтьчеләрнең киләчәктә классика саналачак әсәрләргә генә игътибар итүе шәхси мәнфәгатьләрне дә күздә тотудан булгалый. Танылган яисә яхшы язучы авторларны мактау җиңел, язганнарының җитешсез яклары әзрәк һәм, булып та, аларны «күрмәскә» мөмкин. Тәнкыйтькә тәнкыйтьчеләр дә моңа күз йомачак, мәкаләне матбугатта бастыру исә кыенлык тудырмаячак. Аеруча татар газета-журналларында гел бер авторларның, бигрәк тә зур

урыннарда утыручы язучы һәм шагыйрьләрнең макталуы әнә шуннан да килә.

Бүгенге тәнкыйть язмаларына күзәтү ясасак, аларда анализланган әсәрләрнең татар әдәбиятының бик аз өлешен генә алып торуы күренер. Күпчелек әдәби продукция аннотация, хәбәрләр эчендә генә укучыга тәкъдим ителә, югыйсә актив позицияле тәнкыйтьче игътибарыннан, алда әйтелгәнчә, беллетристик характердагы әсәрләр дә, схемачыл әдәбият та, интеллектуаль примитив детективлар да, социаль яңгырашка ия булмаган фантастика да, мәхәббәт романнары да, җиңел, уйсыз тормышны пропагандалаган яисә эротик эчтәлекле китаплар да төшеп калырга тиеш түгел, чөнки алар да бүгенге әдәби тормышның бер өлешен алып тора. Һәм әдәбият белән шөгыльләнүче кеше, бар төр хезмәтләр белән танышып чыкканнан соң гына, заман әдәби барышы турында гадел хөкем чыгара ала.

*Әдәби әсәргә* анализ бирү тәнкыйтьче эшчәнлегенең беренче адымы булып тора, чөнки *иҗат* һәм *әдәби күренеш, барыш* турында нәтиҗәләр фикерләргә таянып ясала. Каләм ияләрен, зур гомуми күзәтүләрдән битәр, аерым әсәрләр, үзләре иҗат иткән текстлар хакында тәфсилле әйтелгән сүз ныграк кызыксындыра, мирасы күләмле язучы гына иҗаты хакында гомуми характердагы язмалар көтә. Гадәттә, алары бездә юбилей уңаеннан басыла яисә зур фәнни хезмәтләрнең апробацияләре буларак дөнья күрә.

Кайберәүләргә күзәтү характерындагы язмалар иҗат итүгә караганда, кечкенә бер әсәр хакында тирән, башкаларныкын кабатламаган фикерләр әйтү, инде бигрәк тә аларга тулы, системалы анализ ясау авыррак булып тоела. Икенчеләр әдәби әсәрне тар планда тикшергәндә кыенлыклар кичерә. Нинди көчле тәнкыйтьче булуына карамастан, В.В. Виноградов хәтта русларда әдәби әсәрнең стилистик планда да җентекле анализы юклыгын таныган[1].

Нәфис әсәргә тулы анализ ясарга сәләтсез тәнкыйтьче әдәби барыштагы барлык күренешләрне дә тулы күзаллауга ирешә алмый. Тәнкыйтьнең барлык формалары теге яки бу нәфис текстны һәрьяклы бәяләүне максат та итми. Әдәби әсәрне галимнәр өйрәнгәндә, гадәттә, анализны аерым бер аспектта башкаруны хуп күрәләр: композициясен, образлар системасын, мотивларны, пси-

[1] Виноградов В. В. О теории художественной речи. М.: Высшая школа, 1971. С. 15.

хологизмын һәм башкаларны ачалар. Гади укучы исә күп вакыт әдәби әсәрнең идея эчтәлеген аңлату, сюжетын сөйләү, төп геройлары турында фикер әйтү белән чикләнә.

Татар тәнкыйтендә *иҗат портретлары* еш языла, әмма алар камиллектән ерак. Әдәбиятчының тулы иҗатын белмәү, яктыртмау, аның хакында төп, халыкта популярлашкан әсәрләре буенча гына фикер йөртү – әлеге язмаларның еш күзәтелгән җитешсез яклары. Шулай да иҗат портретларында каләм шомарткан осталар да бар. Т. Галиуллин, Р. Сверигин, Г. Ахунов, М. Бакиров кебек тәнкыйтьчеләрне шундыйлар рәтендә атарга мөмкин.

Тәнкыйть алдына язучы чыгарып салган әдәби әсәрләрне анализлау янәшәсендә иҗат лабораторияләрен өйрәнү турында да сүз алып барырга кирәк. Хәзерге вакытта иҗат лабораториясе дигән фән дә мөстәкыйльләшеп килә, ул кайбер урыннарда әдәби тәнкыйть белән шактый кисешә. Әлеге юнәлешләрнең тегесе яисә бусы белән шөгыльләнсәң дә, язучының кайсы да булса әсәрне иҗат итүгә килү юлын, аны башкару процессын ачуга тукталмый калмыйсың. Иҗат кешесен эш барышында өйрәнү аның талантын, язганнарын аңлауда зур роль уйный, әмма шактый четерекле, авыр бер гамәл, чөнки талант ияләре публика каршында ачылып китәргә тырышмый.

Хәзергә кадәр бер генә татар язучысының, шагыйренең, драматургының да иҗат лабораториясе тулы яктыртылмаган. Шул юнәлештәге язмаларда, хәтта фәнни исемгә дәгъвалаган хезмәтләрдә дә нәкъ менә китапның идеядән – кулъязмага, ә кулъязмадан китап продукциясенә кадәр узган юлын яктырту, әлеге баскычларда теге яки бу язучыга гына хас якларны күрсәтү, каләм иясенең иҗатчы буларак формалашуын һәм иҗат хроникасын тулы чагылдыру җитми. Бу төр публикацияләр өлешчә ачылган иҗат портретлары, стиль үзенчәлекләрен күрсәткән мәкаләләр яисә нинди дә булса китапның язу тарихы гына булып тора.

Иҗат лабораториясенә багышланган хезмәтләрдә башка җитешсезлекләр дә очрый. Аларны өйрәнүче кайвакыт әсәрдәге үзенчәлекле якларны ачу артыннан китә я булмаса авторның үзенә генә хас алымнарны эзли һәм һәр иҗатка хас гомуми закончалыкларны күздән ычкындыра. Шулай да була: ул теге яки бу әдипнең генә үзенчәлеге дип тәнкыйть иткән кайбер хәл-сыйфатлар башка язучыларда да мулдан табыла.

Иҗатка хас алымнарны дөрес билгеләгән язмалар тудыру – гаять тә катлаулы бер эш. Бигрәк тә Ш. Әхмәдуллин мәкаләләрендә,

аның әдәби портретларында иҗатчыга хас тенденцияләрне күрсәтү омтылышы зур. Ул, авторның кемлегенә карамыйча, объектив булырга тырыша. Бу уңайдан Ш. Әхмәдуллинның «Киләчәкне уйлап» китабын мисалга китерик. Ул анда бары тик мактаулар гына кабул итеп утырган шагыйрьләргә дә шактый көчле тәнкыйть сүзләре әйтә.

Ш. Әхмәдуллин, әйтик, «Уйланырга кирәк» мәкаләсендә заманыбызның үзенчәлекле шагыйре булган Р. Харис иҗатын тикшерә, аның каләменә хас тенденцияләрне күрсәтә. Шигырьләрендәге уңай якларны шактый гына тапканнан соң, аларның кайвакыт адресаты билгесез икәнлекне, ягъни иҗатының гади халыкка гына түгел, хәтта әдәбият сөючеләргә дә хезмәт итмәвен күрә, «ачык фикерле, сөйләп торучы күренешләр урынына, «телсез» сурәтләр ясап куюын», тасвирларның махсус катлауландырылуын, мәгънәсе ачык булмаганлыгын әйтә. «Сурәтле фикернең аңлашылмаслык дәрәҗәдә катлаулылыгы Ренат Харисов иҗатында ялгыз күренеш түгел, ул системага әйләнеп бара»,– дигән нәтиҗәгә килә.

Тәнкыйтьче мәкалә эчендә саналган кимчелекләрнең укучыны бу шигъръяттән ераклаштыруын, шагыйрьгә үз кабыгында бикләнеп калу куркынычы янаганын күрә. Ш. Әхмәдуллин: «...үзең раслаган иҗат халык тормышының бүгенге ихтыяҗларына ни дәрәҗәдә җавап бирә алуы турында да уйланырга кирәк»[1], – ди.

Аерым әдәби әсәрне анализласаң да, тулы бер иҗатны яктыртсаң да, синең хезмәтең, башка әсәрләрне, авторларны яхшы белгәндә генә, кызыклы булып чыгачак. Галимне, һөнәри тәнкыйтьчене, журналистны стихияле туган язмалар бизәми, әдәбият турында уйлану аларның даими шөгыленә әйләнгәндә генә, ясаган күзәтүләре дә объективлыкка дәгъва итә.

Кемнеңдер мирасын яктыртыйм дисәң, иҗатчы яшәгән чорны, ул хезмәт иткән әдәбиятны яхшы белергә кирәк. Әйтик, унтугызынчы гасырның соңгы чиреге – егерменче гасыр башы әдәбиятын дөрес аңлау өчен, әдәби методлардан, аларның барлыкка килү шартларыннан хәбәрдарлык сорала. XX гасырның соңгы еллары әдәбиятын да, мәсәлән, илдә шул чорда барган иҗтимагый процессларны аңламыйча ачып булмый.

Язучы иҗаты, тулаем алганда гына, үсештә, тик торышта, артка китештә күренә. Иҗатны вербөтен итеп анализлаганда, язучы-

[1] Әхмәдуллин Ш. Уйланырга кирәк // Киләчәкне уйлап. Казан: Татар кит. нәшр., 1979. Б. 76–85.

ның прототипларны, тормыш материалын каян тапканлыгын чамалыйсың, нинди темалар өстендә даими эшләвен күрәсең, кайсы әсәренең элегрәк язганнарына бәйлелеген ачыклыйсың һәм күчемлелек мәсьәләләренә килеп чыгасың, иҗатчының яшәү мәгънәсен аңлыйсың, теге яки бу чорда рухи кризислар кичергәнлеген, физик халәтен тоясың.

Иҗат портретын тудыручы, каләм иясенең әсәрләрен хронологик тәртиптә өйрәнсә дә, язучының тәрҗемәи хәлен вакыт эзлеклегендә теркәүче яисә аның шәхси елъязмачысы гына булырга тиеш түгел. Аерым каләм ияләре калдырган мирастагы эчке элемтәләр хронологик тәртиптә генә бармый.

Әдәби бәйләнешләр, беренче чиратта, типологик янәшә кую һәм чагыштырулар вакытында ачыла. Иҗатны тулаем анализлау аның эчке берлеген аңлатуда ярдәм итә. Кайвакыт каләм иясе тудырган мәдәни байлыкта тематик охшашлык күзәтелмәсә дә, еш кына рухи бөтенлек, идея уртаклыгы күренә. Капма-каршы фикерләргә хезмәт иткән әсәрләр исә язучы күзаллауларында хөкем сөргән карашлар чуарлыгын яисә аның иҗтимагый фикер төрлелегенә хокукны яклавын, бер үк вакытта мәсьәләләрне төрлечә чагылдыра һәм чишә алуын, авторның рухи кризисларын, иҗат эволюциясенең дөньяны күзаллауларында үзгәрешләр барлыкка килү белән бәйле булуын белдерә ала.

Әгәр без Г. Исхакыйның илдә яшәгәндә һәм мөһаҗирлектә язган әсәрләрен янәшә куйсак, аларны берләштергән һәм аерган сыйфатларны да күпләп табарбыз. Милләт яшәешенә хезмәт итүне максат иткән язучы бу идеяне чынга ашыруны эшчәнлегенең һәр этабында төрлечәрәк күзаллый, аның башка әдәбиятларга, мәдәниятларга, аерым иҗатларга булган карашлары да үзгәрә. Димәк, бер үк кеше язган әсәрләр арасындагы аермалар тышкы факторлар белән дә билгеләнә.

*Әдәби процесс*ны, *күренеш*не беренчеләрдән булып аңлату, алдан тоярга тырышу тагын да авыррак. Й. Нигъматуллина, Д. Заһидуллина кебек галимәләр әнә шундый шактый катлаулы объектларны – заман әдәби барышын анализлау юлында, бер яктан, шактый бәхәсле, икенче яктан, кызыклы гына адымнар ясадылар инде[1]. Бу

[1] Нигматуллина Ю.Г. «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань: Фэн, 2002. 176 с.; Заһидуллина Д.Ф. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 255 б.

юлда аларга көнбатыш европа һәм рус тәнкыйте нигез булып тора. Хәер, В. Белинский кебек танылган галимнәр дә Көнбатыш фәненең тәҗрибәсенә еш таянган.

*Әдәби барыш* хакында мәкаләләр язу, *хәрәкәттәге объект* булганлыктан һәм киңмәгълүматлылык, профессиональлек, эрудитлык таләп иткәнгә, башлап каләм тибрәтүчеләргә өчен авыр. Әдәби барышны аңлау өчен, иҗтимагый тормышны тирәнрәк төшенү, әдәбиятның үзен зур мәгънәдәге сәнгатьнең аерылмас бер кисәге итеп күрү, мәдәни барышны күзаллау һәм фаразлый белү кирәк.

Озак вакытлар дәвамында әдәби барыш әдәбият тарихының, теориясенең объекты сыйфатында яшәгән, тәнкыйтьчеләр, нигездә, нәфис әсәрләргә бәя бирү белән шөгыльләнергә тиеш дип саналган. Тәнкыйтьче, аерым бер әсәрне анализлавы белән, әдәбиятка үзгәрешләр китерергә тели икән, димәк, ул бүгенге әдәби процессның үзен дә ачык күзалларга, әдәби әсәрне шул барыш эчендә һәм киләчәккә барган мираста күрә белергә мәҗбүр.

Тәнкыйть, бер яктан, теге яки бу әсәр тууга шарт тудырган, җирлек булган әдәби күренешләрне ачыкласа, икенче яктан, әлеге әсәр ярдәмендә әдәби барышта орлык җибәргән күренешләрне ача. Ул әдәбият мәйданында формалашып килүче тенденцияләрне чагылдыра, аларга объектив бәяләмәсен бирә, әдәби үсешне читкә тайпылдыручы фактлар хакында укучыны да, язучыларның үзләрен дә кисәтә.

Әдәби процессны анализлау исеме киң таралган әдәби мәктәпләрне, актив кулланыштагы методларны, генераль линияләрне, телстиль чараларын ачыклау, темаларны билгеләү, әдәбиятның башка этапларына охшамаган якларны табу рәвешендә бара. Әйтик, ел йомгакларында, съездларда тәнкыйтьчеләр күбрәк тематик блокларны, авыл һәм шәһәр сүз сәнгатен, хатын-кыз һәм ир-атлар иҗат иткән әдәбиятны бер-берсеннән аерып куюга нигезләнгән, кайсы жанрларның өстенлек итүен ачкан чыгышлар ясыйлар; ел эчендә басылган китапларның, авторларның исемлеген бирү белән канәгатьләнәләр; әсәрләргә анализ бирүдән сакланалар. Кыскасы, докладлар гадәти бер күзәтү төсмерен ала. Кайчакта алар вакытлы матбугатка үзгәртелеп тәкъдим ителә, шул сәбәпле язучылар аудиториясе каршында укылганыннан шактый аерыла, яхшырак, эчтәлеклерәк була. Ә бит киләчәк тәнкыйтьчеләре, кайсыдыр корылтай турында сүз алып барганда, нәкъ менә басма докладларга таяначак, теге яки бу чыгыш ясаучы там шулай сөйләгән икән дип ышаначак. Әдәби җыелышлар-

ны яктырткан репортажлар да еш кына, чынбарлыкны бозып, журналист аңлавында, «ишетүендә» күрсәтә.

Чын мәгънәсендәге тәнкыйтьтән ниндидер күренешкә китергән шартларны күрсәтү, әдәби яңалык булырлык хәлләрне табу, жанр сыйфатламаларының саклануына, үзгәрүенә, яңа формалар тууга игътибар сорала. Шул ук вакытта хәтта жанр эчендәге үзгәрешләрне күзәтүнең мөһимлеге тулы бер әдәби барыштагы форма һәм эчтәлеккә бәйле зур проблемаларны күтәрүнекенә караганда кимрәк.

Әдәбият үсешенең теге яки бу этапларында я аның әхлакый нигезенә балта сугылырга, я теле корамаланырга, я анда тематик тарлык күзәтелергә, я ул умыртка баганасыз – үсешенә хезмәт иткән идеясез калырга, милләт проблемаларыннан читкә китәргә, я калку, магистраль геройларын югалтырга, тискәре булырга тиеш кебек персонажларга карата укучыда уңай мөнәсәбәт формалыштыру өчен тырышырга мөмкин. Әдәби барышка бөтен бер объект санап якын килгән тәнкыйтьче аның төп агымнарын, күренешләрен бик җиңел тотып алачак.

Тәнкыйтьче әдәби процессны берничә күренешне – әдәби төргә, жанрга, аның формаларына, әлеге формаларның проблематикасына һәм тематикасына, стиль үзенчәлекләренә хас тенденцияләрне; теге яки бу стиль башында торган авторларны һәм алардан оешкан төркемнәрне; каләм ияләре тудырган агымнарны, мәктәпләрне – бергә кушып күзаллый. Әлеге күренешләр исә иҗтимагый-тарихи шартларга да, шул шартлар тудырган талантларга да бәйле.

Әдәби барышны ачканда, чор әдәбиятына хас проблемаларны, стиль мәсьәләләрен калкуландыру аеруча мөһим санала. Сүз сәнгатенең үсеш-үзгәрешләре турында сүз йөрткәндә, тискәре күренешләрнең – әдәбиятка янаган куркынычын, ә уңайларының аны үстерүгә керткән өлешен аңлауга таянасың.

Узган гасыр ахыры татар тәнкыйтьчеләреннән Ф. Зөлкарнәй язмаларында чорга хас тенденцияләрне барлау омтылышы көчле иде. Моны «Әверелеш: шигырь пародокслары» җыентыгын укып та әйтергә була. Анда тупланган мәкаләләрдә XX гасырның соңгы чирегендәге татар әдәбиятына хас тенденцияләр турында шактый кызыклы фикерләр әйтелә, сүз шулай ук шигъриятнең формасы һәм эчтәлеге, әсәрнең идея-эстетик берлеге турында да бара.

Ф. Зөлкарнәй китабында әдәби барышка хас тенденцияләрне шушы рәвешчә гомумиләштерүләр бар: «График образлылык, үзенең асылы белән, әлбәттә, саф әдәби күренеш түгел. Ул –

әдәбиятның рәсем сәнгате кануннарын үзенә турыдан-туры ярдәмгә алуы гына. Ләкин әдәби әсәрләр, гомумән дип әйтерлек, күз белән кабул итү, уку өчен язылган хәзерге заманда график образлылык чаралары текстта чит-ят тоелмыйлар, саф әдәби чаралар белән үзара керешеп, бер-берсенә булышып яшиләр. Ягъни әдәби текстларда, бигрәк тә шигъри текстларда, фәкать шушы чаралар гына үти ала торган поэтик функцияләр инде күптән ачыкланган. Бу аларга поэзиядә тулы гражданлык хокукы бирә. Ләкин, шуңа да карамастан, хәзерге татар поэзиясендә күз белән кабул итүгә нигезләнгән образ кору чаралары чагыштырмача сирәк очрый. Очрасалар да, кагыйдә буларак, соңгырак елларда иҗат ителгән әсәрләрдә генә»[1].

Әдәбият тарихының бүгенге этапларын язучы галимнәрнең эше гаять дәрәҗәдә катлаулы. Сәнгать өлкәсендә барган күренешхәлләргә үз вакытында гадел бәя бирү һәм анда яралгы хәлендә яшәгән, әмма киләчәктә үстереләчәк орлыкларны күрү бары тик әдәби интуициясе көчле шәхесләргә генә хас. Андый хезмәтләрне язуны әнә шуңа күрә бездә Т. Галиуллин, Ф. Мусин, А. Әхмәдуллин кебек өлкән буын каләм ияләренә тапшыралар да.

Тәнкыйтебезнең аналитик язмаларга ярлылыгын, әдәбиятта барган кайбер күренешләрне, артка чигенешләрне күздән ычкындыруын күреп, язучыларның төп органы булган «Казан утлары» журналы даими рәвештә бәхәсләр клубы оештыра. Узган гасырны тәмамлаганда, ул соңгы унъеллыктагы әдәби барышны чагылдырган – «туксанынчы еллар әдәбияты»н ачкан язмаларга конкурс игълан иткән иде. Бәйгедә катнашучылардан С. Хафизов, Р. Сверигин һәм кайбер башка галимнәребезнең язганнары тирән эчтәлекле, рациональ орлыклы, фактларга таянган нәтиҗәле булып чыктылар.

Әдәби барыш тәнкыйть объектларының иң хәрәкәттәгесе булып тора, аның белән хәтта әдип иҗаты да ярыша алмый. Тәнкыйтьчегә, әдәби барышны чагылдырганда, материалны ретроспектив кына түгел, перспектив үзләштерү дә лазем. Ф. Миңнуллин «Романга ни булды?» язмасында: «Татар романы акрын гына, сиздерми генә, тарая, сыегая, ваклана бара. Безгә нидер булды. С. Хәким әйтмешли, без нәрсәнедер югалттык»[2],– ди. Бу юлларда тәнкыйтьченең татар романының киләчәген фаразлавы да чагылыш таба.

---

[1] Зөлкарнәй Ф. Әверелеш: шигырь парадокслары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. Б. 115.

[2] Миңнуллин Ф. Романга ни булды? // Балта явызлар кулында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. Б.88.

Ф. Миңнуллин тәнкыйть сүзләрен А. Расихның «Ямашев» (өченче китап, 1982), М. Хәсәновның «Шөгеревлар» (1980), Ш. Бикчуринның «Тирән катлам» (1981), М. Маликованың «Ак давылда тал бөресе» (1983) әсәрләренә һәм башка романнарга юнәлтә. Ул, Л. Җәләй кебек зур тәнкыйтьчеләр санаган әсәрләр арасында Н. Фәттахның «Сызгыра торган уклар»ына (1982) гына уңай бәя бирер иде, дигән караштa тора. Алга таба Ф. Миңнуллин: «Аларның байтагы журнал редакциясендә һәм нәшрият коридорларында еллар буе этеп-төртеп йөртелгәннән соң, анда да әле кыскартылып, турап-кискәләп бетергәч басылды»[1],– дип яза. Тәнкыйтьче сиксәненче еллар башында дөнья күргән романнарның авыр укылышына, кайбер авторларның калыплашып җитмәгән тормыш материалы белән эш итүенә, әсәрләрнең сәнгатьчә камилләшеп җитмәвенә басым ясый, мисаллар белән дәлилли. Бүгенге прозабыз белән танышса, Ф. Миңнуллинның бәясе тагын да кискенрәк яңгырар иде шикелле. Димәк, үз фаразлавында тәнкыйтьче хаклы булган...

«Романга ни булды?» язмасының ахырында мондый юллар бар: «Соңгы ун-унбиш ел эчендә бер генә төргә – социаль-психологик романнарга гына йөз тота башладык. Бу роман жанрын ярлыландыруга китерде. Роман жанрының бүгенге хәле ни хәтле генә кыен булмасын, бу вакытлы күренеш дип уйлыйм. Эпик роман казанышларын психологик роман өлкәсендәге тәҗрибәләр белән органик төстә куша алганда, бай тарихы, зур традицияләре булган татар әдәбиятында роман үзенә лаек урынны алыр дип ышанасы килә»[2]. Соңгы елларда романның башка төрләре, әйтик, тарихи романнар артып китсә дә, бу жанрга караган хезмәтләр заман укучысы ихтыяҗын канәгатьләндерә, көтелгән дәрәҗәдә төрле дип әйтеп булмый.

Әдәби барыштагы уңай тенденцияләрне ачып бирү, бер яктан, шул тенденцияләргә хезмәт итүче каләм ияләрен тәрбияли, ә инде аерым иҗаттагы уңай күренешләрне барлау, үз чиратында, шул күренешнең әдәби барышта ныгуына булыша. Тәнкыйтьче әдәбият мәйданындагы эш-хәлләргә механик якын килүдән сакланырга, сүз сәнгатендә күзәтелгән яңа үзенчәлекләрне табу белән мавыгып, әдәби әсәрләрнең асыл мәгънәсен, анда электән килгән кыйммәтле традицияләрнең саклану-сакланмавын күз уңыннан читтә калдырмаска тиеш.

---

[1] Миңнуллин Ф. Романга ни булды? Б. 88.

[2] Шунда ук. Б. 96.

# 2. ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬНЕҢ ҮЗАҢЫ ҺӘМ ҮСЕШ ЭТАПЛАРЫ

*Аларда* (В.Г. Белинскийның «Әдәби хыяллар»ында. – *Р.Х.*)
*тәнкыйтебезнең тәүге аңлы хисе чагылган.*
А.А. Григорьев

Әдәби тәнкыйтьнең үзаңы дигәндә, аның тарафыннан табигатенең теоретик нигезләрен аңлауны күздә тотабыз. Күренешләргә якын килүнең яңачарак методлары формалашкан, кайчандыр кире кагылганнары кайткан яисә кулланыштан төшеп калган һәм фәнни информациянең үсеше тизләтелгән заманыбыз һәр төр белемнәрнең асылын бик тирәнтен өйрәнү, кабат тикшерү бурычын куя.

## 2.1. Әдәби тәнкыйтьнең үзаңы формалашу

Фән буларак нигезләрен барлавы, үзенең методологиясен булдыруы әдәби тәнкыйтьнең тулы мөстәкыйльлеккә омтылышын күрсәтеп тора, ә бу исә – озын һәм катлаулы процесс.

Дөнья тарихында антик чорларда ук фән буларак танылган әдәби тәнкыйть озак вакытлар дәвамында аерым бер әсәргә гомуми бәя бирү, аның кимчелекләрен, уңышлы якларын күрсәтү, авторны мактау яисә хурлау, уңышлы саналган хезмәтләрен укучыларга тәкъдим итү кебек функцияләр башкарган, әдәбият белеме эчендә формалашкан. Ул Греция, Рим, Һиндстан, Кытай кебек борынгы дәүләтләрдә үзенчәлекле һөнәр дип саналган һәм аның гамәли әһәмиятенә басым ясалган.

Әдәби тәнкыйтьнең Көнбатышта калыплашуы XVII гасырда башлана һәм XIX гасыргача дәвам итә. Аны үстерүгә зур өлеш кертүчеләр рәтендә Т. Карлейль, Ш. Сент-Бев, И. Тэн, Ф. Брюнетьер, М. Арнольд, Г. Брандес кебек каләм ияләре атала.

Русларда әдәби тәнкыйтькә мөнәсәбәтле элементлар XI гасырның язма истәлекләреннән күренә башлый. Андый текстларга түбәндәгеләрне кертәләр: «Изборник 1076 г.»; Митрополит Илари-

онның «Слово о законе и благодати» әсәре, «Слово о полку Игореве»; Изгеләрнең тарихлары; Андрей Курбскийның Иван Грозныйга хаты һәм Максим Грек, Симеон Полоцкий, Аввакум Петров, Мелетий Смотрицкий хезмәтләре.

Рәсәйдә әдәби тәнкыйть мөстәкыйльләшүе бик озак һәм иҗтимагый аң үсеше белән тыгыз бәйләнештә бара. Петр Беренченең, көч түгеп, кискен шартларда уздырган реформалары нәтиҗәсендә, башта – русларда, аннан алар кул астында яшәгән башка халыкларда мәгърифәтчелек хәрәкәте киң җәелә, рухи тормышта зур яңалыклар күзәтелә. 1725 елда – Фәннәр академиясе, 1755 тә Мәскәү университеты ачылу фәннәр үсешенә дәүләт дәрәҗәсендәге игътибар башланганны күрсәтә. Реформалар тудырган процесслар рус әдәби тәнкыйте оешуга этәргеч тәэсир ясый. Аның башлангыч этабын 1740–1770 еллардагы әдәби күренешләр, бигрәк тә әдәбиятта классицизм ныгу белән бәйләп карыйлар. «Нәкъ менә шушы вакытта ул әдәбиятта үзенчәлекле роль уйнаячак, аны үстерәчәк һәм баетачак сыйфатларга ия була барды»[1], – дип яза В.В. Петрушевская.

Бу чорда әдәби тәнкыйть милли алгарыш таләпләренә җавап бирү рәвешендә яши. Сан һәм сыйфат үзгәрешләре кичергән әдәбиятка юллар күрсәтәчәк галимнәргә ихтыяҗ туа, яңа, көн таләбен канәгатьләндерерлек әсәрләр үзләре үк аларны үстерә башлый. Ломоносов, Сумароков, Тредиаковский, Державин, Херасков кебек каләм ияләре, дөнья һәм рус әдәбиятының тарихын өйрәнеп, чит ил әдәбият белемнәренә таянып, чын милли әдәбиятны үстерү нигезләрен эшләүне үзмаксат итәләр, туплаган теоретик белемнәрен, әсәрләр белән танышу нәтиҗәсендә туган аналитик фикерләрен әдәби иҗатта сыныйлар.

Рус әдәби тәнкыйтенең предметын формалаштыручылар исемлеген тагын да киңәйтергә булыр иде. Мәсәлән, В.В. Петрушевская шундыйларның берсе – А.Т. Болотов – хакында сүз йөртә һәм, аңа бәйле рәвештә, шул чор тәнкыйтенә хас гомуми үзенчәлекләрне ача – аның «Мысли и беспристрастные суждения о романах как оригинальных российских, так и переведенных с иностранных языков» исемле һәм кайбер башка хезмәтләрендә әдәби әсәрнең уңай якларын һәм җитешсезлекләрен объектив бәяләү, укучыда китап сайлау зәвыгы булдыру, әдәбиятның кемгә һәм

[1] Петрушевская В.В. Критика в поисках предмета // Проблемы развития литературной критики: сб. статей: ред.: В.В. Ефимов, Б.Л. Милявский. Душанбе: ТГУ, 1984. С. 3.

ничек хезмәт итүе, әдәби әсәрләргә таянып, әдәби жанр формалары кебек мәсьәләләргә дә кагылып узуын, кызыклы гына рецензия үрнәкләре бирүен әйтә.

XVIII гасырда яисә алданрак та язылган һәм әдәби тәнкыйть үрнәкләре саналырга хаклы русча хезмәтләрдә әдәби тәнкыйть предметы, әдәбият белеме, әдәбият теориясе кебек фәннәр турында турыдан-туры, тирәнтен, махсус, киңкатлам укучыга җиткереп уйлану юк әле. Шулай да аерым каләм ияләре инде критика, ягъни әдәби тәнкыйть төшенчәсеннән хәбәрдар. «Критик» һәм шул мәгънәдәге «острый судья» төшенчәләрен русларда тәүге тапкыр Антиох Кантемир кулланган дип санала, әмма «критика» киң әйләнешкә XIX гасыр уртасыннан гына керә, әдәбият белемендәге әлеге өлкәнең игътибарга алынырлык үсеше исә әдәби журналлар чыга башлауга бәйле. Шул юнәлештәге тәүге басма буларак «Ежемесячные сочинения, к пользе и увеселению служащие» дип аталган журналны мисалга китерәләр (1755).

XVIII гасыр тәнкыйтенә хас үзенчәлекләр сыйфатында аның төп игътибарны текст җитешсезлекләренә, стильгә юнәлтүен, норматив һәм зәвыкый принципларга таянуын атыйлар. Бу чорда әдәби тәнкыйть белән бары тик язучылар гына шөгыльләнә, һәм аларның язмалары шәхси эстетик тәҗрибә белән уртаклашу төсмеренә ия. В.В. Петрушевская, мәсәлән, XVIII гасырда рус тәнкыйтенең әдәби барышның мөстәкыйль өлкәсе буларак кына формалашуы турында сүз йөртә[1]. Тәнкыйтьнең әдәбият үзе меценатлык һәм чиновниклык киртәләреннән үсеп чыкканнан соң мөстәкыйльләшә башлаганлыгын әйткән В.Г. Белинский шулай ук бу фактны XIX гасыр башы белән терки, бүгенге көн галимнәре исә, социаль-фәлсәфи, эстетик рус тәнкыйтенә нәкъ менә ул нигез салды, дип белдерә[2].

XVIII гасырның соңгы чирегендә рус тәнкыйте чын-чынлап әдәбиятны әйдәүче факторга әверелә. Екатерина Икенченең иҗтимагый юнәлештәге, бигрәк тә әдәби тормышны активлаштыру йөзеннән башкарган эшләре, сәнгатькә, аның белән шөгыльләнүчеләргә аерым бер игътибары әдәби тәнкыйть үсешенә зур этәргеч ясый, аның белән шөгыльләнә алырлык яңа буын әдәбиятчылар барлыкка килә. Д.И. Фонвизин, И.А. Крылов, А.Н. Радищев, Н.М. Карамзин

[1] Петрушевская В.В. Критика в поисках предмета. С. 3.

[2] Басинский П. Искусство пристрастного чтения, В.Г. Белинский // Белинский В.Г., Добролюбов Н.А., Чернышевский Н.Г., Писарев Д.И. Статьи о русской литературе. М.: ЭКСМО-Пресс, 2002. С.5, 7.

һәм башкалар әдәбиятны үстерү хакында тагын да киңрәк планда сүз алып баралар. Аларны әдәби бәйләнешләр, язучы таланты, жанрлар үсеше һәм башка бик күп проблемалар борчый.

Бу чорда әдәби тәнкыйтьнең журналистика белән тыгыз элемтәсе барлыкка килә, ул үзенең укучылар даирәсен киңәйтә. Төрле эчтәлектәге газета-журналлар чыгу жанр формаларының үсешенә китерә: эпистоляр стильдәге әсәрләр, кече күләмдәге тәнкыйди бәяләмәләр янына әдәби фельетон, күзәтүләр, рецензияләр һәм башкалар өстәлә, вакытлы матбугатта әледән-әле дөнья күргән эпизодик характердагы мәкаләләрне әкренләп системалы язмалар алыштыра – махсус рубрикалар барлыкка килә.

Александр Беренче идарә иткән елларда яңа реформалар әзерләнә, Рәсәйнең иҗтимагый һәм мәдәни тормышы тагын активлаша, матбугат органнары төрләнә. Кызыклы сәнгати юнәлешләр барлыкка килгән бу чорда әдәби темаларга бәхәсләр тагын да көчәя. XIX гасырда иң элек В.А. Жуковский, К.Н. Батюшков, О.М. Сомов, К.Ф. Рылеев һәм башкалар торган рус романтик тәнкыйте мәйданга килә.

Рус әдәби тәнкыйтенең алдагы үсеше Н.А. Полевой, К.А. Полевой, Ф.В. Булгарин, П.А. Вяземский, Н.В. Гоголь, Н.И. Надеждин, В.Г. Белинский кебек талантлы шәхесләрнең эзләнүләре белән бәйле. Бу заманда тәнкыйтьчеләрне бигрәк тә әдәбиятның халыкчанлыгы проблемасы борчый. 1830–1840 еллар – рус һөнәри тәнкыйтенең формалашуы һәм чәчәк атуы чоры. Тәнкыйть үзен халыкка хезмәт итүче фән буларак таный.

Әдәбият белеме мөстәкыйль гыйльми өлкә сыйфатында русларда гына түгел, Европада да бары тик XIX гасырда гына ныклап формалашып җитә. Белинский, Чернышевский, Добролюбов, Буслаев, Веселовский һәм Потебня әдәби тәнкыйть турындагы карашларны, аның методологик һәм теоретик нигезләрен калыплаштыралар һәм әдәби әсәргә аның идея-сәнгатьчә эшләнеше ноктасыннан бәя бирү принципларын эшлиләр. Добролюбов әдәби тәнкыйтьнең максатын, әсәрдә сурәтләгәннәрдән чыгып, чынбарлык, социаль типлар турында фикер йөртү дип билгели.

Нинди дә булса эшчәнлекне фән дип бәялисең икән, аның буенча махсус китаплар язылырга, югары уку йортларында укытылырлык итеп программалар эшләнергә тиешлеге бәхәс уятмыйдыр. Ниһаять, бу гамәлләр дә тормышка ашырыла башлады. Яңа гасырда рус тәнкыйте тарихына караган күп кенә хезмәтләр дөнья күрде. Шулардан Мәскәү дәүләт университеты галимнәре В.В. Прозоров,

О.О. Милованова, Е.Г. Елина язган «История русской литературной критики» (2002), Л.М. Крупчановның «История русской литературной критики XIX века» (2005) китапларын эчтәлек тирәнлеге ноктасыннан билгеләргә кирәк.

Икенчел пландагы иҗат булган һәм үзенә кадәр тудырылган сөйләм текстын бәяләүне башкарган әдәби тәнкыйть әдәбият белән янәшә барлыкка килә. Димәк, татар әдәби тәнкыйтенең дә тәүге зәгыйфь яралгылары аның чишмә башына – борынгы төрки әдәбиятка, беренче чиратта, нәфис текстларга, халык авыз иҗаты әсәрләренә, матур яисә ямьсез сөйләмгә карата әйтелгән хурлау-мактау сүзләренә барып тоташа дип уйларга кирәк. Х.Г. Күроглының «Борынгы төрки язмачылык» хезмәтендә: «Ул (Баласагуни. – *Р.Х.*) төрки әдәби телгә нигез салучылардан хисаплана. Үзенең «Котадгу белек» поэмасы» турында ул: «Гарәп һәм таҗикъ телләрендә күп китаплар язылган. Әмма безнең телебездә бу – беренче әсәр»[1],– дигән юллар бар. Әлеге өзек төрки каләм ияләренең көнчыгыш сүз сәнгате үсешеннән хәбәрдарлыгын күрсәтә һәм әдәби барышка мөнәсәбәтле фикер булып тора. Баласагуни әсәрләренең үзенә мөрәҗәгать итсәк тә, сөйләмне бәяләүче юлларны шактый табарбыз. Аның «Шагыйрьләр белән аралашу турында» шигырендә мондый строфалар бар:

...Баса килде шагыйрь – бу сүз тергүче,
Кешег үггүчеләр йәмә йәргүче.
[Янә килде шагыйрь – ул сүз тезүче,
Кешене мактаучы һәм дә сүгүче.]

Кылычта йэтигрәк боларның теле,
Йәнә кылда йинчкә бу хатыйр йулы.
[Кылычтан үткенрәк боларның теле,
Янә кылдан нечкәрәк хәтер юллары.]

Татыг, йинчкә сүзләр укайын тисә,
Болардин ишет сүз, укылгай баса.
[Татлы, үткен сүзләр белим дисәң,
Боларны тыңла, аларның сүзләре җиңел төшенелә.]

Тиңизгә керер күрсә күңлен төгәл,
Гүһәр, йенҗү, йакут чыкарыр мәсәл.

---

[1] Күроглы Х.Г. Борынгы төрки язмачылык // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Т. 1. Б. 77.

[Күрсәң: алар күңел диңгезенә тәмам кererләр,
(Аннан) гәүһәр, энҗе, якутларны чыгарырлар.]

Улар үксәләр, үкде илкә барыр,
Калы сүксәләр, аты артыб калыр.
[Алар мактасалар, мактаулары илгә таралыр,
Әгәр сүксәләр, (кешенең) яманаты калыр.]

Уса, идгү тотгыл боларны, кадаш,
Боларның теленгә эленмә, адаш.
[Уйла, яхшы тот боларны, кардәш,
Боларның теленә эләкмә, адаш.][1]

Югарыда китерелгән өзектә әдәбиятка, талантлы шагыйрьләр иҗатына мөнәсәбәт; шагыйрь хезмәтенең эчтәлеге, җәмгыятькә тәэсире, язу алымнары, тасвир объектлары, таянган материалы, сүз сәнгатенең максат-вазифалары турында фикерләр бар. Автор бер үк вакытта укучыны поэзияне кабул итәргә дә хәзерли.

Үзенә берничә әдәби баскычны берләштергән Урта гасыр хезмәтләрендә сүз сәнгатенә мөнәсәбәтле тәнкыйди фикерләр тагын да күбрәк. Теге яки бу сөйләм төренә, өзекләргә аңлатмалар, әдәбият белеменә нисбәтле төшенчәләр каләм ияләренең нәфис әсәрләрендә еш очрый. Кайвакыт тәнкыйди бәя-хөкемнәргә синкретик характердагы чәчмә төр эчендә дә тап буласың. Әдәби берәмлеккә карата укучы мөнәсәбәте бигрәк тә кульязма битләренең кырларына кырларына күп теркәлгән.

Әгәр без узган чорлардан сакланып калган иң мөһим әсәрләрнең берсенә – мәшһүр Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ына мөрәҗәгать итсәк, шагыйрьнең шигърият кануннарыннан хәбәрдарлыгын, әдәби текстка, иҗатка аңлы якын килүен, сүз сәнгатенә йөкләнгән вазифаларны аңлавын, эчке тоемга таянып кына язмавын күрербез. Поэманың Керешендә автор, Алладан «гыйбрәт-хикмәт сөйләттереп, син куандыр», «хәтеремне якты нурга балкыт», «күңелемә фикер-зиһен яктысы бир», «көчле илһам уңышы бир», «гаклым туры, телем төзек яса» дип сораган юллары белән, нәфис әсәрнең укучыны тәрбияләргә тиешлеген, илһам тәэсирендә язылганлыгын, чынбарлыктан һәм тарихтан алган материалларга – хәтергә

[1] Юсуф Хос Хожиб. Кутадгу билиг (татарчага тәрҗемәчесе күрсәтелмәгән). Тошкент: Фан, 1971. Б. 666–667. URL: // http://kitap.net.ru

таянылып иҗат ителгәнлеген, логик эзлекле һәм сөйләм бөтенлегенә ия булырга тиешлеген дә ирештерә.

«Моңардан соң мин хикмәткә күчәчәкмен,
Гөл һәм рәйхан, энҗе-мәрҗән сибәчәкмен,
Йосыф нәби хәлен сөйләп бирәчәкмен –
Мөмкиннәргә бу файдалы, аңлаң инде.

Кыйссалардан, хикмәтләрдән матуррагы,
Ялыкмыйча тыңлау өчен татлырагы,
Коръәндә дә бу хакта сүз булганлыгы,
Шушы кыйсса икәнлеге ачык инде»[1],–

дигән строфалар сюжет һәм аның борылышларына, текст структурасына, үзәк геройга, тел-сурәтләү чараларына, тәрбияви вазифага, жанрга, әсәр чыганагына, сюжетның кызыклылык, әсәрнең гүзәллек-камиллек дәрәҗәсенә, чор әдәбиятының югарылыгына ишарәли. Шигъри дастаннан авторның сөйләм катламы, пафосы һәм башка үзенчәлекләре турында уйлануларына да мисаллар китерергә мөмкин. Әйтик, «Хәтимә»нең тәүге юлларында – төп текстның, алынмалар булуга карамастан, гарәп-фарсы вариантларыннан аермалы рәвештә, халык теленә якынайтылганлыгы, ә алтынчы-җиденче строфаларда дастанның калыбы-үлчәме турында әйтелә:

Йосыф сәүче кыйссасын без тәмам иттек,
Гарәб-фарсы телләречә бәян иттек,
Уку өчен, тыңлау өчен ансат иттек,
Укыганнар безгә дога кылсын инде.
/…/
Бу зәгыйфьнең шушы нәзмы аз булмады,
Робагые үлчәмендә торсын инде.

Аты – Гали моны төзегән зәгыйфь колның,
Егерме дүрт иҗек итеп тезде юлын...»[2].

Бу өзекләр укучыга Кол Галинең иҗат белән даими шөгыльләнгәнлеген, робагыйларны үз күргәнен, әмма бу очракта юлларны кушканын (24 иҗек!) җиткерә. «Кыйссаи Йосыф» безгә

---

[1] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф: хәзерге әдәби телгә шигъри күчермә авт.: Н. Хисамов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 21.

[2] Шунда ук. Б. 216–217.

шулай ук шагыйрь иҗат иткән әсәрләрнең сакланган мирасыннан күләмлерәк икәнне дә әйтеп бирә. Нәфис текст Кол Гали яшәгән чорда ук поэзиягә мөнәсәбәтле тәгълимат барлыгын һәм аның система рәвешендә яшәвен ачык күрсәтеп тора. Бу очракта автор тарафыннан үз иҗатына кагылышлы мәгълүмат бирелсә дә, еш кына каләм ияләре, шушы рәвешчә, башка кеше әсәрләре хакында да фикер йөртә. Борынгы язма әдәбиятыбыз юкка чыгарылмаса, моның мисалларын күпләп күрсәтә алыр идек.

Язма сүзнең нинди булырга тиешлеге, аңа куелган таләпләр турында тезмә текстларга фикер кертү Алтын Урда чорында көчле бер традициягә әверелә. Мәсәлән, Котбның 1342 елда язылган «Хөсрәү вә Ширин» «шигъри роман»ында Кол Гали заманнарыннан ук килгән шул төр гамәл Аллаһка мөрәҗәгать рәвешендә иҗат ителгән тулы бер Керештә чагылыш таба. Аның соңгы строфаларын гына искә төшереп узыйк:

Давытныкы кебек рух чиста булсын,
Телем Зәбур язарлык оста булсын.

Җанымның һәр сүзе җитсен җанга,
Ягымлы булсын ул барча җиһанга.

Укылгач, яктырып китсен күңелләр,
Телемнән гел чәчелсен мөшек вә ганбәр.

Карагач, барча күзләр нурга булсын,
Ишеткән һәр колак шатлыкта булсын.

Югары кыл да мәгънәсен сүземнең,
Бәхетле ит яшәвемне үземнең[1].

Әдәби тәнкыйть элементлары Урта гасырларда фольклорда шулай ук күренгәләсә дә, чын мәгънәсендә тәнкыйди фикер – әлбәттә, язма әдәбиятта. Ул төрле күләмдәге бәяләмәләр, белешмәләр, аңлатмалар, карашлар рәвешендә яши, һәм әдәбият белеменең терминнар оясын калыплаштыручы төшенчәләр дә инде күпмедер бар.

Татар әдәби тәнкыйтенең ана телебездә язылган фән рәвешендә иртә оешмавында, ислам рәсми дин сыйфатында кабул ителгәннән

[1] Котб. Хөсрәү вә Ширин (шигъри роман). Казан: Мәгариф, 2003. Б. 23.

соң, уку йортларыбызда, ягъни мәдрәсәләрдә гарәп-фарсы телле әдәбияттан, дәреслекләрдән киң файдалану – төп сәбәпләрнең берсе. Гарәп телен камил белгән татар укымышлылары, бигрәк тә үзләре дә иҗат иткән каләм ияләре һәрвакытта әдәби тәнкыйтькә, әдәбият белеменә кагылышлы мәгълүматка ия булган, шул юнәлештәге китапларга ихтыяҗын тәэмин итә алган дип уйларга кирәк. Югары баскыч мәдрәсәләрдә әдәбият укытылу, хәтта нәфис текст формулалары ятлатылу, элекке әсәрләрнең төрле калыпларда иҗат ителүе, форма камиллеге һәм бөтенлеге, дингә генә түгел, әдәбиятка кагылышлы бәхәсләрнең дә традиция рәвешендә яшәве, чичәнлек ярышлары – ерактагы тарихыбызда ук тәнкыйди фикернең көчле булганлыгына бер дәлилдер. Кызганыч ки, соңрак үз галимнәребез дә билгеләгәнчә, мәдрәсәләребездә гасырлар дәвамында милли әдәбиятны үзләштерү читтә калып килә, гарәп-фарсы әдәбиятын өйрәтү, аны аңлатучы фәннәрдән генә хәбәр бирү табигый хәл санала: «Аларның (милли мәдәниятләрнең – *авт.*) милли мәктәпләрендә әһәмият бирелеп укытыла торган дәресләрнең беренчесе, һич шөбһәсез, үзләренең милли әдәбиятлары буладыр. /…/ Әмма, үкенечкә каршы, безнең милли мәктәпләребезнең ибтидаисыннан алып, рөшди һәм галиясенә кадәр, гомумән, һичберсендә әле бу көнгә чикле ана теле вә милли әдәбият дәресләренә әһәмият бирелмәде. Һәм бирелергә дә уйланылмады, әле дә кирәгенчә уйланып вә әһәмият бирелеп җитмидер»[1].

Күп кенә мөселман халыкларында озак вакытлар дәвамында нәфис әсәрләр дә, аны бәяләүче хезмәтләр дә чит телләрдә язылса да, алар әлеге халыкларның үз нәфис байлыгына карый, шунлыктан без, әйтик, фарсы телле азәрбайҗан, үзбәк әдәбиятлары һәм башкалар турында сүз йөртәбез. Ислам кабул ителгәннән соңгы чорда, җирле сүз сәнгате көчлелеккә карамастан, гарәпчә иҗат итүче фарсылар да булган. Үз мирасыбызда да гарәп, фарсы телләрендәге әдәбият шактый зур урын алып тора. Бу мөселман халыкларының ике зур мирасны уртак байлык итеп санауларын сөйли. Фарсыларда һәм гарәпләрдә исә тәнкыйтьнең тарихы бик күптәннән килә. Исламгача да сүз сәнгатен бәяләү традицияләре яшәвенә карамастан, чын мәгънәсендәге гарәп әдәби тәнкыйте Урта гасырларда туган дип санала, бу IX йөздән башлап әдәбият система рәвешендә күзалланган, аны бәяләү критерийлары булдырылган дигән сүз.

---

[1] Сәгъди Г. Әдәбиятыбыз // Мөгаллим, 1913. № 2. Б. 25.

Гарәп әдәби тәнкыйте үз поэтик кануниятенә һәм грек фәлсәфәсенә таянып калыплаша. Филологик тәнкыйтькә нигезне Әбү Гобәйдә (русча: Абу́ Уба́йда Ма́’мар ибн аль-Мусанна́ ат-Тайми́, гарәпчә: أبو عبيدة معمر بن المثنى التيمي; 728–825), әл-Әсмаи (русча: Абдуль-Малик ибн Курайб аль-Бахили; гарәпчә: عبد الملك ابن قريب الباهلي الأصمعي: 740–828) кебек VIII–IX гасырларда яшәгән каләм ияләре салган дип исәпләнә. Әлеге галимнәр нәфис текстларын барлаган, туплаган, өйрәнгән, аларга филологик-тарихи аңлатма-шәрехләр язган һәм үз хезмәтләрендә исламга кадәр таралыш алган бәяләү традицияләрен нык исәпкә алган. Әдәби әсәрләр арасыннан киләчәккә барырга тиешле текстларны сайлауларында ук әлеге галимнәрнең шәхси зәвыклары, димәк, материалга мөнәсәбәте, бәясе чагылыш тапкан. Алга таба матур әдәбиятны бигрәк тә төрле сәяси максатлардан, әдәби-иҗтимагый күзаллаулардан һәм текстның үзенә бәйле критерийлардан чыгып бәяләүчеләр, сайлаучылар, пропагандалаучылар арасында көрәш башланган.

IX гасырда яшәгән Ибн Котайбә (русча: Абу́ Мухаммад ‘Абдулла́х ибн Мусли́м ад-Ди́навари, гарәптә кыска кулланылышта: ابن قتيبة; 828–889) нәфис текстның сәнгати кыйммәтен бәяләүче сыйфатламаларны тәгаенләгән тәүге тәнкыйтьче санала. Ул борынгыдан килгән формалар чисталыгы өчен көрәшә, узган чорларга караган әдәбията та, яңасы да бер үк критерийлар нигезендә бәяләнергә тиеш, дигән фикер әйтә. Шагыйрь-галим Ибн әл-Мөтазз (русча: Абдуллах ибн аль-Мутазз аль-Муртада; гарәпчә: عبد الله بن المعتز; 861–908) исә сәнгать чараларын барлау, кулланылыш тарихын чагылдыру, системага салу һәм терминнар белән билгеләү эшен башлап җибәрә.

Өлкән яшендә ислам динен кабул иткән һәм IX–X гасырларда яшәгән әдәбият тәнкыйтьчесе – грек чыгышлы Кудамә ибн Җәфар (русча: Кудама ибн Джафар; гарәпчә: قدامة بن جعفر; якынча 873 елда туган, 932–948 еллар арасында вафат) «Шигырь тәнкыйте» һәм башка хезмәтләре белән танылa. Ул, тәүгеләрдән булып, гарәп поэтикасының нигезләрен эшли: шигъриияткә билгеләмә бирә, поэтик сөйләм һәм лексика, метрика, рифма, жанрлар, образлар системасы хакында яза, һәрберсен исәпкә алганда гына, югары сәнгать әсәре тудырырга мөмкин булганлыкны әйтә. Алга таба Ибн Рашикъ (русча: Ибн Рашик; гарәпчә: ابن راشق; 1000–1064) тарафыннан да әдәбият белеменә һәм тәнкыйтькә махсус хезмәтләр башкарыла. Мәсәлән, аның кыскача «Таяныч» («Шигырь

һөнәре һәм аңа тәнкыйтькә таяныч китабы» – «Китаб әл-гумдәһ фи синәгать әш-шигър вә нәкъдиһи» һ.б. вариантларда) исеме белән киңбилгеле трактатында шигырьнең сәнгатилеге, аңа ничек ирешергә, тел сурәтләү чараларын ничек сайларга кебек проблемалар күтәрелә, тәнкыйтьнең әдәби әсәрнең эстетик ягына нык игътибар итәргә тиешлегенә басым ясала һ.б.. Гомумән алганда, галим поэзия һәм тәнкыйть теориясен системалаштыра. Руслар тулы атамасын төрлечә тәрҗемә иткән әлеге хезмәтне, заманга яраклаштырып, «Поэтик иҗат һәм тәнкыйть нигезләре» дип тә атарга булыр иде.

Әлбәттә, гарәп әдәби тәнкыйтен үстерүчеләр аталган шәхесләр белән генә чикләнми. Гарәп әдәбият белеме X–XIII гасырларда инде теоретик нигезле, эшләнеп беткән терминологияле көчле фәнни өлкәгә әверелә. Шушы чорда татарларга ислам дине, гарәп-фарсы әдәбияты тәэсире дә нык арта. Икенче яктан, дөньяның төрле почмакларында белем туплаган татар укымышлылары әдәбият белеме һәм тәнкыйте кебек өлкәләрне яхшы белгән һәм, ватанына кайткач, башкаларга да ирештергән дип уйларга кирәк.

Татарларга яхшы таныш фарсы әдәбияты һәм тәнкыйтенең яралгылары шулай ук исламгача чорга барып тоташа. Ул заманнарда ук фарсыларның ораторлык сәнгате, тәнкыйте буенча китаплары булган дип санала. Дөрес, алар сакланмаган, моны соңрак язылган текстлардагы ишарәләр аша гына чамаларга мөмкин. Соңгырак хезмәтләр шулай ук фарсыларның грек риторикасы һәм әдәби тәнкыйте белән танышлыклары турында сөйли[1].

Ислам кабул ителгәннән соң, фарсы әдәбияты, әдәбият гыйльме гарәпнеке йогынтысына бирелә; фарсылар да, үз чиратларында, гарәп сүз сәнгатенә тәэсир итә. Фарсычадан татарчага ирекле тәрҗемәләрдә шулай ук әдәбият белеменә кагылышлы материаллар очраштыра. Тезмә әсәрләрнең үзләрендә нәфис текстка, поэтикага мөнәсәбәтле юлларның булуы әдәби тәнкыйтьнең шушы рәвешчә дә яшәве мөселман сүз сәнгатендә гомуми традиция икәнне күрсәтә. Шулай итеп, татар каләм ияләре ислам динен кабул иткән чордан дөньякүләм танылган ике зур әдәбиятның йогынты мәйданына килеп эләгә.

Мөселман дөньясында фәлсәфи-әдәби фикер үсеше теге яки бу әсәрләргә, шул исәптән хәтта дини китапларга карата да фикер әйтә алу, остазлар мирасына мөнәсәбәт, бәя бирү ирегe өчен көрәш рәвешендә дә бара. Төп китап Коръәнгә язылган бихисап тәфсир-

[1] Abdolhossein Zarrinkoub. Naqde adabi. Tehran, 1947. S. 374–379.

ләрне укыган, үзләре дә язган каләм ияләре филологик фәннәрдә актив булган тикшерү методын – текстны уку һәм шәрехләү стратегиясен яхшы белергә тиеш була, ул исә – әдәби тәнкыйтьнең дә төп методларыннан.

Дини китаплар белән эш итү галимнәрне, теге яки бу таләпләрдән, кысалардан чыгып, текстка кодлар сайларга күнектерә. Шәрехләү вакытында текст күпмедер заманчалаштырылмый калмый, аңлатмаларда автор субъективлыгы, белемлелеге, мәгълүматлылыгы чагылыш таба. Дини әдәбиятка шәрехләр язганда да, каләм иясенең дөньяны күзаллаулары эшкә җигелә. Ул текстны укучыга аңлатып кына калмый, аңа булган шәхси мөнәсәбәтен дә чагылдыра. Бер үк текстларга күптөрле тәфсирләр язылу да киң мәгънәдәге әдәбият мәйданын билгеле бер дәрәҗәдә бәхәс, ярыш мәйданына әверелдерә.

Борынгы чорлардагы тәрҗемәчелек эшчәнлегендә шулай ук югарыда тасвирланганга тартым күренешләр белән очрашабыз. Гарәп һәм фарсы әдәбиятын ирекле тәрҗемә итүчеләр генә түгел, оригиналга якын татарчалаштыручылар да текстка теге яки бу үзгәрешләр кертми калмый. Беренчеләре исә укучы зәвыгын да, аның текстларны кабул итү мөмкинлекләрен дә, үз тормышыбызга хас үзенчәлекләрне дә, башка реалийларны да исәпкә ала. Тәрҗемәчеләрнең теге яки бу текстны сайлауларында ук аларның әсәргә тәнкыйди якын килүләре чагылыш таба. Кыскасы, шартлы рәвештә, шәрехчеләр белән тәрҗемәчеләрне дә тәнкыйтьчеләр янәшәсенә куярга мөмкин.

Урта гасыр әдәбиятына күзәтү ясыйсыңмы, аннан соң иҗат ителгән хезмәтләрне карап узасыңмы, әйткәнебезчә, әдәби тәнкыйтькә кагылышлы фикерләр тапмый калмыйсың, әмма язма мирасыбызның аз саклануы аркасында, филологик фәннәрнең башлангыч чорындагы картинасын күз алдына тулы китерү мөмкин түгел. Төрле тип әдәбият мулрак сакланган һәм инде күпмедер өйрәнелгән XVIII–XIX гасыр сүз сәнгатенә таянып та, әле аны өлешчә генә тасвирлап була. Бу чор әдәби тәнкыйте дә гыйльми эзләнүләр көтә.

Рус дөньясына күп кенә танылган шәхесләр тәрбияләгән, хәтта Н.И. Лобачевскийның остазы булган шагыйрь, галим, тәрҗемәче һәм педагог Нигъмәт Ибраһимов (1778–1818), мәсәлән, Казанда беренче әдәбият сөючеләр җәмгыятен җитәкли, анда йөрүчеләр әдәби әсәрләрне бәяләп кенә калмыйлар, язу алымнарына да

өйрәнәләр. Рус язучысы С.Т. Аксаков үзенең әдәбиятка килүен нәкъ менә аның исеме, аның дәресләре, өйрәтмәләре белән бәйли[1].

Дини-фәлсәфи хөкем йөртүләр көчәйгән кызыклы тарихи-биографик әсәрләр язылган XIX гасыр шул юнәлештәге әдәбият эчендә тәнкыйтькә нисбәтле фикерләргә еш урын бирә һәм яңа иҗтимагый-сәяси шартларда кискен үсеп китәчәк фәннәргә нигез тудыра. Бигрәк тә унтугызынчы гасыр ахырында татарның гуманитар фәннәре ирешкән уңышларга һәм кискен үсеп киткән прозасына – ул чагылыш тапкан басма сүзгә таянып, инде татар тәнкыйтенең торышын ачык аңларга мөмкин. Әйтик, Ш. Мәрҗанинең «Мөстафад әл-әхбәр фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан вә Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр» (1897–1900) һәм кайбер башка хезмәтләрендә татар әдәбиятын дәвамлы барыш рәвешендә күзаллау чагыла, тәрҗемәләр, каләм ияләре, гыйльми, нәфис әдәбият хакында фикерләр бар.

К. Насыйриның татар фольклоры өлкәсендәге эзләнүләре бүгенге көн галимен дә игътибар иттерерлек материалларга, халык авыз иҗатына мөнәсәбәтле кайбер фәнни-тәнкыйди нәтиҗәләргә алып килә. Галимнең «Фәвакиһ әл-җөләса фи әл-әдәбият» («Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимешләре») җыентыгында Кандалый иҗатына мөнәсәбәтле фикерләре, З. Бигиевнең үз хезмәтләренең жанр формаларын билгеләүләре һәм башка мисаллар татар каләм ияләренең, татар телендә әдәбият белеменә кагылышлы саф хезмәтләр булмаса да, чынлыкта теоретик белемгә ияләкләрен, көнбатыш һәм көнчыгыш гыйльмияте әдәбият өлкәсендә ирешкән биеклекләрдән хәбәрдарлыгын сөйли. Р. Фәхретдиннең «Асар» бибиблиографик белешмәлеге исә галимнең татар әдәбияты тарихын, аңа хезмәт итүчеләрнең тормыш һәм иҗат биографиясен озак еллар дәвамында өйрәнүен күрсәтеп тора.

XIX гасырның икенче яртысында, хәтта XX гасыр башында да татар әдәбияты һәм тәнкыйте үсешенә төрек сүз сәнгате йогынтысы биниһая зур була. Тугандаш халык әдипләренең әсәрләре, Көнчыгыштан һәм Көнбатыштан тәрҗемәләре, аларга урнаштырылган кереш сүзләр аша әдәбият теориясеннән шактый мәгълүмат керә. Әлеге мәдәни бәйләнешләр әдәбиятны һәм аңа хезмәт итүче фәннәрне үстерергә булыша. Бу чорда иҗат иткән Ш. Мәрҗани,

[1] Аристов В., Ермолаев Н. Все началось с путеводителя. Казань, Изд-во Казан. ун-та, 1975. С. 64–65.

Р. Фәхретдинов, Ф. Кәрими, Г. Исхакыйның һәм башкаларның иҗтимагый эшчәнлеге, әдәбият-сәнгатькә, дөньяви фәннәргә, икътисади алгарышка, дингә карата фикерләренең, хәтта әһле каләм сыйфатында үсешләренең бигрәк тә Ә. Мидхәтнең иҗтимагый эшчәнлеге, карашлары һәм иҗатының үсеш-үзгәрешләренә авазлаш икәнлеген күрербез.

Татар сүз сәнгатенә йогынты ясаучы төрек каләм ияләренең саны күп була, әмма һәрбер жанрга, әдәбият белеменә төрек иҗтимагый, фәлсәфи-эстетик фикерендә зур роль уйнаган шәхесләрнең йогынтысы барысыннан да калкурактыр. «Төрек энциклопедиясе»ннән алынган түбәндәге юллар белән төп әйдәманнарны шушы рәвешчә ассызыкларга мөмкин: «Романда – Әхмәт Мидхәт исә Нәмык Кәмал, шигырьдә янә – Нәмык Кәмал илә Экрәм вә Хәмид, әдәби тәнкыйтьтә Кәмал вә Экрәм, театр турында исә бонларның һәммәсе бердән бу әдәбиятның корылмасында»[1]. Профессор Орһан Окай исә китапларга керешләр яисә махсус хезмәтләр аша укучыга әдәбият теориясеннән мәгълүмат ирештергән, әдәби барышка мөнәсәбәт белдергән Нәмык Кәмалны «Тәнзимат әдәбияты» китабында шул дәвернең, чор әдәбиятының «гомуми мәсьәләләре хакында иң күп язган мөхәррир»е, «модерн әдәбиятның тәүге тәнкыйтьчесе» (1990, б. 93). дип атый. Белгәнебезчә, аның барлык китаплары татарларга таныш була, һәм кайберләре тәрҗемә дә ителә. Югарыда исемнәре телгә алынган төрек әдипләре үзләре шулай ук алдынгы әдәбиятларның, аны өйрәнүче фәннең көчле йогынтысын тоеп иҗат итә.

Татар әдәби тәнкыйтенең яралгылары, беренче үрнәкләре күпкә алдарак пәйда булса да, асыл сыйфатлары тирәннән ачыклану, аны инде иҗади-фәнни өлкә рәвешендә аңлау чын мәгънәсендә милли әдәбият формалашып җиткән XX гасыр башына туры килә. Бу чорда әдәбиятның һәм аны яктыртуны максат иткән тәнкыйтьнең кискен күтәрелеше үзара ярдәмләшүнең чагылышы булып тора.

XX гасыр башында күпкә ирекләрәк, фикер формалаштыру ягыннан мөмкинлекләре дә зуррак тәнкыйть беркадәр әдәбиятның гомуми үсешен узып киткән кебегрәк тә тоела, чөнки аны нәкъ менә татар прозасының һәм поэзиясенең авангардында барган

[1] Turk Ansiklopedisi. Cilt XXXII. Ankara, Devlet kitaplari, Milli Icitim Basimavi, 1983. S. 512.

каләм ияләре кулда тота. Алар, әдәби тәнкыйтьнең үткен теле белән коралланып, аеруча фельетон кебек сатирик формаларыннан һәм аналитик язмалардан файдаланып, башка каләм ияләрен дә яңа биеклекләргә әйдиләр, әдәбиятның тел ягыннан сафлыгы, реалистик нигезе, иҗтимагый барышка хезмәт итүе, жанрлар ягыннан баюы, үсүе өчен көрәшәләр.

XX гасыр башы татарлар арасында әдәбият тарихын язучы, аны яктыртучы фәннәрнең принципларын эшләүче галимнәр үстерүне көн кадагына куя. Бу чорда югары дөньяви һәм бер үк вакытта дини гыйлемнәр дә алган иҗтимагый эшлеклеләр, әдәбият белгечләре иҗтимагый-фәлсәфи-эстетик фикер мәйданына чыга; аларга Көнбатыш һәм Көнчыгыш әдәбиятлары, фәлсәфәсе бердәй аңлаешлы була; универсаль белемле шәхесләр ике нигезгә таянып үскән татар әдәбиятының киләчәк үсеш юлларын ачык күзаллыйлар. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Н. Гасрый, Г. Кәрам, Г. Рәхим, Г. Сәгъди, Җ. Вәлиди, Г. Кәрам һәм башкалар иҗтимагый аң төре буларак бәяләнгән әдәбиятка зур игътибар бирәләр, аны өйрәнү, башкаларга тәкъдим итү белән актив шөгыльләнәләр. Бу вакытта әдәби тәнкыйть, аның теоретик нигезләре турында махсус китаплар язылмаса да, җәмгыятьтә әлеге фәнне предмет буларак ачык күзаллау яши. Бер генә каләм иясе дә элек һәм хәзер дөньяга килгән әдәбиятны язма яисә һич югы телдән бәяләүдән читтә калмый, торган саен кыза барган иҗтимагый-сәяси көрәш мәйданында әдәбият һәм аны яктырткан тәнкыйть чын мәгънәсендә идеологик коралга әйләнә.

XX йөз башында татар вакытлы матбугатының зур үсеш алуы, аның нәфис әдәбиятка махсус игътибары, сүз сәнгатен кеше холкын камилләштерүче, татар тормышын алга җибәрүче, милли аң һәм әдәби зәвык тәрбияләүче коммуникатив чара итеп каравы, басмаханәләр саны һәм китап-рисаләләр чыгару мөмкинлекләре арту, иҗтимагый-фәлсәфи фикернең алга китеше әдәби тәнкыйть үсешенә һәм иң мөһиме – аның мөстәкыйльләшә башлавына заманга лаек шартлар тудыра.

Татарларга иҗтимагый үзаңны үстерерлек, югары эстетик зәвык тәрбияләрлек әсәрләрне пропагандалау юлында иң башта И. Гаспралының «Тәрҗеман» газетасы зур эшләр башкара. Ул шулай ук төрки каләм ияләренең мәдәни бәйләнешләрен ныгытуга, әдәби уңышлар белән үзара бүлешүгә, төрле халыклар иҗат иткән нәфис әдәбиятны чагыштырып бәяләүгә мөмкинлек тудыра. Алга таба Гаспралы башлаган эшне үз наширләребез күтәреп ала.

XX гасырның беренче унъеллыгында чыгып килгән «Аң», «Шура», «Мәктәп» кебек мәртәбәле журналларда тәнкыйть мәсьәләләренә игътибар тагын да арта. Татар каләм ияләре бу чорда әдәби тәнкыйтьнең предметы, максат-бурычлары, нәфис текстларын бәяләү критерийлары, алым-чаралары, тәнкыйтьче әхлагы һәм башка күпсанлы проблемаларны күтәрә. Язучылар, әдәби-публицистик формалардан да актив файдаланып, теге яки бу әсәрләргә бәйле бәхәсләр кузгаталар, һәм тәнкыйть торган саен җанлана бара. Аның кызыклыгы, төрлелеге арту тикшерү объектларының сан-сыйфат үзгәрешләре кичерүе, жанрлар модификациясе аркасында төрлеләнүе белән янәшә бара.

Яңа иҗат методларының мәйданга килүе, сүз сәнгатенең яңа алым-чараларга, формаларга баюы да тәнкыйтьченең әдәбият турында, үткәне белән бүгенгесен чагыштырып, нәтиҗәләр чыгару, үзенчәлекле фикер әйтү мөмкинлекләрен арттыра. Алга таба әдәбият мәйданына төрле фәлсәфи-эстетик күзаллауларга ия, еш кына бер-берсенекеннән аермалы иҗтимагый-сәяси карашларны пропагандалаган каләм ияләре тагын да күбрәк килә. Татар нәфис әдәбияты да һәм аңа хезмәт иткән тәнкыйть тә, төп максаты рәвешендә сүз сәнгате ярдәмендә милли-мәдәни-иҗтимагый алгарышны кайгыртуны куя. Тәнкыйтьнең үзаңы калыплашу каләм ияләренең һәм татар халкының үзаңы уяну белән янәшә бара.

Икенче унъеллыкта да тәнкыйтьтә бәхәс рухы торган саен ныграк көчәя. Авторларның һәрберсе, шәхеснең кемлегенә карамыйча, укучыны да, язучыны да аямыйча, үзе инанганча, туры сүз әйтеп калырга, фикеренә массаларны ышандырырга тырыша, тәнкыйтьтә объективлык һәм субъективлык бик тыгыз үрелә. Әдип иҗатына бәя чор таләпләреннән чыгып бирелә башлый; язучыга милләт язмышын хәл итү бурычы йөкләнә, моның өчен ул иҗаты аша аңа дөрес юлны күрсәтергә, халык массаларын иҗтимагый-сәяси көрәшкә әйдәргә тиеш була. Шулай итеп, татар әдәбиятының авангардында барган Г. Тукай, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ш. Камал һәм бүген киңкатлам укучы исемнәрен дә белмәгән бик күп каләм ияләре милли әдәби хәрәкәткә тартыла. Әдәбият локомотивы вазифасын башкарган каләм ияләребез исә әдәби тәнкыйтьнең төп вазифасы, принциплары, төрләре, объективлыгы һәм субъективлыгы, чынбарлык һәм әдәбият белән мөнәсәбәтләре, прозабызның, шигъриятебезнең, ныгып килгән драматургиябезнең халыкчанлыгы, миллилеге һәм башка бик күп мәсьәләләр турында уйлана.

XX гасыр башында алдагы чорларда, нигездә, Көнчыгышка йөз тотып үскән әдәбиятыбыз Көнбатышка таба борыла башлый. Ул бу вакытта үзе өчен яңа булган формалар, калыплар, поэтик чаралар үзләштерә, ныгыган эстетик-фәлсәфи күзаллауларын алга киткән әдәбиятлардагы күзаллаулар белән кушарга омтыла, үсәр өчен кыйбла сайлый. Сүз сәнгатенә карата икенчел һәм аны төрле яссылыкларда өйрәнүче филология бу эзләнү-уйлануларда булышлык итәргә, язучыларның фәлсәфи-эстетик карашларына үз мөнәсәбәтен белдерергә, шуның бер тармагы булган әдәби тәнкыйть исә матур әдәбиятка төзәтмәләр кертергә, каләм ияләренә киңәшләр бирергә тиеш була. Шул ук вакытта ул әле үзе дә аягына яңа гына басып килә һәм Көнчыгыш белән Көнбатыш тәкъдим иткән үлчәүләрне, күзаллаулар системасын сайлау алдында тора. Әдәбият белемендә дә, аны калыплаштыручы өлкәләрдә дә Шәрекъ һәм Гареб мәдәниятләренең татар әдәбиятына үз тәэсирләрен саклау яисә ныгыту өчен көрәше бара сыман. Бер-берсеннән шактый нык аерылган мәдәниятләрнең теоретик проблемаларны хәл иткәндәге әлеге дә баягы үзара бәхәс рәвешен алган тәэсире озак вакытлар дәвамында сиздерә. Тора-бара татар укымышлылары ике мәдәни ориентирны үзара яраштыруга, милли сүз сәнгатенең үсешенә хезмәт иттерүгә ирешә. Алай да фәннең һәр өлкәсендә акрынлап Көнбатышка йөз тоту көчәя.

XX гасырның инкыйлабкача чорында фәндә тәнкыйть, интикад кебек терминнарның актив кулланылышы шулай ук әдәби тәнкыйтьне фәнни-иҗади өлкә рәвешендә тануны күрсәтә. Баштарак галимнәребез, гарәпләрдәгечә, интикад төшенчәсеннән күбрәк файдалансалар да, бераздан тәнкыйть терминына өстенлек бирелә башлый. Бу уңайдан, әдәби тәнкыйть хакында махсус сүз йөрткән хезмәтләргә мисал итеп, Г. Сәгъдинең «Өмет» нәшриятында басылган «Әдәбият ысуллары»н (1912), Р. Фәхретдиннең «Шура»да чыккан тәнкыйтьнең эчтәлеген, шуннан чыгып кайбер төрләрен аңлаткан «Интикад вә тагын...» (1916) хезмәтләрен китерергә мөмкин. Бу чор вакытлы матбугатында терминнарның килеп чыгышына, кулланылышына, максат-бурычларына, эчтәлегенә бәйле кызыклы фикерләр чагылыш тапкан язмалар шактый урын алган. М. Укмасый, Н. Гасрый, Җ. Насыйп һәм башкаларның XX гасыр башында дөнья күргән тәнкыйтькә мөнәсәбәтле хезмәтләре аңа гыйльми-әдәби эшчәнлек буларак игътибарның нәкъ менә унынчы еллар башыннан аеруча җанлануын күрсәтә.

Инкыйлабкача ук татар галимнәре әдәбият белеменә, шул исәптән тәнкыйтькә кагылышлы терминнарны татарча эшләргә кирәклеген тоялар, электән кулланылып килгән көнчыгыш терминологиясеннән дә баш тартырга теләмиләр, әмма, рус культурасы тәэсиренә ныграк керә барган саен – моның кыенлыгы, әлеге мәдәниятнең басымы бик нык арткач, инде мөмкин түгеллеге аңлашыла. Шулай итеп, фәндә гасыр башында әйләнештә йөргән кайбер гарәпчә төшенчәләр гасыр дәвамында яшәвен дәвам итсә дә, тора-бара Европа аша кергән терминология зур урын алып тора башлый. Моңа тәнкыйть адресатының, беренче чиратта, вакытлы басмаларны укучылар катламының үзгәрүе, көнчыгыш гыйльменнән тирән хәбәрдар булмаганнар хисабына киңәюе, үз галимнәребезнең дә, ахыр нәтиҗәләр хакында артык уйламастан, кирәктә генә түгел, кирәкмәгәндә дә, рус сүзләрен сөйләмнәрендә активлаштыруы да китерә.

XX гасыр башында әдәби тәнкыйть үсешендә зур роль уйнаган ике шәхес – Г. Ибраһимов белән Г. Баттал. Алар татар тәнкыйтенең нигезләрен эшләү уе белән яналар, аның предметы, үсеш шартлары, максат-бурычлары турында язалар, татар каләм ияләрен Аурупа илләре фәнендә әдәбиятка мөнәсәбәттә инде кабул ителгән кануннар, тәнкыйть өлкәсенә кагылышлы төшенчәләр белән таныштыралар. Шушы чордан башлап, әдәби әсәрләрдә чагылыш тапкан фикерләр, вакытлы матбугат битләренә узган репликалар, тегендә-монда очраклы сакланып калган язмалар рәвешендә яшәгән әдәби тәнкыйть, алар тырышлыгы белән дә, мәдәни-иҗтимагый хәрәкәт эчендәге өзлексез юнәлеш, әдәбият эчендәге уйландыра торган һәм дәлилле, эзлекле хөкем рәвешен ала. Г. Ибраһимов алга таба шушы юнәлештәге эшчәнлеген бервакытта да ташламый.

XX гасыр башы фәнендә Г. Батталның «Нәзарияте әдәбия»се (1913) аеруча игътибарга лаек. Әлеге хезмәттә «критериум» төшенчәсе астында сәнгатькә, шул исәптән әдәбиятка караган әсәрләрне бәяләгәндә, анализлаганда таянылырга тиешле кагыйдәләр җыелмасы тәкъдим ителә. Икенче төрле әйткәндә, Г. Баттал гыйльми эзләнүләрнең, бигрәк тә әдәби тәнкыйтьнең методологиясен эшли. Ул әдәби тәнкыйтьнең фәннилеген алгырак планга чыгара. Ул шул чорда ук, тәнкыйть фән белән нәфис әдәбият арасында торган өлкә саналса да, анда әдәбилекнең басып китмәскә тиешлеген аңлап эш йөртә. Әдәбиятны хөкем итү ничек кенә матур-хисси сөйләм белән алып барылмасын, беренче чиратта, логик эзлекле,

теоретик базага таянган, дәлилле булырга тиеш, һәм бу аның фәннилек дәрәҗәсен, шуның белән беррәттән, мәртәбәлелеген күрсәтеп тора. Билгеле ки, реаль чынбарлыкта тәнкыйть хезмәтләрендә, авторына бәйле рәвештә, фәннилек һәм әдәбилекнең үлчәү тәлинкәләренең я тегесе, я монысы басып китә, әдәбилек исә күпчелек очракта башлап язучыларның, фәнни хәзерлексез тәнкыйтьчеләрнең язмаларында өстенлек итә.

Г. Баттал тәнкыйтьнең әдәби берәмлеккә якын килү юлларын ача. Ул аның белән шөгыльләнүченең нәфис текстның кагыйдә-кануннарга нигезләнүе, структур элементларының эзлеклелеге турында фикер йөртергә һәм сәнгатилегенең, идея эчтәлегенең заманга лаеклылыгын, темаларның ачык һәм тулы чагылышын, стиль камиллеген, текст бөтенлеген ачарга тиешлеген күрсәтеп бирә.

XX гасыр башында әдәби тәнкыйтькә еш кына үтә хирысчан язучы прозаик һәм шагыйрьләрнең дә зур өлеш кертүе аның бәхәсләр мәйданына әверелдерә, тәнкыйтьне нәтиҗәле, кызыклы һәм җанлы итә. Ул стиль һәм алымнарга бай, төрле булып күренә. Анда Г. Тукайның – тешле, ә Җ. Вәлидинең фәнни нигезле тәнкыйте, Г. Ибраһимовның сәнгатьне иҗтимагый-сәяси көрәш белән бәйләгән хезмәтләре, Ф. Әмирханның әдәбиятның иҗтимагый роленә, миллилегенә, халыкчанлыгына басым ясаган язмалары, әдәбият белән театр сәнгатенә бер яссылыктан караткан театраль рецензияләр, язма әдәбият тарихында исемнәре әлегәчә аз яктыртылган күпсанлы тәнкыйтьчеләрнең вакытлы матбугатта дөнья күргән бәхәсле фикерле мәкаләләре шуларга мисаллар булып тора.

Еш кына бер үк әсәрләргә бирелгән каршылыклы бәяләмәләр бу чорда уңай һәм кире, иске тел белән әйткәндә, иҗаби һәм сәлби тәнкыйтьнең шактый зур үсеш алганлыгын күрсәтә һәм әдипләрне, галимнәрне тәнкыйть төрләре турында уйлануларга да этәрә. Калыплаша баручы әдәби тәнкыйть терминологиясенә шәхси, хакыйкый, тәган (сүгү, хурлау) һәм башка төшенчәләр үтеп керә. Шәрех, хашия, тәгъзия язу традицияләре тәмам узмаса да, тәнкыйтьнең, гадәттә, вакытлы матбугат тууына, үсешенә нисбәтле активлашучы хәбәр, аерым әсәргә аннотация яисә рецензия, күзәтүләр һәм башка жанрлары аны бәхәсләр мәйданына әверелдерә.

Инкыйлаб алдыннан вакытлы матбугатта басылган язмаларны, фәнни яисә фәнни-популяр китапларны бергә туплаганда, татар каләм ияләренең тәнкыйтьне күзаллаулары, аңлаулары чорына карата тулы икәнлек күренә. Һәм инде әдәбиятның авангар-

дында баручыларның, тәнкыйть куйган таләпләргә туры китереп, дөнья әдәбияты югарылыгында нәфис әсәрләр тудырулары да шушы аңлауның бер чагылышы булып тора. XX гасыр башында иҗат иткән каләм ияләренең берсе генә дә татар тәнкыйтен калыплаштырудан читтә калмый. Әйтик, Г. Исхакый, Ш. Камал, Г. Камал яисә башкаларның гыйльми-популяр, әдәби-публицистик, публицистик мирасы, хатлардан яисә башка төр истәлекләрдән торган архивлары белән танышканда, тәнкыйтькә нисбәтле хезмәтләр, фикерләр, һичшиксез, табыла.

XX гасырда татар тәнкыйтен үстерүдә аны һөнәр итеп сайлаган Җ. Вәлиди, Г. Кәрам, Г. Баттал, Ә. Нәҗип һәм башкалар бар. Язучылар белән укучылар тәнкыйтенә дә мисаллар җитәрлек. Шул ук вакытта Г. Ибраһимов кебек универсаль талант ияләренең фәнни нигезләү омтылышлы, киң мәгълүматка, эчке тоемга таянган тәнкыйтен бары тик язучыларныкы кысаларында гына карау дөрес булмас иде. Тәнкыйди язмаларны төркемләгәндә, кешенең хезмәт урынын, иҗат юнәлешен исәпкә алудан битәр, текстның үзе, аңа хас сыйфатламалар алгы планга чыгарга тиеш.

Әгәр нәкъ менә XIX–XX гасырлар чигендә формалашкан үз тәнкыйтебезне барлап чыксак, анда да социал-демократик, дини-идеалистик, эстетик, реалистик һәм романтик тәнкыйть; халыкчылар (народниклар) яисә язучылар, вакытлы матбугат тәнкыйте; модернистик тенденцияләр һәм аларның элементлары турында сүз алып бара, мисалларын да күрсәтә алыр идек. Бүгенге галимнәр алдында әдәби тәнкыйть тарихын әнә шулай – киңпланлы, төрле яссылыкларда анализлау проблемасы тора әле. Ул исә, үз чиратында, татар әдәби тәнкыйтенең тарихын гына түгел, нигезләрен дә тирәнтенрәк ачуга китерәчәк.

Татар әдәбият белемендә татар тәнкыйтенең калыплашуын проблема рәвешендә өйрәнүгә дә килик. Теманы махсус чагылдырган хезмәтләр арасында Р. Мөхәммәдиевнең «Проблемы формирования татарской литературной критики (1900–1917)»[1] монографиясен аерып атарга кирәк. Анда сүз тәнкыйтьнең предметы, мөстәкыйльләшүе, иҗтимагый-әдәби вазифалары, тәнкыйть шартлары һәм башка мәсьәләләр карала. Т. Гыйләҗевнең «Татар әдәби тәнкыйте тарихы (1900–1925)» дип аталган махсус курс

[1] Мухаммадиев Р. Проблемы формирования татарской литературной критики (1900–1917). Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. 143 с.

программасында шулай ук татар әдәби тәнкыйтенең үзаңы калыплашуын ачу бар.

Ф. Галимуллин, Э. Галиева, Д. Заһидуллина, И. Нуруллин, Т. Гыйләҗев, Ч. Гыйләҗева, М. Мәһдиев, Ф. Яхин, Ә. Закирҗанов һәм башкаларның хезмәтләреннән дә татар тәнкыйте формалашуга мөнәсәбәтле бүлек-бүлекчәләр яисә мөһим фикерләр табарга мөмкин. Әйтик, Д. Заһидуллина «Формирование и этапы становления теории татарской литературы (первая треть XX века)» дип исемләнгән докторлык диссертациясендә (2006) һәм «Әдәбият кануннары һәм заман» (2000) хезмәтендә, «татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары» проблемасын чишкәндә, әдәби тәнкыйтьтәге инкыйлабкача үзгәрешләрне, күренешләрне дә тасвирлый.

Татар әдәбият белеме тарихын (әдәби тәнкыйтьнең шуның бер өлеше булуын онытмыйк) яктыртуны тар планда алып та, шактый тирән һәм киң күзалларлык чагылдырган хезмәт – һичшиксез, Э.Р. Галиеваның «Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе» китабы. Галимә, беренче чиратта, егерменче еллар татар әдәби фикер хәрәкәтен «рус һәм көнбатыш Европа фәне үсешенең гомуми типологик рәтенә куеп карый», закончалыкларын, принципларын билгели. Э. Галиева шул ук вакытта татар әдәбияты тарихын чорларга бүлү һәм өйрәнү нигезләрен дә махсус тикшерә. Шуңа багышланган бүлектән татар фәннәренең мөстәкыйльләшә баруы хакында кызыклы гына фикерләр табарга була. «Үзенең эшчәнлегендә татарның тарихын, *әдәбиятын*, динен, мәдәниятен – һәрберсен *аерым мөстәкыйль тармак*лар рәвешендә һәм үзара тыгыз, тирән бәйләнешләрдә өйрәнүне төп юнәлеше итеп алып барган Риза Фәхретдинов, киң мәдәни юнәлештә эшләүче Фатих Кәрими (язучы, *тәнкыйтьче*, әдәбият галиме, публицист, журналист, нәшир-матбагачы, педагог, тәрҗемәче...»[1], – дип башланган юллар, мәсәлән, татар әдәби тәнкыйтенең кайсы чорда чын-чынлап мөстәкыйльләшә баруына ишарәләп тора.

Э. Галиева хезмәтендә татар әдәби тарихын чорларга бүлү принципларының узган гасырның унынчы елларында аеруча нык эшләнә башлавы, егерменче елларда методологик позициягә бәйле бәхәсләр көчәю, әдәбиятны өйрәнүнең эзлеклелеге, төр-

---

[1] Галиева Э. Р. Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. Казан: Фән, 2002. Б.280.

ле концепцияләргә нигезләнүе күренә. Галимә: «XIX гасырдан башланып киткән татар Яңарыш хәрәкәте XX гасырның 20 нче еллары – 30 нчы елларының урталарына кадәр дәвам итеп килде, үсеп, күтәрелеп барды», – ди. Әлеге уңай үзгәрешләр, һичшиксез, сүз сәнгате һәм аны яктырткан, әйдәкиләгән әдәби тәнкыйть барышында да чагыла. Нәкъ менә 20–30 нчы елларда Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин, Г. Нигъмәти, Г. Толымбай, Г. Сәгъди кебекләр тарафыннан әдәбият белеменең предметы, вазифалары, иҗат методлары, әдәбият тарихын чорларга бүлү мәсьәләләре, әдәбиятны өйрәнү механизмы һәм башкалар өйрәнелә икән, болар барысы да әдәби тәнкыйть фәненең дә алга таба үсешенә, тагын да ныграк шәкелләшүенә китерә.

Гасыр башы тәнкыйтен өйрәнү соңгы егерме биш ел эчендә нык көчәюгә карамастан, бу юнәлештәге фәнни эзләнүләрне тирәнәйтү мөмкинлекләре зур әле. Галимнәребез алдында түбәндәге бурычлар тора: тәнкыйть материалларын тагын да туплау, аларны шул чорның иҗтимагый-фәлсәфи фикеренә нигезләп анализлау һәм ачык төсләрдәге яисә төсмерләнеп кенә килгән агымнарын бөтен нечкәлекләре белән күрсәтү.

## 2.2. Дөнья һәм рус әдәби-тәнкыйди фикер тарихы

Кайсы гына фән барлыкка килмәсен, аның үсешен аерым этапларда күрсәтми калмыйлар. Тәнкыйди фикер эволюциясе әдәбиятныкы белән тыгыз бәйләнгәнлектән, бергә барганлыктан, үсеш баскычларының чикләрен дә әдәбият тарихы этапларыныкына якынайтырга омтылалар. Әлеге баскычлар шулай ук матбагачылык тарихы, иҗтимагый, мөһим сәяси вакыйгалар белән дә тәңгәл килергә мөмкин. Әдәби тәнкыйть хәрәкәтендә иҗтимагый фикер үсеше чагылган кебек, иҗтимагый тормыш динамикасында да тәнкыйди фикер шулай ук аерым урын алып тора. Әдәби тәнкыйть тарихы этапларында аның үз агым һәм юнәлешләренең алмашынуы да, әдәби барыштагы эчке үсеш закончалыклары да, сәнгати аңдагы үзгәрешләр дә чагылыш таба.

Филологиянең нинди генә өлкәсен алсаң да, чорларга бүлү өчен, җитәрлек күләмдәге материал тупларга кирәк. Ничәмәничә гасырларга сузылган сүз сәнгате тарихын, шуның эчендә үсә башлаган әдәби тәнкыйтьне яктыртканда бу җиңел эш түгел. Бердән, гомуммәдәни хәтердә, аның язма мирасында, төрле сәбәпләр аркасында, барлык әдәби берәмлекләр дә сакланып кала

алмый. Борынгыда, тарих дәвамында зур тарихи фаҗигаләр кичергән халыкларда бигрәк тә. Икенчедән, кулланыштагы графикалар алмашыну сәбәпле, килер чор галимнәренә аларны өйрәнү кыенлаша. Өченчедән, теге яки бу халыклар географик урынчалыкларын үзгәртергә, дөнья буйлап күченеп йөрергә һәм тарихка, әдәбиятка кагылышлы мирасын да таратырга, югалтырга мөмкин. Боларның һәр өчесе дә төрки-татар кавемнәрнең барысына да карый. Галимнәребез алдында һаман да, узганның өзек-өзек һәм аз күләмдә сакланган истәлекләреннән чыгып, чит әдәбиятларның материалларына да таянып, үз тәнкыйть тарихыбызны мөмкин кадәр объективрак һәм ышандыргычрак яктырту бурычы тора.

Әдәбият белеме һәм аның аерым өлкәләре үзенчәлекле фән буларак шактый соң формалашып җитсә дә, тәнкыйть тарихы әдәбият барлыкка килгән көннән – борынгы мифлар чорыннан ук башлана, үзенең тәүге этабында ул гомумфилология һәм философия эчендә үсә. Синкретик характердагы язмалардан әдәбиятка кагылышлы фикерләрне чүпләү һәм шәрехләү әдәби тәнкыйть тарихын тудыручы аз сандагы галимнәрдән күп көч һәм вакыт сорый. Фәнни эзләнү алып баручылар, төрле чорлар тәнкыйтен ачканда, аның үзенчәлекле сыйфатларына игътибар иткән кебек, күчемлелек проблемасын да күз уңыннан чыгармаска тиешләр.

Әдәби тәнкыйтьнең чишмә башы бик борынгы чорларга барып тоташса да, чын мәгънәсендә калыплашып җитүе озак гасырларга сузыла. Шул ук вакытта аның һәр этабында тәнкыйтьчеләрнең әдәбиятка хезмәт иткән бу өлкәне аңлаулары һәм күзаллаулары формалаша. Галимнәр тәнкыйть тарихын чагылдыруны антик заманнардан башлыйлар һәм эчтәлеген аңа хезмәт иткән каләм ияләренең мирасы аша күрсәтәләр. Мәсәлән, А.С. Козлов антик чорлар тәнкыйтенә:

– софистлар һәм риторлар;
– Платон;
– Аристотель;
– Борынгы Рим философларының язганнарын кертә[1].

Урта гасырда тәнкыйть бик йомшак була, үстерелми, Аристотель, Гораций карашларына таянып яши. Ә инде XIII гасырда Аристотель,

[1] Козлов А. С. Основные этапы развития литературно-критической мысли // Основы литературоведения: В.П. Мещеряков, А.С. Козлов и др. М.: Дрофа, 2003. С. 355–414.

Платон идеяләрен яңадан эшкәрткән христиан рухание Фома Аквинский тәнкыйть мәйданына аяк баса. Яңарыш чорында тәнкыйтьчеләр әдәбиятта милли тел, жанрлар мәсьәләсен ныклап өйрәнә.

Мәгърифәтчелек идеяләре иҗтимагый мәйданны яулагач, әдәби тәнкыйтьтә дә акыл культы күзәтелә, классицизмнан килгән кайбер традицияләр дәвам итә. Вольтер, Дидро, Лессинг, Прокопович, Тредиаковский, Ломоносов – шул чорның танылган тәнкыйтьчеләре санала.

Әдәби тәнкыйтьнең үсеш этаплары аның үзен аңлау, бәяләү дәрәҗәсе белән тыгыз бәйләнештә бара. XIX гасырда әдәбият белеме әдәбият тарихы, әдәбият теориясе кебек өлкәләрен формалаштыра, әдәби тәнкыйть тә үзен фән буларак аңлый. Аларның ярдәмче дисциплиналары текстология, чыганакчылык, библиография һәм башкалар калыплаша. Романтикларның эстетик карашлары бик төрле булса да һәм аның мәйданында яңа мәктәпләр (мәдәни-тарихи, чагыштырма-тарихи, рухи-тарихи һ.б.) барлыкка килсә дә, аларны иҗатчы культына, даһига табыну берләштерә.

XX гасырны тәнкыйть югары үсеш алган чор дип бәялиләр. Бу чордан мифологик тәнкыйть (Дж. Фрейзер, Г. Мэррей, Дж. Харрисон, Н. Фрай, Т. Уиннер һ.б.), психоаналитик тәнкыйть (З. Фрейд, К. Эйкен, Д. Крач, Э. Джоунс, Р. Вест, М. Бонопарт һ.б.), структурализм (Р. Барт, Ю. Кристев һ.б.), семиотика (Ф. Де Соссюр, Ч. Прис һ.б.) кебек юнәлешләрне аерып чыгаралар. Болардан тыш, деконструктивизм, формаль мәктәпләр, импрессионистик һәм феноменологик тәнкыйть, герменевтика тарафдарлары һ.б. төркемнәр дә бар.

Дөньякүләм әдәби тәнкыйть үсешенең этаплары, төрле тип бүлүләр һәм әдәби тәнкыйть мәктәпләре турында тирәнтен рәвештә «Әдәби тәнкыйть тарихы» яктыртканлыктан һәм шул юнәлештәге хезмәтләр күплектән, бу бүлекчәдә сүз кыскача һәм өстән-өстән генә күзәтү формасында барыр. Татар әдәбияты һәм тәнкыйте үз үсешендә дөнья халыклары һәм бигрәк тә русларның казанышларын файдаланганга, дөнья әдәби тәнкыйтен үстерүдә зур роль уйнаган рус тәнкыйтенә аерым да тукталырбыз. Әдәби тәнкыйть фәне эчендә аның тарихын еллар-чорлар аралыгында күрсәтү мәсьәләсе, һичшиксез, күтәрелергә тиеш.

Рус әдәби тәнкыйтенең үсеш баскычлары галимнәр тарафыннан инде күпсанлы китапларда чагылдырылган, шуңа да карамастан, этапларга бүленеше генә түгел, хәтта аның башка фәннәрдән аерылып чыга башлавы, мөстәкыйльләшүе вакытына

карата да уртак фикергә ныклы киленмәгән, югыйсә бу турыда инде XIX гасырдан бирле бәхәсләр бара.

Әдәби тәнкыйтьнең башлангыч чорына мөнәсәбәтле киңрәк таралган кайбер фикерләр белән таныштырып узыйк. В. В. Прозоров җитәкчелегендә Мәскәү галимнәре чыгарган «История русской литературной критики» (2002) китабында, рус әдәби тәнкыйте әдәбиятта классицизм ныгуга мөнәсәбәттә башлана, дигән фикер әйтелә һәм, 1740–1770 еллар – аның башлангыч этабы, дип белдерелә[1]. Бу чорда әдәби тәнкыйть әдәбият һәм әдәбият белеме белән тыгыз бәйләнештә, аларның эчендә үсә; нәфис текстларны анализлау белән чын-чынлап шөгыльләнерлек һөнәри тәнкыйтьчеләр әле юк, ул шагыйрь һәм әдипләрнең эшчәнлеге булып тора. «История русской критики XVIII–XIX веков» (1972) китабында В.И. Кулешов шулай ук рус тәнкыйте XVIII гасырда барлыкка килгәнне әйтә, әмма киңрәк аралыкны ала. Ул, рус тәнкыйте формалашу табигый һәм кануни булды, бу чорда каләм ияләре тәнкыйди фикергә зур ихтыяҗ кичерә башлаган иде, дип белдерә.

Б.П. Городецкий редакторлыгында чыккан «История русской критики» (М.; Л., 1958. Т. 1) китабында рус тәнкыйтенең XIX гасырга инде калыплашып җитүе сөйләнелә. Бер төркем галимнәр башкарган «Очерки истории русской литературной критики» хезмәтендә дә әлеге китаптагыга охшаш карашлар чагылыш таба[2].

XXI гасырга аяк атлагач басылган хезмәтләр арасында алда телгә алынган «История русской литературной критики» дәреслеге – әдәби тәнкыйть тарихын этапларда күрсәтү юнәлешендәге хезмәтләрнең шактый тирәне, фәнни нигезлесе булып тора сыман[3]. Анда тәкъдим ителгән бүленеш әдәбият тарихы этапларына һәм шулай ук иҗтимагый формацияләр алмашына таяна һәм, мәсьәләгә формаль якын килгәндә, төрле юнәлештә күренгән процессларның какшамас бердәмлеге турында сөйли. Әлбәттә, тәнкыйть тарихын гуманитар фәннәр тарихы янәшәсенә дә куеп карарга мөмкин. Һәр очракта да ул милли барышның да бер сыйфатламасы рәвешендә күренеп торачак.

[1] История русской литературной критики: учеб. для вузов: В.В. Прозоров, О.О. Милованова, Е.Г. Елина и др.; под ред. В.В. Прозорова. М.: Высшая школа, 2002. С.20.

[2] Стенник Ю.В. Литературная критика периода классицизма (1740-е – 1770-е гг.). Очерки истории русской литературной критики: в 4-х т. СПб., Наука, 1999. Т. 1: XVIII первая четверть XIX в. С. 37–95.

[3] История русской литературной критики. 463 с.

Аталган хезмәттә рус әдәби тәнкыйтенең үсеше унике этапта чагылдырыла:

– XVIII гасыр;
– XIX гасырның беренче чиреге;
– 1830 еллар;
– 1840–1850 еллар башы;
– 1850 уртасыннан алып 1860 еллар ахырынача;
– 1870–1880 еллар;
– 1880 еллар ахыры – 1910 еллар;
– 1920–1930 еллар;
– 1930–1955 еллар аралыгы;
– 1955–1960 еллар;
– 1970–1980 еллар;
– туксанынчы еллар әдәби тәнкыйте.

Югарыдагы бүленеш эчендәге узган гасырга караган этаплар татар тәнкыйте үсешенең баскычларын да чагылдыра ала.

Хәзерге вакытта рус әдәби тәнкыйтенең аерым чорлар эчендә бүленешләре ныклап өйрәнелә. Мәсәлән, XIX гасыр әдәби тәнкыйте Л.М. Крупчанов хезмәтендә бик тирән яктыртыла[1]. Фәнни өлкә тарихын шул чордан тәфсилле анализлау тәнкыйтьчеләрнең, әдәби күренешләрне шәхси зәвыкны һәм авторның стиль үзенчәлекләрен алгы планга куеп бәяләү белән канәгатьләнмичә, әсәрләрнең идея-тематик эчтәлегенә ныклы игътибар итүләре һәм тәнкыйтьне дә мөстәкыйль фән буларак танулары белән бәйле.

«1820 еллар ахыры – 1830 еллар ахырында А. Мерзляков, Н. Полевой, Н. Надеждин язмаларында Рәсәйдә рус реалистик тәнкыйте формалашуны тәмамлаучы Белинский тәнкыйте алдыннан килгән һөнәри тәнкыйть калыплаша»[2],– дип яза Л.М. Крупчанов. Галим XIX гасырдагы рус әдәби тәнкыйте тарихын чагылдырган хезмәтендә аерым чорларда авторлар тәнкыйте белән периодика тәнкыйтен аерып куя һәм түбәндәге бүленешне тәкъдим итә:

**I. XIX гасыр башы тәнкыйте (1800 –1830):**

– классик тәнкыйть;
– сентименталь тәнкыйть;

---

[1] Крупчанов Л.М. История русской литературной критики XIX века. М.: Высшая школа, 2005. 383 с.

[2] Шунда ук. С. 8.

– романтик тәнкыйть (шунда ук декабристлар тәнкыйте, профессиональ тәнкыйть);

– фәлсәфи тәнкыйть;

– славянофилларның башлангыч чор тәнкыйте;

– консерватив-саклаучы тәнкыйть;

– язучылар тәнкыйте;

– тарихи тәнкыйть.

**II. 1840 еллар тәнкыйте:**

– реалистик тәнкыйть;

– аналитик тәнкыйть.

**III. 1850 – 1860 еллар тәнкыйте:**

– неославяннар тәнкыйте (шулар эчендә: органик тәнкыйть, тәнкыйтьтә консерватив славянофил карашлары);

– эстетик тәнкыйть;

– радикаль-демократик юнәлеш.

**IV. 1870 – 1890 еллар тәнкыйте:**

– народниклар тәнкыйте;

– язучылар тәнкыйте;

– социал-демократик тәнкыйть;

– консерватив-саклаучы тәнкыйть;

– дини-идеалистик тәнкыйть;

– эмпирик тәнкыйть;

– модернистик тенденцияләр;

– адогматик тәнкыйть.

**V. XIX гасыр чиге – XX гасыр башы тәнкыйте.**

Безнеңчә, тәнкыйтьнең аерым чорларында карашлар киңлеген бу рәвешчә чагылдыру алай да бик үк отышлы түгел, монда бүлү принципларының төрлелеге күренеп тора, ягъни авторларга, идея-эстетик карашларга, иҗтимагый-сәяси юнәлгәнлеккә, методологиягә яисә фикерләү тибына бәйле бүленешләр үзара керешкән, буталган.

Казан дәүләт университеты профессоры В.Н. Крылов «Теория и история литературной критики» хезмәтендә рус әдәбият тарихының югарыда күрсәтелгән чорларын түбәндәгечә күрсәтә:

**XVIII гасыр әдәби тәнкыйте:**

– рус тәнкыйте формалашуның башлангыч этабы (XVIII гасырның беренче утызъеллыгы);

– классицизм чоры әдәби тәнкыйте (1740 – 1770 еллар);

– сентименталистик тәнкыйть (1780 – 1790 еллар).

**XIX гасыр әдәби тәнкыйте:**

– күчеш чоры әдәби тәнкыйте (1800–1820 еллар уртасы);

– XIX йөзнең 20 еллар уртасы – 50 еллар башы әдәби тәнкыйте;

– 1850–1860 еллар әдәби тәнкыйте;

– 1870–1880 еллар әдәби тәнкыйте.

**XIX гасыр ахыры – XX башы тәнкыйте.**

Бүгенге көндә рус әдәбият белемендә әдәби тәнкыйть тарихын этапларга бүлгән, әлеге этапларның эчтәлекләрен ачкан башка хезмәтләр дә бар, әмма күбесе рус тәнкыйтенең башлангыч этапларын чагылдыра.

## 2.3. Татар әдәби тәнкыйтен чорларга бүлү мәсьәләсе

Тәнкыйтькә мөнәсәбәтле материалларны мөмкин дәрәҗәдә тулы барлау, анализлау, нәтиҗәләр чыгару әдәбият белеменең бу тармагы узган тарихи үсеш баскычларын төгәл күрсәтергә һәм әлеге этапларның эчтәлекләрен тирәнрәк ачарга ярдәм итә.

Татар тәнкыйте әле ахыргача өйрәнелеп бетелмәгән, юнәлешләре барлык тәнкыйди материалларга таянып ачылмаган. Бу аның иң кызыклы, иң катлаулы булган егерменче гасырның беренче чирегенә дә карый. Бер яктан, әлеге чор тәнкыйтенә һәм әдәбият гыйлеменә кагылышлы тирән эчтәлекле хезмәтләр инде бар; икенче яктан, аларда да шул чорның барлык әдәби-гыйльми материаллары фәнни әйләнешкә кереп бетмәгән. Моның төп сәбәбе гарәп графикасында сакланган зур күләмле әдәби-гыйльми, публицистик мирасыбыз кириллицага өлешчә генә күчерелгән һәм хәтта барысының сакланмаган да булуында.

Шуны да билгелик: соңгы елларда узган гасыр башындагы матбугатны цифрлаштыру, кулланыштагы графикага күчерү эше елдан ел кызулана бара, һәм бу эш белән берничә оешмада, шул исәптән ТӘһСИдә дә шөгыльләнәләр. Теге яки бу галимнәрнең күптомлыкларын чыгарганда, каләм ияләренең эшчәнлекләрен чагылдырган диссертацияләр язылганда, монографияләр эшләгәндә дә, узган мирас әкренләп кайта, укучы кулына керә тора. Димәк, алга таба алардагы күп кенә тәнкыйть язмалары ныклап өйрәнелер, тәнкыйть тарихында урынын табар дигән өмет бар.

Әдәбиятта нинди юнәлешләр булса, гадәттә, әдәби тәнкыйть тә шул юнәлешләргә нигезләнеп үсә. Беләбез ки, XX гасыр башы татар сүз сәнгате әдәби юнәлешләрнең, иҗат методларның төрлесенә бай, димәк, аларны әйдәкиләгән, яклаган, фәлсәфи-эстетик-иҗади

платформаларын дөрес дип тапкан тәнкыйть тә ачыкланырга, барланырга һәм анализланырга тиеш. Бүгенге көндә татар әдәбият белемендә XX гасыр башы татар әдәби тәнкыйтендә реалистик һәм романтик төрләрне ачуга гына игътибар зур, һәм аларның барлыгы Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан һәм башка шәхесләребез калдырган мираска таянып исбатланган.

XX гасырның беренче чирегендә каләм ияләре төрле иҗат платформаларында торган, инкыйлабтан соң хәтта сәнгати нигезләмә-принципларын рәсми игълан иткән төркемнәр дә булган. Әлеге дә баягы максат-бурычларны, иҗат үзенчәлекләрен тасвирлаган документларның шулай ук тәнкыйди хөкемнең бер чагылышы икәнлеген истән чыгарырга ярамый. Галимнәр алдында киләчәктә, моннан тыш, каләм ияләренең башкалар иҗатына үз фәлсәфи-эстетик күзаллаулары яссылыгыннан бәя бирүләрен дә исәпкә алып, татар тәнкыйтенең юнәлешләрен ныграк, тирәнрәк өйрәнү бурычы тора.

XX гасыр башы тәнкыйте әлегәчә, моны башкару җиңел кебек тоелса да, язучылар, укучылар, профессионаллар тәнкыйте рәвешендә дә киң планда ачылмаган. Ә бит ике гасыр чигендә татар җәмгыятендә консерватив-саклаучы хөкем дә, тарихи-сәяси карашлар да киң таралыш алган, димәк, тәнкыйтьтә һич югы алар элементар дәрәҗәдә чагылыш тапмый калмаган. Әгәр теге яки бу мираста, мәсәлән, сентименталь әдәбият үрнәкләре булган яисә бар икән, яралгы хәлендәге сентименталь тәнкыйть тә яши дигән сүз, югыйсә бу төр әдәбият тиз арада мәдәни мәйданнан юкка чыгар, онытылыр, укучысын тапмас иде. XX гасыр башы тәнкыйтен өйрәнүләр вакытында, бигрәк тә аналитик я булмаса эстетик тәнкыйтьне аерып күрсәтү өчен дә, махсус эзләнүләр алып барырга кирәк. Санап кителгән юнәлешләрдәге фәнни өйрәнүләр, алар нәтиҗәсендәге ачышлар әдәби тәнкыйть тарихын аерым баскычларга бүлү һәм шул баскычлар эчендә тәнкыйть төрләрен күрсәтү өчен бик кирәк.

Тәнкыйть матур әдәбиятка да караган өлкә булганлыктан, узган чорлар әдәбиятын төрле этаплар рәвешендә күзаллаган хезмәтләрдә аның бүленешләре дә чагыла. Беләбез ки, XIX гасыр ахырында ук каләм ияләрендә сүз сәнгатебезнең Борынгы, Урта гасыр һәм аннан соңгы этапларын һәм аларга хас эчтәлекне аңлау күзәтелә. Инде яңа гасырга кергәч, әдәби барышны фәнни яктырту мәсьәләсе көн кадагына килеп баса. Көнбатыш фәннәренең кискен үсеше, әдәби-эстетик, иҗтимагый-фәлсәфи фикердә яңарыш рухы татар

каләм ияләренә дә көчле тәэсир ясый. Иҗтимагый-сәяси көрәш шартларында шәхес буларак формалашкан заман укымышлылары – Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди, Г. Гобәйдуллин, Г. Гали, Г. Баттал, Ә. Нәҗип һәм башкалар татар әдәбият белеме өлкәсендәге киңпланлы фәнни эзләнүләрен башлап җибәрә. Бу эзләнүләрнең юнәлешен, эчтәлеген билгеләүдә көнбатыш фәне төп кыйблага әйләнә.

Татар халкының алгарыш юлларын, шул алгарышка илтүче көчләрне, аларның әйдәманнарын күзаллауда аермалыклар булган кебек, әдәби барышны, язучылар иҗатын, тәнкыйтьне аңлау-аңлату эчке һәм тышкы каршылыкларны җиңү, шулай ук күпмедер дәрәҗәдә бәхәсләрне хәл итү рәвешендәрәк бара, әмма алга таба гуманитар фәннәрнең һәр өлкәсендә марксистик карашлар шиккә алынмаслык дип саналган нигез принципларга әверелә. Шуның нәтиҗәсендә, әдәбият-сәнгать, фәннәр тарихын этаплар рәвешендә күрсәткәндә, марксистик тәгълимат тәэсиренә нык бирелгән галимнәребез аларны җәмгыять үсешендәге тарихи-иҗтимагый баскычлар, халыкның үзаң үсеше, сыйнфый көрәш тарихы белән бик нык бәйлиләр. Татар укымышлыларының үз эченә әдәби тәнкыйтьне дә алган әдәби барышны шул рәвешчә яктырткан хезмәтләрен тәнкыйть тарихын чагылдыручы тәүге эзләнүләр рәвешендә бәяләп узу хата булмас.

Совет хакимияте урнашканнан соң озак еллар дәвамында татар әдәбият белеме вульгар социологизм йогынтысына килеп эләгә. Җитмәсә, гыйльми көчләрнең репрессияләнүе тәнкыйть тарихын өйрәнүдә дә торгынлыкка китерә. Сугыштан соңгы елларда ул яңа көчләр хисабына тернәкләнеп китә. Х. Госман, Г. Халит, М. Гайнуллин, И. Нуруллин һәм башка галимнәрнең әдәбият тарихына, шул исәптән тәнкыйтенә бәйле эзләнүләрен соңрак алар янәшәсендә М. Хәсәнов, Н. Юзиев, А. Әхмәдуллин, Ф. Хатипов, М. Мәһдиев, аннан соң инде тагын да яшьрәкләр – Ф. Галимуллин, Р. Мөхәммәдиев, Э. Галиева, А. Сәяпова һәм башкалар дәвам итә. Әлеге галимнәр алып барган фәнни эзләнүләрдә тикшерү объекты рәвешендә аерым чорлар, шул чорларда иҗат иткән каләм ияләре мирасы сайлана, димәк, әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть тарихының да аерым этаплары күздә тотыла.

Узган гасырның алтмышынчы еллары башында әдәби тәнкыйть тарихын фән рәвешендә ачу проблемасы бөтен кискенлеге белән көн кадагына куела, һәм Казан дәүләт университетының әдәбият кафедрасында шул юнәлештә белгечләр хәзерләү эше башлана. Шуның нәтиҗәсендә, М. Мәһдиевнең – «Татарская советская литературная

критика (1917 – 1932)» (1963), Э. Бариеваның «Методология советской литературной критики (1917 – 1932)» (1982) темасына язылган кандидатлык диссертацияләре һәм башка хезмәтләр дөнья күрә.

Татар әдәби тәнкыйте үсешен чын мәгънәсендә фәнни нигездә этапларга бүлү һәм милли сүз сәнгате өйрәтелгән югары уку йортларында укыту мәсьәләсе белән дә иң тәүдә КДУ университеты галимнәре ныклап шөгыльләнә башлады. Татар әдәбияты кафедрасы доцентлары М. Мәһдиев һәм З. Мәҗитовлар 1986 елда төзегән программада татар әдәби тәнкыйте тарихы алты этапта яктыртылган иде:

– татар иҗтимагый фикер үсешендә беренче тәнкыйди карашлар (1770 – 1905);

– Беренче рус революциясе һәм татар әдәби тәнкыйте (Октябрь инкыйлабына кадәр);

– социалистик реализм методын үзләштерү өчен көрәш чорында татар совет әдәби тәнкыйте (1917 – 1934);

– татар совет әдәби тәнкыйтенең икенче чоры (1835 – 1955);

–1950 елларның икенче яртысы – 1970 еллар башында татар совет әдәби тәнкыйте (1956 – 1971);

– татар совет әдәби тәнкыйтенең хәзерге торышы[1].

Студентларга белем бирүне күздә тотып язылган әлеге программа татар әдәби тәнкыйтен тәнкыйди фикердә рационалистик агымның формалашуы һәм ныгу тарихы буларак чагылдыра. Тәкъдим ителгән бүленешнең өченче пункты социалистик реализм дип аталган һәм әле яңарак кына актив кулланышта йөргән методның сүз сәнгатенә табигый кермәвен, көчләп тагылуын, зур авырлык белән үтүен күрсәтеп тора.

Узган гасырның соңгы чирегендә басылган алты томлык «Татар әдәбияты тарихы»нда һәм әдәби барышның аерым чорларын чагылдырган башка хезмәтләрдә тәнкыйть торышы шулай ук иҗтимагый-фәлсәфи фикер һәм гомумәдәният үсешенең баскычлары эчендә яктыртыла. Димәк, аның фәнни өлкә рәвешендә калыплашканнан соңгы этаплары татар әдәбияты тарихы этаплары белән тәңгәлләштерелә. Шул ук вакытта галимнәр, сүз сәнгатен баскычлар рәвешендә күрсәткәндә, иҗтимагый-тарихи этапларга таяналар да, болай эшләүнең билгеле бер дәрәҗәдә шартлылыгын да таныйлар.

[1] Мәһдиев М.С., Мәҗитов З.М. Татар әдәби тәнкыйте тарихы: программа. Казан, 1986. 20 б.

Т. Гыйләҗев тәкъдим иткән татар әдәби тәнкыйтен югары уку йортларында укыту программасы Үзгәртеп кору еллары тудырган уңай шартларда киңрәк материалга нигезләнә һәм XX йөз башында әдәбият үсешенә бәйле хөкем сөргән карашларны тагын да тирәнрәк ача. Галим, «10-елларда татар әдәби тәнкыйте тулысынча формалашып» җитте һәм «әдәби хәрәкәттә этәргеч көч ролен уйный» башлады, дип әйтә[1]. Бу программа инкыйлабтан соңгы чорның беренче этабын егерменче елларның яртысы белән чикли. Анда, нигездә, ике канатны – романтик һәм реалистик карашларга нигезләнгән тәнкыйтьне ныклап ачыклау омтылышы сизелә.

Т. Гыйләҗев татар тәнкыйте тарихын өйрәнүне фәнни эзләнүләренең төп юнәлеше буларак сайлады. Алга таба ул туксанынчы елларда тәкъдим иткән тәүге укыту программасының эчтәлеген тагын да киңәйтте, яңа материаллар белән баетты һәм инде аның барлык этапларын да иңләп алган яңа уку әсбаплары төзеде. Галимнең «Әдәби тәнкыйть тарихы» (История литературной критики. 2014) исемле фәнни-методик хезмәтендә, эчтәлегеннән чыгып караганда, тәнкыйть тарихы шушы рәвешчә бүленә:

– әдәби тәнкыйть барлыкка килүгә әзерлек һәм эзләнүләр чоры (борынгы чорлар – XIX гасыр ахыры);

– XX гасыр башында татар әдәби тәнкыйте: аның фән буларак формалашуы (XX гасырның беренче, икенче унъеллыгы);

– тоталитаризм дәвере әдәби тәнкыйте (1920–1950 еллар уртасы);

– тоталитаризмнан соңгы татар әдәби тәнкыйте (1950 елларның икенче яртысы – 1980 елларның беренче яртысы);

– хәзерге чор татар әдәби тәнкыйте (XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы).

Т. Гыйләҗев «Тоталитаризмнан соңгы татар әдәби тәнкыйте» үз эчендә ике баскычка бүленә дип белдерә һәм аның уртадагы чиген җитмешенче еллар башы белән билгели.

Татар әдәбияты тарихын этапларга бүлү шактый шартлы булган кебек, тәнкыйтьтә дә шулай, хәтта катлаулырак та. Аның бүленешен күп вакыт әдәбият тарихы баскычларына яраштыралар, ә ул еш кына әдәбияттан алгарак китә яисә арткарак калырга да мөмкин. Түбәндә татар әдәби тәнкыйть тарихын баскычлар рәвешендә күрсәтүнең тагын бер мөмкин булган вариантын күрсәтик:

[1] Гыйләҗев Т.Ш. Татар әдәби тәнкыйте тарихы (1900 – 1925). Казан, 1999. Б.10.

**Татар әдәби тәнкыйтенең формалашу этаплары (борынгы чорлар – 1920)**

– әдәби тәнкыйтьнең беренче яралгылары һәм эзләнүләр чоры (борынгы чорлар – Беренче рус инкыйлабы);

– әдәби тәнкыйтьнең фән буларак калыплашу еллары (1905–1920).

**Тоталитаризм дәвере әдәби тәнкыйте (1920–1955)**

– 1920–1930;

– 1930–1940;

– 1940–1956.

**Тоталитаризмнан соң татар әдәби тәнкыйте (1956–1990)**

– 1956–1970;

– 1970–1990.

**Хәзерге чор татар әдәби тәнкыйте (XX г. ахыры – XXI г. башы).**

– туксанынчы еллар тәнкыйте;

– яңа гасыр тәнкыйте.

Бу бүленеш тә төгәл түгел, әмма чагыштырмача отышлырак тоела. Әлбәттә, югарыда махсус күрсәтелмәсә дә, әдәби тәнкыйтьнең һәр этабы инде кечкенәрәк баскычлардан оеша. Әлеге этапларны аерым чор тәнкыйтен укытканда аерымлау традициясе яши. Югары уку йортларының рус филологиясе факультетларында XIX–XX чикләрендәге әдәби тәнкыйть үсешен, мәсәлән, әдәбияттагы-иҗаттагы күренешләр белән тыгыз бәйләнештә карап, шушы рәвешчә бүлеп укыту бар:

– 1895–1902 – декадентлык-символистик шигърият формалашу чоры тәнкыйте;

– 1903–1909 – символизмның «икенче» күтәрелеш чорындагы тәнкыйть;

– 1910–1916 – символизмның кризисы һәм башка декадентлык агымнарына алмашу чоры тәнкыйте;

– 1917–1922 – Инкыйлабтан соңгы күптөрле әдәби агымнар яшәгән бишъеллык тәнкыйте.

Татар әдәбият белемендә, әдәбият һәм тәнкыйть тарихын этаплар рәвешендә күрсәткәндә, иҗтимагый-сәяси үсеш закончалыкларын искә алу ачык чагыла, ә бит җәмгыять тарихы белән әдәбият тарихы этаплары якынча туры килсә дә, тәңгәл була алмый. Мәсәлән, ике гасыр чигендәге сүз сәнгатебез тарихына мөнәсәбәттә, Үзгәртеп кору еллары һәм аннан соңгы әдәбият дип сөйләргә

күнеккәнбез, әмма татар әдәбиятында күзгә ташланырлык үзгәрешләр нибары туксанынчы елларда башланды. XIX–XX гасыр чигендәге, ягъни Беренче рус инкыйлабы алды унъеллыгындагы әдәби тәнкыйтьнең дә үз сыйфатлары ачык төсмерләнсә дә, зур этап эченнән аерып чыгарылмады. Теге яки бу тарихи-мәдәни барышны үсеш баскычлары рәвешендә күрсәткәндә, шуны да онытырга ярамый: сүз сәнгате күген кисеп узган тәүге карлыгачларның булуы әле яңа зур күренеш чикләре турында сөйләргә хокук бирми.

Безнең тарафтан тәкъдим ителгән бүленештә туксанынчы еллар әдәби тәнкыйте аерым билгеләнде. Аның икенче чиген кайда тәмамларга – шулай ук шактый бәхәсле. Мөгаен, бу гасырга кереп тер. Алга таба галимнәр алып барган фәнни эзләнүләр аны тәгаенләштерер дигән өметтә калабыз. Яңа гасыр тәнкыйтен, әдәбиятын аерып куйганбыз икән, аның эчендә дә кечерәк баскычлар күренеп торганны әйтик. Тәкъдим ителгән бүленештә туксанынчы еллар әдәбияты дип билгеләү шуның белән дә аңлатыла: рус фәнендә дә әдәби тәнкыйть тарихын ачучы күпчелек галимнәр чагылдыру объектын әлегә шул еллар белән чикли.

Әдәби тәнкыйть тарихын кечерәк этапларга ваклап күрсәткәндә, елларда төгәлрәк чагылдыру җиңелрәк булса да, әлегә зуррак бүленешләрне күрсәтеп узу белән канәгатьләндек. Алдагы бүлектә исә әдәби тәнкыйть тарихының чираттагы үсеш этапларын, гомумкабул ителгәнчә, 1917 елдан башлап китәрбез, әмма эчке бүленешне, нигездә, унъеллыклар рәвешендә бирербез. Тәнкыйть тарихын тасвирлауны исә сиксәненче еллар белән чикләрбез.

ТӘһСИдә басмага хәзерләнгән сигезтомлык «Татар әдәбияты тарихы» хезмәтендә югарыда тәкъдим иткән бүленеш, гомумән алганда, чагылыш таба.

## 2.4. Татар әдәби тәнкыйтенең 1917 елгы инкыйлабтан соңгы үсеш-үзгәреш баскычлары

Әдәби тәнкыйтьнең фән буларак калыплашу чоры Икенче бүлек башында шактый тулы яктыртылганлыктан, бу бүлекчәдә аның чираттагы үсеш баскычлары тасвирлана. Аңа кадәр совет чоры тәнкыйте турында гомуми фикерләргә урын биреп узыйк.

Инкыйлаб чорында тәнкыйтьнең иркен сулыш алып үсү мөмкинлеге булмый, аңа хезмәт итәргә тиешле каләм ияләребез масштаблы иҗтимагый-сәяси хәрәкәткә тартыла. Гражданнар сугышы елларында да тәнкыйтьтә торгынлык сизелә, аның басма

сүз мөмкинлекләре кими, каләм ияләре үзләре дә турыдан-туры сугышта катнаша һәм язуларын чикләргә мәҗбүр була. Соңыннан – яңа тормыш төзү шартларында – җәмгыятьнең, әдәбиятның үзаң чагылышы булган тәнкыйть сүз сәнгатенә тәэсирне бермә-бер көчәйтә.

Егерменче елларда язучылар берләшкән оешмаларның иҗтимагый-әдәби платформаларын өйрәнү, бәяләү, аларның методологик һәм теоретик проблемаларны чишүләренә тәнкыйди якын килү, нәфис текстларны ачу принципларын эшләү, чорның әһәмиятле әсәрләрен, авторларын билгеләү эзлекле һәм өзлексез агым рәвешен ала. Бу чорда татарның профессиональ тәнкыйтьчеләре яңа буын хисабына арта; көчле академик әдәбият белеме калыплашуын һәм ныгуын дәвам итә; гыйльми-тәнкыйди хезмәтләр һәм жанр, һәм стиль, һәм композиция ноктасыннан байый, төрләнә бара.

Инде инкыйлабкача да шактый үсеш алган татар тәнкыйте Гражданнар сугышы елларынннан соң сүз сәнгатенә, аерым авторларга актив тәэсир итәрлек хәлгә килә. Шул ук вакытта ул иҗтимагый шартлардан хәтта әдәбиятка караганда да ныграк бәйлелеккә төшә, тәгаенрәк әйткәндә, хакимлек итә башлаган идеологиягә бирешә – үзе дә тоталитар иҗтимагый кануниятне ныгытуга хезмәт итә башлый.

Әдәби тәнкыйтьнең тулаем дәүләт күзәтчелеге астына керүе бер көндә генә барлыкка килми. Гражданнар сугышы чорында җәмгыятьнең таркалуы, татар сәяси фиркаләренең, төркемнәренең милләтнең киләчәген күзаллауда уртак карашларга килә алмавы, үзара якынаймавы, уртак платформалы милли сәяси партия төзелмәү, төрле фиркаләргә кергән зур шәхесләрнең шәхси мөнәсәбәтләре, рухи әйдәманнарның инкыйлабны кабул итү һәм кабул итмәүгә бәйле ике зур лагерьга бүленүе яисә шул төркемнәрнең берсенә дә кермәве тәнкыйтькә турыдан-туры йогынты ясый. Ул әлеге дә баягы төрле иҗтимагый-сәяси оешмаларның үз карашларын чагылдыру һәм бәхәс мәйданына әверелә. Анда, әлбәттә, зур көрәштә җиңә баручы партия әгъзалары мәйданны ныграк тота.

Егерменче еллар башындагы тәнкыйть төрле тенденцияләргә, карашларга урын бирүе белән кызыклы булса да, инде ул чакта да, Г. Ибраһимов кебек партия эшлеклеләре тәнкыйтеннән һәм ныгып баручы сәяси-иҗтимагый шартлардан чыгып, аның алга таба үсеш юлларын, бигрәк тә генераль линиясен ачык күзалларга мөмкин. Егерменче елларның икенче яртысында – утызынчы еллар башын-

да ахыр чиктә татар совет әдәбиятының, аны яктырткан, әйдәп барган тәнкыйтьнең уртак һәм бердәнбер концепциясе формалаша. Бу исә рус сүз сәнгатенең, марксистик идеологиянең көчле басымы, танылган каләм ияләренең әдәби йогынтысы астында бара. Үз карашларыннан баш тартмаган, сәнгатьтә һәм фәндә объектив калырга омтылган, совет әдәбиятына идеологик кысалардан гына якын килмәгән талант ияләренә – һөҗүм, алга таба хәтта репрессияләр башлана, һәм, гомумән алганда, кискен үсеп китәргә бөтен мөмкинлекләре булган тәнкыйтьтә көтелгән дәрәҗәдәге үзгәрешләр күренми. Ул фикер төрлелеген югалта, әсәрләрнең сәнгатилеген кайгырту ноктасыннан йомшый, аларны идея яссылыгында бәяләүне алгы планга чыгара.

Милли зыялылар катламы зур зыян кичергән, рухи изелгән, бик кечерәйгән шартларда Бөек Ватан сугышы башланып китә, шунлыктан татар тәнкыйте яңадан ныгый һәм бер ирешкән биеклекләренә күтәрелә алмый. Советлар иленең сәясәте тарафыннан җитәрлек томаландырылган, догматизмга, коммунизмга бәйле хыял дөньясына тартып кертелгән иҗтимагый аң, көрәш кырларында зур талантларның һәлак булуы, төрле гаепләр тагылып, һаман да юк ителүе шартларында тулы сулыш ала алмаган әдәбият һәм тәнкыйть сугыштан соң үсеш кичерүдән туктый, полемик характерын тәмам югалта. Шул ук вакытта тар катламнарда эчке уяну, тоталитар режимның афәт икәнлеген аңлау, аңа каршы тору омтылыш-хәрәкәте башлана. Һәм ил, сүз сәнгате, аның бер өлеше булган әдәби тәнкыйть 1954 елдан соң әкренләп, адым-адым атлап, тоталитар канунияят киртәләрен җиңә алырлык әдәбиятка илтәчәк, сүз ирегенә төрлечә мөмкинлекләр тудырган чорларны берләштерүче зур этапка килеп керә.

Хезмәттә татар совет тәнкыйтенең иң кызыклы, иң гыйбрәтле, һәм уңай, һәм тискәре тәэсире озак елларга сузылган чорларына махсус рәвештә зуррак урын бирелде.

### *2.4.1. Тоталитаризм дәвере әдәби тәнкыйте*
### *1920–1930*

XX гасыр башында әдәби тәнкыйть предметын, функцияләрен, өйрәнү объектын ачыклау юлына баса; әдәби барышны, иҗатны, текст берәмлекләрен анализлау-бәяләүнең кануннарын, фәнни нигезләрен ачыклаучы тәгълимат эзләү белән чын мәгънәсендә шөгыльләнә башлый һәм Инкыйлабтан, Гражданнар сугышыннан соң

әлеге мәсьәләләргә яңадан махсус әйләнеп кайта. Бу чорда да аның күзаллавында Гареб янәшәсендә Шәрекъ тә мәдәни маяк рәвешендә яшәвен өлешчә дәвам итә, шунлыктан әдәби тәнкыйть терминнарын кабул итүдә, актив кулланышка кертүдә, төрле телдән алынган төшенчәләрне бер ояга туплауда кыенлыклар барлыкка килә һәм аларны тиз арада чишәргә кирәк була. Шушы проблемалар белән махсус шөгыльләнгән Г. Ибраһимов әдәби тәнкыйть фәне турындагы нәзари эзләнүләрен, инде беренче басмасы 1916 елда «Әдәбият дәресләре» исеме астында дөнья күрсә дә, «Әдәбият кануннары» (1919) хезмәтенә бүлекчә рәвешендә яңадан кертә.

Т. Гыйлаҗев «История татарской литературной критики» дип аталган «лекцияләр конспекты»нда болай дип яза: «Иң беренче нәүбәттә, әлеге методик әсбапта галимнең әдәби тәнкыйтьне фәнни нигезгә утырту омтылышын билгеләргә кирәк. Бу еллар тәнкыйди рухи мирасын актарганда, әдәби иҗатның бу төренә атама булып ике термин: тәнкыйть һәм интикадның фәнни кулланылышта йөрүе күзәтелә. Г. Ибраһимовның аерым мәкалә-язмаларында интикад кулланылса да, тәнкыйть терминына өстенлек бирелә. /.../ Әдәби тәнкыйтьнең предметы, аның шартлары һ.б. гыйльми-нәзари төшенчәләрне шәрехләүдә Г. Ибраһимов /…/ Аурупа-рус әдәбият белеме ирешкән казанышларга таяна. Мәсәлән, ул тәнкыйтьне мантыйкый дәлилләр белән эш итүне һәм исбатлауны таләп иткән мөхакәмәнең бер төре итеп карый һәм алга таба тәнкыйтьнең теоретик мәсьәләләре аның тарафыннан шушы позициядән чыгып аңлатыла»[1].

«Әдәбият кануннары»нда Г. Ибраһимов нәфис текст берәмлекләренә бирелгән «иҗаби» (уңай) һәм «сәлби» (кире) тәнкыйтьне әдәби тәнкыйтьнең төрләре рәвешендә күрсәтә һәм икесенең дә әдәбиятны үстерүгә хезмәт итүен яза. Ул берсенең теге яки бу әсәрдәге җитешсезлекләрне кире кагуын, аларны төзәтергә чакыруы, ә икенчесенең әдәбиятта уңай күренешләрне пропагандалавын, укучыга сәнгати кыйммәтләрне ачып бирүен әйтә.

Галимнәребезнең үз заманында вакытлы матбугатта дөнья күргән язмалары әдәби тәнкыйтьнең инкыйлабкача ук югары үсешкә ияләгән, фәнни өлкә сыйфатында оешуын сөйли. Аерым хезмәтләрдән аңа кадәр дә тәнкыйть терминологиясе билгеле бер дәрәҗәдә кулланылганлык, каләм ияләрендә әдәбиятның төрләренә, чараларына бәйле

---

[1] Гыйлаҗев Т. История татарской литературной критики: конспект лекций. Казань, 2014. Б. 67–68.

күзаллаулар булганлык күренә. Шулай да чын мәгънәсендәге һөнәри тәнкыйть нигезләре соңрак – гыйльмияткә Җ.Вәлиди килгәннән соң бигрәк тә аның каләме белән калыплаштырыла. Әлбәттә, инкыйлабтан соңгы тәнкыйть фәне ул тудырган фәнни-әдәби байлыктан гына түгел, Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов һәм башка күпсанлы язучыларыбыз иҗат иткән хезмәтләрдән дә этәрелеш ала.

Хатип Госман «Татар совет әдәбияты фәненең беренче адымнары»нда чираттагы этапның – татар совет әдәбият белеменең, шул исәптән тәнкыйтенең Гражданнар сугышы елларында формалаша башлавы хакында әйтә[1]. Чыннан да, бу чорда Г. Ибраһимов, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Нигъмәти, Г. Гали, Г. Сәгъди, Г. Ходаяров һәм башка каләм ияләре иске һәм яңа мирасны бәяләгән кызыклы язмалары аша зур тәнкыйтьчеләр сыйфатында таныла; язучыларның күпчелек әсәрләре теге яки бу яссылыкта рецензияләрдә бәяләнеш таба. Гомумән алганда, егерменче еллар башында вакытлы басмалар әдәбиятчыларның төрле эстетик белемгә, иҗтимагый-сәяси күзаллауларга иялеген сөйли. Әлеге күренеш тәнкыйтьнең шулай ук эчтәлек һәм тирәнлек ноктасыннан төрлелегенә хезмәт итә.

Үзгәртеп кору елларына кергәч тә, бу чор сүз сәнгатенә мөнәсәбәттә үтә тискәре фикерләр яңгырый башлагач, И. Нуруллин: «Егерменче еллар әдәбиятыбызның XX йөз башына тиң күтәрелеш һәм чәчәк ату чоры булды»[2], – дип язган иде. Әлбәттә, әлеге тоталитаризм ахыргача урнашып бетмәгән елларда әдәбият үз көч-куәтен булдыра алганча ачып салды, аның таяныш ноктасы зур һәм сыйфатлы, ә традицияләре көчле иде. Татар шигърияте, прозасы, драматургиясе һәм әдәбият белеме мәйданына аларны тагын да үстереп җибәрә алырлык яшь каләм ияләре дулкын булып агылды. Әдәбият сан һәм сыйфат ноктасыннан бик төрләнде, кызыклы әсәрләр дә шактый күп язылды, аның белән беррәттән, хәтта тәнкыйть тә мәдәни тормышның кызыклы өлкәсенә әверелде, аңа яңа җәмгыять, яңа тормыш турындагы хыяллар узды. Шул ук вакытта сүз сәнгатебез үзенең биниһая зур мөмкинлекләрен ачып бетерә алмады, һәр яңалык ниндидер каршылыкка очрады, һәр әйтелгән һәм язылган сүз партия карарлары кысасында тикшерелде, бик үк табигый булмаган нормаларга да салып үлчәнде, аның кысаларыннан чыкканы усал

[1] Госман Х. Татар совет әдәбияты фәненең беренче адымнары // Совет әдәбияты. 1966. № 7.

[2] Нуруллин И. Гадел булыйк! // Соц. Татарстан. 1990. 3 май.

тәнкыйтькә очрады. Ахыр чиктә әдәби тирәлеккә курку-саклану, җитәкчеләргә ярарга тырышу, бигрәк тә иҗтимагый авторитетларга кирәгеннән артык табыну рухы узды.

Татар сүз сәнгатенә юнәлеш күрсәтергә тиешле тәнкыйтьтә зур үзгәрешләр, уңай да, тискәре дә сыйфатларның калкулануы, беренче чиратта, 1917 елгы инкыйлабтан соң тарихи аренада пролетар сыйныфларның төп рольне уйный башлавы белән бәйле иде. Белгәнебезчә, большевиклар бары тик марксизм-ленинизм гына әдәби тарихны дөрес яктыртуның нигезләрен бирә, тәнкыйди реализмның асылына төшенә һәм, шуннан этәрелеп китеп, әдәбият барышын инкыйлаби көрәш кысаларына кертәчәк, гади халык ихтыяҗларына хезмәт иттерәчәк дигән караштa тора.

Егерменче елларда Совет иленең әдәби-мәдәни сәясәтен В.И. Ленин, Л.Д. Троцкий, Н.И. Бухарин, Г.Е. Зиновьев кебек сәясәтчеләрнең әдәбиятка һәм аны үзе күзаллаган тәртипкә китерәчәк тәнкыйтькә кагылышлы язмалары калыплаштыра. Бу чорда рус тәнкыйтенә генә түгел, татар әдәбият гыйлеменә дә Троцкийның «Әдәбият һәм инкыйлаб» («Литература и революция», 1923) хезмәте зур йогынты ясый. Аның тәэсирендә киләчәк әдәбиятны күзаллау барлыкка килә, тәнкыйть терминологиясенә үзгәрешләр керә, татар каләм ияләре тарафыннан да «буржуаз», «пролетар» яисә «крестьян язучы» һәм башка төшенчәләр кулланыла башлый, моңа кадәр һәркемгә аңлаешлы булган күп кенә гарәп-фарсы терминнары активлыгын югалта бара. Хәтта терминологиядәге үзгәрешләр дә тәнкыйтькә әкренләп киләчәктә «вульгар социологизм» дип аталачак зур күренешнең тууына, ныгуына хезмәт итә.

Татар әдипләренең марксизмның иң көчле белгече булган һәм халыкара социалистик хәрәкәт башында торган, хезмәтләре аерым бер этапта В.И. Ленин тарафыннан да нык пропагандаланган Г.В. Плехановның эстетикага, этикага, фәлсәфәгә, иҗтимагый фикер тарихына мөнәсәбәтле теоретик карашларына таянуы да сүз сәнгатендәге проблемаларны марксистлар күзаллаган юнәлештә чишүгә китерә. Марксистик рухлы каләм ияләребез Плеханов, Ленин фикерләрен алга таба хәрәкәт стратегиясе дәрәҗәсендә кабул итә. Аларның бигрәк тә тәнкыйть белән шөгыльләнгән өлеше инкыйлаби көрәшне тагын да җәелдерү, аңа массаларны тарту өчен, рус-революцион демократларының карашларын татар әдәби тәнкыйтенә уздыру һәм әдәбиятны яңа нигезләргә утырту хыялы белән яна башлый. Әлбәттә, бу төр хәрәкәтнең алдында Г. Ибраһимов тора.

Г. Ибраһимов «Китаплар арасында» хезмәтенең (1925) «Ленинизм фикерләрен тарату юлында» бүлекчәсендә юлбашчының һәр юнәлештәге күзаллауларын халык арасында җәелдерүнең төп гамәлләрен ачыклый һәм бу эшне татар әдипләренә йөкли. Ул ленинизм идеяләрен тәрҗемә һәм оригиналь әдәбият аша массаларга тарату проблемасына алга таба да кабат-кабат әйләнеп кайта. Г. Ибраһимов дингә каршы эшчәнлекне шуның янәшәсендә күрә, чөнки аны алмаштырачак ленинизмны бар нәрсәнең нигезендә торган яңа дин дәрәҗәсенә күтәрә. «Китаплар арасында» хезмәтенең «Яшь каләмнәр» өлешендә К. Нәҗми, Ф. Әсгать, Һ. Такташ, Ш. Госманов, И. Хәйруллин, М. Максуд, М. Җәлил, Г. Галиев һәм башкалар иҗатына мөнәсәбәтле әдип түбәндәгеләрне әйтә: «Болар барысы да пролетариат революциясе дәверендә кузгалып, күбе канлы көрәш эченнән, гражданлык сугышларыннан кайнап килеп чыгучылар, әмма кайберләре – башта адашып, чит сыйныфлар тәэсирендә азапланганнан соң, пролетариат идеологиясе чишмәсенә килеп егылучылардыр. Ләкин һәммәсе җыйган уртак бер әйбер бар: болар барысы да көйләп яки көйсез рәвештә Владимир Ильичне җырлыйлар, аның пролетариатка юлбашчылык ролен төрле күренешләр, төрле сурәтләр аркылы укучыга күрсәтәләр»[1].

Г. Ибраһимов матбугат ireген, әдәбиятка һәркем килергә хаклыкны таныган Ленинның 1905 елда ук язган «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» мәкаләсендәге яңа заман сүз сәнгатенә биргән билгеләмәсен, алдыбызда төрле рәвештәге әдәби эшләрне социал-демократик эшчеләр хәрәкәте белән тыгыз һәм өзлексез бәйләнештә оештыру бурычы тора, «бөтен социал-демократик әдәбият партияле булырга тиеш», дигәннәрен үзенә маяк итеп ала. Ул да, Ленин кебек, бер яктан, һәр төр эчтәлектәге, сәнгати дәрәҗәдәге һәм юнәлештәге әдәбиятның яшәргә хаклыгын таный да кебек, икенче яктан, художество эшләнеше түбән, заманча булмаган, бигрәк тә эчтәлеге инкыйлаби хәрәкәткә зыянлы тоелган әсәрләргә, шуларның авторларына каршы көрәш утын кабыза. Г. Ибраһимов, шул рәвешчә, киләчәктә әдәбиятны тар кысага кертеп утырту юлына ишекләрне киң ача. Кызганыч ки, күренекле җәмәгать эшлеклесе, сәяси-иҗтимагый, тарихи яссылыктагы хезмәтләрендә, катгый һәм кискен әйтелгән сүзләре белән, күпләрне Совет иленең дошманнар лагерена куып кертә һәм шуның белән алга таба татарның

[1] Ибраһимов Г. Китаплар арасында // Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Т. 6. Б. 398.

талантлы шәхесләрен репрессияләүгә юл салуда катнаша. Ә бит егерменче гасыр башында каләм ияләре һәр өлкәдә эшли: алар – тәнкыйтьче дә, язучы да, тарихчы да. Кайсын гына югалтсаң да, татар тәнкыйтенә зур зыян килә дигән сүз.

Егерменче елларда большевиклар әдәбиятның, тәнкыйтьнең үзләре калыплаштырган кысалардан, шул исәптән идеологик киртәләрдән тышка чыгуында, каләм чатаклыкларында марксист булмаган яисә татарның мөстәкыйль ил булып яшәү идеясеннән баш тартмаган әдипләр йогынтысын күрә. Мәсәлән, «Габдулла Кариев иптәш рухына»да (1920) Г. Ибраһимов: «Тормышның төбеннән, ярлы крестьян эченнән чыккан Кариев, моннан берничә ел элек үз сыйныфының юлыннан, демократик нигезеннән бераз читкәрәк тайган, аннан ары Исхаков-Туктаров компанияләренә эләгеп, бераз адашып киткән икән, моннан Кариевнең үзеннән бигрәк заман агышының тәэсире гаепледер»,– дип белдерә.

Шәһәр-авыллардагы мәдәни тормышны өйрәнгән Г. Ибраһимов сәнгать чаралары уздыруны, хәтта аңа тәнкыйди мөнәсәбәт булдыруны коммуна эшчәнлегенең бер өлеше дип саный, яңа рухи тормышны төзүдә революцияне чын күңелдән кабул иткән һәм «яңа фикерләргә, яңа эзләнүләргә, яңа иҗатларга урын бирәчәк» коллективларга зур өмет баглый. Ул әдәбиятны да, шул әдәбиятны яктырткан һәм яңа буынны тәрбияләргә тиешле дәреслекләрне дә «дәүләт механизмында даими винтларның берсе» дип бәяли, шуңа күрә уку әсбапларының эчтәлекләре заманга лаек булуны, коллектив рәвештә хәл ителүне кайгырта[1]. Г. Ибраһимов нәкъ менә егерменче елларда әдәбиятны, шул исәптән аның әйдәүче көче тәнкыйтьне һәм аларны халыкка җиткерүче матбага эшен партия контролендә тотуны яклый, һәрдаим «матбага эшчеләрен гаскәри хәлгә кертү» проблемасын күтәрә[2].

Г. Ибраһимов әдәби тәнкыйть язучыга туры юлны ачык сызып күрсәтергә тиеш дигән караштa тора. Ул әлеге юлны гади халык арасыннан чыкканнарның аңласына, башта адашып йөргән очракта да, ахыр чиктә барыбер ленинизм тарафдарларына әвереләселәренә һәм, иҗатлары белән, халыкка шул ук идеяләрне та-

---

[1] Ибраһимов Г. Яңа мәдәният төзү юлында гыйльми әдәби коллективлар // Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Т. 6. Б. 237–243.

[2] Ибраһимов Г. Кызыл штык һәм кызыл каләм // Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 6. Б. 219.

ратуга хезмәт итәселәренә ышана. Г. Ибраһимов егерменче елларда марксистик-пролетар күзаллауларны шул кысага сыешмаганча фикер йөртүчеләрнекенә һәрвакыт каршы куя, чит карашларның өскә калыкмавы өчен тырыша. Әдип «Дүртенче елга кергәндә» (1920) язмасында, зур гомумиләштерүләр ясап, болай ди: «Без бер дә шикләнмичә, әдәбиятка, фәлсәфәгә, театрга, мәктәпкә, сәнаигы нәфисәгә буржуазный яки пролетарский дип үлчәү сала алабыз, шундый гөруһка, шундый дәверләргә аера алабыз» (5 том. Б. 243).

Г. Ибраһимов татар тарихындагы иҗтимагый дәверләрне һәм шуларга мөнәсәбәттә барлыкка килгән рухи-мәдәни мирасны чагылдыруны төп бурычларыннан итә. Әдәбиятны дәвергә бәйле аңлату проблемасын ул әллә ничә хезмәтендә яктырта. Болар: күзәтү-хисап алгарак чыккан «Татар әдәбияты», аналитик характердагы «Татарның соңгы тарихында өч дәвер (эпоха), «Бөек өмидләр алдында» һәм башка язмалар. Әлеге күләмле хезмәтләр алга таба әдәбият белеменең, шул исәптән тәнкыйтенең, үткәндәге һәм киләчәктә язылачак милли әдәбиятыбызның чорларга бүленешен хәл итә.

Г. Ибраһимов Гражданнар сугышыннан соң фәнни-тәнкыйди эзләнүләрен сүз сәнгатен өйрәнү принципларын ачыклауга юнәлтә, тәнкыйтьнең концепциясен эшли һәм берничә күләмле мәкаләдә махсус яктырта. «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» дигән язманың, атамасыннан ук күренгәнчә, әдип хәзер үзе әдәби мирасны ачканда таянган алымның марксизмга нисбәтлеген ассызыклый һәм төп эчтәлектә милли әдәбиятыбызны, гадәтенчә, шуның ярдәмендә баскычларга бүлә.

«Татар әдәбиятын өйрәнү юлында» мәкаләсендә Г. Ибраһимов маркистик әдәбият белемендә ясалма агитациягә мохтаҗ юклыкны, чын фәнни принципларга таяну кирәклеген әйтә, марксизмның төп тикшерү ысулы сыйфатында тарихи материализмны күздә тотканлыгын шушы рәвешчә төшендерә: «…идеологияне, әдәбиятны матди туфракка үсеп чыккаен җимешләр дип карау, әдәбияттагы үзгәрешләрне, хасиятләрне мөндәриҗә, төп фикерләрне аларның шул дәвернең техникасы, икътисади иҗтимагыяте белән ни дәрәҗәдә бәйләнуларын ачып бирә бару ысулы»[1].

Г. Ибраһимовның егерменче еллар тәнкыйтендә яңа әдәбиятның нинди булырга тиешлеге дә һәрвакыт нигез һәм өскорма

---

[1] Ибраһимов Г. Татар әдәбиятын өйрәнү юлында // Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Т. 5. Б. 390.

бәйләнешләре аша күз алдына китерелә. Ул, яңа төр сүз сәнгате барлыкка килүнең төп шарты итеп, икътисади мөнәсәбәтләрдәге үзгәрешләрне күрсәтә: «Гыйлемнең, әдәбиятның, сәнаигы нәфисәнең, театрның төп нигезләре, ысуллары, тышкы рәвешләре шул элеккечә, ләкин фикер, мәгънә алган чишмәләре, үсеп чыккан тамырлары, күзәткән әмәлләре бөтенләй башка – элекке икътисади мөнәсәбәтләр әдәбиятны, сәнаигы нәфисәне милек, милли, дини, ватани дошманлык рухында сугаралар, шуңа хезмәт кыйлдыралар иде; капитализм гыйлемендә, фәлсәфәдә, сәнаигы нәфисәдә үзен аклый, үзенә юл ача торган идеология эшли иде. Тарихның хәзерге бөек кузгалышлар дәвере исә, үзенең кызыл каһарманнары, сугышчан егетләре белән бергә, икътисади азатлык әмәлләрен җырлаучы шагыйрьләр, җир йөзен яңа, якты, ирекле тормышка чыгаручы әдипләр, философлар, гыйлемне, фәнне яңа әмәлләргә тәтбикъ кыйлучы галимнәр, техниклар тудырды»[1].

«Татар әдәбиятын өйрәнү юлында» (1923) мәкаләсендә Г. Ибраһимов, тагын да кыскарак һәм ачыграк итеп: «Элек матди тормышны, аннан соң аның өстендә үсеп чыккан һәм аңар хезмәт иткән, аңар организаторлык кыйлган идеологияне шулай һәр дәвернең, һәр баскычның үзендә тикшерә килеп, аеруча әдәбияты нәфисәгә тукталгач, моның инде безгә тагы да тәфсилгә, тагы да нечкәлекләргә күп урын ачыла», – дип белдерә[2]. Ул, әсәрләрнең идеясен, эчендә тасвирланган сыйнфый-иҗтимагый мөнәсәбәтләрне ачу тәнкыйтьчеләр һәм укучылар тарафыннан әдипнең кыйбласын билгеләү өчен дә кирәк, дигән караштa тора. Шулай итеп, әдәби әсәр концепциясен аңлау юлындагы гамәлият аны иҗат иткән авторның марксистларга тарафдармы, әллә башка юлдан барамы, пролетариатка, революция эшенә идеяләргә хезмәт иткән әдәбиятны кайгыртамы, дигән сорауга да җавап бирәчәк булып чыга.

Базис һәм өскорма күренешләр аша әдәбиятны аңлату проблемасына Г. Ибраһимов башка мәсьәләләрне чишкәндә дә әйләнеп кайта һәм аны әдәбиятта тормышны тарихи принципларга таянып яктырту белән тыгыз үрә. Теоретик планда сүз йөрткәндә, әдәбиятның чынбарлыкны анализлау, аннан материал сайлап алу кебек

---

[1] Ибраһимов Г. Дүртенче елга кергәндә // Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5. Б. 241.

[2] Ибраһимов Г. Татар әдәбиятын өйрәнү юлында // Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5. Б. 387.

якларына, идея эчтәлегенә күп урын бирүгә карамастан, тәнкыйтьче әсәрләрнең сәнгати эшләнеше проблемасын да күз уңыннан тәмам чыгарып ташламый. Ул, марксист булмаганнар: «иҗтимагый нигез хәтердән чыгарылмау белән бергә, «әдәби кыйммәт», «әдәби дәрәҗә», «әдәбилек», «тел-өслүб», чыгарылган типлар, реалист, романтик, символизм кебек нокталар табигый тикшереләләр.

Болар марксист булмаган тикшерүчеләрдә зур урын алалар. Бездә дә әһәмият бирмичә үтәргә ярамый»[1], – ди.

Тәнкыйтьне эшчеләр сүз сәнгатен тудыруга хезмәт иттергән Г. Ибраһимов «Пролетариат әдәбияты турында» язмасында, бик хаклы рәвештә, әгәр әдәбияты турында сөйләшәбез икән, бездә пролетариат бармы, ул нинди; аны пролетариаттан чыккан язучы гына язамы, әллә башкалар дамы; аңа завод-фабрика-шахта тормышы яктырткан әсәрләр генә керәме, әллә ул киңрәк әдәбиятмы, кебек сорауларны куя һәм аларга җавап бирүнең вакыты җиткәнне әйтә. Ул анда тарихта әдәбиятның бурыч-максатларын аңлауны чагыштырма планда, янәшәлекләр ярдәмендә тасвирлый.

Г. Ибраһимов әдәбиятка мөнәсәбәтнең үзгәрүен XIX йөзнең алтмышынчы елларындагы «азатлыклар»дан соң башланган иҗтимагый хәрәкәтләр белән бәйли. Шушы вакытта тәнкыйтьче симпатиясенең әдәбиятны халыкка корал дип караучы Добролюбов, Чернышевский, Некрасовлар ягында икәнлеге ачык күренә. Ул рус революцион-демократларының һәм марксист эстетикларының хезмәтләреннән, бигрәк тә Г.В. Плехановның «Искусство и общественная жизнь», «Письма без адреса», «Сәнгать турында» мәкаләләреннән мул файдалана, язмаларындагы төп гыйльмитеоретик фикерләрне үз фәнни-публицистик стилендә сөйләп бирә. Әдип хәтта башка каләм ияләренең әйткәннәрен дә, Плеханов текстларыннан гына алып, мәкаләсенә, урыны-урыны белән, ирекле тәрҗемә рәвешендә кертеп җибәрә. Моннан чыкканда һәм бу чорда иҗат ителгән башка язмаларының да Плеханов мирасы белән бәйләнеше барлыгын истә тотканда, егерменче елларда дөньякүләм танылган марксистның сәнгать һәм әдәбият үсешенә, әдәби тәнкыйтькә мөнәсәбәтле карашлары, фәлсәфи-эстетик күзаллаулары Г. Ибраһимов өчен төп теоретик чыганак, методикметодологик ярдәмлек вазифасын башкарган, дигән нәтиҗә дә

---

[1] Ибраһимов Г. Татар әдәбиятын өйрәнү юлында // Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5. Б. 388.

ясарга мөмкиндер. Татар тәнкыйтьчеләре исә, үз чиратында, язганнарында аның фикерләренә иярә.

Г. Ибраһимов әдәбиятның бурычлары проблемасына, шул исәптән «Сәнгать – сәнгать өчен» дигән фикергә ачык һәм төгәл мөнәсәбәтен мәкаләнең «Бу мәсьәләгә марксистларның карашы» бүлегендә белдерә. Монда Г. Ибраһимовның сүз сәнгатенең иҗтимагый функцияләрне үтәвен доминанта позициягә чыгарганлыгы күренеп тора. Кайчандыр әдәбиятның сәнгати камиллеген нык кайгырткан каләм иясе инде болай яза: «…бик күп белогвардеец шагыйрьләр, әдипләр революция әдәбиятын – әдәбият түгел, сәнгать түгел, диләр. Шигырь – плакатта, заборда булмаска, агитация эшенә корал ителмәскә, урамга хезмәт кыйлмаска тиешле; Демьян Бедный – шәп сатирик, шәп көйле фельетончы, ләкин һичбер хәлдә шагыйрь түгел, чөнки ул – бөтен язганнары белән, көндәлек тормышның кирәкләреннән үтә алмый, диләр.

Менә болар, үзләренең бу карашлары белән, тарихның хәзерге дәверендә, әлбәттә, зур зарар кыйлалар. Чөнки кирегә өстериләр»[1].

Югарыдагы өзектән күренгәнчә, Г. Ибраһимов әдәбиятның сугышчан рухын чор, алгарыш таләбе белән бәйли. Ул, сүз сәнгатенең иҗтимагый функцияне гади халык файдасына үтәвен даими кайгыртуына карамастан, үзе дә зур художник буларак, аның сәнгатилек дәрәҗәсе өчен дә көя, әмма, революция агымына марксистлар ягыннан кушылганлыктан, тарихи барышта әдәбиятны корал сыйфатында пропагандаларга мәҗбүр. Шул ук вакытта басма сүзнең сугышчанлыгы аның ихтыярыннан гына да тормый, чор ихтыяҗыннан чыккан, заман тудырган бер күренештер. Әдәби барышны ачуга марксистларча якын килүенең сәбәпләре, беренче чиратта, Яңаны төзәргә кирәклектән килеп чыкканлыкны Г. Ибраһимовның шушы сүзләре дә аңлата булса кирәк:

«Шигырьдә, сәнгатьтә, әдәбиятта булган төрле үзгәрешләрне тикшергәндә, бигрәк тә марксист булмаган тарихчыларны актарганда, безгә башка күп сәбәпләр арасында өч нәрсәгә күбрәк очрарга туры килә:

1 – җәгърәфи сәбәпләр;

2 – талантлар, даһилар;

3 – чит тәэсирләр.

---

[1] Ибраһимов Г. Пролетариат әдәбияты турында // Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5. Б. 428.

Без боларның рольләрен бөтенләй юкка чыгара алмыйбыз, ләкин идеализм тарафыннан утыртылган урыннарыннан куып төшерергә мәҗбүрбез, юкса вакыйгаларны аңлауда адәмнең башын чуалталар, яңлыш юлга җибәрәләр»[1].

Г. Ибраһимов аталган сәбәпләрнең әдәбиятның нинди эчтәлеккә ия булуында төп рольне уйнамавын ача, ләкин артык чиккә ташлана, бигрәк тә иҗтимагый фикер үсешендә, әдәбият яңарышында тышкы тәэсирләрнең, шәхесләрнең ролен соң дәрәҗәдә киметергә, төрле тип йогынтылар эчке үзгәрешләр аркасында гына булганлыкка нык басым ясарга тырыша. Хезмәттә әдәбиятның килеп чыгышы, әдәби өслүб һәм башка күп кенә нәрсәләр дә Плехановча ачыла.

Э. Бариева «Әдәбият белеме һәм тәнкыйть» язмасында, Г. Ибраһимовның яңа социологик гомумиләштерүләргә килүенә бәйле рәвештә һәм үз заманы, ягъни Торгынлык чоры аңлау-аңлатуларыннан чыгып, болай дип белдерә: «Ул Г.В. Плеханов концепциясендә танылган биш рәтле бәйләнеш схемасын төзи (җитештерүче көчләр – җитештерү мөнәсәбәтләре – социаль мөнәсәбәтләр – иҗтимагый психология – әдәбият). Сәнгать эволюциясенең объектив социаль сәбәпләрен ачыклауга юнәлдерелгән әлеге социологик схема, мондый фәлсәфи ориентация – яңа сыйнфый-пролетар караш ноктасыннан кабул итүнең беренче һәм дөрес адымнарыннан иде. Әмма кайбер очракларда бу юнәлеш әдәбиятның материаль һәм сыйнфый җирлек белән бәйләнешен үтә схематик сурәтләүгә китерде. Ялгышлардан котылуның бердәнбер дөрес юлы турыдан-туры марксизм-ленинизм классиклары хезмәтләренә мөрәҗәгать итү, шулардан өйрәнү иде, билгеле»[2]. Күренә ки, монда әдәбият белеме фәне җибәргән хаталар өлешчә тотып алынса да, инкыйлабкача чорда Г.В. Плеханов язганнарының күпчелек очракта Ленинныкына һәм төп марксистларныкына аваздашлыгы исәпкә алынмый.

Әдәбиятны кабул итүгә, аңлатуга, үткән чорларда иҗат ителгән сәнгать әсәрләрен бәяләүгә бәйле дә, Ленин, күпләрдән аерымрак позициядә торуга карамастан, танылган марксистны үзенең

---

[1] Ибраһимов Г. Пролетариат әдәбияты турында // Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5. Б. 430.

[2] Бариева Э. Әдәбият белеме һәм тәнкыйть // Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Т. 4: Татар совет әдәбияты (1917 – 1941). Б.300.

остазы саный, бигрәк тә баштагы чор әсәрләренә югары бәя бирә. 1921 елда «Еще раз о профсоюзах…» хезмәтендә ул Плехановның фәлсәфә буенча барлык хезмәтләрен укымый торып, аңлы чын коммунист була алмыйсың, чөнки алар – марксизмның халыкара әдәбиятында иң яхшысы, дип белдерә[1]. Нәкъ менә Ленин тәкъдиме белән, Совет хөкүмәте егерменче елларда Плеханов хезмәтләрен бастырып чыгара, чит илдә калган китапханәсен һәм архивын Ленинградка кайтарта.

Марксистлар эшчәнлегенә һәм илкүләм үзгәрешләрдән рухланган Г. Ибраһимовның 1917 елдан соңгы тәнкыйте революцион һәм аналитик рухтагы рус тәнкыйтендәге эстетик концепцияләрне татар җирлегенә күчерүне, алга таба үстерүне һәм шулар ярдәмендә халыкның күзаллауларын киңәйтүне, әдәбиятны инкыйлаб эшенә, заман кешесен тәрбияләүгә хезмәт иттерүне күздә тота. Бүгенге көндә Г. Ибраһимов язганнарга, XXI гасыр фәне кыйбласыннан чыгып, тәнкыйди якын килүебезгә карамастан, шуны да танырга кирәк: хезмәтләренең тирәнлеге, идеялеге, төрле формада һәм характердалыгы, җәмәгатьчелек, бигрәк тә каләмдәшләре тарафыннан игътибарга алынуы язучының шушы чор тәнкыйтендә тоткан гаять зур роле турында да сөйли. Халык бәхете өчен дип инанып, инкыйлаби көрәшкә җанын-тәнен фида кылганлыктан, үзе дә зур талант булганлыктан һәм, иң мөһиме, фикердәшләре күплектән дә, 1917 елдан соң ул агитацияләгән, аңлаткан юнәлеш татар әдәби тәнкыйтенең умыртка баганасына әверелә.

Егерменче елларда илкүләм җәелгән вульгар социологизм тәнкыйте әдәбиятны схематизм юлыннан алып киткәндә, аңа каршы тора алырлык берләшкән зур көчләр табылмый. Иҗат методларын аңлатудагы ялгышлыклар, каршылыклар, аларны көлке терминнар белән төрләргә бүлүләр, теге яки иҗатны, әсәрне авторның социаль чыгышына бәйләп анализлаулар, язучының иҗтимагый аң дәрәҗәсен ул сайлаган иҗат методы аша бәяләүләр, сәнгати сыйфатсыз әдәби әсәрләрне дә коммунистик карашларга нигезләнгән идея уздырганда югары күтәрүләр, югары сәнгать әсәрләреннән яшерен дошманлык эзләүләр, һәр язучыда зур идеолог күрү омтылышлары… – барысы да вульгар социологизм дип исемлән-

[1] Ленин В.И. Ещё раз о профсоюзах, о текущем моменте и об ошибках тт. Троцкого и Бухарина // ПСС. М.: Изд-ство политической литературы, 1967. Т. 42. С. 290.

гән һәм бөтен Совет иле мәйданнарын иңләп алган афәти күренешнең чагылышларыдыр.

Г. Ибраһимов, Г. Галиләрнең генә түгел, хәтта ки Г. Нигъмәти һәм Г. Сәгъди кебек зур тәнкыйтьчеләрнең, галимнәрнең татар тәнкыйтендә марксистик әдәбият социологиясен урнаштыруы кайвакыт диалектик-тарихи материализм принципларын сүз сәнгатебезгә механик күчерү рәвешен ала. Әлбәттә, тәнкыйди барыштагы заман күренешләре белән килешмәүчеләр яисә килешмәгән очраклар була, кайбер галимнәр ахыр чиктә хакыйкать ягына баса. Әйтик, Г. Нигъмәти, марксист Плехановка барып тоташкан тәгълиматка ияргәндә, социологик адашулар, схематизм юлыннан китү сагалаганны күрә. Ул «Безнең юл» журналында (1928) басылган «Соңгы җавап» хезмәтендә әдәбиятны социологик һәм фәнни планда өйрәнүнең авыр эш икәнлеген язып чыга. Ә инде «Әдәбият фәненең үсеш юлы нинди булырга тиеш» мәкаләсендә, вульгар социологларның ялгышларын аңлатып, «әдәбият социаль-экономик хәл һәм идеологик ситуацияләрнең автоматик чагылышы түгел, ә чагыштырмача мөстәкыйль иҗтимагый организм, һәм аның «үзенә караган аерымлыклары да бар», дип белдерә. Аның 1930 елда басылган «Әдәбиятта формализм-буржуа карашы» (1930) татар әдәбияты тарихын тудырудагы тайпылышларны ачып бирергә омтылган тәүге язмалардан була.

Г. Нигъмәти 1917–1930 еллар тәнкыйтендә, һичшиксез – зур фигуралардан. Бердән, ул, бигрәк тә гыйльми-әдәби аудиториягә, каләм ияләренең үзләренә дә адресланган язмалары белән, иҗатчылар алдына куелган сәнгати таләпләрне, талант иясенең үзаңын һәм фәнни-иҗади фикерләвен калыплаштыруда катнаша, аларда да әдәби берәмлеккә якын килүнең методларын формалаштыра, татар әдәбият белемендә фәнни эзләнүләр методологиясен үстерүгә көч куя. Икенче яктан, ул тәнкыйтьнең күптөрле чаралары, калыплары белән җиңел эш йөртә, һәм татар тәнкыйтенең шул нокталардан үсүенә, фикеренә һәм гамәлиятенә, чор сүз сәнгатенең кыйммәтләрен аралап алуына үзеннән биниһая өлеш кертә. Аның тарафыннан рецензияләр дә, монографияләр дә, әдәби портретлар да, күзәтүләр һәм башкалар да иҗат ителә. Г. Нигъмәтинең вакытлы матбугат битләрендә һәрвакыт дөнья күргән тәнкыйть хезмәтләре, бигрәк тә каләм ияләренең иҗат алымнарын дөрес тотып алган мәкаләләре хәтта әдәбиятны сыйнфый позицияләрдән торып бәяләгән елларында да татар укучысында югары әдәби зәвык формалаштыруга булыша.

Ф. Галимуллин «1920–1930 еллар әдәби хәрәкәтенә бер караш» рәвешендә язган «Әле без туганчы…» китабында «әдәби әсәрне, сәнгать күренеше итеп караудан бигрәк, идеология чарасы буларак файдалануга борылышны» шулай ук Г. Сәгъди кебек олы тәнкыйтьчеләр эшчәнлегендә дә күрергә мөмкинлекне әйтә. Галим Г. Сәгъди 1923 елда Г. Тукайны шагыйрь җанлы шәхес буларак тасвирласа, үзе исән чагында ук «беренче шагыйребез» дип таныса, БКП ҮКның 1925 елгы «О политике партии в области художественной литературы»[1] резолюциясеннән соң басылган «Татар әдәбияты тарихы»нда (1926), беренче чиратта, идеолог сыйфатында күрүен яза[2]. Белгәнебезчә, резолюция сыйныфлар арасындагы көрәшнең әдәбиятта һаман дәвам итүе, сәнгатьнең, гомумән, сыйнфыйлыгы; партиянең әдәбият белән идарә итәргә, язучыларга мөнәсәбәт булдырырга, тәнкыйть мәсьәләләрен күздә тотарга тиешлеге; әдәбиятта пролетариат язучыларның гегемонлыгы һәм башка проблемаларны чагылдыра.

Егерменче елларда Г. Сәгъдинең дә әдәбиятның иҗтимагыйсәяси тормыш белән бәйләнешләрен аңлау-аңлатуларында, чыннан да, бер эзлеклелек юк сыман. Тирән белемгә, югары әдәби зәвыкка ия галимнең сүз сәнгатенә кагылышлы мирасы күңеле белән әдәби берәмлекнең асыл сыйфатлары нинди принципларга таянырга тиешлекне аңлаган, әмма шул төр аңлауны арткарак куеп, кайчак онытып торып, идеология ничек таләп иткәнне язарга мәҗбүр кешенең вакыт-вакыт буталып китүләрен хәтерләтә. Галимнәр бик хаклы билгеләгәнчә, ул әдәбият тарихын чагылдырган хезмәтләрендә, шул чорда популярлашып киткән М.В. Фриче карашларына ияреп, зур тарихи чор стиле белән әдәбиятныкы арасында туры сызыклы тиңдәшлек уздыра. В. Фриче исә русларда әдәбият теориясенә көчле тәэсир ясаган вульгар социологизм теоретигы буларак билгеле. Э. Бариева фикеренчә, сәнгатьне җәмгыять структурасы, иҗтимагый-экономик формация белән бәйләп карарга омтылу, бер яктан, сәнгать анализында уңай бәяләнсә, икенче яктан, мәсьәләне артык гадиләштерү әлеге уңай күренешне мәгънәсезләндерә[3]. Чыннан да,

[1] Резолюция ЦК РКП (б) «О политике партии в области художественной литературы» от 18 июня 1925 года // Известия ЦК РКП(б). 1925. 1 июля, № 25–26. С. 8–9.

[2] Галимуллин Ф. Әле без туганчы: 1920–1930 еллар әдәби хәрәкәтенә бер караш. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. Б. 19.

[3] Бариева Э. Әдәбият белеме һәм тәнкыйть. Б. 302.

әдәби берәмлекләргә болай якын килгәндә, әдәбият тарихы – иҗтимагый барыш, икътисади төзелеш һәм аның идея өслүбе тудырган стильләр тарихына әверелә.

Г. Сәгъдинең әдәбият үсешендәге кайбер баскычларны Казан алынганчыгы, милли буржуазия, социализм-коммунизм дәвере гыйбарәләре белән атавында һәм соңрак, Г. Ибраһимов фикерләренә таянып, «Татар әдәбияты тарихы»нда (1926) феодализм, капитализм һәм социализм-коммунизм этапларындагы әдәбият дип каравында, беренче чиратта, тарихи принципка һәм милләт тарихының чорларына таянуында чагыла. Г. Сәгъди алга таба үз карашларын аныклый, төзәтә төшә, әдәбият тарихына, сәнгати мирасыбызга вульгар социлогизм күзлегеннән карау биеклегеннән югары күтәрелә, шул сәбәпле оппонентларының көчле һөҗүменә эләгә һәм татар тәнкыйтен үстерүдән читләшә.

Г. Сәгъдинең гыйльми мирасы татар тәнкыйтендә чагыштырма-типологик методның ныгуына китерә, әдәбиятны төрле бәйләнешләр яссылыгында киң планда өйрәнүне, әсәрләргә идея-тематик кына түгел, фәлсәфи-эстетик ракурстан да анализ бирүне дә көчәйтә. Аның фәнни эшчәнлеге татар әдәбият белемендә, шул исәптән тәнкыйтендә аерым бер иҗатны махсус комплекслы өйрәнүләргә дә юнәлеш бирә.

Г. Сәгъдинең «Татар әдәбияты тарихы» әдәби тәнкыйть үсешенә гаять зур этәргеч ясый, чөнки әле яңа гына узган чорга һәм шул чорның аерым баскычларына характеристикасы, XX йөз башындагы нәфис текстларның нинди иҗат методларына каравын ачыклавы, төрле платформаларга нигезләнеп хәрәкәт иткән иҗатчылар турында язуы, әдәби күренешләрне, юнәлешләрне ачуы, укучыны тәнкыйть кулланачак терминология белән коралландыруы белән, тәнкыйтькә методологик-теоретик таяныч булып тора. Инде 1917 елдан соңгы әдәбиятны чагылдырган «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты» (1930) хезмәте аналитик, проблематик, күзәтү характерындагы язмаларга бер үрнәк рәвешен үти. Г. Сәгъдинең татар әдәбиятында футуризм, кубофутуризм, имажинизм, гыйсъянчылык күренешләрен чагылдырган язмалары – егерменче еллар тәнкыйтенең бәһасез байлыгыдыр.

Г. Сәгъдинең «Безнең юл» журналында басылган «Бездә әдәби тәнкыйть» (1927) мәкаләсе һәм шул исемдәге китабы – татар әдәби тәнкыйте үткән юлны тарихи планда яктыртуның беренче һәм уңышлы тәҗрибәсе. Автор тәнкыйть тарихын мәгърифәтче

галимнәр, төрле чорларда яшәгән һәм иҗат иткән фикер ияләре эшчәнлеге белән бәйләп тасвирлый. Соңгы дәвердән бигрәк тә Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Г. Кәрамнарның бу өлкәдә хезмәтләрен югары бәяли. Ул тәнкыйтьне, гомуми дә карап, әдәби тәнкыйтькә һәм театр тәнкыйтенә бүлә, аларны реалистик һәм романтик дип атамыйча, чор шаукымына бирелеп, реалистик һәм идеалистик төрләргә аера.

1920 елларда татар гыйльми-тәнкыйди эшчәнлегендә «яңа совет әдәбиятының чынбарлык, җәмгыять белән бәйләнеше, әдәбиятта сыйнфыйлык һәм партиялелек принциплары, иҗат методы һәм әдәби герой, әдәби мираска мөнәсәбәт мәсьәләләре куела. Әлеге проблемаларны аңлауда шул чор язучылары, шагыйрьләре дә (Ф. Бурнаш, К. Тинчурин, Һ. Такташ, К. Нәҗми, М. Җәлил, А. Шамов, Ә. Фәйзи һ.б.) катнаша. Әдәби тәнкыйть, бу үзәк мәсьәләләрне үзләштерүдә пролетар идеологиягә нигезләнеп, нәфис әдәбиятның эстетик кыйммәтен, сәнгать кануннарын күләгәдә калдыра, әдәбиятның социологиясен, сыйнфыйлыгын беренче планга куя. Дөрес, матур әдәбиятның табигатенә, асылына каршы килә торган чит, ят кануннарга каршы тәнкыйди фикер көрәшеп карый. Эстетик тәнкыйть традицияләрен саклау омтылышы Җ. Вәлиди, Ф. Әмирхан, Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин хезмәтләрендә күзәтелә»[1].

Г. Ибраһимов һәм тарафдарлары, марксистик тәнкыйтькә нигезләнсәләр дә, әдәбиятның матурлыгы, эстетик-этик тәэсире кебек проблемаларны да, билгеле, игътибарга ала. Эш шунда: аларның, әдәби текстларны эстетик категорияләр ярдәмендә ачканда, заман күренешләрен, әдәбиятта тасвирланган эш-хәлләрне еш кына башкачарак ракурслардан торып бәяләве күренә. Нәфис әдәбиятны Яңа ил төзүгә, Яңа кеше формалаштыруга гына хезмәт иттерүче сәясәткә каршы торучылар исә – нәкъ менә әдәбиятның үз асыл максатларыннан чыгып хәрәкәт итүчеләр. Болар арасында Җ. Вәлиди, Г. Рәхим, Г. Гобәйдулиннар кебек асыл татар тәнкыйтенең нигез ташларын салучыларны махсус аерып күрсәтергә кирәк. Алар сүз сәнгатебез иҗтимагый-сәяси көрәш мәйданына әйләнгән шартларда матур әдәбиятның, беренче чиратта, эстетик кыйммәткә ия булырга тиешлеген, сәнгатилеген һәм гүзәллек-ямьсезлек, нәфислек-тупаслык, югарылык-түбәнлек һәм башка категорияләрен алга куеп эш йөр-

[1] Гыйлаҗев Т. История татарской литературной критики: конспект лекций. Б. 82–83.

тергә чакыра. Араларыннан бигрәк тә Җ. Вәлиди әдәби мираска мөнәсәбәттә дә, әдәби әсәрне бәяләүдә дә, сәнгатьнең үсеш юлларын яктыртуда да даими рәвештә Г. Ибраһимов һәм тарафдарлары белән бәхәскә керә, кемнәрдер Г. Исхакый кебек мөһаҗирләрнең исемен дә телгә алырга курыккан бер вакытта, алар мирасын яклап, сүз әйтергә батырчылык итә[1].

Г. Ибраһимовның милли изелгәнлеккә каршы көрәш башында торган әйдәманнарыбызның үзләрен генә түгел, язганнарын да тәнкыйтьләве инкыйлабтан соң ныклы большевистик позицияләргә басуына бәйле. Әдипнең иҗтимагый-тарихи хезмәтләре әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен бәяләгән тәнкыйди язмалары интеллигенцияне, аның инкыйлаб чорындагы ролен яктыртуында кискен үзгәрешләр 1917 елдан соң башлануын ачык күрсәтеп тора һәм аның Совет илен торгызу юлындагы гамәлләренең бер өлешен тәшкил итә. Ул бигрәк тә егерменче елларда танылган зыялыларыбызны Яңа ил төзүгә, Яңа әдәбиятка хезмәт иттерү һәм гади халыктан яңа тип зыялылар калыплаштыру турында уйлана. 1920 елда «Габдулла Кариев иптәш рухына» дип язылган мәкаләсендә Г. Ибраһимов болай белдерә: «Үзенең шөһрәте белән татар дөньясын яңгыраткан Габдулла Кариев түбәннән, тормышның төбеннән, ярлы, караңгы авыл эченнән күтәрелде». Алга таба шушы мотивны әдип һәм прозасында, һәм публицистикасында, һәм фәнни хезмәтләрендә еш ассызыклый, шулай итеп, халыктан чыккан язучы халыкка гына хезмәт итә идеясенә кирәгеннән артык бирелә.

Г. Ибраһимов егерменче елларда зыялыларны инкыйлабка хезмәт иттерү өчен көч куя, бу катламга мөнәсәбәттә марксистларның, бигрәк тә В. И. Ленин һәм аңа ияргән А. В. Луначарский тарафдары була. Әйтик, зыялылар хакындагы язмаларында («Интеллигенция в ее прошлом, настоящем и будущем» (1924), «Интеллигенция и ее месте в социалистическом строительстве» (1927), «Интеллигенция и социализм» (1930) и др.), Луначарский интеллегенциянең уңга авышуларын, демократиягә хыянәт итүләрен тәнкыйтьли, һәм моны төзәтергә мөмкин булган хаталану дип таный, сәбәпләрен күрсәтеп бирә. Ул сәяси дошман зыялылар белән каты көрәш алып барырга, ә иске буын укымышлыларның реакцион

---

[1] Вәлиди Җ. Әдәби мөсахәбә // Татарстан хәбәрләре. 1922. 5 март; Вәлиди Җ. Аңларга тырыштык, аңлый алмадык (Галимҗан иптәш Ибраһимовка җавап) // Татарстан хәбәрләре 1922. 10 март.

элементларын читкә тибәрергә, инкыйлабка каршы көрәшмәгәннәрен социалистик төзелешкә тартырга кирәк дигән фикердә тора.

Г. Ибраһимов инкыйлабтан соң интеллигенциянең бер өлеше аңлы рәвештә маркистик позицияләргә басты, ә бер өлеше – урталыкта, өченчеләре дошман сыйныфларга хезмәт итә дип саный һәм шулай ук урталыктагыларны большевикларга хезмәт иттерү өчен көрәш башлый. Әдип иҗтимагый көрәшкә катнашкан танылган татар зыялылары хакында еш кына ирония белән яза, аларның теге яки бу хәрәкәтләр эчендәге гамәлләрен, позицияләрен тәнкыйть утына ала, кайчандыр көрәштәшләре булган аерым затларга антипатиясе сизелеп тора. Бу, әдәби тәнкыйть яисә башка төр фәнни хезмәтләреннән читкә чыгып, хәтта нәфис иҗатына да үтеп керә. «Яңа кешеләр» (1920) драмасында советка каршы позициядә торган матди хәле яхшы милләтче татар зыялысы Әхтәм Банаев сыйнфый алышта инкыйлабчылар тарафдары булган гади кыз мөгаллимә Камәргә каршы куела. «Милли идарәче» Әхнәф, кызылларның җиңгәнлеген күргәч кенә, үзе әйтмешли, «Чехның, Колчакның йөзе ачылгач», «фикерләремездә тирән үзгәреш – зур перелом булды» дип белдерә, мескенләнә, чарасызлана, ахыр чиктә большевиклар, гавам алдында тезләнә – каләме белән бары тик советка гына хезмәт итәргә ант-вәгъдә бирә.

Г. Ибраһимов «фикерләре төзәлгән»нәр янәшәсенә «эшчекрәстияннан» үсеп чыккан каләм ияләрен дә китереп кушу, һәрдаим халыкка, каләмдәшләренә Яңа заман кыйммәтләрен аңлату эшен аеруча актив алып бара. «Кызыл каләмгә юл ачылсын!» (1920) язмасында әдип: «Искене җимереп, яңа азат тормыш төзүдә кызыл штык, чүкеч һәм урак белән бер дәрәҗәдә хезмәт йөкләтелгән кызыл каләм үз өстендәге бурычны үти алсын өчен, эшчекрәстиянның авыр канлы көрәшендә үткен корал булган кызыл каләмгә киң юл ачылсын өчен, һич нәрсәне яшермәскә, авыруны бөтен куркынычы белән ачып бирергә мәҗбүрбез»,– дип яза[1].

Г. Ибраһимов «Дүртенче елга кергәндә» (1920) мәкаләсендә татар интеллигенциясе каршында кыйбла сайлау мәсьәләсен кабыргасы белән куя: «Ике сыйныф бар. Аларның көрәше дәвам итә. Әдипләр, шагыйрьләр, артистлар, журналистлар, философлар, галимнәр үзләрен алдамасыннар, бу ике сыйныфның кайсы белән баруларына җавап бирсеннәр – халык үзе дә, һичнәрсәдән курыкмыйча, болар-

[1] Ибраһимов Г. Кызыл каләмгә юл ачылсын! // Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5. Б. 237.

ны шул үлчәүләргә салырга тиешле»[1]. «Өч җавап» (1922) хезмәтендә исә Г. Ибраһимов, әдипләрнең әдәби пәрдә астына яшерелгән яисә ачыктан-ачык фикере, тасвирлаганы халыкка тәэсир иткәнлектән, «шагыйрьнең, әдипнең кемгә, нинди әмәлгә, кайсы сыйныфка хезмәте мәсьәләсе килеп чыга. Шигырьнең, әдәбиятның хезмәт, тәрбия мәсьәләсе сүз белән агитациядә, вәгазьдә, фәлсәфәдә, коры фикер сатуында түгел, бәлки адәмнәрнең рухында нинди эз калдырачак күренешләр, вакыйгалар бирүендәдер»[2], дип белдерә.

Үзе дә каләм иясе булган Г. Ибраһимов, интеллигенция һәм инкыйлаб мөнәсәбәтләре турында сүз йөрткәндә, күбрәк әдипләргә, алар иҗатына, инкыйлаб чорында тоткан мәсләкләренә тукталa. Аның язганнары теге яки бу каләм иясенең әдәбият тарихында калу-калмавында, иҗаты ничек бәяләнүдә төп рольне уйный башлый. Егерменче елларда нәкъ менә басма сүзнең халыкның үзаңын үстерүдәге, күзаллауларын формалаштырудагы роле шулкадәр зур була ки, большевиклар, беренче чиратта, нәфис әдәбиятны, аның локомотивы булган тәнкыйтьне һәм вакытлы матбугатны көчле контрольгә ала. Шулай итеп, алар кулындагы тәнкыйть әдип-зыялыларның һәр төр эшчәнлеге белән идарә итүгә керешә.

Г. Ибраһимов татар интеллигенциясенең милләт алгарышындагы гамәлләрен тасвирлаудан бервакытта да туктамый. Ул «Татар әдәбияты хакында тагын бер әсәр» (1923) һәм башка язмаларында тарихыбыздагы иҗтимагый чорларны инкыйлабка килү баскычлары рәвешендә дә күзаллата һәм һәрберсендә иҗтимагый мәйданда билгеле шәхесләр тоткан урыннарны билгели. Әдип «Аңларга тырышыгыз, туганнар!», «Пролетариат әдәбияты турында» (1923) кебек мәкаләләрендә марксист әдипләрнең һәрдаим пролетариатка ничек һәм нинди эчтәлектәге әсәрләре белән хезмәт итәргә тиешлеге, әдәбияттагы сыйныфчылык турында сүз йөртә.

Г. Ибраһимов «Кара маяклар, яки ак әдәбиятлар» дип исемләнгән күләмле хезмәтендә гомерләре буе татар милләтенең алгарышын кайгырткан атаклы шәхесләребезгә, бары тик пролетариатка гына хезмәт итү-итмәү, инкыйлабны кабул итү-итмәү кебек позицияләрдән чыгып, кара мөһер суга: аларны төрек-татар, ислам контрлары һәм «кара әдәбият тудыручылар» дип бәяли. Ул, инкыйлабка төрле юллар белән килүче М. Бигиев, Исхаков, Әмин бәк һәм

[1] Ибраһимов Г. Дүртенче елга кергәндә // // Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5. Б. 243.

[2] Ибраһимов Г. Өч җавап // // Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5. Б. 312.

башка татар зыялылары инде бер кыйблага җыелды, дип белдерә. Ахыр чиктә язучы каләме шуңа барып җитә ки, «„Хәрби шуралар“ һәм буның тирәсендә оешкан барлык тәти „милли“ егетләр, ак офицерлар, боларның иярченнәре – Европадагы хәзерге фашизмның икенче исемдә, икенче төстәгеләре генә иде»,– дип котычкыч нәтиҗә ясый. Кызганыч ки, алар арасында милләт хәдиме булган зыялыларыбыз, татар тәнкыйтенең үсешенә үзеннән өлеш керткән әдипләребез дә бар. Г. Ибраһимовның даими рәвештә татар каләм ияләренең совет иленә каршы эшләре турында сүз алып баруы әлеге иҗатчыларның әсәрләрен әдәбият, шул исәптән тәнкыйть тарихыннан да сызып ташлый.

Г. Ибраһимов, бер яктан, инкыйлабка хәзерләнү дәверендә татар интеллигенциясенең игелекле эшләрен, бигрәк тә заман әдәбиятын формалаштырудагы һәм үстерүдәге ролен уңай бәяли, икенче яктан, инде ул дәвер зыялыларының чоры үтте, пролетариат диктатурасын яклаган, советка хезмәт иткән яңа буыннарны тәрбияләргә, каршы көчләрне большевиклар ягына аударырга кирәк, дигән караштa тора, бу идеяләрне тормышка ашыруда үзе дә бик күп реаль эшләр башкара. Ахыр чиктә хакимлек иткән сәясәт белән тәмам агуланган Г. Ибраһимов, сыйныфлар алышында марксистик күзалламаган, гомуммилләт яшәеше, татарның барлык катлауларының да алга китешен кайгырткан зыялыларыбызга каршы рәхимсез көрәш юлына басып, бик нык хаталана. Аның гыйбрәтле язмышында – шушы чорда иҗат иткән башка татар тәнкыйтьчеләренең дә язмышы, ә гамәлләрендә – теге яки бу күләмдә шул юнәлештәге хәрәкәтләре чагыла.

Г. Ибраһимов марксистларның әдәбиятның сыйнфыйлыгына бәйле кайбер адашуларын, соң чиккә җитүләрен егерменче елларның уртасына җитәрәк үзе дә таный: «Пролетариат әдәбияты» турында китабында: «Бу мәсьәләдә бик зур аңлашылмаучылык бар. Кайберәүләр пролетариат әдәбияты дигән сүздән тик пролетариат тормышыннан алып язылган әдәбиятны гына аңлыйлар, икенчеләр пролетариат әдәбияты эченә мөхәррире эшчеләрдән чыккан әсәрләрне генә кертәләр. Бундый карашлар, әлбәттә, яңлыш»[1]. Әлеге мәсьәләдә Г. Нигъмәти дә шушы позициядә тора. Вакыт аларның хаклылыгын дәлилләде. Яңа унъеллыкка аяк басканда, ил сәясәтендә мөһим роль тоткан коммунист идеологлар тарафыннан В.Ф. Переверзев, Г.В. Плеханов, Ф.М. Фричеларның сыйнфыйлыкны аңлауда

[1] Ибраһимов Г. Пролетариат әдәбият турында // Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5. Б. 445.

ялгыш концепция тудырулары танылa. Язучыларны, аларга хезмәт иткән тәнкыйтьне алга таба да абынулардан саклау кирәклеген аңлаган Г. Нигъмәти 1930 елда «Әдәбият фәненең үсеш юлы нинди булырга тиеш?» рәвешендә уйлануларын бастыра. Ул анда Переверзевның әдәби образны әдип шәхесенең икенче формада яшәве дип санавын кире кага, язучы карашының киңлеген, иҗтимагыйсоциаль тормышның һәр ягына үтеп керә алуын яза[1]. Г. Гали дә Переверзев концепциясендә каләм иясен тар даирәгә бикләү күрә[2]. Х. Хисмәтуллин, Ф. Бурнаш, И. Гази, А. Шамов һәм башкаларның язмаларында шулай ук әдәби әсәргә бәя биргәндә вульгарлаштыруга каршы төшүләр күзәтелә.

Инкыйлабкача ук тәнкыйтьче рәвешендә формалашып җиткән каләм ияләре арасында, һичшиксез, көчлесе – Җ. Вәлиди. Галим фәнни эзләнүләрендә үткәннең теоретик табышларын, әдәбитәнкыйди фикердәге уңышларын нигез итеп алуның әһәмиятен, әдәбиятны милли-иҗтимагый аңның үзенчәлекле – сәнгать чаралары ярдәмендә чагылышы рәвешендә ачарга кирәклекне аңлап эш йөртә. Ул Г. Ибраһимовның мәдәни мирасны бәяләүдә сыйнфыйлык принцибын алга куюына каршы чыгарга батырчылык итә.

Галим тәнкыйтьче Җ. Вәлиди каләменең көче – йөгерек һәм үткер телле язучылар тәнкыйтеннән аермалы буларак, фәнни нигезлелектә, логик эзлеклелектә, кире кагып булмаслык дәлилллелектә. Ул алдан сүз әйтеп ялгышудан курыкмый: милли әдәбиятыбызның актуаль проблемаларына үз вакытында җавап бирергә тырыша. Җ. Вәлидинең күләмле «Әдәби хәрәкәт» (1915) исемле соңгы чор әдәби барышны яктырткан аналитик язмасы инкыйлабтан соңгы журнал мәкаләләренә генә түгел, китап рәвешендәге монографик хезмәтләргә дә, хрестоматияләр, дәреслекләр төзүгә дә, гомумән, бөтен әдәбият белеменә һәм тәнкыйтенә искиткеч зур тәэсир ясый.

Егерменче елларда татар әдипләре матур әдәбиятның үсеш юлы, үткәндәге әдәби мираска мөнәсәбәт турында уйлана икән, монда татар эстетик фикер үсешенә юнәлеш биргән Җ. Вәлиди мәкаләләренең роле, һичшиксез, зур. Нәкъ менә егерменче еллар башында Җ. Вәлиди, Г. Рәхим, Г. Гобәйдулиннар торган бер төркем галим тәнкыйтьчеләр үз хезмәтләрен, иң тәүдә, сәнгать әсәрләренең

---

[1] Нигъмәти Г. Әдәбият фәненең үсеш юлы нинди булырга тиеш? // Яңалиф. 1930. № 1. Б. 42.

[2] Гали Г. Абынуларыбызның берсе // Атака. 1930. № 2. Б. 15.

этик, идея тәэсирен генә түгел, эстетик кыйммәтен, художество эшләнешен кайгыртып язалар, чөнки югары кимәлдә иҗат ителгән, кешене матурлыкка әйдәгән, шул матурлыкны күрсәтеп бирә белгән, тормыштагы ямьсез, имәнгеч, тискәре күренешләрне кире каккан әсәрләрнең генә җәмгыятьтә гомере озын була дип саныйлар.

Иҗтимагый-икътисади тормышның әдәбиятка тәэсирен билгеләгәндә, шул як белән генә чикләнмәү, ә әдәбият тарихының тикшерү объекты матур әдәбиятның үзе, аңа хас сыйфатлар булырга тиешлекне күрсәтү Г. Галинең «Без әдәбият тарихын ничек аңлыйбыз» (1927) мәкаләсендә дә күзәтелә. Бу проблема бөтен ачыклыгы белән бигрәк тә Җ. Вәлидинең «Әдәби мөсахабә», ягъни «Әдәби әңгәмә» (1922), язмасында куела. Галим әдәбият, сәнгать әсәрләрен анализлаганда аларга хас образлы фикерләү, эстетик тәэсир итү сыйфатларын ачыклауны әдәби тәнкыйтьнең иң төп максаты икәнлекне дәлилли.

Җ. Вәлиди әледән-әле әдәби әсәргә сыйнфый ноктадан гына якын килүнең хаталыгын исбатлап чыгышлар ясый. Ул, милли мәдәни-иҗтимагый аңны үстерү максатыннан, шушы чорда кавемдәшләренә татарларның мәдәниятле, укымышлы, зур әдәбиятлы халык икәнлеген күрсәтү белән генә чикләнми, иҗтимагый фикер баскычындагы уңышларыбызны башкаларга да җиткерү өчен, рус телендә гаять тирән эчтәлекле «Очерк истории образованности и литературы волжских татар (до революции 1917 года)» (1923) дип аталган хезмәт – зур вакыт аралыгындагы әдәби барышны да үз эченә алган киңпланлы очерк бастыра. Анда чагыштырма-типологик планда фикер йөртү дә, тасвирлама, текстка анализ һәм башка алымнар да күзәтелә; теге яки бу әдипнең иҗат лабораториясенә, әдәби алымнарга, шәхси стильләргә, гомумән алганда, татар милли стиленә кагылышлы бик кызыклы һәм яңа фикерләр яңгыраш таба, традициялелек һәм яңачалык мәсьәләләре күтәрелә. Бу хезмәт тә, Җ. Вәлидинең башка язмалары да татар әдәби тәнкыйтен алга таба үстерүдә, бер калыпка салуда бик зур роль уйный. Ул инде татар каләм ияләренә матур әдәбият тарихы системалы өйрәнелергә, әдәбият белеме һәм аның бер өлеше булган тәнкыйте фәнни нигезле булырга, галимнәр үз тикшеренүләрендә теге яки бу методологияләргә таянырга тиешлекне ачык күрсәтеп бирә. Г. Сәгъди, Г. Рәхим, Г. Гобәйдулиннар гына түгел, хәтта кайбер мәсьәләләрдә Җ. Вәлидигә принципиаль каршы Г. Ибраһимов та әдәби әсәргә, сәнгати барышка кагылышлы хезмәтләрендә аңа таянмый булдыра алмый.

Танылган тәнкыйтьчеләрнең тәрҗемә эшчәнлеге, моның өчен югары зәвык белән әдәби текстлар сайлавы да әдәбият мәйданына яңа аяк басучылар өчен кирәкле, мөһим. Инкыйлаб һәм Гражданнар сугышы чорында чын әдәбиятның сыйфатын күзаллатырлык, шул хакта уйлатырлык әсәрләрне – сүз сәнгатенең классик үрнәкләрен – татарчалаштыруга Г. Рәхим керешкән була, аннан соң да үз эшчәнлегендә әлеге юнәлешне туктатмый. Аның кереш сүзе белән, мәсәлән, «Шәрык шагыйрьләре» җыентыгы (1919) чыга һәм башка тәрҗемә әдәбият дөнья күрә. Г. Рәхимнең бу чорда тәнкыйтьне үстерүгә керткән өлеше «Сәнгать вә әдәбият» (1917), «Халык әдәбиятымызга бер караш» (1919), «Театр вә әдәбият: „Зәңгәр палас“» (1923), «Тукай һәм балалар әдәбияты» (1923), «Татарстанда матбугат-әдәбият» (1925) мәкаләләре белән билгеләнә. «Г. Рәхим Бөек Октябрь революциясе көннәрендә, хезмәт халкын яклап, сыйныфлар көрәшенә ташланган язучы түгел. /…/ Совет властеның беренче елларында ул әле сәнгатьнең демократлашуына тискәре мөнәсәбәттә булган. Шул позиция аны «демократлашкан сәнгать, шөбһәсез, чын сәнгать булудан чыга. Аның кыйммәте югала»,– дип язуга китергән[1]. Х. Госман «Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе» хезмәтендә Г. Гобәйдуллин белән Г. Рәхимне совет ягында калган һәм эшкә җәлеп ителгән милләтчелек «теоретиклары» дип атады[2].

Г. Рәхимнең фәнни-тәнкыйди карашлары гына тәнкыйтькә алынмады, хәтта ки татар әдәбиятының иң гүзәл үрнәкләреннән булган «Идел» повесте, романтик рухтагы башка әсәрләре дә зур каршылыкка очрады, әдәби җәмәгатьчелектә көчле бәхәсләр уятты. Г. Толымбайский, «Идел» дөнья күргәннән соң, аңа бәясен «иске милли язучының белә торып кирле-морлы язуы» дип гомумиләштерсә[3], С. Җәләл повестьның әдәби зәвык, матур тел, өслүб белән иҗат ителгәнлеген таныды[4].

---

[1] Мәһдиев М. Ерактан яңгыраган аваз // Әдәбият һәм чынбарлык: ХХ йөз башы татар әдәбияты тарихына яңа материаллар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 127.

[2] Госман Х. Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1960. Б. 113.

[3] Толымбайский Г. Китапларны ничек нәшер итмәскә? // Татарстан. 1923. № 205.

[4] Җәлал С. «Ярдәм» мәҗмугасы // Татарстан хәбәрләре. 1922. № 30.

Кызганыч ки, чор идеологиясеннән тулаем читтә кала алмаган Г. Рәхим соңрак «Идел»не үзе дә иске дәвер рухындагы әсәр дип атый, әмма монда романтик әдәбиятка тискәре мөнәсәбәттән битәр, әдәби әсәрнең нинди традицияләрдә язылганлыгын күрү, билгеләү, заман көткәнне әйтүгә мәҗбүр булу дип уйларга кирәк. «Яңа укучылар һәм яңа тәнкыйтьчеләр даирәсе нәфис әдәбиятта иске дәвер рухындагы әсәрләргә юл бирмәү юлында бик сак торалар, «Идел» хикәясе, Ф. Әмирханның «Тәгъзия»се кебек әсәрләргә каршы шау-шулар моны бик ачык күрсәтә» дип уйлаганга да, әдип проза иҗат итүдән туктый, көчен фәнне үстерүгә сала башлый[1].

Егерменче елларда татар тәнкыйте әдәби бәйләнешләр проблемасын киң планда – сәнгать һәм әдәбият, фәнни өлкәләр һәм әдәбият, матбугат һәм әдәбият, халык авыз иҗаты һәм әдәбият, Шәрекъ, Гареб һәм татар әдәбияты, узган һәм соңгы чорлар мирасы, каләм ияләренең үзара мөнәсәбәтләре, традицияләр һәм яңачалык, иҗат методлары кысаларында өйрәнүне көчәйтә. Моңа Г. Рәхим дә үзеннән өлеш кертә. Мәсәлән, ул «Иран шагыйрьләре» дип исемләнгән язмасында мөселман дөньясына иранлылар аша таралган суфичылык һәм аның төп сыйфатлары, фарсы әдәбиятыннан тәрҗемәләргә текст сайлау юллары, телдән телгә күчерү принциплары турында да сүз алып бара[2].

Көрәшнең иң кызган елларында Г. Рәхимнең суфичылык әдәбияты турында уңай планда фикер йөртүе, аның үрнәкләре белән башкаларны да таныштырырга омтылуы каләм иясенең татар әдәбият дөньясында инанган шәхси позициясе барлык турында сөйли. Ә бит Инкыйлабтан соң ук татар әдәби тәнкыйте күтәргән теманың үзәктәгесе – әдәбиятта Искене кире каккан Яңа тормышны яисә аны тудыручыларны сурәтләү була. Бу чорда тәнкыйтьчеләрнең тикшерү объекты, нигездә – уяну дәвере сүз сәнгате, әлеге дәвер исә төрле өслүбле, төрле эчтәлектәге әсәрләр тудырган әдипләрне берләштерүче берничә этаптан тора.

Узган гасыр башында яшәгән каләм ияләре иҗатын теге яки бу яссылыкны аеруча калкытып тикшергәндә дә, Гали Рәхим анализ өчен сайлап алынган әсәрләргә төрле проблемалар ноктасыннан күз ташлый. Ул башкаларга да сүз сәнгатен өйрәнүгә комплекслы

---

[1] Рәхим Гали. Биш ел эчендә татар әдәбияты // Биш ел эчендә. Казан, 1925. Б. 153–195.

[2] Рәхим Г. Иран шагыйрьләре // Шәрык шагыйрьләре. Казан: «Корылтай» ширкәте, 1919. Б. 2–5.

якын килергә кирәклекне әйтә: «Әдәбият тарихын өйрәнү анда гакес ителгән фикер вә идеология тарихын гына өйрәнүдән гыйбарәт икән дип уйланмасын. Әдәбиятның бу ягын өйрәнү аны эстетика (нәфасәт) һәм форма ягыннан өйрәнүне читтә калдырмый; ул һәр яктан өйрәнелергә тиеш»[1].

Егерменче еллар урталарында Гыйльми Үзәк каршында «Татар әдәбияты китапханәсе» дигән сериягә китаплар хәзерләнгәндә, зур галимлеген, әдәбият тарихын яхшы белүен күздә тотып, аларны рецензияләү һәм Кереш сүзләр язу Г. Рәхимгә тапшырыла. Г. Камал, Г. Ильяси, Әхмәт Уразаев-Курмашидай көчле әдипләребезнең иҗат һәм тормыш биографияләре әдәбият тарихына аның каләме белән уза.

Егерменче елларда үзен инде талантлы язучы итеп тойган, таныткан Һ. Такташ, Ф. Бурнаш, Ф. Әмирхан кебекләр генә түгел, тормышка актив позициядә торган бик күп эре һәм вак әдипләр вакытлы матбугатта дөнья күргән әсәрләргә, китап киштәләренә чыккан хезмәтләргә тиз арада мөнәсәбәт белдерергә тырыша. Бу чор тәнкыйтен чын мәгънәсендә бәхәсләр мәйданы дип атарга мөмкин. Ул Г. Гали, Һ. Такташ һәм С. Баттал, Җ. Вәлиди, Г. Ибраһимов һәм башка бик күпләр арасында барган дәвамлы полемикалар белән истә кала.

Инкыйлабтан соң көрәш темасын үзәккә куйган әдәбиятта темалар тарлыгы үзен сиздерсә дә, башка проблемалар белән мавыккан тәнкыйть моңа тиешле игътибар бирми. Шул ук вакытта ул әдәби герой мәсьәләсенә карата үзенең ныклы мөнәсәбәтен булдыра: «стандарт», «коллектив», «схематик», «җанлы», «көрәшче», «эшче», «милләтче» һәм башка каһарманнар турында сөйли, конфликт бик еш «советка дошман элементлар» һәм «безнекеләр» – совет тарафдарлары арасында оеша. Әдәби тәнкыйть теләсә кайсы конфликтның иҗтимагый-икътисади һәм сәяси нигезләнүен, пролетариат күзаллавындагы уңай көрәшче герой файдасына хәл ителешен кайгырта. Алда карап узганча, Г. Ибраһимов кына түгел, Г. Нигъмәти, Г. Сәгъди, К. Нәҗми кебек тәнкыйтьчеләр дә әдәби герой, образ проблемасына революцион көрәш, Социалистик Яңаны кору ноктасыннан якын килә.

1917 елгача дөнья тарихында хакимлек иткән эстетик теорияләрдә үзәккә матурлык категориясе куелса, Яңарыш чорында

[1] Рәхим Г. Урта мәктәпләрдә әдәбият укыту турында // Мәгариф. 1924. № 5.

философлар, беренче чиратта, эстетик идеалга табынса, мәгърифәтчеләрдә матурлык инде, эстетик идеалдан битәр, этик идеалда чагылса, татар тәнкыйтьчеләре инкыйлабтан соң таяныч тапкан марксистик-ленинчыл диалектик һәм тарихи материализмның материя һәм аң, материализм һәм идеализм, эчтәлек һәм форма, сыйнфыйлык һәм партиялелек, интернациональ һәм милли категорияләренә таянуны алгы планга чыгара. Коммунистлар иҗатта сыйнфый карашларны аңлы, тенденциоз рәвештә уздыруны яклый.

Кайбер тәнкыйтьчеләр бигрәк тә егерменче-утызынчы еллар чигендә сыйнфыйлык белән сәнгатьчәлекне органик берләштерү, үзара яраштыру юллары турында да уйлана: «Сыйнфый карашлар, сыйнфый вәһәрләр, митингларда сөйләнә торган сүзләр-пафослар, хәрәкәтләр, әсәрнең әдәби, шигъри ягын капласалар, әсәрнең бөтен идеясе, рухы озын-озын декламацияләр, монологлар аркылы гына бирелә торган булса, язучының сыйнфый тенденциясе кара өстендә ак тегәрҗеп кебек күренеп барса, сәхнә өчен язылган әсәрдә хәрәкәт, матурлык булмаса, пролетариат сәхнәсендә шундый әсәрләр куелса, пролетариат мондый сәхнәдән акылы өчен дә, рухы өчен дә бернәрсә дә ала алмаячак»[1].

Социализм чоры әдәбият белеме сыйнфыйлык һәм партиялелек халыкчанлык белән һәрвакыт янәшә атлый дип санады, күпсанлы пролетариат мәнфәгатьләрен кайгыртуны халыкны яклауга тиңләштерде. Г. Ибраһимов «Пролетариат әдәбияты турында» хезмәтендә шулай ук әдәбиятның халык тормышы белән тыгыз бәйләнештә үсәргә тиешлеген, үсә алганлыгын әйтте[2]. Г. Сәгъди «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты»нда әдәбиятның халыкчанлыгын ленинчыл рухта яклап чыкты[3]. Тора-бара бу карашлар тәнкыйтьтә дә ныгыды, уңдырышлы туфрак тапты. Әдип аңының халык аңы белән кушылуы, массаларга аңлаешлы телдә язу, әсәрләрдә гади кешеләрне тасвирлауны, сүз сәнгатенең фольклор уңышларына таянуын алга сөрүнең татар әдәбияты үсешенә уңай тәэсире, билгеле, зур иде. Егерменче елларда ул бигрәк тә яшь язучыларның, рус әдәбияты экспериментларына ияргән каләм ияләренең формалистик мавыгуларына һәм вульгар социо-

[1] Ходаяров Г. Матур әдәбият турында // Таң. 1929. 25 ноябрь.

[2] Ибраһимов Г. Пролетариат әдәбияты турында // Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5. Б. 469.

[3] Сәгъди Г. Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты. Казан: Татгиздат, 1930. Б. 71.

логизм чиренә көрәштә таяныч булды. Халыкчанлык ахыр чиктә узгандагы мираска мөнәсәбәттә дә төп критерийга әйләнде.

Татар әдәби тәнкыйте иҗат методы мәсьәләләрен бервакытта да читләп узмады. Егерменче еллар уртасына кадәр аны аңлау-аңлатуда да вульгар социологизм чагылыш тапты. Инкыйлабтан соңгы елларда хәтта традициялелеккә, әдәби күчемлелеккә каршы чыгучылар, романтизмның Яңа дәвергә хезмәт итәргә яраклыгын кире кагучылар да булды, ул реализмга каршы куелды, аның тирәсендә аеруча көчле бәхәсләр купты. Романтизмны Октябрьгәчә күпләр төп иҗат методы дип санаганга, инде аның чоры узды, ул чынбарлыкның идеалистик чагылышын гына бирә ала, әдәбиятта социаль мотивларны ачып бетерми яисә гомумән аларын уздырмый дип каралды. Шул ук вакытта Г. Ибраһимов кебек талантлы әдипләр дә, Г. Гали дәрәҗәсендәге зур тәнкыйтьчеләр дә марксистик әдәбият белемендә романтизм методының ахыргача ачылып бетмәвен, аңа карата әлегә объектив фикер әйтелмәвен эчке тоем белән тойды, бу хакта сиздергәләп тә алдылар. Аларның романтизмга карата негатив караштa тормауларын, башкача аңлауларын чагылдырмауларында яисә бу күренешләргә мөнәсәбәтләрендә эзлеклелек юклыкта заманга иярү генә түгел, үзләренең дә дошманга әйләнүеннән күпмедер курку һәм әдәбиятның киләчәген ахыргача күзаллап бетермәү дә сәбәпче булгандыр дип уйларга кирәк. Г. Нигъмәти исә романтизм методының яшәвен һәм яшәргә хаклылыгын аңлап эш итте, әмма бу очракта ул да аның «актив», «прогрессив» канатлары хакында фикер йөртте.

Гыйльми эзләнүләрдә совет чорында реализм методының кирәклеген тану зур авырлык белән барды. Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти, Г. Сәгъдиләр реалистик әдәбиятны алга таба тарихи аренада яшәячәк зур көч итеп күрде, чөнки реалистик иҗат методын, беренче чиратта, чынбарлыкны сәнгатьчә гомумиләштерү, сәнгатьтә социализм идеалларына хезмәт итү, үткәндәге әдәбияттан килгән уңай традицияләрне үстерү чарасы дип санадылар. Бу уңайдан Г. Сәгъди яңа чорда кулланыштагы реализмны социализм планындагы реализм, пролетариат реализмы гыйбарәләре белән атады һәм аңа карата төп фикерләрен шушы рәвешчә белдерде: «Реализм – совет әдәбиятының төп, үзәк ноктасы, төп хасияте. Аның өслүбе дә төбендә реализм өслүбе»[1]. Күрәбез ки, хәтта совет әдәбият белеме «социалистик реализм» төшенчәсен кабул иткәнче үк, әлеге термин татар тәнкыйтендә

[1] Сәгъди Г. Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты. Б. 12.

үзенең чагылышын тапкан иде инде. Һ. Такташ яңа заманда язучыларның иҗат итү алымын «неореализм» дип атаса, Г. Гали, Ф. Сәйфи-Казанлылар диалектик материализм методы хакында сүз йөрттеләр. Әдәби һәм фәлсәфи методларны уртак термин белән атауны РАППчыларның диалектик материализмны сәнгатьчә иҗат методы дип белдергән концепцияләре тамырландырды. Методологиягә мөнәсәбәтле бу төр хаталану, фәнни буталчыклык әдәби иҗат спецификасын, әдәби стиль төрлелеген, гомумән, шәхсилекне, иҗади барышта төрле агымнар яшәргә хаклыкны танымауга да китерә иде.

Татар әдәби тәнкыйте егерменче гасырның икенче унъеллыгында да күбрәк журнал формалары, бигрәк тә полемик характердагы язмалар рәвешендә яши. Анда, реплика, хәбәр, кыска бәяләмә, күләмлерәк рецензия, кайтаваз, проблемалы һәм монографик пландагы очерклар янәшәсендә, нәфис-публицистик оя да зур үсеш ала. Тукайлардан килгән традиция буенча, әдәбият мәйданында ат уйнаткан каләм ияләре фельетон, юмор-сатира аша әдәби барышка, теге яки бу әсәргә кагылышлы фикерләрне еш җиткереп тора. Чын галимнәр тәнкыйте күпчелек очракта сәнгати маһирлыкны алга куеп эш йөртә, геройлар һәм характерлар, әдәби типлар, сәнгать әсәренең милли алгарышка, халык тормышына тәэсире кебек проблемаларны чишәргә алына. Әдәби тәнкыйтьнең үсеше вакытлы матбугатның, басма сүзнең хәл-торышына нык бәйле була.

Егерменче еллар уртасыннан фольклорны өйрәнү эшендә җанлануның әдәби тәнкыйтькә тәэсире шактый. 1921 елда Татар халык комиссариаты каршында беренче фәнни оешма – Академик үзәк төзелә, һәм ул эшчәнлеген 1933 елгача дәвам итә. 1925 елдан анда Г. Ибраһимов рәислек итә. Әдип үз тирәсенә Ш. Әхмәдиев, Г. Нигъмәти, М. Корбангалиев, Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди, Г. Рәхим, Г. Толымбайский, М. Парсин, Г. Максудов, М. Васильев кебек танылган галим һәм иҗтимагый эшлеклеләрне туплый, татар фольклористикасы үсешендә ул язган хезмәтләр, аның идеяләре төп юнәлешне билгели башлый. 1926 елда Г. Ибраһимовның «Безнең юл»да «Тел, әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы. Татар халык әдәбияты турында» исемле күләмле хезмәте дөнья күрә, һәм бераздан М. А. Васильев, Г. Рәхимнәрнең «Фольклор һәм халык әдәбияты җыю өчен кулланма»сы басыла. Г. Ибраһимовның фольклорга мөнәсәбәтле язмаларыннан халык авыз иҗатында матур әдәбиятның тел байлыгы ята дип санавы, аны даими барларга, фәнни өйрәнергә кирәк дип тануы күренә.

Фольклорны өйрәнү методологиясен эшләү белән махсус шөгыльләнгән Ф. Туйкә «Халык әдәбиятын тикшерү юлында» хезмәтендә нәфис әдәбият һәм фольклорның үзара мөнәсәбәтенә, егерменче елларда фольклорның популярлык дәрәҗәсенә кагылышлы бик кызыклы фикер әйтә: «Бер халыкта язма әдәбият ни тикле көчәйсә, ул халык әдәбиятын шултикле кыса, озайта бара. Халыкның язма әдәбияттан читтәрәк торган өлеше аны табигый юл белән, бер яктан, үстерергә омтылса, язма әдәбиятка чумучы төркем аннан ераклаша бара. Бу тиклесен язма әдәбиятның азлыгы яисә шуның киресенчә күренә торган башка халыклар барышыннан да чамалап була.

Безнең язма әдәбиятыбызның фәнни, әдәби, сәяси һәм иҗтимагый яклардан киңәя башлавы, әле бик күптән булмаса да, хәзерге яшьләрнең халык әдәбиятыннан аз өлешле булулары күзгә бәрелеп тора»[1].

Ф. Туйкәнекенә аваздашрак фикерне Г. Рәхимдә дә очратырга мөмкин: «Бер халыкның шәһәр мәдәниятенә керүе – ул халыкның халык әдәбиятына үлем түшәге. Халык әдәбияты акрын-акрын онытыла, ташлана; аның урынын язма әдәбият ала бара. /…/ Халык арасыннан табигый шагыйрьләр һаман чыгып торса да, алар инде үзләренең көчләрен халык әдәбиятына сарыф итә алмыйлар. Аларны шәһәр мәдәнияте үз эченә ала: алар «милли шагыйрьләр»гә әверелеп китәләр»[2].

Егерменче еллар татар совет әдәби тәнкыйте үзенең кайчак – үткен, шифалы, файдалы, ә кайчак хәтта зарарлы, конструктив булмаган сүзе белән, күп хаталыкларга корылган, әмма бай һәм кызыклы Яңаны төзешү эшенә ныклап керешә, әдәби барышның аерылгысыз өлешенә әверелә. Анда идеологик юнәлгәнлек, иҗтимагый күзаллаулар яссылыгыннан һәм социаль-мәдәни кыйммәтләр ноктасыннан бәяләмә, әдәби әсәрне, иҗатны, сүз сәнгатен эпоха һәм шул дәвердәге мәдәни барыш җирлегендә ачу өстенлек итә. Татар әдәби тәнкыйте тарихында нәкъ менә шушы чор тәнкыйтьнең мәдәни тормышта гаять мөһимлеген, әдәбиятның ничек, нинди кызулыкта, нинди юнәлештә үсүендә зур урын тотуын раслый.

[1] Туйкә Ф. Халык әдәбиятын тикшерү юлында // Безнең юл. 1927. № 18. Б. 33–37.

[2] Рәхим Г. Халык әдәбиятымызга бер караш // Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык: төз. Р. Мәрданов, И. Һадиев. Казан: Җыен, 2008. Б. 76.

*1931–1940*

1930–1940 елларда СССР тоталитар идеологиягә нигезләнгән хәрби-сәнәгати дәүләткә әверелә башлый. Халыкара сәяси вәзгыятьтән чыгып, империалистик илләр белән сугышка хәзерләнү кирәк дип табыла, моның өчен дәүләт аппараты үзгәртеп корыла, партия яшәешнең һәр өлкәсенә, барлык иҗтимагый-социаль институтларга тәэсирен көчәйтә, идеология соң дәрәҗәдә монополиянә, ил алып барган сәясәт белән килешмәүчеләрне, башка төр эчке дошманнарны эзләүнең озакка сузылган компаниясе оештырыла. Ниһаять, өзлексез барган репрессияләрдән илдә – тынычсызлык, гомумпсихоз атмосферасы, кеше күңеленә курку хисе урнаша. Совет чорының нәкъ менә шушы унъеллыгында коммунистлар партиясе – зур халык массалары белән җиңел идарә итәрлек көчкә, ә система рәвешен алган сәяси цензура каләм ияләренә – тәнкыйтькә һәм әдәбиятка юнәлеш бирүче, язучылар язмышы белән идарә итүче коралга әйләнә.

Тоталитар хакимиятнең ныгуы шартларында утызынчы елларда эчке һәм тышкы цензура тагын да көчәя, хәтта әдәбият, әдәби тәнкыйть кебек ирекле фикер мәйданы булырга тиешле өлкәләр дә бюрократлаша, хакимиятнең төрле чаралары ярдәмендә изелә. Инде утызынчы еллар ахырына җиткәндә, Советлар илен махсус мактамаган теләсә кайсы каләм иясе шунда ук дошманнар исемлегенә кертелә. Әдәбият өстеннән 1922 елгача Госиздат, Гражданнар сугышы чорында һәм аннан соң Революцион хәрби шураның цензура бүлеге, Бөтенрәсәй гадәттән тыш хәлләр комиссиясе каршындагы хәрби цензура күзәтчелек итсә, аннан соң бу гамәлият Әдәбият һәм нәшрият эшләре буенча Баш идарәгә тапшырыла, хәрби серне саклауның үз күзәтче оешмалары һәм җаваплылары билгеләнә, әдәби һәм сәнгати барыш мәдәният министрлыкларының һәм башка комитетларының да идарә итү өлкәсенә әверелә.

Уен теләгәнчә белдерү ирегеннән мәхрүм, фикер юнәлеше, эчтәлеге, максат-бурычлары өстән билгеләнгән, тоталь күзәтчелек астына куып кертелгән сүз сәнгате, аның әйдәманы булган әдәби тәнкыйть рухи һәм идея планында зәгыйфьләнә, әмма исән калу өчен көрәшүдән туктамый. Ул иҗат процессының, әдәби барышның актуаль проблемалары белән шөгыльләнә, әдәби берәмлекнең партиялелеге, идеялелеге, халыкчанлыгы янәшәсендә, билгеле бер дәрәҗәдә сәнгати кыйммәте, сыйфаты[1] турында да сүз йөртә,

[1] Тинчурин К. Югары сыйфат өчен // Совет әдәбияты. 1936. № 4.

ә тәнкыйтьчеләр үз эшчәнлегендә һәрвакыт макрксистик-ленинчыл генераль линияле методологиягә генә таяна.

Егерменче елларда, Г. Ибраһимов кебек марксист әдипләр, иҗтимагый тормышны һәм шуның бер чагылышы булган әдәбиятны уртак кыса эчендә карап, программ характердагы критик хезмәтләр башкаруны алга куя. Алар тарафыннан иҗат ителгән күләмле мәкаләләрне иҗтимагый-тарихи-тәнкыйди монографияләр кебек карарга, бер үк яисә охшаш темага язылганнарын хәтта циклларга берләштерергә булыр иде. Бу чорда әдәбият белеме тарих, психология, педагогика, социология һәм башка фәннәр фикеренә таянып хәрәкәт итә. Еш кына шул сәбәпле дә язмалар синкретик характер ала. Инкыйлабкача әдәби тәнкыйть теге яки бу сәнгать әсәрен, әдәби күренешне, барышны, язучы иҗатын автор сайлаган позицияләрдән бәяләсә, егерменче еллардан башлап авторга әлеге позицияне Советлар илендә хакимлек иткән Коммунистар партиясе көчләп тагу эшенә керешә. Шушы ук күренешләр инде яңарак шартларда алдагы унъеллыкта да дәвам итә.

Әдәби барышның яңа этабына кергәндә, төп тәнкыйтьчеләр рәтен һаман да тирән белемгә ия әдәбиятчылар, сәнгати барышта, татар мәгарифендә эз калдырган шәхесләр – Г. Ибраһимов, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Нигъмәти, Г. Гали, Г. Сәгъди, Г. Ходаяров кебекләр тәшкил итә, әмма бу хәл тиз арада үзгәрә башлый. Югары вазифалар биләү дә, коммунистик хәрәкәткә керткән өлеш тә исәпкә алынмастан, әлеге каләм ияләре бер-бер артлы хөкем җәзасына тартыла. Шәхес культы елларында Сталин яклаган «сыйнфый көрәш» теориясе татар әдәби тәнкыйтенә дә үтеп керә, аның үзенә генә тәэсир итеп калмыйча, тәнкыйтьчеләр тирәлегендә зур югалтуларга китерә. Хәтта марксистик-ленинчыл тәгълиматка үтә ышанган Г. Ибраһимовның да гомере фаҗигале рәвештә киселә, Г. Рәхим, Ж. Вәлиди, Г. Гали, Ф. Бурнаш, К. Тинчурин һәм башкалар тоталитаризм чорының корбаннарына әверелә.

Утызынчы елларда совет режимы репрессиясеннән өч дистәдән артык танылган татар каләм иясенең гомере өзелә. Аларның барысы да милли тәнкыйть үсешенә теге яки бу күләмдә өлеш керткән була. Әйтик, Галә Ходаяров Казан педагогика институты директоры (1929–1930), Татарстан мәгариф халык комиссары (1931) кебек төрле үтә җаваплы вазифалар башкаруына карамастан, «советка каршы пропаганда алып бару»да гаепләнеп, башта өч елга Әстерхан төбәгенә сөрелә. Аннан ул 1936 елда, яңадан гаеп

тагылмастан, биш елга Колымага озатыла. Ә бит Г. Ходаяров – сәяси китаплар тәрҗемәчесе, дәреслекләр авторы, сәясәт, хуҗалык, мәдәният, әдәбият, сәнгатькә мөнәсәбәтле актуаль проблемаларны яктырткан һәм һәр нәрсәгә карата актив позициядә торган шәхес. Репрессия Партия, совет, җәмәгать оешмаларында, уку йортларында хезмәт иткән, инкыйлабтан соң социализм идеологиясенә үтә бирелгән Ф. Сәйфи-Казанлыны да читләп узмый. Ул 1936 елның сентябрендә, контрреволюцион эшчәнлектә гаепләнеп, кулга алына, ВКП(б)дан чыгарыла һәм 1937 елның 3 август карары буенча шул көнне үк атып үтерелә. Г. Нигъмәтинең дә гомере аяныч тәмамлана. Аны 1937 елның 16 сентябрендә кулга алалар һәм шулай ук троцкийчы контрреволюцион оешмада торуда гаеплиләр. Г. Нигъмәти 1941 елның 4 декабрендә Устьвымлаг исемле тоткыннар лагеренда вафат була.

Милли әдәби көчләрне юкка чыгару сыйнфый көрәш байрагы астында алып барылды, моның өчен төрле «эш»ләр оештырылды. «Сыйнфый көрәшне бигрәк тә рус булмаган җөмһүриятләрдә кискенләштерергә омтылу үзен нык сиздерде. Ул вакыттагы ил җитәкчеләренең берсе Каганович болай диде: «Әдәбият сызыгы буенча, бигрәк тә милли җөмһүриятләрдә сыйнфый көрәш кискенләште, бу фронтта аеруча уяулык кирәк». Милли җөмһүриятләрдә сыйнфый көрәш юк икән, аны тудыру кирәк иде. Татар-башкорт әдәбиятларында милләтчелеккә каршы ыгы-зыгу кузгату, «җидегәнчелек» дигән нәрсәне уйлап табу нәкъ менә шул максатка хезмәт итте дә»[1].

Үзен «халтура» язучы дип таныган тәнкыйтьтән үч алырга, киң җәмәгатьчелектә танылырга, югарыдагыларның мактавын ишетергә теләгән Т. Гыйззәтуллинның (тәхәллүсләре: Ченәкәй, Сәмави) «татар пролетариат әдәбият мәйданын үз монополиясенә» кертү өчен төзелгән «Җидегәнчелек»не пролетар фаш итүче «Идарәгә ачык хат» «иҗат итә». Әлеге хат әдәби җәмәгатьчелектә зур шау-шу куптара. Шул хәлдән соң татар әһле каләм тирәлегеннән эчке дошман эзләү хәрәкәте башлана. Аңа бик күпләр, хәтта башта хат авторының үзен гаепләүчеләр дә, талантлы һәм моңа кадәр иманын саклаган тәнкыйтьчеләр дә аңлы һәм аңсыз рәвештә кушыла. Шушы ук елларда татар каләм ияләре арасыннан «солтангалиевче»ләрне эзләү һәм башка компанияләр дә оештырыла, уйлап чыгарылган эчке дошман-

[1] Галимуллин Ф. «Җидегәнчелек» // Табигыйлеккә хилафлык. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. Б. 84.

нарны, төркемнәрне совет иленә, пролетар көчләргә каршы гомуми хәрәкәтнең бердәм өлешләре итеп күрсәтергә омтылыш күзәтелә. Татар тәнкыйтендә бик ямьсез эчтәлеккә ия – шикаять рухындагы язмаларның саны арта, дөресрәге, ул күзәтче оешмаларга җибәрелгән «донослар» рәвешендә дә яши башлый.

Совет иле утызынчы елларга кергәндә, унъеллык ахырының зур фаҗигаләре әле ачык тоемланмый, соңрак язучыларның күбесе тоталитар режимның һәркемнән дошман эзләү сәясәте гамәлләре үзләрен әйләнеп узар дип өметләнә. Асылда бу төр режимның мәйданга килүендә һәм ныгуында һәркемнең, аңлы һәм аңсыз башкарылган күп гамәлләрнең, бигрәк тә рәхимсез җәберләнгән каләмдәшләр язмышына битарафлыкның, шәхси мәнфәгатьләр хакына үтә саклануның, кирәгеннән артык сугышчан әдәбиятка хезмәт итүнең, иҗат эшен партия күзәтчелеге астына кертүгә бердәм ризалашуның, хакимият тарафыннан чыгарылган һәрбер карарны хуплап каршы алуның, Яңаны сүз һәм кылыч ярдәмендә төзүне дөрес дип табуның, кыскасы, милли һәм шәхси үзаң түбәнлегенең роле зур була.

Рәсәй Коммунистлары Үзәк Комитетының (ЦК РКП(б)) 1925 елның 18 июнендә кабул ителгән резолюциясендә үк, алда да әйтеп үтелгәнчә, сүз әдәбиятта партия сәясәтен ничек уздыру хакында бара. Шуннан соң сүз иреге, фикер төрлелеге кысыла, хакимлек иткән идеологиядән бәйсез тәнкыйть басмалардан кысрыкланып чыгарыла. Дөрес, тәнкыйтьнең дәүләт карамагына кертелүе һәм аңа әдәби эшне оештыру коралы итеп карау Гражданнар сугышыннан соң ук башлана, әмма бу хәрәкәт утызынчы елларга килеп җиткәндә зур тизләнеш ала һәм алга таба көчәйгәннән көчәя.

1925 елны дөнья күргән резолюциянең тәэсире утызынчы еллар башыннан үзен тагын да ныграк сиздерү татар тәнкыйтенең эчтәлегендә ачык күренә. Аның йөзен калыплаштыруда вульгар социологизмга ныклы хезмәт иткән һәм уртакул каләм, фикер ияләре генә саналырлык Ф. Мөсәгыйть, З. Галинең, «марксизм тәнкыйте»н җаны-тәне белән яклаган, талантларга кизәнүдән тәм тапкан Ф. Мөбарның усал рецензияләре, Х. Наумның фикри һәм теоретик планда буталчык мәкаләләре, аларның, чыгышларында кызып китеп, артыгын узынып, үзара да бәхәскә керүләре, сәнгати югарылыктагы әсәрләрдән дошман күренешләр, әйтик, «оппортунизм» чагылышлары эзләүләр, әдәби образларны пролетариатныкына, пролетариатныкы түгелгә бүлүләр һәм башка төр тайпылышларның һәрберсе катнаша.

Дошман эзләү идеясе белән яну еш кына мәкалә атамаларында да яңгыраш таба[1]. Бу еллар тәнкыйте татар әдәбият белеме тарихында иң усал, иң мәрхәмәтсез тәнкыйть булып күзгә ташлана. Әдәби әсәрләргә бәяләмәләрнең теле, лексик кыры кайвакыт юмор-сатира әсәрләренекенә, иҗтимагый-сәяси опуснықыларга якыная. Бу уңайдан Х. Наумның әдәби әсәрне ачу юнәлешендә биргән тәкъдимнәрен өлешчә мисалга китерү дә җитәр иде. Ул «Октябрь» журналының 1931 елгы гыйнвар санында: «Әдәби әсәрнең иң элек идеологиясен ачып салырга кирәк. Моны ачып салу өчен, иң элек ул идеяне каплаган художество пәрдәләрен тәнкыйть пычагы белән рәхимсез «ертып» җибәрергә кирәк»,– дип яза.

Утызынчы елларда кулланылган «әдәби суд», «юлаучылар», «эчке дошман», «эчке эмигрант», «кызыл каләм», «марксист каләм», «марксист фикер», «тарихи материализм», «контрреволюцияче буржуа укымышлылары», «марксизм-ленинизм буенча тикшерүче», «пролетариат идеологиясе белән сугарылган» кебек төшенчәләр тәнкыйтьнең эчтәлеген, кемгә һәм нинди максатлар белән хезмәт итүен күзалларга мөмкинлек бирә. Бу чорда Г. Ибраһимов кебек марксист тәнкыйтьчеләр сүз сәнгатен сәнәгатькә, чын мәгънәсендәге көрәшкә янәшә куя, форма камиллеген әдәби әсәр уздырган идеология белән бәйли: «Димәк, без, индустриядәге кебек, әдәбиятта да иске форма ягыннан да куып җитү һәм узып китү, дип лозунг куйсак, хәзер бу фронтның кайбер тармакларында инде иске әдәбиятны куып җителде, узып кителде. /.../ безнең хәзерге иҗатның дәрәҗәсе үткәннән югары торырга, Керженцев әйтмешли, идеология ягыннан югары куелышы нигезендә форманың камиллеге табылырга тиеш»[2]. Бер үк вакытта тәнкыйтьтә әдәби әсәрнең эстетик кыйммәте я бөтенләй исәпкә алынмый, я кимetelә, я арткы планга калдырыла: «Ләкин безнең совет шагыйренең бу «Сайланма»сы безгә үзенең сүз чибәрлеге, стиль уенчаклыгы, бетем, басым гармонияләре, композиция шаянлыклары белән түгел, бәлки үзенең, үсә-үсә, Октябрьгә килеп җитә алуы, Советны җырлавы, Совет өчен көрәш моментларын массага ачуы, Ленин, Кызыл Армия, комсомоллар турында җанлы шигъри сурәтләр аркылы

[1] Толымбай Г. «Галимҗан Ибраһимов» җыентыгындагы ялгыш һәм дошман карашлар // Яңалиф. 1930. № 5. Б. 70–73.

[2] Ибраһимов Г. Еракtan сәлам // Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5. Б. 507–508.

укучыга тиешле мәгънәләрне бирергә теләве белән кадерле, шулар белән кыйммәтле»[1].

Утызынчы елларда әдәбиятның һәм тәнкыйтьнең торышы, совет әдәбиятының эчтәлеге, формасы, иҗат методы мәсьәләләре кебек проблемалар актуаль булды, алар өчен махсус җыелышлар багышланды, вакытлы матбугатта да сүз сәнгате үсешенә һәм аны яктырткан тәнкыйтькә кагылышлы мәкаләләр даими басылды. Әдәбият белеме һәм тәнкыйтьтәге үзгәрешләргә Партия кабул иткән аерым карарлар юнәлеш бирде. Аеруча Бөтенрәсәй Коммунистлар партиясенең Үзәк Комитеты (ЦК ВКП(б)) 1932 елның 23 апрелендә чыгарган «Әдәбият-сәнгать оешмаларын үзгәртеп кору турында»гы («О перестройке литературно-художественных организаций») карардан соң вакытлы матбугатта тәнкыйть алдында торган максат-бурычларны яктырткан мәкаләләр күренде. Боларга мисал итеп, Ә. Фәйзинең «Иҗат кыюлыгына – юл!» (1933), Г. Галинең «Тәнкыйть турында» (1935) хезмәтләрен китерергә мөмкин.

Ә. Фәйзи тәүге юллары үтә югары күтәренкелек, ясалма пафос белән башлаган әлеге мәкаләсендә болай дип белдерде: «Әдәбият өлкәсендә партия күрсәткән шул киң иҗат мөмкинлекләреннән файдалану, андагы моңарчы яшеренеп яткан потенциаль көчләрне ачу, безнең көчле иҗат омтылышына дөрес юнәлеш биреп җибәрү кебек мактаулы бурычның зур өлеше, һичшиксез, тәнкыйть өстенә төшә. Тәнкыйть – оештыручы. Шуның белән бергә тәнкыйтьне мин «әдәбияттагы учет» дип атасым килә. Ә учет нәрсәне сорый? – Төгәллекне. Учет берьяклы гына булу мөмкинме? – Һич. Учет очраклылыкны сөяме? – Сөйми. Шуңа күрә без тәнкыйтебезнең менә бу кимчелекләрдән котылуын кайгыртырга тиешбез. Иң элек безнең тәнкыйть очраклы, стихиячел булмасын, ягъни ул, әллә нидә бер, туры килгән арада гына язуны ташлап, системага күчсен. Моның өчен бездә тәнкыйтьчеләр кадры җитәрлек түгел икән, аларны булдыру чарасы күрелсен.

Бездә тәнкыйть берьяклы гына булмасын. Гадәттә, безнең тәнкыйтьчеләргә язучының уңышы түгел, ә аның кимчелеге каләм тотып язарга «илһам» бирә. /.../ Тәнкыйть, киресенчә, язучының бөтен ягын үлчәп бәя бирә торган, аңардагы актив һәм пассивның принципиаль дөрес учеты булырга тиеш»[2].

---

[1] Ибраһимов Г. Карт шагыйрьнең яхшы сайланмасы // Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5. Б. 518.

[2] Фәйзи Ә. Иҗат кыюлыгына – юл! // Коммунист. 1933. № 90.

Ә. Фәйзи үзенчәлекле төшенчәләр – хисап терминнары ярдәмендә фикер йөртсә дә, тәнкыйтьнең әдәби берәмлеккә комплекслы һәм «һәр яктан пропорциональ үлчәнгән» якын килүен кайгырта. Ул кимчелекле якларны гына эзләү өйрәнү объектына яман ярлык тагуга китерә дип саный, аларын күрмәүне зарарлы демагогиягә тиңли. Әдип булмаган уңышны да бар дип белдерүне дә, җитешсезлекләрне «тырнап» кына үтүне һәм кайбер башка алымнарын да чын тәнкыйть сыйфатлары дип күрми. Әлбәттә, Ә. Фәйзинең үз язмасыннан да каршылыклы фикер уятырлык урыннарны тотып алырга мөмкин. Мәкаләсе Партиянең 1932 елның 23 апрель аендагы карары нәтиҗәләреннән этәрелеп язылса да, әдип: «Безнең тәнкыйтьчеләребезнең күбесе вакытлы установкалар белән, бүгенге көн сәясәтеннән генә чыгып, Маркс-Ленинның озак дәверләргә каратылган тирән классик тәгълиматына бик аз кагылып үтү белән генә характерлы»,– дип белдерә. Әлеге хезмәттә Ә. Фәйзи әдәби хәрәкәтне җайга сала торган язучылар оешмасы төзү кирәклеген әйтә. «Бу оешма элекке казынучылыкның, шулай әйтергә яраса, әдәби бюрократлыкның дошманы булып, ул иҗат мәсьәләләре белән кайнап тора торган әдәби үзәк булырга тиеш. Әсәрләр уку, алар буенча диспутлар, әдәбият ярышлары, олимпиадалар – бу оешманың һавасы булсын»[1].

Әлбәттә, «Әдәбият-сәнгать оешмаларын үзгәртеп кору турында»гы карарның әдәби тәнкыйтькә уңай да, тискәре дә йогынтысы булды. Ул, бердән, кайбер әдәби оешмаларны юкка чыгаруга, тәнкыйтьне һәм әдәбиятны үстерүгә юнәлтелүе белән, татар әдәби көчләрен үзара якынайтты, иҗтимагый-әдәби оешма сыйфатында көчәйтеп җибәрде, әдәби барыштагы ролен ныгытты, иҗат потенциалына әдәби мәйданга килүгә, әдәбият һәм тәнкыйть турында зур сөйләшүләргә юллар ачты кебек. Икенче яктан, каләм ияләрен партия тирәсендә берләштерү, тәнкыйтьнең тар төркемнәр ихтыяҗына хезмәт итүдән алып китү һәм маркистик-ленинчыл нигездә үстерү, халык каршында гына түгел, партия алдында да җаваплылыгын арттыру рәвешендәге максат-бурычларны байрак итеп күтәртеп, тәнкыйтьтәге фикер хөрлеген, киңлеген кысты, аны һәм әдәбияны партия күзәтчелеге астына куып кертте, фәндә һәм сәнгатьтә диктатура оештыруга шартлар тудырды.

Карар нәтиҗәләре озак көттерми: ВОАПП, РАПП, ТАПП һәм башка оешмалар таратыла, аларның әгъзаларына бердәм союзга

---

[1] Фәйзи Ә. Иҗат кыюлыгына – юл! // Коммунист. 1933. № 90.

керү тәкъдиме ясала, моңа кадәр тәнкыйть үсешенә һәм төрлелегенә үзләреннән зур өлеш керткән «Атака», «Яңалиф» журналлары ябыла, алар урынына чираттагы ел башыннан «Совет әдәбияты» исемле айлык әдәбият, сәнгать һәм тәнкыйть журналы Татарстан совет язучыларының органы сыйфатында чыга башлый. Редакция тәнкыйть методологиясен алга таба да калыплаштыру мөһимлеген, аның үсеш дәрәҗәсен күрсәтә торган проблемалы мәкалә, әдәби портрет, рецензия кебек формаларның яшәве кирәклеген игътибарга алып эшкә керешә. Журнал әдәбият белеменең сүз сәнгате үсешенә бәйле актуаль проблемаларны заманга яраклы чишү, әдәби барышны ачып бирү һәм әдәби әсәрләр аша чагылдыру юлында зур гамәлләр башкара. Заман тәнкыйтенең үсешендә «Совет әдәбияты» тиз арада мөһим роль уйный башлый.

Утызынчы еллар татар әдәби тәнкыйте тарихында ил күләмендә булып узган вакыйгалар да зур эз калдыра. Шуларның иң мөһиме – 1934 елның 17 августыннан алып 1 сентябрьгәчә Советлар йортының Колонналар залында барган һәм эчтәлеге, һәм дәвамлылыгы белән тарихта таң калдырган язучылар җыены – Беренче Бөтенсоюз оештыру корылтае. Аңа хәзерлек уңаеннан июль аенда Совет язучыларының Беренче Бөтен Татарстан съезды үткәрелгән була. Корылтайда, Гаяз Ризвановның өч сәгатьлек чыгышыннан соң, үзләре дә тәнкыйть белән турыдан-туры шөгыльләнүчеләр – Г. Нигъмәти, К. Тинчурин, Р. Ишморат, Г. Гали, Ф. Кәрим кебек атаклы әдипләрнең берсеннән-берсе кызыклы докладлары һәм күпсанлы чыгышлар тыңлана.

Татар әдәбиятының торышы турында Бөтенрәсәй язучылары җыенында ясалачак докладны хәзерләү Татарстан Язучылар союзы рәисе Кави Нәҗмигә тапшырыла, ә фиркасез делегатлар исеменнән Кәрим Тинчурин сөйләячәк дип билгеләнә. Татар язучылары бу вакытка зур югалтулар кичергән булуга карамастан, әле Рәсәй халыклары әдәбияты кысаларында милли сүз сәнгатебез һаман да югары биеклекләрне бирми, сөйләрлек уңышлар күп була.

Докладлар, әлбәттә, заман идеологиясе, партия таләп иткән рухта – сыйнфый позициядән языла. Шул ук вакытта, бүгенге күзлектән чыкканда да, фикер хилафлыкларына карамастан, корылтайдагы чыгышларның әһәмияте аз түгел. Әйтик, К. Нәҗми докладында башка халыкларга татар әдәбиятының зурлыгы, талантларга байлыгы, тиешле сәнгати югарылыкка ияләге һәм киләчәктә үсү юллары күрсәтелә. Әдип, «татар совет әдәбиятының иң зур

уңышы – аның милли чикләнүне бетерүдә, безнең чынбарлыгыбыз шулкадәр бай булган яңа социаль һәм культура-көнкүреш күренешләрен бөтен төрлелекләрендә чагылдыруда, темалар һәм проблемаларда чикләнүне бетерүдә сизелерлек адымнар ясавыннан тора. Бу уңышлар әдәбиятның идея-художество дәрәҗәсенең тагын да үсүе, чынбарлыкны тирәнрәк сурәтләве, тематиканың киңәюе белән билгеләнә»[1], дигән мөһим фикерләр әйтә.

К. Нәҗминең чыгышы татар әдәбиятына карата зур кызыксыну уята, корылтайдан соң әдәби бәйләнешләр көчәеп китә. Чыгышлар татар тәнкыйтенең мөмкинлекләрен дә күрсәтә, аларда хисап, анализ, шулар нәтиҗәсендә туган фараз кебек тәнкыйть алымнары матур үрелә.

Татар әдипләрен съездны ачканда М. Горький әйткән милли әдәбиятларга мөнәсәбәтле җөмләләре аеруча рухландыра. Ул чорда әдәби-мәдәни барышта мөһим рольне уйнаган әдип совет әдәбиятының барлык милләтләр әдәбиятыннан оешуы, азчылык милләтләр иҗатын игътибарсыз калдырырга хак юклык турында сүз алып бара[2].

Корылтай әдәбиятка «үсештәге чынбарлыкны дөрес, тарихитәгаен тасвирлау» таләбе куя. Сталинның хуплавы белән, сүз сәнгатебез алга таба «социалистик реализм» дип аталган методка таянып хәрәкәт итәргә, аның алгарышын кайгырткан тәнкыйть тә аңа шул яссылыктан чыгып бәя бирергә тиеш дип табыла, совет язучылары гына түгел, тәнкыйтьчеләре дә хезмәт кешеләрен соцреализм рухында тәрбияләүче коралга әверелә. Җыеннан соңгы чорда, андагы чыгышлар һәм кабул ителгән карарлар тәэсирендә, әдәбиятның агитацион функциясе калкулана, совет чынбарлыгы идеаллаштырыла, язучылар өстеннән контроль арта, цензорлар һәм редакторларның әдәби барыштагы роле көчәйтелә, әдәби тәнкыйть зур сәнгать әсәрләренең дөнья күрү-күрмәвендә, теге яки бу исемнәрнең макталуы-хурлануында тагын да зуррак роль уйный башлый.

Әдәби тәнкыйть көче белән дә, милли сүз сәнгате традицияләрендә һәм заманга бәйле рәвештә, халык бәхетен, аның киләчәген кайгыртучы сыман тасвирлануларына карамастан, уңай әдәби геройлар элекке уңай персонажларның гүзәл сыйфатларын югалта бара. Алар халык бәхетенә ирешү юлын еш кына канлы сыйнфый

[1] Нәҗми К. Татар матур әдәбияты. Совет язучыларының I Бөтенсоюз съездында ясалган докладның кыскартылган стнеограммасы буенча // Совет әдәбияты. 1934. № 10. Б. 39–49.

[2] Горький М. Әдәбият турында. Казан: Татгосиздат, 1941. Б. 210–211.

көрәштә күрә, әлеге көрәшне эшче массалар бәхетен алга куйган социалистик тормышның гуманистик асылы дәрәҗәсенә күтәрә. Дөрес, тора-бара бу төр геройларның еш кына схематик тудырылуы, шәхсилек сыйфатларына ия булмавы яңа буын әдипләре һәм тәнкыйтьчеләре тарафыннан кире кагыла (М. Җәлил. Чакырылучы ударникларның иҗатлары турында берничә сүз. 1933; һ.б.) Ә. Фәйзинең «Сәхнәдә йөрүче аяклы плакатлар белән тамаша залында утыручы геройлар» мәкаләсе шушы рәвешчә башлана: «Сәхнәдә сыйнфый көрәшне күрсәтү бездә күпвакыт «сыйнфый көрәшле» уйнау булып чыга. Бер якта – «бик яхшы коммунистлар, ударниклар, намуслы инженер». Алар шундый «яхшы», хәтта… тәмәке дә тартмыйлар. Икенче якта – вредитель, лодырь һ.б. Алар шундый явызлар, аларның эшләмәгән бозыклыгы юк»[1].

Әдәби тәнкыйть тарафыннан төп геройларны иҗат итүгә дөрес таләпләр куела башлауга карамастан, социаль бурычны үтәү рәвешендә иҗат ителгән әсәрләрдә сюжет барышында мөһим урын тоткан уңай образлар партиянең, хөкүмәтнең алып барган сәясәтен яклаучылар, альтруистлар, шәхси сыйфатларын югалткан адәмнәр рәвешендә тасвирлану дәвам итә. Ф. Мөсәгыйть, Х. Наум, С. Каратай, Г. Толымбай, Х. Хисмәтуллин һәм башка кайберәүләрнең язганнары вульгар социологизмның һаман да тарихи аренадан төшеп калмавына, хәтта вакыт-вакыт көчәеп алуына китерә. Әйтик, «Ф. Мөбар мәкаләләренең күпчелеге тиешенчә дәлилле һәм этрафлы булмаса да, теге яки бу аерым язучы һәм каләм әһелләре төркеме турында билгеле бер иҗтимагый фикер тудыруда аның башкарган эшләре аз булмый. Аерым алганда, ул Г. Сәгъди, Г. Рәхимнәрне марксизм тәнкыйтенә бөтенләй каршы шәхесләр итеп күрсәтә»[2].

Утызынчы елларның кайчылы-пычаклы тәнкыйтеннән вакытлы матбугат та зыян күрә, аларда басылган әдәби әсәрләрне кирәксезгә чыгару, әдәби барыш үсешенә юнәлтелгән эшләрен танымау күзәтелә, редакция әгъзаларының эшчәнлеген шиккә алырлык мәкаләләр басыла.

Утызынчы елларга кергәндә, реализмга нигезләнгән иҗат методларының чираттагысы – яшәешне И.В. Сталин җитәкчелегендәге

---

[1] Фәйзи Ә. Сәхнәдә йөрүче аяклы плакатлар белән тамаша залында утыручы геройлар // Әдипнең эрудициясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. Б. 126.

[2] Галимуллин Ф. Әле без туганчы: 1920–1930 еллар әдәби хәрәкәтенә бер караш. Б. 40.

коммунистлар партиясе ихтыяҗларына, таләпләренә җавап бирерлек һәм чын хакыйкатьне ачарга бердәнбер сәләтлесе дип саналган социалистик реализм методы калыплаша. Ул атама, 1932 елда А.М. Горький тарафыннан тәкъдим ителеп, 1934 елда совет язучыларының Беренче Бөтенсоюз съездында кабул ителә. Бу уңайдан, И. Нуруллин «Реализм турында» китабында болай дип яза: «Совет әдәбияты тарихының беренче ун-унбиш елын искә төшерик. «Социалистик реализм» дигән сүзнең әле исе дә булмаган бер вакытта язучылар һәм тәнкыйтьчеләр (Горький исә революциягә кадәр үк) үзен пролетариат белән бәйләгән әдәбиятның сыйфат ягыннан яңа рәвеш алганын һәм алырга тиешлеген ачык күрделәр. Бу әдәбиятның үзенчәлеген билгеләү һәм методына лаеклы исем эзләү белән бәйләнешле рәвештә, «неореализм», «диалектик материализм методы», «теденциоз реализм», «монументаль реализм», «пролетар реализм» кебек терминнар телгә кереп чыкты. Дөрес, эзләнү процессы шома гына бармады. Практик иҗатта һәм тәнкыйтьтә утын вату, мөгез чыгарулар да булды. Ә тулаем алганда, бу яңа заманның яңа алым, яңа стиль, яңа метод таләп итүен аңлаудан туган эзләнү иде. Һәм ул матур нәтиҗәләрен бирде. Ниһаять, 1932 елда яңа методка исем табылды: социалистик реализм. Әдәбиятның үзендә барлыкка килгән сыйфат үзгәрешенә туры килә һәм шуны чагылдыра торган термин иде ул»[1].

Әгәр утызынчы еллар тәнкыйтен күздән кичерсәк, анда социалистик реализм терминын аңларга һәм киңкатлам укучыга аңлатырга тырышып язылган саллы мәкаләләрне күп күрербез. Мәсәлән, Г. Нигъмәти «Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре» хезмәтендә социалистик реализм методы төшенчәсенә «социалистик идея җитәкчелегендә типик характерларны типик хәлләр эчендә бирү аша тормышны дөрес һәм җанлы итеп сурәтләүләрдә гәүдәләндерү» дигән мәгънә сала. Галим фикеренчә, «каһарманның типик характерлы булуы аның сыйнфый яки сыйнфый катлауның табигатенә тапкыр килүе дигән сүз. Характер бөтен индивидуаль төрлелеге белән бирелергә, бөтен эчке каршылыклары белән күрсәтелгән булырга тиеш, ләкин шул вакытта анда билгеле бер сыйныф үзен сиздереп торырга, шул сыйныфның сыйнфый табигате өчен типик булган черталар өстенлеге

[1] Нуруллин И. Иҗат методыбыз турында уйланулар // Реализм турында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. Б.58.

анда табылырга тиеш[1]. «Әйтергә кирәк, иҗат методы мәсьәләләрен яктырткanda да Нигъмәтинең сыйнфыйлыкка болай басым ясавы очраклы хәл түгел иде,– дип яза Ф. Мусин.– /…/ бу принципка мондый зур игътибар егерменче еллар әдәбият фәнендә сәнгатьнең сыйнфыйлыгын я бозып аңлату, яисә аны бөтенләй кире кагу тенденцияләре белән көрәштә туды»[2].

Утызынчы еллар әдәби тәнкыйтендә шактый эз калдырган М. Җәлил мирасында да иҗат методы мәсьәләләре зур урын алып тора. Ул социалистик реализм әдәбиятының җанлы сурәтләр, җанлы характерлар һәм художество чаралары аша чынлыкны бирергә һәм чорның бөтен дөреслеген ачарга тиешлеген әйтә[3]. М. Җәлил социалистик реализмны революциягә кадәрге әдәбиятка хезмәт иткән «буржуа реализмы», «статик реализм» янәшәсенә куеп карый һәм яңа методның уңай ягы тормышны хәрәкәттә-үсештә, бөтен тулылыгында сурәтләүдә дип таба. Чит әдәбият белеменнән күчеп утырган әлеге төшенчәләр яисә башка терминнар ул чорда күп тәнкыйтьчеләрдә очрый.

Әдәбиятта ныгып килгән методка күпләр уңышлы санаган термин табылуына карамастан, тәнкыйтьнең, гомумән алганда, бердәнбер иҗат методын гына пропагандалавы, алга таба әдәбиятта ул гына калырга тиешлекне раславы сәнгати уйланмалылыкны чикләүгә, текстлар эчтәлеген бер юнәлешкә салуга, каләм ияләренең күзаллауларын тарайтуга, хәтта әдәби алымнарын, язу манераларын мәҗбүри тагылган методка яраклаштыруга китерә. Съезд, партия куйган бурычларны үтәү кирәклеге матур әдәбиятны бәяләргә һәм үстерергә тиешле булган тәнкыйтьнең үзен дә катгый нормалар кысасына куып кертә. Язучылар Беренче Бөтенсоюз съездыннан әдәбиятның һәм тәнкыйтьнең алга таба кискен үсеп китәчәгенә зур хыял-өметләр белән кайта, әмма озакламый алар җимерелә башлый. «…зур съездда яхшылар рәтендә макталган язучыларның яртысыннан күбесе репрессия корбаннарына

[1] Нигъмәти Г. Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре // Совет әдәбияты. 1933. № 11–12. Б. 84.

[2] Мусин Ф. Әдәбият белеме һәм тәнкыйть // Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Т. 4: Татар совет әдәбияты (1917–1941). Б. 487.

[3] Җәлил М. Сайланма әсәрләр: 3 томда. Казан: Татгосиздат, 1956. Т. 3. Б. 123.

әверелә!»[1] Сәбәбе шунда ки: корылтайда сәнгатькәрләргә мөнәсәбәттә егерменче елларда башланган гаделсез сәясәт анализланмый, аңа объектив бәя бирелми, аның сәнгать һәм әдәбиятта чагылган аянычлы нәтиҗәләре күрсәтелми.

Язучылар берлегенең оешуы, әдәби бәйләнешләр көчәю, әлбәттә, сүз сәнгатенең барышын кызулатып җибәрә, тәнкыйть тә активлаша төшә, аның гамәли әһәмияте арта. Утызынчы елларда бигрәк тә рус тәнкыйте бер-бер артлы чиратлашкан һәм татар тәнкыйтенә дә тәэсир ясаячак дискуссияләр чорына килеп керә, әмма тәнкыйтьтәге бәхәсләрнең чишелеше алдан ук партия карарлары һәм күрсәтмәләре белән билгеләнә. Бу чорда татар тәнкыйтендә әлеге бәхәсләрнең кайтавазлары әледән-әле ишетелә, һәм куелган проблемалар һәрвакыт рус тәнкыйтендәгечә хәл ителә.

Язучыларның Беренче Бөтенсоюз съездыннан соң ук Ф. Панферов, А. Серафимович, М. Горький, А. Толстойлар арасында нәфис әдәбиятның теле нинди булырга тиешлек турында бәхәсләр бара. Иҗатының башыннан ук пролетар позицияләрдә торган Панферов бигрәк тә стилендәге шигари риторика, стиль төссезлеге, фабуланың тормышчан булмавы, тасвирның өстән-өстәнлеге хакындагы тәнкыйтьләрне күтәрә алмый, үзен бу мәсьәләләрдә иң нык тәнкыйтьләгән М. Горькийга җавап хаты белән чыга, язу манерасын камилләштерми. Әдәби тәнкыйтьтә барган бәхәсләрнең күбесе әдәбият файдасына хәл ителмәүне татар әдәбиятындагы мисаллар белән дә дәлилләргә мөмкин булыр иде. Диспутлар ничек кенә кайнар бармасын, утызынчы елларның икенче яртысында иҗатта натуралистик тасвир, әдәби уйланмалылыкка игътибарсызлык яисә ясалмалылык, купшылык, бизәп күрсәтү, стилизация тенденцияләре, капма-каршы геройларны иҗат итүдәге тенденциозлык көчәя генә.

Каләм ияләренең уртак берләшмәсен ештыру корылтаеннан соң үзләрен чынлыкта да күпмилләтле совет язучыларының бер өлеше дип аңлаган татар язучылары тарафыннан русча тәнкыйди язмалар, рус әдәби тирәлегендәге күренешләр үзләренеке кебек үк кабул ителә, игътибар үзәгеннән читтә калмый. Әдәбиятның социалистик төзелешкә яраклы эчтәлеге һәм формасы турында, иң беренче чиратта, саф тәнкыйтьчеләр генә түгел, татар язучыларының барысы да уйлана. Әлеге уйланулар, шул хактагы чыгышлар еш кына мәкаләләр

[1] Фәйзуллин Р. Шомлы еллар, канлы җиңүләр (1934–1945) // Татарстан язучылар берлеге: публицистик уйланулар, тарихи фактлар, хатирә-күзәтүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. Б. 23.

рәвешендә дөнья күрә[1]. М. Максуд, мәсәлән, үзенә хас күтәренке пафос белән: «Шагыйрь социализм төзелешенең авырлыкларыннан курыкмаска, аларны «бизәп» азапланмаска, ләкин җиңүче эшче сыйныфының сау оптимистлыгы белән сугарырга тиеш»,– дип белдерә (Яңалиф. 1931. № 1. Б. 65).

1933–1934 елларда совет әдәбиятындагы юнәлешләр турындагы кайнар бәхәсләр рәтеннән А. Фадеевның төрле иҗат юнәлешләренә каршы төшүен, ә В. Киршонның юнәлешләр төрлелеген яклавын искә алырга кирәк. Болар янәшәсендә шулай ук «новаторлык» һәм «консерваторлык», гомумиләштерү яисә детальләштерү мөһимлеге, аларның төрләре, драматургиядә чынбарлыкны публицистик яисә психологик чагылдыру хакындагы фикер көрәшләрен дә атап узарга мөмкин. Утызынчы елларда рус каләм ияләренең «Совет әдәбияты»нда дөнья күргән актуаль яңгырашлы мәкаләләре шулай ук тегеяки бу бәхәсләрне җанландыруга хезмәт итә. 1936 елның дүртенче санында М. Горькийның «Формализм турында» язмасы басыла. Шуның артыннан ук тәнкыйтьтчеләр «әдәбиятта формализм» проблемасы хакында фикер алышырга керешә, иҗатта күптөрле уйланмалар, калыплар һәм стильләр яшәргә хаклымы-юкмы икәнлек хакында сүз алып бара. Тагын алдан ук көтелгән карашка өстенлек бирелә – әдәби берәмлекләр көнкүрештә булганны тасвирларга тиеш, ә шартлы формалар тормыш-чынбарлыкны аңлаудан ерагайта, дигән нәтиҗәгә киленә. Шул ук вакытта формализмны тормышны конфликтсыз, гади, шомартып тасвирлау дип аңлап, кире кагу кебек уңай тенденция дә күзәтелә, әмма шуңа да карамастан утызынчы еллар ахырында әдәбиятта конфликтсызлык та үз урынын таба.

1936 елда язучыларның берничә көн дәвамында барган гомуми җыелышында ясаган докладында К. Нәҗми, М. Горький һәм башка рус язучыларының үрнәгендә, татар әдәбиятында формализм проблемасын махсус күтәрә. Ул «Татар әдәбияты яңа күтәрелеш алдында» дигән темага докладында, бүгенге кайбер галимнәр дә билгеләгәнчә, әдәби характерларның һәм типларның сәнгатьчә җирлеген ачуга натуралистиграк якын килгән, әдәби уйланмалылыкка аз урын калдырган Х. Вәлинең «Әдәби типлар механизмы»нда (1929) һәм «Татар шигырь төзелеше (метрикә)» (1929) китабында формализм чагылышын күрә. Тәүге хезмәтендә Х. Вәли образ тудыру юлларын,

[1] Гыйззәт Т. Бәхетле, шатлыклы чынбарлыгыбызны дөрес чагылдырыйк (татар совет язучылары дискуссиясендәге чыгыштан) // Совет әдәбияты. 1936. № 4. Б. 40.

гомумән, иҗат психологиясен аңлата, шуңа күрә әдәби геройларны да, беренче чиратта, холык үзенчәлекләренә таянып, «актив һәм сүрән типлар», «салмак һәм күчмә типлар», «пошынкы», «кабаланмалы» һәм башкалар төшенчәләр ярдәмендә, психологик-энергетик типлар рәвешендә тасвирлый. Х. Вәли типлар бүленешендә кеше тән төзелешен өйрәнгән фәннәрнең дә ачышларын куллана һәм, әдәби иҗат механизмын ачканда, аларның терминнарына да таянып эш йөртә. Галимнең әлеге хезмәтен әдәби образларны сурәтләү методикасы рәвшендә аңларга кирәк тә.

Х. Вәли кулланган типка мөнәсәбәтле терминнардагы аныклагыч төшенчәләрдән геройларның холкын, психологиясен ачуда, портретын бирүдә, аерым очракларда, бигрәк тә театр тәнкыйтендә файдалану һәрвакыт мөмкин һәм кызыклы, әмма тормыш-чынбарлыкны чагылдыручы әдәби әсәрләрне анализлаганда, анда нинди социаль типлар хәрәкәт итүен, үзара конфликтка керүен күрсәтү мөһимрәк. Э. Галиева, Х. Вәли хезмәтләренә мөнәсәбәттә, түбәндәге фикерләрне әйтә: «Х. Вәлинең «Әдәби типлар механизмы» хезмәте дә, «Иҗат нигезләре «мәкаләсе кебек, бөтен сәнгать, әдәбият күренешләренә реализм концепциясен күчереп карау кебек кимчелектән азат түгел. Әмма аерым кимчелекләре, җитешсезлекләре булуына карамастан, /…/ 20 нче елларда иҗат процессы мәсьәләләрен фәнни тикшерү һәм хәл итүгә билгеле бер өлеш керттеләр дип әйтә алабыз»[1].

«К. Нәҗми әлеге җыелышларны ачып җибәргән докладында Х. Туфанны, М. Җәлилне, Ф. Кәримне, Ә. Фәйзине һәм Ф. Бурнашны формализм чире белән авыруда, К. Тинчуринны, Х. Садрины, Ф. Сәйфи-Казанлыны, Ш. Усмановны натурализмга бирелүдә гаепли. Җыелышта бу тенденциягә Г. Гали каршы чыга. Мәсәлән, ул Х. Туфанның аерым кимчелекләре буенча аның бөтен иҗатын юкка чыгарырга маташуларны кискен рәвештә тәнкыйтьли. Шул ук вакытта тәнкыйтьче Х. Туфанның формализм карашлары йогынтысыннан арынып бетмәвен дә әйтә. Шагыйрь иҗатындагы формализм күренешләрен Г. Гали аның «авыр алымнар», «декапот» кебек авыр сүзләр, абстракт мәгънәләргә төзелгән, бүгенге чынбарлыкның актуаль мәсьәләләреннән читтә торган афоризмнар» белән мавыгуда күрә. Тәнкыйтьченең бу фикере белән килешүе кыен, чөнки биредә әсәргә форма камиллеге, аныклы җитмәү формализм күренеше итеп бәяләнә. Ә формалистлар, билгеле булганча, киресенчә, форма ка-

[1] Галиева Э. Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. Б. 271–272.

миллеге мәсьәләсен беренче планга куйдылар, әсәрнең эчтәлеге белән исә ныклап кызыксынмыйлар»[1].

Утызынчы елларның икенче яртысында да татар тәнкыйтьчеләре съезд күтәргән мәсьәләләргә әледән-әле әйләнеп кайта, бигрәк тә әдәби методлар турында уйлану өзлексез дәвам итә. К. Нәҗминең 1936 елгы җыелышта методлар мәсьәләсенә шулай ук махсус туктала[2], чөнки бу чорда аларны аңлауда төрле каршылыклар күзәтелә, романтизм методына мөнәсәбәт чиктән тыш катлаулана; кайберәүләр тарафыннан ул, «консерватив» дип табылып, хәтта сүз сәнгате мәйданыннан китәргә тиеш дип карала. Шул ук вакытта иҗат ысулларын идеология белән бәйләү, «кызылландыру» күзәтелә, әдәби тәнкыйтьтә «кызыл романтизм», «революцион романтизм», «актив романтизм» атамалары кулланылышка керә. Димәк, диалектик каршылыклардан чыгып караганда, Яңа ил төзелешенә аяк чалучы яисә хезмәт итмәүче, «пассив» һәм башка төр реализмнар да фаразлана ала. Бу момент тәнкыйтькә иҗатны кирәкмәгән тураклауга, бәяләүгә шарт тудыра.

Социалистик төзелеш әдәбиятында романтизм һәм реализм каршылыкларын җиңүнең ахыр чиктә юлы табыла: социалистик реализм методы реализм һәм «кызыл» романтизмның синтезы рәвешендә игълан ителә, романтизмның сурәтләү алымнары, традицияләре аның эстетикасын баета дип табыла. 1930 елларда әдәби тәнкыйть тарафыннан да социалистик реализм совет әдәбиятында бердәнбер иҗат методы дип танылганнан соң, романтизмның мөстәкыйль метод буларак яшәргә хокукы киселә. Дөрес, романтизмны тулаем кире агу, аны реакцион метод итеп карау хәрәкәте әдәби тәнкыйтьтә бераздан йомшый. Монда Г. Нигъмәти, Г. Сәгъди, Г. Гали кебек зур галимнәр исә романтизм һәм реализмны дөньяга караш ноктасыннан аңлатулары зур роль уйный. Г. Нигъмәти «Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре» (1933), «Социалистик реконструкция чорында татар совет матур әдәбияты» (1934), «Татар совет әдәбияты күтәрелештә» (1934) дигән хезмәтләрендә совет сүз сәнгатендә романтизм һәм реализм урыны мәсьәләсен җентекле анализлый, үзәккә иҗат методы эстетикасын аңлауны куя, реализмның төп принцибы тормышны объектив сурәтләү икәнлекне күрсәтә. Г. Нигъмәти «реалистик романтизм» термины белән эш йөртә, әлеге төшенчәнең эчтәлеген социалистик

---

[1] Мусин Ф. Әдәбият белеме һәм тәнкыйть. Б. 492.

[2] Нәҗми К. Социалистик реализм өчен! // Совет әдәбияты. 1936. № 4. Б. 27–32.

реализмдагы романтизм һәм реализмның синтезы рәвешендә күз алдына китерә: «Революцион романтизм буржуаз әдәбиятның һәр төр романтизмыннан материалистик дөньяга карашка нигезләнүе белән аерыла. Бу романтизм укучыны дулкынландыручан булырга, идеаллаштырылып бирелгән характер, вакыйгаларга урын бирергә, анда хыял байлыгына мөмкинлек ачылырга тиеш. Ләкин революцион романтизм – реалистик романтизм ул: анда хыял белән чынбарлык килешмәслек каршылыкка бирелми»[1].

Утызынчы елларда барган бәхәсләр вакытында романтизм проблематикасы һәм поэтикасы турында соңгы сүз әйтелми, бу метод белән язылган әсәрләрдә уңай герой нинди булырга тиешлекне ахыргача аңлау күзәтелми, шунлыктан романтик әдәбияттагы хыялга бай, көрәшче рухлы легендар каһарманнар еш кына ясалма дип табыла, югары сәнгать таләпләренә җавап бирерлек иҗат ителсәләр дә, тәнкыйтькә дучар була.

Утызынчы елларда совет әдәбиятының төп иҗат методы дип сайланган социалистик реализмга галимнәрнең мөнәсәбәте әлегәчә каршылыклы, әмма күпчелек тарафыннан аның яшәве, әдәбиятка хезмәт итүе кире кагылмый. Алтмышынчы еллар җепшеклегендә дә, Торгынлык этабының соңгы елларында да аның тууын, сәнгатьтә ныгуын табигый күренеш дип тану күзәтелә: «Социалистик реализм ул совет әдәбиятының үсеш юллары һәм аның перспективалары турындагы теоретик бәхәсләр нәтиҗәсе, яки аерым шәхесләрнең фантазиясе белән уйлап чыгарылган метод түгел. Бу яңа иҗат методының беренче тәҗрибәләре Октябрь революциясенә кадәр үк барлыкка килгән иде.

Совет әдәбиятының үсеш тарихы яңа иҗат методы барлыкка килүнең иҗтимагый тормыштагы кискен үзгәрешләр, социалистик революциягә хәзерлек һәм аның җиңеп чыгуы белән бәйле булганлыгын күрсәтә. Үзендә яңа типтагы пролетар партия барлыкка килгән, социалистик революция җиңеп чыккан Россиядә социалистик реализмның формалашуы шуның өчен дә бик табигый күренеш иде. Алдынгы социалистик теорияне халык массаларының революцион хәрәкәте белән кушкан бөек тарихи процесс беренче тапкыр күпмилләтле совет әдәбиятында гәүдәләнде»[2].

---

[1] Нигъмәти Г. Социалистик реконструкция чорында татар совет матур әдәбияты // Совет әдәбияты. 1934. № 7. Б. 106.

[2] Гыйззәтуллин Н. Әдәби хәрәкәт // Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр, 1989. Т. 4. Б. 346.

Утызынчы елларда аерым иҗатларга мөнәсәбәттә дә кайнар бәхәсләр бара. Бигрәк тә зур талантлар каләменнән төшкән әсәрләр тирәсендә шау-шу еш куба. Мәсәлән, «Такташ иҗатын тәнкыйди үзләштерү тарихыннан» язмасында М. Гайнетдинов, шагыйрьгә карата шул чор тәнкыйте мөнәсәбәтен чагылдырып, болай ди: «... тоталитарлыкка йөз тоткан елларда татар әдәбиятында, мөнәсәбәтләре кискен конфликт дәрәҗәсенә якынлашып, ике капма-каршы тенденция формалаша. Беренчесен, Һ. Такташ иҗатында бөреләнгән сызыгын /.../ җәмгыятьне, тормышны яңартуны – җәмәгатьчелек һәм шәхеснең «ирке чикләнмәгән» иҗат һәм фикер, сәләт активлыкларына нигезләүгә каратылган юнәлеш дип атый алабыз. /.../

Яңа әдәбияттагы икенче тенденция – Такташ юнәлешенә каршы ярсу сугыш позициясенә баскан төркем. Бу тенденция асылда кешелеккә, иҗатка каршы булган ясалма принципларга нигезләнә. Аларча, җәмгыятьне яңарту – яңа дәүләт, партия, яңа активистлар (халык тәгъбиренчә, куштаннар) эше; халык, ил исә – пассив инерт масса, стихия дип карала. Ул стихия әлеге актив тарафыннан гына мәгънәле, уңай эчтәлекле хәрәкәткә китерә ала». М. Гайнетдин татар тәнкыйтендә дә оешкан әлеге төркем башында, ягъни Такташ кебек талантларга һөҗүм оештыручыларның алдында К. Нәҗми тора дигән фикерне уздыра, шагыйрьгә сәбәпсез бәйләнүләр, аны нигезсез кыерсытулар, эчкерле тәнкыйть нормага әйләнә, дип белдерә. Ул утызынчы елларда Г. Нигъмәти, Г. Сәгъди кебек намуслы галимнәр дә Һ. Такташ иҗатын бәяләүдә хаталанды дигән карашны яклый[1].

Утызынчы елларда вакытлы матбугатта әдәби осталык турында фикер йөрткән мәкаләләр күп күренә. Әдипләр, тәнкыйтьчеләр бигрәк тә драматургияне сыйфат ноктасыннан үстерү, тематик киңәйтү, әсәрләрне сәхнәдә куелышлы итү турында уйлана. 1933 елда, Совет язучылары союзын оештыру комитеты пленумы үрнәгендә, Татарстан совет язучылары съездын оештыру комитеты да драматургиянең сыйфатлылыгы мәсьәләсен күтәргән махсус җыелыш уздыра. Бу чорда М. Җәлил, К. Тинчурин, Ә. Фәйзи, Ш. Камал, Г. Нигъмәти һәм башкаларның драматургия тәнкыйтенә караган язмалары дөнья күрә, аларның һәрберсе драматургиягә багышланган пленум карарлары тәэсирендә языла. Әлеге хезмәтләрдә татар драматургиясе алдында торган бурычлар, аның халыкны тәрбияләүдәге роле, жанрлары, аларга хас сыйфатлар, драма әсәрләренең башка

[1] Гайнетдин М. Такташ иҗатын тәнкыйди үзләштерү тарихыннан // Хакыйкать юлыннан. Казан: Татар. кит. нәшр, 2001. Б. 143–145.

формалардан аерымлыгы, чималы, сәнгатьчә эшләнеше кебек проблемалар күтәрелә. Тәнкыйтьчеләр сәхнә әдәбиятына карата тәнкыйть сүзләре дә әйтә: агымдагы драматургиягә шаблонлык, ясалмалылык, декларативлык, мәгълүмат бирү белән мавыгу, геройлар бүленешендә схематизм, аларның ак һәм кара персонажлардан гына торуы, фикер сайлыгы һәм башка җитешсезлекләр билгеләнә. Шушы ук чорда аерым иҗатчыларның драма өлкәсендәге уңышлары, яңа куелган яисә язылган әсәрләр хакында да мәкаләләр дөнья күрә, заман традициясенә ияреп, аларда социологик анализга өстенлек бирелә.

Вакытлы матбугатта басылган мәкаләләрдә, аерым әсәрләргә рецензияләрдә, иҗат портретларында драматургиядә киң таралган кимчелекләрнең проза һәм поэзия әсәрләренә дә хаслыгы күзгә ташлана. Ф. Бурнаш «Муса Җәлил шигырьләре» хезмәтендә болай ди: «Лирик шигырьләр дә, агитацион-оештыручы шигырьләр дә бик кирәкле, бик зур тармаклар. Ләкин болары коры декларатив сүзләргә һәм рифмалашкан лозунгларга гына кайтып калмаска тиешләр.

Безнең өчен зур киндерле, сюжетлы әсәрләр кирәк. Алар аша характерлар, кешеләр, геройларны, социалистик төзелеш мәйданнарын бөтен киңлеге белән гомумиләштереп бирергә кирәк»[1].

Татар галимнәренең һәм тәнкыйтьчеләренең әдәби тел үсешен кайгырткан, төрле төшенчәләр, сүзләрне дөрес куллану хакындагы я булмаса язучылар стилендәге җитешсезлекләрне билгеләгән язмалары утызынчы еллар тәнкыйтенең мөһим бер өлеше булып тора. Аларда еш кына эчтәлек һәм тел турында уйланулар үзара берегә, тәгаен мисаллар янәшәсендә көтелгән гомумиләштерүләр дә бар. Мәсәлән, Ф. Бурнаш Ә. Фәйзинең «Качкын» либреттосын шушы эзлеклелектә анализлый: «Либреттоның эчтәлеге», «Либреттоның уңышлы яклары», «Кайбер сурәтләр турында», «Тел эшләнеше», «Уңышсыз сүзләр, мәгънәләр» һ.б. Тәнкыйтьче: «…либретто шигырь, я ак шигырь, я проза белән, я шулардан катнаш формада язылу мөмкин, ләкин, һәрхәлдә, ул матур эшләнгән, музыкаль тел белән язылырга тиеш. Монда ритмик эшләнеш мәсьәләсенә аеруча әһәмият бирергә кирәк.

Автор бу яктан канәгатьләнерлек эшләмәгән. Күп урында ритм агышы өзелеп китә. Строфалар бик «ирекле», очраклы төзелгәннәр. Күп урыннар тонык яңгырыйлар. Уңышсыз рифмалар очрый»[2].

[1] Бурнаш Ф. Муса Җәлил шигырьләре // Әдәбият һәм сәнгать турында. Мәкаләләр һәм рецензияләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 202.

[2] Бурнаш Ф. Качкын (3 пәрдәлек опера либреттосы. Ә. Фәйзи әсәре) // Әдәбият һәм сәнгать турында. Б. 212.

Утызынчы елларда танылган каләм ияләренең юбилейларын уздыруның ныклы традициясе урнаша. Аларга мөнәсбәттә язылган мәкаләләр яисә ясалган чыгышлар, классикларның сәнгати мирасын эстетик һәм идея планында ачуга өстенлек биреп яисә теге яки бу иҗатның татар иҗтимагый-фәлсәфи-эстетик фикер үсешендәге ролен күрсәтеп, агымдагы татар тәнкыйтен баетып җибәрәләр. Бу уңайдан, М. Җәлил фикерләре бик хаклы яңгырый: «Аерым җитешсезлекләренә карамастан, бу әсәрләр, бердән, классикларыбыз турында тәнкыйтьтә урын алып килгән зыянлы, хата карашларны юкка чыгарып, төбендә дөрес карашлар урнаштырдылар; икенчедән, алар халыкта әдәби мираска карата зур кызыксыну уяттылар, аларны яшь буынны тәрбияләү коралына әйләндерделәр; өченчедән, алар татар әдәбияты тарихын тудыру бурычын өлешчә үтәделәр»[1].

Утызынчы еллар әдәби тәнкыйте хакындагы язылганнарны гомумиләштерү рәвешендә, Ф. Мусин фикерләрен китерергә мөмкин: «Гомумән алганда, тәнкыйть бу елларда әдәбиятның идея сафлыгы һәм җитлеккәнлеге мәсьәләләрен үзәккә куя, язучы иҗатының шушы сыйфатлары өчен көрәшә. Әдәбиятның форма ягына игътибар азрак булды яисә форма мәсьәләләре кайчак бик гадиләштерелеп аңлатыла. Кайбер чыгышларда мәгънәләре ягыннан бик ерак төшенчәләрне, мисал өчен, «символ» белән «символизм»ны, «форма» белән «формализмны», «тормыш дөреслеге» белән «натурализм»ны бутау кебек хәлләр хасил булды. Әдәбиятның идея сафлыгы мәсьәләсендә уяулык күрсәткән, әмма эстетик критерийлары анык булмаган мондый тәнкыйть әдипләрнең сәнгатьчә эзләнүләрен еш кына шик астына ала һәм аларга тиз генә сәяси мәгънә бирү ягын карый иде. Кайчак шулай була: бу төр тәнкыйть сүздә әдәбиятның сәнгатьчәлек сыйфатын күтәрүне дүрткуллап яклый, шуның өчен көрәшкә чакыра, ә практикада язучыларның шул юнәлештәге эзләнүләрен формализм күренешләре дип бәяләп кире кага»[2].

### *1941–1955*

Сугыш һәм сугыштан соңгы чор еллар исәбендә зур булса да, татар әдәби тәнкыйте сан һәм сыйфат ноктасыннан үтә дә зәгыйфь, чөнки 1941–1955 еллар – аның үсеше өчен шартлар бөтенләй юкка чыгарылган вакыт. Бердән, сугыш башланыр алдыннан

[1] Җәлил М. Сайланма әсәрләр: 3 томда. Казан: Таткнигоиздат. 1956. Т. 3. Б. 334.

[2] Мусин Ф. Әдәбият белеме һәм тәнкыйть. Б. 491.

гына татар тәнкыйтенең төп көчләре, иң гыйлемле һәм хөррәк фикерле катламы тулысынча диярлек репрессияләнгән, берәүләр халык хуҗалыгының башка тармакларына эшкә тартылган, икенчеләр әдәби хәрәкәттән читләштерелгән, кемдер үз тарихи Ватаныннан чит җирләргә китәргә мәҗбүр ителгән, икенче халыклар фәненә хезмәткә күчкән я тулысынча партия эшенә бирелгән. Бөек Ватан сугышы башланганнан соң, татар әдипләренең калганнары да, нигездә, фронтка җибәрелгән. Кыскасы, әдәби тәнкыйть чын мәгънәсендә кадрлар кытлыгы кичерә. Шушы шартларда ул җанлы методологик эзләнүләрдән читләшә, Сталин догмаларына бирешә, партия күрсәтмәләрен берссүзсез кабул итә һәм хөкүмәтнең кол дәрәҗәсендәге сәнгать көченә әверелә. Анда әдәбият үсешен хакимият эшчәнлеге белән бәйләп мактау, әдәби көчләр белән мактану, совет социалистик әдәбиятын тулысы белән чит ил әдәбиятларына каршы кую, буржуаз сүз сәнгатеннән өстенлеген раслау хакимлек итә. Чын тәнкыйть сүзе бу этапта вакыт-вакыт күбрәк әдәби барыш өчен җаваплыларның гомуми чыгышларында яңгырап-яңгырап ала яисә аны теге яки бу әсәргә мөнәсәбәттә язылган бәяләмәләрдә, кайбер очракларда фронтовик-язучыларның көндәлекләрендә һәм хатларында очратырга мөмкин.

Бөек Ватан сугышы елларында тәнкыйтьнең йомшавына китергән сәбәпләр арасында тарихи-объективлары шактый. Аларның беразы югарыда да аталды. Бу чорда тәнкыйтьнең басылу мөмкинлекләре чикләнә, нәшриятлар продукцияне сугыш чоры ихтыяҗларыннан чыгып сайлый. Русча нәшер ителгән күп кенә журналлар ябыла, ә аларда басылып килгән тәнкыйть мәкаләләре татар гыйльми-тәнкыйди фикеренә турыдан-туры тәэсир итә торган була.

Тирән аналитикага корылган тәнкыйть язмаларының юклыгы сугыш чорында вакытлы матбугатның публицистик тәнкыйтькә йөз белән борылуына да бәйле. Әдәбият, бигрәк тә аның оператив формасы шигърият кенә түгел, әдәби тәнкыйть тә халыкны фронтка мобилизацияләүче көч дип каралганлыктан, аның белән шөгыльләнүчеләр әдәби иҗатка якын килү юлларын гадиләштерәләр, эчтәлекне, аңлаешлылык дәрәҗәсен киң массаларга көйлиләр.

Сугыш чоры әдәби тәнкыйте үзенең төп бурычы дип агитация-пропаганда нәтиҗәләренә ирешүне сайлый. 1941–1945 еллардагы тарихи-сәяси хәлләр әдәбиятның эчтәлеген тиз арада үзгәртүне таләп иткәнлектән, әдәби тәнкыйть Ватанны сакларга, якларга өндәү, дошманга нәфрәтне чагылдырган, фронттагыларның һәм тыл

көрәшчеләренең эчке күңелләрен ачкан, бөтен көчләрен зур Җиңүгә сарыф иткән геройларны тасвирлаган әдәбиятны мактауны алгы планга чыгара.

Кайчак әдәбият гыйльменә караган русча хезмәтләрдә, сугыш чорында партия әдәби тәнкыйть өстеннән идарәчеклекне йомшатканга да, әлеге өлкә үсештән туктый, кебегрәк фикерләргә тап буласың. Бу һич тә алай түгел. Кырыгынчы еллар башына сәяси цензура гадәттән тыш ныгый. Партия әдәби барыш белән идарә итүен бервакытта да туктамый, моның өстенә, ул әлеге функцияне дәүләт органнары булган Главлит һәм Главреперткомга йөкли. Тәнкыйть белән идарә итү әдәбиятка мөнәсәбәтле башка оешмалар, шул исәптән Язучылар берлекләре аркылы да бара. Бу хәл хәтта «җепшеклек еллары»нда да үзгәрми, әдәбият өстеннән күзәтчелек итүчеләрнең либераллашуы бик өстән-өстән генә була һәм вакытлы характер ала. Сталин үлгәннән соң Л. Берия Главлитны хәтта СССР Эчке эшләр министрлыгына буйсындыру адымы да ясый.

Бөек Ватан сугышы елларында Главлитта хәрби тәртип урнаштырыла, цензураның җирле органнарындагы эш шулай ук ныклы күзәтчелек астына алына. 1940 елның 5 февралендә Бөтенрәсәй коммуннистлар (б) партиясенең Үзәк комитеты (ЦК ВКП(б)), «Цензураның түбәндәге органнары» («О низовых органах цензуры») дигән карар чыгарып, әдәбиятчылар өстеннән күзәтчеләрне билгеләүне җирле партия органнарына тапшыра. Карардан соң цензорлар саны да, аларның үз хезмәтен тикшерү дә арта. Меңнәрчә цензор басма сүзнең совет иле сәясәтенә тугрылыгы сагына баса. Шуның нәтиҗәсендә, Бөек Ватан сугышы елларында фронттан җибәрелгән бик күп хатларны цензура аша уздыру мөмкинлеге арта. Бигрәк тә танылган кешеләр, моңа кадәр совет иленең иҗтимагый-сәяси тормышында зур роль уйнаган шәхесләрнең корреспонденциясе ныклы тикшерелә. Шундый шартларда әдәбиятка кагылышлы фикерләрне әйткәндә дә, каләм ияләре бик сакланган дип уйларга кирәк.

1941–1945 сугыш елларында, чишелергә тиешлеге мәҗбүри һәм сугышта җиңүдә хәлиткеч мәсьәләләр артып киткәнлектән, әдәби тәнкыйть икенче пландарак калган кебек булса да, язучыларга партиянең идеологик басымы кимемәгәнне партия чыгарган карарлар ачык күрсәтеп тора. БК(б)П ҮК 1942 елның 6 февралендә кабул иткән «Матбугат өлкәсендә партиянең иң әһәмиятле бурычлары турында»гы һәм 1944 елгы «Татарстан партия оешмаларында масса-политик эшнең торышы» карарлары – нәкъ менә шул күренешнең

чагылышлары. Беренче карар нәтиҗәсендә фронт өчен чыгарылган милли басмалар саны артса да, аларның максаты фәнне, тәнкыйтьне үстерү түгел, ә халыкта зур сугышта дошманны җиңү рухын тәрбияләү була. Соңгы карар исә татар әдәбияты барышына да, әдәбият гыйлемендә үткәнне бәяләүгә дә, тәнкыйтькә дә күпмедер күләмдә тискәре йогынты ясый, көтелмәгән карардан куркып калган әдипләрнең иҗади активлыгын киметә.

Бу чорда вакытлы матбугат язмаларының бик нык регламентлануы да сүз сәнгате үсешен тоткарлый. Күп кенә материалларны хәтта өлкә, край комитетлары секретарьларының рөхсәтен алып кына бастырырга батырчылык итәләр. Дошман якка чыккан, илгә хыянт итте дип фаразланган теләсә кайсы язучының әсәре СССР-да басылу хокукыннан мәхрүм ителә, һәм тәнкыйть алар хакында башкача уңай сүз әйтмәскә тиеш була.

1943 елның 21 октябрендә СССР Язучылар союзы Президиумында татар әдәбиятының Бөек Ватан сугышы елларындагы торышы тикшерелә. Аның эшендә катнашу өчен, кайбер язучылар хәтта фронттан кайта. Утырышта ясалган чыгышлар, гомумән алганда, сугыш елларында да татар әдәбиятының барышы тәнкыйтьчеләр игътибарыннан бөтенләй читтә калмавын күрсәтә. Әлеге утырыш милли сүз сәнгатебезнең художестволылык дәрәҗәсе, жанрлары, заман сулышы, традициялелеге, басма мөмкинлекләре кебек проблемаларны күтәрә.

1944 елның февралендә СССР Язучылар союзы идарәсенең пленумында ясалган чыгышларда да татар әдәбиятына кагылышлы фикерләр әйтелә. Татарстан язучыларының партия җыелышларында вакыт-вакыт яңа әсәрләр тикшерелә, кереш сүзе – фәнни чыгышы да булган әдәби кичәләр еш уздырыла, Татарстан Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институтының гыйльми сессияләрендә дә татар әдәбиятының барышы мәсьәләләре карала. Әлеге чараларда Л. Җәләй, К. Нәҗми Г. Кутуй, А. Шамов, Ш. Рамазанов, Г. Халит, Г. Кашшаф, Я. Агишев һәм башка каләм ияләре актив катнаша. Алар тарафыннан ясалган докладлар, чыгышлар сугыш еллары тәнкыйтенең төп өлешен тәшкил итә.

Сугыш башланганнан соң вакытлы матбугатта алдагы чорда башкарылган кайбер язмалар дөнья күрә һәм әдәби тәнкыйтьнең нинди шартларда да яшәргә тиешлеген искәртә. Мәсәлән, М. Җәлилнең 1940 елның декабренда Татарстан совет язучылары идарәсендә ясаган «Югары сыйфат өчен көрәшкәндә» дип аталган доклады «Со-

вет әдәбияты»нда 1941 елның январь-февраль саннарында басыла. Сугыш елларында татар әдәби тәнкыйтенең күзәтү, хисап рәвешендәге мисаллары янәшәсендә рецензия, шуның бигрәк тә сәхнә әдәбиятын ачкан төре берән-сәрән очрый.

Сугыш еллары тәнкыйте, әдәби әсәрне бәяләгәндә, беренче чиратта, геройлардагы ватанпәрвәрлеккә, сугыштагы һәм тылдагы каһарманлыкка, рухи ныклыкка аеруча игътибар итә, әдәбиятның тормышчанлыгы, заманчалыгы мәсьәләләрен дә онытмый, сугыш чоры әдәбиятындагы геройлар бирелешендәге чиктән тыш схематизм, аклык-каралык күренешләренә, төчелек, пафослылык кебек сыйфатларга күз йома, чөнки алар чор кешесендә социалистик системага мәхәббәт тәрбияләүдә шушы этапта мөһим тоела.

Кырыгынчы-илленче еллар чигендә дә И.В. Сталин җитәкчелегендә төрле пропаганда кампанияләре оештырыла. Әйтик, «космополитлыкка», «буржуаз милләтчелеккә», «патриот булмаганнарга» каршы ачыктан-ачык көрәш башлана. Бу кампанияләрдән бигрәк тә сәнгать һәм театр тәнкыйтьчеләре зур зыян күрә. ҮК 1946 елның 14 августында ««Звезда» һәм «Ленинград» журналлары турында» һәм 26 августта «Драма театрларының репертуары һәм аны яхшырту чаралары турында» һ.б. карарлар чыгара, анда шулай ук сәнгатькәрләр, бигрәк тә драматурглар һәм киномотографистлар иҗатына тупас тыкшыну чагылыш таба.

Сугыш елларында, агитация ничек кенә көчле алып барылмасын, дөнья күргән, башка алдынгы илләр аркылы узган каләм ияләренең әкренләп иҗтимагый аңы үсә, акыллары айный бара һәм зыялыларның таррак булган катламы хакимияткә карата үзендә яңача караш формалаштыра башлый, чөнки дошман яулаган Ватан кырларыннан зур җиңүләр яулап кайткан интеллигенцияне тагын да кысрыклау, аннан һаман шикләнү, аны, төрле сәбәпләр табып, һаман да җәзага тарту, теге яки бу әсәрләрне «идеологик зарарлы» мөһере сугып бастырмау дәвам итә.

1946 елда ҮК Секретариатының «Әдәби-нәфис журналлар өстеннән контроле» карары юкка чыгарылса да, чынлыкта хакимят күзәтчелектән баш тартмый, ул төрле битлекләр астына ныграк яшеренә генә. Коммунистлар партиясенең Политбюросы даими рәвештә агитэшчәнлек, әдәбиятны норматив тәнкыйть иләге аркылы уздыру чараларын оештыруны кайгырта. Әсәрләре, үзләре тәнкыйтьчеләрнең идеология кайчысына эләккән иҗатчыларның алга таба китаплар гына түгел, Үзәк журналларда һәм газеталарда

мәкаләләр бастыру мөмкинлекләре дә чикләнә я бөтенләй киселә. Җитәкче постлар биләгән рус язучыларының – А. Фадеев, А. Сурков һәм К. Симоновның 1953 елның 24 мартында Н.С. Хрущевка аерым иҗатчылар өстеннән язган шикаять рәвешендәге хаты яңа репрессияләргә, бигрәк тә рус булмаган милләтләрнең каләм ияләрен җәзага тартуга, язучылар оешмаларыннан чыгаруга җирлек хәзерли.

Хәтта Сталин вафатыннан соң да тоталитар системаның җәза институтлары инерция буенча үз эшләрен башкаруын дәвам итә. 1955 елның декабреннән соң гына, репрессияләнгән еврей язучыларының гаиләләре басымы астында, милли телдә язучы каләм ияләренә карата рәсми сәясәттә җибәрелгән хаталар таныла.

Әдәби хәрәкәттәге, язучылар хакимиятендәге теге яки бу эшхәлләр, тәнкыйтьтәге үзгәрешләр кайбер каләм ияләренең, бигрәк ил башлыкларына якынайтылганнарның, кайвакыт хәтта алардан алардан ерак торганнарның да үзара көрәше аркасында килеп туа. СССР Язучылар союзының тарихы шуны ачык күрсәтә. Бу көрәш сугыштан соңгы елларда бик нык көчәя, һәм һәр як, һәр төркем әлеге бил алышуда, хакимияткә ыргылуда тәнкыйтьне корал итә. И.В. Сталин үлгәннән соң, озак вакытлар идарәчелектә утырган, үз эшчәнлегендә тупас хаталар җибәргән, каләмдәшләренең фаҗигале язмышында зур роль уйнаган А. Фадеев һәм аның тарафдарларын хакимияттән читләштерүгә мөмкинлекләр туа. Бу вакытта тагын әдәби тәнкыйть, шикаятьләр, төрле җыелышлар ярдәмгә килә. Шушыңа ук аваздаш күренешләр кечерәк масштабларда татар әдәби тирәлегендә дә күзәтелә.

Милли гыйльми потенциалга сугыш һәм башка тарихи-иҗтимагый-сәяси хәлләр ничек кенә зыян салмасын, аны тәмам юкка чыгу куркынычы астына куймасын, Бөек Ватан сугышыннан соңгы тәнкыйть һәм әдәбият белемендә күпмедер җанланыш сизелә. Татарстан Язучылар союзы һәр атнада «Әдәби җомга» кичәләре уздыра. Анда яңа әсәрләр белән танышалар, аларны тикшерәләр, төрле докладлар тыңлана, бәхәсләр оештырыла. Шушы чорда СССР Язучылар идарәсе Пленумында да милли әдәбиятларны өйрәнү мәсьәләсе хакында сүз кузгатыла, А. Фадеев тарафыннан утырышчыларга, төрле милләтләрнең әдәбиятын өйрәнү үзара дуслыкны, совет патриотизмын көчәйтүгә булышлык итә, дигән фикер җиткерелә.

Татар каләм ияләре үзләре дә милли әдәбият тарихын язу кирәклеген аңлыйлар, бу хакта даими рәвештә сүз алып баралар. 1955 елның ноябрь санында «Совет әдәбияты» журналында Х. Хәйринең «Татар әдәбияты тарихын өйрәнү мәсьәләләренә кара-

та» һәм Г. Халитнең «Татар совет әдәбиятын өйрәнү тарихыннан» мәкаләләре басыла. Әдәбият тарихын язуга кагылышлы сүзләрнең, эш-гамәлләрнең нәтиҗәсе дә күренә: М. Гайнуллин һәм Җ. Вәзиевалар 1947 елда XX йөз башы татар әдәбиятын чагылдырган дәреслек-хрестоматия бастыра. Г. Халит, Х. Хисмәтуллин, Б. Гыйззәтләрнең «XX йөз башындагы татар әдәбияты» (1954) дөнья күрә.

Илленче елларның беренче яртысында бигрәк тә мәгърифәтчелек әдәбияты фәнни нигездә ныклап өйрәнелә һәм аның хакында алда басылып чыгачак шактый хезмәтләр языла. Шушы ук елларда «Татар поэзиясе антологиясе» дә хәзерләнә. Әлбәттә, аның нинди эчтәлектә чыгуында, әсәрләр сайланышында әдәби тәнкыйтьнең роле зур була.

Кырыгынчы еллар ахыры – илленче еллар башында теге яки бу каләм иясенең иҗатын тикшерү объекты иткән монографик хезмәтләр бер-бер артлы дөнья күрә, тәнкыйди-биографик очерклар басыла башлый. Бигрәк тә Тукай, Такташ, Җәлил поэзиясенә игътибар арта. Моңа дәлил рәвешендә, Х. Хәйринең «Һ. Такташ (Тормышы һәм иҗат юлы» (1949), М. Маминның «Һ. Такташ поэзиясе» (1952), Х. Госманның «Такташ поэзиясе» (1953) хезмәтләрен китерергә мөмкин. 1956 елда, фронт юлларын узып, иҗат мәйданына кайткан яшь прозаик һәм тәнкыйтьчеләрдән И. Нуруллинның «Тукай эстетикасы» басыла. Н. Гыйззәтуллин – К. Нәҗми, Б. Гыйззәт, Т. Гыйззәт, ә М. Җәләлиева Г. Бәширов хакында күләмле хезмәтләр бастыра. Галимнәр узгандагы мирасны, бай фактик материалларга таянып, әлеге материалны күп очракта беренче тапкыр гыйльми әйләнешкә кертеп, объектив бәяләргә, һәр иҗатка комплекслы якын килергә тырыша.

Тәнкыйтьчеләр әдәби жанрлар, аларның төп үзенчәлекләре, жанрара бәйләнешләр турында сүз алып баралар, шуңа мөнәсәбәтле бәхәсләргә киң юл ачалар. Бәхәс мәйданында бигрәк тә Х. Хәйри активлык күрсәтә. Ул 1948 елда «Совет әдәбияты» журналында «Сугышчан поэзия өчен», «Тормыш поэзиясе» исемле мәкаләләр бастыра. Бәхәскә Л. Җәләй, Ә. Фәйзи кебек атаклы тәнкыйтьчеләр дә кушылып китә. Аталган проблема белән беррәттән, әдипләр әдәбиятта уңай герой, яңа кеше образы, яңа сәнгатьнең эчтәлеге, сүз сәнгатенең халыкчанлыгы кебек башка мөһим мәсьәләләрне дә күтәрәләр.

Илленче еллар башы һәм рус, һәм татар тәнкыйте яңа кеше образы турында сөйләшүләрне яңадан калкуландыра. Татарстан Язучылар союзының 1954 елда уздырган III съезды алдыннан ук

«кимчелекле» һәм «кимчелексез» герой мәсьәләсе турында сөйләшүләр бәхәс төсен алган була. Съездда бу яңадан кабатлана. Берлек идарәсенең хисабында да, төп докладта да, аерым чыгышларда да уңай герой проблемасы үзәк урынны ала. Корылтайдан соң «Совет әдәбияты» (1954) журналының сигезенче санында М. Әмир («Кимчелексез уңай герой») белән Ф. Хөснинең («Кешегә мәхәббәт турында») уңай геройны иҗат итү принцибын күзаллаулары мәкалә рәвешендә дөнья күрә. Үзе дә шул рәвешчә иҗат иткән Ф. Хөсни каләмдәшләрен уңай геройны схематик түгел, ә җанлы кеше итеп һәм яратып сурәтләргә чакыра.

Корылтайда уңай герой проблемасының чишелешенә нокта куелмый, чөнки аны әсәрнең конфликты белән бәйләү җитми. Совет язучыларының Икенче Бөтенсоюз съезды (1954) әлеге проблеманы шулай ук читләп узмый. Анда кимчелексез уңай каһарман турындагы карашлар кискен кире кагыла. Тәнкыйтьчеләр уңай геройны идеаллаштыруга каршы чыга, чөнки дискуссиядә катнашучыларның күпчелеге, образларны идеальләштерү конфликтсызлыкка китерә, дигән караштa тора. Язучыларның зур җыелышында шулай ук әдәбиятның романтик сыйфатлары да карала, романтик стильдә язуның әдәбият өчен кирәклеге, аны баету турында фикерләр әйтелә. Корылтай делегатлары, иҗат методлары мәсьәләсен күтәреп, социалистик реализм методының катып калган кагыйдәләр җыелмасы булмавына, тормышны тулы гәүдәләндерүенә һәм үсештәлегенә басым ясый.

Язучылар алдында торган актуаль бурычларны ассызыклавы белән, корылтай әдәби тәнкыйтьне тагын бер кат активлаштырып җибәрә. Әлеге мөһим чарадан соң вакытлы матбугатта съезд күтәргән проблемаларны яктырткан мәкаләләр янәдән янә басыла. Татарстан язучылар союзының III съездындагы «Татар совет әдәбиятында уңай герой» темасына доклад ясаган Г. Бәшировның бераздан язучылар алдында торган бурычларны яктырткан һәм турыдан-туры «Безнең бурычлар» дип исемләнгән мәкаләсе «Совет әдәбияты» журналының 1955 елгы март санында дөнья күрә.

Әдипләр корылтайда күтәрелгән төп мәсьәләләр белән генә чикләнми. Ә. Фәйзи алып барган көндәлектә матур әдәбиятка хезмәт иткән тәнкыйть спецификасы, тәнкыйтьче турында шундый уйланулар бар:

«18.1.55.

Матур әдәбиятның нечкәлекләрен (спецификасын) иң төшенгән кеше – язучы. Ул – иң яхшы литературовед, критик, эстетик.

Монда аңа язучылыгының субъектив сыйфатлары ярдәм итә. Ләкин шул ук субъектив сыйфатлар аны объектив бәяләүдән читкә өстерәп алып китүе мөмкин. Әйтик, Толстойның Шекспирны тәнкыйте. Шуңа күрә укучыга язучының субъектив фикерләрен объектив фикерләреннән аера белергә кирәк…»[1]

Н. Гыйззәтуллин, сугыштан соңгы әдәби хәрәкәттә тәнкыйтьтәге үзгәрешләрне шушы рәвешчә тасвирлады: «Илленче еллар уртасыннан башлап әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә, илнең иҗтимагый-политик тормышындагы үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, аерым язучылар иҗатын бәяләүдә дә, шулай ук әдәби процессны тулы итеп күзаллауда да догматизмнан котылырга омтылу, социологизм чиреннән арыну процессы ачык төс алды. Утызынчы еллар ахырында хаксыз рәвештә әдәбият тарихыннан сызып ташланган язучы һәм тәнкыйтьчеләрнең аклануы әдәбият галимнәренә зур мөмкинлекләр ачты. Татар совет әдәбияты тарихын бөтен тулылыгында өйрәнү, аның төрле этаплардагы үзенчәлекләрен, уңай һәм кимчелекле якларын дөрес бәяләү өчен мөмкинлекләр туды. Яңадан әдәбиятка кайткан язучыларның әсәрләре кабат басылып чыга башлады һәм язучыларга заман таләбе югарылыгыннан бәя бирүнең беренче тәҗрибәләре эшләнде»[2].

Илленче елларның беренче яртысында татар тәнкыйтендә ниндидер уңай күренешләр күзәтелсә дә, аның заман тормышын яктырткан, Яңаны төзүчене, совет иле патриотларына дан җырлаган әдәбиятны мактавы аркасында, сүз сәнгатенә күп кенә тарихи темалар үтми торды, бер ачыла башлаганнарыннан баш тартылды. Агымдагы әдәби процесс һаман да партия салган юлдан баруын дәвам итте, аның үсеше схематик һәм рус совет әдәбияты үсеше үрнәгендә булды, чөнки тәнкыйтьчеләр моның шулай булуы уңай дип санады. Зур күпчелек, партия рөхсәтен сиземләми торып, төрле карарлар чыгарылганчы я булмаса җитәкче постта утырган тәнкыйтьчеләр сүз алганчы, теге яки бу проблемаларны башлап күтәрергә җөрьәт итмәде, кайберәүләр хак фикерләрен дә төрле Пленум карарларыннан соң үзгәртте, чыгышларын аңлы рәвештә хакимият көткәнчә, җитәкчеләр теләгәнчә язды. Татар әдәби тәнкыйтендә рус тәнкыйтеннән күчеп утырган штамп фикерләргә өстенлек бирелде. Җанлы әдәби барышны гадел яктырту игелексез һәм автор шәхесен

[1] Фәйзи Ә. Көндәлек дәфтәреннән // Әдипнең эрудициясе. Б. 271.

[2] Гыйззәтуллин Н. Әдәбият белеме һәм тәнкыйть // Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр, 1989. Т. 5. Б. 485.

куркыныч астына куючы гамәл икәнлеген аңлап, кайберәүләр тәнкыйтьтән читләшә баруны яисә тәмам китүне һәм әдәбият тарихына мөнәсәбәтле хезмәтләр язуны хуп күрде. Әдәби тәнкыйтьнең нормативлыгы, аның өстеннән партия күзәтчелеге чын тәнкыйтьчегә ачылырга һәм үсәргә ирек бирмәвен дәвам итте.

### *2.4.2. Тоталитаризмнан соң әдәби тәнкыйть*

Советлар иле тарихында алтмышынчы – сиксәненче еллар – әдәби тормышның кызыклы, кискен үсеш-үзгәреш кичергән, әдәбиятка яңа көчләр килгән бер чоры иде. Әдәби барышның тизләнеш алуы, андагы яңа күренешләр бары тик Сталин культының фаш ителүе нәтиҗәсендә генә була алды. КПССның XX съездында Н.С. Хрущев «шәхес культы турында» ясаган чыгыш җәмгыятьнең, иң тәүдә алдынгы карашлы каләм ияләренең сәяси-иҗтимагый аңына нык тәэсир итте, күпләрнең моңа кадәр зынҗырлап тоткан фикерләренә тышка чыгу мөмкинлеге тудырды. Илдәге үзгәрешләр алай да зур авырлык белән – демократия тарафдарлары һәм тоталитар системаны саклау ягындагыларның кискен көрәше шартларында башланды. Эчке-тышкы сәясәттәге уңай пландагы хәрәкәтләр дә ул чакта инде массалар чын-чынлап кабул иткән, һичшиксез, җиңүләргә һәм бәхетле киләчәккә алып барачак дип ышанган коммунистик идеология кысаларында гына була ала иде.

Зур иҗтимагый вакыйгалар чорында илгә үзгәрешләр киләчәкне көткән, кайбер әсәрләре белән аңа хезмәт тә иткән алдынгы карашлы татар каләм ияләре шунда ук үз язганнарында социаль-сәяси яңгырашка, шәхес ирегенә һәм индивидуальлегенә; милли гореф-гадәтләрне яшәтү, татар авылын саклау һәм табигать экологиясе, төрле милләт-кавемнәрнең рухи бергәлеге, аралашу мәйданнарының киңәергә тиешлеге кебек проблемаларга игътибарны арттыра. Шул ук вакытта рус сүз сәнгатендә дә, аны үрнәккә куеп үскән башка әдәбиятларда да Көнбатышка дошманлыклы мөнәсәбәт йомшый төшә, әмма бөтенләй юкка чыкмый. «Җепшеклек» шартларында көнбатыш фәне совет әдәбият белеменә үз йогынтысын күпмедер көчәйтә, аның белән танышу мөмкинлекләре дә арта. Болар барысы сүз сәнгатенең алга таба үсешен кайгырткан тәнкыйтьнең эчтәлегендә ачык чагылыш таба. Татар совет тәнкыйте, коммунистик идеологиягә таянып, әмма моңа кадәр катгый куелган кысалардан күпмедер читкә чыгып, башкача уйлаучыларны аңларга һәм аларга үз фикерен нигезле җиткерергә, капиталистик илләрдә

көн күргән каләм ияләренең совет иленә, коммунистик идеологиягә мөнәсәбәтен үзгәртергә тырышып, социалистик илләр әдәбиятларын үз кысаларына тартып кертергә омтылып хәрәкәт итә башлый.

### *1956–1970*

Илленче – алтмышынчы елларда татар әдипләре зур игътибар белән рус әдәбияты һәм тәнкыйте алга таба нинди юнәлеш алыр дип күзәтә. Аларда исә И.В. Сталин вафатыннан соң узган тормышка һәм аны чагылдырган әдәбиятка, шул әдәбиятларны бәяләгән язмаларга тәнкыйди рухтагы яңача караш формалаша башлый, кайбер галимнәрнең вакытлы матбугатта әдәбият белән бюрократларча җитәкчелек итүгә каршы юнәлтелгән мәкаләләре дөнья күрә. Шул ук вакытта төрле зур җыелышлардагы һәм басмалардагы А. Караганов, В. Тендряков, И. Эренбург, В. Каверин, Т. Трифонова, Л. Чуковская, М. Алигер һәм башкаларның заманы өчен үтә кискен тоелган чыгышларын кабул итмәүчеләр, каршы җавап бирүчеләр дә табыла. Партиянең мәдәният өлкәсендәге сәясәтен тулаем кире кагу күзәтелми, аның бик күп күрсәтмәләре гамәлдән төшми, СССРда яшәгән каләм ияләренең Көнбатыш белән мәдәни көрәш фронты ябылмый.

Илленче елларның икенче яртысыннан илнең иҗтимагыйрухи шартлары язучыларга һәм аларның иҗатларын бәяләргә тиеш тәнкыйтьчеләргә моңа кадәр катгый билгеләнгән, норма дип кабул ителгән идея-эстетик кысалардан чыгу мөмкинлеге тугач, әдәбиятның үзенә дә, тәнкыйди хөкемгә дә яңа сулыш өрелгәч, милли зыялылар күңеленә күпмедер ирек хисе уза, татар каләм ияләрендә әдәбиятны үзләре теләгәнчә иҗат итәргә мөмкин булачак дигән өмет-хыял бөреләнә, әмма чынбарлык аларга тулысынча тормышка ашарлык шартлар барлыкка китерми.

Инде илленче еллар ахырында ук яңача рухтагы, чагыштырмача кыюрак фикерле, совет кешесе тормышындагы җитешсезлекләрне дә ачып салган әсәрләрне социалистик реализм методыннан китеп, тәнкыйди реализмга чигенеш дип атаулар; демократизм артык киң җәелә дип исәпләп, тәүге омтылышларны басма сүз ярдәмендә тәнкыйтькә алулар башлана. Бу азмы-күпме дәрәҗәдә татар әдәбиятында да күзәтелә. Гомумән алганда, әлеге эшкә иң элек, теләп, һәр коммунист алдырган һәм аның өстәл журналы саналган «Коммунист» журналы керешә («Партия и вопросы развития советской литературы и искусства»; «За ленинскую принципиальность литературы и искусства». 1957. № 3, 10). Сүз сәнгате көтелмәгән якка

борылыш алыр дип куркып калган җитәкчелек әлеге журналда мәдәниятны ленинчыл-коммунистик аңлау, иҗатның партиялелеге; язучының күзаллаулары нинди булырга тиешлек турында һәм башка сорауларга рәсми җавап рәвешендәге язмалар басылуны кайгырта.

И.В. Сталин вафатыннан соң КПСС ҮК тарафыннан узган чор тәнкыйтенең чикләнгәнлеге танылса да, 1956 елның 30 июнендә «О преодолении культа личности и его последствий» дип аталган һәм элек тәнкыйтькә алынган кайбер авторларны, әсәрләрне яклап язылган карарлар бастырылса да, бераздан Коммунистлар партиясе башында торган Н.С. Хрущев партия линиясенә каршы торучы «ревизионистлар»га каршы кискен көрәш уты ача һәм бу хакта ачыктан-ачык СССР язучыларының Өченче корылтаендагы чыгышында да белдерә.

Партия әдәбиятны һәм ничек кенә яңадан үз кулына ныклап алырга теләмәсен, талантлы һәм үзкарашлы каләм ияләре хөр фикерне яңадан кысаларга тартып кертү ягында тормый. Җитмәсә, аларның рәтләре исән калган һәм акланган әдипләр хисабына да ныгый. СССР язучылар оешмасы җитәкчелеге алмашыну, яңа төр әдәби-нәфис-иҗтимагый басмалар барлыкка килү һәм 1957 елдан «Вопросы литературы» исемендәге әдәбият белеменә, шул исәптән тәнкыйтькә кагылышлы мәкаләләр басуны алга куйган журналның чыга башлавы, беренче санында ук әдәби тәнкыйтьтәге нормативлыкка, ярлыклар табуга каршы юнәлтелгән декларация кабул итүе; яңа оешкан РСФСР язучылар берлегенең беренче съездында Л. Соболевның тәнкыйтьне үстерү, яңа әдәби продукцияне рецензияләү проблемаларын күтәргән чыгышы; ике унъеллык чигендә тәнкыйтьтәге торгынлыкны, «Октябрь», «Литературная Россия» басмаларында аның әдәбияттан артка кала башлавын раслаган язмалар һәм башка шул рухтагы күренешләр ахыр чиктә тәнкыйтьне дә азмы-күпме хәрәкәткә китерә.

Илленче еллар уртасыннан бигрәк тә Г. Тукай иҗаты ныклап өйрәнелә башлый. Г. Халитның «Габдулла Тукай һәм XX йөз башында татар әдәбияты хәрәкәте» (1956), И. Нуруллинның «Тукай эстетикасы» (1956), К. Насыйри, З. Һади, З. Бигиев һәм башкаларның иҗатын, тормыш юлын ачкан күпсанлы язмалар, китаплар татар тәнкыйте үсешен дә чагылдыралар дип карарга кирәк, чөнки аларда бәя узгандагы мираска, әдәби барышка, аерым кеше иҗатына заман биеклегеннән торып бирелә, күп кенә материаллар беренче мәртәбә гыйльми әйләнешкә кертелә.

Бу чорда Х. Хәйри, Г. Кашшаф, Х. Хисмәтуллин, Н. Гыйззәтуллин һәм башка әдәбиятчылар Һ. Такташ, М. Җәлил, Т. Гыйззәт, К. Нәҗми кебек классикларыбызның иҗатын өйрәнү һәм пропагандалау эше белән шөгыльләнә; язучылар тәнкыйте яңадан тернәкләнеп китә. Г. Бәширов, Г. Ахунов, Ә. Фәйзи, Ш. Мөдәррис һәм башкаларның мәкаләләре янәшәсендә яшь буын галимнәрнең – И. Ахунҗанов, Н. Юзиев, И. Надировларның язмалары да даими рәвештә басыла башлый.

Илленче еллар уртасыннан моңа кадәр иҗатлары ныклап өйрәнелмәгән яисә берьяклырак бәяләнгән, вульгар социологизм тарафдарлары пычагыннан киселгән авторларга яңа төр мөнәсәбәт калыплаша, әдәбиятка әйләнеп кайтучыларның әсәрләре басылу һәм инде тәнкыйть тарафыннан уңай бәяләнүләр күзәтелә. Басма мирасның сан ягыннан артуы, авторларның күбәеп китүе, милли стильнең баюы, әдәби иҗек төрлелеге сүз сәнгатендәге барышны тулырак, объективрак яктырту мөмкинлекләре тудыра, методлар һәм стиль мәсьәләләре турында сөйләшүләргә алып чыга. Ничәмә еллар фәнне объективлыктан читкә алып киткән вульгар социологизм калдыкларыннан арыну, кире кагылып килгән романтик методны өйрәнү һәм, шуңа бәйле рәвештә, әдипләр иҗатын методлар планында дөрес яктырту хәрәкәте яңадан җанлана. Бу эшләр барысы да югары сыйфатлы сәнгать әсәрләрендә тәрбияләнгән яшьләрнең күпләп мәйданга килүенә хезмәт итә.

Илленче еллар әдәби тәнкыйтендә яңа кеше турында башланган сөйләшүнең кайтавазлары соңрак та ишетелә, бигрәк тә әдипләрне күләмле әсәрләр язганда бу проблема хакында уйланырга мәҗбүр итә.Уңай герой темасы гына түгел, әдәбиятның заманчалыгы, анда күтәрелгән проблемаларның актуальлеге мәсьәләләре дә һәрвакыт тәнкыйтьнең игътибар үзәгендә тора. Татарстан язучыларының Дүртенче съезды (1958) шулай ук аларны мөһим проблемалар сыйфатында күтәрде. Соңрак Ф. Хөснинең корылтайда ясаган чыгышы «Литературная газета»да «Глубокое течение, или пузырьки на поверхности?» исеме астында русча дөнья күрде (1958. 4 июль) һәм башка милләт язучылары арасында да резонанс алды. СССР Язучылар союзының Өченче съездында шулай ук заманчалык һәм актуальлек мәсьәләсе үзәккә куелды.

Илленче еллар ахырында әдәбиятның тирәнлеге һәм югары сәнгатьчә эшләнеше өчен оешкан көрәш атмосферасы алтмышынчы елларга да уза. Каләм ияләре заманга лаек язу идеясен күтәреп

чыгалар, чор стиле турында сөйләшүләр башлана. Татарстан язучыларының Бишенче корылтаенда ясаган чыгышында Г. Халит борынгыдан килгән уңай традицияләрне дәвам итүнең – аз сүзле, әмма зур эчтәлекле, динамикага һәм психологизмга корылган әсәрләр язуының һаман да актуаль икәнлеген ачып бирә һәм яңа заман әдәбиятын үстерү дә шул юлдан барырга тиешлекне сөйли[1].

Р. Мостафин, М. Әмир һәм башка кайбер тәнкыйтьчеләр татар әдәбиятында искергән, бигрәк тә мәгърифәтчелек чорыннан килгән стилистик алымнарның әле дә яшәвенә игътибар итәләр һәм алардан инде котылу мөһимлеген әйтәләр, боларга кирәгеннән тыш детальләштерү, бүгенге көн укучысына ачык аңлаешлы әйберләрне дә шәрехләү кебек әдәби алымнарны, стиль үзенчәлекләрен кертәләр[2]. Заман стиле турында сүз алып барганда, тәнкыйтьчеләр аңа фикер тирәнлеге, тыгызлыгы, җыйнаклыгы, образ отышлылыгы, җиңел укылышлылык, буш фактлардан качу кебек сыйфатларга киң тукталалар.

Алтмышынчы еллардагы тәнкыйть язмаларында сүз логик эзлеклелек, вакыйга-күренешләрне социаль-тарихи мотивлаштыру, каһарманнарны социаль һәм психологик планда ачу, бигрәк тә күңел диалектикасына зур игътибар бирү, тасвир гүзәллеге, иллюстрацияләүдән һәм шаблонлыктан качу һәм башкалар турында бара. Шулай ук фикерне кыска, отышлы, тирән әйтүне яклаган И. Нуруллин хезмәтләрендә әдәби әсәрләрдә куелган проблемаларның зурлыгы, характерларның өлгергәнлеге, дөрес сайланган тормыш материалы һәм башка проблемалар күтәрелә[3]. Кыскасы, алтмышынчы еллар башында татар тәнкыйтьчеләре сүз сәнгатебездә форма камиллеге, фикер тирәнлеге, тәэсирлелек, образлылык кебек һәм формага, һәм эчтәлеккә караган күренешләр турында сүз йөртәләр. Тиздән аның нәтиҗәсе дә күренә. Әдәбиятка алтмышынчы еллар уртасыннан фикерен тыгыз, метафоралар ярдәмендә һәм үзенчәлекле калыпларда, оригиналь әйтә алган яшьләр зур дулкын булып бәреп керә.

Алтмышынчы елларга хас «Җепшеклек чоры»ның рухы, шуның тәэсирендә кискен үсеш алган рус әдәбияты, бигрәк тә поэзиясе

---

[1] Халит Г. Әдәби тәнкыйтебез киң колачлы һәм кыю булырга тиеш // Совет әдәбияты. 1963. № 4. Б. 147.

[2] Мостафин Р. Бүгенге романнарны укыганда // Совет әдәбияты. 1960. № 7; Әмир М. Заманга хас стиль // Соц. Татарстан. 1962. 16 июль.

[3] Нуруллин И. Кыскалык турында // Совет әдәбияты. 1963. № 6. Б. 128.

татар сүз сәнгатенә шулай ук эз сала. Үзенчәлекле яшь иҗатчыларының каләме формалашуга яңача фикерләүче, заманга төс язучыларның тәүгесе булган Роберт Әхмәтҗанов иҗаты аеруча зур йогынты ясый. Андагы яңалыкка баштарак тиеш дәрәҗәдә игътибар итмәгән татар тәнкыйте инде алтмышынчы елларда әдәбиятка килгән бер төркем шагыйрьләрдәге үзенчәлекләрне тиз тотып ала һәм бәхәскә дә керешә. Әлеге бәхәсләр бигрәк тә Равил Фәйзуллин иҗатына бәйле кыза һәм башта шагыйрьләрнең үз эчендә генә бара.

Гомер бакый традициялелекне алга сөргән көнчыгыш сүз сәнгатенең бер өлеше булган татар әдәбиятында заманга лаек фикер әйтергә мөмкинлек биргән формалар эзләү белән мавыгуга мөнәсәбәт бераздан вакытлы матбугат битләрендә дә чагыла башлый. Иң тәүдә Рөстәм Кутуй «Что называть поэзией?»[1] язмасында татар шигъриятендәге шаблонлыкка, бертөслелеккә каршы чыга һәм Р. Фәйзуллиннар буынының үзенчәлекле иҗат итүләрен талант билгесе буларак ача, каләм иясенең, милли традицияләрдән тыш, дөньяви традицияләрне дә белергә тиешлеген әйтә.

Ф. Хөснинең РСФСР язучыларының Икенче съездын каршылау уңаеннан, «Литературная Россия» газетасының 1965 ел 1 гыйнвар санында бастырган «Что называть поэзией?» мәкаләсе Р. Кутуйга җавап сүзе кебегрәк тә яңгырый. Ул анда Р. Фәйзуллинның зур талант икәнлеген таный, әмма узгандагы тәҗрибәләр белән дә санлашырга чакыра.

«Татарстан яшьләре» газетасының 1966 ел, 17 декабрь санында Зәки Нуриның «Яшьләргә – яшел урам» язмасы дөнья күрә. Ул исә яшь каләм ияләренең заман үзгәрешләрен яхшы тоюын, әдәби традицияләрне дә исәпкә алуын, шул ук вакытта яңачалык принциплары белән дә эш итүләрен ача, Р. Фәйзуллин иҗатын уңай планда бәяли.

Бәхәскә күпсанлы язучылар тартыла. Шуның тәэсирендә, ягъни татар шигъриятендә күзгә ташланырлык үзгәрешләр булганга һәм тәнкыйть шуңа карата саллы фикерен әйтергә тиешлектән, 1966 елда «Социалистик Татарстан» газетасында «Г. Тукай, М. Җәлил традицияләре һәм хәзерге татар поэзиясе» дигән темага дискуссия оештырыла. Бәхәс дәвамлы, җитди рәвештә бара, аңа Х. Госман, И. Нуруллин һәм башка зур галимнәр, хәтта Н. Фәттах кебек прозаиклар да катнаша.

[1] Кутуй Р. Что называть поэзией? // Лит. газета. 1964. 3 дек..

Х. Госман «Ачыклык кертәсе бар»[1] язмасында әдәбиятта инде урын тоткан, борынгыдан килгән ак һәм ирекле шигырьне үстерергә, баетырга кирәк дигән карашны яклый. Дөрес, ул шигырьнең электән урнашкан традицион системасыннан качкан шагыйрьләрнең язганнарын озын гомерле дип уйламый. Шул ук вакытта Х. Госман Р. Фәйзуллин иҗатының кызыклыгын форма яңалыгы белән генә бәйләп карамый. Галим аның аерым әсәрләренә хас җитешсезлекләрне дә күрсәтә, шигырьләренең кайберләрен тормыштан уңышлы эләктереп алынган детальләр, сурәтләр рәтенә генә кертә. Х. Госман фикеренчә, Р. Фәйзуллин әсәрләре арасында гомумән төшенеп булмый торганнары байтак. Әлеге күләмле хезмәттә галим тәнкыйть объектына компекслы якын килә, аерым бер иҗатка бәйле рәвештә, әдәбият барышына, нәфис текстларның сәнгатилегенә, иҗат лабораториясенә кагылышлы бик күп проблемалар хакында фикер йөртә.

Кызганнан кыза барган бәхәстә Флүн Мусин «Аларга турылыклымы без?» (1965. 26 сент.) дип исемләнгән мәкалә белән катнаша һәм яшьләрнең әдәбият өлкәсендәге эзләнүләрен уңай бәяли. Ул үз язмасында Ф. Яруллин, Р. Әхмәтҗанов кебек каләм осталарының уңышларын билгеләп уза. Р. Фәйзуллин иҗатындагы уңай яклардан тыш, аерым әсәрләрендә «сурәтләнүче вакыйга һәм факт турында артык абстракт фикер йөртү, вак кына нәрсәдән дә зур фәлсәфә чыгарырга тырышу, көтелмәгән шигъри борылышлар белән мавыгу, поэтик фикерне ачык һәм гади итеп чагылдыруга игътибар бирмәү»не дә күрсәтә.

Ф. Мусин, әдәби традицияләрне саклау, үстерү белән беррәттән, форма эзләнүләре, заман фикерләрен аңа хас калыпларда бирү омтылышы да яшәргә тиеш, дигән караштa тора, моның әдәбиятны шаблонлык, схемачылык кебек күренешләрдән саклауга хезмәт иткәнен әйтә. М. Бакиров Р. Фәйзуллин иҗатында татар шигъриятендә электән килгән образлар системасының тагын да баюын, сүзнең яңа мәгънә киңлекләре алуын, көтелмәгәнчә яңгырашны һәм башка уңай сыйфатларын күреп ала[2].

Дискуссиягә галимнәрдән – Р. Мостафин, З. Мәҗитов, М. Мәһдиевләр, ә татар шагыйрьләреннән И. Юзиев, Ә. Давыдов һәм баш-

---

[1] Госман Х. Ачыклык кертәсе бар // Соц. Татарстан. 1965. 31 дек.

[2] Бакиров М. Поэзиябезнең тәмен тирән тоябызмы? // Соц. Татарстан. 1966. 10 июль.

калар тартыла. Торгынлык чорында барган бәхәсләр арасында Тукай һәм Җәлилләрдән килгән традицияләр турында сөйләшү – иң кызыклысы, иң ихласы, иң нәтиҗәлесе һәм әдәби барышыбызда моннан соң бервакытта да кабатланмаганы. Ул татар тәнкыйтенә рух өргәндәй була, аны объективлыкка чакыра, шул ук вакытта карашлар төрлелегенә дә урын бирә. Ул рус матбугаты битләренә дә чыга, авазы хәтта аннан еракларга да ишетелә.

Шул чорда фәнгә яңа гына аяк баскан галим Мөхәммәт Мәһдиевнең «Яшь шагыйрьләрне укыгач…»[1] язмасы әлеге бәхәсләргә бер нәтиҗә ясап куйгандай була, чөнки анда аңа кадәр язылган мәкаләләргә дә мөнәсәбәт белдерелә. Ул яшь шагыйрь иҗатына кирәгеннән артык игътибар бирүнең талантны юкка чыгарырга, бозарга мөмкинлеген, тәнкыйтьнең поляр карашларга нигезләнгәнен күрә.

Зәет Мәҗитовның бәхәсләр бераз тынганнан соң язылган «Хәере белән үссеннәр» күзәтүендә дә Равил Фәйзуллин иҗатына һәм аның, яшьләр поэзиясе тирәсендә барган бәхәсләргә мөнәсәбәт чагылыш таба. Галим шагыйрь язганнарның һәм уңышларын, һәм җитешсезлекләрен отышлы тотып ала, «Нюанслар иле»нә тәнкыйтьнең гаделлеген әйтә. З. Мәҗитов әлеге циклга хас җитешсезлекләрне Р. Фәйзуллинның куе сурәтле буяулар белән артык мавыгуында, шул сәбәпле фикернең, эчтәлекнең укучыга ачык ирешмәвендә күрә. Тәнкыйтьче: «…циклда уңышлы тотып алынган шигъри детальләр дә булуын әйтми китәргә ярамый»[2],– дип белдерә, гади генә детальдә шигърият табарга омтылуны Р. Фәйзуллин каләменә хас үзенчәлек дигән караштa тора.

Совет системасы шартларында хәтта җепшек чорларында да һәр халыкның тәнкыйте, әдәбият теориясенең үсеше, сүз сәнгате тарихын язу рус әдәбият гыйлеме тармакларыныкы белән тыгыз бәйләнештә генә бара. Бу коммунистик партиялелекне, идеялелекне алга куйган һәм фирка күзәтүе астында үскән гуманитар фәннәрдә башкача була да алмады. Уртак мәгариф, гомуми белем системасы, гыйльми эшчәнлекнең дәүләт планы рәвешендә үсеше, аның күзәтчелеге астында алып барылуы һәм башка бик күп шартлар шуңа хезмәт итә. Ахыр чиктә, зур күпчелек моны табигый

[1] Мәһдиев М. Яшь шагыйрьләрне укыгач… // Соц. Татарстан. 1966. 18 сент.

[2] Мәҗитов З. Хәерләре белән үссеннәр // Казан утлары. 1967. № 1. 121 б.

бер хәл рәвешендә кабул итә башлады, әмма аның бигрәк тә милли әдәбиятларга, фәнни ачышларын милли телдә чагылдырырга омтылучыларга зыяны бихисап зур иде. Әйтик, Рәсәй Федерациясендә яшәгән күпсанлы халыклар өчен гыйльми казанышлар уртак булганлыктан, татарча фәнни терминнар ясалу тулысынча тукталды, гарәп-фарсы алынмаларын массалар аңламый башлады, шунлыктан рус теле аша кергән терминологиягә мәйдан киңәйде. Чынлап караганда, бүгенгәчә татар телендә «Әдәби тәнкыйть теориясе» дип аталган махсус хезмәт язылмавы да аңа ихтыяҗны русча китаплар ярдәмендә канәгатьләндерү аркасында да булды.

Әдәбиятның, аңа хезмәт иткән фәннәрнең үсешендәге торгынлык яисә тизләнеш һәм артка чигенешләр әдәби хәрәкәт өстеннән контроль дәрәҗәсен ачык күрсәтеп тора. СССР Брежнев этабына килеп кергәч, Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә сүз сәнгате белән идарә итү омтылышы яңадан көчәя башлый. Алар тарафыннан махсус оештырылган рәсми пропаганда, мөһим карарлар, төрле югарылыктагы җыелышлар, ахыр чиктә корылтайлар язучыларның һаман да социализмны дөньядагы иң алдынгы һәм гадел, бар халыкны кайгырткан, хезмәт кешесенеке булган иҗтимагый система итеп күрсәтергә бурычлы икәнлеген раслый, моны ил уңышлары, нык үскән социализмның тормышка ашуы белән дәлилләргә тырыша. Ул бурыч тәнкыйтьчеләргә бөтен җаваплылыгы белән йөкләнә.

Әдәби хәрәкәт өстеннән партия җитәкчелеге СССР язучыларының берлеге һәм милли оешмалар аша тормышка ашырыла, аларның башына шулай ук партияле кешеләр генә куела. Өстән төшкән күрсәтмәләргә ияреп, тәнкыйть тә хезмәт-производство темасын ачкан, ил хуҗалыгының реаль предприятиеләрендәге, авыллардагы тормышны, уңыш өчен көрәшләрне тасвирлаган әсәрләрне мактый, әдипләрне шулар хакында язарга әйди башлый. Әдәби тәнкыйть каләм ияләре игътибарын милләтара дуслык, тынычлык темаларына, яңаны төзүче хезмәт кешесенә юнәлтә, производство алдынгыларын, коммунистларның уңай образларын тасвирларга әйди. Шул рухта язылган әсәрләргә Үзгәртеп кору елларына кергәч мөнәсәбәт үзгәрү исә татар әдәбиятында хезмәт кешесен ачкан, хезмәтне зурлаган әсәрләрне юкка чыгарды, аны тематик тарайтып җибәрде сыман.

Торгынлык елларында тәнкыйтьнең русча терминологик аппараты үсә, заман әдәбиятын узгандагы мирас җирлегендә бәяләү мөмкинлекләре арта, чөнки әдәбият белеменең башка тармакларындагы алга китеш аңа да тәэсир итми калмый. Татарстанда бөтенсоюз

һәм бөтенроссия фәнни конференцияләр узу, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Җәлил кебек дөньякүләм билгеле шәхесләрнең юбилейларын зурлап уздыру, аларның вакытлы матбугатта яктыртылышы, чыгышларның төрле басмаларда урын алуы да әдәби тәнкыйть үсешенә этәргеч фактор булып тора.

Язучыларның даими җыелган корылтайларында әдәбиятка һәм тәнкыйтькә үсеш юллары сызып күрсәтелү инде бер традициягә әйләнә. Бу чорда тәнкыйтьчеләр заман әдәбиятының тормышчанлыгы, сәнгати осталык, традиция һәм новаторлык, уңай герой, әсәрнең конфликтлылыгы һ.б. мәсьәләләр күтәреп чыгалар, вакытлы матбугатны шул темалар тирәсендә оешкан бәхәс мәйданына әверелдерәләр. 1964 елдан алып Татарстан язучылары берлегенең әдәби ел йомгакларына хисап җыелышлар үткәрелә башлау исә агымдагы хәрәкәтне тизләтүгә, җитешсезлекләрен һәм уңышларын үз вакытында билгеләүгә хезмәт итә, әдәби тәнкыйтьнең күзәтү тибындагы, аналитик язмаларының үсешенә китерә.

Татар язучылары тарафыннан да әдәбиятының аерым жанрлары торышын махсус тикшерүләр оештырыла, әдәбиятны төрле яктан үстерү проблемасы, корылтайдан тыш, партия җыелышларында, иҗат союзларының пленумнарында карала. Бу юнәлештәге эшләр бигрәк тә алтмышынчы, аннан инде җитмешенче елларда актив алып барыла. Вакытлы матбугат органнары тәнкыйть материалларын хәзерләүгә һәм бастыруга да зур игътибар бирә. «Социалистик Татарстан»да 1962 елдан соң әдәбият-сәнгать сәхифәсе ачыла, анда, алда телгә алынган Г. Тукай, М. Җәлил традицияләренә мөнәсәбәтлесеннән тыш та (1965 ел), татар драматургиясе һәм театры (1961 ел), татар прозасы (1962 ел), һ.б. турында дәвамлы, кызыклы һәм әдәби барышка сизелерлек тәэсир ясаган дискуссияләр үтә.

### *1971–1990*

Җитмешенче еллардагы фәнни эстетик фикер үсеше әдәби тәнкыйтьнең таяныч нокталарын ныгыта, анда язучыларга сәнгати таләпләр ныграк куела башлый. Әдәби тәнкыйтьтә һөнәрилек, объективлык көчәю аңа үзләре язучы булган яисә кайчандыр каләм сынаган зур шәхесләрнең хезмәт итүе белән дә бәйле. Бу чорда иң элек үзләрен шигърияттә яисә прозада сынаган Х. Госман, И. Нуруллин, М. Мәһдиев, М. Бакиров, З. Мәҗитов, Н. Хисамов һәм башка күпсанлы галимнәр каләме белән әдәбият белеменең тәнкыйтькә тәэсире көчәйтелә.

Вакытлы матбугатта укучылар фикеренә игътибар арта. Еш кына аларның хатларыннан өзекләр, укучы рецензияләре дөнья күрә. Язучыларның, шул исәптән тәнкыйтьчеләрнең укучылар аудиториясе белән очрашулары даими төс ала. Әлеге очрашуларда тәнкыйть һәм әдәбият мөнәсәбәте, тәнкыйтьнең уңышлы һәм җитешсез әсәрләрне күрсәтеп бирергә, аңлатырга тиешлеге кебек проблемалар күтәрелә.

1972 елда КПСС ҮК «О литературно-художественной критике» исемле карар чыгара. Шуның нәтиҗәсендә, СССР язучылар берлеге һөнәри тәнкыйтьчеләр хәзерләү эше белән махсус шөгыльләнә башлый, Әдәби институтка (Литературный институт) төрле өлкәләрдән студентлар, тыңлаучылар китертүне кайгырта; көн кадагына әдәби тәнкыйть буенча төрле семинарлар уздыру, югары уку йортлары программаларына «Рус совет тәнкыйте тарихы» дип исемләнгән курс кертү мәсьәләсе куела.

1976 елдагы «О работе с творческой молодежью» карары исә әдәбиятка яшь талантларны тарта, аларны иҗатка хәзерләү проблемасын күтәрә. Әлеге карар нәтиҗәсендә, 1978 елда «Литературная учеба» исемле журнал яңадан торгызыла, һәм ул үз битләрендә башлап язучыларның әсәрләрен, алар янәшәсендә шуларны бәяләгән, анализлаган язмаларны бирү эшенә керешә.

Алтмышынчы елларда Татарстан язучылар оешмасы да әдәби алмаш тәрбияләү проблемасы белән махсус шөгыльләнә башлый, ә җитмешенче елларда бу эш тагын да ныграк җәелдерелә. Яшь каләм тибрәтүчеләрнең район, региональ һәм республика конференцияләре даими уздырыла, һәрбер иҗат секцияләрендә язганнарын тикшерүләр, уңай бәяләнгән хезмәтләрне басмага тәкъдим итүләр, яшь авторларны матбугатта пропагандалаулар татар әдәбиятын үстерүдә, яңа көчләр белән баетуда зур эш башкара, һәм аңа тәнкыйтьчеләр дә актив тартыла.

Сиксәненче елларда рус тәнкыйтендә әдәби барышны тасвирлаган мәкаләләр арта, сәнгати ел нәтиҗәләрен чагылдыру активлаша, әдәбиятның киләчәген фаразлау күзәтелә. Татар тәнкыйтендә бу төр хезмәтләрнең кызыклылары дип Ф. Миңнуллин каләменнән төшкән шул эчтәлектәге язмаларны атарга булыр иде. Ул роман, повесть кебек жанрларның алга таба татар прозасында тотачак урынын, сан-сыйфат үзгәрешләрен фаразларга омтылыш ясый.

Башка каләм ияләре дә әдәбиятның киләчәгенә кагылышлы фикерләре белән уртаклаша. Мәсәлән, М. Мәһдиев алга таба

реалистик эчтәлекле, вакыйга-күренешләре тормышның үзеннән алынган урта күләмдәге әсәрләр күбрәк язылыр, чөнки укучылар андый иҗатка ныграк тартылыр, дигән карашта тора. Әдип әлеге фикерне үз прозасында да уздыра. Ул «Бәхилләшү» повестена Л. Н. Толстойдан эпиграф итеп алган «Миңа калса, заманнар узу белән, язучылар әдәби әсәр уйлап чыгарудан гомумән туктарлар кебек… Язучылар, әгәр инде алар булсалар, уйлап чыгарып язмаслар, бәлки тормышта үзләре күзәткән, әһәмиятле яисә кызыклы нәрсәләр турында гына сөйләрләр»[1],– сүзләре дә шул хакта сөйли.

М. Мәһдиевнең «Бәхилләшү»гә куйган икенче эпиграфы – М.Ю. Лермонтовның «Безнең заман герое»ннан. Әлеге өзек әдипнең иҗатка материал сыйфатында тормыштан кеше аңына тәэсир иттерерлек гыйбрәтле вакыйгалар сайларга кирәклеген, әдәбиятның төп функциясе хакыйкать аша тәрбия бирү икәнлеген ассызыклый: «Бәлки, сез, «әхлакка моннан ни файда», диярсез. Гафу итегез – кешеләргә татлы әйберләрне җитәрлек ашаттык, моңардан аларның ашказаннары бозылды; ачы дарулар, яндыра торган хакыйкатьләр кирәк».

Җитмешенче еллардан башлап, илдә урнашкан тынычлык һәм гади кешенең матди тормышын чагыштырмача бөтенәйткән хезмәт рухы шартларында, чыннан да, әдәбиятта совет кешесенең әхлагы турында язулар калкулана, тәнкыйть тә каләм ияләренең игътибарын шуңа юнәлтергә тырыша. Һәркемгә таныш гадәти тормышны чагылдырган әсәрләр, хезмәт геройларын, романтикасы белән алгысытып торган төзелешләрне чагылдырган проза, тәнкыйть тырышлыгы белән дә, укучыга бермә-бер якыная.

Җитмешенче-сиксәненче елларда рус тәнкыйте төп игътибарын дөнья әдәби барышы, авыл прозасы, хәрби проза үсеше, поэзия һәм дараматургиядәге яңалыклар, аларның үсеш перспективалары кебек мәсьәләләргә юнәлтә. Бүгенге әдәбиятчылар аларда проблемалар ахыргача хәл ителмәде, галимнәр һәм язучылар аларга бәйле бәхәсләргә теләп катнашмады, күбесе ясалма рәвештә, мәҗбүриятән оештырылган иде дигән караште тора. Гомуми әдәби барышка, жанрларга бәйле дискуссияләрнең озак бармавы, чынлыкта да, бу фикердә өлешчә хаклык барлыгын күрсәтә. Әлеге дискуссияләр татар галимнәре тарафыннан игътибарга алынса да, әдәбиятыбызга күпмедер тәэсире булса да, җирле матбугатыбызда шулай ук кайнар

[1] Мәһдиев М. Бәхилләшү // Мәһдиев М. Сайланма әсәрләр: 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Т. 3: Повестьлар, роман. Б. 3

бәхәс рәвешендә кабынып китми. Дөрес, «Казан утлары» журналы, алар тәэсирендә дә, заман татар прозасы (1972–1973), поэзиясе (1979), тәрҗемә (1986) һәм башка мәсьәләләргә багышланган тирән эчтәлекле сөйләшүләр оештыра.

«Социалистик Татарстан» газетасында шулай ук әдәбиятка мөнәсәбәтле зур чаралар яктыртыла, төрле дәрәҗәдәге җыелышлар алдыннан сөйләшүләр уздырыла, танылган тәнкыйтьчеләргә фикер әйтергә мәйдан бирелә. Ул, мәсәлән, укучыларны алдагы унъеллыкта күтәрелгән проблемаларга яңадан алып кайта. Татарстан язучыларының Тугызынчы съезды алдыннан (1979) «Бүгенге татар әдәбиятында заманчалык» дигән темага дискуссия оештырып җибәрә. Бу төр сөйләшүләр татар әдәби тәнкыйтендә бәхәс рухын күпмедер үстерә, аналитик характердагы һәм фәнни нигезле күләмле язмаларга туугa сәбәп була.

«Социалистик Татарстан» газетасы оештырган сөйләшү дә «Литературная газета» һәм башка рус матбугаты битләрендә барган бәхәскә кайтаваз рәвешендә барлыкка килә. Алдагы унъеллыкта русларда да, татарларда да «физиклар» һәм «лириклар» бәхәсе куерып алган була. Аннан соң да дәвам иткән бәхәстә стиль мәсьәләләре дә калкулана. Җитмешенче еллардагы сөйләшүләр барышында да сәнгати стильнең заманчалыгы алгырак планга чыга, чор алгарышының, бигрәк тә фән-техника яңалыкларының нәфис әдәбиятка тәэсир итүе һәм аның әдәби иҗектә дә чагылырга тиешлеге турында сүз бара. Дискуссия әдәбиятның сыйфат үсешен кайгырту рухында була. Әлеге бәхәс тамырларының, чит тәэсирләргә генә бәйле булмыйча, алтмышынчы еллар башында татар матбугатындагы «заманчалык» турында сөйләшүләргә дә тоташканлыгын онытмаска кирәк.

Кызганыч ки, әдәби барышта уңай күренешләр күп булса да, гомумән алганда, җитмешенче елларда әдәбиятта яңадан рәсми күзаллауларны канунилаштыру, аерым темалардан качарга тырышу, мактау рухында язу күзәтелә. Бу чор совет тәнкыйтендә, шул исәптән татарныкында да, уңай рецензияләр алгы планга чыга, шаблонлаша, жанрлар стандартлаша башлый. Рус телле матбугатта әдәбиятка, бигрәк тә башка милләтләр телендә язылган әсәрләргә игътибар кими, читтә яшәүчеләрне әдәби тәнкыйть проблемалары тирәсендә оешкан зур сөйләшүләргә тарту туктала. Әдәби тәнкыйтьнең пропаганда вазифасына, теориясенә, «буржуаз методология»гә каршы торырга тиешле эш алымнарына партия игътибары арта. Фәнни хезмәтләрдә партия материалларына, коммунистлар-

ның язмаларына таяну һәм аларны махсус күрсәтеп узу мәҗбүри һәм катгый рәвештә куела.

Торгынлык еллары татар әдәби тәнкыйте татар шигъриятен, прозасын һәм драматургиясен зур совет әдәбиятының бер өлеше итеп күрә һәм күрсәтергә тырыша. Ул заман әдәбиятының спецификасын чор һәм гомуммәдәният үсеше белән бәйләнештә аңлый. Мөмкин һәм көтелгән үсеш үк күзәтелмәсә дә, укучыларның китап яратуы, күп укуы, аларга таләпчән якын килүе аркасында, алтмышынчы еллар башында югары сәнгатилеккә булган омтылыш каләм ияләрендә сиксәненче еллар башында да сүрелми. Әдәбият үзе дә, аны ачкан һәм пропагандалаган тәнкыйтьчеләр дә күбрәк әхлакый проблемаларны калкыта.

Бу чор әдәбият белемендә әдәбият тарихын тулы, объектив яктырту көн кадагына бөтен кискенлеге белән килеп баса. Татар галимнәренең төрле яшьтәге буыннарын үз эченә алган зур төркеме оеша. Югары уку йортларында әдәбият белеменә нисбәтле фәннәрне торган саен тирәнрәк өйрәнү-өйрәтү эше җайга салына, ТӘһСИ фәнни хезмәткәрләренең эшчәнлеге нәтиҗәсендә, «Татар әдәбияты тарихы»ның алты томлыгы дөнья күрә.

Бигрәк тә җитмешенче елларда урта гасырлар әдәбиятын өйрәнү көчәеп китә. Г. Таһирҗановның «Тарихтан – әдәбиятка» хезмәтендә аны укытуның кайбер проблемалары күтәрелә, «Урта гасыр әдәбияты тарихыннан» исемле коллектив хезмәт дөнья күрә (1981). XIX гасырдагы, XIX – XX йөз чигендәге әдәбиятны өйрәнү юлында М. Гайнуллин зур эшләр башкара. Ул «Татар әдәбияты. XIX йөз» (1968) хезмәтен 1975 елда рус телендә чыгара. 1978 елда аның «Татар әдипләре» җыентыгы дөнья күрә. И. Нуруллин, Г. Халит, Х. Миңнегулов, Ш. Садретдинов, кебек зур галимнәр дә узгандагы мирасны барлау, анализлау, әдәби барыш рәвешендә чагылдыру белән шөгыльләнә. Егерменче-утызынчы еллардагы әдәби хәрәкәтне өйрәнүгә Г. Халит, Х. Госман, А. Әхмәдуллин, М. Хәсәнов, Т. Галиуллиннар да зур көч куя. Һәм бер-бер артлы дөнья күргән фәнни хезмәтләр белән танышу татар тәнкыйтьчеләренә хәзерлек мәктәбе узу да була.

Н. Юзиев, З. Мәҗитов, Н. Ханзафаров, Ф. Ибраһимова, З. Рәмиев, Н. Гыйззәтуллин, А. Әхмәдуллин һәм башка галимнәр әдәбият тарихын, аның хәзерге барышын ныклап яктырту эшенә керешә, Ф. Миңнуллин, Т. Галиуллин, Р. Сверигин, Ф. Хатипов, Мөд. Вәлиев, М. Вәлиев, Р. Мостафин һәм башка күпсанлы һөнәри тәнкыйтьчеләр вакытлы матбугатта даими рәвештә аерым әсәрләргә бәя

биргән рецензияләр, теге яки бу иҗатны киң планда ачкан аналитик мәкаләләр белән чыгыш ясый.

Торгынлык еллары тәнкыйте шулай ук язучылар тәнкыйтенең активлашуы, С. Хәким, Х. Сарьян, Ә. Еники, Г. Ахунов һәм башкаларның әдәби тәнкыйть тарихында аерым эз калдырган, соңрак фәнни хезмәтләрнең әйләнешенә кертелгән иҗат портретлары, аерым әсәрләргә рецензияләр, теге яки бу әдәби проблемаларга кагылып узган эсселар белән истә кала. Бу чорда, татар әдәбияты тарихын яктырту гына түгел, тәнкыйтен үстерү дә фәнни-тикшеренү институтларының, югары уку йортларының, Татарстан язучылар оешмасының планлы эше рәвешендә алып барыла.

Даими рәвештә региональ, бөтенсоюз күләмендә оештырылган фәнни конференцияләрдә татар әдәбият белеменең актуаль мәсьәләләре һәрвакыт үзәккә куела. Й. Нигъмәтуллина, Н. Юзиев, Р. Ганиева, Ш. Абилов, А. Яхин һәм башкалар, сүз сәнгатен өйрәнү методологиясе проблемаларын чишү максатыннан, төрле эчтәлектәге фәнни эзләнүләр алып баралар, теге яки бу дәвер яисә халыклар әдәбиятын нәрсәгә нигезләнеп яктыртуның отышлыгы турында уйланалар.

Сиксәненче елларда Татарстан язучыларының төрле югарылыктагы җыелышларында ясалган докладларда, конференцияләрдәге чыгышларда һәм күзәтү мәкаләләрендә, аналитик очеркларда татар әдәбиятының аерым жанрлары үсеше, татар әдәби хәрәкәтенең гомуми хәле, нигездә, уңай планда ачыла. Әдәбиятта тиз арада хәл ителергә тиешле проблемалар булса да, алар калку куелмый. Гомумән алганда, галимнәр аны заманга лаек үсештә кебек күрсәтә. Әкренләп тәнкыйтьнең көрәшче рухы сүрелә, бәхәсле дискуссияләр кабынмый, татар тәнкыйте әдәбиятны уңай планда гына яктырту, мактау юнәлешен ала. Бу аның, ил кебек үк, кризиска керүен һәм чыгарга юллар эзләргә тиешлеген сөйли.

Тарихка Үзгәртеп кору исеме белән кереп калган һәм идеологиядә, икътисадта, сәясәттә зур үзгәрешләр алып килгән чор 1985 еллардан башлана һәм 1991 елларгача дәвам итә дип санала. Бу чорда илкүләм алып барылган реформаларның максаты СССРдагы иҗтимагый-сәяси һәм икътисади стройны һәр яктан демократияләштереп, социалистик системаны саклап калу була. Аның икътисади планын 1983–1984 елларда КПСС ҮКның генераль секретаре вазифаларын башкарган Ю.В. Андропов эшләтә, әмма икътисади тизләнешкә курс алуны 1985 елның 23 апрелендә Партия пленумында М.С. Горбачев игълан итә. Ул шул елның 11 мартында

властька килә. 1985–1986 елларда Брежнев чорыннан калган иске кадрларны яңаларына алмаштыру башлана. Яңа идарәчелек илне сәяси-икътисади, идеологик кризистан чыгару юллары турында уйлана, һәм, нәтиҗәдә, 1986 елның февраль-март айларында барган XXVII съездында Коммунистлар партиясе «социализмны камилләштерү» курсын игълан итә.

Бөтен илне тамырдан яңача кору, хөкүмәтнең эчке һәм тышкы сәясәтенә дә үзгәреш кертү исә 1987 елның гыйнварыннан башлана. КПСС ҮК пленумында бу юлы үзгәртеп кору дәүләтнең яңа идеологиясе дип белдерелә. Сүз иреге, хәбәрдарлык кебек күренешләргә юл ачкан бу еллар әдәбиятка һәм аны яктырткан тәнкыйтькә дә зур үзгәрешләр алып килә. Аның беренче чалымнары 1986 еллар ахырыннан тоемлана башлый. Вакытлы матбугатта кыю фикерле язмалар арта, әдәбиятка һәм гуманитар фәннәрне үстерүгә игътибар көчәя; СССР Язучылар берлегендә, башка төр оешмаларда, журнал һәм газета редакцияләрендә җитәкчелек алмашына, җитәкчелекне коллектив тарафыннан сайлап кую хәрәкәтләре башлана, каләм ияләре иҗтимагый тормышта активлыгын арттыра һ.б.

Үзгәртеп кору елларында татар әдәби җәмәгатьчелегендә билгеле бер җанланыш сизелсә дә, тәнкыйть кискен үсеп китә дип булмый, әмма аның тәүге карлыгачлары инде үзләренең авазын сала. Татарстан Язучыларының 1989 елгы корылтаенда Ә. Еники, Р. Харис, Ф. Миңнуллин кебек татар әдәбиятының авангардында баручы каләм ияләре ясаган чыгышларда матур әдәбият торышыннан канәгатьсезлек сизелә. Шушы төр карашлар язучылар арасында да хөкем сөрә, ел йомгакларында бигрәк тә реплика рәвешендә әледән әле әйтелә, кыска чыгышларда, янәшә докладларда чагылыш таба, вакыт-вакыт газета-журнал битләрендә дә яңгырап ала. Шуңа да карамастан, корылтайда Т. Галиуллин татар әдәбиятының заман хәлен уңай бәяли, ә тәнкыйтенең үсештә икәнлеген сөйли. Аның уңай сыйфатлары итеп, әдәби барыштагы төп үзенчәлекләрне билгеләвен, әдәби күренешләрне чынбарлыкка тыгыз бәйләвен атый. Бу төр каршылыклы фикерләр яшәү күчеш чоры өчен табигый була. Сүз иреге, хәбәрдарлык игълан ителсә дә, бик күпләр көтү, сүз әйтүдән качу халәтендә яши, әдәби хәрәкәттә кискен үзгәрешләр күзәтелми. Сиксәненче елларның икенче яртысында татар әдәбияты, тәнкыйте, бер яктан, кризис кичерә, икенче яктан, кыю фикерләр әйтү, мөһим нәтиҗәләр ясау өчен мая да туплый сыман. Һәм туксанынчы еллардагы әдәби хәрәкәттәге күренеш-хәлләр моның шулай икәнлеген раслый да.

Татар тәнкыйтендә ун-унбиш ел саен заманчалык турында бәхәсләр калкып ала. 1988–1989 елда «Казан утлары» әдипләрне тагын әлеге проблемага тартып карый. «Заман һәм шагыйрь» темасына барган фикер алышуда Т. Галиуллин, М. Вәлиев, М. Шабаев, Г. Рәхим, Г. Гыйльманов һәм башкалар катнаша, әмма, аерым язмаларда кызыклы гына проблемалар күтәрелүгә карамастан, ул әдәби җәмәгатьчелектә элеккечә зур шау-шу кузгатмыйча гына узып китә.

Сиксәненче елларның икенче яртысыннан бигрәк тә, аерым мәкаләләрне чыгарма рәвешендә искә алмаганда, татар әдәби тәнкыйте әдәбияттагы төссезлек һәм уртакуллык турында гомуми фикер җиткерүләр, ә аерым авторларны, әсәрләрне кирәгеннән тыш күпертеп мактаулар рәвешендә яши. Әдәби барышны намуслы һәм объектив яктырткан, аның киләчәген фаразлый алган, бигрәк тә проза үсешенә кызыклы күзәтүләр ясаган Ф. Миңнуллинның авыруы, язучылар арасыннан китүе, тәнкыйтькә аны үстерәчәгенә зөр өметләр уятып аяк баскан М. Вәлиев һәм башкаларның әлеге эшчәнлектән читләшүе яисә сирәк кенә мактау рухында язылган мәкаләләр белән канәгатьләнүе аның торгынлык елларында да исән калган көрәшчелек рухын тәмам сүндерә.

Шул ук вакытта Үзгәртеп кору елларында татар галимнәренең дөнья күләмендәге фәнни казанышлар белән танышу мөмкинлекләре зурая, ул һаман да маяк иткән рус тәнкыйтенең методологиясен эшләүгә игътибар тагын да арта төшә. Татар әдәбиятының тыелган мирасын, шәхесләре иҗатын өйрәнүгә юллар ачыла. Бу исә, үз чиратында, әдәби җәмәгатьчелекнең, шул исәптән галимнәрнең һәм тәнкыйтьчеләрнең дә фикри үсешенә этәргеч бирә.

Яңа чорда татар каләм әһле Ч. Айтматов, В. Астафьев, В. Белов, В. Распутин, Ю. Бондарев кебек танылган рус язучыларының тәнкыйди рухтагы чыгышларын, мәкаләләрен, әдәби әсәрләрен көтеп ала, әсәрләренә бирелгән капма-каршы фикерләр белән таныша, уйлана, татар әдәбиятын да рус тәнкыйте үлчәмнәренә куеп карый. Аның өчен тәнкыйтьнең хискә нигезләнгән, кискен бәяләмәле, кирәгеннән тыш теориягә батмаган тәнкыйте кызык. Ул инде әдәбиятны социалистик реализм яисә башка методлар белән аңлаткан мәкаләләргә ихтыяҗ кичерми, әдәби текстка башкача якын килү юлларын көтә. Аңа яңа исемнәр, тыелган әсәрләр турында уку, проблемалы күләмле мәкаләләр белән танышу мөһим. Болар барысы да татар тәнкыйтенең нинди юлларда үсәргә тиешлеген күрсәтеп тора.

# 3. ТӘНКЫЙТЬЧЕ ОСТАЛЫГЫ

*Даһиның материалы – көчле*
*тоемчанлык ул...*
В.С. Соловьев

Бөтенлеккә, тәмамланганлыкка, идея-эстетик эчтәлеккә ия нәфис текст – мөстәкыйль яши алучы берәмлек, шул ук вакытта ул әдәби барышны, мәктәпне, агымны, юнәлешне, әдәбиятны, сәнгать системаларын оештыручы төп берәмлек тә булып тора. Талант һәм фикер иясе үзе яшәгән тирәлек, җәмгыять, үткән чорлар хакында карашлары системасын, үзен борчыган проблемаларны иҗтимагый аңның бер чагылышы булган әдәби әсәр аркылы җиткерүне хуп күрә, шунлыктан матур әдәбият объектив чынбарлыкның оригиналь чагылышы дип санала.

Бер генә әдип тә, шагыйрь дә дөньяга, сәнгать әсәренә битараф рәвештә иҗат итми, ул куйган проблема һәм яктыртылган темаларга этәргеч көч булып тормыш, аннан алган шәхси кичерешләр тора. Димәк, яшәешкә актив позицияле шәхес кенә язучы дәрәҗәсенә күтәрелә. Әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнүче дә әнә шул сыйфатларга ия, аны да җәмгыятьнең алга китеше, шул китештә әдәбиятка тапшырылган вазифалар мәсьәләсе тирәнтен борчый.

Тәнкыйть язмаларына теләсә кайсы фәнни хезмәткә куелган таләпләр ноктасыннан якын киләләр. Алар *бөтенлеккә, тәмамланганлыкка,* мөстәкыйльлеккә ия булырга тиеш дип саныйлар. Бу урында тәгаен фәннәр буенча башкарылган гыйльми язмаларның гуманитар фәннәрнекеннән нык аерылуын әйтергә кирәк. Беренче чиратта, ул *эмоциональ-фикри эчтәлек*тә чагыла.

Әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнүчедән тарихчы, телче һәм башка гуманитарийларга караганда да көчлерәк тел остасы булу, әдәби күренешләргә бик нечкә якын килү сорала. Ул әдипкә, әсәргә, әдәбият үсешенә зыян салмау принцибы белән эш итәргә тиеш,

чөнки материальләшкән – әйтелгән, бигрәк тә язылган һәм күпләр тарафыннан кабул ителгән сүз рухи субстанция булып тора, озак вакытлар дәвамында тәэсир көчен югалтмый.

Тәнкыйтьче, өйрәнү объекты итеп әдәби әсәрне алса да, язмасында сәяси, икътисади, тарихи, этик, педагогик, психологик, тел күренешләренә карата үз фикерләрен белдерергә мөмкин, ягъни ул укучыны төрле өлкәләрдән *таныту* вазифасын үти. Фәнни-фантастик әсәрләрне анализлаганда, мәсәлән, космос, кибернетика кебек күпләр өчен таныш булмаган тирәлеккә, гыйлемнәргә үтеп керә. Производство темасын чагылдырган прозаны өйрәнгәндә, җитештерү урыннарында эшне оештыру, коллектив эчендә, эшче һәм җитәкче арасындагы мөнәсәбәтләр кебек четерекле якларны да күзалларга тиеш була. Икенче төрле әйткәндә, бигрәк тә прозаиктан эрудитлык, яңалыклардан артка калмау, фикерләү сәләтенә осталык көтелә. Дөрес, ул әлеге өлкәләргә бәйле фикерләрне әдәби әсәр яссылыгында, аның белән бәйләп кенә җиткерә.

Әдәбият белеме фәне, шул исәптән әдәби тәнкыйть тә фәлсәфә, мәдәният белеме, психология, тел белеме кебек гуманитар фәннәргә генә таянып калмый, бигрәк тә компьютерлашу заманында ул әдәби күренешләрне төгәл фәннәр эшләгән программалар нигезендә тикшерә, алар ярдәмендә статистик исәпләүләр ала, аерым бер әдипнең стиле турында нәтиҗәләр чыгара, сюжет оригинальлеген ачыклый, метод һәм жанрлар хәрәкәтен күзәтә, төрле халыклар әдәбиятын чагыштырма-типологик тикшерә ала һ.б.

*Шагыйрь, драматург, прозаик – тормышны яңадан торгызып тудырса, тәнкыйтьче – әлеге иҗат берәмлеген һәм тормышның үзен дә анализлау аша күзаллата.*

Тәнкыйтьнең тагын бер функциясе булып *әсәрнең бәһасен билгеләү* тора. Ул әдәби берәмлекнең рухи кыйммәтләрен төрле – иҗтимагый-сәяси, педагогик-этик, фәлсәфи-эстетик аспектларда ача һәм аларны глобаль масштабта, ил күләмендә, милләткә, шәхескә бәйле табарга мөмкин.

Тәнкыйть, әсәрне алга куйган кыйммәтләре яссылыгында анализлап, *эстетик, этик* функцияләр дә башкара, шәхеснең *үз фикерен чагылдыру* чарасына әверелә. Шуларның барысын да күздә тотып язу, әдәби тәнкыйть хезмәтен бөтен, идея-эстетик эчтәлекле итә.

## 3.1. Тәнкыйди анализ принциплары

Әдәби әсәр – күпкатламлы сәнгати дөнья, һәр кисәге бер-берсенә тыгыз үрелгән, аерып алганда, ниндидер зыян да салынырга мөмкин бербөтен ул. Аны образ, метод, стиль, типиклык кебек *гомумсәнгать* терминнары, форма һәм эчтәлек, бөтенлек кебек *фәлсәфи-эстетик* төшенчәләр; матурлык, түбәнлек, югарылык, әхлаксызлык тибындагы *эстетик-этик* категорияләр ярдәмендә анализлыйбыз, аңа *заман күренеше* буларак һәм *тарихи* якын киләбез.

Иҗат ителү чаралары белән аерылган сәнгать төрләрен анализлауда тәңгәллек булмаса да, матур әдәбият һәм сәнгатьнең башка төрләре арасында тыгыз бәйләнеш бар, аларны иҗат итүдә, бәяләүдә дә уртаклыклар күзәтелә. Мәслән, картиналарны бәяләгәндә, анда сурәтләнгән образлар, чагылган сюжет, идея һәм тема турында сүз йөртәбез. Әдәби әсәр хакында да шул рәвешчә сөйләргә мөмкин. Җыр, музыканың яңгырашы, нечкәлеге, эчтәлеге була, болар – матур әдәбиятка да хас сыйфатлар. Архитектура истәлекләрен анализлаганда, монументальлек, героиклык, купшылык, тоныклык терминнарын кулланабыз икән, болар әдәби тәнкыйтьтә дә киң әйләнештәге төшенчәләр булып тора. Театр сәнгатендәге постмодернизм күренешләре әдәбияттагы шул ук күренешләр белән тыгыз бәйләнештә яши. Кыскасы, сәнгать өлкәләрен берләштерүче сыйфатлар булган кебек, алар хакында тәнкыйди сүз әйтергә алынучыларның да коралланган күп кенә чаралары, гыйльми терминнары уртак.

Сәнгать төрләре иҗат чагылышы булудан килгән гомуми охшашлык бар, тарихи-иҗтимагый чорлар яссылыгында барлыкка килә торган стиль һәм методлардагы янәшәлек бар. Төрле өлкәләр өчен иҗат методларының яшәү чикләре төп-төгәл кисешмәскә дә мөмкин, әмма билгеле бер чорда ниндидер иҗат төрендә барлыкка килгән яңалык, озакламый икенчесендә дә чагылмый калмый, чөнки аларның җирлеге булып тормыш үзе тора.

Тәнкыйтьченең бөтен сәнгатьләргә хас терминнарны һәрвакыт куллануы, тирәнтен белүе мәҗбүри дә түгел кебек, әмма әлеге терминнар белән очрашканда, ул текст чагылдырган мәгънәне төгәл аңларга тиеш, ә инде үзе кулланганда, бервакытта да хаталанмавы кирәк.

Әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнүчеләр еш кына язмаларында башка сәнгатьләргә дә үтеп керәләр. Драма әсәрен сәхнәдә

күргәннән соң анализлаучы я булмаса әдәби сюжетның сынлы сәнгатьтә чагылышын тикшерүче берничек тә башка сәнгать законнарыннан хәбәрсез була алмый. Бүгенге укучы һәм тамашачы да шулай. Әйтик, Казанның Бауман урамында Су анасына куелган һәйкәлне күргән кеше фольклор яисә Тукай әсәрендәге образның статик формада ничек, ягъни отышлымы-отышсызмы чагылыш табуы турында уйланмый калмый.

Башкалабызда С. Сәйдәшевкә, М. Вахитовка, Р. Яхинга, Г. Тукайга, Һ. Такташка куелган һәйкәлләр бар. Татар иҗтимагый эшлеклеләренең, сәнгатькәрләренең һәйкәлтарашлар тарафыннан башкарылган сыннары матур әдәбиятта чагылган образлары һәм үз шәхесләре турында искә төшерә, аларны үзара чагыштыру нәтиҗәсендә төрле фикерләр уята. Соңгы елларда аталган шәхесләребезнең таштан ясалган сыннарына мөнәсбәттә бигрәк тә интернет челтәрләрдә төрле катлам кешеләре арасында барган кызу бәхәсләр, аларга хас җитешсезлекләрне табулар, тәгаен атаулар фикеребезгә дәлил булып тора.

Әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнүче, иҗат әсәреннән күпмедер читкәрәк тә китеп, проблемалы мәкаләләр язаганда, танылган шәхесләрнең исемен мәңгеләштерү турында сүз алып барса, мәҗбүриятән сәнгатьнең барлык төрләренә дә хас булган объективлык-субъективлык, тема, идея эчтәлеге, зәвыклылык кебек төшенчәләргә килеп чыга.

Әлбәттә, тәнкыйтьче махсус белгечләр дәрәҗәсендә сәнгать беленә хас терминологияне кулланмаска да мөмкин, әмма аның арсеналында фикерен фәнни нигезләү өчен кирәкле микъдарда махсус инструментарий булырга тиеш. Әлеге терминнар фәнни тикшеренүче кулында әсәрне аңлауга китерүче ачкычлар вазифасын башкара.

Тәнкыйтьче әдәби әсәрне анализлауны *таркату*дан башласа да, ахыр чиктә ул аны *бербөтен* рәвешендә күзаллатырга тиеш.

Һәр кеше, иҗатка якын килүдә оригиналь алымнары булуга карамастан, фәнни фикернең кануннарыннан читкә китми. Әдәби әсәрне анализлау юллары пьеса, роман, шигырь авторының талантына, стиленә, аларның язылу вакытына да бәйле.

Әдәби әсәр талант җимеше генә түгел, ул – чор, халык продукциясе, әмма аңа заманчалык принцибыннан да, гомумкешелек кыйммәтләре, мәңгелек ноктасыннан да якын килергә кирәк.

Тәнкыйтьче аерым бер әсәргә бәя бирсә дә, тулы бер иҗатны анализласа да, автор һәм әдәби процессларга бәйле фикерне

системалаштырырга булыша, аерым бер иҗат хакында белемнәр җыелмасына яңаларын өсти, моңа кадәр булган күзаллауларга төгәллек кертә.

Әдәби әсәргә якын килүдә дөрес булмаган принципларга таяну үз заманында әдәбиятта һәм әдәби тәнкыйтьтә, гомумән гуманитар фәннәрдә вульгар социологизм күренешен барлыкка китергән. Димәк, тәнкыйтьче авторның иҗтимагый статусын, социаль җирлекне, күренешләрне һәм башка кайбер факторларны үз хезмәтендә исәпкә алса да, әдәби берәмлеккә алдан ук иясенең социаль хәленә яисә чыгышына карата булган негатив позициясеннән якын килергә тиеш түгел. Тормыш күренешләренең матур әдәбиятта чагылышы, монда социаль факторның зур роль уйнавы турында карашлар бары тик фактлардан чыгып, эчтәлеккә тирән анализ ясалып кына әйтелә ала. Иҗатчының үз социаль төркеменә хас карашларны гына уздыруы һич тә котылгысыз хәл түгеллеген онытырга ярамый.

Әдәбиятны өйрәнү белән шөгыльләнүче андагы уңай күренешләрне үз яклавы астына алса, аларны ныгытуга көч куйса гына, тәнкыйтьче буларак вазифасын ахырынача башкара. Перспективасыз, бигрәк тә гомумкешелек кыйммәтләренә аяк чалучы тенденцияләрне яклау аны бизәми.

Бүгенге татар әдәби тәнкыйтендә комплиментар формада язу өстенлек итә. Бик күп мәкаләләр бастырып та, гомер эчендә бер генә тәнкыйть сүзе әйтергә батырчылык итмәгән галимнәр, язучылар юк түгел. Китап укучы мәкаләләре өчен бу сыйфат гафу ителсә дә, чын галимнән, үзе иҗат белән шөгыльләнүчедән һәрвакыт этрафлы бәяләмәләр генә көтелә.

Чын тәнкыйтьчеләр һәрвакыт вакытлы матбугатта хөкем сөргән үзара макташу, буш сүз сөйләү кебек күренешләргә каршы көрәшкәннәр. Шушы уңайдан хәтта чагыштырмача тәнкыйть итү рухы көчле булган рус әдәби тәнкыйте хакында шуңа бик игелекле хезмәт иткән Феликс Кузнецовның бер мәкаләсеннән өзек китерик:

«Нашей критике, к сожалению, и сегодня далеко не всегда хватает принципиальности, гражданского мужества и последовательности в борьбе с идейно-художественным браком, в утверждении созвучных времени высоких идейно-художественных, эстетических критериев. Это отрицательно сказывалось не только на достоинстве литературы, но и на достоинстве самой критики. Подлинно аналитическая литературная критика сплошь и рядом уступала

место критике апологетической или ее видимому антиподу – критике разносной. А ведь и комплиментарная, и разносная критика по существу не что иное, как две стороны одной медали»[1].

Кыюлык, тел осталыгы, белемлелек, күзәтүчәнлек, күренешләргә диалектик якын килә белү сәләте, оригиналь фикер йөртү, үз позицияләрендә нык тора тору, бәхәсләшү культурасы, хезмәтләрендә эчтәлек һәм форма бөтенлегенә ирешә алу, фикер һәм хис гармониясен күздә тотып язу, әдәби идеалга ия булу, фаразлау таланты, чама-хис тойгысы, тагын башка бик күп сыйфатлар шәхестән танылган тәнкыйтьче ясый.

## 3.2. Тәнкыйди осталык алымнары һәм сәнгатьлелек мәсьәләсе

Тәнкыйтьче әдәби әсәр белән аны бәяләргә алынган укучы сыйфатында танышканда да, һичшиксез, тәм-ләззәт тоя. Иҗатка үтеп керү, аны аңларга тырышу, кабул итү вакытында туган *эстетик кичерешләр* нигезендә кеше аңында кайчандыр барлыкка килгән һәм инде ныгыган эстетик *күзаллаулар* ята. Әлбәттә, дөньяны, аның төрле тип күренешләрен ныграк аңлый барган саен, әлеге күзаллаулар киңәя һәм үзгәрә, әмма билгеле бер чорларда кешедә аларның тотрыклылары да барлыкка килә. *Эстетик күзаллаулар*ның тәүгеләре, үз чиратында, шулай ук сәнгать җимешләре белән беренче тапкыр танышудан башлана, *кабул ителгән объектның кеше хәтерендә урын алган сурәте* булып тора.

Борынгы грек сүзе булган *эстетик* терминының мәгънәсе нәкъ менә тою органнары ярдәмендә кабул ителгәнлекне аңлата. «Соңгы йөзъеллыклар дәвамында бу сүз белән кешенең чынбарлыкны эмоциональ-бәяләүле үзләштерүенең үзенә башка төре билгеләнә башлады. Эстетик эшчәнлек ул – барыннан да битәр, тәмамланган һәм бөтен дип уйланылган аерым бер предметларны күзәтү», – дип яза В.Е. Хализев. Галим бөтенлекне предметның кабул итүчедә бердәм реакция уяткан, гомуми хис тудырган һәм билгеләве кыен сыйфаты, дигән караштa тора[2].

Даими рәвештә алынган эстетик тәэсирләр, алар ярдәмендә барлыкка килгән эстетик күзаллаулар, үз чиратында, *эстетик зә-*

---

[1] Кузнецов Ф. С веком наравне: критика прозы. Критика критики. М.: Моск. Рабочий, 1981. С. 209.

[2] Хализев В. Е. Теория литературы. М.: Высшая школа, 1999. С. 16.

*вык* тәрбияли. Кешенең, кабул ителгән мәгълүматы, дөньяны танып белү тәҗрибәсе арта барган саен, эстетик зәвыгы да ныгый төшә. Шул ук вакытта, заманга, яңа алган мәгълүматка, кешенең рухи һәм физик халәтенә бәйле рәвештә, әлеге зәвыкта үзгәрешләр дә барлыкка килә.

*Эстетик зәвык* дип шәхеснең эчке культурасына нигезләнгән сайлау сәләтен һәм юнәлешен, алга куйган эстетик кыйммәтләрен атыйбыз. Гади тел белән әйткәндә, эстетик зәвык – кешенең ошату һәм ошатмавы, теләве һәм теләмәве, кабул ителгән мәгълүматтан канәгатьлелеге һәм канәгатьсезлеге ул.

Эстетик зәвык һәм *эстетик идеал* үзара тыгыз бәйләнештә, бер-берсеннән аерым яши алмыйлар. «Эстетик идеал – чынбарлыктагы һәм мәдәнияттагы югары гармония һәм камиллек турында кеше эшчәнлегенең максатына, критериена һәм векторына әйләнүче күзалалу. Идеал эстетик зәвык тарафыннан билгеләнгән иң яхшы эстетик ориентацияләрне сайлап алу юлы белән формалаша»[1], – дип яза Ю. Борев.

Зәвыклар турында бәхәсләшмиләр, әйтемен еш ишетергә туры килә. Әлбәттә, кешеләрнең материаль һәм рухи байлыклар белән танышу дәрәҗәсе төрле икән, күзаллаулары, зәвыклары, ахыр чиктә матурлыкка бәйле идеаллары аерыла һәм теге яки бу бәхәснең чишелешен булмастай итә. Киң кулланышта йөргән әлеге гыйбарәдән һич кенә дә бәхәсне кире кагуны аңларга ярамый, аның кирәклеге шик уятмый. Андый төр сүз көрәштерүләрнең уңай идеаллар ягына хәл ителеше яшь буыннарны киләчәккә хәзерләүдә, аларда җәмгыятьне алга алып барачак нормалар тәрбияләүдә хәлиткеч факторлардан саналырга хаклы.

Җәмгыятьтә яшәгән кешене иң матур сәнгать үрнәкләре белән таныштыру да бик мөһим, ул, аларның зәвыгында ямьсез күренешләргә, тупас гадәтләргә, камил булмаган нәфис иҗатларга уңай мөнәсәбәтне, битарафлыкны тулаем бетерә алмаганда да, уңай идеалларга шактый якынайтачак, ә инде түбән күренешләргә җәелү, ныгу мөмкинлеге бирмәячәк.

Зәвык турында бәхәсләр һәрвакыт бары тик бәяләү характерында гына бара. Безнең заман кешесенең, элек яшәгәннәрнеке белән чагыштырганда, эстетик тәҗрибәсе зуррак һәм киңпланлырак. Ә менә төрле чорларда әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнүчеләр

[1] Борев Ю. Эстетика. М.: Высшая школа, 2002. С. 31.

турында фикер йөрткәндә, бу хакта һәрвакытта да кистереп әйтеп булмый. Заман агышы кешенең буш вакытын нык чикли, ул барлык сәнгать күренешләрен өйрәнергә физик өлгерми, югыйсә, беренче карашка, глобализация чорында, теоретик планда карагаңда, тәнкыйтьченең төрле тип тәнкыйть язмалары, сәнгать әсәрләре белән танышу мөмкинлекләре зуррак та кебек.

Тәнкыйтьченең *эстетик концепцияләре* үзенең һәм башкаларның шул юлдагы эшчәнлеген аңлау аркасында формалашкан. Бу фәнни белемнәрне үзләштерү, әдәби продукция белән танышу, күренешләрнең эстетик ягын ачу рәвешендә бара. Фән белән шөгыльләнүченең эстетик концепцияләре системасы *эстетик карашлары* санала. Алар җәмгыятьтә хөкем сөргән һәм сәнгатькәрләрнең рухи эшчәнлегенең кыйммәтләр аспектын билгеләгән эстетик карашлар системасы белән ярашса гына, тәнкыйтьче үз хезмәтләренә уңай бәяләмә ала, киресенчә булганда, ул еш кына тәнкыйтькә дә очрый.

Эстетик карашлар, зәвыклар, идеаллар, үз чиратында, кешенең рухи эшчәнлегенең формаларын билгели. Аерым бер идеаллар ноктасыннан торып сүз әйткән тәнкыйтьче язучы иҗатына *эстетик юнәлеш* бирергә алына булып чыга.

Кешелек җәмгыяте үзен чорнап алган предметларны, инсан эшчәнлеге тудырган продукцияләрне бәяләү ихтыяҗы кичерә. Әлеге ихтыяҗ гомумкешелек кыйммәтләрен югары куярлык тәнкыйтьчеләр, сәнгать белгечләре тәрбияләүдә дә чагыла.

Әдәби әсәргә тенденциоз, утилитар-гамәли, хакимият алып барган идеология ноктасыннан якын килү тәнкыйтьче әхлагы, этикасы турында сүз алып баруга китерә. Кайберәүләр сәнгатьне конъюнктура, сәясәт чарасы итә, җирдә матурлыкны яшәтү өчен көрәшкән язучыга каршы көчле бер коралга әверелә. Тәнкыйтьче, җәмгыятьтәге сәяси карашларны исәпкә алса да, аларның вакытлылыгын, эстетик эшчәнлеккә кагылышсызлыгын онытмаска тиеш.

Әдәби әсәрне бәяләгән тәнкыйть материалы үзе дә – эстетик күренеш. Әгәр эстетик кыйммәтләр гомумкешелек кыйммәтләренең бер өлеше икән, аны иҗат иткән кеше дә җәмгыятьтә гуманистик принциапларның яшәвенә хезмәт итә.

Тәнкыйтьче осталыгы, димәк ки, нинди эстетик идеал белән кораллануына, эстетик зәвыгына бәйле. Аның әдәби әсәрләргә мөнәсәбәте генә түгел, әдәби-фәнни хезмәтләре дә башкалар тара-

фыннан эстетик кыйммәтләр сыйфатында һәм билгеле бер эстетик карашлар ноктасыннан бәяләнә.

Тәнкыйть язмаларының фәнни югарылыгы һәм сәнгатьлелеге турында сүз йөрткәндә, тагын авторлык мәсьәләсенә килеп чыгасың. Әдәби тәнкыйть киң мәйданнар биләсә дә, аның тарихы бары тик һөнәри тәнкыйть тарихы сыйфатында гына языла.

Һөнәри тәнкыйть дип автор өчен төп яисә даими булган шөгыльне әйтәләр. Бу өлкәдә эшләүчеләр татар фәнендә күп түгел. Соңгы чор тәнкыйтьчеләреннән Мансур Вәлиев, Мөдәррис Вәлиев, Рафаэль Мостафин, Рафикъ Шәрәфиев, Дания Заһидуллина, Әлфәт Закирҗанов, Рифә Рахман һәм башкаларны атарга мөмкин. Шунысы да бар: тәнкыйтьне һөнәр итүчеләрнең дә әлеге хезмәткә хәзерлек дәрәҗәсе төрле. Аларның барысы да югары уку йортларының филология яисә махсус факультетларында белем алмаган. Кайберләре, белемнәрен күтәрү, даими язу аркасында, хезмәтләрен фәнни нигезле иткән һәм укучы тәнкыйтеннән һөнәри тәнкыйть биеклегенә күтәргән.

Тәнкыйтьнең профессиягә әверелүе иҗтимагый-эстетик аңның соңгырак этапларында барлыкка килә, һәм бу эшчәнлек үзе биләгән мәйданны чын мәгънәсендәге фәнни гыйлемнәр өлкәсенә әврелдерүгә хезмәт итә. Язмаларның һөнәрилек дәрәҗәсе тәнкыйтьченең әдәби әсәрне текст үзенчәлекләреннән чыгып аңлау һәм бәяләү осталыгы аша билгеләнә.

Һөнәри тәнкыйть китап сөючеләргә әдәбиятның матурлыгын ачу, аңа хас сәнгатилекне яисә җитешсез якларны күрсәтү белән шөгыльләнә. Тоталитар системаларда тәнкыйть хакимлек иткән идеологиягә буйсындырылган һәм хаким сыйныфларга, хакимлеккә ия каләм ияләренә ялагай булырга мөмкин, әмма шушы күренешкә каршы торучы, иҗаттан рәсми төркемнәр таләп иткәнне эзләмәүче, әдәбиятны иҗатчылар куйган киртәләр эченә куаламаучы намуслы тәнкыйтьчеләр һәрвакыт бар.

Милли матбугатта тәнкыйть өчен рубрикалар булдыру, махсус газета-журналлар чыгу әдәби тәнкыйтьнең һөнәрилеккә омтылышын күрсәтә. Язучылар оешмаларында барлыкка килгән тәнкыйть остаханәләре, уку йортларында ачылган махсус белгечлекләр дә тәнкыйтьне фән буларак тануны, аның белән фәнни һәм сәнгатьчә югарылыктан торып шөгыльләнү кирәклеген аңлауны чагылдыра.

Тәнкыйтьнең аерым жанрлары формалашу, аларның тулы бер системага әверелүе һөнәри тәнкыйть туу, үсү этапларына бәйле.

Цикллы мәкаләләр язу, еллык күзәтүләр ясау, программ манифестлар төзүләр һәм башкалар бары тик профессиональ тәнкыйтьчеләр кулыннан гына килә.

Язучылар тәнкыйте дә бик күп очракта һөнәри тәнкыйтькә дәгъвалый. А.С. Пушкин, Ф.М. Достоевский, Н.С. Гумилев кебек талантлар иҗатның бу юнәлешенә дә зур игътибар биргәннәр. Татар прозаикларыннан Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, А. Хәлим, Р. Мөхәммәдиев һәм башкалар тәнкыйть язмалары бастырганнар. Шунысы кызыклы: бик күп кенә каләм ияләре югары уку йортлары каршысында аспирантурада укыганнар. Алар арасында М. Мәһдиев, Н. Хисамов, Ә. Мәхмүди, Р. Фәйзуллин, Ф. Низамова, Л. Янсуар, Җ. Сөләйман, А. Расих һәм башкалар бар. Нәфис сәнгать белән шөгыльләнүчеләр бүген дә югары уку йортларында әдәбият, тел фәннәреннән лекцияләр укыйлар, әдәби тәнкыйть курсларын алып баралар, студентларны иҗат эшенә өйрәтәләр. Бу урында М. Гәрәев, Р. Батулла, Г. Гыйльманов кебекләрне телгә алырга кирәк.

Турыдан-туры иҗат белән шөгыльләнүчеләрнең тәнкыйте популяррак телдә язылган, укырга кызыклы була, аларда язучының әдәби зәвыгы ачык чагыла, ул әйткән фикерләр еш кына башкаларныкына туры килми яисә бик үзенчәлекле. Иҗатчы читләр язганны үз гамәлияте аша аңлый, үз эстетик эзләнүләре җирлегенә куеп карый.

Каләм ияләре тәнкыйди карашларын эссе, көндәлек, истәлек язмалар рәвешендә уздыруны хуп күрәләр, аларны һәрвакытта да киңкатлам укучыга тәкъдим итмиләр: авторга кискен сүзле хатлар юллыйлар, аерым бер әсәргә карата фикерләрен дус-ишләренә генә әйтәләр, теге яки бу китап кырыена карашларын белдергән бәяләмәләр язып китәләр.

«Писательская критика в своих лучших образцах поучительна и ценна отсутствием авторитарности и педантизма, от которых мы, профессиональные критики, так страдаем. Отрицательно сказывается на наших работах склонность к разжевыванию общеизвестных истин, большей частью не поддающихся окончательным решениям»[1], – дип яза Б.И. Бурсов. Галим хаклы. Шул ук вакытта чын мәгънәдәге *язучы тәнкыйте* һәм *һөнәри тәнкыйть* арасында принципиаль аерма юк диярлек.

[1] Бурсов Б.И. Критика как литература. Л.: Лениздат, 1976. С. 30.

Шуны тагын бер азсызыклыйк: тәнкыйть мәкаләләрен күпчелек очракта үзләре дә әдәби әсәрләр иҗат иткән галимнәр яза. Татарда бигрәк тә. Бу тәнкыйть калыплашкан заманнардан алып бүгенгәчә шулай булган. Хәтта әдип һәм шагыйрь сыйфатында дан алмаган Фәрваз Миңнуллин, Марсель Бакиров, Дания Заһидуллина һәм башка бик күпләрнең иҗат белән дә шөгыльләнгәннәре мәгълүм. Нурмөхәммәт Хисамов, Әмир Мәхмүди, Рифә Рахман, Равил Рахмани кебек шагыйрьләр һәм Ибраһим Нуруллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Тәлгат Галиуллин кебек прозаиклар – бер үк вакытта галимнәр дә. Инде аларга алмашка килгән буыннардан Луиза Янсуар, Рөстәм Галиуллин һәм башкалар шулай ук каләмнәрен ике өлкәдә дә сыный. Язучы тәнкыйте белән һөнәри тәнкыйтьнең якынаюы, тиңләшүе каләм ияләренең фәнни эшкә әзерлек дәрәҗәсе һәм язучы буларак талант зурлыгы белән билгеләнә. Менә ни өчен югарыда аталган авторларның тәнкыйть мәкаләләре укучыда зур кызыксыну уята.

*Укучы тәнкыйте* дип китап киштәләренә чыгарылган, вакытлы матбугатта дөнья күргән продукциягә әдәбият сөючеләр тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәткә әйтәләр. Аны *үзешчән тәнкыйть* дип тә йөртәләр. Үзешчәннәр язучыларга хатлар юллыйлар, вакытлы матбугатта аларга адресланган репликалар бастыралар, рецензияләр язу белән мавыгалар. Китап укучылар арасында да тәнкыйть белән һөнәри дәрәҗәдә шөгыльләнүчеләр очрый. Гадәттә, алар үзешчән әдипләр, филологлар яисә әдәбиятка хас үзенчәлекләргә тоемчан шәхесләр була.

Үзешчән тәнкыйтьтән чыгып, укучыларның нинди әдәбиятка ихтыяҗын, әдәби зәвык дәрәҗәсен, сүз сәнгатен кабул итүгә хәзерлеген чамаларга мөмкин. Еш кына һөнәри тәнкыйть уздырган карашлар белән укучы тәнкыйтендә яңгыраган фикерләр капма-каршы килә, китап сөюче өчен кайвакыт, әсәрнең сәнгатьчә эшләнешеннән битәр, мавыктыргыч сюжеты, әхлакый эчтәлеге, кызганыч язмышлы яисә бәхетле геройлар мөһимрәк булып чыга. Берәүләрне әдәби әсәр персонажларының халыкчан теле, көлке ягы белән җәлеп итә.

Ничек кенә булмасын, гади укучы үз язмаларында профессиональлеккә омтылган кебек, һөнәри тәнкыйтьче дә хезмәтләрен халык аңларлык, яратырлык итеп язарга тиеш.

Матур әдәбиятның көче язучы таланты белән билгеләнә, ә фәнни-әдәби сүз көченә тәнкыйтьче булдыклылыгы ярдәмендә ирешелә. Талант табигать тарафыннан бирелгән бүләк булса да,

үстерелергә, актив иҗатка хезмәт итәргә тиеш, югыйсә ул, язмый торган каләм кебек, сыначак, тоныкланып калачак. Тәнкыйтьче исә үз гыйлемнәрен арттыра, карашларын киңәйтә алса да, фикерләрен сәнгатьчә чаралар ярдәмендә, укучы яратып укырлык җиткерә алмаска мөмкин. Күпләрнең боларны истә тотмавы аркасында да, элементар алымнар белән генә тудырылган әдәби тәнкыйть һаман да тәнкыйди мирасыбызда зур урын алып тора.

Тәнкыйди осталык әйтергә теләгәннәреңне үткен, ачык, эзлекле, объектив һәм тәэсирле җиткерә алуда, форма һәм фикердә бөтенлеккә ирешүдә чагыла. Тәнкыйтьче үз язмаларында эстет я булмаса сәясәтче, философ һәм башка һөнәр ияләре сыйфатында да чыгыш ясарга мөмкин. Ул язган тәнкыйтьнең тирәнлеге *шәхси аң* һәм җәмгыятьнең *гражданлык аңы* белән билгеләнә.

## 3.3. Бөтенлек категориясе

Теләсә нинди теркәлгән фәнни фикер текстта чагылыш таба. «Лингвистик энциклопедик сүзлек»тә: «Текст – (лат. *textus* – тукыма, үрелмә, кушылма) төп сыйфатлары бөтенлек һәм бәйләнешлелек булган тамга берәмлекләренең мәгънәви бәйләнештә берләшкән эзлеклелеге», – диелгән.

Текстның бөтенлеге фикердә тәмамганлыкны, тематик тулылыкны күрсәтә. Композиция, логик эзлеклелек, стиль, жанр һәм башка кайбер чаралар тәнкыйтьче язмасына бөтенлек сыйфаты бирергә булыша. Текстның бөтенлегендә композиция өлешләренең, берәмлекләренең үзара бәйләнеше, мөнәсәбәте аеруча мөһим булып тора.

Тәмамланган текст сыйфатында вакытлы матбугатта дөнья күргән фәнни язма тәнкыйтьченең фикерләү дәрәҗәсен, тел осталыгын сөйли. Әлеге язмаларның бөтенлегенә еш кына редакторларның әдәпсез тыкшынуы, урынсыз кыскартулар, ялгаулар зур зыян сала. Авторның катгый позициясе, үз мәнфәгатьләре сагында нык торуы гына язманы камил яшәтә ала. Күләмдә чикләнгән әдәби тәнкыйть рубрикалары тәнкыйтьчегә фикерен тиеш дәрәҗәдә җәелдерергә, тирән язарга яисә тәмамлап бетерергә мөмкинлек бирми, ул матбугатның аяусыз таләпләре каршында үзен көчсез тоя.

Әдәби уйланма булган кебек, тәнкыйтьтә кечкенә бер рациональ орлыктан – идеядән, тәнкыйди уйланмадан үсеп китә. Гариф Ахуновның Салих Батталның «Олы юл буйлап» шигъри повестена мөнәсәбәтле язылган «Поэзиянең олы юлыннан» мәкаләсе бар. Ике

әсәр атамасында күзгә ташланырлык охшашлык нәкъ менә отышлы, эчтәлеккә аваздаш исемнең, повестьның беренче юллары ук тудырган эстетик кичерешләрнең, алар нәтиҗәсендә хәтердә яңарган эстетик күзаллауларның, әдәбият аша тупланган эстетик тәҗрибәнең тәнкыйть хезмәтенә этәргеч булганлыгын күрсәтә. Без моны мәкаләнең тәүге абзацы ярдәмендә дәлилли алабыз: «...Сызылып аткан җәйге таңны, алтынланып кояш чыгуны кайсы шагыйрь генә җырламаган да, кайсы шагыйрь генә табигатьнең уянуын, яңа көн тууын күреп илһамланмаган! Йөз мәртәбә сурәтләнгән, барлык эпитетлары әйтелеп беткән таң картинасын йөз дә беренче мәртәбә сурәтләү шагыйрь өчен җиңел эш түгел. Шулай булуга карамастан, Салих Батталның «Олы юл буйлап» повестендагы таң күренеше беренче юлларыннан ук күңелне кузгатып җибәрә».

Г. Ахунов, моңа кадәр укыган әсәрләрен күздә тотып, алардан аермалы яклар эзләп, повесть белән танышырга керешә һәм әсәрнең яңалыгын шунда ук таба да башлый: монда көнчыгыш шигърияте хас купшылык юк, гади сурәтләр эчендә герой күңеле ята, прозаик төгәллек күзгә ташлана... Шагыйрь әнә шул җирлектә ничек герой характерын ачса, аның башкалар белән барган һәм үз эчендәге конфликтларына килеп чыкса, тәнкыйтьче дә яңадан бер тапкыр аның геройларын гади, мәгънәле матурлыкка куеп карый. Бу хакта Г. Ахунов шушы рәвешчә фикер йөртә: «Биредә инде күз камаштыргыч бизәкләр арасыннан повестьның героен эзләп маташмыйсың, ул синең алдыңда үзе басып тора, гүя ул үзенең хәле, эше, туган авылына мөнәсәбәте турында синең белән чын күңелдән сөйләшергә җыена һәм, бик табигый, моннан соң инде син аның алдагы тормышы белән кызыксынмый кала алмыйсың».

Әсәрнең структурасы Г. Ахуновка мәкалә төзелешен дә әйтеп яздыра кебек. Сүзне гади генә сурәтләрдән башлаган әдипшагыйрь аны повестька сайланган тормыш материалының никадәр катлаулы булуы аңлашылгач тәмамлый. Мәкаләнең дә шул катлаулылыкка бару формасында язылуы аны темпераментлы, кызыклы итә. Асылда эчтәлекне ачу рухындарак булса да, даими рәвештә автор ирешкән уңышларны һәм җитешсезлекләрне атау янәшәдә аналитик фикернең дә яшәвен күрсәтә.

Г. Ахунов, бер әсәрдән этәрелеп китсә дә, проблеманы киңәйтә, глобальләштерә һәм язмасын шушы рәвешчә йомгаклый: «„Олы юл буйлап“ повесте сугыштан соңгы колхоз авылы тормышын мөмкин кадәр киң планда, катлаулы ситуацияләр эчендә күрсәтүе

белән, колхозчы хезмәтенең матурлыгын күрә белүе белән, безнең поэзиянең мөмкинлекләре никадәр зур булуын тагын бер тапкыр раслады»[1]. Мәкаләгә куелган атама һәм әлеге атамага салынган мәгънәне тулы ачарлык соңгы абзац хезмәтнең бөтенлеге, тәмамланганлыгы тойгысын уята.

Тәнкыйтькә нисбәтле язмалар гына түгел, махсус китаплар турында сүз йөрткәндә дә, бөтенлек төшенчәсенә тукталмый булмый. Г. Ахуновның әлеге мәкалә урнашкан китабы «Әдәби язмышлар» дип атала. Укучы бу хезмәтне аерым бер әсәрнең, авторның, иҗатның катлаулы, бәхетле я булмаса башка бер төрле язмышы хакындагы мәкаләләр тупланмасы сыйфатында кабул итә. Һәрбер язманың төгәлләнгәнлеге, аларның уртак идея белән тыгыз бәйләнгәнлеге, бүлекләрнең аерым бер принциплар ярдәмендә оешуы, әдипнең тәнкыйтьче буларак фикер йөртү стиле китапны бербөтен хәленә китерә.

Тәнкыйть мәкаләләрендәге бәйләнешләрне төркемләгәндә, логик, өлешара, текст эчендәге лексик һәм грамматик бәйлелек турында сүз йөртә алабыз. Язма башка тәнкыйть материаллары, сәнгатькә, хәтта икенче өлкәләргә кагылышлы текстлар белән дә тыгыз элемтәдә булырга мөмкин. Бу элемтә кайвакыт интертекстуальлек рәвешендә чагылыш таба.

Тәнкыйть хезмәтләрендә укучы өчен таныш яисә таныш булмаган цитаталар кулланыла. Ачыктан-ачык китерелгән өзекләрнең, фикерләрнең, бигрәк тә фәнни эчтәлеккә ия булсалар, астөшермәләрдә чыганагы күрсәтелә, бу мәҗбүри бер гамәл санала.

Фикерне нигезләү, бәхәс, методологик таяныч сыйфатында китерелгән өзекләрдән тыш, текстта авторлыгы махсус яшерелгән яисә әдәби тәнкыйтьтә таралган, киңкулланышка кергән, әмма кайчандыр кемдер тарафыннан әйтелгән фикерләр дә урын ала. Димәк, әдәби тәнкыйть язмалары тәнкыйтьчеләрнең үзара диалогы рәвешендә дә дөньяга килә.

Галимнәр интертекстуальлекнең теләсә кайсы текстка хаслыгын әйтә, шул ук вакытта бу сыйфат калкуланырга, алга чыгарылырга тиеш түгел, ул чагында язма бөтенлеген, мәстәкыйльлеген югалта, кайвакыт авторның фикерсезлеге, хәтта ки плагиатлыгы турында карашларга урын калдыра.

---

[1] Ахунов Г. Поэзиянең олы юлыннан // Әдәби язмышлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. Б. 129–139.

Тәнкыйтьче һәр укучысына билгеле *социаль*, аерым төркемнәргә аңлаешлы *коллектив* һәм *авторның* үзенә генә ачык белемнәргә таянырга мөмкин. Текст оешудагы өченче төр җирлек язманы басып китсә, укучы тарафыннан материал шулай ук бөтен рәвешендә кабул ителә алмый.

Тәнкыйть язмасы структур бөтен булсын өчен, автор текстның мәгънәви-төзелеш яссылыгындагы элементларына да (җөмләләргә, фразаара бәйләнешләргә, төрле фрагментлардан оешкан блокларга) композиция яссылыгындагыларына да (абзацлар, бүлек һәм бүлекчәләр...) бердәй игътибар итәргә тиешле.

Әдәби тәнкыйть язмасының стилистик бөтенлеген аны тематик һәм стиль доминантасына буйсындыру дәрәҗәсе билгели. Шул ук абзац, төрле тип кабатлаулар, информация җиткерү юллары, автор модальлеге бер үк вакытта һәм композиция, һәм стиль берәмлекләре булып тора.

Әдәби тәнкыйть язмаларының берише сәнгати булмаган текстларга карый, чөнки алар логик фикерләү нигезендә төзелә, ә саф сәнгатьчә текстлар ассоциатив күзаллауларга таяна. Без уртадарак торган язмалар белән дә еш очрашабыз. Хәтта фикерләү төре дә тәнкыйть хезмәтенең бөтенлегенә ирешүгә булыша.

### 3.4. Эчтәлек һәм форма мөнәсәбәте

Табигатьтә, иҗтимагый тормышта, кеше яшәешендә, аерым предметларда форма һәм эчтәлек бер-берсеннән аерылгысыз. Әйтик, без сәнгатьне тормышны аңлау формасы дип таныйбыз, шул аңлауны, шул аңлаудан аерып алган эчтәлекне аерым төрләрдә, жанрларда, жанр формаларында чагылдырабыз. Һәм фән, шуның мөстәкыйль өлкәсе әдәби тәнкыйть хакында да шулай әйтергә мөмкин, әмма, *әдәби тәнкыйть – тормышның бер күренеше булган сүз сәнгатен аңлау формасы ул,* дисәк, төгәлрәк яңгырар.

Әдәби-фәнни текстның бөтенлеге мәсьәләсен *форма һәм эчтәлек* мөнәсәбәтеннән башка күз алдына китерү кыен. Сыйфатламалары ачыкланган жанр формаларында иҗат иткәндә, каләм иясе җиткергән эчтәлек шул форма таләп иткән кысалар белән билгеләнә. Әйтик, тәнкыйтьче китапка аннотация яза ди. Бу вакытта ул әсәр иҗат ителгән чордагы әдәби процессларга тукталмый, язучының шәхси тормышына кагылып узмый.

Кызганыч ки, тәнкыйтьтә сайланган формасына туры килмәгән эчтәлек һәрвакыт очраштыра. Бу чирнең барлык жанр формаларына

хаслыгын да билгеләргә кирәк. Әгәр жанр сыйфатламалары даими рәвештә исәпкә алынмый икән, аларны үзгәртү турында уйланырга урын бар. Мисалга Г. Гыйльмановның «Тозлы яңгыр» китабына язылган аннотацияне китерик. Беренче күз ташлауга ук, аның күләм ягыннан зурлыгы күзәтелә. Эчтәлеге белән дә, ул китап басылып чыкканнан соң газета битләрендә урын алучы реклама материалына, кечерәк күләмле укучы рецензиясенә охшаган. Икенче яктан, аннотациядә тәкъдим ителәсе әсәр турында гына сүз алып барыласы җирдә, язучы иҗаты хакында гомуми фикерләргә дә урын зур бирелгән. Гомумиләштереп әйткәндә, җыентык хакында сөйләүнең килешле юллары табылмаган, ул иҗатка кыскача бәяләмә-реплика характерын алган.

Аннотацияләрдә сорау җөмләләр язу, сорау-җавап алымы гайре табигый санала, әмма аны башкарган автор моңа игътибар итмәгән: «Язучы Галимҗан Гыйльмановның чәчмә әсәрләре кайсы ягы белән җәлеп итә соң? Иң элек, тормышчанлыгы, рухи киеренкелеге һәм авылга, табигатькә тугрылыгы белән. Аның әсәрләрендә гайрәтле алып батырлар да, чит дөньядан килгән тылсымлы затлар да юк. Аның геройлары – гади җир кешеләре – явачак яңгырны үз җанытәне белән тоеп яшәүче Ак бабайлар, бүгенге рәхимсез тормышта алган беренче күңел яраларына дәва эзләүче Саматлар, Миләүшәләр, бөтен йөрәк җылысын, күңел сафлыгын кошларга биргән Булатлар... Авторның уңышы шунда ки, ул халыкта «сәер җаннар» буларак телгә кергән кешеләрнең язмышларына, күңелләренә тирән төшеп, аларның бай, матур, омтылышлы рухиятен ачып бирә алган».

Югарыда китерелгән текстны аз гына редакцияләү дә аны куелган таләпләр кысасына кертәчәк. Аннотациядә китапның гадәти, әмма үзенчәлекле холык сыйфатларына, язмышларга ия авыл кешеләре тормышын чагылдыруын әйтү белән канәгатьләнергә, ә инде иң отышлысы: күп әсәрләрдән торган җыентыкның тематик киңлеген яисә уртаклыгын ачарга кирәк.

«Эчтәлек – предметны, күренешне, процессны барлыкка китерүче әһәмиятле элементлар җыелмасы ул. Форма – эчтәлекнең эчке һәм тышкы структурасы, аны чагылдыру алымы»[1],– дип яза Ф.И. Калошин.

---

[1] Калошин Ф.И. Содержание и форма в произведениях искусства. М.: Госиздат политической литературы, 1953. С. 24.

Болай уйлау бик шартлы булса да, эчтәлек – формага карата беренчел. Һәм бу ике төшенчә тормыштагы барлык күренешләргә карата кулланыла ала, философик категорияләр дип санала. Фәлсәфи мәгънәдә карап, форманы – билгеле бер эчтәлекнең яшәү рәвеше, закончалыклы эчке оешуы, дип аңлаталар.

Форманың икенчеллеге танылганда да, эчтәлеккә карата актив позициядә булуы кире кагылмый: «Активная роль формы по отношению к своему содержанию может проявиться двояко: она может соответствовать данному содержанию, и тогда она способствует развитию содержания, поступательному ходу процесса; но форма может и не соответствовать содержанию, ее развитие может отставать от содержания, и тогда форма начинает задерживать, тормозить его развитие, а при известных условиях и прямо превращается в оковы развития содержания. В тех случаях, когда форма не соответствует содержанию, между содержанием и формой неизбежно возникает конфликт, приводящий к замене старой формы новой формой»[1].

2005 елның 23 августында Тукай музеендагы яңа күргәзмә тәкъдир итү кичәсендә чыгыш ясаучыларның берсе, танылган шагыйрь, укучыларга XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы әдәбияты турында сөйләгәндә, бу чорда татар шигърияте Көнчыгыштан форма алып, Көнбатыш эчтәлегенә йөз тотып үсте, диде. Шушы күренешне евразиялелекнең бер чагылышына мисал итте. Ике гасыр чигендә, нәкъ менә иске формаларның яңа эчтәлеккә комачаулык итүе аркасында, форма эзләнүләре башлана да инде. Яңа жанрлар, аларның модификацияләре барлыкка килә. Бу формалар чорга хас материалны заманга, язучыларның күзаллау, профессиональ үсеш дәрәҗәсенә лаек итеп чагылдыру мөмкинлеге бирә.

Теләсә кайсы өлкәдә форма үзгәрешләре тарихи барыш белән бәйләнгән. Филологиядә, бигрәк тә әдәбиятта һәм аны чагылдырган тәнкыйтьтә бу күзгә ташланырлык чагылыш таба. Форма һәм эчтәлек кебек аерылмас берлек эчендә нииндидер якның күпмедер алга китеше әдәбияттамы, әдәби тәнкыйтьтәме, башка бер өлкәдәме, икенче якның да үзгәрүен таләп итә башлый. Үзгәрешләрне көтү чорлар дәвамына сузылмый, алар озакламый үзләрен сиздерә. Бу күренеш әлеге өлкәнең гомуми үсешенә этәргеч тәэсир ясый. Әлбәттә, заманнар узган саен, эчтәлекнең кискен яңарганы

---

[1] Калошин Ф.И. Содержание и форма в произведениях искусства. С. 113.

сизелгән хәлдә дә, форма үзгәрешләре кычкырып тормаска, күзгә нык бәрелмәскә мөмкин, әмма тормышны туктата алмаган кебек, аны чагылдырган сәнгать һәм фәннең эш алымнары ягыннан үсешен дә туктата алмыйсың. Яңа инструментлар, методлар барлыкка килә, эш калыпларының моңа кадәр күрелмәгән мөмкинлекләре ачылып китә, алар, үз чиратында, яңа чынбарлык тудыруга хезмәт итә. Үзгә эчтәлеккә, нинди дәрәҗәдә генә булмасын, инде икенчерәк тышкы сыйфатларга ия әдәби тәнкыйть текстлары әнә шул яңа чынбарлыкны бер мисалына әверелә.

Гомумиләштереп әйткәндә, теләсә кайсы идея аерым бер формаларда чагылыш таба икән, әдәби берәмлек хакындагы карашлар да үзләренә лаек кысалар сайлый. Иҗтимагый аңның бер төре саналган әдәби тәнкыйть тә, заманнар узган саен, дифференциацияләнә бара, үзенең төрле эчтәлеккә, чагылдыру алымнарына ия жанр формаларын булдыра.

«Сәнгать әсәрләрендә эчтәлек һәм форманың аерылгысызлыгы турында Аристотельдән башлап сәнгатьнең барлык теоретиклары яза. Безгә бу хакта язарга кирәк түгел, дип әйтмим. Минем игътибарны форма һәм эчтәлек арасындагы үзара бәйләнгәнлек хакында туйдыргыч кабатлаулардан бернинди файда юклыгына гына юнәлтәсем килә. Тәнкыйтьчеләргә беренчесенең дә, икенчесенең дә киңкырлылыгын исәпкә алырга кирәк»[1],– ди Б.И. Бурсов.

Әлбәттә, форма һәм эчтәлек берлеге турында фикер йөрткәндә, без мәсьәләгә механик якын килергә тиеш түгел. Оста тәнкыйтьче, фикерен белдерү өчен, кирәкле жанрны сайлый, хәтта аның берничә формасын таба ала, тонын, стилен, язмасының күләмен дә бик җиңел ачыклый. Язучылар галимнәрнең мәкаләләрен дәлилле фикерләүгә, тирән эчтәлеккә үрнәк итсәләр, галимнәр әдипләрдән әдәбилеккә, форма төрлелегенә өйрәнә. Дөрес, татар тәнкыйтендә еш кына теге яки бу якның берсе аксый. Тәнкыйтьчеләр алдында әнә шуңа да үзләре хезмәт иткән өлкәне үстерү, форма һәм эчтәлек ягыннан баету бурычы тора.

[1] Бурсов Б. И. Критика как литература. С. 30.

# 4. ИНФОРМАЦИЯ-ПРОПАГАНДА ЧАРАЛАРЫ ҺӘМ ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

*Күптән ачыкланган:*
*кешеләргә, әгәр пресса чагылдыра икән,*
*теләсә кайсы вакыйга ун мәртәбә әһәмиятлерәк тоела.*
Борис Акунин

*Шигыремне яздым, басылды, мин тагын зур кайгыда:*
*Фикеремә юк-бар белән исememне игъланып килә.*
Габдулла Тукай

Әдәби тәнкыйть – галимнең, әдәбият сөючененң үз-үзен реализацияләү юлы, әмма аның продукциясе кайдадыр дөнья күрергә, ничектер халыкка барып ирешергә тиеш. Бу очракта информация, пропаганда чаралары ярдәм кулы суза. Болар: вакытлы матбугат, радио-телевидение һәм интернет.

Вакытлы матбугатның һаман да әдәбиятка, аны чагылдырган фәннәргә ихтыяҗ кичерүе аларны социаль, мәдәни үсеш факторлары дип санавыннан; халыкка якын өлкәләр булганга, аудиторияне киңәйтүдә файдалануыннан; әдәби тәнкыйтькә социаль барышны, үзгәрешләрне аңлатуда өмет баглавыннан, кешеләрне агарту чарасы дип каравыннан; ахыр чиктә, информатив орган булганга, әдәбият турында да мәгълүмат бирергә тиешлегеннән килә. Вакытлы матбугат әдәбиятка, аны чагылдырган фәннәргә яңалыклар кертү, аларга бәйле фикерләрне оператив җиткерү мөмкинлеге бирә.

Тәнкыйтьчеләр талантлар алдында һәрвакытта да баш ими, объектив булырга омтылганнары хәтта тәнкыйть итүгә «табу салынган» каләм ияләре хакында да кискен сүз әйтә. Кискенлек, үткенлек, кыюлык төшенчәләре тәнкыйтьченең холык сыйфатларын да, эш алымнарын да күрсәтеп тора, тик аларны кире кагарга, әдәпсезлек кебек төшенчәләр белән тәңгәлләштерергә, үз иҗатына бәя биргән язмаларына әхлаксыз бер рәвештә каршы чыгарга

ярамый. Әлбәттә, әдәби дискуссияләр генә түгел, тәнкыйть язмаларының һәркайсы авторның йөзе кызармаслык языларга тиеш.

## 4.1. Пропаганда, агитация чарасы буларак әдәби тәнкыйть

Вакытлы матбугатта дөнья күргән әдәби тәнкыйтьнең бер вазифасы – *массакүләм пропаганда*. Радио, телевидение аша тәнкыйтьче авызыннан яңгыраган сүзнең дә көче зур. Кешелек җәмгыятенең мәдәни-тарихи этапларында мәгълүмат чаралары төрле үсешкә ия, шунлыктан әдәби тәнкыйть таралышы да бердәй түгел, әмма берсенең үсешенә икенчесенеке пропорциональ дип әйтү дә хата булыр иде. Мөмкинлекләр һәм аларны файдалана белү һәр заманда үзгә. Ул бик күп очракта халыкның мәдәнилек дәрәҗәсе, кайсы төр сәнгатьләргә һәм фәннәргә өстенлек бирүе, хөкүмәт сәясәте, матбугат органнарының эш алымнары, асыл максатлары белән бәйле. Хәзерге вакытта пропаганда чараларының саны артты, әмма әдәби тәнкыйтькә мәйдан кысылды, әдәбиятны чагылдыручы мәкаләләр редакцияләрдә һәрдаим тоткарлана, кыскартып чыгарыла я бөтенләй бастырылмый. Авторларның үз хокукларын дәгъваларга маташуы да проблеманы уңай хәл итми, тәнкыйтьченең алга таба мөмкинлекләрен тагын да ныграк чикли.

Әле чын мәгънәсендә әдәби тәнкыйть калыплашканчы, башта нәфис иҗатка карата телдән шәхси мөнәсәбәт белдерелгән, тар даирә эчендә фикерләр әйтелгән, соңрак тәнкыйди сүз кульязмаларда, басма китапларда бер рәвешчә урын алган. Тәнкыйди хезмәтләр үсешендә алга таба вакытлы матбугат этәргеч көчкә әверелгән.

Әлбәттә, тәнкыйть белән баштарак тирән белемле шәхесләр шөгыльләнә һәм адресат сыйфатында алар шулай ук әдәби хәзерлекле укучыны күздә тота, шунлыктан беренче гыйльми эчтәлекле язмалар иҗтимагый-фәлсәфи китапларга кертелә яисә әдәби тәнкыйть эстетика, сәнгать турында статьялар эчендәге карашлар җыелмасы буларак чагылыш таба. Кайда гына, нинди генә күләмдә дөнья күрмәсен, сөйләнмәсен, башка кешеләргә җиткерелгән тәнкыйть сүзе теге яки бу фикерләрне уздыру, халык эчендә, аерым бер даирәләрдә тарату чарасына әверелә.

Татар әдәби тәнкыйтенең тарихына күз салсак, аның язмышы милләт, шул милләтнең вакытлы матбугаты язмышыннан

аерылгысыз икәнлеге күзгә ташлана. Ул башта XIX–XX гасыр чикләрендә әдәби-фәнни «салон»нарда әйтелгән тәнкыйть, түгәрәкләрдә яңгыраган хөкеми чыгышлар, авторның үз китапларына урнаштырылган хатимәләре, мөкаддимәләре, чыгачак продукциягә реклама-аннотацияләр, чит матбугатта, цензура архивларында теркәлгән фикерләр рәвешендә яши. Беренче газета-журналларга рөхсәт алыну белән исә, зур дулкын шикелле, матбугат битләренә бәреп чыга.

XIX гасыр ахырына кадәр интеллектуаль мөмкинлеге булып та, милли фәнгә иреге чикләнгән татар зыялылары әдәби тәнкыйтькә халыкның алга китешенә тәэсир итәрлек бер көч дип карый. Универсаль шәхесләр булган укымышлылар барысы да язу белән шөгыльләнә, үз алларына фәннәрне татар телендә үстерү бурычын куя. Шушы чорда рус газета-журналларында да, төрки матбугатта да татар әдәбиятына карата кызыксыну арта.

Татар әдәби тәнкыйтен формалаштыруга зур өлеш керткән кешеләрнең берсе – һичшиксез, алдарак телгә алынган шәхес – Бахчасарай шәһәрендә «Тәрҗеман»ны чыгарган И. Гаспринский. Аның газетасында ана телебездә дөнья күргән һәр мөһим яңа хезмәт хакында бер-ике сүз булса да язылмый калмый: я кече күләмле мәгълүмат җиткерелә, я әсәргә рецензия урнаштырыла, я тәнкыйтьчеләр «әдәби бәхәсләр» рәвешендәге рубрикаларда аналитик язмалар белән чыгыш ясый.

Гасыр башында үтә сәяси эчтәлектәге периодика битләрендә дә әдәбиятка, аны бәяләүгә зур игътибар бирелгән. 1907 елның беренче гыйнварыннан дөнья күрә башлаган «Урал» газетасы үзенең тәүге номерында эшчәнлек программасын бастырып чыгара. Анда түбәндәге юллар бар:

«Әдәби кыйсьмендә: фельетоннар, шигырьләр, хикәятләр; фәнни кыйсьмендә: икътисади, сәяси мәсьәләләрдән, тарихтан һәм башка фәннәрдән мәкаләләр.

...Яңа чыккан китаплар һәм аларга тәнкыйть».

Тәнкыйтьне, әле генә китап базарына чыгарылган матур әдәбиятка гаид аннотацияләрне аерып алып күрсәтү, фәннәр һәм әдәбият җөмләсеннән генә карап узмау гасыр башында бу эшнең ни дәрәҗәдә мөһимлеген аңлауны, яңа өлкәнең махсус сыйфатламалары барлыкка килә башлауны күрсәтә.

Тәнкыйтьнең махсуслашуы аны чагылдырачак периодика тууны таләп итсә дә, төрле фикергә ирек зуррак һәм билгеле бер

дәрәҗәдә икътисади мөмкинлекләр дә булган гасыр башында да бу тормышка ашмый кала, чөнки әле сәяси көрәш дәвам итә, аның чишелеше беренче урынгарак чыга.

Вакытлы матбугат органнарының махсуслашуы укучылар катламын төркемнәргә аера, һәрберсенең үз аудиториясен барлыкка китерә. Бигрәк тә иҗтимагый-сәяси эчтәлектәге газета-журналларның укучылар саны күп була, һәм аларда тәнкыйтькә багышланган рубрикалар урнаштыру пропаганда челтәрен киңәйтә. Илебездә әдәбият сөючеләрнең күплеген истә тоткан мөхәррирләр үзләре җитәкләгән периодик басмаларда нәфис текстларга, әдәби барышка кагылышлы язмаларга нинди дә булса мәйдан бирми калмый, чөнки аларда җәмгыятькә, көнкүрешкә, теге яки бу сәяси хәлләргә дә караш-фикерләр белдерелә.

Тәнкыйть һәм әдәбият үсешен чын-чынлап кайгыртуны алга куеп ачылган махсус органнарның укучысы бик күп була алмый. Шул ук вакытта аларның барлыгы зыялыларның тәнкыйтькә, әдәбиятка, ул хезмәт иткән кешегә һәм милләткә хәер-хаһлы мөнәсәбәтен, әдәби-иҗтимагый позициясен ача; тәнкыйтьнең теге яки бу халыкта фән буларак мөстәкыйльләшү дәрәҗәсен; әдәбият үсешен чагылдыра – гомумиләштереп әйткәндә, мәдәни-тарихи тирәлектәге социаль-тарихи вазгыятьне күрсәтеп тора.

Язучылар бүгенге татар дөньясында чишелеше оператив хәл ителергә тиешле мәсьәлә буларак күтәрсәләр дә, нәкъ менә тәнкыйтьчеләр генә чыгыш ясый торган газета-журналлар ачылмый, аның каравы фәнни академик басмаларның саны арта бара. Югары уку йортлары фәнни-гамәли конференция материалларын туплап бастыра, бер-бер артлы монографик пландагы хезмәтләр дөнья күрә. «Фән һәм мәктәп», «Фәнни Татарстан», «Безнең мирас» һәм башка гыйльми, әдәби-гыйльми, фәнни-популяр журналларда тәнкыйтькә багышланган язмаларның даими урын алуы заманыбызның уңай күренеше дип бәяләнерлек.

Тәнкыйтьнең пропаганда чарасы вазифасын башкаруы үз битләренә аңа урын биргән вакытлы матбугат органнарының максат-бурычларыннан ук килеп чыга. Пропаганда функциясе агитация функциясе белән тыгыз бәйләнештә яши, әмма тәңгәл килми. Соңгысы халыкта теге яки бу кыйммәтләр ориентиры формалаштыруны үзмаксат итә, ә алар әдәби барыштагы тәгаен фактларны анализлау, бәяләү вакытында туа, тәнкыйтьче бу

эшләрне үзе генә башкарып калмый, укучыны да актив кабул итүгә этәрә.

Бер төр әдәби күренеш-хәлләр турында даими сөйләп тору, ягъни аларны һәрвакыт пропагандалау үзе дә агитация рәвешен алырга мөмкин. Әдәби әсәрләрне пропагандалаганда, кайсыдыр эстетик идеалларга йөз тоту вакытлы матбугат органнарын гамәлгә куючыларның ихтыяҗы я булмаса редакция коллективының уртак эстетик зәвыгы, дөньяга һәм әдәбиятка карашлары белән билгеләнә.

Газета-журнал редакцияләрендә, әдәбият-фән, шул исәптән тәнкыйть бүлекләрен электә язучылар үзләре яисә махсус белгечләр җитәкли, бу турыдан-туры тәнкыйтьнең объективлыкка, фәннилеккә, актуальлеккә, заманчалыкка омтылышына, шул ук вакытта кайчак кеше факторына бәйле субъективлыгына да китерә иде. Соңгы вакытта әдәбият бүлеге мөдирлегенә журналистлар куела башлады, һәм бу күренеш вакытлы матбугат эчтәлегендә үзен тиз арада сиздерде дә. Дөнья күргән нәфис текстларның сыйфаты төште, редакияләнү дәрәҗәсе йомшады, әдәби тәнкыйтькә мәйдан киселде.

Язмалары күпчелеккә укылышлы һәм ямьсез күренешләрнең сатирага алынуыннан тәм тапкан укучыга кызык булсын дип, әдәбият белән шөгыльләнүче тикшерү объектына берьяклы якын килергә тиеш түгел. Аның хурлауда да, мактауда да чама хисен югалтмавы, заман күренешләрен дөрес тотып алуы, аудиторияне, аның ихтыяҗларын, фәнни терминологияне нинди күләмдә кабул итәргә хәзерлеген ачык күзаллавы мөһим.

Бүгенге көндә иҗтимагый карашларны формалаштыруда, вакытлы матбугаттан битәр, радио-телевидение, бигрәк тә интернет челтәре зур роль уйный. Аның аудиториясе бик киң, шунлыктан үтә чуар да. Киң публикага адресланган телетапшыруларда чыгыш ясаганда әдәбиятны уртачарак белгән, аңа зәвыгы артык югары булмаган укучылар катламына йөз тотсаң да, әдәбият-тәнкыйтькә махсус электрон газеталарга, сүз сәнгатен яктыртуны алга куйган сайтларга язганда, әдәбият-сәнгать сөючеләрнең тар төркемнәрендә фикер алышканда, кайвакыт эфирның аудиториясе чикләнгән махсус тапшыруларында катнашканда, бу принциптан читкә китәргә кирәк. Тәнкыйтьнең төп вазифасы югары мәдәниятлы, зәвыклы укучылар катламы тәрбияләү, язучыга киңәш бирү, асыл әдәбиятны яраткан төркемнәрне сүзгә игътибар кимегән заманда саклап калу икәнне бервакытта да онытырга ярамый.

Вакытлы матбугатның ялкынлы корал булуын кайбер язмаларның хәтта халыкны кузгатып җибәрә алу очраклары ук күрсәтеп тора. Шуны белгән тәнкыйтьчеләр үз хезмәтләрен каләм ияләрен – теге яки бу тенденцияләргә йөз белән боруда, ниндидер идеяләр тирәсендә бергә туплауда, шуларга хезмәт иттерүдә куллана. Гомумиләштереп әйткәндә, пропаганда һәм агитация чарасын башкарган әдәби тәнкыйть кешеләрне билгеле бер гамәлләргә оештыру чарасы булып китә.

Совет чорында периодиканың пропаганда һәм оештыру сыйфатларыннан бик оста файдаландылар. Тәнкыйтьчеләр әдәбияттагы, әдәби барыштагы кирәксез һәм чит дип кабул ителгән күренешләргә – тискәре, ә идеология кысаларыннан чыкмаганнарына уңай мөнәсәбәт формалаштырдылар. Мәсәлән, укучыны Г. Исхакый, Г. Рәхим кебекләрнең иҗатларыннан читләштерделәр, милли хисләрне алгарак куеп язган әдипләргә карата массакүләм кире кагу хисләре тәрбияләделәр. Моның мисаллары шактый. Егерменче еллар башында Г. Ибраһимовның «Кара маяклар һәм Ак әдәбиятлар» дигән китабы дөнья күрә, әдип шул темага докладлар да укый, һәм шунда ук «Татарстан»да бу хакта информацияләр басыла (1924. № 77, 82, 91). Беләбез ки, Г. Ибраһимов язмасының хәтта атамасы гына да халык игътибарын җәлеп итә, ә эчтәлеге аерым бер әдипләр иҗатына субъектив булган карашларны җәелдерә.

Кире каккысыз факт: кайвакыт талантлы каләм ияләре аңсыз рәвештә дә чор сәясәтенә бирешәләр, хакимлек иткән идеологияне, әдәбияттагы тискәре күренешләрне пропагандалый башлыйлар. Ә. Фәйзинең революциядән соңгы тәнкыйтьди эшчәнлеген чагылдырган бер язмасында Н. Юзиев түбәндәгеләрне әйтә: «Аның бу еллардагы аерым мәкалә-рецензияләрендә шул чорда хөкем сөргән РАПП установкаларына ияреп туган кайбер хата карашларны да очратырга мөмкин. Әйтик, революциягә кадәрге әдәбиятның иҗат методын буржуаз реализмы дип билгеләү, яисә революциягә кадәрге татар музыкасын тулаем милли буржуазиягә генә хезмәт иткән дип санау – әнә шул карашларның тәэсирен чагылдыра иде»[1].

Язучылар бастырган мәкаләләрнең оештыручанлыгы укучылардан килгән хатларда да күренә. Бу уңайдан, Н. Юзиевнең шул

---

[1] Юзиев Н. Әхмәт Фәйзи – тәнкыйтьче // Әдипнең эрудициясе. Б. 5.

ук мәкаләсеннән бер өзек китерик: «„Әдипнең эрудициясе“ исемле мәкаләсе „Литературная газета“да басылып чыгу белән, Әхмәт Фәйзигә укучылардан күп хатлар килә. Алар мәкаләне ошатулары турында язалар һәм, үзлегеңнән укып, эрудицияне тирәнәйтү турында киңәшләр сорыйлар. Хәлбуки бу мәкаләдә әдипнең эрудициясе турында сүз бара. Мәкалә укучыларда гына түгел, әдәбият һәм сәнгать җәмәгатьчелегендә дә тирән кызыксыну уята»[1].

Әдәби тәнкыйтьнең пропаганда, агитация, оештыру чарасы икәнлеген күздә тотып, аның алдына түбәндәге бурычлар куела:

– әдәбият, әдәби тәнкыйть өлкәсендә алга этәргеч булырлык уңай күренешләрне, сәнгатьчә камил һәм гуманистик идеяләргә, әхлаклы кеше формалаштыруга хезмәт иткән әсәрләрне пропагандаларга;

– массаларда әдәби зәвыкны үстерүгә, китап продукциясенең сыйфатлы булганына ихтыяҗ тудырырга;

– китап укучыда әдәбияттагы уңай күренешләр сагына басу теләге уятырга.

Бүгенге тәнкыйть вәгазьчелектән ерак тора. Ул укучыны әдәби әсәрнең барлык аңа ачылып бетмәгән якларын яктырту, үткенәйтелгән анализ бирү аша тәрбияли. Әдәби күренешләрне туплау һәм нәтиҗәләр чыгару аудиториядә тормыш-яшәеш кануннарына карата да фикерләр формалаштыра.

Вакытлы матбугат язучы-шагыйрьләрнең, драматургларның, галимнәрнең тормыш юлын чагылдыру, алар хакында мәгълүмат җиткерү чарасы булып тора. Бу төр язмалардан укытучылар – дәресләрдә, тәрбия сәгатьләрендә, ә мәдәният хезмәткәрләре, тәрбиячеләр төрле чаралар уздырганда файдалана. Газета-журналлар укучы һәм язучы арасында арадашчылык итә, аларны үзара аңлаштыра, бәхәсләштерә. Әдәби бәхәсләр башка укучыларны да хакыйкатькә якынайта, аларның эрудициясен арттыра. Вакытлы матбугатның системалы таралуы тәнкыйтьнең өзлексез яшәвенә китерә, ул аның пропаганда, агитация, оештыру вазифаларын да системалаштыра.

Көндәлек, айлык басмаларда дөнья күргән язмаларның популярлыгы еш кына авторның язучы яисә җәмәгать эшлеклесе, галим буларак танылуына да бәйле. Укучы Т. Миңнуллин, А. Хәлим, Ф. Бәйрәмова, И. Низамов, Ф. Баттал, З. Зәйнуллин кебекләрнең

[1] Юзиев Н. Әхмәт Фәйзи – тәнкыйтьче. Б. 8.

язмаларын, теге яки бу күренеш турында алар нәрсә әйтә икән, дип кулга ала, кайберәүләрнең тирән эчтәлекле мәкаләләрен дә кайвакыт укымый китә. Бу хәлләр авторларга шундый бер сабак бирә: тәнкыйтьтә бервакытта да дәрәҗә ярлыгына тап төшерергә, чиле-пешле язмалар язып, укучының гайрәтен чигерергә ярамый.

Вакытлы матбугат әдәбиятка, аны чагылдырган тәнкыйтькә хезмәт иткән кебек, тәнкыйтьчеләр дә периодиканың аудиториясен арттыру, аларда теге яки бу органга мәхәббәт тәрбияләү ролен башкара. Укучының күзаллауларын киңәйтү аркылы аны башка төр материалларны да кабул итүгә хәзерли. Тормышны чагылдыруның үзенчәлекле чарасы булган матур әдәбиятны яхшы аңлаган кеше социаль тормыш, сәяси хәлләр хакындагы язмаларны укып та тәэсирләнәчәк, тулы эстетик кичерешләр дөньясына чумачак.

Теләсә кайсы иҗтимагый күренеш, кеше тормышындагы эш-хәлләр эстетик һәм этик, иҗтимагый мәгънәгә ия икән, этик-эстетик һәм иҗтимагый функцияләр башкарган әдәби тәнкыйть матурлык һәм ямьсезлек, түбәнлек һәм югарылык кебек эстетик категорияләр яссылыгыннан бәяләнә ала. Сәнгатьнең гуманлылыгы сагында торган фән буларак, ул кешеләр арасындагы гуманистик мөнәсәбәтләр сагына да баса.

## 4.2. Тәнкыйтьченең һөнәри әхлагы

Тәнкыйтьче җәмгыятьтә ныгып урнашкан әдәп-әхлак кагыйдәләре белән һәрвакыт хисаплаша. Әхлакны исә гамәли философия – этика фәне өйрәнә[1]. Бик күп фәннәрнең тарихы ерак чорлар белән бәйләнә, этиканың килеп чыгышы, мәсәлән, Аристотель заманнарына барып тоташа. Норматив фән булган этиканың предметы турында уйланулар «бәхет һәм мәрхәмәтлелек (добродетель) мөнәсәбәте, шәхси һәм социаль этика; мораль мотивлаштыруда акыл һәм хис; кешенең үз-үзен тотышында ирек һәм кирәклек нисбәте кебек үтәли проблемалар» тирәсендә туплана[2].

Е.В. Золотухина-Аболина, әхлак – индивидуаль кешенең характеристикасы да, берьюлы күп кешегә (төркемгә, җәмгыятькә, халыкка, кешелеккә) хас булган күзаллаулар да, телибезме без,

---

[1] Этика: энциклопедический словарь: под ред. Р.Г. Апресяна и А.А. Гусейнова. М.: Гардарики, 2001. С. 573.

[2] Шунда ук. С. 580.

юкмы, ул һәрчак – социаль феномен, иҗтимагый аң төре, социомәдәни тормышның рухи-гамәли сфреасы, дип белдерә[1].

Әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнүченең әхлагы турында фикер йөрткәндә, *фән этикасы* хакында сүз алып барыла: фәннең һәм фәнни эшчәнлекнең мораль нигезләре, тәнкыйтьчеләрнең үзара, халык, иҗатчылар белән мөнәсәбәтләре күздә тотыла.

Һәрбер профессия үз ияләре алдына төрле таләпләр куя. Табиблар, укытучылар һәм башкалар өчен язылган һәм язылмаган кануннар яши. Элек-электән халык арасында «сәүдәгәр сүзе», «табиб намусы», «рухани әхлагы», «педагог йөзе» кебек гыйбарәләр таралган. Шул ук вакытта кеше мәнфәгатьләрен күздә тотып барлыкка килгән теләсә кайсы фән «зыян салма» дигән гап-гади бер принципка нигезләнә.

Бик борынгы заманнардан ук һәр эшчәнлекне әхлакый ноктадан анализларга омтылганнар. Фәннәрне этик бәяләү турында бигрәк тә Икенче бөтендөнья сугышыннан соң ныклап фикер йөртә башлыйлар, чөнки, тормыштагы тискәре күренешләр, яулап алу сугышлары артында фәнни эшчәнлек, фән-техника революциясе тормыймы икән, дигән сорау туа. Һәм галимнәр фәнни эзләнүләр юлында социаль, әхлакый җаваплылык мәсьәләсен күтәреп чыга. Бу гуманитар өлкәләргә дә кагыла.

Төрле фәннәргә, аларның этик эчтәлегенә якын килү бердәй була алмый, шунлыктан әкренләп этика фәненең аерым тармаклары формалаша. Әхлакның һөнәргә бәйле үзенчәлекләрен ачу белән һөнәри этика шөгыльләнә. Тәнкыйтьче язган материаллар вакытлы матбугатта дөнья күргәнгә, аңа мөнәсәбәттә, еш кына публицист яисә журналист этикасы турында сүз алып барыла; әмма тәнкыйтьче әхлагы журналистлык әхлагы сыйфатында гына бәяләнә алмый, күпкә киңрәк төшенчә буларак яши.

Педагоглар, хөкемдарлар, табиблар этикасының тарихы шактый озын. Тәнкыйтьче этикасының тарихы да журналист этикасыныкына караганда озынрак, һәм бу аерма әлеге һөнәрләрнең барлыкка килү вакыты белән билгеләнә.

Профессиональ әдәп әхлакның гомуми нормаларын билгеле бер өлкәгә бәйле тәгаенләштерә. Д.С. Авраамов «Профессиональная этика журналиста» китабында журналистлар өстеннән

---

[1] Золотухина-Аболина Е.В. Современная этика: истоки и проблемы. Ростов н/Д.: МарТ, 2000. С. 59–60.

шикаятьләргә С. Худяков уздырган анализ вакытында бу һөнәр иясенә мәҗбүри булган әхаклый сыйфатлар арасында күпчелекнең гаделлек һәм объективлыкны беренче урынга куйганы ачыклanганны әйтә. Ул, журналистларның үзләреннән сораштыру да шуны сөйли, һәм аларның укучыларныкы белән фикер уртаклыгы төп характеристикага бәйле генә туры килә, ә калган әхлакый сыйфатлар иерархиясе башкача төзелә, дип белдерә[1].

Төрле бәйләнешләр даирәсендә журналист аңлавында укучы белән үз мөнәсәбәте беренче урында торса, нәкъ менә әдәбиятны яктыртучы кеше, аерым алганда тәнкыйтьче өчен бигрәк тә аның каләм иясенә карата кылган гамәлләре – аны шәхес буларак рәнҗетмичә сүз әйтүе, язучыга каләмен камилләштерүдә ярдәм кулы суза алуы, әдәбият мәйданында үз урынын табарга булышуы, ул катнашкан бәхәсләр вакытында дөреслек тарафына басуы мөһимдер. Нәфис иҗат белән шөгыльләнүчеләр исә тәнкыйтьче әхлагын аның әдәбиятны һәм аерым бер иҗатны, әсәрне объектив яктырту-яктыртмавы аша бәяли.

Әдәбиятның идея-сәнгатилек дәрәҗәсе – тәнкыйтькә куелган критерийларның берсе. Хәтта ки шуңа ирешү дә тәнкыйтьче әхлагының үзенчәлекле чагылышы булып тора. Фәнни хәзерлексез, әдәби күренешләрдән хәбәрсез килеш, шуларны чагылдырырга алыну кешенең үзе һәм башкалар алдында әхлакый җавапсызлыгын күрсәтә.

Тәнкыйди язмаларга этик күзлектән якын килүнең жанр формаларына бәйле аермасы да барлыкны әйтергә кирәк. Әдәби портретларда, био-библиографик язмаларда, иҗат лабораториясен ачкан хезмәтләрдә язучының сер рәвешендә генә әйткән информациясен куллану, үзе исән чагында, рөхсәт алмый торып, аның шәхси, бигрәк тә интим тормышына тыкшыну шулай ук – әдәпсезлекнең бер чагылышы.

Җитди һәм фәнни булыр дип көтелгән чыгышларны юмор-сатира алымнарына кору да кайвакыт – тамашачы, ә кайвакыт докладларда телгә алынган әһле каләм тарафыннан әдәпсезлек сыман кабул ителә. Әйтик, үзара шаярып сөйләшүчән язучылар, гомуми җыелышларда әдәби барышка күзәтү ясаганда, каләмдәшләрен дусларча «чеметкәләп», «төрттергәләп» алырга яраталар, әмма бу

[1] Авраамов Д.С. Профессиональная этика журналиста. М.: Изд-во Моск. ун-та, 2003. С. 29, 30.

төр «шаяртулар»ны адресатлар арасыннан тыныч кабул итүчеләр сирәк. Аеруча телдән тәнкыйтьтә әдәби геройны, бигрәк тә лирик минне авторның үзенә тиңләп мыскыллаулар еш күзәтелә, чөнки шундый рухта ясалган чыгышларның залга тәэсире көчле була. Эффектлылык артыннан куган докладчылар талантлы кешеләрне рәнҗетәм дип башына да китерми. Юмор-сатирада, мәсәлән, жанры автор тарафыннан пародия дип билгеләнгән кайбер әсәрләрдә, еш кына теге яки бу текстка хас җитешсезлекне тәнкыйтьләү бөтенләй булмыйча, автор шәхесеннән көлү генә күзәтелә. М. Галиевнең «Язмышка рәхмәт» исемле бер сәяхәттән этәрелеп китеп язган эссесында саксыз яисә урынсыз сүз әйтеп рәнҗетү уңаеннан мисалга китерерлек мондый юллар бар:

«Ел йомгагы вакытында Тукай клубы мөнбәреннән Разил шигърияткә багышланган доклад сөйләгән иде. Шунда ул Сибгат ага Хәкимнең, авылга кайтып, җим чүпләгән тавык кебек йөрүе хакындагы дүртьюллык шигырен мисалга китергән иде. „Минем бер дә аксакалыбыз Сибгат аганы тавык белән чагыштырасым килми, хәер, ул үзен миңа караганда яхшырак беләдер...“ – дигәч, зал ду кубып көлгән иде. Сибгат аганы үпкәләтүе дә ихтимал иде югыйсә, әмма залны көлдерәчәк эффектны югалтасы килмәде. Разил шуннан соң берничә ел Язучылар союзы әгъзасы булып раслана алмады. Сибгат ага кабул итү комиссиясе рәисе иде»[1].

Язмаларының принципиальлек, гражданлык хисләре, үз-үзенә таләпчәнлек белән башкарылуы, фикерне җиткерүдә мәдәни алымнарга таяну тәнкыйтьченең аңлылык дәрәҗәсенә, кеше буларак яшәү һәм хезмәт итү позицияләренә бәйле. Ул эстетик сукырлыгын, тәнкыйтьтә гаделсезлеген, әдәпсез адымнар ясавын вакытында күреп алырга, укучысы һәм иҗатчы алдында гафу үтенә белергә тиеш. Сәнгатьчә анализ вакытында фәнни критерийлардан китү аны һәрвакыт авыр хәлләргә куячак.

Тәнкыйтьче әдәбиятның югары художество эшләнеше, гуманистик асылы сагында торган кебек, тәнкыйтьне дә шул рәвешчә сакларга, шул нокталардан үстерергә омтыла. Әдипкә яла ягу, аның хакында язганда әдәпсез сүзләр куллану, фикер җиткерүдә дорфалык, махсус өзекләр сайлау белән, ялган карашлар уздыру кебек күренешләр бер генә тәнкыйтьчене дә бизәми. Башкалар

[1] Галиев М. Язмышка рәхмәт // Галиев М. Сайланма әсәрләр: 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. Т. 4. Б. 283.

иҗатын өйрәнүче ул иҗат артында аны сөйгән меңнәрчә кешеләр торганлыгын, укучының әдип язган телдә тәрбияләнүен онытмаска тиеш.

Әдәби объектны сайлауны да тәнкыйтьче этикасы белән бәйләп карарга мөмкин. Азгынлыкны пропагандалаган, үз милләтенең яшәешенә балта чапкан әсәрләрне мактаган, күптөрле җитешсезлекләрен күрмәскә тырышкан, әдәбияттагы тискәре күренешләр белән килешкән әдәбиятчыны да әхлаклы дип санап булмый. Лаексызларга мактау өләшкәннәрнең, түрә әдипләр хакында гына язганнарның да әхлакый йөзе саф түгел.

Кыскасы, тәнкыйтьчедән корректлылык, дөрес фактлар һәм гадел шәрехләр бирү, әдәби әсәрнең эчтәлеген хаксыз рәвештә язучының шәхси сыйфатлары белән бәйләп карамау, аның иҗатын тәрҗемәи хәле генә дип күрмәү, авторны шәхес буларак түбәнсетмәү юлыннан бару һәм намуслылык таләп ителә. Ул, әдәби берәмлек белән турыдан-туры эш йөртеп, аның хакындагы фикерләрне җәмгыятьтә яшәгән әхлак нормалары кысасында халыкка җиткерә. Тәнкыйтен башкалар өчен язган әдәбиятчы әйтелгән сүзгә сизгер әдип, укучысы, милләте, аның киләчәге һәм үзе яшәгән җәмгыять алдында һәрвакыт җаваплы. Ул аларга гына түгел, иленә, аның тарихына, шуның бер өлеше булган әдәбият тарихына да ихтирам сакларга тиеш. Кешене иҗтимагый бурычларына аңлы якын килүе, актив позициясе шәхес югарылыгына күтәрә.

## 4.3. Тәнкыйтьченең әхлакый позициясе

*Һөнәри әхлаклылык* турында сүз рухи кыйммәтләр ноктасыннан алып барыла. Әлеге кыйммәтләр кешене теге яки бу күренешкә карата билгеле бер позициягә бастыра һәм ике яклы – беренчедән, *социаль*, икенчедән, *шәхси* тәҗрибә юлы белән тупланган кыйммәтләр булып тора. Шәхескә хас әхлаклылык төрле яссылыкларда чагылыш таба. Ул *карашлар формасы, инанулар тупланмасы, әхлакый кичерешләр* һәм *ихтыяҗлар, таләпләр* рәвешендә яши ала.

*Әхлакый карашлар* – тәнкыйтьченең җәмгыять куйган таләпләргә мөнәсәбәте, шәхеснең ихтыярый кабул иткән үз-үзен тоту нормалары ул. Алар кешедә принцип дәрәҗәсенә күтәрелгән тотрыклы сыйфатлар формалаштырырга булыша. Әйтик, шәхес йомшак күңелле, миһербанлы, көнчел, ярдәмчел һ.б.ча була ала.

Әхлакый инанулар *әхлак нормаларын* һәм *рухи кыйммәтләрне* белүгә нигезләнә. Бу кыйммәтләр *гомумкешелек кыйммәтләре* *яисә* аларга каршы килмәгән, рухи байлыкны гуманистик ноктадан тагын да үстергән *милли-мәдәни кыйммәтләр* булырга мөмкин. Нәкъ менә инанулар кешедә хаклык хисен ныгыта, каләмен үткен, сүзен укучыны инандырырлык итә. Инанган шәхес үзен һәрвакыт дөрес дип саный. Әхлакый инанулар тәнкыйтьченең өлешчә – язу рәвешен, холык сыйфатларын, укучыга һәм авторларга карата кылган гамәлләрен билгели.

Яшәү мәгънәсе, ирек, бәхет иң *югары әхлакый кыйммәтләргә* керә. Кеше гомер буе шулар турында уйлана, аларның эчтәлегенә бәйле сорауларга җавап табарга тырыша. Югары әхлакый кыйммәтләр үз эчләренә әхлакның барлык категорияләрен дә сыйдырып бетерми. Аларга әле яхшылык һәм явызлык, ирек янәшәсендәге җаваплылык, бурыч, намус, оят, гаеп, намуслылык һәм гаделлек, Кеше булу хисе, мәхәббәт тә керә. Бу төшенчәләр һәрвакыт антиномик парлар хасил итә һәм *әхлак кагыйдәләре*н нигезли. Җәмгыятьтә хөкем сөргән әдәп нормалары шәхес тормышында кулланган кагыйдәләр белән тәңгәл килмәскә дә мөмкин, чөнки һәр кеше югарыда саналган категорияләргә үзгәрәк эчтәлек сала.

Әхлакый инанулар төрлечә формалаша. Берәүләр авторитетлар әйткән сүзләргә сукырларча табына, икенчеләр аларга тормыш сынаулары аша килә, өченчеләр чынбарлык күренешләрен тирәнтен анализлау юлы белән ирешә. Күпчелек очракта кеше үз тормышында аларның һәрберсен файдалана. Әхлакый инануларның хаклык дәрәҗәсе төрлечә. Ул заман идеологиясенә, аны тормышка ашыручыларның эш итү алымнарына, тирә-юньдәге реаль шартларга бәйле.

Үзгәртеп кору елларында һәм аннан соң да тәнкыйтьнең йомшак булуы кешеләрнең идеологик ориентирларын, гомумән, инануларын югалтуларын да чагылдыра. Тормышта ныклы позицияле, милләтне яшәтү, аның әдәбиятын, фәнен үстерү кирәклегендә шикләнмәгән Р. Сверигин, Ф. Бәйрәмова, Р. Рахман, С. Хафизов кебекләрнең әдәбият хакында чыгышлары, аңа кагылышлы язмалары һәрвакыт үткен, ышандыру көченә ия һәм халыкта төрле бәхәсләр уятып җибәрүгә сәләтле булды. Оппонентларының чыгышында еш кына нинди бизмән белән үлчәү аңлашылмады, башкалар исеменә ышыкланып тәнкыйтьләсәләр дә, мәкаләләреннән шәхси

мәнфәгатьләр тоемланды. Инанулары нык кешеләргә каршы тору, хәтта алар каләменнән бик күп хата фикерләр чыкканда да, шундый ук инануларга ия булу кирәклеген тагын бер кат күрсәтте.

Бүгенге кеше – зыялымы ул, башка бер социаль төркемнәнме – элеккечә яшәргә теләми, әмма күпләрнең хәзергебездән дә күңеле кайткан, якты киләчәккә өмете киселгән. Моны интернет челтәрендәге бик күп язмалар ачык күрсәтә. Илбашчылар алып барган сәясәт даими үзгәреп торган һәм милли мәсьәләләрнең хәл ителешенә юл ныклап киселә башлаган шартларда, чыннан да, татар кешесеннән милли барышның, әдәби барышның киләчәгенә зур өметләр таләп итү, аны шул өметләрнең чынга ашасына ышандыру бик авыр. Халыкны, кыю һәм тугры сүз белән, артларыннан иярттергә тиеш татар зыялылары еш кына үзләре дә рухи терәккә, халык ярдәменә мохтаҗ булып кала. Алар, ашкынып, тәм табып иҗат итәр өчен дә, әсәрләренең укучысын табарына, тәнкыйтьнең гадел бәясен аласына ышанырга тиеш.

Икенче яктан, әдәбиятың нинди, аның тәнкыйте дә шундый. Без еш кына сүз сәнгатенең барышын дөрес яктыртырлык, аерым әсәрләргә объектив бәя бирерлек тәнкыйтьчеләр юклыгы хакында сөйләшәбез, шул вакытта үз-үзебезгә, әдәбият үскән этапларда тәнкыйте дә үскән бит, димибез. Әдәби тәнкыйть тә, әдәбият та – бер үк хәл-күренешнең ике ягы. Алар бер-берсен үстерешә.

XX гасыр ахырында татар сүз сәнгатенең корифейларын, исән чагында ук классик булып йөргән язучыларын күпләп югалтуы, әдәби казанның сыекланып калуы әдәби җәмәгатьчелектәге, бигрәк тә каләм ияләрендәге милли иҗади потенциалның яңадан тулыландырылуына өметне сүрелдерде. Алмашчылар арасында прозага килүчеләрнең азлыгы, яшьләр шигъриятенең бертөслелеге һәм башкалар әдәбият язмышы өчен кайгыручыларда пессимистик тойгылар уятты.

Инанулар кешедә комплекс хәлендә яши. Үз-үзенә инанганлык кешенең ныклы бер сыйфаты булырга мөмкин. Андыйларның әдәби тәнкыйть язмаларында да әйткәннәренең хаклыгына бик чынлап ышанганнары, ниндидер мәкер белән язмаулары ачык күренә. Татар тәнкыйтьчеләреннән бигрәк тә И. Нуруллин каләмдәшләре алдында ясаган чыгышларында үз фикеренә нык ышанып сөйли һәм, үзенә каршы төшүчеләр булганда да, аннан кире кайтмый иде. И. Гази, Ш. Әхмәдуллин һәм башка кайберәүләрнең тәнкыйть язмалары шулай ук авторларның чын күңелдән әдәбият язмышын

кайгыртканнарын күрсәтеп тора. Тәнкыйтьченең хаталануын да укучы ихластан әйтелгән сүз булса кичерә, аңлый.

Әхлакый инанган кешеләргә еш кына принципиальлек хас. *Әхлакый принципларга* ия булу тулаем *мораль ориентлашуны* күрсәтә. Тәнкыйтьче, әйтик, мәкаләләрен эгоистик тойгылардан чыгып, аерым бер төркем мәнфәгатьләрен генә яктыртып язарга мөмкин. Кайберәүләрдә бу принцип дәрәҗәсенә китерелгән була. Тәнкыйтьтәге төркем интересларын ачу кыен түгел. Мәсәлән, татар тәнкыйтенә хезмәт итүче кайбер ирләребез даими рәвештә хатын-кыз иҗатын түбәнәйтергә тырыша, бары тик ир-атларны гына мактап яза; болардан тыш, берничә язучыдан торган төркемнәр эчендә кара-каршы үзара макташу кебек күренешләр дә күзәтелә.

«Под моральными чувствами мы подразумеваем все такие чувства, которые испытываются человеком при восприятии им явлений действительности под углом зрения нравственного начала, отправляясь от категорий морали, выработанных обществом»[1], – дип яза П.М. Якобсон.

Һөнәри исемеңне пычратмау теләге кешене һәрвакыт дөрес булмаганны язудан, мескенне тәпәләүдән, чиле-пешле мәкаләләр бастырудан саклый. Дөрес, тәнкыйтьченең әхлакый позициясе үзенә генә дә бәйле түгел. Ул эш урынында, җәмгыятьтә, әдәби җәмәгатьчелектә хөкем сөргән кагыйдәләргә ярашырга, үзенә башкалар куйган таләпләрне үтәргә тырышырга һәм кайчак шуның белән бик нык ялгышырга да мөмкин.

Газета-журналларның иганәчеләре, аны гамәлгә куючылар, югары рәсми җитәкчелек, баш мөхәррирләр кайвакыт җәмгыятьтә үзен чагыштырмача иректе тоткан яисә иректе булырга тиеш кебек журналистларны да ниндидер кысалар эчендә язарга мәҗбүр итә. Азсанлы, дәүләт хисабына яшәгән татар матбугатында туры сүзле, милли идеяле мәкаләләрне бастырырлык орган табу кыен. Киләчәктә тәнкыйтьче булачак яшьләр, шуны белсәләр дә, үзләренең әхлак принципларына хыянәт итмәскә, көрәш юлына басарга, намуслылык сыйфатларын, иҗатчы дәрәҗәсен саклап калырга тиешләр.

Бу урында тәнкыйтьченең үзаңы турында да фикер йөртү файдалы. Билгеле бер принципларны алга кую кешенең үзен

[1] Якобсон П. М. Психология чувств. М.: Акад. пед. наук РСФСР, 1961. С. 210.

төркемнән аеруын, аның тәэсиренә сукырларча бирешмәвен сөйли. Үзаң шәхеснең бер сыйфатламасы булганга, икесенең дә формалашуы янәшә бара. Тәнкыйтьченең үзаңга иялеге, беренче чиратта, үз һөнәренә хас бурычларны, шул бурычлар куйган таләпләрне аңлавын, аларга хыянәт итмәвен күрсәтә.

Тәнкыйтьче, гадел позициядән торып хак хөкем йөртсә, киңкарашлы, эрудицияле булса, әдәби җәмәгатьчелек, автор, укучы белән зур конфликтка керми. Ф. Кузнецов әдәбият белән тәнкыйть арасындагы каршылыклар «чынбарлыкның сәнгати ачышлары», тормыш чынлыгы урынына, «искергән корылыш» белән тикшерелгәндә башлана, һәм «тәнкыйть үзенең әхлакый-интеллектуаль авторитетын югалта», ди[1].

Әдәбиятчының әхлакый позициясе иҗтимагый көрәшләрдә, кайнар бәхәсләрдә ачыклана, әдәбиятның сафлыгы өчен хезмәттә ныгый.

[1] Кузнецов Ф. С веком наравне: критика прозы. Критика критики. М.: Моск. Рабочий, 1981. С. 81.

# 5. ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ ЖАНРЛАРЫ

*Төрлелектән камил гармония барлыкка килә.*
Гераклит

Әдәби тәнкыйтьнең үсеш биеклеге, гомумән алганда, әдәбиятның, аның белән шөгыльләнүчеләрнең белем дәрәҗәсен чагылдыра. Әлеге үсешнең югарылыгы теге яки бу халыкның гуманитар фәннәр өлкәсендә ирешкән уңышларына бер дәлил булып тора. Әдәби тәнкыйтебезнең нәкъ менә татарның милли үзаңы югары вакытта фән сыйфатында формалашып җитүе, тәнкыйтьчеләрнең кайсы чор-елларда әдәби барышта һәм иҗтимагый-сәяси тормышта активлашуы – шулай ук игътибарга алынырлык фактлар.

Әдәби тәнкыйтьнең халыкка барып ирешүе өчен, мәйдан кирәк. Әлеге мәйданны аңа, беренче чиратта, вакытлы матбугат бирә, аннан инде ул башка басмаларда да дөнья күрә. Әдәби тәнкыйтьнең публицистиклыгы фәнни һәм сәнгати башлангычлар белән үзара тәэсир итешкән бик мөһим сыйфатыннан санала. Тәнкыйтьче үз язмаларында шәхес буларак ачыла, интеллектуаль-аналитик пландагы мөмкинлекләрен күрсәтә ала, иҗтимагый фикер формалаштыруда катнаша.

Вакытлы матбугатка материал хәзерләгән тәнкыйтьче аны күбрәк кемнәр алдыруны да, газета-журнал спецификасын да, баш мөхәрриренең әдәби тәнкыйтькә мөнәсәбәтен дә, нинди эчтәлектәге, рухтагы, калыптагы язмаларга урын бирү-бирмәвен дә истә тота. Димәк, ул баштан ук нәрсә турында, нинди жанрда һәм ничек язасын ачык күзаллый. Моның өчен аның әдәби тәнкыйть жанрларыннан, аның төрле формаларыннан хәбәрдарлыгы, алым-чараларын белүе һәм куллану осталыгына ия булуы кирәк.

## 5.1. Әдәби тәнкыйть жанрларын төркемләү

Сәнгатьтә, фәндә жанр төшенчәсеннән башка эш йөртеп булмый, тик тәнкыйтьтә әлеге терминны билгеләүдә аермалы карашлар хөкем сөргән кебек, классификацияләүдә дә бердәмлек күзәтелми. Әдәби тәнкыйть турында сүз алып барганда, берәүләр рецензия, проблемалы мәкалә, эссе кебек традицион жанрлар белән чикләнсә, икенчеләр, газета-журнал битләрендә урын алганнан тыш, радио-телевидение челтәреннән яңгыраган әдәбиятка кагылышлы кыска чыгышларны да һәм шактый үзенчәлекле башка формаларны да, әйтик, хәтта җөмлә-репликаларны да шушы өлкәгә кертеп карый. Без дә, кайберләренең публицистика белән тәнкыйть ызанында торганын, тәнкыйтьне калыплаштыручы төп форма түгеллеген таныган хәлдә, жанр челтәренең киңлеген яклыйбыз. Үзара сөйләшкәндә әдәбиятка бәйле әйтелгән сүзләрнең, архивларның магнитофон тасмаларына яздырылган чыгышларның, фикер-карашларның яисә вакытлы матбугаттагы, башка төр басмалардагы кече күләмле тәнкыйтьнең дә аерым очракларда әдәби барышны, иҗатчы яисә тәнкыйтьче күзаллауларын, әсәрне һ.б.ларны аңлауда бик мөһим булуы бар.

Жанр – әдәбият белеменә, сәнгатькә, эстетикага кагылышлы термин. Галимнәр аңа аң үсешенә бәйле *тарихи үзгәрүчәнлек, мәдәни хәтер* хаслык хакында язалар. Жанр төшенчәсен ачыклаганда, *тарихи, эчтәлеккә бәйле, статик* сыйфатламаларны исәпкә алалар. Мондый якын килү аларның үз эчендә дә иерархик система төзү мөмкинлеге бирә. Әдәби тәнкыйть фәнендә мәсьәләнең бу ягы хәзергә ныклап эшләнмәгән.

Сәнгатьтә, фәндә даими кабатланучы модельләр жанрлар системасын тәшкил итә. Әдәбият белеме термины буларак, ул XV гасырда Франциядә барлыкка килә һәм, кайбер русча сүзлекләрдә билгеләнгәнчә, тәрҗемәдә «төр»[1] (род) мәгънәсен аңлата. Татар галимнәре төзегән «Әдәбият белеме сүзлеге»ндә «төркем» дип татарчалаштырылган[2]. Н.Д. Тамарченконың «Теоретическая поэтика: Понятия и определения» хрестоматиясендә бирелгән билгеләмәләр эчендә аны «төркем» (вид), «тип» дип аңлатулар очрый.

[1] Жанр // ru.wikipedia.org.

[2] Әдәбият белеме сүзлеге: төз.-ред.: А.Г. Әхмәдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. Б. 52.

Әдәби төрләр үз эчләрендә дә дифференциацияләнә башлагач, жанр төшенчәсе шул аерымлануның бер баскычына карата кулланыла. Шунысы бар: татар әдәбият белемендә әлеге бүленешне терминнар аша чагылдыруда русчадан аерымлыклар күзәтелә, юкса тәңгәллеккә ирешү юллары ачык та кебек. Мәсәлән, без төркемләүне шушылай күрсәтә алыр идек: *төр – род, төркем – вид, жанр һәм жанр формалары.* Болай эшләү баскычлар санын арттыру, әле киләчәк гасырларда да жанр эчендә барачак мөстәкыйльләшүне чагылдыру мөмкинлеге бирә.

Эпос, лирика, драмадан торган беренче баскыч, үз эчендә бүлгәләнеп, икенче яссылыкны тәшкил итә: мәсәлән, драмадан трагедия, комедия, драма аерылып чыга. Вид урынына жанр төшенчәсен куллану татар әдәбият белемендә гомумкабул ителгән башка терминнарны да икенче төрле аңлауга китерә. Дөрес, рус гыйльмиятендә дә бу проблема тулысынча хәл ителмәгән. Әйтик, жанр еш кына ике мәгънәдә: род урынына һәм жанр сыйфатында кулланыла. Бу буталчыклык аның беренчел мәгънәсенең һаман саклануыннан килә. Әле бит киң пландагы әдәбиятның төрле өлкәләрен, мәсәлән, публицистиканы, әдәбиятны жанр дип атау да очраштыргалый; төр дигәндә, тезмә һәм чәчмә әсәрләрне күздә тоту да бар.

С. Калачева, П. Рощиннар төзегән белешмәлектә терминнар кулланышындагы төрлелек шушы рәвешчә тасвирлана: «Жанр (фр. genre – төр (род) /.../ кайбер галимнәр, сүзнең этимологиясеннән чыгып, әдәби төрләрне – эпос, лирика, драманы – шулай атый. Икенчеләре бу термин эчендә төр бүленгән әдәби төркемнәрне (роман, повесть, хикәя һ.б.) күздә тота. Болай аңлау, мөгаен, иң киң таралганыдыр»[1].

Күргәнебезчә, бүгенге көнгәчә, әдәби тәнкыйтьне генә түгел, ничәмә-ничә гасырлык тарихы булган әдәбиятны төркемләүдә дә бер фикергә килмәгәннәр, шунлыктан галимнәр ул юнәлештә һаман да эзләнүләрен туктатмый. Әдәбиятны Аристотель заманнарына барып тоташкан өч зур төргә аеру традициясеннән баш тартучылар да бар. XX гасырда аны психологик, лингвистик күренешләр, вакыт категориясе, рәссам кулланган эстетик гаммалар нигезендә төрләргә бүлү омтылышлары ясалды, әмма әдәбият белгечләре традицион

---

[1] Калачева С. Рощин П. Жанр // Словарь литературоведческих терминов. М.: Просвещение,1974. С. 82–83.

бүленеш үзен ныграк аклый, дигән караштa тора һәм шуңа таянуларын дәвам итә.

Инде әдәби тәнкыйтьнең үз эчендәге бүленешкә килгәндә, аның критерийлары булып *тикшерү объекты, язылу максаты, күренешләрне иңләү дәрәҗәсе, фәнни нигезләү, фактларны җиткерү ысулы, анализлау алымнары* һәм башкалар санала. Шулар ук бер төркем эчендәге мөстәкыйльләшүләргә яисә төрлелелеккә дә китерә. Әйтик, рецензия жанрындагы язмаларның аеруча чуарлыгы күзгә ташлана.

Ю.Б. Боревның «Эстетика. Әдәбият теориясе» хезмәтендә жанр төшенчәсе хакында шундый юллар бар: «Жанр – ... әдәби иҗатны калыплаштыруның бик мөһим тибы; традицияләрне сакларга һәм сәнгати фикерләү тәҗрибәсен гомумиләштерергә булышкан мәдәни хәтер; нәфис әсәрләрнең кайсы иҗатка караганлыкларын билгеләүче тотрыклы формасы»[1]. Без әдәби тәнкыйть жанрларына карата да шушы рухтарак фикер йөртә алыр идек.

Бу урында, отышлы билгеләмәләр булмау сәбәпле, бары тик әдәби тәнкыйтькә мөнәсәбәтле рәвештә, жанр төшенчәсен үзебез аңлаганча аныклап узарбыз: «Жанр – әдәби тәнкыйть язмаларының үзенчәлекле формага, техникага һәм эчтәлеккә ия категориясе яисә тибы».

Теләсә кайсы өлкәдә жанрлар тулы бер система тәшкил итә, ә системалылык элементларның гомумвазифа башкаруга юнәлтелгән берләшүен һәм шул берләшүдән туган какшамас бөтенлеген күрсәтә. Тәнкыйть берәмлекләренең үзара бәйләнеше әдәби күренешләрне халыкка хәбәр итү, аларны аңлатып бирү, шул күренешләр турында иҗтимагый фикер тудыру, кешеләрнең бу төр мәгълүматка ихтыяҗын канәгатьләндерү; аның вакытлы матбугат органнарында урын алуы һәм радио-телевидение аша яңгыравы; фәнни-әдәби-публицистик нигезлелеге, уртак эчке үсеш кануннарына буйсынуы белән билгеләнә.

Жанр мәйданының киңлеге аның эчке, тышкы ресурсларын, ягъни формада үсеш мөмкинлекләрен һәм эчтәлекнең зурлыгын, тирәнлеген, әдәби тәнкыйтьчеләргә хас эрудитлыкны, бу өлкәдә күптөрле танып белү һәм сурәтләү чараларын кулланып булганлыкны күрсәтә.

«Кыскача әдәби энциклопедия»дә нәфис әсәрләрне төркемләү принципларының үзара кисешүен, ә күптөрлелегенең бәхәсләр ту-

---

[1] Борев Ю. Б. Эстетика. С. 126.

дыруын, хәтта әле жанр төшенчәсенең форма яисә эчтәлеккә бәйлеме икәнлеге дә ачыкланмауны, жанрлар теориясенең бөтен системаны иңли алмавын язалар[1]. Тәнкыйтьтә бу бигрәк тә шулай.

Әдәби жанрлар турында хөкем йөртүче күпчелек галимнәр текст структурасын исәпкә ала, танылган фән эшлеклеләре тарафыннан бергәләп төзелгән «Зур Совет энциклопедиясе»ндә дә шул ук караш ассызыклана, әдәби әсәрнең структур-композицион сыйфатламалары алгы планга куела[2]. Әлбәттә, әдәби тәнкыйть язмаларын төркемләгәндә дә, формаль билгеләр дә күздә тотылырга тиеш, әмма эчтәлекнең үтә мөһимлеген, форма белән тыгыз бәйләнештәлеген истән чыгарырга ярамый.

Тәнкыйть жанрларын публицистика да, әдәби тәнкыйть тә өйрәнә, шулай да алар публицистлар тарафыннан ныграк тикшерелгән дип әйтергә кирәк, чөнки фәнни-публицистик-әдәби нигезле бу иҗат, үзенә генә хас сыйфатламалары булса да, публицистик жанрлар системасында бик хаклы рәвештә аерым бер урын алып тора. Дөрес, күпчелек галимнәр публицистика аңа үз махсус жанрларының структурасын күчерә алмый дигән карашны яклый, әмма бу фикер соңгы вакытларда бәхәскә алына башлады.

Белгәнебезчә, кайбер формаларда публицистик алымнарга урын зур бирелә, аерым төр язмаларда чиста публицистика саф әдәби тәнкыйть белән чиратлаша. Катнаш төзелештә иҗат ителгән әсәрләр җитәрлек булса да, әлеге хәлне публицистик язмалар структурасының әдәби тәнкыйтькә тулаем күчеше дип бәяләү дөрес түгел. Нәкъ менә шундый материаллар, тәнкыйть матур әдәбияткамы, публицистикагамы, фәнгәме – кайсына карый, дигән сораулар тудыра һәм бәхәсләр китереп чыгара. Икенче яктан, барлык әдәби тәнкыйть язмаларын берничек тә публицистика эчендә карап булмаячак. Димәк, тәнкыйтьчеләр кулланган бөтен формаларны да публицистик жанрлар системасына кертеп бетерә алмыйбыз. Бу исә – әдәби тәнкыйть фәне өчен мөһим факт.

Әдәби тәнкыйть материалының ниндилеге, нинди жанрга караганлыгы ахыр чиктә тәнкыйтьче мөмкинлекләренә һәм аның үз алдына куйган максат-бурычларына барып тоташа. «…сүз белән эш итә алу югарылыгы тәнкыйтьне әдәби иҗатның үзбашка төре ясый, бу аны саф публицистикадан һәм әдәбиятчының үз фәнни

---

[1] КЛЭ: в 9-и томах. М.: Сов. энцикл., 1964. Т. 2. С. 914.

[2] БСЭ: в 50 т. 2-изд. М.: Сов. энцикл., 1952. Т. 15. С. 589.

эшчәнлегеннән бер рәвешчә аерып куя. Тәнкыйтьченең, бер яктан, тәнкыйди-аналитик, икенче яктан, иҗади-сәнгати сәләтләргә ни дәрәҗәдә ия булуына бәйлелектә, укылган әсәргә тәнкыйди материал язу һәм аны тәнкыйтьченең билгеле бер ситуацияләрдәге бурычларына җавап бирерлек жанр ярдәмендә калыплаштыру нияте туа»[1], – дип яза В.А. Найданова.

Тел һәм әдәбият гыйлеме факультетларын тәмамлаучылар гына түгел, һөнәри журналистлар да әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнә; һәм язганнары матбугат битләрендә урын ала икән, журналистика фәне аны читләп уза алмый. Менә шунлыктан да әдәби тәнкыйть материалларын иҗат итү журналистлар тарафыннан мөһим һәм махсус ныклап өйрәнелергә тиешле юнәлеш дип санала да.

Шуны да исәпкә алырга кирәк: әдәби барышны тормыш-көнкүрешне чагылдырган язмалар эчендә яктырту – киң таралган күренеш. Бу аны публицистика белән якынайта һәм керештерә. Моның озын тарихы, сәбәпләре бар. Әйтик, мәгърифәтчелек чорында халыкны һәръяклы үстерү проблемасы куела, шунлыктан «халыкны агартучы»ларның хезмәтләре, гадәттә, киңпланлы. Халыкчылар, революцион демократлар һәм башка төрле хәрәкәт вәкилләре – универсаль шәхесләр булалар, һәм алар калдырган рухи-матди мирас шулай ук универсальлеккә дәгъва итә. Яшәешнең барлык яклары турында катнаш калыпта язу асмәгънәлелеккә юл калдыра, бер күренеш аша икенчесе хакында уйлау мөмкинлеге тудыра, кайбер фикерләрне цензор кайчысыннан саклап кала. Торабара әлеге алым ныклы традициягә дә әйләнә.

Әгәр автор һәр мәкаләсенә темаларны киң итеп ала икән, бу очракта аның иҗат стиле турында фикер йөртергә урын бар. Язмаларның синкретиклыгы, әдәби тәнкыйтькә кагылышсыз өлешләрнең текст эчендә зур урын алып торуы һәрвакытта отышлы дип әйтеп булмый. Моны тәнкыйтьчеләр үзләре дә таный һәм заман таләбе белән аңлата. Алар андый хәлләрнең күпчелек очракта иҗтимагый-сәяси шартлар белән бәйлелеген, аерым очракларда әдәби тәнкыйтьнең фәлсәфә, социология, сәясәт, җәмгыять белеме буенча карашларны җиткерү юлы буларак сайлануын язалар. Әнә шуңа күрә тарихчыларның (М. Усманов...), педагогларның (М. Әхмәтҗанов...), философларның (К. Фасеев...), авыл хуҗалыгы белгечләренең (Р. Рәүпов) һ.б.ларның әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнүе яисә

[1] Найданова В.А. Становление и развитие жанров в литературной критике Бурятии XX века. С. 22.

башка өлкәгә кагылышлы чыгышларында да әдәбиятка бәйле фикерләр әйтүе табигый.

Г. В. Плеханов Добролюбов иҗатын анализлаган мәкаләсендә моңа бәйле рәвештә түбәндәгеләрне әйтә:

«...ул менә дигән публицист кына иде, дип раслау акыллылык түгел... Ул шулай ук искиткеч әдәби тәнкыйтьче дә иде. Дөрес, әдәби эшчәнлегендә публицистлык әдәби тәнкыйтьчедән өскә чыга иде.

Шул да хак, Добролюбов публицистикасы, әдәби тәнкыйтьтән ызанлашканда, аз отмас иде: ул укучыларга тагын да көчлерәк тәэсир итәр иде. Аның әдәби тәнкыйте турында да шуны ук әйтергә кирәк. Әмма ул, мөгаен, үзе дә публицистиканы әдәби тәнкыйтьтән аерып чыгаруга каршы булмагандыр. Әле Белинский ук борчу катыш кычкырып әйткән: «...Лермонтов, Гоголь, Пушкин турында һаман бер үк нәрсәне туку /.../, гомумән, нинди газап икәнлеген белсәгезче: билгеле бер чикләрдән чыкмаска – бары тик сәнгать һәм сәнгать! Соң, нинди тәнкыйтьче инде мин! Мин памфлетист булып туганмын!» Ул чагыштыргысыз әдәби тәнкыйтьче булган,– моны хәзер барысы да таныйлар кебек,– әмма, күргәнебезчә, ул да әдәби тәнкыйтьне публицистикадан аерып куюга каршы түгел. Тик ул да ызанлап алмаган. Нигә соң? Чөнки «билгеле кысалардан» чыгарга комачаулаучы «соры киемдәге берәү» булган: цензор»[1].

Югарыдан аңлашылганча, узган чорларда әдәби әсәрләр анализын, язучы иҗаты хакындагы фикерләрне халыкка тормышны аңлату максатыннан тагын да ешрак кулланганнар, тәгаен бер мисалда сыйныфлар арасында барган мөнәсәбәтләрне ачканнар, үзләре сайлаган яшәү яисә көрәш юлларына халыкны әсәр фәлсәфәсен тәнкыйтьләү, яклау аркылы чакырганнар.

Саф әдәби тәнкыйть язмаларының сыйфатламалары саф публицистик мәкаләләрнекеннән аерыла. Аларда бер-берсеннән ерагаю, аерымлану омтылышы көчле. Белгәнебезчә, диалектик кануният буенча, теләсә кайсы күренешнең капма-каршысы була. Димәк, ике арада кушылу юнәлешендә дә хәрәкәт бара дигән сүз. Тәнкыйть һәм публицистика уртасында торган формалар барлыгы шул якынаюны чагылдырып тора да. Әлеге формалар әдәбият белән шөгыльләнүче галимне – журналистикага, журналистны тәнкыйть фәненә якынайта. Дөрес, күп вакыт тәнкыйтьче һәм

[1] Плеханов Г.В. Добролюбов и Островский // История в слове. М.: Современник, 1988. С. 161,162.

журналист бер үк проблеманы төрле планда, төрле киңлектә ача. Мәсәлән, журналистларның, рецензия, очерк, башка калыпларда иҗат иткәндә, тасвирлау объектын киңрәк алуларын, әдәбият һәм сәнгать белән генә чикләмәүләрен ассызыклап узарга кирәк.

Жанр сыйфатламаларының «юылуы», «тоныклануы» аркасында да, кайбер язмаларны әдәби тәнкыйть эчендә караргамы-юкмы дигән бәхәсләр туганга, ахыргача хәл ителмәгәнгә һәм жанрга бәйле башка проблемалар да чишелмәгәнгә булса кирәк, күпләр тәнкыйть жанрларын төркемләүдән кача. Галимнәр уку әсбапларында, дәреслекләрдә бәхәс уятмый торган жанрларны ачу һәм гамәли дәресләрдә шул формаларда язу күнекмәләрен үстерү белән чикләнә. Киләчәктә әдәбиятка хезмәт итәчәк шәкертләрнең төрле характердагы хезмәтләр язачагын уйлаганда, югары уку йортларында фәнни нигезлелеге күзгә ташланып тормаган, авторлары фикерләрен гыйльми чыганаклар белән яисә башкача дәлилләмәгән әсәрләрне дә, публицистикага яисә нәфис әдәбиятка ныграк караган фельетон, пародия һәм башка калыптагы язмаларны да өйрәнү, шул жанрларда каләм сынап карау бик кирәк.

Теләсә кайсы сәнгать төрендә, жанр һәм жанр формаларын аеру өчен, беренче чиратта, тема һәм проблема сайланышын, структур төзелешне һәм композицияне, аларның үзара ярашуын, берлеген, күләмне таяныч итәләр. Бу жанрның үз табигатенә барып тоташа, чөнки һәрбер форма материал киңлеген, күренешләрне чагылдыру масштаблылыгын, аларны гомумиләштерү дәрәҗәсен, аудиториягә юнәлгәнлекне билгеләүдә катнаша. Әдәби тәнкыйтьтә жанрларга бүлү аның табигатендәге тотрыклылык һәм үзгәрүчәнлек бәйләнешенә, тәнкыйтьнең иҗади төр сыйфатындагы үзенчәлекләренә, эчтәлек-төзелешенә һәм башкаларга нигезләнә.

Әдәби тәнкыйть жанрларын классификацияләү принципларының әлегәчә эшләнеп бетмәвенә тәнкыйть жанрларындагы үзгәрешләр, бигрәк тә аларга хас тарихи үзгәрүчәнлек, кайберләренең асылын, эчтәлеген төгәл билгеләү кыенлыгы да сәбәпче. Теге яки бу формаларның заманга бәйле искерүе яисә яңарыш алуы, барлыкка килүе дә жанрлар классификациясенә үзгәрешләр кертүне таләп итә.

«Тәнкыйть жанрлары һәр жанры башкалар арасында үзенең логик нигезләнгән урынындагы һәм алар белән закончалыклы бәйләнешләрдәге система булып тора. Бу урын һәм әлеге бәйләнешләр реаль мөнәсәбәтләргә туры килә, тәҗрибә, гамәлият, күзәтү ярдәмендә, турыдан-туры һәм читләтеп тикшерүне рөхсәт итә.

Вакыт жанрларга берләрен престижлы ясап һәм икенчеләрен популяр түгел итеп, берәүләрен үлемгә һәм икенчеләрен яңа импульслар алырга мәҗбүр итеп йогынты ясый»[1], – дип яза А.Г. Бочаров. Шул ук вакытта галим үз хезмәтендә атаган һәм анализлаган рецензиянең, иҗат портретының, тәнкыйди статьяның, теге яки бу үзгәрешләр кичереп, гасырлар дәвамында актив кулланышта йөрүен билгеләргә кирәк. Алга таба да шулай булыр. Һәм нәкъ менә аларның гына әдәби тәнкыйть нигезләрен язучылар тарафыннан һәрвакытта аерым игътибарга алынуы шуңа бәйле дә.

А.Г. Бочаров, публицистиканың информатив, аналитик, әдәби-нәфис төрләргә бүленеше инде тотрыклы һәм чишмә башларын күрсәтеп тора, дип әйтә, әмма тәнкыйтьне шул рәвешчә бүлгәләү белән бик үк килешми. Әдәби тәнкыйть язмаларын, галим билгеләгәнчә өч ояга туплау рецензия, иҗат портреты һәм мәкаләнең өч таяныч форма булуына каршы килми. Шул ук вакытта гасырлар дәвамында баба формалардан аерылып чыккан тәнкыйть язмаларының әлеге төрләр тирәсендә генә калуы мәҗбүри булырга тиеш түгел. Бар нәрсә үсә, үзгәрә, керешә, аерымлана – бу әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә шулай.

Журналистларның классификацияләренә күз салганда, күбесендә төшенчәләрнең киң мәгънәсе алга чыгарылганлык һәм теге яки бу жанрны үз эчендә төркемләү күренә. Мәкаләләрнең, репликаларның һәм башкаларның ниндиләре генә юк. Тәнкыйть фәне белән шөгыльләнүчеләр дә төркемләүдә төшенчәләрнең киң мәгънәсен актив файдалана. Мәсәлән, репликага – бер темага шәрех, фикер йөртү, җавап бирүне кертеп карыйлар һәм аның аналитик төренә нигезендә анализ һәм шәрех яткан әдәби тәнкыйть мәкаләсен кертәләр; тәнкыйть теориясе сорауларына җавап бирүче язмаларны теоретик дип атасалар, игътибарны гамәлиятнең актуаль хәлләренә юнәлткәннәрен проблемалы реплика дип билгелиләр.

Барлык төркемләүләргә, билгеләмәләргә таянып, әдәби тәнкыйть жанрларын классификацияләү – мөмкин булмаган эш. Кемдер бер жанрны икенчесе эчендә күрсә, башкасы әлеге дә баягы икенчене беренчесен чагылдырган төшенчә аша ача. Шулай итеп, дәреслек язу да, дәреслекләргә һәм башка төр ярдәмлекләргә таянып, студентларга фәнне үзләштерү дә шактый авырая. Әле бит кайбер жанрларны һәм киң, һәм тар мәгънәдә аңлау да бар.

[1] Бочаров А.Г. Жанры литературно-художественной критики. М.: Изд-во Моск. ун-та, 1982. С. 5.

Мәсәлән, фәннән ерак укучы шул ук репликаны әдәби күренешкә, әсәргә карата әйтелгән кыскача фикер, теге яки бу каләм иясенә каршы төшү яисә аерым бер карашларын яклау дип кенә белә.

Бу дәреслектә тәкъдим ителгән бүленеш тә авторны канәгатьләндерми, чөнки аның шулай ук күзгә ташланырлык җитешсезлекләре бар. Бер үк жанрда язылган хезмәтләрне, эчтәлегеннән, язылу алымнарыннан чыгып, төрле ояларда карарга туры килә. Бигрәк тә «информатив төр» уйландыра. Шул ук вакытта аннан баш тарту да дөрес булмас кебек: публицистикага хас алымнар белән язылган һәм әдәби барыштагы хәлләрне, күренешләрне, фактларны укучыларга җиткерүне алгарак куйган, әмма билгеле бер күләмдә аларның эчтәлеген дә ачкан, бәя элементлары да булган аерым калыпларның әдәби тәнкыйть үсеше, тарихи сәхифәләренең тулылыгы өчен гаять мөһим.

Әдәби тәнкыйтьне система рәвешендә тәкъдим иткәндә, жанрлар байлыгын тулысынча чагылдыру бу өлкәнең матур әдәбият һәм публицистика белән бәйләнешләренең ни дәрәҗәдә тыгыз икәнлеген ачык күрсәтә. Дөрес, татар тәнкыйтенең төрле формалардагы язмаларга ярлылыгы, теге яки бу жанрлар турында сүз алып барганда, иркенәеп китәргә ирек бирми, әйтелгән сүзгә отышлы мисаллар табу шактый авыр, кайчак мөмкин дә түгел, ә фикерне рус тәнкыйтенә нисбәтле язмалар ярдәмендә генә дәлилләү дөрес булмас шикелле.

Игътибарга алырлык факт: соңгы заман гыйльми эзләнүләрендә әдәби тәнкыйтькә кагылышлы язмаларның публицистиканыкына бик нык якынлыгын, еш кына хәтта тәңгәллеген дә раслаулар күзәтелә. Бу очракта тәнкыйтьтә публицистиканыкына охшаш бүленеш, һичшиксез, аклана. Тәнкыйть язмаларын публицистик материалга тиң күрүнең, публицистик сыйфатларының әдәбилек белән гыйльмилегеннән калкурак дип санауның сәбәпләре юк түгел. Фәнни эзләнүчеләр андый очракта мәсьәләгә, теория ноктасыннан да битәр, реаль чынбарлыктан якын килә. Вакытлы матбугатта урын алган тәнкыйть эчендә публицистик аһәңе көчле язмалар шактый, һәм аларның саны торган саен арта.

Галимнәр тәнкыйтьченең хезмәтләрен төрле эстетик кичерешләр һәм йогынтылар астында язуын, аның укучыга хисси тәэсир итү омтылышын, язмаларында шәхес буларак ачылуын сөйли. Ә бит журналистлар да нәкъ шулай. Тәнкыйтьче, тормышны һәм аның аерым күренешләрен өйрәнгән публицист кебек үк, әдәби әсәрне

үзләштерү вакытында, тойгыларга бирелә һәм шул сәбәпле язмасында бик еш кына публицистик пафос өстенлек итә башлый.

В.А. Найданова «Становление и развитие жанров в литературной критике XX века» дип аталган хезмәтендә, тәнкыйть жанрларының сыйфатларына, объектларның эстетик тибын анализлау гына түгел, заманны тәнкыйди аңлаган публицистик пафос та кирәк, дип белдерә. Галимә әдәби тәнкыйтьтә жанрларны классификацияләүне методологик нигезләүләр нәфис жанрларны аерып чыгару принципларыннан аерылганны; андагы проблемалылыкның, «предметлыкның», композицион структураларның башка икәнлеген; тәнкыйть жанрларын системага салуның логикасы һәм аеру критерийлары әлеге эшчәнлекнең табигатеннән килүен, иҗтимагый вазифалар башкаруына барып тоташуын әйтә.

В.А. Найданова язганча, тәнкыйть методы, әдәби төр, объектларны иңләү киңлеге, факт һәм проблеманың структур-композицион мөнәсәбәте буенча классификацияләүне аерып куйганда, әдәби тәнкыйтьне публицистик нигездә төркемләү фикеренә киленә. «Тикшеренүчеләр әдәби тәнкыйть жанрлары еш кына журналистика жанрлары – мәкаләләр, рецензияләр, җаваплар, эсселар, юбилей сызмалары, очерклар белән туры килә дип саный»[1].

Киң таралыш тапкан шушы төр фикерләрне дә искә алып, хезмәтебездә әдәби тәнкыйтьне тарайтып карамабыз, иң элек, журналист язмаларын бүлгәндәге кебек (аларның әлеге бүленешкә әдәби тәнкыйтьне дә керткәннәрен онытмаска кирәк), мәсьәләгә *системалы* якын килеп, *функциональ үзенчәлекләрен, шәхси сыйфатламаларын* һәм үзара *диалектик мөнәсәбәтләрен* исәпкә алып, өч ояга аерып күрсәтербез, әмма аерым жанрларның, билгеле бер үзгәрешләр кичереп, төрдән төргә күчеп йөрүләрен дә ассызыклап барырбыз.

А.Г. Бочаров публицистикада үзе күрсәткән өч ояга бүленешнең тотрыклылыгын язса да, әлеге мәсьәләгә журналистлар, чынлыкта да, зуррак игътибар бирсә дә, жанрны дифференциацияләү проблемасын аларның да ахыргача хәл иткәне юк, ә инде әдәби тәнкыйть, әдәбият белеме белән махсус шөгыльләнүчеләрнең күпчелеге, әйткәнебезчә, бу күренешне яктыртудан һаман читләшә.

Д.В. Смирнов журналистиканың үзара бәреккән өч бурыч башкаруын яза. Болар: 1) фактлар хәбәр итү; 2) фактларны, вакыйгаларны, күренешләрне шәрехләү, анализлау, бәяләү; 3) фактларны,

[1] Найданова В.А. Становление и развитие жанров в литературной критике Бурятии XX века. С. 2.

вакыйгаларны, күренешләрне тасвирлау. Алга таба галим, әлеге бурычлар нәкъ менә мәгълүмати, аналитик, документаль-нәфис ояларны калыплаштыра, дип белдерә[1].

Әгәр галимнәр әдәби тәнкыйтьнең дә шуңа охшаш бурычларны башкаруы хакында даими сөйлиләр икән, димәк, жанр формаларын төркемләгәндә, боларны исәпкә алу табигый. Әлбәттә, әдәби тәнкыйтьнең төп бурычы, гомумән алганда, өйрәнү объектына анализ һәм бәя бирү булып кала. Һәрбер форма һәм хәтта аны кулланган каләм иясе аны төрле дәрәҗәдә хәл итә.

Әле 1925 елда ук Л.П. Гроссман әдәби тәнкыйтьтә 17 төрнең иркен кулланылуын билгели һәм боларга: әдәби портретны, фәлсәфи трактатларны (эссе), импрессионистик этюдларны, статья-трактатларны, статья-инструкцияләрне хәтерләткән публицистик яисә агитацион тәнкыйтьне, әдәби хатны, тәнкыйди диалогны, пародия һәм памфлетны, фельетонны, рецензияне, әдәби күзәтүне, тәнкыйди рухлы хикәяне, әдәби янәшәлекләрне, академик бәяләмәне, тәнкыйди монографияләрне һәм статья-глоссаларны кертә. Галимнәр бүгенге көндә инде аларның кайберләре, әйтик, иҗтимагый вазифаларын башкарып, актив кулланыштан төшеп калганнары хакында сүз алып бармый, әмма һәрберсенең әле дә әдәбиятны чагылдыра, бәяли, тәкъдир итә һәм тәнкыйтьли алуы һич бәхәс уятмый. Б.Ф. Егоров та үз классификациясендә Л.П. Гроссман тәкъдим иткән бүленешкә таяна һәм әдәби портрет, күзәтү, рецензия, монография кебек язмаларны тикшерү объектларын иңләү киңлеге буенча берләштерә[2].

Соңгы вакытта тәкъдим ителгән бүленешләрдә тәнкыйть язмаларын күләмгә: кече (рецензия, реплика, аннотация, кече некролог...); урта (күзәтү, уртача озынлыктагы мәкаләләр, эссе, фельетон, памфлет, иҗат портреты, характеристика-некролог...); төзелешкә: гади (аерым кешенең берһөтен язмасы) яисә катлаулы (төрле язмалардан, төрле авторлар фикереннән оешкан) жанрлар дип төркемләүләр очрый. Гади һәм катлаулы дип бүлгәндә, эчтәлек тирәнлеген һәм киңлеген дә истә тотып, дискуссия, мәкаләләр җыентыгы, цикл, монографик мәкалә, әдәби портрет, кереш һәм йомгак мәкаләләрен бер ояга туплау да күзәтелә.

---

[1] Смирнов В.В. Жанры радиожурналистики. М.: Аспект Пресс, 2002. С. 39.

[2] Егоров Б.Ф. О мастерстве литературной критики. Жанры, композиции, стиль. Л.: Сов. писатель. 1980. С. 14.

Казан галиме В.Н. Коновалов, мәсәлән, «вертикаль буенча» классификация тәкъдим итә һәм аны нигезләп тә бара. Беренче төркемдә ул бүгенге әдәбиятның әһәмиятле күренешләрен анализлаган һәм оператив башкарылган, яңалыклы тәнкыйди язмаларны – библиографияне, рецензия-бәяләмәне, монографик мәкаләне күрә. Икенче төркемне теоретик мәсьәләләр, әдәбиятның хәле турында уйланулар чагылган проблемалы мәкалә калыплаштыра. Өченче төркем: теге яки бу этаптагы әдәби барышның үсеш закончалыкларын, үзенчәлекләрен бәяләгән концептуаль, мәгълүмати күзәтүләр, күзәтү-цикллар. Дүртенче төркем исә: тәнкыйтькә тәнкыйть. Галим каләм иясен шәхес һәм иҗатчы буларак ачкан язмаларны, ягъни тәнкыйди-биографик очеркларны, әдәби портретларны бишенче төркемгә кертә.

В.Н. Коновалов карашынча, бу бүленеш жанрлар өчен уртак булган формалар хисабына «горизонталь рәвештә» тулыланырга тиеш. Боларга ул хат, уйлану-фикерләү, язма-эссе, диалог, параллель, очерк һ.б.ны кертә[1]. Димәк, мәсьәлә шулай ук ахыргача хәл ителеп бетмәгән, «вертикальлек» принцибы гына тәнкыйтьнең жанр классификациясендә ахыргы сүзне әйтү мөмкинлеге бирми икән.

М.Я. Поляковның да тәнкыйть жанрларын төркемләүгә бәйле кайбер фикерләренә тукталыйк. Ул әдәби тәнкыйть материалларына алардагы әдәби факт һәм проблематиканың структур-композицион нисбәте яссылыгыннан якын килә һәм, тәнкыйтьченең субъективлыгы эстетик яисә публицистик проблема күтәрүенә бәйле, дигән караштa тора. Галим шуңа мөнәсәбәттә түбәндәге төркемнәрне аерып чыгара:

1) шәрехләүче тип (мәкаләдә әдәби фактан социаль һәм әдәби проблемага таба хәрәкәт ителә);

2) идеологияләштерелгән тип (проблемалы фикер белдерүләрдән әдәби фактка күчү, мәсәлән, күзәтүләрдә);

3) фактан фактка таба хәрәкәткә нигезләнгән төр (әдәби портрет, фәлсәфи-тәнкыйди этюдлар, кайбер рецензияләр;

4) рефлектив яисә полемик жанрлар (әдәби фактларны чикләү һәм проблемадан проблемага таба хәрәкәт итү.[2]

---

[1] Коновалов В.Н. Теоретические проблемы классификации литературно-критических жанров // Жанры русской литературной критики 70–80-х годов XIX века. Казань: Изд-во Казанского ун-та, 1991. С. 9–16.

[2] Поляков М.Я. Динамика критических жанров // В мире идей и образов. Историческая поэтика и теория жанров. М.: Советский писатель, 1983. С. 53–91.

Күргәнебезчә, төркемләнештә тәнкыйтьченең фикер йөртү рәвеше мөһимләштерелә. Галимнәр, бу төр аерымлауның әдәби барышны өйрәнгәндә отышлы икәнлеген билгеләсәләр дә, әлеге классификация шулай ук канәгатьләндерерлек түгел дип исәпли.

XX йөз башында татар язучылары һәм галимнәре тәнкыйтьнең төр-жанрларын бөтен система рәвешендә ачык күзаллый. Бу чор әдәби тәнкыйтен ныклап өйрәнгән КФУ (КДУ) галиме Т. Гыйлаҗев әлеге система эчендә тотрыклы жанрларны шушы рәвештә билгели һәм төркемли: 1. Рецензия (кыска рецензия, монорецензия, күзәтү рецензиясе, рецензия-мәкалә, мәкалә-диалог). 2. Мәкалә (программ мәкалә, проблемалы мәкалә, бәхәсле мәкалә, күзәтү мәкаләсе, юбилей мәкаләсе, әдәби параллель, диалог). 3. Әдәби портрет (әдәби-тәнкыйди портрет, иҗат очеркы, мемуар очерк, силуэт). 4. Некролог – тәгъзия (некролог-мәкалә, некролог-хәбәр, некролог-эссе, шигъри прозадагы некролог, некролог-сыктаулар). 5. Хат (аерым хатларның бәхәсле мәкаләгә, авторецензиягә, үзтәнкыйтькә, хәбәргә, күзәтү мәкаләсенә якынлыгы искәртелә). 6. Хәбәр[1].

Ә. Закирҗанов «Яңарыш юлында» китабында болай дип яза: «Тәнкыйть объектының төренә һәм эчтәлегенә карап, гадәттә, тәнкыйди язмаларның берничә төркемен аерып чыгаралар. Берсе – хәзерге әдәбиятның әһәмиятле булган аерым күренешләре тәнкыйди анализның предметы булып тору. Ул үз эченә библиографик язма, рецензия-бәяләмә, монографик мәкалә кебек жанрларны ала»; «Мәкаләләрнең икенче төркемендә тәнкыйди анализ предметы булып, теоретик мәсьәләләр, әдәбиятның торышы турында уйланулар тора»; «Тәнкыйди язмаларның өченче төркемен әдәби барышның аерым чорын, аның үсеш закончалыкларын һәм тенденцияләрен бәяләү тәшкил итә. Андый мәкаләләрне әдәби күзәтү жанры дип атау кабул ителгән»[2].

«Әдәби энциклопедия»дә («Литературная энциклопедия») хәзерге тәнкыйтьтә статья, рецензия, күзәтү, эссе, әдәби портрет, полемик реплика, библиографик язмачык кебек төрләрнең культивацияләнүе»[3] белдерелә, ә «Литературно-художественная критика» китабында башка жанр формаларының рецензия, иҗат портреты, статья

---

[1] Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән – тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 9–23.

[2] Закирҗанов Ә.М. Яңарыш юлында. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 148.

[3] Литературная критика // КЛЭ. URL: feb-web.ru/images/logoDB.gif; Литературная критика // ЛЭС URL: slovari.yandex.ru

кебек таяныч төрләр тирәсенә туплануы һәм әлеге бүленешнең тәнкыйть объектларына: әсәр, автор, процесска бәйлелеге әйтелә[1].

Әдәби тәнкыйть жанрлары турында сүз йөрткәндә, аларны субъектына нисбәтән дә ачыклау гадәте бар. Һөнәри тәнкыйтьнең традицион формаларына әдәби-тәнкыйди статьяларны яисә аларның циклларын, күзәтүләрне, еллык хисапларны, очеркларны, рецензияләрне, бәхәс мәкаләләрен, программ манифестларны, диалогларны, эсселарны, библиографик тасвирламаларны һәм аннотацияләрне кертәләр.

Язучы тәнкыйте дигәндә, нигездә, нәфис әдәбият язу белән шөгыльләнүчеләр вакыт-вакыт тудырган тәнкыйди мирасны күздә тоталар. Алар арасында тәнкыйди-публицистик яисә әдәби-публицистик язмалар, рецензияләр, хатлар зур урын алып тора. Әдәби бәхәсләр вакытында әдипләр авторецензияләр белән дә катнаша.

Әлбәттә, язучы тәнкыйте өч-дүрт жанр белән генә чикләнә алмый. «Язучыларның әдәби-тәнкыйди чыгышлары дигәндә, мин аларның мәкаләләрен генә түгел, төрле калыптагы сөйләмнәрен, интервьюларын, кем беләндер диалогларын, теге яки бу әсәр аша бирелгән җавапларын, үз алларына куйган әдәби максатюнәлешләренә характеристикаларын да күздә тотам – барысын санап бетереп тә булмый»[2],– дип яза Б.И. Бурсов.

Язучылар әдәбиятка мөнәсәбәтле карашларын, эсселарда, нәрсәне дә булса игътибарга алган «заметка»ларда, көндәлек язуларында, әдәби әсәрләре эчендәге чигенешләрдә, матбугатка чыгарылмаган һәм исән чагында бастырылмаячак каралама дәфтәрләрдә, каләмдәшләренә язган характеристикаларында яисә үзләренең биографияләрендә һәм башка формаларда да җиткерергә мөмкин.

Китап укчылар үзләрен теге яки бу төрләрдә талант мөмкинлекләреннән һәм белем дәрәҗәләреннән чыгып сыный. Аның иң киң таралган төрләре – язучыларга, тәнкыйтьчеләргә, наширләргә юлланган хатлар, интернет форумнарда белдерелгән төрле күләмдәге фикерләр, халык алдындагы чыгышлар булып тора. Аларда гавам, аерым катламнар зәвыгы, ихтыяҗы, әдәбиятка мөнәсәбәте, теге яки бу әсәрне ярату-яратмавы ачык чагылыш таба.

---

[1] Баранов В.И., Бочаров А.Г.Н., Суровцев Ю.И. Литературно-художественная критика.М.: Высшая школа, 1982. С. 140.

[2] Бурсов Б.И. Критик как писатель // Критика как литература. Л.: Лениздат, 1976. С. 50.

Әдәби тәнкыйть жанрларының системасы әле тагын да үсәчәк, үз эчендә дифференциацияләнә барачак, әмма аның башлангыч, ягъни баба төрләре калыр, һич югы тарихи хәтер, код буларак яңа туган калыпларда яшәр дип уйларга кирәк. Һәм тәнкыйтьче нинди генә материалны яктыртырга алынмасын, үзе сайлаган жанрның табигатен, аның форма чараларын белеп эш итсә, аларны билгеле бер максатка хезмәт иттерә алса гына, сыйфатлы язма тудырачак.

Кыскасы, әдәби тәнкыйть жанрларының төрлелегенә, язмаларның күләменнән тыш, тәнкыйтьченең үз алдына куйган иҗади бурычы, хезмәтнең нәрсә өчен башкарылганлыгы, вакыйгаларның иңләнү киңлеге, исәпкә алынган фактларның күләме һәм аларның шәрехләнү характеры, хезмәтнең теоретиклык дәрәҗәсе, автор тарафыннан әдәби-стилистик чаралар сайланышы да тәэсир итә. Боларның барысын да истә тотып, тәнкыйть жанрларын төркемләү бик кыен, шунлыктан тәкъдим ителгән бүленешләрдә һәрвакыт искәрмәләр, өстәлмәләр, төр читеннән тышка чыгулар, төрләрнең үзара керешүләре күзәтелә.

Әдәби күренешләргә карата фикер җиткерү мөмкинлекләренә ия жанрларның һәм жанр формаларының кайсын әдәби тәнкыйть өлкәсенә кертеп карау кирәклеге тәмам хәл кылынмаганлыктан, әлеге юнәлештә эзләнүләр дәвам итә, шулай да бу проблема ахырга кадәр уңышлы чишелер һәм аның һәркемне канәгатьләндерерлек принцибы табылыр кебек тоелмый. Монда теге яки бу төшенчәне аңлаудагы, аның төрләре буларак кайсы тип язмаларны күрсәтүдәге аерымлыклар аеруча зур киртә булып тора.

Хезмәтебезнең тәнкыйть жанрларын төркемләгән бүлекләрдә «төр» турында сүз барачак, аларны, әйтик, информатив, аналитик, әдәби-публицистик оя дип тә бирергә яисә башкача да атарга булыр иде. Жанр сүзе белән буталу күзәтелмәсен өчен, әлегә шушы төшенчәгә тукталдык.

## 5.2. Иноформатив төр

Әдәби тәнкыйтьнең төп бурычы теге яки бу әсәрнең эчтәлеген ачу, каләм иясе иҗатына бәя бирү, әдәби барыштагы күренешләрне анализлау, һәм ул шуның белән журналистикадан аерыла да. Бер үк вакытта, тәнкыйтькә кагылышлы хезмәтләрдә информатив жанрларны да исәпкә алмыйча булмый. Бердән, алар тәнкыйтьче таянган чыганаклар булып тора, икенчедән, аның үзенә дә еш кына

әлеге формаларда да эш итәргә туры килә. Өченчедән, журналистикада информатив формалар дип каралган язмаларда да бәяләмәле җөмләләр, теге яки бу күренешкә билгеле бер күләмдәге анализ күпмедер очрый. Ә бит матур әдәбиятка кагылышлы аннотацияләрне, күзәтүләрне күбрәк тәнкыйть белән шөгыльләнүчеләр яза, әдәби вакыйга-хәлләрне дә әдәбиятчылар яктырта, алар хакында газета-журналларга хәбәрләр юллый.

*Информатив жанрларга хәбәр-мәкаләчекне, аннотацияләрне, күзәтүләрне, хисапларны, язучы яисә башка берәү белән әдәбият хакында оештырган информатив характердагы әңгәмәләрне, әдәбиятка гаид репортажларны һ.б.ларны кертергә мөмкин.*

Мәгълүмати формалар тизлек, кыскалык, төгәллек, үтемлелек, гадилек сыйфатларын таләп итә. Аларга күпмедер дәрәҗәдә тәкъдир-тәкъдим итү рухы хас. Бигрәк тә рисалә-китапларның алгы битләрендәге, газета-журналлардагы аннотацияне әдәби продукциягә реклама дип бәяләргә мөмкин.

Классификациябезнең һәр оясында, шул исәптән монысында да материал, аны җиткерү күләме һәм тирәнлеге буенча үсүгә таба хәрәкәт күзәтелә, монолог яисә диалог калыплары да бар. Төркемләнештә икеләндерүче төп сәбәп галимнәр тәкъдим иткән күпчелек бүленешләрнеке кебек: кайбер жанр формаларын, материалны җиткерү ысулына, аларның сизелерлек үзгәрешләренә бәйле рәвештә, аналитик төркемдә карап була.

Әдәби тәнкыйть язмаларын өч ояга берләштерүнең чагыштырмача отышлыгын тану бигрәк тә журналистлар арасында күзәтелә. Кайберәүләр аның информатив төренә: а) аннотацияне – әсәр эчтәлегенә мөнәсәбәтле кече шәрехле хәбәрне; б) әдәби барыштагы мөһим бер вакыйганы хәбәр иткән «заметка»ны («хәбәрчек»не); в) бер темага шәрех, җавап-кайтаваз, хөкем рәвешендәге берьяклы, әмма аралашу тәэсире калдырган репликаларны да кертәләр.

Информатив характердагы тәнкыйтьнең төп максаты – әдәбиятка кагылышлы фактны халыкка җиткерү. Анда тирән анализ юк, бәяләмәле җөмләләр аз, бәя-анализ алгы планга чыгарылмый. Без бу бүлекчәдә шундый язмалар турында сүз алып барырбыз да.

Язучылар оешмасындагы вакыйгаларны, эш-хәлләрне, республикакүләм, илкүләм уздырылган әдәбиятка кагылышлы чараларны, тар җирлектәге әдәби барышка мөнәсәбәтле күренешләрне хәбәр итүче жанр формаларына кече күләмле мәкалә-хәбәрләрне һәм репортажларны кертәбез.

Иң элек *хәбәрчекләр*гә тукталыйк. Әдәби барышка мөнәсәбәтле теге яки бу күренешләрне күреп-күрсәтеп алган *«заметка»*ларның а) фикерләр тирәнлегенә дәгъваламаучы, гомуми характеристика бирүче *информатив*; б) тәфсиллерәк чагылдыручы *киңәйтелгән*; асылын билгеләүче һәм характерлы сыйфатларын атаучы *тәнкыйди* төрләре була дип саныйлар, соңгысының рецензиягә тартымлыгын яисә якыная башлаганлыгын күрсәтәләр.

Әдәби тәнкыйтькә нисбәтле бу төр язмалар әдәби-иҗтимагый эчтәлектәге вакытлы матбугатта урын ала, һәм аларның актуаль – кирәкле, кызыклы, мөһим булуы шарт. Бер үк күренеш турында ике-өч җөмлә белән язарга, кечкенә генә хәбәрчек хәзерләргә яисә аңа кемнеңдер мөнәсәбәтен җиткерергә мөмкин. Информацияләр радио яисә телевидение аша әйтелсә, аудиторияне исәпкә алу бик кирәк. Үз алдыңа, укытучылар, әдәбиятчылар, китап сөючеләр әлеге төр тапшыруларның эфирга кайчан чыгуларын теләрләр иде икән, соравын куеп эшләү мөһим.

Әдәби-музыкаль тапшыруларны гадәттә ял көннәрендә күрсәтәләр. Аларда мәдәни тормыш киң яктыртыла. Бу очракта тыңлаучыга мәълүматның ничек ирешүе, сөйләмнең аңлаешлылык дәрәҗәсе турында да уйланырга кирәк. Көн дәвамында җиткерелгән яңалыкларда шулай ук язучылар тормышына караганнары да еш хәбәр ителә. Әлеге яңалыкларда теге яки бу әсәрләрнең тәкъдир яисә тәкъдим кичәләре, юбилейлар, үлем-китемнәр турында сүз бара, шул темаларга бәйле рәвештә, язучы иҗатына кагылышлы фикерләр дә яңгырый.

«Казан утлары» журналының соңгы битләре тулысы белән кечкенә *хәбәрләргә* бирелә. Аларның күпчелеге мәдәният яңалыкларын яктырта, араларында әдәбиятка кагылышлылары да байтак. Мисалга 2004 елның 10 санын алыйк. «Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан» рубрикасының «Җәлилчеләрне искә алу» язмасында, җәлилчеләрнең җәзалап үтерелүенә алтмыш ел тулу уңаеннан уздырылган хәтер җыенында Илбашының Җәлилнең көрәшче, иҗатчы гомере турында да сүзләр сөйләве әйтелә (Б. 188).

Икенче бер язма «Юбилей уңаеннан» дип атала. Аны тулысынча китерик: «Сентябрь аенда Мәскәүдә элеккеге халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә 17 нче халыкара китап ярминкәсе ачылды. Анда төрле чаралар да уздырылды. *Мәгълүм булганча, Мостай Кәримгә 85 яшь тула. Шул уңайдан, Мәскәүнең «Ватан каһарманнары» нәшрияты Башкортостанның халык ша-*

*гыйре турында «Мостай Кәрим: сугышчы, шагыйрь, гражданин» дигән китап чыгарды. Аның авторы – Ильяс Вәлиев. Җыентыкта Мостай Кәримнең катлаулы тормыш юлы җентекләп тасвирлана һәм рус телендә күп кенә әсәрләре тәкъдим ителә.* 3 сентябрьдә күргәзмә-ярминкәдә шушы китапны тәкъдим итү тантанасы булды. Бирегә Башкортостан, Татарстан һәм Мәскәү җәмәгатьчелеге вәкилләре җыелган иде. Казаннан бу бәйрәмдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин һәм Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис катнашты һәм чыгыш ясады» (Б. 189).

Әдәби күренешләр турында типик хәбәр үрнәге бу. Сыйфатлары: илкүләм әһәмиятлелек, вакыйгалылык, тәгаенлек, чынлык. Аңа хас җитешсезлекләрне һәм уңай якларны карап узыйк. «Казан утлары» – айлык журнал, димәк, материал оператив һәм яңа түгел, әмма вакыйгаларның теркәлүе кирәк, чөнки Язучылар берлегенең башка махсус органы юк, бәйрәм вакыйгалары иҗатчылар елъязмасының аерым сәхифәсе сыйфатында тарихта сакланырга тиеш.

Төп максатыбыз теге яки бу жанрларга караган язмаларга хас җитешсезлекләр турында сөйләү булмаса да, текст бөтенлегенә зыян китерүче кимчелекләргә дә күз салыйк. Бу киләчәк тәнкыйтьчеләренә үз хезмәтләренә җитди якын килү теләге уятмый калмас.

Иң элек укучы игътибарын хәбәрнең, озын булуына карамастан, абзацларга бүленмәвенә юнәлтәсе килә. Әгәр башка язмалар да шушылай – бер генә өлешле бирелсә, моны билгеле бер принципка нигезләнү дип карарга булыр иде, әмма янәшәдәгеләр бүлгәләнгән. Аларында хәтта, болай эшләүнең тиешсезлеге күренеп торганда да, аерым җөмләләр дә абзац рәвешендә шәкелләшкән. Мәсәлән, «Шүрәлегә рәхим итегез»дә аттракционнар паркы ачылу турындагы җөмлә ялгызы тора, ә аннан соң килгәнендә сүз шул парк, аның кышка да ябылмаячагы турында дәвам итә.

Алда мисалга китергән язманы өч абзацка бүлү отышлы: беренчесе – күргәзмә ачылу, икенчесе – Мостай Кәрим турында информация бирсә, соңгысы делегацияләр турында мәгълүмат була ала (урта кисәген авышлык ярдәмендә аердык). Болай эшләү өч фикерне дә укучыга тиз җиткерә, исендә калдыра, аңлаешлы итә.

Хәбәрдәге мәгълүматлар арасындагы бәйләнешкә шулай ук төзәтмә кертергә кирәк. Анда төрле чаралар да уздырылу хакындагы җөмлә үзеннән соңгысына ялганмый. Моннан качу өчен, арттагы җөмләне, бераз үзгәртеп, алга күчерәбез яисә болай дип язып китәбез: «анда яңа китапларны тәкъдир итү кичәләре дә уздырылды.

Башкортостанның халык шагыйре Мостай Кәримгә 85 яшь тулу уңаеннан, Мәскәүнең «Ватан каһарманнары» нәшрияты аның турында «...» дигән китап чыгарган иде».

Текстка тулаем үзгәреш кертү стилистик хаталардан да арындырачак. Әйтик, чираттагы җөмләдә «аның» алмашлыгының кирәге юк, артык. Хәбәрне җыйнаклау өчен: «Авторы: Ильяс Вәлиев»,– дип язу яхшырак булыр. Икенче яктан, Вәлиевне шагыйрь хакындагы язманың яисә Керешнең генә авторыдыр, хезмәтнең төзүчеседер дип фаразларга да урын бар, чөнки җыентыктагы әсәрләр – Мостай Кәримнеке бит. Әллә ул аларның тәрҗемәчесе микән? Ул булмаса, кем аларны русчалаштырган? Хәбәр һәр мәгълүматны ачык, аңлаешлы җиткерергә тиеш.

Журналист үз мәкаләчегендә һич югы «Мостай Кәрим әсәрләре рус теленә тәрҗемәдә» дип әйтсә дә, бу сораулар алга таба да дәвам итмәс иде. Әле бит укучыда, әллә шигырьләрнең русчасын шагыйрь үзе язган микән, дигән сорау да туарга мөмкин. Киңәшләребезне кабул итмәгәндә, «... күп кенә әсәрләре рус телендә тәкъдим ителә» дип язу – сүзләрнең урынын алмаштыру отышлы булыр. Соңгы җөмләне дә катнашты яисә чыгыш ясады хәбәре белән тәмамлау матуррак. Бердән, алдагы җөмләдән Татарстаннан вәкилләр катнашканлык аңлашылды инде, исем-фамилияләрне атау шуны тәгаенләштерә, ә менә кемнәрнең чыгыш ясавын ассызыклау, чыннан да, кирәк.

Газета-журналлардагы «Хәбәрләр» рубрикасында күләмлерәк җөмләләр кулланылу ярый дип санала. Аларда һәр яңа хәбәр бер-ике кыска җөмлә белән җиткерелсә яисә озыннары кечерәкләре белән чиратлашса отышлы дип фикер йөртү дә киң таралган. Кайберәүләр, радио аша әйтелгән яңалыклар кыска булырга, ике юл озынлыгыннан артмаска тиеш, югыйсә аңлау кыенлаша, ди. Соңгы елларда интернет челтәрен яулап алган кайбер агентлыклар, шул исәптән Татар-информ да, белгәнебезчә, нигездә, кыска күләмле хәбәрләр белән эш итә. Ул җиткергән мәгълүматлар эчендә әдәби барышка караганнары да еш очрый. Әлбәттә, журналист булып эшләмәгән һөнәри тәнкыйтьче, әйтик, электрон газеталарга, басма органнарга юллаган «хәбәре»ндә бер-ике җөмлә белән генә чикләнми.

Әдәби барыштагы яңалыкларны *репортаж* рәвешендә дә җиткерергә мөмкин. Репортажны төрлечә классификациялиләр. Аны төркемләп булмый яисә барысын да информатив төр дип кенә карарга кирәк дигән карашлар да бар, шулай да галимнәр-

нең күпчелеге репортажны тематикасына һәм предметына бәйле рәвештә бүлүне яклый. Бу ноктадан караганда, аның *вакыйгалы*сы, *проблемалы*сы, *танып-белдертүче*се бар. Кайберәүләр әлеге жанрны *вакыйгалы, махсус, тикшерүле, шәрехләүче* формаларга бүлә. Вакыйгалы (событийный) репортажда тасвирланган күренешләрнең тышкы ягын гына түгел, эчке асылын да ачарга кирәк, дип белдерсәләр, махсус (специальный) репортажда актуаль темалар яктыртылганны, теге яки бу эш-хәлнең нәтиҗәләре сөйләнүне ассызыклыйлар. Репортаж-тикшерү (-расследование) дигәндә, теге яки бу проблеманы тирәнтен ачу максатыннан, күпсанлы чыганаклар белән эш итүне күздә тоталар. Репортаж-шәрех (-комментарий) исә – вакыйганы детальле өйрәнү ул, дип әйтәләр.

Тагын бер бүленешне – М.Н. Ким тәкъдим иткән классификацияне карап узыйк: 1) аналитик (проблемалы), 2) танып белүле-тематик (төркемнәре: махсус, тикшерүче, шәрехле)[1]. Репортажның проблемалы – аналитик төркемен информатив төргә түгел, ә аналитик ояга кертергә киңәш итүчеләр дә бар. Хакыйкатькә якын караш кебек тоелса да, шунда ук күңелгә теләсә кайсы репортажның төп бурычы теге яки бу вакыйганы анализлау түгел, беренче чиратта, аның хакында хәбәр җиткерү икәнлеге турындагы билгеләмәләр килә.

Л.М. Майданова, коммуникатив максатлардан чыгып, репортажны ике төркемгә аерырга һәм мәгълүмати, һәм аналитик репортажлар барлыгын танырга чакыра[2]. Әлеге карашны яклаучы галимнәр фикеренчә, аналитик репортаж хәбәр сыйфатларын башкарак югарылыкта чагылдыра.

Репортаж термины журналистикага инглиз теленнән кергән (report) һәм ирештерү, җиткерү мәгънәсен аңлата. Нәкъ шул мәгънәсе аның информацион ояга кертелергә тиешлеген күрсәтеп тора да. Репортаж авторы укучы я тыңлаучы игътибарын хәбәр иткән вакыйгадагы аерым детальләргә юнәлтергә тырыша. Әдәби барышка кагылышлы репортажда информация сәнгати-публицистик кабыкта бирелә.

Гомумән алганда, репортажны синтетик төр дип саныйлар. Анда тасвирламалар, җитез сурәтләр (зарисовка), әңгәмәләр,

---

[1] Репортаж // Ким М.Н. Репортаж: технология жанра. СПб.: Изд-во Михайлова В.А., 2005. 221 с. // studbooks.net›

[2] Майданова Л.М. Стилистические особенности газетных жанров: лекции по спецкурсу. Свердловск: УрГУ 1987. С. 59.

шәрехләр (комментарий) еш кулланыла. Аларның барысын уртак текст эченә урнаштыру зур осталык таләп итә. Авторга бу очракта төп тема, мөһим проблемаларны үзәккә куя алу, кирәкле фактларның күз уңыннан ычкындырылмавы, әңгәмә элементлары кергәндә, катнашучыларны отышлы сайлап алу, фикерләрен бер проблема тирәсенә юнәлтү булыша.

Репортажчыны һәр урында буш сүзгә бирелү, лирик чигенешләрнең озынаеп китүе, икенчел пландагы детальләргә, кирәксез сүзләргә игътибар итү кебек кимчелекләр сагалый. Әңгәмәдәшченең темадан читкә чыгуы, сөйләшүне үзен борчыган проблемаларга борырга тырышуы мөмкин. Бу турыда я итәгатьле әйтергә, я урынсыз, чит материалны язмада кулланмаска, икенче хезмәттә файдалану өчен алып куярга, я башкаларның да фикер сөрешен кирәкле юнәлешкә бора белергә кирәк. Комментарийларның урынсызлыгы, артык озынлыгы, нигезсезлеге дә репортажларның сәнгатьлелегенә суга, авторның иҗатчы талантына тап төшерә. Язманы матбугатка яисә эфирга хәзерләүченең вакыйга барган урында булуы зарури, ул бары тик үзе күргәнне, үзе ишеткәнне генә теркәргә, хәбәр итәргә тиеш.

Әдәби чара урыннарыннан басма репортажлар моннан ун ел элек, нигездә, вакытлы матбугатта чагылыш таба иде. Хәзер алар белән электрон чыганаклардан күбрәк тә танышырга мөмкин. Репортажның жанр формасы сыйфатларына документальлек, оперативлык, дөреслек, вакыйгалылык, яңалык, хәрәкәтчәнлек керә. Алар язманың актуальлеген билгелиләр дә.

Татарстан Язучылар берлегендә әдәби ел йомгаклары узганнан соң, барлык газеталар диярлек нindидер материал бирми калмый, күпчелек авторлар укучыда вакыйга турында җанлы картина тудырырга тырышалар, мөһим дип уйлаган чыгышларга киңрәк тукталалар, аерым кешеләрдән фикер әйттерәләр. Еш кына язма эчтәлегенең чынбарлыкка туры килмәве журналистларның бик субъективлыгын, игътибарсызлыгын, кайвакыт хәтта махсус рәвештә дә чынбарлыктан читкә китүен күрсәтә. Алай гына да түгел, мәкалә авторлары кайчак үзләре дә язганнарының редакция хезмәткәрләре тарафыннан хәтта капма-каршыга үзгәртелүләреннән җәфалана.

Объективлыктан курыкмаучы, вакыйгаларны әдәби җиткерүче татар каләм осталары күп түгел, әмма бар. Шуларның берсе – Мәгъсүм Гәрәев. Яшь журналистларга әдәби чаралар хакындагы аның авторлыгындагы хезмәтләр белән күбрәк танышырга кирәк.

Алар арасында репортажлар да бар, әмма әлеге язмалар без күрергә гадәтләнгән билгеле бер калыптагы әсәрләр түгел, һәрберсендә автор иҗеге ачык тоемлана.

М. Гәрәев «Татарстан язучылары, берләшегез!» язмасының «әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышта сөйләми калган нотыгы» икәнлеген әйтә. Шулай икән, аның, докладлардагыча, «Хөзрәти каләмдәшләр!» дигән мөрәҗәгатьтән башлануы һәм язучыларга адреслануы табигый. Авторның язмасын – «нотыкчыгыш» дип тәгаенләштерүе исә әдәби алым гына булып тора. М. Гәрәев бу аныклагыч аша репортажның туу сәбәбен җыелышның әдәби барышны да, язучылар тормышын да кайгырткан мәгънәле чыгышларга, докладлардан соң объектив фикер алышуларга урын бирмәве дип аңлата.

«Татарстан язучылары, берләшегез!» язмасының эчтәлеге белән кыскача гына таныштырып узыйк. Әдип анда татар каләм ияләренә хезмәт иткән бинаның озак еллар ремонт күрмәвен, сәхнәсеннән, җитди фикергә караганда, җырның күбрәк яңгыравын, ә әйтелгән сүзләрнең чынбарлыкка туры килмәвен, бирелгән вәгъдәләрнең үтәлмәвен сөйли[1]. Ул, әле генә булып узган җыешлышны тасвирлаганда, укучыны да шулар турында уйланырга чакыра.

М. Гәрәев хәбәр иткәнчә, чираттагы җыелыш та элек-электән килгән проблемаларга багышлана, анда шулай ук ремонт турында да сүз кузгала. Димәк, автор, бу хәбәре белән, каләм ияләрен бергә туплаган мәҗлесләрнең файдасызлыгы турында фикер җиткерә. Укучы Язучылар берлеген салган юлдан чыкмаучы арбага тиңли башлый. Шуннан соң журналист колхоз җыелышыннан янәшәлек китерә, димәк, бу чараның да дәрәҗәсе, мәгънәсе гади кеше, хуҗалык проблемаларын күтәрәсе урынга, буш сүз сөйләп узган гадәти авыл җыелышларыныкына тиң.

Шунда ук М. Гәрәевнең икенче бер язмасы килә. «Ярый безгә – майлы күзгә әйрән каткан ботка да!»[2] мәкаләсендә дә ул чираттагы ел йомгакларын тасвирлаган иде бит! Аны исә җыелышка җитәкчеләрнең соңга калып килүен, залда, нигездә, пенсионерларның күтеп утыруын әйтүдән башлаган иде.

М. Гәрәевнең тормышның башка өлкәләреннән чынлыкта әдәби барышка мөһим тәэсир ясарга тиешле вакыйгага аналогияләр эзләве чираттагы язмада да табигый килеп чыга. Әлбәттә, авторның

[1] Гәрәев М. Мин, Чуен Гәрәй малае... Казан: Идел-Пресс, 2004. Б. 334.

[2] Шунда ук. Б. 331–334.

язучыларның җитди җыелышын колхозда уздырылган чарага тиңләве кемнедер сагайтырга да мөмкин: тупаслык, чиккә ташлану түгелме, нииндидер асмагънә белән әйтелгән сүзме, әллә нигезле рәвештә янәшә куюмы? Алга таба М. Гәрәевнең әлеге фикере фактлар белән кире кагылмаслык дәлилләнә: җыелышларның сирәклеге, бәхәсле узуы, җитәкчелекнең чараны җитди эштән битәр бәйрәмгә алмаштыру омтылышы... Димәк, М. Гәрәевнең Татарстан язучылар берлегендә уздырылган чаралар турында я тотрыклы карашлары бар, я оешма эшчәнлегендә, чыннан да, уңай якка үзгәрешләр сизелми. Бу структур һәм фикри кабатлау очрауга карамастан, мәкаләләр бер-берсе белән кирәгеннән тыш кисешә дип булмый, чөнки һәрберсе аерым булып узган вакыйганы чагылдыра. Шул ук вакытта публицистның һәр төр язмаларда, репортажда да үз стиле, фикер йөртү калыплары, нәтиҗә ясау ысуллары барлык та тоемлана.

Яңадан авторның тәүге репортажына кайтыйк. Журналист-тәнкыйтьче докладларда чагылыш тапкан, табарга тиешле әдәбиятка анализ турында тирәннән фикер йөртми, чөнки, язмадан аңлашылганча, ул хакта язучылар җыелышында да чын-чынлап, саллы проблемаларны уртага салып сөйләрдәй кеше булмаган я андыйларга сүз бирелмәгән. Репортаж укучыны әнә шундый фикергә алып килә.

Димәк, өстән генә караганда, Татарстан язучылар берлегендә узган «мөһим» вакыйга хакында хәбәр итү вазифасын башкарган репортажның үзәгендә тәнкыйтькә тәнкыйть бар. Автор анда, татар әдәбияты буенча еллык хисапларда, докладларда шаблончылык, кызыксызлык, дәлилсезлек хөкем сөрә, бернинди анализ юк, дип белдергән. Әдәбиятның кайбер жанрлары буенча хәтта доклад сөйләүчеләр дә табылмаганлык әйтелгән. М. Гәрәев, каләм ияләренең хезмәт йомгакларына багышланган мәҗлесе хакында хәбәр бирү белән генә чикләнми; анда фикер йөртүгә, бәя бирүгә һәм укучы аңын активлаштырырлык моментларга да урын калдырылган.

М. Гәрәев репортажда, җыелышның хроникасын тудыру янәшәсендә, үзе күргән проблемаларны чишү юлларын да тирәнгә китмичә генә күрсәтеп бара[1]. Репортер, жанр формасы биргән мөмкинлекләрдән тулысынча файдаланган; сәнгатьчә чаралар ярдәмендә текстын үтемле, кызыклы итә алган. М. Гәрәевнеке кебек көнендә, үз вакытында язылган репортажлар да, айга бер генә чыгучы журналларда урын алганда, оперативлыгын югалта. Шуны күздә тотып,

[1] Гәрәев М. Мин, Чуен Гәрәй малае... Б. 334, 336.

мөхәррирләр басарга хәзерләнеп беткән басмаларда аңа урын калдырып торалар.

Язучыларның ел йомгакларында, корылтайларында укылган докладлары – үз иҗатларына еллык *хисап*лары булып тора. Гадәттә, рәисләр бу көнне Татарстанда, аның төрле шәһәрләренә һәм район үзәкләренә сибелгән нәшриятларында күпме китап басылуы, кемнәрнең кайсы жанрда нинди уңышлары барлыгы, нинди бүләкләр алулары, кемнең дөньядан китүе, кемнең берлеккә алынуы һ.б. турында саннар ярдәмендә сөйли. Аналитик эчтәлектә булырга тиешле махсус чыгышлар да күпчелек очракта хисап дәрәҗәсендә генә кала, уңышларны, авторларны, әсәрләрне коры санау рәвешендә бара. Аларның кайберләре вакытлы матбугатта чыккан язмаларга ясалган гадәти күзәтүдән ерак китми, чөнки әдәби барышка, аерым язучы иҗатына хас проблемалар күтәрелми, сәнгати процесстагы тенденцияләр ачылмый.

Әдәби әсәргә реклама рәвешендә бирелгән кечкенә язмаларны, китапның алгы яисә арткы өлешләрендә урнаштырылган *аннотацияне* кайберәүләр кече күләмле рецензия дип карасалар да, информатив ояга кертергә кирәк дип уйлыйбыз. Алардагы аннотация без күрергә гадәтләнгән рецензиянең барлык сыйфатларына да ия түгел, анда бәяләү юк, булса да, алгы планга чыкмый. Тәнкыйть хезмәтләрен өч умыртка баганасы дип саналган жанрлар тирәсенә туплауны хуплаучылар әнә шул рецензиягә хас төп сыйфатны исәпкә алып бетермәскә мәҗбүр. Башка жанр формаларын әлеге өч ояга оештырганда да, бәхәсле моментлар гел туып тора, шунлыктан андый бүленешне кабул итү авыр да.

Мәсьәләгә төрлечә якын килү сүзлекләр төзегәндә бик ачык чагыла. Әйтик, «Әдәбият белеме сүзлеге»ндә аннотация аерым да, рецензия эчендә дә карала:

1. «Аннотация – (латинча: кечкенә мәкалә) – берәр китапның, мәкаләнең һ.б. төп эчтәлеген ача торган кыскача аңлатма (характеристика). А.– китапның эчтәлеген кыскача язып аңлату.

А.-лар әдәби белешмә материалларында, китап каталогларында һ.б.ларда басылалар»[1].

2. «Китапның идея-эчтәлеген ачуны максат иткән һәм материал сайлау принцибы ягыннан бәя бирүче аннотация»[2].

---

[1] Әдәбият белеме сүзлеге: төз.-ред.: А.Г. Әхмәдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. Б.16.

[2] Шунда ук. Б. 148.

Аерма артык зур да түгел кебек, әмма, аннотацияне рецензия төренә кертү өчен, аңа «бәя бирү» сыйфаты өстәлгән. Шул ук вакытта, безнең уйлавыбызча, рецензияләр китапка «материал сайлау принцибына бәя» бирми. Бәлки, белешмәлекне төзүче авторларны я булмаса әсәрләрне сайлау принцибын ачуны яисә атауны күздә тоткандыр? Хәтта алай язу да төшенчәне ачу өчен отышлы дип булмый.

Без терминны аңлатып узганда, аның латин телендә үк салынган төп мәгънәсенә таянабыз һәм: «Аннотация – нинди дә булса басма хезмәт эчтәлегеннән кыскача белешмә»,– дигән билгеләмә төгәллек, яңгырашлылык, кыскалык, сыйдырышлылык белән аерылып тора дип саныйбыз. Информатив ояда шул тип мәкаләчекләр хакында сүз алып барырбыз да.

Бу төр белешмәләрне төрле тип басма хезмәтләрнең, шул исәптән әдәби журналларның ахыргы битләреннән табарга мөмкин. Соңгы вакытта китапларга аннотация бөтенләй көтелмәгән товарларга да урнаштыргалый. Мәсәлән, ул, интернеттан ниндидер материал белән танышып утырганда, реклама рәвешендә сәхифәң өстендә калкырга мөмкин.

Аннотацияләрдә автор турында төче эпитетлар, аның тормыш юлыннан мәгълүмат куллану артык. Кызганыч ки, нәкъ әлеге сыйфатлар татар китапларына язылган аннотацияләргә хас бер җитешсезлек булып тора. Китапка урнаштырылган белешмәне редактор язарга тиеш. Бу – шактый катлаулы эш. Кеченә күләмдә зур фикер әйтергә, моның өчен кыска язу осталыгына ия булырга, хезмәтнең эчтәлеген яхшы күзалларга кирәк. Әле бит вакыты белән редактор атна саен аннотация язарга мөмкин. Димәк, аеруча шигырь җыентыкларын тәкъдим иткәндә, аны үз-үзен кабатлау сагалый. Шуларны күздә тотыпмы, редакторлар еш кына аннотация язуны авторга йөкли. Һәм кайберәүләр, бирелгән мөмкинлекләрдән файдаланып, үзе хакында мактау сүзләре сибәргә тотына.

Типик бер мисал карап узыйк:

«*Шәүкәт Галиев – Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге һәм А. Алиш бүләге лауреаты, Х.Г.-Андерсен исемендәге халыкара почетлы диплом иясе.* Җыентыкта яңа лирик һәм юмористик шигырьләр тупланган. Аларда – шагыйрьнең егерменче гасыр азагында илебез кичергән үзгәрешләр хакында тәэсирле уй-фикерләре, яшьлек, мәхәббәт хисләре чагыла»[1].

[1] Галиев Ш. Серләрем бар: лирика, юмор. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Б. 2.

Аннотациядә безнең тарафтан махсус билгеләнгән беренче җөмләнең артыклыгы кычкырып ук тора. Икенчесендә тәэсирле дигән эпитетны куллану кирәк микән? Аны китап белән танышкан укучы үзе хәл итәр, әлегә аңа туачак яисә бөтенләй тумаячак хисне көчләп тагу нигә кирәк?

Автор үзе турында күбрәк мәгълүмат бирергә теләсә, җыентыкка кереш сүз, био-библиографик материал урнаштыру отышлырак. Әле шундый озын керешле, йомгаклы, автор мөрәҗәгате, сүзе урнашкан китапларда да алда аталган хаталар кабатлана. Гөлшат Зәйнәшеваның «Мәхәббәт һәм җыр» тупланмасының тәүге битләрен карап китик. Шагыйрә керештә, үзе, җырлар язу тарихы һәм башкалар турында язганнан соң, исеме астына титулларын куйса, бик җитәр иде, чөнки мондый традиция бар. Кызганыч ки, бу очракта да аннотациядә урынсыз рәвештә аның дәрәҗәле исемнәре санала:

«Зәйнәшева Г. Мәхәббәт һәм җыр: Шигырьләр, җырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 192 б.

Күренекле шагыйрә, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гөлшат Зәйнәшеваның яңа китабына *төрле елларда язган* шигырьләре, халык арасында *популярлашкан, шулай ук соңрак язылган* җырлары тупланды».

Аннотациядә чагылыш тапкан кайбер кимчелекләрне карап узыйк. Укучыга тәкъдим ителгән хезмәтнең яңалыгы, авторының Г. Зәйнәшева булуы, тупланманың шигырь һәм җырлардан торуы алдагы информациядән дә билгеле, әмма ул кабатлана. Китапта халык арасында киң таралмаган җырлар да очрый. «*Шулай ук*» сүзләренең нәрсәне тиңдәшлеккә куюы да аңлашылмый. Кыскасы, аннотация кирәксез һәм дөрес булмаган мәгълүмат җиткерә, стилистик дөрес формалаштырылмаган, анда артык һәм кабатланган сүзләр күп. Эчтәлеге аны укымыйча да ачык әлеге аннотацияне һич югы түбәндәгечә редакцияләргә кирәк:

*«Бу китапка шагыйрәнең төрле елларда язылган шигырьләре һәм соңгы чор җырлары тупланды.»* Аннотациядә китапка кергән әсәрләрнең тематик ояларын билгеләү исә тагын да отышлырак булыр.

Текстларга аннотация язуның төп максаты – кыска вакыт арасында укучыны аның хакында мөмкин кадәр тулырак информация белән тәэмин итү. Һәрбер кеше, кибеттә кулына теге яки бу китапны алгач, тиз генә – күз йөртеп кенә, эчтәлек белән таныша, аны үзләштереп җиткерә алмый, шунлыктан сатуда тәкъдим ителгән

продукцияләрдә тиешенчә ориентлашмый. Ул я «Эчтәлек»не, я аннотацияне укый, һәм аларның үзара кабатлануына караганда, өстәмә мәгълүмат җиткерүләре – кирәклерәк эш.

Зөлфәт Хәкимнең «Сентябрь сабаклары»ның (Татар. кит. нәшр., 2004) титул битенә «Афоризмнар, шигырьләр, җырлар» дип язып куелган, җыентыгының структурасы шул жанр формаларына бәйле, һәм «Эчтәлек»тә дә әлеге терминнар аша чагыла. Бик юка китап булганлыктан, бер-ике җиреннән ачып карауга, шулай ук жанр формаларының өч төрдә икәнлеген күрәсең. Инде аннотацияне укыйк:

«Китапта танылган драматург һәм шагыйрь Зөлфәт Хәкимнең афоризмнары, шигырьләре һәм җырлары урын алды».

Бер информация ничә мәртәбә кабатлана! Ә укучы барыбер идея-тематиканы ачыкламый кала. Әгәр автор шагыйрь һәм драматург сыйфатында бик танылган икән, бу хакта укучыга әйтүнең кирәге юк. Җитмәсә, аның прозаиклыгы исәптән сызып ташланган. Авторның һөнәрләрен санау бик мөһим дип уйлыйбыз икән... Хәер, бу урында әһәмиятле түгел шул.

Китапка аннотация язу хәтта авторларга да кыен, дигән фикер кала: кайберәүләр җыентыкларын я бөтенләй аннотациясез чыгара, я аның бер җөмләлесе белән чикләнә. Татарстан китап нәшриятында озак еллар дәвамында мөхәррир, баш мөхәррир вазифаларын башкарган Харрас Әюповның үз китапларына язылган аннотацияләрне янәшә куеп карыйк:

«Китапка шагыйрьнең чирек гасырлык иҗатыннан иң яхшы үрнәкләр тупланды» («Җәяүле буран», 1996).

«Шагыйрьнең бу китабы төрле елларда иҗат ителгән поэмаларын һәм балладасын эченә ала» («Көй эзләү», 2001).

Шунда ук аннотацияләрнең үзара охшашлыгы, иң беренче чиратта, әсәрләрнең төрле елларда язылганнарын хәбәр итүләре күзгә ташлана. Бер генә язма да китапның идея эчтәлеген ачмый. Икенчесе информациянең күбрәк булуы белән характерлы: җыентыктагы әсәрләрнең жанр формалары да билгеләнгән. Кыкасы, китерелгән мисаллардагы аннотацияләр вазифаларын таләп ителгәнчә башкармый. Әле бит аннотациядән башка гына чыккан китаплар да бихисап (Д. Салихов. Узып барышлый. Казан: Мәгариф, 2002. 271 б.).

Без югарыда Дәүләт яклавындагы, китап бастыру культурасы югары нәшриятлар чыгарган продукция турында сүз алып бардык. Шәхси оешмаларга килгәндә, алар аеруча үз хезмәтләренең ахыр нәтиҗәсенә игътибарсыз. Аннотацияләрсез язу вак шәхси нәшри-

ятларда тагын да киңрәк таралган күренеш булып тора. Бигрәк тә район җирләрендә басылган хезмәтләрдә китап культурасының түбәнлеге ярылып ята. Дөрес, тәҗрибәле мөхәррирләр эшләгән, оештырган нәшриятларда да аннотациясез китаплар басылып тора: «Мәгъсүм Насыйбуллин. Елан гадәтен үзгәртми. Казан: Матбугат йорты, 1998».

Бүгенге көндә нәшрият хезмәткәрләре кулы аша узмаган җыентыклар байтак, чөнки авторның үзе теләгән хезмәтне үзе сайлаган басмаханәләрдә чыгару хокукы кайтарылды. Андый китаплар республикадан читтә дә, «Идел-Пресс» матбага үзәгендә еш басылып тора. Мәсәлән, Рифат Җамалның «Идел-Пресс» басмаханәсендә дөнья күргән «Күңел сүрәләре» – шундыйлардан. Әлеге җыентык Р. Низаминың кызыклы гына кереш сүзе белән ачыла, әмма ул китапка язылырга тиешле аннотацияне алмаштыра алмый. Аның белән тәэмин ителеш автор белән килешенеп сайланган редактор җаваплылыгында кала.

Фән-техника алгарышы китапларның кәгазь сыйфатын, тышкы бизәлешен матурайту мөмкинлеге тудырды, әмма тизлек заманында башка төр җитешсезлекләр артты. Бигрәк тә эчтәлеккә, тел матурлыгына игътибар кимеде. Үзгәртеп кору елларына кадәр басылган китапларның күбесендә аннотацияләрнең жанр таләпләренә туры китереп язылуы бу фикерне раслап тора.

Аннотацияләрнең иң йомшаклары – пьеса җыентыкларына багышланганы, чөнки башкаручы кеше төрле темага язылган әсәрләргә бер фокус аша карамый, сүз алып барырлык таяну ноктасын тапмый. Бу очракта тематик киңлекне, хәтта жанр формаларының төрлелеген күрсәтүне урынлы санарга кирәк. Театрда кую өчен пьеса эзләүчеләргә бу мөһим булып тора. Еш кына авторлар «төрле елларда иҗат ителгән төрле пьесалар» рәвешендәге бер җөмлә язу белән канәгатьләнә. Хикәя китабында – «хикәяләр тупланмасы», роман-китапта – «фәлән исемдәге роман», кебегрәк язылган аннотацияләр бөтенләй аптырашта калдыра һәм проза жанрындагы тупланмаларны һич кенә дә бизәми. Сүзебез дәлилле булсын өчен, бер генә мисал китерик:

«Рәфкать Кәрами. Өзелгән чәчәк: *Хикәяләр*. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 224 б.

Бу җыентыкта танылган язучы Рәфкать Кәраминең төрле елларда иҗат иткән *хикәяләре* тупланган».

Аерым калын китап чыгарырлык сандагы вак хикәяләр бер елда гына язылмый торгандыр. Бу эш җитез талантлы сирәк авторлар

кулыннан гына килә, шул сәбәпле аннотациядә моны әйтү шулай ук килешле түгел. Аларның язылу вакытын белдерү бик мөһим икән, еллар аралыгын чагылдырырга, мәсәлән, әдипнең җитмешенче-сиксәненче елларда иҗат иткән әсәрләре, дип куярга мөмкин. Хәер, аларны һәр хикәя ахырында билгеләп чыгарга да була. «Төрле еллар» гыйбарәсе укучыга бернәрсә дә бирми.

Проза җыентыкларына анннотацияләр язу җиңелрәк. Бу төр хезмәтләрдә кабатланмаган аннотацияләрнең еш очравы шуны сөйли дә. Анда, аеруча әсәрләр саны аз булганда, тематиканы, сурәтләнгән чорны чагылдыру авырлык тудырмый, шуңа да карамастан проза җыентыкларына урнашкан аннотацияләрдә дә җитешсезлекләр җитәрлек.

Мисал нигезендә сүз алып барыйк. Чираттагы аннотация Вахит Имамовның «Утлы дала» тарихи романына язылган:

«Яр-Чаллы каласында яшәп иҗат итүче прозаик Вахит Имамов әдәбият сөючеләргә татар халкының милли азатлык көрәшенә багышланган «Татарларның Ватан сугышы», «Сәет батыр», «Татарлар Пугачев янында» исемле әсәрләре белән яхшы таныш. Ул – Гаяз Исхакый исемендәге бүләк иясе. «Утлы дала» дип исемләнгән яңа романында ул халкыбызның тарихының тагын да тирәнрәк катламнарына үтеп керә. Исемнәре бөтен дөньяга билгеле Чыңгызхан, Кол Гали, Юрий Долгорукий, Андрей Боголюбский, Всеволод Зур Оя образлары аша Рус һәм Болгар дәүләтләре, татар, монгол һәм кыпчак халыкларының XII–XIII гасырлардагы тормышыннан тарихи сәхифәләрне ачып сала. Әлеге роман да халкыбызның югалган һәм онытылган тарихын кайтаруда олы бүләк булыр дип өметләнәбез».

Күргәнегезчә, моны кыска белешмә дип санап булмый. Ни генә әйтелмәгән анда: Вахит Имамовның кайда яшәве дә, шунда гына язуы да, узган еллардагы уңышлары һәм киләчәккә өметләре дә. Бу укучыны күпмедер саташтыра да, чөнки кайбер әдипләр яшәү урыннарын алмаштыргалый. Хәзерге вакытта В. Имамов, мәсәлән, Казанда көн күрә. Китапны тәүге тапкыр кулына алган яшь укучы аның хакында әле дә Чаллыда яшәп язучы дип уйларга бик мөмкин.

Татар газеталарында нәшриятларда яңа басылган китапларга күзәтү ясау яисә аннотацияләр рубрикасы урнаштыру традициясе тотрыклыга әйләнде. Мөгаллимнәр газетасы саналган һәм моннан берничә ел элек чыгудан туктаган «Мәгърифәт» озак еллар дәвамында «Мәгариф»тә һәм «Мәгариф-вакыт»та чыккан китапларны пропагандалады. «Мәгариф» хезмәткәрләре вакытлы матбугат өчен

хәзерләгән махсус сәхифәләрдә хәбәргә, аннотациягә, авторлар яисә редакторлар белән әңгәмәләргә, алар эшчәнлеген яктырткан хәбәрләргә дә урын бирелеп килде. «Мәдәни җомга» белән «Казан утлары» шулай ук бик күптәннән Татарстан китап нәшрияты продукциясен тәкъдир итү белән шөгыльләнә. Әлеге басманың соңгы битенә урнаштырылган бер аннотация-рекламага күз салыйк:

«Чаллыда яшәп иҗат итүче күренекле балалар язучысы Рәшит Бәшәрнең...» – дип башлана ул. Әллә соң Чаллы язучылары үзләренең Казан кешеләреннән аерымлыкларына басым ясарга телиләрме? Мөслим, Әлмәт якларында яшәүче иҗатчыларыбыз да безгә аннотацияләр аша үзләренең кайда яшәүләре хакында даими искә төшерергә тырыша. Күрәсең, аннотацияләрне шушы калыпта иҗат итү төбәк традициясенә әверелгән. Китапларның тәүге битенә урнаштырылган белешмәләрдән башка төр хаталарны да шактый табар идек.

Аннотацияләрдәге типик җитешсезләргә шуларны кертергә мөмкин: китап турында сүз йөртмичә, авторның гомуми иҗаты турында сөйләү, текстны риторик сораулардан башлау («Нәрсә турында соң бу әсәр?» // Р. Батулла. Юл буенда зәңгәр чәчәк. 1990); драматургның сәхнәдәге уңышларын билгеләү («...уңыш белән уйналган әсәрләрен туплады...» // Д. Салихов. Яшьлек хатам – йөрәк ярам. 1998); фәлән китапка фәлән әсәр керде дип, шул ук исемне атау (Т. Нәбиуллин. Качкын, 2001); атамага жанрны куя һәм аннотациядә дә шуны ук җиткерү («... төрле елларда язылган, республикабызның төрле театрларында куелган пьесалары тупланды» // Ф. Яруллин. Пьесалар. 1998); укучылар турында уйлану рәвешендә язу («Бу әсәрләр укучыларны битараф калдырмас, дип уйлыйбыз» // Н. Хәсәнов. Сагыш. 2002); игезәк диярлек җөмләләр («Бу китапта драматургның төрле елларда уңышлы уйналып килгән сәхнә әсәрләре тупланды» // Г. Каюмов. Упкын өстендә. 2003; «Драматург Мансур Гыйләҗевнең беренче китабына аның төрле театрларда уңыш белән барган әсәрләре туплап бирелә» // М. Гыйләҗев. Бичура. 2002).

Жанр формасы таләпләренә җавап бирерлек кебек аннотацияләрне дә еш кына стилистик камилләштерергә кирәк. Мостай Кәримнең «Гомер мизгелләре»нә язган «аңлатма»ны укып узыйк:

«Башкортостанның күренекле язучысы Мостай Кәримнең әлеге китабына күренекле әдипләр, замандашлары турында истәлекләр, фәлсәфи уйланулар, халыкның акыллы хикмәтләре, якташлары тормышыннан алынган тирән мәгънәле хикәяләре туплап бирелде».

Бу җыентык Татарстаннан читтә яшәүче авторныкы, әдәбияттан хәбәрсез укучыда ялгыш фикер тумасын өчен, аның хакында кыска гына мәгълүмат артык булмас. Әлбәттә, текстка стиль төзәтмәләре кертергә кирәк: бер үк җөмләдә *күренекле* сүзенең ике мәртәбә кулланылуы аны бизәми, шунлыктан икенчесен танылган кебек яисә башка синонимнар белән алмаштыру хәерле. Аннотацияне «Китапта М. Кәримнең күренекле әдипләр, замандашлары турында истәлекләре, фәлсәфи уйланулары, халыкның акыллы хикмәтләре, якташлары тормышыннан алынган тирән мәгънәле хикәяләре туплап бирелде» дип язу тагын да отышлырак.

Күпчелек аннотацияләр, редакцияләнмәү аркасында гына, таләпчән укучыны канәгатьләндерми, югыйсә бу зур көч тә сорамый. Әйтик, аларда әсәрләрнең тормышны чагылдыруы турында җөмләләр еш очрый. Әдәбиятның, гомумән алганда да, тормышка нигезләнүе инде һичкемгә яңалык түгел, аннотацияләрдән китапның үзенчәлекле ягын атау, эчтәлеген ачу көтелә.

Кайбер белешмәләрдә охшаш фикерләрнең, сүзләрнең берничә мәртәбә төрле формаларда очравы аеруча эчне пошыра. Мисал: «Мәхмүди Заһид. Әче балан: *Кыйссалар, хикәяләр, фәлсәфи уйланулар*. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 206 б.

Җыентыкка кергән *кыйссалар, хыялый хикәяләр, фәлсәфи уйланулар* һәм үзенчәлекле шигырьләр тормышның үзенә, андагы вакыйгаларга нигезләнеп язылган. Аларда безнең бүгенге көнебез, кеше һәм җәмгыять арасындагы мөнәсәбәтләр, һәркайсыбызны нык борчыган наркомания, хөсетлек, икейөзлелек кебек проблемалар сурәтләнә».

Югарыда китерелгән аннотациядә беренче җөмлә артык, чөнки икенчесендә әсәрләрнең тормышның кайсы ягына нигезләнүе, нинди проблемаларны яктыртуы ачык күренә. Аннан соңгы җөмлә эчтәлекне төгәл һәм тулы ачуы белән аерылып тора. Димәк, аннотацияне редакцияләү өчен, артык җөмләне сызып ату да җитә. Әдәби тәнкыйтьнең кече төрләрендә генә дә җитешсезлекләрнең күплеге тагын бер кат махсус белгечләр тәрбияләү кирәклеген, бу проблеманың үтә актуальлеген күрсәтә.

Биографик белешмәләрне, рәсми автобиографияләрне, әдәбиятка кагылышлы сорауларга җавап рәвешендә тутырылган анкеталарны да информатив оянең периферик жанрлары рәвешендә карап узарга мөмкин. Мисалга Һ. Такташның «Автобиография»сен китерик. Анда язучының тормыш юлы бик тәфсилле тасвирлана,

әлеге материаллар аның иҗатчы буларак нинди шартларда өлгерүен ачык күрсәтеп тора. Автобиографиянең әдәби тәнкыйть өчен аеруча кызыклы өлеше – әдипнең үз мирасыннан әһәмиятле дип аерып алган әсәрләр исемлеге[1].

Болардан тыш, автор автобиографиясенә, тормышын, карашларын аңлауда мөһим дип санап, әдәби тәнкыйть мәкаләләрен һәм әсәрләрен дә терки. Һ. Такташның «Үтенеч хат»ларында да әдәби хәрәкәткә кагылышлы мәгълүмат бар[2]. Шагыйрьнең ТАПП ка язган гаризасы исә «Ялчы» газетасында үзенә карата басылган ялаларга җавап һәм язучы хокукларына дәгъва рәвешендә. Димәк, хәтта гаризалар да хәбәрчек, авторецензия, реплика, аңлатма һәм башка калыпларга ия була ала. Тәнкыйть тарихы өчен андый язмаларны өйрәнү дә кирәк. Әйтик, Һ. Такташның «гариза»сы авторга багышланган тәнкыйть мәкаләләренең объективлык-субъективлыгын тикшергәндә, әдәби тәнкыйть тарихын язганда таянырлык чыганак булып тора. Анда язучының иҗат мәсләген ачкан юллар бар:

«Мин партиянең тоткан юлы, алган идеаллары нигезендә үсәргә, бүгенгенең көрәш җырын җырларга омтылам. Шагыйрьлегемнең үзем һәм җәмәгать өчен булган бөтен кыйммәте бары шул омтылышлар белән иҗатымны бәйли алуымда гына дип уйлыйм. Мин һәм минем иҗатым бары партиянең бөек теләкләре белән генә яши ала. Ул коммунизм идеясе көрәшенә корал була алса гына яшәргә тиешле»[3].

Язучыларның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнгәндә, әдәбиятчыларга резюме да ярдәмгә килә. Ул безгә европа, америка кадрлар менеджменты практикасыннан узды һәм бүгенге көндә эшкә алу технологиясендә актив кулланыла, хәтта күп җирдә, бигрәк тә Рәсәй Федерациясендәге чит ил компанияләрендә автобиографияләрне тулысынча алмаштырды.

Резюмега (французча résumé – җыелма хәбәр ( «сводка») дигәнне аңлата) синоним буларак латинчадагы curriculum vitae (кури́кулюм ви́тэ) – татарчадагы «тормыш агымы», «тәрҗемәи хәл» яисә безнең илдә гомуми кулланышта йөргән автобиография төшенчәләрен

---

[1] Такташ Һ. Автобиография // Такташ Һ. Әсәрләр. 3 томда Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Т. 3. Б. 360–363.

[2] Такташ Һ. Татарстан Советлар Җөмһүрияте Башкарма комитетына үтенеч, 1929 ел, 17 апрель // Такташ Һ. Әсәрләр.Т. 3. Б. 364–366.

[3] Такташ Һ. Татарстан пролетариат язучылары оешмасына гариза, 1930 ел, 19 май // Такташ Һ. Әсәрләр. Т. 3. Б. 366–369.

китерәләр. Шул ук вакытта «җыелма хәбәр»ләрдә кандидатка кагылышлы фактлар күбрәк җиткерелергә тиеш дип карала.

Резюме – кешенең эш тәҗрибәсе, осталыклары, белеме турында хәбәр итүче документ ул. Каләм иясе, мәсәлән, әдип яисә галим, теге яки бу мөһим эшкә конкурс аша узганда, анда фәнгә яисә иҗат мәйданына килү юлларын, иҗади-гыйльми осталыкларын, бастырган хезмәтләрен, авторлык патентларын, аларның фән яисә әдәбият үсешендәге ролен, чит кызыксынуларын күрсәтергә мөмкин. Ул эшкә чакыручының игътибарын Сезнең шәхескә юнәлтүне, талантларын ачуны максат итә.

Резюмеларның һөнәри (универсаль), хронологик, функциональ, хронологик-функциональ, максатчан һәм академик формалары була. Шуларның соңгысы, мәсәлән, галим-педагогларның эш эзләвендә файдаланыла. Боларда фәнни эшләрне, мәкаләләрне, алар аша ирешкән уңышларны, шул исәптән бүләк-исемнәрне дә санау мәҗбүри шарт булып тора.

Бу урында фәнни хезмәтләргә язылган резюмелар турында да әйтеп узарга кирәк. Алар белән кыска күләмле аннотацияләр арасында охшашлык зур, кайвакыт аерма да булмый. Терминнарга бирелгән кайбер билгеләмәләр дә моның шулай икәнлеген күрсәтә. Д.Н. Ушаковның аңлатмалы сүзлегендә резюменың сөйләгән, укыган, язган текстлардан, төп нигезләмәләрне чагылдырып, кыскача нәтиҗә ясау икәнлеге әйтелә[1].

Кайбер жанр формаларының төрле характердагысы була алганлыктан, күздә тоткан мәкаләләрне, төп сыйфатларына таянып, теге яки бу төргә кертәбез. Күргәнебезчә, информатив ояга берләшкән язмалар эчендә дә аналитик фикер, проблемалы абзацлар очрарга мөмкин. Бер караганда, кечкенә генә информацияне укучыга җиткерү, әйтик, аннотация язу өчен дә, башта фактлар тупларга, аларны төркемләргә, күңелдән анализларга, аз күләмдә зур фикер сыйдырырлык оригиналь һәм үтемле җөмләләр табарга кирәк.

Информатив оя эчендә некролог-хәбәрләргә дә тукталырга кирәк. Грекча «үлгән» һәм «сөйләм» сүзләреннән килеп чыккан әлеге төшенчә белән теге яки бу каләм иясенең вафаты хакында киң җәмәгатьчелеккә ирештерү максатыннан хәзерләнгән публицистик башлангычлы кыска күләмле язманы атыйлар. Соңгы дәвердә вакытлы матбугатта аларның, танылган әдипләр, сәнгатькәрләр, галимнәр

[1] Резюме // Толковый словарь Н.Д. Ушакова. slovari.yandex.ru.

вафатына мөнәсәбәтле рәвештә, тотрыклы калыпта язылганнары күзәтелә башлады. Әлеге некрологларда шәхеснең тормыш һәм иҗат юлыннан мәгълүмат китерелә, әдәбият-фән мәйданында ирешкән уңышлары санала, үлеменең сүз сәнгатебез һәм милләт өчен зур югалту икәнлеге әйтелә. Язучы бик нык танылган очракта хушлашу сүзе астына мәрхүмнең каләмдәшләре, җәмәгать эшлеклеләре һ.б. алдыннан төрле дәрәҗәдәге хакимият башлыклары кул куя.

Некрологның тарихы шактый озын. Аның татар тәнкыйтенә караган тәүге басма үрнәкләре К. Насыйри календарьларында очрый. XX гасыр башында милли матбагалар ачылгач, некрологлар шактый еш языла башлый. Әлеге калыпның активлашып алуы иҗтимагый чорга да, шул чордагы бер-бер артлы килгән зур югалтуларга да, милләттәшләре бик нык хөрмәтләгән аерым шәхеснең үлеменә дә бәйле.

Татар тарихында иң күп некрологлар, мөгаен, Тукай вафатыннан соң язылгандыр. Бердән, милли үзаңның бик нык үскән вакыты. Икенчедән, матбугат мәйданы киң. Өченчедән, Тукай – шул матбугатны үстерүгә, иҗтимагый фикер үсешенә зур өлеш керткән шәхес. Болардан тыш, каләм иясенең карендәш халыклар әдәбиятына да йогынтысы ачык күренерлек дәрәҗәдә. Шулай итеп, некролог бөек шәхес белән хушлашу турындагы хәбәрне бөтен төрки дөньяга һәм хәтта кан-кардәш булмаган халыкларга да ирештерә.

Некрологларның кайчандыр күп төрләре актив кулланган. Аның мәкалә, эссе, сыктау һәм башка калыптагылары бар. Эчтәлеккә һәм калыпка мөнәсәбәттә, алар тәнкыйть жанрларының төрле ояларында каралырга тиешле. Әйтик, эссе-некрологны әдәбипублицистик ояда өйрәнү лазем.

## 5.3. Аналитик төрләр

Әдәби тәнкыйтьнең икенче зур төркеме әдәби күренешләргә аналитик якын килгән язмаларны тәшкил итә. Боларга: *рецензия; әдәби күзәтү; проблема күтәргән әңгәмәләр, әдәби берәмлекне бәяләү характерындагы эпистоляр язмалар, гыйльми анализга нигезләнгән комментарийлар; фәнни бәхәсләр һ.б.* керә, әмма бу исемлекне тагын да киңәйтү җае бар. Кайвакыт санап узган жанрлар да үзара кисешә: проблемалы әңгәмә бәхәс төсен алырга, эпистоляр язма да, әдәбият хакында аерым фикерләрне теркәү белән генә чикләнмәскә, комментарий, әдәби күзәтү һәм башка характерда булырга мөмкин. Кайберәүләр әдәби портретларны я

аналитик оя эчендә, я әдәби-публицистик язмалар төрендә карый. Аналитик төр а) социаль, полемик очерк-портретлардан; б) әдәби барыштагы актуаль күренеш-хәлләрне анализлаган яисә шәрехләгән теоретик һәм проблематик мәкаләләрдән; в) монографик, проблемалы-публикацион, библиографик рецензияләрдән; г) әдәби күзәтүләрдән тора дип санаучылар да бар.

Информатив төр белән чагыштырганда, аналитик материаллар масштаблылык, фикер тирәнлеге, фактларны һәрьяклы анализлау, дәлилле, эзлекле фикер йөртү кебек сыйфатлар белән аерылып тора. Аларның беришләренә алдарак ныклап тукталырбыз.

Әдәбияттагы охшаш күренешләрне туплау һәм аерым нәтиҗәләргә килү, әдәбият белеменең, әдәбиятның актуаль проблемаларын чишү, сәнгати берәмлекне, авторның язу стилен аңларга тырышу һәм башка сәбәпләр – аналитик язмалар иҗат итүгә китергән мотивлар. Әнә шуңа күрә дә бу төр хезмәтләрдә фактлар шәрехләнә, өйрәнелә, янәшә куеп карала, чагыштырыла, фәнни эшкәртелә.

Тәнкыйть жанрлары арасыннан иң киң таралганы – рецензия. Рецензиягә билгеләмә бирүдә чуарлык күзәтелә. Берәүләр әдәби әсәргә бәясе булган теләсә кайсы тәнкыйть язмасын рецензия дип саный. Икенчеләр рецензиянең үзенә генә хас сыйфатламаларын таба һәм тар мәгънәдә генә аңлый. Әлбәттә, бу буталчыклык хәл ителергә тиеш, чөнки ул белешмәлекләр төзегәндә зур кыенлыклар китереп чыгара. Рецензиянең киң мәгънә алуының бер сәбәбе классификацияләү проблемасына, тәнкыйди язмаларны шул исем тирәсенә берләштерүгә дә, баба форма булуына да барып тоташа.

Галимнәребез кайбер русча хезмәтләргә таянып төзегән «Әдәбият белеме сүзлеге»ндә рецензиягә «Аерым бер китап турында сөйләп, аның мисалында гомуми әдәби хәрәкәткә кагылышлы әһәмиятле темалар күтәргән, бу әсәр тирәсендә бәхәс кузгатып җибәргән критик яки публицистик *мәкалә»*; «Китапның идея-эчтәлеген ачуны максат иткән һәм материал сайлау принцибы ягыннан бәя бирүче *аннотация»*; «Китапны укып чыккач, тәнкыйтьче башында туган уйларны лирик чигенешләр белән сөйләү (*эссе*); «авторның үз китабына каршы яки бу китапка карата әйтелгән фикерләргә җавабы» – *авторецензия* кертелгән[1].

Югарыда үзенең типик сыйфатламалары белән танылган рецензия чагылыш тапмый. Жанрларга аңлатмалар да бәхәсле.

[1] Әдәбият белеме сүзлеге . Б. 148.

Авторлар, гадәттәгечә бер жанрны икенче жанр атамасы аша ача. Белешмәлектә рецензия терминының мәгънә эчтәлеген тасвирлаучы тәүге абзац исә нәкъ менә аны аерым төр итеп тану кирәклегенә ышандыра да: «Рецензия (латинча: тикшерү, карау) – әдәби тәнкыйть жанры. Р. гадәттә, китапка библиографик күзәтү ясый, кыскача гына булса да, эчтәлеген сөйли яки күтәргән проблемалары турында мәгълүмат бирә, авторы белән таныштыра, файдаланган материалы һәм композициясе турында фикер әйтә»[1].

Күргәнебезчә, классификациядә терминга гомуми аңлатма калыплаштырганда, авторлар аңа үзләре тарафыннан кертелгән «төрләр»нең һәрберсенең дә төп билгеләмәгә җавап бирмәвен исәпкә алмаган. Безнеңчә, аерым бер китапка яисә әсәргә мөнәсәбәтле язылган һәр тәнкыйть язмасын рецензия оясына тупларга телибез икән, аның 5 төрен аерып чыгарырга һәм аңлатмаларга да үзгәреш кертергә кирәк. Галимнәребез исә бу очракта рецензияне ике төрле аңлауны отышсыз берләштергән.

Кайбер сүзлекләрдә, мәсәлән, журналистлар төзегән белешмәлекләрдә, рецензияне шушы рәвешчә аңлауга өстенлек бирелә: ул әдәбият һәм сәнгатькә, фәнгә, журналистикага караган әсәрләр хакында мөнәсәбәт белдерүле хөкем йөртә һәм газетаның башка жанрларыннан (очерклардан, корреспонденциядән, зарисовкадан, репортаждан һ.б.дан) предметының чынбарлык факты булмыйча, ә китап, рисалә, фильм, спектакль, телетапшыру кебек мәгълүмати күренешләр булып торуы белән аерыла. Рецензия, гадәтә, бер-ике әсәргә бәя бирә һәм үз алдына артык катлаулы бурычлар куймый[2].

Инде әдәбият белеме сүзлекләренә мөрәҗәгать итик: «Рецензия – ( латинчадан: рецензио – карау) – әдәби тәнкыйтьнең замана әсәрен актуаль шәрехләүче һәм бәяләүче төре.

Рецензия – тәнкыйть жанры: әдәби әсәргә бәя бирү һәм тикшерү максатыннан җавап (отклик).» Рецензиядә библиографик белешмә бирелә, әсәрнең проблематикасы, әдәбилек сыйфатлары характерлана, язучының үз иҗатында һәм заман әдәбиятында тоткан урыны билгеләнә[3].

Т. Гыйләҗев «Рецензияләрдән – тәгъзияләргә» хезмәтендә, XX гасыр башы материалларына таянып, аның татар тәнкыйтен-

---

[1] Әдәбият белеме сүзлеге . Б. 148.

[2] Рецензия. URL: smi.academic.ru

[3] Рецензия // КЛВТ. URL: slovari.yandex.ru

дәге актив төркемнәрен аерып күрсәтә (кыска, күзәтү рәвешендәге, монорецензия, рецензия-мәкалә, авторецензия) һәм бик уңышлы мисалларын китерә[1].

Әдәби рецензия сәнгать өлкәсенә караган рецензияләрнең дә баба формасы булып тора, әмма алар арасында шактый гына аерма бар. Иң башта рецензияләр, эчтәлек һәм композицион төзелешләре буенча *монологик* (һәм уйланма, һәм башкару авторныкы гына булган әсәрләргә), *башкаручыныкыларга* (язучы әсәренең интерпретациясенә) бүленә. «Театрда, кинода, телевидениедә, автордан тыш, режиссерлар, актерлар, операторлар, музыкантлар һәм башкалар катнаша, һәм рецензия автор (режиссер) уйланмасын гына түгел, ә аны тормышка ашырган башкаручылар коллективының, әлеге коллектив звеноларының да эшен бәяләргә тиеш[2], дип яза А.Г. Бочаров.

Татар тәнкыйтендә сәхнәләштерелгән әсәрләрне анализлау традициясе көчле. Автор һәм режиссер уйланмасы артистлар тарафыннан тормышка ашырылганнан соң текстка бәя бирү – бик кирәкле бер эш. Ахыр чиктә, пьесалар нәкъ менә сәхнәләштерелү өчен языла лар да. Шунысы бар: автор идеясе белән режиссерныкы һәрвакытта да туры килми яисә артистлар коллективы алар теләгәнчә уйнарлык талантка, амплуага ия булмый.

Әдәбиятчылар еш кына сәхнәләштерелгән әсәр белән китаптагысы арасына тигезлек билгесе куялар һәм тамашаны әдипнең генә әсәре кебек анализлыйлар, бәялиләр, бу исә – зур хата. Уйналу вакытында хәтта текстка да үзгәрешләр кергән булырга мөмкин. Драма әсәрләренең сәхнәләштерелмәгән килеш, саф әдәби берәмлек сыйфатында да үз мәгънәсе, кыйммәте бар. Бәлки, алар сәхнәдә уйналганыныкыннан зуррак та булыр. Әле бит режиссерлар сәхнәләштерелүе һич мөмкин түгел дип санаган әсәрләр дә яшәү һәм бәяләнү хокукына ия. Бу урында татар-башкорт халкының пьесалар укырга яратканлыгын, алар белән яхшы танышлыгын да истә тотарга кирәк.

Бер авторның эпик яисә лиро-эпик әсәренә нигезләнеп, икенчесе пьеса язган очраклар торган саен ишәя. Бу вакытта текстның идея эчтәлегенә кергән үзгәрешләрне, һичшиксез, истә тотарга, әдәби берәмлектә һәр авторның үз өлешен күрә, бәяли белергә кирәк. Әйтик, проза әсәренә таянып башкарылган инсценировка-

[1] Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән – тәгъзияләргә. Б. 24–58.

[2] Бочаров А.Г. Жанры литературно-художественной критики. М.: Изд-во Моск. ун-та, 1982. С. 16.

ның отышсыз чыгуы беренчел вариантның сәнгатьлелек дәрәҗәсен чагылдырырга яисә яңадан эшкәртүченең таланты белән дә бәйле булырга мөмкин.

Әсәрне сәхнәләштерүчеләр, яңа вариантта язучылар еш кына автор уйланмасын үзгәртәләр, мөһим фикерләрен юкка чыгаралар, яңаларны өстиләр, ә әдәби текстны укымаган тамашачының «эшкәртелгән» вариантны тәүге авторныкы кебек кабул итүе бар. Игълан-буклетларда текст үзгәрешләре тегеләйме-болаймы чагылыш табарга тиеш. Тәнкыйтьче рецензиясендә режиссер яисә текстны хәзерләүче әдәби әсәргә керткән үзгәрешләрне күрсәтергә, уйнаучыларның әсәрне һәм үзләре башкарган образны ни рәвешле шәрехләвен ачып бирергә бурычлы. Бу урында «Зөләйха» пьесасының Г. Исхакый кулы белән язылганын, сәхнәләштерелгәнен, киного төшерелгән вариантларын анализлау һәм, иң мөһиме, табыла калса – текстның идея эчтәлегенә һәм сәнгати эшләнешенә зыян салган аермаларны күрсәтү урынлы булыр иде.

Театраль тәнкыйть белән гади мәдәният хезмәткәрләре дә, театр белгечләре дә, әдәбиятчылар да шөгыльләнә. Бер үк сәхнәләштерелгән әсәр буенча аларның язганнарында аерма зур була. Берәүләре артистлар уйнавы, сәхнәләштерү үзенчәлекләре, декорация, бутафория, кием-салым турында сөйләүгә урын күп бирә. Әдәбият галимнәре пьесаның идея эчтәлегенә, теге яки бу геройны характерлауга, конфликтка һәм аның чишелешенә игътибарын ныграк юнәлтә. Әлеге язмалардан сәнгатькәрләрнекендә сәхнә кануннарын ныграк белеп фикер йөрткәнлек күренә. Тәнкыйть тарихын өйрәнүчеләр, тәнкыйтькә тәнкыйть язучылар өчен төрле тип язмаларны үзара чагыштыру шулай ук кирәк.

Соңгы елларда әдәбиятчыларның спектакльләр буенча артистлар уенын да киң чагылдырып язган мәкаләләре еш басыла, әмма барыбер рольләрне башкаруга сәхнә таләпләре ноктасыннан чын мәгънәсендә тәнкыйди якын килү юк. Асылда әлеге мәкаләләр барыбер драматургиянең үзенә тәнкыйть булып кала, шул сәбәпле дә без аларны татар әдәби тәнкыйте барышын, аерым чордагы үсешен яктыртканда исәпкә алабыз.

Әдәби рецензия, әдипнең генә түгел, тәнкыйтьченең дә таланты чарлануга, аның да дөрес юлдан үсүенә ярдәм итә; укучыга тормыштагы катлаулы вакыйгаларны тагын да дөресрәк аңларга булыша. Әдәбиятчы, рецензия язганда, автор күреп яисә аңлап бетермәгәнне эзләп таба, бөтен кешеләр өчен тигез дәрәҗәдә

аңлаешлы булмаган әсәрләрнең асылын ача, идея-тематик киңлеген күз алдыбызга китереп бастыра.

Тәнкыйди осталык формаль анализ ясауга, әдәбият һәм тормыш кануннарыннан сабак бирүгә генә кайтып калмый. Язучының позициясе, гуманистик идеалларга тугрылыгы кебек хәлиткеч күренешләр ул иҗат иткән әсәрдә ни дәрәҗәдә сәнгатьчә гәүдәләнеш тапкан, ул тудырган геройлар кайсы яклары белән кадерле, аларда тормыш чынлыгы никадәр – тәнкыйть мәкаләсендә болар барысы да киң яктыртылырга тиеш. Әсәрнең көчле якларын, йомшакларын ачып салу, үзәккә куелган конфликтын ассызыклау, аерым бер мөһим моментларын калкуландыру, башкаларыннан аерып күрсәтү шулай ук әдәби рецензия өстенә төшә.

Әдәби тәнкыйть материаллары, шул исәптән рецензия әсәрне популярлаштыруда зур роль уйный. Ул, әдәби хәрәкәттә кайсы традицияләрне алга сөрергә, нинди матур яралгыларны башкалар яисә автор киләчәктә язачак әсәрләрдә үстерергә тиешлекне язуы белән, әдәбиятның алга китешенә булыша.

Бүгенге әдәби рецензиянең милләтнең иҗтимагый аңын формалаштыруда роле аеруча зурайды, шунлыктан ул язучыга милләт һәм Милли Ватан алдында җаваплылыгын тирәнрәк аңлап эш итәргә тиешлеген һәрдаим исенә төшереп торырга бурычлы. Моңа кадәр, бирәк тә совет чорында, яисә башка халыкларның басмаларында милләтне бетерү файдасына эшләгән фикерләрнең череклеген дә әдәби тәнкыйть бик үтемле фаш итә ала.

Әдәбият-сәнгать әсәрләрен пропагандалап, аерым бер идеяләрне үткәреп, халыкны эстетик һәм әхлакый тәрбияләү чарасына әйләнгән рецензиягә, аны иҗат иткән рецензентка кайбер башка гомуми таләпләр дә куела. Ул үз материалының нинди максатка хезмәт итәргә тиешлеген баштан ук билгеләргә, ягъни кем һәм ни өчен язганын белергә тиеш.

Рецензиянең кайсы вакытлы матбугат органына юллануына бәйле таләпләр дә бар. Газета һәм журналларны алдыручылар эш урыны, белем дәрәҗәсе, социаль чыгышы, яше белән аерыла. Әйтик, кече һәм урта яшьтәге балаларга адресланган «Сабантуй» да басылган мәкалә әбүнәчеләре «Шәһри Казан»ныкына ошый алмый. Беренчесендә язучы турында мәгълүматка, әсәрнең идея-тематик эчтәлегенә һәм тәрбияви әһәмиятенә зур урын бирелсә, икенчесендә аның бүгенге әдәби барышта урынына, шулай ук идея эчтәлегенә, тормыш белән якынлыгына һәм башка сыйфатларына игътибар ителә.

Журналларда, сүз сәнгатенә яисә фәнгә гаид күләмле айлык яисә атналык газеталарда, гадәттә, тирән эчтәлекле, төзелеше нык уйланылган, әдәбият сөючеләргә кызыклы, стиле матур, камил мәкаләләр басыла. Гыйльми нигезле, актуаль яңгырашлы, фән үсеше өчен мөһим рецензияләр иң элек «Фәнни Татарстан», «Мирас» («Безнең мирас») кебек журналларга тәкъдим ителә, фәнни-популяр рухтагылары күбрәк «Казан утлары»нда дөнья күрә, әдәбиятны укыту алымнарын да үз эченә алган язмалар «Мәгариф» («Совет мәктәбе»), «Фән һәм мәктәп» кебек журналларга җибәрелә.

Журнал газеталардан оперативлыкта калыша, шунлыктан аларда халык арасында инде популярлашкан, нык таралган әсәрләр хакында рецензияләр дә еш басыла. Аларда эчтәлекнең киңрәк булуы, әдәби әсәргә җентекле анализ ясалу, китаптагы уңай һәм кимчелекле якларның калку күрсәтелүе яхшы. Мәртәбәле фәнни журналларның авторлары – күбесенчә галимнәр. Тәнкыйтьче буларак, алар һәрвакыт үз алларына, беренче чиратта, язучының үсешенә ярдәм итү бурычын куярга тиеш.

Газетада басылган рецензиядә төп игътибар китапны укучылар массасына пропагандалауга, популярлаштыруга юнәлдерелә. Анда әсәргә анализ икенче планга да күчкәли. Газеталар элегрәк укучы фикере, аның тәнкыйть мәкаләсенә мөнәсәбәте белән күбрәк кызыксына һәм, теге яки бу рецензия чыгу уңаеннан, әдәби бәхәсләр дә оештыра иде, әмма бу эш соңгы елларда сүлпәнәйде.

Китапларга язылган рецензиянең үзендә үк урын алырга мөмкинлеген, вакытлы матбугатта басылмаса да, тупланмаларга кертелүен, элеккерәк елларда радио-телевидение аша да яңгыравын әйтергә һәм мәгълүмат чарасына бәйле үзенчәлекләре турында да сөйләргә мөмкин.

Тар мәгънәсендә рецензия жанры турында сүз алып барганда, алда китерелгән билгеләмәләрдән дә күренгәнчә, аның китапка библиографик күзәтү ясавы, кыскача гына булса да эчтәлеген җиткерүе, күтәргән проблемалары турында мәгълүмат бирүе, авторы белән таныштыруы, файдаланган материалы һәм композициясе турында фикер әйтүе ассызыклана. Тикшерү объекты сыйфатында сайланган нәфис текстны каләм иясенең башка әсәрләре янәшәсенә куеп карау аны тагын да кызыклы итә, яңа хезмәтнең, язучы иҗатында гына түгел, гомуми әдәби хәрәкәттәге урынын да билгеләргә, күзалларга булыша.

Дөрес, көндәлек матбугаттагы һәр рецензиядә аның барлык сыйфатлары сакланмый. Әгәр шулай булса, бу форма бик шаблонлашыр, кабатлануы белән туйдырыр, укучыны тәнкыйтьтән ерагайтыр иде. Рецензияләрдә, мәсәлән, библиографик белешмә очрамаска мөмкин. Күп авторлар, аерым бер әсәр турында фикер йөртсәләр дә, аларның әдәби барыштагы, милли әдәбияттагы урынын билгеләү проблемасын чишми.

Редакция заказы буенча язылган рецензияләр дә була. Аларны эчке рецензия дип йөртәләр. Бу төр язмаларның бурычы – автор кулъязмасын объектив бәяләү, басмага бары тик яхшы әсәрләрне генә уздыру, сайлап алу, теге яки бу текстларның камилләшүенә хезмәт итү. Аны редакциянең штаттагы хезмәткәрләре яисә читтән чакырылган тәнкыйтьче башкара.

Текстларга мөнәсәбәтле шәхси фикерләрне теркәүнең башка юллары да мәгълүм. Әдәби әсәргә комментарийлар – бәя белдерүнең шулай ук киң таралган чарасы, калыбы, алымы. Бу төр язулар китап кырыйларында очрый, укучыга хат формасында ирешә, истәлекләрдә һәм башка җирләрдә урын ала, махсус хезмәтләр рәвешендә дә басыла. Үзара әңгәмә, язма фикер алышулар вакытында да каләм ияләре теге яки бу әсәрне шәрехләп үтәләр.

С. Ожегов һәм Н. Шведова сүзлекләренә таянганда, «Комментарий дип 1) нинди дә булса текстка аңлатмалы искәрмәләргә; /.../ 2) нидер хакында хөкем йөртүләргә, аңлатмалы һәм тәнкыйди искәртүләргә әйтәләр»[1]. Беренче мәгънәсендәге шәрех күпчелек очракта астөшермәләр рәвешендә төп текст белән янәшә бирелеп бара. Хронологик тәртиптә текст артыннан урнаштыру традициясе дә бар. Икенче мәгънәсендә комментарий информативлык төсмере дә ала һәм иҗтимагый-сәяси тормышның теге яки бу хәлләрен, фактларын анализлый, аңлата.

Узган чорлар мирасына караган нәфис әдәбиятка, бигрәк тә академик басмаларга язылган комментарийлар төп текстны өстәмә мәгълүмат ярдәмендә ача, киңәйтә, киңкатлам укучы аңларлык итә. Бу төр шәрехләр китапның, хезмәтнең соңгы битләрендә аерым өлеш яисә бүлекчә рәвешендә урын ала. Әдәбиятчыларның, журналистларның иҗат алымы да булып торган комментарий барлык жанрларда да кулланыла ала. Аны хәтта фәнни хезмәтләрнең структурасында да файдаланырга – зур язманың һәр чираттагы

[1] Комментарий // Толковый словарь русского языка: С. Ожегов, Н. Шведова. URL: slovari.yandex.ru

өлешен алдагы бүлек яисә бүлекчәгә комментарий рәвешендә оештырырга мөмкин.

Кайберәүләр, шәрех мөстәкыйль материал була алмый, ә бары тик ниндидер язманың фрагменты гына саналырга тиеш, ди. Икенчеләр, шәрех теге яки бу тексттагы аерым урыннарны, гомумән текстны, анда күтәрелгән проблеманы, әдәби барыштагы эш-хәлләрне аныклаучы күләмле мөстәкыйль язма була ала, дигән фикердә тора. Андый шәрехләр тәнкыйтьнең башка жанрлары белән бик нык якыная, керешә, тәңгәлләшә һәм мәкалә төренә әйләнә, дип әйтүчеләр дә бар. Димәк, комментарийларны бүлүдә шулай ук бәхәсле моментлар калган. Көнчыгышның язма мирасында шәрехнең мөстәкыйль форма була алуына мисаллар җитәрлек.

Киңәйтелгән шәрехләр язарга шарт-сәбәпләр күп. Әйтик, тәнкыйтьче язучыларның теге яки бу проблемага багышланган җыелышыннан анда яңгыраган фикерләр белән килешмичә кайтып китте ди. Ул аңа оператив рәвештә публицистик, публицистик-гыйльми комментарийлар яза ала. Белгечләр фикеренчә, бу төр хезмәтләрдә иң мөһиме – ниндидер мәсьәләне аныклап узу һәм бәяләү; шул ук вакытта анализның тулы булуы мәҗбүри түгел.

2016 елда Гүзәл Яхина әсәре буенча интернет челтәрендә барган фикер алышуларда (форумнарда) кайберәүләр әдибә «Зөләйха» романында татар тормышыннан алып тасвирлаган күренешләрнең чын асылын, ул аңламаган мәгънәләрен күләмле язмалар аша шәрехләп уздылар. Вакытлы матбугатта дөнья күргән очракта аларны публицистик комментарий дип атаулары мөмкин иде.

В.В. Ворошилов, А.А. Тертычный һәм башка галимнәрнең хезмәтләрендә комментарий аналитик төргә керә дип карала[1]. Ул информатив язмаларга карата икенчел булып тора. Галимнәр шәрехләрнең *киңәйтелгәнен; белгеч авторлыгындагысын; полярын* (төрле белгечләр аңлатуындагы); *синхронын* (сөйләм, уку барышындагы), *тәфсиллесен* аерып күрсәтәләр.

Шәрех рус тәнкыйтендә, жанр буларак, нибары XX гасырда гына формалаша дип санала, ә менә Көнчыгыш халыкларында комментарий язу – киң таралган һәм бик озын тарихлы күренеш. Коръәннең гарәп телендәлеге, әдәби әсәрләрнең дә гарәпчә-фарсыча иҗат ителүе һәм киң массаларга аңлаешсызлыгы, аларның

[1] Ворошилов В.В. Журналистика: учеб. 7-е изд., стер. М. : КНОРУС, 2010. С. 179; Комментарий // Тертычный А.А. Жанры периодической печати. URL: studbooks.net

дини эчтәлектәге әсәрләрне хата төшенеп гөнаһланам дип куркуы яисә теге яки бу галимнең дини текстларны башкаларның аңлатуы белән килешмәве һәм башка сәбәпләр татарда да герменевтиканы шактый үстергән. Дини юнәлештәге хезмәт кенә булмыйча, әдәби җәүһәрләрдән дә саналган Коръәнгә, аерым аятьләренә тәфсир язу, хәдисләрнең эчтәлеген аңлату эше һаман дәвам итә, аңа зур әдипләребез дә алына. Әйтик, танылган прозаик Рабит Батулла «Коръән аятьләренең татарча мәгънәләре һәм аңлатмалары» китабын бастырды. Бу урында галимнәрнең, тәнкыйтьчеләрнең дини-дидактик рухтагы нәфис текстларга да шәрехләр язуы хакында да искә алып узарга кирәк.

Миллионлаган кешеләр табынган хезмәтләргә комментарий хәзерләү эшенә бик җитди якын килергә кирәк. Бу уңайдан Р. Батулланың «Акчарлак» газетасы журналисты Габдрәхим сораулары на биргән җаваплары гыйбрәтле. «Коръән серләре»нең тәрҗемәсе хакында ул түбәндәге фикерләрне әйтә:

«Гариф Гобәйнең китабын укымаган кеше калмагандыр. Ул китап ел саен басыла килде, чөнки ул вакытта динне сүгү мода иде. Гариф Гобәй динне, Коръәнне сүгүгә алынды һәм бик зур ялгышлык эшләде. Үзенә генә түгел, бөтен татар милләтенең йөзенә кызыллык китерде. Ул бит анда бик күп ялган язды. Һәм бик күп әйберләрне ул үзе дә аңламаган. Әбугалисинаны ул динсез дип саный. Китапның башында эпиграф булып Әбугалисина сүзләре китерелә: «Минем юлым хакыйкать, мин бары тик хакыйкатькә ышанам». Гариф Гобәй: «Әбугалисина үзе дә Аллага ышанмаган», – ди. Хакыйкатьне Гариф Гобәй үзенчәрәк, коммунистларча аңлаган. Хакыйкать дигән сүз, Хак – Аллаһы Тәгалә дигән сүз ул. Минем юлым бары тик хакыйкать һәм мин бары тик хакыйкатькә инанам, мин Аллаһка ышанам дигән сүз ул. Беренче сүзендә үк ялгыш шәрехләгән һәм китапның буеннан-буена Коръәнгә каршы сүз. Изге китапка кизәнергә ярамый. Динне хурларга кушсалар, мин ул эшкә алынмыйм. «Коръән серләре» фәнни әсәр түгел, уйдырма һәм ул Коръәнне хаксыз тәнкыйтьли»[1].

Әңгәмәдәшләр Тукайның Коръәнне тирәннән өйрәнгән һәм, гомумән, бу өлкәдә зур белгеч саналган М. Бигиевнең: «Тәмуг бар, ләкин барыбер гөнаһысы өчен янганнан соң бөтен кеше чистарынып оҗмахка керә», – дигән сүзләрен көлкегә алуына да кагылып

[1] Габдрәхим. М. Бигиев сүзләреннән Тукай көлгән бит. URL: khalkym-minem.ucoz.ru›index/rabit batulla kor…gob…

уза. Шагыйрь тәнкыйтенә мөнәсәбәттә Рабит Батулла шушындый фикер әйтә:

«Тукай ул – сездәй, бездәй кеше, ләкин аңа бөек талант бирелгән. Ул кайчакта хаксыз, кайчакта хаклы, төртмәле, энәле булган. Кайчакта кызып китеп үзенең дусларын да чәнчегән. Сүнчәли, Рәмиевне чәнчегән дә, соңыннан үкенеп йөргән чаклары да булган. Ләкин тегеләр аңа үпкәләмәгәннәр, дус булудан туктамаганнар. Тукай әйткән сүз закон булырга тиеш дигән сүзгә мин бик ышанып бетмим. Тукай да бит ул – дөнья кешесе. Муса Бигины 13 тапкыр төрткәли ул, аның бакчасына таш ыргыта. Ләкин Тукай хаклы түгел: «Муса Коръәннән ялгыш тапкан», – ди. Муса Коръәннән ялгыш тапмаган, Коръәнне шәрехләүчеләрнең ялгышын тапкан. Бу икесе – ике әйбер. Коръәндә хата юк, шәрехләүчеләрдә булырга мөмкин. Курсави да үзеннән алда килгән шәрехләрне төзәткән. Муса Биги Тукайның сатирасына үпкәләмәгән, үзен унөч тапкыр тәнкыйтьләп чыккан кешене газетага (Петербургка) эшкә чакыра»[1].

Дини текстларга гына түгел, әдәби тупланмаларда искәрмә тамгасы куелган сүзләргә комментарий язуга да игътибарлы һәм сак якын килү тиешле. Шәрехчеләрдән тирән белем, төгәллек, язганны кат-кат тикшерү сорала. Безнең тупланмаларда кимчелекле язмалар шактый күп. Бу хаталар җыентык төзүдән үк башлана. Мәсәлән, С. Рәмиевнең «Таң вакыты»[2] (1980) җыентыгына Г. Исхакыйның «Хәлимә туташ» хикәясе кертелгән. Әлеге хикәя югары уку йортларында Торгынлык елларында С. Рәмиевнеке сыман бәяләнде һәм укытылды. Җыентыкны төзүче XX гасыр башы әдәбиятының зур белгече Шәйхи ага Садретдинов иде, әмма җаваплылыкны аңа гына кайтарып калдырырга ярамый. Бердән, мондый зур эшләр, нигездә, коллектив күзәтүе, тикшерүе астында башкарыла, икенчедән, чыганакларны табу мөмкинлеге булмаганда, андый хата «ачыш»ларга юл кала. Өченчедән, совет чорында бик азларның гына Г. Исхакый иҗатыннан танышлыгы бар иде. Текстлардан хаталарны табып төзәтү эше ул – килер буыннарның да бер вазифасы, чөнки, бүгенге тизлек белән хезмәт иткәндә, ни генә тырышсаң да, ялгышлардан тулысынча арыну бик авыр. Шул ук вакытта бигрәк тә тәнкыйтькә кагылышлы язмаларны хатасыз башкару – бер идеалдыр.

[1] Габдрәхим. М. Бигиев сүзләреннән Тукай көлгән бит.

[2] Рәмиев С. Таң вакыты: шигырьләр, хикәяләр, сәхнә әсәрләре, публицистика: төз., кереш сүз һәм искәрмә-аңлатмалар авт.: Ш. Садретдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 272 б.

Тупланмага ялгыш кергән әсәргә аңлатма шушы рәвешчә бирелә: «Хәлимә туташ. Бу хикәя С. Рәмиев эшләгән «Тавыш» газетасының 1907 ел, 30 апрель (2) санында имзасыз басылган. Табигатьтәге гүзәллек һәм гармониягә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне романтик кискен каршы куеп сурәтләү һәм әсәрнең тел-стиль үзенчәлекләрендә (сүзләрне, гыйбарәләрне бер озын җөмләдә яисә рәттән берничә җөмләдә әледән-әле кабатлап китерү һ.б.) С. Рәмиев стиле ярылып ята. Әдип җыентыгына беренче мәртәбә кертелә».

Әдәбиятны, барлык әдипләрнең язу манерасын яхшы белгән һәм тоемчан галим, үзе иҗат эше белән шөгыльләнүче бигрәк тә хикәядә нәкъ менә Г. Исхакыйның кыска хикәяләр язу стиле «ярылып ятканлыкны» күрәчәк һәм әсәрне С. Рәмиевнеке дип санамаячак. Шунысы сөенечле: Г. Исхакый әсәрләре әйләнеп кайтканнан соң, яңадан басылганда «Хәлимә туташ»ның авторы кем икәнлек киңкатлам укучыга да билгеле булды.

Хаталану, барлык очракта дип әйтерлек, фаразны реальлек дип тәкъдим итү яисә чынбарлык итеп күрергә теләү, мәсьәләне махсус өйрәнмәү, китапханәләрдә эзләнмәү, әдәби әсәрне укып чыкмыйча гына фикер йөртү аркасында да була.

Текст эчендә тамгаланган гыйбарәләргә, сүзләргә бәйле рәвештә, галимнәр еш кына әдәби күренешләр турында фикер йөртәләр, теге яки бу фактларны, прототипларны ачыклыйлар һәм аларны аңлатма рәвешендә китапның соңгы сәхифәләренә урнаштыралар. Нәкъ менә шул төр комментарийларда фаразга зур урын калдырыла, тарихи, фактик төгәлсезлекләр еш очрый. Ф. Әмирхан язган хаттан өзек китерик һәм аңа шәрехне карап узыйк.

«... Дачага чыгу Осланга булмады, бәлки Ботанич. Сад янында бер квартира алдык. ...Вафа белән Кәбир җидесендә күченәләр.

...Мин кичә «Күңелле иде ул вакытлар...» исемле бер хикәя яза башладым. Хикәянең сюжеты сезнең дачада уздырган көннәремез. Анда минем Лизаны сөюем, Ибрайның «Кикүәк»ләре, Кулиның җырлары, Солтанның гармуннары, сүгешләремез, паштитлар – һәммәсе булачак.

... Ш. туташ мәсьәләсенә килгәч, «ахры, минем любовь та синеке белән бертуган» дияргә мәҗбүр булып торам әле. Можешь ли представить себе, мин бу арадагы бер-ике сәбәпләр белән Х. хатыны сеңлең З. гә влюбиться итеп торам булырга кирәк, ахры...

Матур түгел, әллә ник миңа мәхәббәтле күренде һәм...»[1] (Искәрмә саннары төшерелеп калдырылды.)

Исмәгыйль Аетовка. 1909 ел, 5 май, Казан. Беренче мәртәбә басыла. Автографы Г. Ибраһимов исем. институт архивында саклана (16 ф., 3 тасв., 4 эш). Исмәгыйль бу вакытта Урта Азия шәһәрләренең берсендә була.

Текст автографтан алынды.

Хат шушы китапның 268 нче битендә урнаштырылган.

Ф. Әмирхан һәм аның иптәшләре Казанның хәзерге Һ. Такташ урамындагы Литовченко йортын җәйге ял урыны итеп арендага алганнар.

Вафа – Вафа Бәхтияров. «Әльислах» газетасының рәсми редакторы.

Кәбир – «Әльислах»ны оештыручылардан Кәбир Бәкер.

Сүз «Фәтхулла хәзрәт» повестеның беренче кисәге «Фәтхулла хәзрәтнең үлеп терелүе басылып чыгу турында бара (Казан, «Үрнәк» матбагасы, 1909 ел, 32 б.)

«Татар кызы» хикәясе 1909 елны Казанда «Сабах» китапханәсе тарафыннан бастырып чыгарыла. 20 бит.

«Күңелле иде ул вакытлар хикәясе» әдипнең «Картайдым» хикәясенә аваздаш булырга охшый.

Лизаны сөюем – ?

Ибрай – Ибраһим Әмирхан.

Ибраһим Кулиев – аның турында 343 нче биттән карагыз. Ул матур гына җырлый торган булган. Аның тарафыннан башкарылган «Ашказар», «Корсын балам бу кала» һ.б. җырлар революциягә кадәрге татар пластинкаларына, башкаручы «Азаматов» (?) исеме белән язылган булганнар.

Солтан Рахманколый гармунда уйнаган.

Ш. туташ – Шәмсениса Мөхәммәд-Закир кызы Камалова»[2].

Әгәр автор сүзнең ни өчен «Картайдым» хикәясенә ошавы турында аналитик фикер йөртсә, сорау куелып киткән урыннарга шул рәвешчә җавап бирергә омтылса, язма аналитик комментарий булыр иде, болай информатив характердагы аңлатма гына булып калган. Чагыштырма-типологик анализ ике әсәр арасында охшашлык

---

[1] Әмирхан Ф. Исмәгыйль Аетовка // Әмирхан Ф. Әсәрләр: 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Т. 4. Б. 271.

[2] Әмирхан Ф. Исмәгыйль Аетовка. Б. 369–370.

юклыгын да ачачак. «Картайдым»да яшьлек идеаллары, милләткә хезмәт итү теләге сүнгән яшь егетне хәтта мәхәббәт турында истәлекләрнең дә газапка гына салырга сәләтлеге турында бара. Әлеге әсәр татар иҗтимагый тормышына, аның көндәлек яшәешенең төссезлегенә бер тәнкыйть сыман кабул ителә, шунлыктан ул «Вактөяк» исемле тупланмага кертелгән дә.

Дөрес, «Картайдым» язылуга дачада яшәгән вакытта Кабан күлендә ял итүләр, Лиза (хикәядә – Нина) исемле кызны сөюләр этәргеч биргән һәм анда ике арадагы мөнәсәбәт сурәтләнгән булырга мөмкин, әмма әлеге әсәрдә Ф. Әмирхан хатта тасвирлаган геройларның башка берсе дә очрамый.

Яшьләрнең җыелып ял итүләре, ашау-эчүләре, күңел ачулары вакыйгасы үзәккә куелган әсәрләр Ф. Әмирханда берничә. «Көндезге сәхәр яки рузасызлар», әйтик, шундый. Димәк, без аларның барысын да анализлап чыгарга тиеш булабыз.

Төп герое Рашад рус кызы Аляга гашыйк булган «Кадерле минутлар» хикәясен карап узыйк. Ул аның белән яз көнендә Ботаник бакчадан ерак түгел Кабан өстендәге күпердә очраша. Шулай икән, вакыйга барган урын, вакыт туры килә. «Бер көймәдә скрипка һәм гармун белән «Сакмар су» көен уйнап» киләләр. Игътибарга лаек деталь. Искә алырлык моментлар бу хикәядә күбрәк һәм автор белән булган җәйге вакыйгалар аны да мотивлаштыра ала икән. Әсәрнең язылу вакыты да шул тирәдәрәк.

Тыелган мәхәббәт темасы, рус кызларына гашыйк булу мәсьәләсе Ф. Әмирхан тарафыннан еш күтәрелә. Бу аның үз тормыш тәҗрибәсенә бәйледер дә. Шуларның иң көчлесе – әлбәттә, «Хәят» повесте. Язылып бетүе Ф. Әмирхан хатыннан соң бераз вакыт үткәч – 1911 елның 18 июлендә. Повесть язу тиз арада була алмый. Автор бер үк вакыйгалардан башта хикәяләр язарга, соңыннан күләмлерәк әсәрләргә күчәргә мөмкин. Повестьта без Лиза исемле чибәр рус кызы белән очрашабыз.

Ф. Әмирхан хат юллаганда, «Күңелле иде ул вакытлар» әле языла гына башлаган була, һәм, безнеңчә, ул авторның тәүге планындагыча башкарылмый. Дача вакыйгалары берничә хикәягә нигез итеп алына. Аннан соң автор башка елларда да яз-җәйдә шул ук урында яши[1].

Хәер, Ф. Әмирхан үзе дә башлаган хикәясе тәмам ителер яисә мөстәкыйль әсәр булыр дип вәгъдә бирми, «Кичә ярымын язып

[1] Әмирхан Ф. Исмәгыйль Аетовка. Б. 286.

ташладым инде. Настроение булса, бүген язып тәмам да итәрмен. Аннан соң иске хикәяләремнең берәрсе белән кушып бастырырмын дип уйлыйм»,– ди[1].

Авторның язылa башлаган хикәясе томлыкларының беренчесенә «Дача» исеме астында теркәлгән тәмамланмаган әсәре дә була ала. Ул үзе хатта да төп сюжетны фаразлау хәлендә калдыра. «Дача»ның ахырында яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләр тасвиры, рус һәм татар кешеләренең психологиясе каршы куелган моментлар булачагы шик астына алынырлык түгел. Язылган өлеше әлегә күләмлерәк бер әсәрнең өчтән бер өлеше сыйфатындарак кабул ителә. Димәк, бу хикәя шушы урында өзелеп калырга, ә күңелдә йөргән күренешләр башка хикәяләрдә урын алган булырга мөмкин. Ф. Әмирханның Р. Алушига юллаган хатларында аңа кире әйләнеп кайтмавы да шуның белән аңлатыла торгандыр.

Кыскасы, без охшаш мотивлы хикәяләрнең барысын да бергә тупларга, үзара чагыштырырга һәм кайсы әсәр турында сүз баруына кагылышлы фикерне дәлилләргә, моны укучыга да җиткерергә тиеш булабыз. Күрәсез: кеп-кечкенә мәкаләчек язу өчен дә автор бик күп эшләргә тиеш. Әлегә без дә мәсьәләгә якын килү юлларын өстән-өстән генә күрсәттек.

Шәрехләр белән язучыларның персоналийларында күп очрашабыз. Кайчандыр төзелгән «Тукай» белешмә-сүзлеге шундыйлардан иде. Аның өчен язылган мәкаләләр зур фәнни тикшеренүләр, шулар нигезендә төрле нәтиҗәләргә килүләр, гомумиләштерүләр көтә дип уйлыйбыз. Алар Тукай иҗатына мөнәсәбәтле проблемаларны чишкәндә зур таяныч булып тора. Бу төр аннотацияләр аеруча төгәллек һәм фикерне җыйнак әйтү сорый. Профессор Р.К. Ганиева тарафыннан язылган мәкаләләрнең берсен карап узыйк:

«Толстой сүзе (Кирәк анчак...)»

«Толстой сүзе (Кирәк анчак...)» (1913) – фәрд. Бер генә бәеттән торган фәрд – Шәрык әдәбиятларындагы иң кечкенә әдәби жанр. Шигырь юллары унберәр иҗектән торган, анафора, эчке һәм тышкы рифмалар белән бик тә сәнгати бизәкләнгән бу фәрдне «хикмәт», «хикмәтле сүз» дип тә атарга мөмкин.

Яшәү фәлсәфәсен гәүдәләндергән бу фәрднең нигезендә халык мәкалләре традициясе һәм Толстойча белдерелгән фәлсәфи-эстетик карашлар ята. Кешеләр җирдә ни өчен яшиләр? Әллә байлык туплау өчен генәме? Мондый сорауларга Тукай болайрак җавап җирә:

[1] Әмирхан Ф. Исмәгыйль Аетовка. Б. 271.

Кирәкми анчак яшәр микъдар ашарга,
Кирәкми тик ашарга да яшәргә.

Җирдә яшәүнең максаты – Толстой һәм Тукай фикеренчә – халыкка хезмәт итү идеалларын тормышка ашыруга юнәлдерелгә булырга тиеш.

«Толстой сүзе (Кирәк анчак...)» «Аң» журналының 1913 елгы 7 санында (15 март) басылган. Кульязмадан фотокүчермә биштомлык Тукай әсәрләренең (1985) икенче томында бирелгән.

Әсәрләр: Тукай Г. Биштомлык, 2 т., 272 б.»[1].

Дөрес, белешмә-сүзлектән соң «Тукай энциклопедиясе» дә дөнья күрде инде, һәм аңа мәкаләләр язуның шактый катлаулы эш икәнлеген татар галимнәре, хезмәтнең фәнни мөхәррирләре аны хәзерләү барышында тагын да ныграк аңлады.

Шәрехләүнең күләмле һәм кызыклы төрләре – әсәрләргә язылган кереш һәм соң сүзләр. Билгеле ки, китапның алгы һәм арткы өлешләренә урнаштырылган һәр мәкаләнең шәрех рәвешендә булуы катгый бер күренеш түгел, андыйлар, киресенчә, сирәгрәк очрый. Теге яки бу сыйфатлары аларны рецензиягә, авторецензиягә дә тартым итә.

XIX гасырда, XX гасыр башында әдәби әсәрләргә редакторлар яисә автор тарафыннан шәрех язу бер «мода»га әйләнә. Әлбәттә, бу очракта да моңа төп сәбәп – укучылар арасында зур күпчелекнең әдәбиятны аңлауга хәзерлексезлеге.

Заманының иң катлаулы әсәрләреннән булган һәм милләт каршында зур вазифалар башкарачак «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ның беренче өлеше – һичшиксез, автор тарафыннан иҗат ителгән күләмле шәрех. Ул әсәрнең идея-тематик эчтәлеген, язылу максатын мөмкин кадәр җыйнак ачып бирә, әнә шуңа күрә язманың тәүге абзацлары шушындый юллар белән башлана: «„Ике йөз елдан соң инкыйраз“ны язудан максудым –...», «Бу китапта минем милләткә карашым ничек икәнлеге күрендеге кеби, китмешемезне үзгәртсәк, минем бу өметсезлегем урынына «өмет» тууы да мөмкин икәнлеге ачык белдертелгәндер»[2].

---

[1] Ганиева Р.К. Шагыйрьнең рухи дөньясы («Габдулла Тукай» энциклопедиясе сүзлек-белешмәсенә әзерләнгән материаллардан). Казан: ТаРИХ, 2002. Б.46–47.

[2] Исхакый Г. Ике йөз елдан соң инкыйраз // Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. Т. 1. Б. 154.

Төп өлешнең «Мәрхәмәтле Алла теләсә» дип башлануы, чынлыкта да, беренче кисәкнең әдәби әсәргә карамавын күрсәтеп тора. Мисалга китерелгән комментарий үз заманында язылган шәрехләрнең типигы түгел, ә Г. Исхакый китапларыннан аларның гадәти формадагыларын күрсәтергә мөмкин. Мәсәлән, «Бай угылы»ның ике басмасына да авторның укучыга мөрәҗәгате басыла. Шуның беренчесе – киң һәм әсәрне ничек аңларга кирәклекне өйрәтү рәвешендә. Анда риторик сораулар, эндәшләр мул кулланылган. Автор укучы белән ике арада диалог булдырырга тырышкан, аның күңелендә туачак сорауларны үз авызыннан әйткән һәм җавабын да биргән, китапны уку өчен күрсәтмәләр дә язган: «...сездән назыйре гыйбрәт берлән карап, Кәримнең һәммә эшенең, һәр хәрәкәтенең сәбәбене тикшереп укуыңызны үтенәм»[1].

Ә инде укучының әдәби зәвыгы үскәннән соң басылган китапка әсәрдә булган хаталар өчен гафу үтенү һәм аларның төзәтелмәү сәбәпләрен генә аңлату бар[2]. Бүгенге көндә өлкәннәр өчен язылган нәфис әдәбиятны ничек укырга кирәклек хакында инструктаж уздыру әдәбият сөючеләрне аптыраушта калдырыр иде.

Укучыларга мөрәҗәгать рәвешендә язылган беренче мөкаддимәне, кайбер формаль билгеләреннән чыгып, хат дип тә санарга булыр иде. Г. Исхакый «Кәләпүшче кыз»га, үз аңлатмаларыннан тыш, *укучы хаты*н да урнаштырган. Әлеге хатта әдип язган әсәргә бәяләмә зур урын алып тормый, укучы анда Г. Исхакый тасвирланган хәлләргә охшаш күренешләрнең тормышта да булганлыгын һәм үзенә билгеле вакыйгаларның тагын да кызганычрак икәнен әйтә. Хат Г. Исхакый кулланган материалның чынлыгы, тәэсирлеге турында сөйли[3].

Әдәби тәнкыйть фикерләре чагылган мәктүпләр язу өчен, аларның авторын нидер дулкынландырырга тиеш. Һәм ул шуның тәэсирендә кайсы да булса эшне, адымны, карашларны кире кага яисә яклап чыга. Әдәби тәнкыйтькә кагылышлы хатларга яшь алмашка остазларның күрсәтмәләре, теоретик күзаллауларын чагылдырган язмалары керә ала. Рус тәнкыйтендә ул төргә мисаллар аеруча күп. И.С. Тургеневның дусларына юлланган кайбер хатлары,

[1] Мөхәммәд Гаяз. «Бай углы»ның беренче басылуына мөкаддимә // Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. Т. 1. Б. 113.

[2] Шунда ук. Б. 114.

[3] Маһиҗиһан анасы Гафифә. Мөхәммәд Гаяз әфәнде! // Исхакый Г. Әсәрләр. Т. 1. Б. 154.

мәсәлән, нигездә, әдәбиятка кагылышлы фикерләрдән генә тора. 1853 елның 21 апрелендә П.В. Анненковка адреслап язганы әсәрләрне, авторларны, төрле халыклардагы тәнкыйтьне янәшә куя, типик охшашлыклар таба, әдәби тәнкыйтькә хас проблемалар күтәрә:

«Я все время читал переписку Мерка, друга Гете, с которого Гете списал Мефистофеля, подпустив в него диаволщины. Это был человек, одаренный необыкновенно верным критическим взглядом. Ни в одном суждении он не ошибся. Нашей литературе нужен бы такой человек. Хоть бы так судить о произведениях – не скажу как потомство, а как обыкновенная публика судит о них пять лет после их появления! А то явится что-нибудь новое – нет у нас критической силы отдаления предмета, при всей любви к нему – которая позволила бы нам обнять его взглядом. ... сказать о вещи – она хороша или дурна – мало; талантливый критик направляет дарование, уясняет ему его задачу. Мерк – как Сократ – любил, чтобы его называли повивальной бабкой чужих мыслей». Күзәтүләреннән чыгып, автор үзе өчен дә кирәкле нәтиҗәләр ясый:

«Что же касается до «Дяди Тома», которого я на днях прочел – то меня самого поразила мысль – что ведь пожалуй и Аким такого же калибра. Ваше письмо подтвердило это впечатление – вследствие чего я себе дал слово этаких вещей более не писать»[1].

Узган гасырның икенче яртысында әдәбиятка, язучыга, аерым әсәргә мөнәсәбәтле фикерләр уздырган хатларны А. Гыйләҗевнең күп язганлыгы билгеле. Шулай да кәгазьдә теркәлгән эпистоляр хезмәтләрнең чоры узып бара. Каләм ияләре укучылар белән дә, галимнәр белән дә, дуслары белән дә хатларны, нигездә, электрон почталар аша алмаша, шунлыктан алар тарих сәхифәләрендә теркәлеп калмый диярлек.

Әгәр әдипләребез XX йөзнең беренче яртысында актив язышмаган булса, без бүген, ул чор әдәби барышын тасвирлаганда, бай материалга таяна алмас идек. Алар арасында бигрәк тә М. Җәлил, Ә. Фәйзи һәм башкаларның фронт хатлары үзенчәлекле урын алып тора һәм гадәттән тыш авыр шартларда да каләм иясенең халкының рухи тормышы, әдәбияты, аны саклау, үстерү юллары турында уйланганлыгын күрсәтә. Галимнәребез һәм тәнкыйтьчеләр, шул юнәлештә махсус шөгыльләнеп, төрле давыллы чорларның эписто-

[1] Тургенев И. П.В. Анненкову // Тургенев И. Полное собрание сочинений и писем: в 13 томах. М. – Л.: Изд. АН СССР, 1961. Т. 2. С. 144–146.

ярикасын, төрмәләрдән, ял йортларыннан, окоплардан язылган хатларны үзара чагыштыра һәм кызык нәтиҗәләр ясый алырлар иде.

XX гасыр башы әдәби хәрәкәте авторлар һәм газета-журнал идарәләре, мөхәррир һәм әдип арасындагы теге яки бу әсәргә мөнәсәбәтле фикер алышулар, эшлекле сөйләшүләр рәвешендәге хатлар белән дә истә кала. Кайбер хатлар ул чорда еш кына ике кеше арасындагы бәхәсне чагылдыра яисә теге яки бу авторның авторецензиясе сыйфатында языла. Мәсәлән, Ф. Әмирхан 1910 елның 23 мартында «Йолдыз» идарәсенә, аның мөхәрриренә «Фәтхулла хәзрәт»кә фельетон һәм рецензия бастырулары уңаеннан язма юллый. Кечкенә тәнкыйть мәкаләләренә каршы җавап бирү гадәте булмаса да, андагы җитешсезлекләрне күрсәтергә мәҗбүрлеген әйтә. Хат ике өлештән тора, беренчесе – гадәти авторецензиягә якын, икенчесе алдагы өлештә әйтелгән фикерләрне фельетон рәвешендә яңадан белдерә[1].

Хатлар аша әдәбияттагы күренешләргә мөнәсәбәт белдерү, алар хакында фикер алышу, иҗатны яклау, теге яки бу әсәр эчтәлеген аңлату һәм башка күренешләр утызынчы еллар ахырынача бик көчле була. Мәсәлән, М. Җәлил мирасханәсендә сакланган хатларда утызынчы еллар әдәби хәрәкәте шактый киң күзаллана, алардан бигрәк тә язучының үз иҗат биографиясенә кагылышлы мәгълүматны мул алырга мөмкин. Бер мисал китерик. 1937 елның август урталарында М. Җәлил «Кызыл Татарстан» редакциясенә Ф. Мөсәгыйтьнең газетаның унынчы август санында чыгарган мәкаләсенә мөнәсәбәт белдергән хат юллый. Ул анда авторның Татар опера студиясенең эшчәнлеген дөрес тәнкыйть итүен, ләкин үзенә бәйле кайбер юлларда хата фикерләр барлыгын ача:

«Ф. Мөсәгыйть үзенең мәкаләсендә минем тарафтан язылып ята торган кайбер әсәрләр турында «М. Җәлил иптәш «Алтынчәч», «Балыкчы кыз»ны яза, ләкин... алар бүгенге көн сорауларына җавап бирерлек булмыйлар»,– ди. Аннан: «...аның (Төхфәтуллинның – М.Ж.) биргән темалары да үзләренең исемнәре һәм эчтәлекләре белән бераз уйга калдыралар»,– ди дә, шул әсәрләр арасында «Балыкчы кыз» белән «Алтынчәч»не күрсәтеп, түбәндәге юлларны өсти: «Болар, бүгенге көн продуктлары булудан бигрәк, совет эшчеләр сыйнфы тарафыннан җимерелгән иске тормышның үлем

[1] Әмирхан Ф. «Йолдыз» идарәсенә // Әмирхан Ф. Әсәрләр: 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Т. 4. Б. 278–280.

алдында, актыккы сулышларын алганда хыяллану нәтиҗәсендә туган «җимеш»ләренә охшыйлар».

Башлап «Балыкчы кыз» турында:

«Балыкчы кыз» әле минем тарафтан язылып беткәне юк, бер җирдә дә укылганы да, тикшерелгәне дә юк. Бары үткән ел студия каршындагы бер киңәшмәдә аның планы гына тикшерелде һәм төбендә темасы, сюжеты ярарлык табылды. /.../ Шулай булгач, Ф. Мөсәгыйть бу әсәр белән бөтенләй таныш түгел. Тик аның исемен генә ишетеп белә».

М. Җәлил язылачак әсәрләренең эчтәлеген сөйли, актуальлеген аңлата, тәнкыйтьченең әсәр исеменнән чыгып фикер йөртүен, белмәгән хезмәткә сәяси ярлык ябыштырырга маташуын әйтә. Хатта Ф. Мөсәгыйтьнең башка ялганнары да ачыла, шагыйрь аның «РАПП тәнкыйтьчеләренчә» эш иткәнлеген билгеләп уза.[1]

Бу төр хатларның күпләп саклануы өчен без күпчелек очракта редакцияләргә бурычлы. Совет чорында аларга килгән хатлар архивлаштырыла һәм автор кулына кире кайтарылмый иде. Бүгенге көндә бу эш тукталды диярлек. Димәк, әдәбиятка кагылышлы хатларны өйрәнүче тәнкыйтьче кулланырга мөмкин чыганаклар саны көннән-көн кими бара.

Каләм ияләре тарафыннан үзләре иҗат иткән әсәргә бирелгән тәнкыйди бәя, анализ *авторецензия* дип атала. Анда автор хисләргә бирелергә, үтә субъектив булырга да мөмкин. Шәхси текстка гадел анализ ясау һәм дөрес нәтиҗәләргә килү өчен, ул хезмәтенә чит кеше, әйтик, икенче галим, башка тәнкыйтьче яисә укучы күзе белән карарга тиеш. Үзтәнкыйтьтән башка бу төр язмаларның объективлыгына ирешеп булмый.

Авторецензияләр соңгы вакытта презентация, тәкъдим итү кичәләре уңаеннан еш иҗат ителә. Ул шулай ук авторның үз китабына урнаштырылган Кереш рәвешендә дә очрый, кайчак көтмәгәндә вакытлы матбугатта кабынып киткән бәхәсләрдә дә катнаша.

Каләм ияләре әсәрләренең эчтәлеген аңлатып язган кайбер хатлар авторецензиягә тартым. Авторецензияләрнең тәнкыйтьче тарафыннан әсәренә карата әйтелгән тискәре фикерләрне кискен яисә тупас рәвештә кире кага торганнары да очраштыра. Андый хезмәтләр әдипне аклау, яклау яисә әсәрен уңай планда ачу максатыннан язылса да, автор шәхесенә карата тискәре мөнәсәбәт уятырга мөм-

[1] Җәлил М. Әсәрләр: 5 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. Т. 5: Сәнгать турында мәкаләләр һәм хатлар. Б. 226–229.

кин. Әлбәттә, һәр тәнкыйть язмасы авторны диалогка яисә бәхәскә тартып кертми. Әдипләр күпчелек очракта, тәнкыйтьче фикерләре белән килешепме-килешмичәме, тискәре бәяләмәләрне игътибарсыз калдыралар яисә оппонентларга реплика әйтү белән чикләнәләр.

Репликага билгеләмәләр күп. Аны аңлауда төрле өлкәләргә бәйле аерымлыклар бар. Ул шулай ук тар һәм киң мәгънәләрдә кулланыла. Н.Д. Ушаков сүзлегендә репликага бирелгән билгеләмәләрнең әдәби тәнкыйть өчен дә туры килгәннәрен китерик: «*Реплика* /…/ (фр.: réplique; лат.: replico) – тагын, янына өстим. 1. Бер әңгәмәдәшнең икенчесе сүзләренә җавабы, каршы төшүе, искәртү ясавы. /…/ 3. Оратор сөйләменең эчтәлегенә карата урыннан торып кычкырып кую, каршы төшү, кисәтү ясау»[1].

Әдәби тәнкыйтькә караган реплика төшенчәсе теге яки бу жанр эчендә кулланылган сәнгати алымны яисә әдәбиятка мөнәсәбәтле карашларны кире кагуны, иясенә җавап бирүне, аңа берәр искәрмә ясауны да аңлатырга мөмкин икән. Талантлы әдипләр үз иҗатларына таләпчән якын килә, шунлыктан алар кайвакыт сәнгати яктан йомшак әсәрләрен күпертеп мактаучыларга каршы да төшкәлиләр. Әйтик, Фатих Әмирхан Ризван Алушига юллаган бер хатта: ««Яшьләр» тугрысында берникадәр отзывлар алдым. Яшьләр «Яшьләр»не бик, хәтта артык яраткалыйлар икән. Бу да бер нәүгы партия тәгассыбы бит.

«Яшьләр»нең художеств. җәһәте бик начар бит»[2], – дип, үз әсәре хакында кыскача гына тискәре фикер белдереп уза.

Реплика төшенчәсен киң мәгънәдә бер темага язылган күләмле шәрех, фикер-хөкем дип аңлаучылар жанрның аналитик, теоретик, проблематик планда язылган мәкалә һәм рецензия төрләрен күрсәтәләр.

Тәнкыйтьнең киңкатлам укучыларга, бигрәк тә әдәбият сөючеләргә, галимнәргә һәм язучыларның үзләренә дә кызыклысы – әдәбиятны киңрәк иңләгән, үсештәме-торгынлыктамы, әллә артка ук китештәме икәнлеген дә чамаларга мөмкинлек биргән, сүз сәнгатендәге мөһим күренешләрне ассызыклаган, теге яки бу әсәрнең әдәби барыштагы урынын да ачыклап узган *әдәби күзәтүләр.*

«Күзәтү (обозрение, обзор) – 1. Журнал тәнкыйте жанры. Тәнкыйди К.-дә, гадәттә, агымдагы әдәбиятка караган бер яисә

[1] Реплика // Толковый словарь русского языка Н.Д. Ушакова. URL: slovari.yandex.ru.

[2] Әмирхан Ф. Ризван Алушига // Әмирхан Ф. Әсәрләр. Т. 4. Б. 283.

берничә жанрдагы (повесть, хикәя, поэма) әсәрләрнең билгеле бер җыелмасы тикшерелә; бу вакытта әдәби үсешнең күзәтелгән чорга хас үзенчәлекләре һәм тенденцияләре анализлана»[1].

Әдәби күзәтү, редакция яисә язучылар оешмаларының почтасына нигезләнеп, тәүге тапкыр каләм тибрәтүчеләр иҗатына да, агымдагы әсәрләргә дә ясалырга мөмкин. Тәнкыйтьнең үзенә дә күзәтү эшләү аеруча мөһим, чөнки ул аны тирәнәюгә, фәннилеккә, эзлеклелеккә, үсешкә әйдәүче бер юл булып тора.

Вакытлы матбугатыбызда исемле тәнкыйтьне бастыру – шактый кыен, еш кына булмастай бер эш. Бүгенге көндә кыю тәнкыйтьчеләр җитмәүне актуаль бер проблема итеп күтәрсәк тә, кыю редакторлар хәзерләү турында онытабыз; әдәби әсәрләрендә башкалардан милли мәнфәгатьләрне яклап көрәшүне таләп иткән язучы-редакторларының милли сүз иреге сагында торачагына юкка өметләнәбез. Димәк, мәсьәләгә икенче яктан, редакция коллективларын тәрбияләүдән якын килергә кирәк. Ә бу, үз чиратында, шулай ук әлеге төр язмаларны бастыруны таләп итү, аларны язудан туктамау, яшь алмаш хәзерләү аша чишелә ала, ягъни әлеге мәсьәләләр бер үк күренешнең ике башына барып тоташа.

Әдәби күзәтүнең тикшерү объектларын аерым бер матбугат органында басылган язмалар, жанр яисә жанр формасы, авторлар даирәсе, тематикага бәйле, идея сайланышы ноктасыннан яисә материал белән һәм башкача чикләргә мөмкин. Объектны зуррак алган саен, әдәби барыш турындагы гадел гомумиләштерүләргә якынаясың, тарайтканда – аерым бер күренешләр хакында төгәлрәк нәтиҗәләр чыгарасың.

Билгеле бер чорда иҗат ителгән әсәрләрдән тупланган китапка рецензия кайвакыт күзәтүләргә тартым яисә тиң була, шул сәбәпле аларны китапка күзәтү дип тә атарга мөмкин. Ш. Камалның М. Әмир иҗатына мөнәсәбәтле «Бер китапның уңышлы һәм уңышсыз яклары» – шундыйлардан. Анда автор 9 әсәргә аерым-аерым туктала һәм аларның уңай яисә кимчелекле якларын әйтеп чыга. Ш. Камал хезмәте аша М. Әмирнең хикәя жанрында иҗат ителгән әсәрләренә хас гомуми үзенчәлекләрне күреп була[2]. Кайбер галимнәрнең рецензия-

---

[1] ЛЭТП: под ред. А.Н. Николюкина; Институт научной информации по общественным наукам РАН. М.: Интелвак, 2003. С. 669.

[2] Камал Ш. Бер китапның уңышлы һәм уңышсыз яклары // Камал Ш. Әсәрләр: 4 томда. Казан: Таткнигоиздат, 1956. Т. 4. Б. 233–238.

дән рецензия-күзәтүләрне тармакландыруы нәкъ менә аерым формаларны һәм рецензия, һәм күзәтү дип атап булуга барып тоташа да.

Соңгы ике гасыр чигендә вакытлы матбугат челтәре киңәйде һәм китаплар күп басыла башлады, күзәтүләрдә әдәбиятны тулаем иңләү, һәр яңа чыккан китапка бәя биреп яктырту кыенлашты, еш кына мөмкин дә түгел. Мондый шартларда әдәбиятчылардан сайлап алу интуициясе, эрудиция кебек сыйфатлар таләп ителә. Тәнкыйтьче, теманы ничек кенә киң алмасын, барыбер мисалларда чикләнәчәк, шул заманда җәмәгатьчелектә хөкем сөргән карашларга, икенчеләр тарафыннан язылган мәкаләләргә, бигрәк тә рецензияләргә таяначак, әмма аның күз уңыннан әдәби барышта яисә аерым бер автор иҗатында мөһим роль уйнаган китаплар, әсәрләр һич кенә дә төшеп калырга тиеш түгел.

Әдәби күзәтүләр рус вакытлы матбугатында да, татар басмаларында да элек-электән басылып килгән. Аларның идея эчтәлеге автор куйган максатка, өйрәнү аспектына бәйле. Күзәтүләр – әдәби барыштагы тәгаенләшкән яисә формалашып килүче үзенчәлекләрне аңлауга таба ясалган бер адымдыр. Алар башка тәнкыйтьчеләргә зур проблемалар күтәргән мәкаләләр язуга этәргеч бирә. Шулай да була: күзәтү авторы үзе үк аны икенче хезмәт башкарганда таяныч итә. Әйтик, тәнкыйтьче, аерым бер газетада басылган шигъри әсәрләргә берничә ел дәвамында күзәтү ясый икән, шуннан соң әлеге органның әдәбият бүлегенә хас эш алымнары, әдәби тупланмаларны сайлау принциплары, яшьләр иҗаты, бүгенге шигърият хакында актуаль яңгырашлы зур мәкалә язарга мөмкин.

Күзәтүче материал сайлауда әсәр басылачак матбагага бәйле дә чикләнә: хезмәтен мөхәррир, рубрика таләпләренә буйсынып һәм башка шартлардан да чыгып башкара. Мәсәлән, автор «Сабантуй» газетасында басылган балалар иҗатын анализлаганда, чагыштырма планда фикер әйтү өчен, шул ук аудиториягә хезмәт иткән башка органнарга да таянырга мөмкин, әмма барыбер артык читкә китәргә тырышмаячак.

Күләмле аналитик язмаларда үзара охшашлык шактый булса да, аермалы яклары да ачык күзгә ташлана. Рецензияләрдә автор образы, аның сөйләм манерасы ачык чагыла, чөнки аларны язучы объектка битараф була алмый; проблемалы язмаларга килгәндә, бу бигрәк тә шулай. Кайвакыт беренчеләре, күләм ягыннан зураеп, эчтәлек ягыннан тирәнәеп, материалны арттырып, зур тәнкыйди мәкаләләргә якыная, шулай да алар арасында аерма кала әле.

Әгәр рецензияче әдәби әсәрне, китапны – комплекслы, тулы яктыртса, иң характерлы сыйфатларын ачып бирергә омтылса, күләмле *мәкалә*ләр авторы язучы тудырган әдәби дөньяга алып керергә тырыша. Соңгыларының, тәнкыйтьче осталыгына бәйле рәвештә, *гадәти*ләре һәм *проблемалы*лары очрый. Беренчеләре зыялы укучы өчен кызыксыз, буш текстлар кебек тоелырга мөмкин. Әлбәттә, күп хезмәт куеп иҗат ителгән проблемалы язмаларның теге яки бу мәсьәлә рәвешендәге композицион үзәге булырга тиеш.

Тәнкыйди статьяларны күләме тагын да зуррак һәм аерым китап, кулъязма хәлендә дөнья күргән *монография*ләр белән чагыштыру да урынлы, чөнки алар язылу рәвеше, мәсьәләне чишү формасы белән бер-берсеннән аерыла. Тәнкыйтьчегә үзенчәлекле стильдә фикер йөртү хас булса, саф гыйльми хезмәтләрнең фәнни, бераз шаблонрак теле күзгә ташлана. Аларның катгый таләп ителгән формасы бар.

Проблематик характердагы тәнкыйть мәкаләләрендә фәнни һәм публицистик башлангыч тыгыз үрелә. Аларның максаты булып, әдәби барышта яисә аерым бер кеше иҗатында һәм әсәрдә туып килгән бер күренешне, күзгә бәрелердәй сыйфатларны аңлату, бәяләмә бирү, иҗтимагый тормыш, үткән тарих белән бәйләү тора. Тәнкыйтьче бу вакытта зур гомумиләштерүләр ясый, күренешләрне тирәнтен анализларга тырыша. Андый язмаларда, гадәттә, заман әдәби барышының, тәнкыйтенең актуаль яңгырашка ия проблемалары күтәрелә, шунлыктан таяныч материал да бүгенге көннән сайлана.

Тар темаларны яктыртырга алынганда, авторның әсәрне һәрьяклы характерлавы язманы таркау, эзлексез итәргә мөмкин. Билгеле бер мәсьәлә көн кадагына куелган, аерым нәтиҗәләр ясалган икән, ул мисаллар ярдәмендә дәлилләнергә, буш сүз булып калмаска тиеш. Монда гомумиләштерелгән фикер белән тәгаен анализны үзара яраштыру турында да уйланырга кирәк.

Проблемалы мәкаләләрне иҗтимагый күзаллаулары киң, теоретик белеме тирән шәхесләр генә җиренә җиткереп башкара. Аларны язуның схемалары төрле. Әйтик, алдан ук ниндидер әдәби фактка кагылышлы фикерне әйтә һәм аннан соң мисаллар белән дәлилли алабыз. Шуның нәкъ киресен башкару да кызыклы. Башта гомумиләштерүләр ясалса, аларның игътибарны алыр дәрәҗәдә яңгырашлы, үткен әйтелүе кирәк.

Әдәби проблемаларга тормышның үзеннән этәрелеп китеп тә килергә була. Алай эшләү әдәбият белән көнкүрешне үзара бәй-

ләргә, укучыда әсәр укуга теләк уятырга ярдәм итә. Проблемалы мәкаләләрдә халыкчанлык, тормышчанлык, иҗат методлары, магистраль герой, антигерой һәм башкалар хакында сүз йөртергә мөмкин, шулай ук мәсьәләләрнең ваграк пландагылары чишелә ала.

Мәкалә язу – бер нәрсә, укучыны җәлеп итү – икенче. Әгәр язмага куелган атама үзенчәлекле булмаса, вакытлы матбугат алдыручылар еш кына аны әйләнеп уза. Вакытлы матбугатта дөнья күргән мәкаләләргә бигрәк тә күпчелекнең игътибарын юнәлтү өчен, кызыклы, үзенчәлекле эчтәлеккә ия җөмләләр, гыйбарәләр уйлап табарга кирәк. Кайвакыт мәкаль-әйтемнәрдән файдалану уңышлы. Проблеманы атамага чыгару исә мәкаләгә, беренче чиратта, әдәбият һәм фән сөючеләрнең игътибарын тартачак.

Әдәбиятка кагылышлы мәсьәләләр *юбилей уңаеннан* басылган мәкаләләрдә дә, *теоретик* хезмәтләрдә дә, *бәхәс характерындагы язмалар*да да күтәрелә ала, шунлыктан әлеге формаларның үзләрен дә проблемалы мәкаләнең модификацияләре дип карарга мөмкин, әмма шул ук вакытта юбилей материалларының проблематик булмаганнары (*информатив, әдәби-публицистик*) барлыгын да искә алырга кирәк.

Ш. Камал, Тукайны хәтеренә төшереп, «Халыкның самими җырчысы» исеме астында чыгарган язмасында шагыйрь иҗатының Беренче рус инкыйлабы шартларында чәчәк атуын, киң алымлы каләм иясе булуын, сыйнфый җәмгыятьнең әшәкелекләренә каршы юмор-сатира коралы ярдәмендә көрәшүен әйтә, язганнарының халыкчанлыгы мәсьәләсенә туктала. Бу мәкалә Тукайдан соң яшәгән укучыга информация кебек тә кабул ителә, зур гомумиләштерүләр артында тирән анализ торганлыгы да чамалана.

Теоретик хезмәтләр заманның әдәби материалы нигезендә теге яисә бу мәсьәләне чишүне максат итсә, аерым бер каләм иясенең юбилее уңаеннан басылганнары авторга хас стиль үзенчәлекләрен яктырта, аның үсеш этапларын күрсәтә, иң яхшы әсәрләрен билгеләп, бәя биреп уза, шул ук вакытта анда гомуми әдәби барыш һәм аңа хас проблемалар да күтәрелә ала.

Әдәби тәнкыйть тарихын яктырткан бүлектән күренгәнчә, татар шигъриятендә ритм, рифма, форма һәм эчтәлек кебек, алтмышынчы елларда башланып, җитмешенче елларда да дәвам иткән, традициялелек һәм новаторлык кебек зур мәсьәләләргә алып чыккан бәхәсләрне шушы төр язмалар эчендә карарга мөмкин. Әдәби бәхәс купсын өчен, кемнең дә булса үз язмасында, чыгышында

берәр проблеманы калкытуы яисә әдәбиятта кичекмәстән хәл ителергә тиешле мәсьәләләрнең тууы кирәк. Ахыр чиктә андый зур проблемалар әдипләрнең мәртәбәле җыелышларына да үтеп керә яисә язучыларны әлеге җыелышларда актуаль темага сөйләшүгә хәзерли. Әйтик, РСФСР язучыларының II съездын каршылау уңаеннан «Литературная Россия» газетасында бастырган мәкаләсендә Ф. Хөсни дә шигърияттә яңа сыйфатлар хакында сүз алып барган һәм строфа төзелеше, метафоралылык, рифмага осталык кебек мәсьәләләрне күтәргән[1].

Әдәби бәхәс кызсын, аңа күпләр тартылсын һәм әдәбият тарихы сәхифәләрендә кызыклы язмалар теркәлеп калсын өчен, уңай бәяләмәләр янәшәсендә тискәреләрнең дә булуы кирәк. Бу очракта да Н. Фәттах кебек зур, әмма прозаик сыйфатында танылган язучының күпләр тарафыннан мактала башлаган шагыйрьләргә карата кискен яңгыраган тәнкыйть сүзе («Шигырьме, әллә башваткычмы?» – «Татарстан яшьләре» газетасының 54 саны – 1965 ел, 17 июнь) әдәби җәмәгатьчелекнең үз эчендә барган әдәби бәхәсне вакытлы матбугатка ныклап алып керә. Әйткәнебезчә, ел дәвамында төрле газеталар мәйданында барган сүз көрәштерүләр 1966 елда «Социалистик Татарстан» газетасының «Г. Тукай, М. Җәлил традицияләре һәм хәзерге татар поэзиясе» дигән проблеманы күтәреп чыгуына китерә.

Әдәби проблема күтәргән мәсьәләләрне җитди рухта да, шаян формада да язып була. «Чаян» битләрендә чыккан әдәбиятка кагылышлы язмалар – шуның мисалы. Ш. Галиев белән Шомбай алып барган «Дөрес сүзгә җавап... бар!» әңгәмәсенең умыртка баганасы булып юмор-сатирага хас сыйфатларны, аның җәмгыятьтә башкарган функцияләрен ачыклауга юнәлтелгән сораулар тора. Менә алар: «...юмор кешене дәвалый аламы?», «Үзгәртеп кору чоры, дибез... Юмор ничек үзгәрергә тиеш?», «Көлкедә көндәш буламы?», «Әче телле шагыйрьләр һәрвакыт дөньяны үзгәртергә тырышалар. Менә син үзең үзгәртә алдыңмы соң?», «Үгезне мөгезеннән алыйм инде: нәрсә ул – елмаю?»…[2]

Әңгәмәләрнең бер проблема тирәсендәге сорауларга җавап рәвешендә оешканы, тар планлысы аз була. Язучы белән әдәбият-

[1] Хусни Ф. Шаги догоняющих // Лит. Россия.1965. 1 январь.

[2] Дөрес сүзгә җавап... бар!: «Чаян»да Шомбай белән әңгәмә // Галиев Ш. Сайланма әсәрләр: 5 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Т. 5. Б. 441–482.

ка кагылышлы проблемалар хакында гәпләшкәндә журналистлар еш кына темадан читкә алып китүче сораулар да биреп куя. Әлеге хәл хезмәтне тарката. Югарыда телгә алынган әңгәмәдә автор шагыйрьнең иҗат лабораториясен иңләгән сораулар бирә, Ш. Галиевнең юмор-сатирага килү юлларын, нәселдән бирелгән сәләтләрен, жанрга хезмәт итүенең озын гомерлеге шартларын, басылмаган әсәрләрен, сатира-юмор формасында тасвирлаган темаларын, әдәбиятта күтәргән проблемаларын, иҗатның халыкчан нигезләрен, һөнәри осталык мәктәбен, юморның адресатын ачыклый. Язмада, болардан читтәрәк торган кебек сорау да бар: «Ә нәрсә соң ул, ачуым бер килмәгәе, картлык?». Мәкалә авторының фикерләү рәвешенә туры килгәнлектән, башка сорауларга кушып карап булса да, анысы текст бөтенлегенә зыян салып тора.

Күп кенә әңгәмәләр иҗатны, әдәби әсәрне яисә барышны яктыртуны тормышның башка проблемаларын күтәрү белән тыгыз үрелә, дидек. Кайвакыт, нәкъ менә киңпланлылык, сүзне бер мәсьәлә тирәсендә генә тупламау аларны таркау итеп кенә калмый, укучыда әңгәмә хәзерлексез генә алып барылган дигән фикер дә формалаштыра.

## 5.4. Әдәби-публицистик төр

Тәнкыйтьнең әдәби-публицистик жанрлары дигәч, төргә хас сыйфатлар шунда ук күз алдына килә. Әлеге ояга караган язмаларда автор индивидуальлеге, аның әдәби күренешләргә үзенчәлекле шәрех бирүе, проблемага үз күзаллаулары яктысыннан якын килүе чагыла. Аларда яктыртылган темаларның актуальлеге, фикернең үкенлеге, яңгырашның киң публикага тәэсир итәрлек көче тоемлана. Әдәбилек һәм публицистизм берлегенә тәнкыйтьчеләр образлар байлыгын, башкару оригинальлеген, типиклаштыру һәм гомумиләштерү, детальләр сайлау, төрле тип пафосларны куллану яисә чиратлаштыру осталыгын, психологизмны, журналист кыюлыгын эшкә җигеп ирешә.

Әдәби-публицистик хезмәтләрнең бигрәк тә *гомуми пландагылары автордан язучылык* осталыгы таләп итә, чөнки хикәягә тартымрак була. Монда гадәти санаулар, коры сүз йөртү бармый, чөнки язмадагы сәнгатилекне какшата. Каләм иясе тормышның үзеннән алынган күренешләрне, бу очракта аның әдәби бирәмлекләрен укучыны уйга салырлык, объектны бәяләтерлек тасвирларга тиеш.

Тәнкыйть материалларының әдәби-публицистик оясына *әдәби портрет*, *очерк*, гадәттә «әдәби штрих» исеме астында чыгып килүче *сызма*-зарисовкалар (*җитез сурәт*ләр), *фельетон*, *пародия*, *шарж*, *памфлет* кебек сатирик характердагы яисә юмористик пландагы язмалар карый.

*Очерк*ларга без әдәбиятка кагылышлы күренешләр, проблемалар максатчан яктыртылган а) *сәяхәтнамә-юлъязма*ларны, б) *очерк-портрет*ларны, в) *проблемалы очерк*ларны кертәбез. Шул ук вакытта Ф. Кәриминең әдәбиятка кагылышлы фикерләре дә булган «Кырымга сәяхәт»е кебек язмалар әдәби тәнкыйть дип санала алмый, аларның төп максаты – иҗтимагый-мәдәни тормышны яктырту. Әлбәттә, бу төр хезмәтләрдә аның аерым бер өлеше булган әдәби барыш яисә хәрәкәт, сүз сәнгате үрнәкләре һәм башкалар да күпмедер тасвирланырга мөмкин. Икенче яктан, әдәбият тарихын үткәндәге мираска таянып өйрәнгәндә, без аларны да игътибар үзәгендә тотабыз, чөнки әлеге сәяхәтнамәләр, дини-философик яисә дидактик-педагогик трактатлар һәм башка төр синкретик язмалар эчендә татар әдәби тәнкыйтенең беренче орлыклары шытым җибәрә.

Кайбер классификацияләрдә очеркның алты төрен күрсәтәләр. Алда саналганнан тыш, социологик, публицистик, нәфис төрләрен дә билгелиләр. Социологик очерк, әгәр тәнкыйтькә кагылышлы икән, ул аның проблемаларын иҗтимагый проблема дәрәҗәсендә чагылдырырга, реаль фактларга һәм саннарга нигезләнергә тиеш; публицистик калыпта язылганында автор позициясе ачык тоемалана дип карала; нәфис очеркларның төп максаты – укучыга хисси тәэсир итү, шунлыктан анда детальләр муллыгы, тел-сурәтләү чараларының байлыгы күзәтелә.

Татар әдәбиятында сәяхәтнамә жанры инде зур үсешкә ия, әмма әдәбиятка кагылышлы фикерләрне генә уздыру өчен махсус язылган һәм халык күңелендә яшәгән, киң билгеле тәнкыйть юлъязмаларының хәзергәчә юклыгын әйтеп узарга кирәк.

Кайберәүләр катгый кире какса да яисә искәрмә белән генә исәпкә алса да, без очеркларда сюжетлылыкны тану тарафдарлары ягында, чөнки ул оештыручы, типиклаштыруга һәм идеяне ачуга ярдәм итүче, логик эзлеклелек бирүче чара булып тора. Сюжет иҗатны аңлауга, бөтен катлаулылыгында, каршылыкларында чагылдыруга, әдәби характерлар тудыруга хезмәт итә.

Әлбәттә, документаль очерктагы сюжет белән гомумиләштерүләргә нигезләнгән очерк сюжеты бер төсле була алмый.

Е.И. Журбинаның бу уңайдан әйткән фикерләре кызыклы. Анычча, әгәр очеркчы тапкан сюжеты ярдәмендә документальләштерелгән тормыш картинасын ачуны максат итмәсә, күзәтүләренә таянып, кешеләрнең уйлап чыгарылган, гомумиләштерелгән, типиклаштырылган образларын тудырырга һәм соңыннан, теге я бу проблеманы чагылдыру өчен, аларны янәшә куярга теләсә, очерк үзе дә, аның сюжеты да башка кыяфәттә була. Гадәти тормыш күренешләрен генә түгел, әдәби барышны да шул рәвешчә – төрле тип очерклар аша яктыртырга мөмкин.

Әдәби-публицистик язмаларның автордан шагыйрәнә осталык һәм прозаиклык таләп иткәне – һичшиксез, *эссе*. Эссены аңлауда һәм аңлатуда аерымлыклар бетеп килә шикелле. Иң элек алдагы елларда чыккан хезмәтләрдән «Әдәбият белеме сүзлеге»нә мөрәҗәгать итик:

«Эссе (латинча – «үлчәп карау» дигән мәгънәдә) инглиз һәм француз теленә очерк, мәкалә мәгънәсендәрәк тәрҗемә ителә. Ә гомумән, Э. – ул тәнкыйть жанры, нинди дә булса проблеманы ирекле хәлдә тасвирлый. Э. авторы үзе сайлап алган нинди дә булса әдәби, эстетик, фәлсәфи һәм башка төрле проблемаларны анализлый»[1]. Шушы ук сүзлектә, алда китереп үткәнебезчә, «Рецензия» статьясы эчендә эссега башка төрлерәк билгеләмә бирелә.

Хәзерге хезмәтләрдә бу жанр формасына «композиция рамкалары, шартлары белән чикләнмәгән, зур булмаган һәм авторның фикер йөртүләрен чагылдыручы әдәби-публицистик әсәр» рәвешендәге аңлатмаларны очратырга мөмкин[2].

Терминнар энциклопедиясендә эссеның француз сүзе икәнлеге, төп мәгънәсенең эшләп карау (попытка), очерк икәнлеге әйтелә. «...прозаическое сочинение небольшого объема и свободной композиции, выражающее индивидуальные впечатления и соображения по конкретному поводу или вопросу и заведомо не претендующее на определяющую или исчерпывающую трактовку предмета. Как правило, Э. предполагает новое, субъективно окрашенное слово о чем-либо и может иметь философский, историко-биографический, публицистический, литературно-критический, научно-популярный или чисто беллетристический характер. Эссеистический стиль

---

[1] Әдәбият белеме сүзлеге. Б. 148, 220.

[2] Кременцов Л.П. Теория литературы. Чтение как творчество. М.: Флинта: Наука, 2003. С. 156.

отличается образностью, оформленностью и установкой на разговорную интонацию и лексику»[1].

Билгеләмәдә эссеның киңпланлылыгы, төрле өлкәләрне тасвирлый алуы, тел-стиль үзенчәлекләре ачык чагыла. Әдәби тәнкыйтькә караган эсселарның үзләрендә дә кайсы да булса башлангыч алгы планга чыгарга мөмкин, шунлыктан без аларны әлеге жанр эчендә *а) фәлсәфи, б) биографик, в) беллитристик характердагы* дип аерым сыйфатлары белән төркемли алыр идек. Эсселарда, гомумән алганда, табигый булган вакыйгалылык, лиризм, публицистлык һәм башка сыйфатлар калкулана.

Эссе популяр жанр булуга карамастан, аны укучы күңеленә охшарлык башкару теләсә кем кулыннан килми. Бигрәк тә әдәбиятка кагылышлы проблемалар күтәргән эсселар автордан талант янәшәсендә тирән белемлелек тә таләп итә. Татар тәнкыйтьчеләре арасында Р. Сибат, М. Галиев кебек күренекле эссеистларны аерып күрсәтергә була. Башкаларның, әйтик, Р. Гаташ, Р. Фәйзуллин, Н. Гамбәрләр мирасында да эссе калыбындагы әсәрләр бар.

Әдәби-публицистик оя эчендә дә төркемләү шактый кыен. Әдипләр һәм тәнкыйтьчеләр, мөхәррирләр дә еш кына теге яки бу язманы кайсы төркемгә кертергә белмичә аптырап кала. М. Галиев, дүрттомлыгына кергән әсәрләренең аерым китапларга бүленешен болай күрсәтә: «4 том. Эссе-әдәби портретлар, фәлсәфи уйланулар»[2]. Әлбәттә, җыентыктагы хезмәтләрнең барысы да эссе калыбында, әмма теге яки бу кешенең иҗатын, шәхесен ачкан язмаларны авторның әдәби портрет дип атавы да табигый кебек.

Томлыкка аннотациядә дә эссе сүзе аныклагыч белән берлектә килә: «Бу җыентыкка Марсель Галиевнең туган җире, туган халкы, каләмдәшләре хакында эссе-сурәтнамәләре, заман-чор, тарих, әдәбият турында фәлсәфи-лирик уйланулары тупланды». Күргәнегезчә, сурәтнамә портрет сүзенә синоним буларак файдаланылган. Әдипнең үзе кебек фикер йөрткәндә, шушы тупланмага кергән кайбер хезмәтләрне, мәсәлән, «Оҗмах бакчалары хозур»ны эссе-сәяхәтнамә дип тә атарга булыр иде. Араларыннан эссе-истәлек («Тәңренең тамгасы белән») һәм башка төрләрне дә аерып куярга мөмкин.

Субъективлык көчле булган эсселарда язучылар кайвакыт дорфалык күрсәтәләр, шәхестән көлүгә урын бирәләр. Тәнкый-

[1] ЛЭТП. М.: НПК Интелвах, 2003. С.669.

[2] Галиев М. Сайланма әсәрләр: 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. Т. 4. Б. 428.

ди рухтагы хезмәтләргә хас әлеге проблеманы кайчак эссистлар үзләре дә күтәреп чыга. «Догалы еллар» циклындагы «Оҗмах бакчалары хозур»да М. Галиев тормышның бик күп якларын тасвирлый, бер сәяхәт тарихын чагылдыра, әледән-әле әдәбиятка, шуның корифейларыннан булган А. Гыйләҗевкә әйләнеп кайта. Һәм язмасының соңындарак, аның турыда уйланып, түбәндәгеләрне әйтә:

«Аяз ага Сибгат Хәким шигыренә язылган «Минем таныш өянкеләр» җырын ишетсә, күңеле актарылып чыга, күңеленнән генә кушылып, җырның самими дулкынына башын куя да сабылып җылый /…/

Үзе, кешеләр янында хискә бирелеп, беркайчан да күз яшен күрсәтмәгән Мөхәммәт ага Мәһдиев «Ачы тәҗрибә авазы» китабында Аяз аганың бу йомшаклыгыннан саксызрак көлеп язган иде»[1].

Тәнкыйтьчеләребез еш кына, иҗатның тулы ачылып бетмәвенә ишарәләп, язмаларының жанр формасын «*иҗат портретына штрихлар*», «*әдәби портретка штрихлар*» гыйбарәсе аша билгелиләр, әмма аларның кайберләре икенче бер авторның *әдәби потрет* сыйфатында тәкъдим ителгән язмаларыннан тирәнрәк эчтәлектә дә булгалый. Гомумән алганда, эссеистик *сызма*лар тулы булмаган әдәби портретларга охшап тора һәм язучы иҗатының, иҗат лабораториясенең теге яки бу якларын ачуны максат итә.

*Әдәби портрет* төшенчәсенә «Кыскача әдәбият сүзлеге»ндә бирелгән билгеләмәне укып узыйк: «Әдәби портрет – язучы, рәссам, күренекле җәмәгать эшлеклесе һ.б. турында «каһарман» белән сөйләшү нигезендә туган документаль очерк яисә әлеге герой хакында кыскача мемуар очерк ул»[2].

А.А. Сивогривова, китерелгән билгеләмәдән әдәби портрет натурадан зарисовка кебек күз алдына килә, ди. Һәм болай дип өсти: «А между тем нам известны литературные портреты писателей, созданные на основе изучения документов и творчества. Таковы литературные портреты А. Моруа (о Бальзаке, Стендале и др.). А. Моруа как бы вводит портрет в круг историко-литературных жанров. Литературный портрет как жанр критики заключает в себе исследовательское начало.

---

[1] Галиев М. Оҗмах бакчалары хозур // Галиев М. Сайланма әсәрләр. Т. 4. Б. 269.

[2] Портрет // Краткая литературная энциклопедия. URL: www.feb-web.ru

Создать литературный портрет писателя – значит прежде всего показать его творческое лицо. В зависимости от того, какие цели перед собой ставит писатель-критик и на какой материал, кроме произведений, он опирается (личные впечатления или документы), в портрете меняется соотношение литературно-критического и биографического материала. Но в любом случае перед нами портрет писателя, в котором нельзя отделить его жизнь, его личные качества от его творчества»[1]. Без дә галимә белән килешәбез.

Әдәби портретларны тәнкыйтьтә *иҗат портреты*, *иҗатчы портреты* терминнары белән алмаштыру отышлы булыр сыман. Ул чагында, әдәби портрет дигәндә, ниндидер шәхесне төрле планда сәнгати чагылдыруны күздә тотсак, иҗат портреты дигәндә, нәкъ менә сәнгатькәр эшчәнлеген сурәтләү аңлашылачак. Әдәби портретларның *монографик пландагылары*, *әдип иҗатына, шәхесенә бер проблема яссылыгында якын килгәннәре*, *иҗатны өлешчә, сызыклар рәвешендә генә яктыртканнары була*... Беренчеләре диссертацияләргә якыная башлый.

Иҗат портретлары – әдәби тәнкыйтьнең бик популяр төре. Аның жанр модификацияләре, күләмнән тыш, сөйләм манерасына, иҗатка якын килү алымнарына бәйле. Әдипне характерлаганда, автор аның тәрҗемәи хәлен, иҗат итү алымнарына бәйле тудырылган әдәби дөньяны һәм әдәби әсәрләренә нигез биргән чынбарлыкны күздә тота. Шул өч якның берсенә өстенлек бирү жанр модификацияләрен тудыруда хәлиткеч роль уйный да. Беренчесен генә яктырту *биографик очерк* язуга хезмәт итә, башкаларына да бераз игътибар бирү *тәнкыйди-биографик очерк*лар язуга китерә, беренче моментны күздән ычкындыру исә *иҗат* манерасын ачкан *очерк*ларга сәбәпче була.

Әдип һәм шагыйрьләрнең иҗади эзләнүләрен, тормыш юлын бердәй тигез яктырткан язмалар вакытлы матбугатта ешрак басыла шикелле. Әдәби портретларда еш кына каләм иясенең көндәлек яшәешен сурәтләү, детальләштерү яисә очеркның башка алымнарына хас сыйфатлар күзгә ташлана. Алар әсәрне басып та киткәли. Һәм шул сәбәпле кайберәүләр әдәби портретны очерк белән бер төркемдә яисә аның эчендә карый; бериш галимнәр андый төр язмаларны әдип иҗатын яктыртуга багышланган тәнкыйди-биографик

[1] Сивогривова А. А. Литературный портрет // Основы литературной критики. Ростов н/Д: Изд-во Ростовского-н.-Дону госпединститута, 1975. С. 55.

эсселар дип атый. Күрәбез ки, һәр очракта да бер жанрны икенчесе аша билгеләү күзәтелә.

Әлбәттә, тәнкыйть жанры булган әдәби портрет (иҗат портреты) һәм сәнгати очерк саналырдай әдәби портрет бер-берсенә бик охшаган. «И в том, и в другом авторы не претендуют на исчерпывающее описание жизненного пути героя, а материалом для произведения являются личные впечатления автора и документы (а так же творчество писателя – героя очерка). Но среди портретных очерков литературный портрет писателя занимает особое место: он связан с открытием и утверждением художественных ценностей, то есть несет в себе те качества, которые характеризуют литературную критику»[1], – дип яза А. Сивогривова.

Теләсә кайсы әдәби тәнкыйть жанрына мөнәсәбәттә без кабат объективлык һәм субъективлык мәсьәләсенә кайта алыр идек. Иҗат портретларында авторның иҗатка гына түгел, каләм иясенең үзенә карата да мөнәсәбәте еш чагыла. Ул аның тормышын сайланышлы яктырта, махсус детальләр белән бизәкли. А. Сивогривова шул ук «Литературный портрет» исемле язмасында, бу уңайдан, М. Кораловның «Литературное обозрение» журналында басылган (1973 ел, №7) «Образ личности и облик эпохи» исемле мәкаләсеннән өзек китерә. Анда шундый юллар бар:

«Литературный портрет – последняя или даже высшая ступень субъективности, понятно, уже переходящая в субъективизм; еще более лаконичная разновидность критического жанра. Помимо прочих достоинств, она требует от критика остроты психологического видения и мастерства. В ней личность художника самодовлеет. Эпоха, окружение, творчество обретают здесь право на внимание в той степени, в какой работают на образ художника. Искусство критика венчает здесь собой труд исследователя»[2].

Әдәби портретлар галим язган зур хезмәтнең аерым өлешләре булырга, мөстәкыйль генә дә яшәргә мөмкин. Кайчагында алар тәнкыйтьче китабының кайсыдыр кисәге рәвешендә оеша. Мәсәлән, Гариф Ахуновның «Әдәби язмышлар» (1970) китабының беренче бүлеге «Иҗат портретларына тәҗрибә» дип атала. Автор, әйтерсең, зурдан кубып сүз алмавын, каләм генә сынап каравын искәртә, ә язганнары кызыклы, мәгънәле, тирән булып чыккан. Мәкаләләр

---

[1] Сивогривова А.А. Литературный портрет. С. 59.

[2] Шунда ук. С. 55.

үзәгенә иҗатлары куелган шәхесләр Гомәр Гали, Шәйхи Маннур, Гомәр Бәширов, Ибраһим Гази барысы да – классик әдипләребез. Аларның иҗат портретлары аша автор яшь каләмдәшләргә әдәбият мәйданына нинди юллардан атлап керергә, кая таба һәм ничек юл тотарга кирәклекне күрсәтә.

Мисалга «Тауга күтәрелү» исеме белән язылган әдәби портретны китерик. Ул Шәйхи Маннур поэзиясенең асыл сыйфатларын ачуга юнәлтелгән.

Г. Ахунов башламда тауга күтәрелү турында образлы һәм фәлсәфи фикер йөртә һәм икенче абзацта, сикәлтәле юллардан, тау бормаларыннан курыкмыйча, әдәбият биеклекләренә омтылган Ш. Маннур иҗатына, аның татар совет поэзиясенә шәхси өлеш кертүе мәсьәләсенә күчә. Шуннан соң тәнкыйтьче шагыйрьнең үз тавышын табуын тормыш юлы белән бәйли, бер-бер артлы әсәрләренең эчтәлеген ача, китаплары хакында сөйли. Ул Ш. Маннур шигъриятенә хас сыйфатларны даими рәвештә тәгаен мисалларда күрсәтә һәм игътибарга лаек, объектив нәтиҗәләр ясый:

«Татар совет поэзиясенең олы юлын билгеләүче иң яхшы әсәрләрдә шагыйрь тавышы һәркайчан актив, уйланулар тирән, дәүләт интереслары, яңа кеше өчен көрәш мәсьәләсе беренче планда булды»[1].

Язманың соңгы өлеше Ш. Маннур иҗаты хакында гомуми сүз әйтү планында. Ул шушы эчтәлектәге абзац белән тәмамлана: «Шәйхи Маннур – киң колачлы шагыйрь. Аның иҗат биографиясендә – дистәләрчә поэма, баллада, зур бер том лирик шигырь, халык яратып җырлый торган җырлар. Шуларның барысы өстенә, ул балалар әдәбиятын үстерүгә күп көч куйды, рус классикларын һәм бүгенге совет шагыйрьләрен һәм язучыларын татар укучысына җиткерү буенча төрле-төрле жанрларда күп һәм яхшы тәрҗемәләр эшләде. Болар барысы да аның хезмәт сөюче, күп яклы, зур әдип булуын тагын бер мәртәбә раслыйлар»[2].

Г. Ахуновның «Тауга күтәрелү» язмасы – классик, ягъни жанр таләпләренә җавап бирә торган иҗат портреты үрнәге.

Әдәби портретларның кайберләрендә авторның эссеистлыгы сизеләнә һәм ике жанр формасы арасында киртә уздыруы бик кыен

[1] Ахунов Г. Тауга күтәрелү // Ахунов Г. Әдәби язмышлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. Б. 29.

[2] Шунда ук. Б.40.

була. Язучыларның жанр чикләрен тәгаенләштерүдә авырлык кичерүе тупланмалардагы һәр тәнкыйть әсәренең жанрын аерым-аерым билгеләмәүләрендә һәм аннотацияләрдә дә чагыла. Фикеребез эссега мөнәсәбәттә дә алда әйтелгән һәм М. Галиевнең 1999 елда чыккан «Сайланма әсәрләр»нең дүртенче томына таянып дәлилләнгән иде. Бу урында тагын бер мәртәбә тәнкыйтьтә генә түгел, башка өлкәләрдә дә катгый канунилык булмауны танырга мәҗбүрбез, ә ул исә алар эчендә барган яңарыш күренешләренә, укучы ихтыяҗына, автор теләгенә, хәтта ки иҗтимагый тормыштагы үзгәрешләргә дә бәйле.

Әдәби-публицистик ояда фельетон, пародия, әдәби шарж, памфлет кебек төрләр аерым урын алып тора. Кайбер галимнәр бу формаларның барысын бер төшенчә – фельетон термины белән билгели. Фельетон турында сөйләгәндә, моннан тыш, аның да төрле мәгънәдә кулланылуын истә тотарга кирәк.

Француз теленнән XIX гасыр башында кергән *фельетон* (*feuilleton*, от *feuille* — «бит», «сәхифә») төшенчәсе элек кыска күләмле сатирик сызмаларны, очеркларны, мәкаләләрне аңлаткан. Фельетон сүзенең кулланышка керүе 1800 елда «Journal des Débats» газетасы наширенең басмага кушымта битләр чыгара башлавына һәм 1803 елда аның калыбын үзгәртүгә бәйле була. Ул газетасын, уртада һава калдырып, аска таба озынайта, һәм өстәлгән өлеш фельетон дип йөртелә башлый. Газета күбрәк таралсын өчен, әлеге биттә укучыга кызыклырак материаллар икенчерәк стильдә бирелә, театр репертуарлары, шигъри табышмаклар, ребуслар, игъланнар һәм башкалар урнаштырыла. Тәүге мәртәбә кулланышка керүе газета тарихына һәм «Фельетон» рубрикасына барып тоташканлыктан, фельетон сүзе башта, киң мәгънәсендә дә, ял иттерү рухындагы язмаларны аңлата. Тора-бара сәнгатьчә эшләнеше бик үк югары булмаган һәм позитив эчтәлекле, шулай ук укучыга ял биргән газета беллетристикасын да шул төшенчә белән атыйлар. Кече күләмле фельетон торган саен зурая, темаларын киңәйтә, үсә, үзгәрә. Аның сатирик-юмористик эчтәлек алуы узган гасырда гына көчәя.

Татарларда фельетон вакытлы матбугат белән бергә, шактый соң барлыкка килә, чөнки милли газета-журналларыбызның чыга башлавы Рәсәйдә демократик шартлар тууга бәйле була. Фельетонның рәсми матбугат органнарында бөтенләй урын алмавы яисә аз басылуы аның үсешенә шартлар кирәклеген күрсәтә. Аңа бирелгән урын күләме исә газета-журналның ни дәрәҗәдә сүз ирегенә юл куюын чагылдыра. Һәм фельетон да, үз чиратында, демократик

яшәү принципларының, әдәбиятның объективлыгының, язучы ирегенең сагында тора.

1905 елдан соң яңа сулыш алгандай иҗат итеп киткән Тукай мирасында фельетонга урын күп бирелү бер дә гаҗәп түгел. Әлбәттә, бу чорда фельетонны аңлау бездә дә төрлечә. Әлеге термин еш кына теләсә кайсы эчтәлектәге кече күләмдәге мәкалә мәгънәсендә кулланыла, шуңа да карамастан инде узган гасыр башы вакытлы матбугатында жанр сыйфатламалары ачык һәм бүгенге аңлавыбыздагы фельетон да очрый.

Кайберәүләр беренче фельетоннарны реклама тексты булган дип саный, аларда чагылыш тапкан эчтәлек төрлелеген исәпкә алмый. Мәсьәлә тарихын ныклап өйрәнгән Е.И. Журбина: «Что касается зарождения фельетона в «Журналь де Деба», то нужно учесть следующее. В первые дни существования «Листка» материал подбирался туда случайный по своему конкретному содержанию, но не случайный принципиально. Это были литературные мелочи развлекательного, подчеркнуто неполитического, неофициального характера»,– дип яза. Автор шул ук вакытта аббат Жоффруа тарафыннан язылган беренче фельетонның театраль рецензия булуын билгели[1]. Бу язма фелтонның башлангыч чорында ук әдәбият-сәнгать белән тыгыз бәйләнештә торганлыгын күрсәтә. Тәүге вакытлы матбугатта дөнья күргән татар фельетоны да төрле объектларны тасвир итә, һәм, әлбәттә, әдәби күренешләргә бәя бирү эшенә дә керешә.

Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Ш. Камал кебек фельетончыларыбызга Пушкин, Некрасов, Чехов, Достоевский кебек рус язучыларының тәэсире зур була. Алар татар каләм ияләрен тормыш күренешләренең җанга тиярлек моментларын табарга өйрәтәләр, фельетонны әдәбиятның югары сәнгатьчә эшләнеше, актуаль идея эчтәлегенә иялеге өчен көрәш коралына әверелдерү юлларын күрсәтәләр. Киң массаларга аңлаешлы, оператив характерлы, «тәрбияви» эчтәлекле я булмаса тормышның җитешсез якларын ачып бирергә сәләтле «фельетон» үз заманында кешеләрдә тирәлеккә, күренеш-хәлләргә мөнәсәбәт формалаштыруда зур роль уйнаган һәм хәзер дә шул ук вазифаларны башкарырга омтыла.

Ш. Камалның «Вакыт» газетасында 1910–1913 еллар арасында басылган һәм күптомлыгына «хикәяләр, фельетоннар, очерклар» исеме астында берләшкән фельетоннарына тематик

[1] Журбина Е.И. Теория и практика художественно-публицистических жанров. Очерк. Фельетон. М.: Мысль, 1969. С. 209–210.

күзәтү ясыйк. Төрле жанр төшенчәләре белән аталсалар да, язу ысулында һәм күренешләрне чагылдыруда, тормыш вакыйгаларына мөнәсәбәттә алар үзара бик охшаш, барысын да фельетонга кертеп карарга мөмкин. Әлбәттә, сәнгатьчә югарылыкта иҗат ителгән, сюжетлы, әһәмиятле проблемаларны сатирик планда яктырткан бу әсәрләрне (Татарстанның ял йортларыннан, тарихтан мәгълүмат бирүче очерк, публицистик язма дип саналырга тиешле «Тын таулар җилкәсендә»не исәпләмичә) сатирик хикәяләр дип тә атарга булыр иде. Шулай да беренче төркемгә кертү дөресрәктер, аларның реаль вакыйгаларны, шәхесләрне күздә тотып язылганлыгы, иҗтимагый актуаль мәсьәләләрне күтәргәнлеге, газетаны алдыручыларда тасвирланган хәлләргә мөнәсәбәт формалаштыруны максат иткәнлеге ачык, һәм шул чор кешеләренә вакыйгага нигез биргән материалның танышлыгы да сиземләнә. Дөрес, китапның редакторы һәм аңлатма язучысы М. Максуд тупланмада бер генә фельетон бар дип исәпли[1].

Ш. Камал «Чуар манзара» исемле язмасында, геройлар тасвирына нигезләнеп, әдәбиятның тормышчанлыгы, күтәренкелеге-төшенкелеге, бу сыйфатның авторга бәйлелеге; чын милләтпәрвәрлекнең нәрсәдә чагылуы, әдәбиятның миллилеге, яңача укыту, китап бастыру культурасы, иҗтимагый аңны уяту һәм башка үзара тыгыз бәйләнгән мәсьәләләр турында сөйли.

Шушы ук китапка кергән «Нидер җитми» гә М. Максуд түбәндәгечә аңлатма бирә: «Бу хикәя, бердән, ул вакытта татар издатель-редакторларының хәле тотрыксыз булганлыгын, икенчедән, баю максатына гына омтылган кешеләрнең дә редакторлык, издательлек «кәсебенә» тотынып карауларын күрсәтә». Башка әсәрләре хакында тәнкыйтьче шундый фикерләр яза: «Минем таныш» хикәясендә үзенчә политика белән кызыксынучы, юан корсаклы татар бае исереп пычрак канауда аунаган чагында да, өстерәп корыга чыгара башлагач, «мәсехем, мәсехем!» – дип, таһәрәте бозылмавын кайгырта. Үтергеч сатира!», «Айлар җыелышы» исемле хикәясендә дә автор динчеләрнең бозык һәм монафыйк кешеләр икәнлеген фаш итә. Бу әсәрендә дә автор фантастикага мөрәҗәгать итә, ләкин Шәриф Камалның фантастикасы /.../ реаль вакыйгаларны сурәтләүнең аерым алымы булып кына хезмәт итә»; «„Өтер үз урынында түгел“ исемле фельетон совет

[1] Максуд М. Шәриф Камал әсәрләренең дүртенче томы турында // Камал Ш. Әсәрләр: 4 томда. Казан: Таткнигоиздат, 1956. Т. 4. Б. 7.

учреждениеләрендә очраштыргалый торган бюрократизм күренешләренә каршы юнәлдерелгән» һ.б.[1]

«Хикәяләрнең» билгеле бер чор вакыйга-күренешләренә нигезләнгәнлеге ачык күренеп тора. Тәнкыйтьнең сатирик төрләре саналган фельетон белән памфлетның төп сыйфатламасы – нәкъ менә фактик нигезлелек. Кайбер әсәрләрдә Ш. Камал сурәтләгән геройларның кемнәрне чагылдырганын, кемнәрне күздә тотып иҗат ителгәнен узган гасырның сугышкача әдәбиятын яхшы белгән, иҗтимагый тормышыннан хәбәрдар кешеләр чамаларга мөмкин. Теге яки бу чорда язылган фельетоннарда тасвирланган шәхесләрне ачыклауда башкалар иҗатына кагылышлы өйрәнүләр бик нык ярдәм итә. Әйтик, егерменче йөзнең беренче унбиш еллыгында иҗат иткән кайбер әдипләрнең, бигрәк тә Тукайның язма мирасы шактый тикшерелгән, күп кенә сатира объектларының прототиплары билгеләнгән.

Ш. Камалның «Нидер җитми» фельетонын, гомуми рәвештә, әдәби барышка зыян китерүче күренешләрне тәнкыйть иткән әсәр дип бәяләсәк, «Минем таныш» дип аталганына бирелгән аңлатма аның нигезенә Төрек-Балкан сугышы салынганлыкны күрсәтә. Фельетон, идея эчтәлеге белән, Ш. Мөхәммәдовның «Япон сугышы яки доброволец Батыргали агай» повестена якын тора. Беренчесендә ялган ватанпәрвәрлек, томаналык кебек күренешләр тәнкыйть ителсә, икенчесендә замандашларына хас булган ялган мөселманчылык, милләтчелек, томаналык һәм башка сыйфатлар сатира утына алына.

*Фельетон*, гомумән алганда, көндәлек фактларны үз вакытында ук тотып алып яктыртса да, *типик күренешләрне эзли*, *типик тискәре сыйфатларны тәнкыйть итә.* Аларны, фактларны чагылдырудагы төгәллек дәрәҗәсенә таянып, *документаль* һәм *беллетристик* төрләргә бүлеп йөртәләр; кайберәүләр *адреслы* (адресатлы) һәм *адрессыз* (адресатсыз) фельетоннарны да аерып күрсәтәләр. Хикәяләү рәвешенә бәйле рәвештә дә төркемләү бар. Фельетонның *тәгаен-тасвири* һәм *аналитик*, ягъни *гомумиләшереп характерлаучы* төрләре дә була дип санала.

Әдәби-публицистик формаларда да һәрвакыт жанр аныклыгы сакланмый, катнаш төркемнәргә хас сыйфатларны файдаланып иҗат итү күзгә ташлана. Әнә шуңа булса кирәк, кайберәүләр памфлет, па-

---

[1] Максуд М. Шәриф Камал әсәрләренең дүртенче томы турында. Б. 6–9.

родияләрне фельетон эчендә карыйлар да. Әле 1927 елда «Техника газетного фельетона» язмасында И. Груздев: «Фельетон – алмашынучан үлчәм. Аның характеры барысыннан да бигрәк тирәлегенә бәйле… фельетон турында гомуми сөйләү бик авыр һәм ахыр чиктә нәтиҗәсез», – дип язган икән[1].

Фельетон үз оясына кергән эссе, очерк кебек төрләрдән заман хасиятләрен оператив кайгыртуы, үткен теллелеге белән аерылып тора, вакытлы матбугатның кыюлык дәрәҗәсен дә күрсәтә. Фельетон анализ юлы белән ачылган җитешсезлекләргә укучыда кире кагулы мөнәсәбәт формалаштырырга сәләтле. Игътибарны нәкъ менә тискәре фактларга юнәлтүе текст белән танышучы күңелендә төрле хис дулкыннары уянуга китерә. Укучы яшәешебезнең характерлы, әмма юк ителүе иҗтимагый әһәмияткә ия күренешләре турында ныграк уйлана башлый. Тормыш факты фельетон өчен таяныч нокта булса да, автор аның кайбер якларын калкуландыра, күпертә, шунлыктан бу формада гипербола, антитеза, чагыштыру кебек алымнарның файдаланылуы табигый.

XX гасыр башы фельетоннарында әдәби барышка кагылышлы мәсьәләләр хакында сөйләү популяр булган. Әйтик, Ш. Камалның күптомлыгына кертелгән фельетоннарда шулай ук әдәбиятсәнгатькә, мәдәнияткә кагылышлы бик күп проблемалар күтәрелә, барысын тулаем күздән кичергәндә, авторның җәдитчелек тарафдары сыйфатында, кадимче муллаларга, мөгаллимнәргә каршы сугыш ачуын, әдәбиятның тормышчанлыгы, халыкчанлыгы хакында фикерләр әйтүен күрәсең.

Әдәби тәнкыйтькә кагылышлы заман фельетоннары арасында Рифә Рахман архивында сакланган, тасвирланган шәхесләрнең кемлеге ачык аңлашылганлыктан, редакторлар тарафыннан җыентыклардан һәрвакыт төшерелеп калдырылган «Таракан яки замана фәненә бер караш»та кайбер галимнәрнең әдәбияттан юкны эзләү белән мавыгулары көлкегә алына.

Татар фельетоны тел-сурәтләү чараларына, алымнарына бай, киңпланлы булып туса да, беренче чорында ук әдәби тәнкыйтькә караган фельетоннар да мулдан язылса да, узган гасырның икенче яртысында бу эш сүрелде. Туксанынчы елларда кайберәүләр, мәсәлән, Ф. Әгъзәмов, «Мәгърифәт» газетасында бастырган

---

[1] Журбина Е.И. Теория и практика художественно-публицистических жанров... С. 243.

язмалары белән, бу жанрны җанландырып җибәрү омтылышы ясап карады, әмма аның хәзергәчә актив кулланышта йөргәне юк. Дөрес, әлеге хезмәтләрнең дә әдәби тәнкыйть белән уртаклыгы юк иде.

Галимнәрнең берише, памфлет белән фельетон – бер-берсенә шактый охшаш, әмма күзгә бәрелерлек аермалыклары да бар, дигән фикердә тора. Әйтик, кайберәүләр фельетон белән памфлетны аерып куючы төп сыйфатлар дип беренчесенең күбрәк – көлке алымнары, ә икенчесенең үткен сатира чаралары белән эш итүен әйтә. Ике жанрның әдәби алымнарын бер үк күрүчеләр һәм фельетонның да сатирик рухталыгына басым ясаучылар да бар. Кыскасы, әдәби тәнкыйть, вакытлы матбугат жанрларының кайсын гына алма, һәрвакыт фикерләр бәхәсенә юлыгасың.

В.Д. Пельт памфлетта масштаблырак күренеш-хәлләр типиклаштырыла һәм калкуланган, төгәлләнгән сатирик образлар тудырыла, ди. Аныңча: «Фельетоннан аермалы буларак, памфлет тамга суга, фаш итә, аерым хаталарны һәм җитешсезлекләрне, аерым кешеләрне гаепләми, ә сыйнфый дошманның, коммунизмга каршыларның, безгә дошман сәяси көчләрнең, сугыш уты кабызучыларның йөзен ачарга, аларны фаш итәргә омтыла. Памфлет эре мишеньнәргә ата». Бу аңлатмада чор тәэсире ярылып ята, памфлет коммунистларның гына сәяси-сыйнфый сугыш коралы кебек аңлашыла, һәм шул сәбәпле аны кабул итеп булмый.

Барлык галимнәр югарыда китерелгән фикерне якламый. А. Квятковскийның «Поэтический словарь» сүзлегендә памфлетка мондый билгеләмә бирелә: «күпчелек очракта көн кадагына сугучан, нинди дә булса иҗтимагый-сәяси күренештән көлүчән яисә иҗтимагый зур дәрәҗәгә ия шәхесне фаш итүчән әдәбипублицистик жанр әсәре»[1]. Күрәсез, болай дип әйтү памфлетның сыйнфый юнәлгәнлеген, коммунизмга каршылар белән көрәшүен һәм масштаблы күренеш-хәлләрне типиклаштыруын нык ассызыклаган В.Д. Пельт аңлатмасы белән туры килми.

«Энциклопедик сүзлек»тә дә памфлетның актуальлегенә, гражданлык пафосына ия булуына, күпчелек очракта социаль-сәяси эчтәлегенә һәм публицистиклыкның еш кына әдәби сатира белән кушылуына басым ясала, нәфис әдәбият жанрларының памфлетка калып бирә алуы искәртелә[2]. Ушаков сүзлегендә памфлетның аерым

[1] Квятковский А. Поэтический словарь. М.: Сов. энцикл., 1966. С. 191.

[2] Памфлет // Энцикл. словарь. URL: slovari.yandex.ru

бер шәхесне, иҗтимагый яисә сәяси күренешне тәнкыйтьләве әйтелә[1]. Брокгауз – Ефрон сүзлегенең тулы версиясендә әлеге төшенчә хакында киңрәк сүз алып барыла: «Памфлет (англ., от *palme-feuillet* – листок, который держат в руке) – термин не вполне определенного содержания, обыкновенно обозначающей небольшое литературное произведение публицистического и чаще всего вызывающе-личного характера. Предмет П. – нападение на политический или общественный строй, в его характерных явлениях или в лице его выдающихся, всем известных представителей. В противоположность сатире, П. редко касается общего состояния нравов и не пользуется художественными обобщениями; объект его критики – определенные, реальные факты и люди; отвлеченная мораль сатиры сменяется в П. резко выраженным практическим взглядом на политическую жизнь страны. /…/ Он, однако, не рассчитывает на спокойное, объективное рассуждение публики; его цель — общественная сенсация, беспокойство, пробуждение недовольства. /…/ В России, при отсутствии политической жизни, почти отсутствует литература памфлетов. Форма брошюры вообще у нас не популярна и сколько-нибудь влиятельные писатели редко прибегают к ней, предпочитая вести проповедь своих идей путем журнальных статей»[2].

Үз галимнәребез памфлетның беренче мәгънәсен – шулай ук «билгеле бер иҗтимагый-политик күренешләрне (дәүләт, сыйныф, ил, дөньяга караш, политик строй) усал итеп көлеп фаш итү», ә икенчесен «персонаж-характерларның һәм сюжетның эчке хасиятләренә буйсындырылмыйча язылган, фаш итү көченә ия булган көчле публицистик әсәр» дип билгели[3]. Памфлет хакында әдәби тәнкыйтькә гаид фикер йөрткәндә, икенче мәгънәсен дә истә тотарбыз. Бу урында шуны да әйтик: А.Г. Әхмәдуллин төзегән «Әдәбият белеме сүзлеге»ндә памфлетның бер төренә дә мисаллар китерелмәгән. Димәк, төшенчәне ачучылар өчен, памфлетка татарча текстлар арасыннан мисал табу кыен булган.

Бер-берсенә каршы килгән, охшаган, керешкән күпсанлы билгеләмәләр белән танышканнан соң, памфлетны әдәби тәнкыйтьтә кулланып буламы, дигән сорау туды. Була. Моның өчен аның

[1] Памфлет // Словарь Ушакова. URL: slovari.yandex.ru

[2] Памфлет // Брокгауз Ф., Ефрон И. Энцикл. словарь. URL: slovari.yandex.ru; Брокгауз Ф., Ефрон И. Энцикл. словарь. Современная версия. М.: ЭКСМО, 2002. С. 428.

[3] Әдәбият белеме сүзлеге. Б. 130.

«Энциклопедик сүзлек»тәге аңлатмасына таянырга кирәк. Без памфлетның шәхси характердалыгын; публицистик һәм әдәби башлангычларны бергә кушуын; фаш итүчән рухын; тәнкыйть объектының реаль фактлар һәм кешеләр булуын; авторның укучыны уятып җибәрергә, анда тормыш күренешләренә карата канәгатьсезлек хисе тудырырга, теге яки бу шәхесләргә карата җәмәгатьчелекнең тискәре фикерен булдырырга теләвен таныйбыз. Памфлет ярдәмендә әдәби барышка мөнәсәбәтле фиркаләр яисә дәүләт сәясәтен, мәдәни хәрәкәттә зур роль уйнаган шәхесләрнең чын йөзен ачарга, сүз сәнгате үсешенә китергән зыяннарын фаш итәргә мөмкин. Шулай да бу жанрны әдәби тәнкыйтьтә куллану шактый четерекле, авыр бер эш, һәм шул сәбәпле ул беркайчан да әлеге өлкәдә популяр булмас дип фаразлыйбыз.

Рус әдәби мирасында күләмле һәм сәяси эчтәлекле памфлетлар күп. Авторның сыйнфый позициясе ачык булганнары да юк түгел. Яңа гасырда сәяси эчтәлекле татарча памфлетлар вакытлы матбугатта сирәк булса да күренде. Әйтик, А. Хамзин шул төр эчтәлектәге «Гадәттән тыш съезд» язмасының жанрын памфлет дип билгеләгән[1].

Памфлетларның әдәби калыпларда – роман, повесть жанрында язылганнары да бар. Бездә дә төрле югары кәнәфиләр биләгән шәхесләрне тәнкыйтьләгән нәфис әдәбият, әдәби-публицистик язмалар чыгып торса да, араларында әһле каләмне фаш иткән хезмәтләр бармак белән санарлык кына. Күпләрнең памфлетны бары тик зур сәясәткә кагылышлы эчтәлеккә генә ия, рәсәйкүләм мәсьәләләрне ача, дип аңлавы аркасында да, тәнкыйтьчеләр аны социаль-иҗтимагый статуслары татар дөньясында гына югары язучыларны фаш итү максатыннан файдаланмый булса кирәк.

Дөрес, бүгенге көндә вакытлы матбугатта зур иҗтимагый вазифалар башкарган, хакимият кәнәфиләрендә утырган каләм ияләренә мөнәсәбәтле памфлетларның очрамавын аларның бөтенләй язылмавы белән түгел, беренче чиратта, сүз ирегә кысылу яисә авторның язмасын басмага тәкъдим итәргә кыюлыгы җитмәү белән бәйләп карарга кирәктер.

Кайвакыт, сатира объектларының эзәрлекләвеннән, хөкемгә бирүеннән сакланып я булмаса теге яки бу әсәрен цензура кайчысы кискәләүдән куркып, каләм ияләре текстка танылган шәхесләрнең исемен үзгәртми керткәндә дә, хезмәт жанрын «хикәя» термины

[1] Хәмзин А. Гадәттән тыш съезд // Идел. 2015. № 7. Б. 76–80.

белән билгеләргә мөмкин. Шул юл белән җыентыкларда урын алган заман памфлетларына мисал рәвешендә З. Зәйнуллинның «Татарның кеме генә юк» китабындагы кайбер язмаларны китерергә булыр иде. Араларында әдәби хәрәкәттәге күренеш-вакыйгаларның иҗтимагый-сәяси асылын фаш иткәннәре дә, түрә кәнәфиләрендә утырган әдәбият-сәнгать әһелләрен чакканнары («Татарның «зур» шәхесе») да бар.

Безнеңчә, памфлетларның әһәмияте зурлыкта түгел, кече күләмле әсәрләрдә дә тормышның мөһим күренешләрен көчле тәнкыйть утына алырга мөмкин. Мәсәлән, Тукайда кече күләмле памфлетлар шактый еш очрый. XX гасыр башы тәнкыйтькә бай, әмма барлык әдипләр һәм шагыйрьләр, галимнәр мирасында да Г. Тукайдагыча форма байлыгы бар дип булмый. Ул төрле күзәтүләр дә ясый, әдәби бәхәсләргә дә керә, мөхәррир-наширләргә җавап-репликалар да ыргыта, рецензияләр һәм әдәбиятка кагылышлы гына фикерләрне үз эченә алган хатлар да яза, шулай да аның чын таланты аеруча сатирик формаларда ачыла. Тукайның публицистик каләме Г. Исхакый, М. Гафури, Г. Ибраһимов, Ф. Кәрими, Һ. Максуди, И. Гаспринский кебек зур шәхесләрне дә чәнчеп үтә. Г. Тукай үз язганнарын да юмор-сатира ярдәмендә яклый, һәм әлеге язмаларның еш кына кайсы жанрга керүен билгеләү дә кыен.

Әдәби-публицистик ояга караган жанрларның чираттагысы – пародия. «Әдәбият белеме сүзлеге»нә таянсаң, әлеге төшенчә грек телендә кабатлау, көлке тудыру өчен бозып күрсәтү дигәнне аңлата[1]. Башка сүзлекләрдә дә аңа якынча шундыйрак билгеләмә бирелгән: «пародия (от греч. пародия – перепев) – жанр критико-сатирической литературы, основанный на комическом воспроизведении и высмеивании стилистических приемов какого-либо писателя, на каррикатурном подчеркивании и утрировке особенностей его писательской манеры»[2].

Тәнкыйтькә кагылышлы пародияләрнең барысы да тәгаен әсәр калыбында гына иҗат ителми; сатирик киң таралыш алган ниндидер форманы, теге яки бу методка нигезләнгән әсәрләрнең, мәктәпләрнең язу стилен дә өлге итеп алырга мөмкин. Мәсәлән, «Безнең заман»да Г. Тукай рецензиягә хас форманы пародия калыбы итә һәм Ф. Сәйфи-Казанлының шул исемдәге драмасыннан түбәндәгчә көлә:

---

[1] Әдәбият белеме сүзлеге. Б. 131.

[2] Квятковский А. Поэтический словарь. С. 195.

«Харис Фәхретдинов нәшер иткән, бер школьник язган «мәнзум» (тезмә. – *Р.Х. тәрҗ.*) комедиядер. Мөндәриҗаты (эчтәлеге. – *Р.Х.* тәрҗ.) шуннан гыйбарәт:

Мин урамга чыгам,
Баганага сөялеп торам,
Тамагымны да кырам,
Ну, яман безнең заман.
Яшьләр бозыла һаман.
Куда конь с копытом,
Мин дә кыстырдым ботым.

Бу школьникның яшьләрдән көләм дип азаплануы нинди көлке булып чыкканлыгын күрер өчен, бу көлке бер пәрдәдә «мәнзум» комедияне алып укырга эшсез кешеләргә тәүсыя итәмез (киңәш бирәбез. – *Р.Х.* тәрҗ.)»

Язманың шул чор рекламаларына да охшашлыгын билгеләргә кирәк. Шушы ук әсәрнең дөнья күрү уңаеннан, Борһан Шәрәф, Сәгъди псевдонимы белән култамга салып, рецензия язган була. Соңрак Тукай, «Безнең заман вә Сәгъди абзый» исемле фельетоны белән, авторны әсәрнең асыл яңалыгын күрә белмәве, кирәксез, мөһим булмаган якларга игътибар итүе өчен тәнкыйтьли.

Татар әдәбиятында пародиянең иң ачык мисалы дип Г. Тукайның «Яңа Кисекбаш» поэмасын атыйлар. Шагыйрь «дини эчтәлекле «Кисекбаш» китабының сюжетын, стилен саклап, эчтәлеге аңа бөтенләй капма-каршы булган әсәр яза»[1].

Кайвакыт юмор-сатира рухындагы әдәби тәнкыйть көндәлекләрдә дә урын ала. Мәсәлән, Фатих Әмирханның 1926 елда теркәгән фикерләренең аерымланып куелган өлеше – шигырьгә карата язылган сатира-юмор:

«„Шәрекъ яшьләре“ журналының 9–10 санында Кәрим Әмиринең „Сахра баласы“ исемле шигырен укып бик яраттым. Яратмаслык түгел, күз алдына гаять шагыйрәнә бер күренеш килә: чипчибәр генә дүрт-биш потлык, сакал-мыеклы бер сахра баласы, күп уйлап тормастан, гөлгә басып талпына башлый, үзе нәрсәгә ачуланыптыр бик ярсый...

Хәер, аның мөндәриҗәсен болай шигырьсез генә аңлатуы кыен. Мин сезгә аның шигырен үзен китерим. Үзен дигәч тә, бө-

[1] Әдәбият белеме сүзлеге. Б. 131.

тенләй үзен үк түгел, бер-биш алты гына сүзен үзгәртеп, вәзенен, кафиясен, шигъри картинасын, бигрәк тә үзенә бөртөрле мантыйгын тәмамән саклаган хәлдә каршыңызга куям:

Зур тимсахтай талпынам,
Гөлгә ятып,
Тирбәнеп:
Көнне сүгеп ярсынам,
Җилләнеп...
Койрыгымны сыртыма салып,
Күккә үрлим –
Болыт күреп.
Самаларның эчен ярып,
Җирдә җырлыйм –
Бака күреп ...
Таң җилләре искәндә,
Иркә күлдән –
Чүп алам.
Былбыл думбра чирткәндә,
Теге бакадан сер алам...»[1]

Шигырь шул рәвешчә дәвам итә. Сатирик пландагы бу язма катнаш характерда, һәм аның тезмә өлеше – билгеле әсәргә пародия. Чәчмә өлешендә лирик миннең комик портреты тасвирланган.

Шарж төшенчәсе французчадан алынган *(Charge)* һәм арттыру мәгънәсен аңлата. Аның тамырлары фольклорга барып тоташа, әдәбиятта активлашуы XX гасыр башына карый һәм юмор-сатирага урын биргән вакытлы матбугат чыга башлауга бәйле.

Теге яки бу күренешне, кешене, аларга хас сыйфатларын арттырып, күпертеп, күпмедер үзгәртеп, әмма тар тирәлек булса да танырлык итеп сурәтләгән әсәрләрне шарж термины белән атыйлар. Әдәби формадагы шарж да, рәсем рәвешендәгесе дә сурәтләү объектыннан усал яисә яратып көлә, андагы җитешсез һәм тискәре якларны ача, фаш итә, шул сәбәпле тирәлектә иҗтимагый-мәдәни вазифа да башкара.

Бүгенге көндә каләм ияләренә шаржларны иң күп ясаучы һәм язучы – Зөлфәт Хәйруллин. Ул, гадәттә, язучыларның көлкеле

[1] Әмирхан Ф. «Йолдыз» идарәсенә // Әмирхан Ф. Әсәрләр. Т. 4. Б. 278–280.

сурәтләре янәшәсенә тасвир объектларын яратып, якын итеп сурәтләгән шарж-текст та урнаштыра.

Тәнкыйть жанрларын төркемләгән бүлек укучыга бу өлкә алдында торган проблемаларның шактый катлаулылыгын, һичшиксез хәл ителергә тиешлеген күрсәткәндер. Анда, укучы үзе дә уйлансын, теге яки бу фикергә килсен өчен, жанрларга бәйле төрле карашлар, классификацияләр, билгеләмәләр китерелде. Шунысын да әйтергә кирәк: жанрга кагылышлы проблемаларны чишүдәге буталчыклык соңгы вакытларда һич кенә дә кимеми, торган саен арта гына бара шикелле. Аның исә һәм объектив, һәм субъектив сәбәпләре бар.

Әдәби тәнкыйть терминологиясен эшләүдә татар галимнәре рус гыйльмиятенә таяна, бу юнәлештә мөстәкыйльлекләре чикләнгән – үз карашларын башкаларга уздыру мөмкинлекләре юк дәрәҗәсендә. Димәк, әдәби тәнкыйть өлкәсенә караган бәхәсле моментларның уңай, кайберләренең исә кире әйләнеп кайтмаслык хәл ителешен, нигездә, рус тәнкыйть теориясенең киләчәктәге үсешенә бәйләргә кала.

Вакытлы матбугат киң таралган чорда гына түгел, аларның укылышы кимегән заманнарда да тәнкыйть – кирәкле шәйдер. «Ләкин тәнкыйть итүченең дә кем очрады шул булуы тагы ярамый. Тәнкыйтьче булыр өчен, әлбәттә, үзләре дә әдәбият галәмендә ат уйнаткан тәҗрибәле һәм әхлаклы кеше булуы таләп ителә»[1]. Тәнкыйтьнең жанр формаларын уңышлы, нәтиҗәле файдалана белү, иҗтимагый әһәмиятле язмалар белән чыгыш ясау аның белән шөгыльләнүченең тирән белеменә, әхлакый сафлыгына нигезләнә.

Сүз сәнгатенең озын тарихы дәвамында тәнкыйть, төрле формалар кулланып, чынбарлыкны өйрәнү һәм нәфис иҗатта чагылдыру юлларын ача, шул чагылдыруны камилләштерү турында фикер йөртә. Ул җәмгыятьнең, каләм иясенең һәм укучының сәнгати аңын үстерә һәм, нинди генә калыпларда яшәсә дә, мәдәни кыйммәткә ия әсәрләрнең дөньяга килүенә хезмәт итәргә тиеш.

---

[1] Тукай Г. Тәнкыйть – кирәкле шәйдер // Тукай Г. Әсәрләр: 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. Т. 3. 245 б.

# ЙОМГАК

*Бер дигән тәнкыйтьче булу өчен,*
*яхшы язучылык сәләте кирәк.*
*Бары тик талант кына*
*зәвык офыкларын киңәйтә ала.*
Ф. Вильме.

Әдәбият үскән саен, аны өйрәнгән фән алдында да таләпләр арта. Бүгенге тәнкыйтьче вакытлы матбугатта методологик культурага ия журналист та, гыйльми төшенчәләрне яхшы белгән, әдәби барышны дөрес күзаллаган галим дә, билгеле бер дәрәҗәдә язучы сәләтенә ия каләм әһле сыйфытында да чыгыш ясый. Әхлакый позициясе ныклы тәнкыйтьче һәр нәрсәдә күләм-чама тойгысын югалтмаска, уңай холык сыйфатларына, үз фикерен якларлык рухи көчкә ия булырга һәм, тәнкыйтьчегә дә, укучыга да, әдәбиятка да зыян салма, принцибыннан торып эш итәргә тырыша.

Сүз сәнгатебезнең тарихы шактый озын. Аңа хезмәт иткән фәннәрнең тарихы да инде кыска түгел. Алар үсештә, үзгәрештә. Әлеге барышта әдәби тәнкыйть жанрлары арткан, үзгәргән кебек, әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнүченең дә күзаллаулары киңәергә, талант ы үсәргә, язганнары кызыклырак, укучыга кирәклерәк, милләтенә файдалырак була барырга тиеш. Үз заманында илебездә тәнкыйтькә игътибар һәм хөкүмәт, һәм халыкның төрле катлаулары, һәм әдәбиятчылар тарафыннан зур булган. Бу әкренләп үзгәрде һәм үзгәрүен инде кызу тизлекләр белән дәвам итә. Шушы шартларда алдыбызда тәнкыйтьне кризистан чыгару, яңадан җанландыру, укылышлы итү бурычы тора.

Интернет челтәренең киңәюе, басма сүзнең электрон төрләргә алмашына башлавы да әдәби тәнкыйть хезмәтенә үз эзен салды. Бердән, ул тагын да оперативлашты. Икенчедән, тәнкыйть язмаларын туплаган китаплар аз чыга башлады, вакытлы матбугат та әдәбиятка кагылышлы язмаларга мәйданны чикләде, кайберләре

бөтенләй кисте. Өченчедән, журналистлар, галимнәр, язучылар саны артканнан арта барган бүгенгебездә югары квалификацияле тәнкыйтьчеләргә кытлык кичерә башладык.

Тәнкыйтькә зур талантларның килмәве аның актив кулланышта йөргән формаларын киметте. Бүгенге көндә югары уку йортлары алдында алдында тирән эчтәлекле проблемалы мәкаләләр яза алган, үзенчәлекле әдәби-публицистик формаларда иҗат итәргә сәләтле һөнәри тәнкыйтьчеләр, өметле яшь галимнәр тәрбияләү бурычы тора. Тәнкыйть жанрларына билгеле бер дәрәҗәдә күз ташлаган бу китап аларга күпмедер ярдәмче булыр, һәм укучы аннан үзенә кызыклы мәгълүмат та алыр, дигән өметтә калабыз.

## БЕЛЕМНӘРНЕ ИСӘПКӘ АЛУ ӨЧЕН СОРАУЛЫК

Фән буларак әдәби тәнкыйть, предметы, бурыч-максатлары.

Әдәби тәнкыйтькә куелган таләпләр.

Әдәби тәнкыйтьнең принциплары.

Әдәби тәнкыйтьнең башка фәннәр белән бәйләнеше.

Әдәби тәнкыйтьнең фәнни нигезе.

Әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме; аларның тикшерү объектын сайлау һәм аңа якын килү үзенчәлекләре.

Вакытлы матбугат – әдәби тәнкыйть мәйданы.

Әдәби тәнкыйтьнең адресатка бәйле аерымлыклары.

Һөнәри, һәвәскәр тәнкыйть һәм язучы тәнкыйте.

Әдәби тәнкыйтьнең иҗтимагый нигезе.

Әдәби тәнкыйть – идеологик корал.

Сүз иреге, цензорлык мәсьәләсе.

Әдәби тәнкыйтьтә объективлык һәм субъективлык мөнәсәбәте.

Тәнкыйтьнең сәнгатилеге.

Тәнкыйтьче осталыгының алшартлары.

Тәнкыйть язмаларының тәмамланганлыгы, бөтенлеге.

Тәнкыйтьтә эчтәлек һәм форма мөнәсәбәте.

Әдәби тәнкыйтьнең публицистик асылы.

Тәнкыйть материалларын объект ноктасыннан төркемләү.

Әдәби тәнкыйтьнең үзаңы.

Әдәби тәнкыйть тарихын этапларга бүлү принциплары.

Татар әдәби тәнкыйть тарихының гомумкабул ителгән этаплары.

Татар әдәби тәнкыйть тарихын ачкан хезмәтләр.

Тәнкыйть һәм вакытлы матбугат үсешенең үзара бәйләнгәнлеге.

Әдәби тәнкыйть – пропаганда чарасы.

Тәнкыйтьтә һөнәри әхлак проблемасы.

Тәнкыйтьченең әхлакый позициясе.

Жанр формаларын төркемләү принциплары.

Информатив төр.

Тәнкыйть язмаларының аналитик оясы.

Әдәби-публицистик төр.

Әдәби портрет: материалы һәм аны ачу юллары.

Эссега бүгенге билгеләмәләр.

Очерк һәм аның төрләре.

Фельетон, пародия, памфлет; охшаш һәм аермалы яклары.

Проблемалы мәкалә.

Күзәтү, хисап; уртак яклары.

Комментарийлар язуга фәнни һәм әдәби хәзерлек.

Рецензия; терминны аңлауда төрлелек.

Рецензия һәм авторецензия.

Аннотация һәм аңа куелган таләпләр.

Хатлар, истәлекләр эчендә әдәбиятны бәяләү.

XIX–XX гасыр чигендәге елъязма һәм юлъязмаларда әдәбият чагылышы.

Некролог. XX, XXI гасыр некрологлары арасында охшаш һәм аермалы яклар.

Т. Гыйлаҗевнең «Рецензияләрдән – тәгъзияләргә» хезмәтендә XX гасыр башы әдәби тәнкыйть язмаларын төркемләү.

Ә. Закирҗановның «Яңарыш юлында» китабында әдәби тәнкыйть жанрларына кагылышлы фикерләр.

Тәнкыйтьченең әдәби барыштагы роле.

Журнал һәм газеталардагы тәнкыйть арасында аермалыклар.

Электрон газета-журналлардагы һәм интернеттагы тәнкыйть.

Тәнкыйди фикернең телдән сөйләмдә яшәү формалары.

Тәнкыйтьченең хакимият, цензура, идеология белән мөнәсәбәтләре.

Тәнкыйтьченең иреге һәм ирексезлеге.

Тәнкыйтьченең басмаханәләр эшчәнлегенә тәэсире.

Тәнкыйтьче һәм әдип репутациясе.

Бүләкләр, әдәби премияләр бирүче оешмаларда тәнкыйтьче башкарырга тиешле вазифа, тәнкыйтьченең алар эшчәнлегенә йогынтысы.

# ӘДӘБИЯТ


## Дәреслекләр һәм уку әсбаплары

*Рус телендә*

Баранов В.И., Бочаров А.Г., Суровцев Ю.И. Литературно-художественная критика. М.: Высшая школа, 1982. 206 с.

Бочаров А.Г. Жанры литературно-художественной критики. М.: Изд-во Моск. ун-та, 1982. 51 с.

Гилязов Т.Ш. История татарской литературной критики: конспект лекций. Казань, 2014. 125 с.

Крылов В.Н. Теория и история русской литературной критики. Казань: Казан. ун-т, 2011. 124 с.

*Татар телендә*

Гыйләҗев Т.Ш. Татар әдәби тәнкыйте тарихы (1900–1925): методик кулланма. Казан, 1999. 42 б.

Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән – тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 254 б.

Закирҗанов Ә.М. Яңарыш юлында (хәзерге татар әдәбият белеме мәсьәләләре). Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 303 б.

Харрасова Р.Ф. Әдәби тәнкыйть теориясе: махсус фән программасы. Казан: КДУ нәшрияты, 2007. 32 б.

## Өстәмә әдәбият

*Рус телендә*

Авраамов Д.С. Профессиональная этика журналиста. М.: Изд-во Моск. ун-та, 2003. 264 с.

Азизова Г.А. Вопросы истории татарской литературы в трудах Гали Рахима: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2001. 21 с.

Аристов В., Ермолаев Н. Все началось с путеводителя. Казань, КГУ. С. 64–65.

Аристотель // Античные риторики / под ред. А.А. Тахо-Годи. М.: Изд.-во Мос. ун-та, 1978. С. 134–135;

Басинский П. Искусство пристрастного чтения, В.Г. Белинский // Белинский В.Г., Добролюбов Н.А., Чернышевский Н.Г., Писарев Д.И. Статьи о русской литературе. М.: ЭКСМО-Пресс, 2002. С. 5, 7.

Бахтин М.М. Эстетика словесного творчества. М.: Искусство, 1986. 449 с.

Белинский В.Г. Полное собрание сочинений: в 13 т. М.: Изд. АН СССР, 1955. Т. 6. С. 270.

Бикчантаев А. Я побывал у друзей // Лит. Россия. 1964. 18 дек.

БСЭ. 3-е изд. М.: Сов. энцикл., 1973. Т. 14. С. 1550.

БСЭ. 2-изд. М.: Сов. энцикл., 1952. Т. 15. С. 589.

Борев Ю.Б. Искусство интерпретации и оценки. М.: Сов. писатель, 1981. 399 с.

Борев Ю.Б. Эстетика // Теория литературы: нциклопедический словарь терминов. М.: Астрель, 2003. С. 31, 126, 278.

Брокгауз Ф., Ефрон И. Энцикл. словарь. Современная версия. М.: ЭКСМО, 2002. С. 428.

Бурсов Б.И. Критика как литература. Л.: Лениздат, 1976. 320 с.

Введение в литературоведение / под ред.: Л.В. Чернец. М.: Высшая школа, 2000. 556 с.

Виноградов В.В. О теории художественной речи. М.: Высшая школа, 1971. 239 с.

Волков Ю.Г., Поликарпов В.С. Человек: энцинклопедический словарь. М.: Гардарики, 1999. С.179.

Вопросы истории литературной критики / редкол.: М.М. Владимирова, А.С. Дмитриев, И.К. Киреева и др. Тюмень: Изд. Тюменьского госуниверситета, 1977. 156 с.

Ворошилов В.В. Журналистика: учеб. 7-е изд., стер. М. : КНОРУС, 2010. 496 с.

Гилазов Т.Ш. Основные тенденции развития татарской литературной критики в 20 – 30-е годы (проблемы метода и героя): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1992. 25 с.

Голубков М.М. История русской литературной критики XX века (1920 –1990-е годы). М.: Академия, 2008. 366 с.

Горохов В.М. Газетно-журнальные жанры. М.: Моск. экспериментальный гуманитарный ун-т, 1993 175 с.

Горький М. С кем вы, мастера культуры? / сост.: Е. Стояновской. М.: Худ. лит., 1985. С. 8–28 .

Григорьев А. Литературная критика. М.: Худ. лит., 1967. С. 114.

Громов Е.С. Искусство и герменевтика. СПб.: Алетейя, 2004. 335 с.

Гроссман Л.П. Жанры художественной критики // Искусство. 1925. № 2. С. 61–81.

Дускаева, Л.Р. Диалогическая природа газетных речевых текстов. Пермь, 2004. 276 с.

Егоров Б.Ф. О мастерстве литературной критики: жанры, композиция, стиль. Л.: Сов. писатель, 1980. 318 с.

Елисеев А.И., Полякова Л.Г. Словарь литературоведческих терминов. Ростов н./ Д.: Феникс, 2002. С.92.

Есин А.Б. Литературоведение. Культурология. М.: Флинта, Наука, 2002. 353 с.

Есин А.Б. Принципы и приемы анализа литературного произведения. М.: Флинта, Наука, 2002. 248 с.

Житкова Л.Н. История и теория русской литературной критики XIX века. Екатеринбург: Изд-во Урал. ун-та, 2004. 160 с.

Журбина Е.И. Теория и практика художественно-публицистических жанров. Очерк. Фельетон. М.: Мысль, 1969. С. 209–243.

Загидуллина Д.Ф. Формирование и этапы становления теории татарской литературы (первая треть XX века): автореф. дис. ... докт. филол. наук. Казань, 2001. 70 с.

Зайнуллина Г. Бег: беседа с искусствоведом Р. Султановой // Звезда Поволжья. 2005. 7–13 июля.

Закирзянов А.М. Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. XX – нач. XXI вв.). Казань: Ихлас, 2011. 320 с.

Зельдович М.Г. Уроки критической классики. Вопросы теории и методологии критики. Очерки. Харьков: Вища школа, 1976. С. 3.

Золотусский И.П. Вместо послесловия // Очная ставка с памятью. М.: Современник, 1983. С. 285–286.

Золотухина-Аболина Е.В. Современная этика. Сущность, истоки, категории морали, проблемы. Ростов-н/Д: МарТ, 2000. 448 с.

История татарской литературы нового времени (XIX – начало XX в.). Казань: Фикер, 2003. 472 с.

Истратова С.П. Литература – глазами писателя. М.: Знание, 1990. 63 с.

Прозоров В.В., Милованова О.О., Елина Е.Г. и др. История русской литературной критики / под ред. В.В. Прозорова. М.: Высшая школа, 2002. 463 с.

История русской литературной критики / под ред. В.В. Прозорова. М.: Академия, 2009. 432 с.

Калошин Ф.И. Содержание и форма в произведениях искусства. М.: Гоиздат политической литературы, 1953. С. 24, 113 .

Квятковский А. Поэтический словарь. М.: Сов. энцикл., 1966. С. 191, 195.

Козлов А.С. Основные этапы развития литературно-критической мысли // Основы литературоведения / В.П. Мещеряков, А.С. Козлов и др. М.: Дрофа, 2003. С. 355–414.

Коновалов В.Н. Теоретические проблемы классификации литературно-критических жанров // Жанры русской литературной критики 70–80-х годов XIX века. Казань: Изд-во Казанского ун-та, 1991. С. 5–16.

Коновалов В.Н. Литературная критика 70 – начала 80-х годов XIX века (системный анализ): дис. ... докт. филол. наук. Саратов, 1996. 56 с.

Корман Б.О. Целостность литературного произведения и экспериментальный словарь литературоведческих терминов // Проблемы истории критики и поэтики реализма. С. 39–54.

Краткая литературная энциклопедия / гл. ред. А.А. Сурков. М.: Сов. энцикл., 1964. Т. 2: Гаврилюк – Зюльфигар Ширвани. 1056 стб.

Краткий словарь литературоведческих терминов: кн. для учащихся / ред.-сост. Л.И. Тимофеев, С.В. Тураев. 2-е изд., дораб. М.: Просвещение, 1985. 208 с.

Кременцов Л.П. Теория литературы. Чтение как творчество. М.: Флинта: Наука, 2003. С.156.

Кройчик Л.Е. Система журналистских жанров // Основы творческой деятельности журналиста / ред.-сост. С.Г. Корконосенко. СПб.: Об-во «Знание», 2000. С. 125–168.

Крупчанов Л.М. История русской литературной критики XIX века. М.: Высшая школа, 2005. 383 с.

Крылов В.Н. Русская символистская критика (1890–1910-е гг.): генезис, типология, жанровая поэтика: дис. ... докт. филол. наук. Казань, 2007. 508 с.

Кузнецов Ф. С веком наравне: критика прозы. Критика критики. М.: Моск. Рабочий, 1981. С. 81.

Курилов А.С. Проблема «литературного направления» в русской критике первой трети XIX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1972. 17 с.

Кутуй Р. Что назвать поэзией? // Литературная газета. 1964. 3 дек..

Лазутина Г.В., Распопова С.С. Жанры журналистского творчества: учеб. пособие. М.: Аспект Пресс, 2011. 320 с.

Лежнев С.П. Проблемы писательской критики // Русская литературная критика. Саратов: Изд-во Саратовского ун-та, 1994. С. 84–89.

Лингвистическкий энциклопедический словарь. М.: Сов. энцикл., 1990. С. 505.

ЛЭТП / под ред. А.Н. Николюкина. Институт научной информации по общественным наукам РАН. М.: Интелвак, 2003. 1600 стб.

Литературный энциклопедический словарь / под ред. В.М. Кожевникова и П.А. Николаева. М.: Совет. энцикл., 1987. 750 с.

ЛЭ. М.: Сов. энцикл., 1981. С. 169.

Магдеев М.С. Татарская советская литературная критика (1917–1932): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1964. 25 с.

Магдеев М.С. Социальные корни таланта. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1990. 159 с.

Майданова Л.М. Стилистические особенности газетных жанров: лекции по спецкурсу. Свердловск: УрГУ 1987. С. 59.

Майков В.Н. Литературная критика. Л.: Худ. лит., 1985. 408 с.

Мамардашвили М.К. Литературная критика как акт чтения. URL: http://www.philosophi. ru /library /mmk/ critique.html

Марков Г. Советская литература в борьбе за коммунизм и ее задачи в свете решений XXVI съезда КПСС // Вопр. лит. 1981. № 8. С. 13–48.

Михайлова М.В. История русской литературной критики конца XIX – начала XX века: метод указания. М.: Изд-во Моск. ун-та, 1985. 80 с.

Михайловский Н. Литература и жизнь // Субъективизм и индивидуализм в общественной философии. Н.А. Бердяев. М.: Канон+ 1999. С. 315.

Мухамадиев Р.С. Проблемы формирования татарской литературной критики (1900–1917). Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. 143 с.

Надеждин Н.И. Литературная критика. Эстетика. М.: Худ. лит., 1972. 575 с.

Найданова В.А. Становление и развитие жанров в литературной критике Бурятии XX века. Улан-Удэ, 2014. 174 с.

Недзвецкий В.А. Русская литературная критика XVIII–XIX веков: курс лекций. М.: Изд-во МГУ, 1994. 182 с.

Нигматуллина Ю.Г. «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань: Фэн, 2002. 176 с.

Нигматуллина Ю.Г. Национальное своеобразие эстетического идеала. Казань: Изд-во Казан.ун-та, 1970. 212 с.

Нигматуллина Ю.Г. Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фән, 1997.190 с.

Нигматуллина Ю.Г. Системно-комплексное исследование художественного творчества: история научного направления в Казанском университете. Казань: Фән, 2004. 251 с.

Нигматуллина Ю.Г. Изучение русской литературы в КГУ // Ученые записки Казанского государственного университета. Серия Гуманитарные науки. 2009. Т. 151, кн. 3. С. 7–20.

Никитин Л.А. Эстетика. М.: Юнити-Дана, 2003. 439 с.

Николаев П.А. Марксистско-ленинское литературоведение. М.: Просвещение, 1983. С. 221, 225.

Нуруллин И.З. Путь к зрелости: формирование и развитие критического реализма в татарской литературе. Казань: Татар. кн. изд-во, 1971.271 с.

О литературно-художественной критике: Постановление ЦК КПСС от 21 января 1972 года // КПСС в резолюциях и решениях съездов, конференций и пленумов ЦК. М., 1978. Т. 11. С. 31.

Очерки истории русской литературной критики: в 4 т. / под ред. Ю.В. Стенника. СПб.: Наука, 1999. Т. 1: XVIII – первая четверть XIX в. 368 с.

Папернов Е. Новые книги // Новый мир. 1982. № 5. С. 268.

Пельт В.Д. Дифференциация жанров газетной публицистики. М.: Изд-ство Мос. госуниверситета, 1984. С. 17.

Петрушевская В.В. Критика в поисках предмета // Проблемы развития литературной критики: сб. статей / ред.: В.В. Ефимов, Б.Л. Милявский. Душанбе: ТГУ, 1984. С. 3.

Плеханов Г.В. Добролюбов и Островский // История в слове. М.: Современник, 1988. С. 161,162.

Плеханов Г.В. Избранные философские произведения: в 5 томах. М., 1958. Т. 5. С. 186.

Прозоров В.В. О принципах периодизации истории литературной критики // Освобождение от догм. История русской литературы: состояние и пути изучения. М.: Наследие, 1997. Т. 1. С.79–97.

Резолюция ЦК РКП (б) «О политике партии в области художественной литературы» от 18 июня 1925 года // Известия ЦК РКП(б). 1925. 1 июля, № 25–26. С. 8–9.

Русская литературная критика / под ред. В.В. Прозорова. Саратов: Изд-во Сарат. ун-та, 1994. 191 с.

Русская советская литературная критика (1917–1934): хрестоматия. М.: Советский писатель, 1981. 297 с.

Русская советская литературная критика (1956–1983): хрестоматия / сост.: Л.Ф. Ершов, В.П. Муромский. М.: Просвещение, 1984. 367 с.

Салтыков-Щедрин М.Е. Литературная критика. М.: Современник, 1982. 349 с.

С кем вы, мастера культуры / сост.: Е.В. Стояновская. М.: Худ. лит., 1985– 542 с.

Сивогривова А.А. Литературный портрет // Основы литературной критики. Ростов н.-Дону: Изд-ство Ростовского-н.-Дону госпединститута, 1975. С. 55, 59.

Смирнов В.В. Жанры радиожурналистики. М.: Аспект Пресс, 2002. С. 39.

Стадников Г.В. О специфике писательской критики // Зарубежная литературная критика. Вопросы теории и истории. Л.: ЛГПИ, 1985. С. 3–20.

Стенник Ю.В. Литературная критика периода классицизма (1740 – 1770-е гг.) // Очерки истории русской литературной критики: в 4-х т. СПб.: Наука, 1999. Т. 1: XVIII – первая четверть XIX в. С. 37–95.

Соловьев В.С. Литературная критика. М.: Современник, 1991. 421 с.

Страхов Н.Н. Литературная критика. М.: Современник, 1984. 431 с.

Тертычный А.А. Жанры периодической печати: учеб. пособие. М.: Аспект Пресс, 2000. 310 с.

Тимофеев, Л.И. Основы теории литературы. 5-е изд., испр. и доп. М., 1976. С. 353–406.

Томашевский Б.В. Теория литературы. Поэтика. М.: Аспект Пресс, 1996. 334 с.

Топоров В.Н. Миф. Ритуал. Символ. Образ: исследования в области мифопоэтического. М.: Прогресс-Культура, 1995. 624 с.

Троцкий Л. Литература и революция (печатается по изд. 1923 г.). М.: Издательство политической литературы,1991. 400 с.

Тургенев И.С. П.В. Анненкову // Тургенев И.С. Полное собрание сочинений и писем: в 13 томах. М.–Л.: Изд-ство АН СССР, 1961. Т. 2. С. 144–146.

Хализев В.Е. Интерпретация и литературная критика // Хализев В.Е. Проблемы теории литературной критики. М.: Изд-во МГУ, 1980. С. 49–93.

Хализев В.Е. Драма как род литературы (поэтика, генезис, функционирование). М.: Изд-во МГУ, 1986. 260 с.

Хализев В.Е. Теория литературы. М.: Высшая школа, 1999. С. 16.

Хализев В.Е. Теория литературы: учеб. 2-е изд. М: Высш. шк., 2000. 398 с.

Ханзафаров Н.Г. Татарская комедия. Казань: Фән, 1996. 189 с.

Ханнанов Р.Г. Татарская сценическая литература в контексте тюркской драматургии (конца XIX – начало XX веков): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2009. 22 с.

Харрасова Р.Ф. Практикум по литературной критике (Әдәби тәнкыйть буенча практикум): программа спецкурса: на тат. и рус. яз. Казань: ГАРТ, 2004. 19 с.

Хасавнех А.А. Этико-эстетические воззрения поэта-суфия XIX века Ахметзяна Тубыли: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2002. 28 с.

Хусни Ф. Шаги догоняющих // Лит. Россия.1965. 1 январь.

Шелгунов Н.В. Литературная критика. Л.: Худ. лит., 1974. 416 с.

Шостак М.И. Репортёр: профессионализм и этика. М., Изд. РИП-холдинг, 2001. 192с.

Штейнгольд А.М. Анатомия литературной критики (природа, структура, поэтика). СПб.: Дмитрий Буланин, 2003. 201 с.

Элиот Т. Назначение поэзии и назначение критики // Элиот Т. Статьи о литературе. Киев: AirLand, 1996. С. 40–150.

Эсалнек А.Я. Основы литературоведения. Анализ художественного произведения: практикум. 2-е изд. М.: Флинта: Наука, 2004. 216 с.

Этика: энциклопедический словарь / под ред. Р.Г. Апресяна и А.А. Гусейнова. М.: Гардарики, 2001. С. 573, 580.

Якобсон П.М. Психология чувств, М., 1958. С. 210.

Якупова Г.Х. Дискуссии писателей в контексте татарской духовной жизни начала XX века (на примере Г. Исхаки, Ф. Карими и др.): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2006. 25 с.

Якушин Н.И. Русская литературная критика XVIII – начала XX века: учеб. пособие и хрестоматия. М.: Камерон, 2005. 816 с.

*Татар телендә*

Ахунов Г. Әдәби язмышлар: мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. 190 б.

Ахунҗанов И. Поэзия турында фрагментлар // Художник һәм аның сүзе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 89–98.

Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред.: А.Г. Әхмәдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 238 б.

Әмир М. Кимчелексез уңай герой // Совет әдәбияты. 1954. № 8.

Әмир М. Заманга хас стиль // Соц. Татарстан. 1962. 16 июль.
Әмир М. Иҗат дәрте. Татарстан язучыларының VII съездында сөйләгән докладтан // Үзебез турында: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре, чыгышлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. Б.73–101.
Әмирхан Ф. «Йолдыз» идарәсенә // Әмирхан Ф. Әсәрләр: 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.Т. 4. Б. 278–280.
Әмирхан Ф. Ризван Алушига // Әмирхан Ф. Әсәрләр: 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Т. 4. Б. 283.
Әмирхан Ф. Исмәгыйль Аетовка // Әмирхан Ф. Әсәрләр: 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Т. 4. Б. 271.
Әмирхан Ф. Исмәгыйль Аетовка // Әмирхан Ф. Әсәрләр: 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Т. 4. 286 б.
Әхмәдуллин А. Г. Дөреслеккә ирешү юлында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 255 б.
Әхмәдуллин А. Г. Офыклар киңәйгәндә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 239 б.
Әхмәдуллин Ш. Уйланырга кирәк // Киләчәкне уйлап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. Б. 76–85.
Бакиров М. Поэзиябезнең тәмен тирән тоябызмы? // Соц. Татарстан. 1966. 10 июль.
Баттал Г. Нәзарияте әдәбия. Казан: Өмет, 1913. 104 б.
Бариева Э. Әдәбият белеме һәм тәнкыйть // Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Т. 4: Татар совет әдәбияты (1917–1941). Б. 302.
Баянов Ә. Заман сурәтләре: лирик язмалар, мәкаләләр, очерклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 272 б.
Бәширов Г. Безнең бурычлар // Совет әдәбияты. 1955. № 3.
Бурнаш Ф. Муса Җәлил шигырьләре // Әдәбият һәм сәнгать турында. Мәкаләләр һәм рецензияләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 202.
Вәлиди Җ. Әдәби мөсахәбә // Татарстан хәбәрләре. 1922. 5 март;
Вәлиди Җ. Аңларга тырыштык, аңлый алмадык (Галимҗан иптәш Ибраһимовка җавап) // Татарстан хәбәрләре. 1922. 10 март.
Вәлиев М. Табарга һәм югалтмаска!: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 104 б.
Вәлиев М. Күңелнең көткәне: тормыш һәм әдәбият турында уйланулар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 179 б.
Вәлиев М. Учагың сүнмәсен: әдәби әңгәмәләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 192 б.
Вәлиев М. Каһарманнар кирәк: тормыштагы һәм әдәбияттагы уйланырлык күренешләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 238 б.
Вәлиев М.Х. Гамәл дәфтәре: Әдәбият һәм тормыш турында уйланулар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 447 б.
Вәлиулла И. Ә. һәр шагыйрь – бер дәрья... Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 156 б.

Гайнетдин М. Такташ иҗатын тәнкыйди үзләштерү тарихыннан // Хакыйкать юлыннан. Казан: Татар. кит. нәшр, 2001. Б. 143–145.

Гали Г. Абынуларыбызның берсе // Актака. 1930. № 2. Б. 15.

Галиев М. Оҗмах бакчалары хозур // Галиев М. Сайланма әсәрләр: 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. Т. 4. 269 б.

Галиев Ш. Серләрем бар: лирика, юмор. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Б. 2.

Галиева Э.Р. Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. Казан: Фән, 2002. 360 б.

Галимуллин Ф. Инешләр Иделгә кушыла. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 135 б.

Галимуллин Ф. Офыкларны алдан күреп: тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 201 б.

Галимуллин Ф.Г. Эстетика һәм социологизм: 20–30 нчы еллар татар әдәбиятында эстетика кануннарының һәм социологизм таләпләренең үзара мөнәсәбәте. Казан: Мәгариф, 1998. 223 б.

Галимуллин Ф.Г. Әле без туганчы: 1920–1930 еллар әдәби хәрәкәтенә бер караш. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 320 б.

Галимуллин Ф.Г. Табигыйлеккә хилафлык.Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 303 б.

Галиуллин Т. Буыннар һәм язмышлар. Хәзерге татар поэзиясе турында уйланулар // Казан утлары. 1974. № 5. 157–176 б.

Галиуллин Т. Шагыйрьләр һәм шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 208 б.

Галиуллин Т. Тәнкыйть кемгә кирәк? // Татарстан яшьләре. 1989. 28 гыйнвар.

Галиуллин Т. Гомер учагы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 207 б.

Галиуллин Т. Дәгъва: хикәяләр, публицистика, әдәби тәнкыйть. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 255 б.

Галиулин Т. Шигырь кемгә кирәк? // Казан утлары. 1995. № 7. Б. 139–142.

Галиуллин Т. Шәхесне гасырлар тудыра. Әдәби тәнкыйть, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 319 б.

Гамбәр Н. «Башны салларга салып…» Портретка штрихлар // Казан утлары. 1993. № 8. Б. 96–110.

Ганиева Р.К. Шагыйрьнең рухи дөньясы («Габдулла Тукай» энциклопедиясе сүзлек-белешмәсенә әзерләнгән материаллардан). Казан: ТаРИХ, 2002. Б. 46–47.

Гасрый Н. Әдәбиятыбыз мөнтәкыйдкә мохтаҗ // Ил. 1913. 14 ноябрь.

Гәрәев М. Мин, Чуен Гәрәй малае... Казан: Идел-Пресс, 2004. 334, 336, 628 б.

Гәрәй Р. Таныш булыгыз: Р. Фәйзуллин // Татарстан яшьләре. 1962. 22 ноябрь.

Госман Х. Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1960. Б. 113.

Госман Х. Татар совет әдәбияты фәненең беренче адымнары // Совет әдәбияты. 1966. № 7.

Горький М. Әдәбият турында. Казан: Татгосиздат, 1941. Б. 210–211.

Гыйззәт Т. Бәхетле, шатлыклы чынбарлыгыбызны дөрес чагылдырыйк (татар совет язучылары дискуссиясендәге чыгыштан) // Совет әдәбияты. 1936. №4. 40 б.

Гыйззәтуллин Н. Әдәби хәрәкәт // Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр, 1989. Т. 4. Б. 346.

Гыйлаҗев Т.Ш. Әдәби мирас: тарих һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 206 б.

Дөрес сүзгә җавап... бар!: «Чаян»да Шомбай белән әңгәмә // Галиев Ш. Сайланма әсәрләр: 5 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Т. 5. 441– 482 б.

Еники Ә. Әдәбият – тормыш фәне // Татарстан яшьләре. 1980. 11 декабрь.

Еники Ә. Хәерле сәгатьтә! // Татарстан язучыларының XI съездын ачканда сөйләгән сүзе // Казан утлары. 1989. № 11. Б. 127–128.

Җәлал С. «Ярдәм» мәҗмугасы // Татарстан хәбәрләре. 1922. № 30.

Җәлил М. Сайланма әсәрләр: 3 томда. Т. 3. Казан: Татгосиздат, 1956. Б. 123, 334.

Закирҗанов Ә.М. Заман белән бергә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 175 б.

Зарипов Р. Төрле-төрле уйласак та // Казан утлары. 2005. 7 сан. 143, 144 б.

Заһидуллина Д. Ф. Әдәбият кануннары һәм заман.. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 271 б.

Заһидуллина Д.Ф. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 255 б.

Заһидуллина Д.Ф. Тәнкыйтьсез үсеп булмас // Казан утлары. 2003. № 8. Б. 146–152.

Зөлкарнәев Ф. Әверелеш: шигырь піародокслары // Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 119 б.

Зөлкарнәев Ф. Чакма чакмый, ут чыкмый. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. Б. 21–54.

Ибраһимов Г. Әдәбият кануннары. Теория словесности. Өченче басма. Казан: Сабах, 1919. 126 б.

Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 том. 32, 237, 241,243, 301–307, 312, 38-390, 428, 445, 507, 508, 518 б.

Ибраһимов Г. Әсәрләр. 8 томда. Т. 6. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.– Б. 237–243, 398.

Исламов Р.Ф. Әдәбият гыйлемендә эзлебез // Мәдәни җомга. 2009. 23 окт., 30 окт. .

Исхакый Г. Ике йөз елдан соң инкыйраз // Исхакый Г. Әсәрләр. 15 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. Т. 1. 154 б.

Камал Ш. Бер китапның уңышлы һәм уңышсыз яклары // Камал Ш. Әсәрләр. 4 томда. Казан: Таткнигоиздат, 1956. Т. 4. Б. 233–238.

Кандалый Г. Шигырьләр һәм поэмалар / төз., кереш сүз авторы М.Г. Госманов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 558 б.

Каюм Насыйри (1825–1945): тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. Казан: Татгосиздат, 1948.145 б.

Кол Гали. Кыйссаи Йосыф / хәзерге әдәби телгә шигъри күчермә авт.: Н. Хисамов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 21, 216, 217.

Котб. Хөсрәү вә Ширин (шигъри роман). Казан: Мәгариф, 2003.

Күроглы Х.Г. Борынгы төрки язмачылык // Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Т. 1. Б. 77.

Лаисов Н., Мәһдиев М., Ганиева Ф. Әдәбият теориясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 189 б.

Латыйфи Ф. 2002 ел прозасына бер караш (язучыларның «Әдәби ел йомгаклары» җыелышыннан) // Казан утлары. 2003. № 5. Б. 135–140.

Максуд М. Шәриф Камал әсәрләренең дүртенче томы турында // Камал Ш. Әсәрләр: 4 томда. Казан: Таткнигоиздат, 1956. Т. 4. Б. 6–9.

Мәһдиев М. Бәхилләшү // Мәһдиев М. Сайланма әсәрләр: 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Т. 3: Повестьлар, роман. Б. 3

Мәҗитов З. Бүгенге поэзиябездә кайбер тенденцияләр // Совет әдәбияты. 1965. № 4. Б. 113–118.

Мәҗитов З. Хәерләре белән үссеннәр // Казан утлары. 1967. № 1. Б. 121.

Мәрдәнов Р. «Шура» журналы (1908–1917): әдәбият мәсьәләләре. Казан: Рухият, 2001. 152 б.

Мәрҗани Ш. Әл-кыйсме әс-сани мин китаби Мостафад әл-әхбар фи әхваль Казан вә Болгар. Казан: Университет табгыханәсе, 1900. Б. 347.

Мәһдиев М.С., Мәҗитов З.М. Татар әдәби тәнкыйте тарихы: программа. Казан, 1986. 20 б.

Мәһдиев М.С. Ерактан яңгыраган аваз // Әдәбият һәм чынбарлык: XX йөз башы татар әдәбияты тарихына яңа материаллар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 127.

Мәһдиев М.С. Реализмга таба. XX йөз башы татар әдәбиятында чынбарлыкның чагылышы мәсьәләләре. Казан: КДУ нәшр., 1989. 154 б.

Мәһдиев М.С. Кыршауланган әдәбият // Соц. Татарстан. 1990. 1 апр.

Михалков С. Халыкчан әдәбият, тормышчан әдәбият // Казан утлары. 1974. № 10. 169–174 б.

Минһаҗева Л. Ибраһим Салахов (тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Матбугат йорты, 1999. Б. 71, 73.

Миңнуллин Ф. Балта явызлар кулында: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 334 б.

Морат Г.В. Җәяүле кошлар: публицистик мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 223 б.

Мостафин Р. Бүгенге романнарны укыганда // Совет әдәбияты. 1960. № 7.

Мостафин Р. Тәнкыйтькә – тәнкыйть уты // Казан утлары. 1972. № 4. 154–165 б.

Мостафин Р.Ә. «Берәү» повесте һәм аның тәккәбер герое // Алга барышлый: тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Б. 63–66.

Мөхәммәд Гаяз. «Бай углы»ның беренче басылуына мөкаддимә // Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. Т. 1. Б. 113.

Мөхәммәд Гаяз. «Бай углы»ның икенче басылуына мөкаддимә // Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. Т. 1. Б. 114.

Мөхәммәдиев Р. Әгәр без янмасак. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 144 б.

Мусин Ф. Әдәбият белеме һәм тәнкыйть // Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Т. 4: Татар совет әдәбияты (1917–1941). Б. 487, 491.

Мусин Ф. Көмеш көзге: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 256 б.

Мусин Ф. Әдәбият тарихын яңача өйрәнү // Казан утлары. 2005. 7 сан. 147, 157 б.

Мусин Ф. Әдәби хәрәкәт // Мирас.1996. № 5–6. Б. 104–124.

Мусин Ф. Әдәбият фәне һәм тәнкыйть // Мирас. 1996. № 12. Б. 38–47.

Мөхәммәдиев Р.С. Күңелдәге эзләр // Якутлар табыладыр вакыт белән: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Б. 141–143.

Наум Х. Октябрь (Уфа). 1931. № 1. Б. 3.

Нәҗми К. Социалистик реализм өчен! // Совет әдәбияты. 1936. № 4. Б. 27–32.

Нәҗми К. Татар матур әдәбияты. совет язучыларының I Бөтенсоюз съездында ясалган докладның кыскартылган стнеограммасы буенча // Совет әдәбияты. 1934. № 10. Б. 39–49.

Нигъмәти Г. Әдәбият фәненең үсеш юлы нинди булырга тиеш? // Яңалиф. 1930. № 1. Б. 42.

Нигъмәти Г. Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре // Совет әдәбияты. 1933. № 11–12. Б. 84.

Низами Р. Тәнкыйть тә – тирән дәрьядыр // Казан утлары. 2007. № 6. Б. 169–172.

Низамов И.М. Эссе жанры // «Әдәби-публицистик жанрлар» курсыннан журналистика факультеты студентлары, аспирантларына уку кулланмасы. Яр Чаллы: Оператив полиграфия лабораториясе, 2007. 80 б.

Нури З. Яшьләргә – яшел урам // Татарстан яшьләре. 1966. 17 дек.

Нуруллин И. Кыскалык турында // Совет әдәбияты. 1963. № 6. Б. 128.

Нуруллин И. Иҗат методыбыз турында уйланулар // Реализм турында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. Б.58.

Нуруллин И.З. Әдәбият теориясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 89 б.

Нуруллин И.З. XX йөз башы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 288 б.

Нуруллин И. Акыл һәм күңел кушканча // Соц. Татарстан. 1990. 25 март.

Нуруллин И. Гадел булыйк! // Соц. Татарстан. 1990. 3 май.

Нуруллин И. Булган ул тәнкыйди реализм! // Казан утлары. 1995. № 2. Б. 176–180.

Рәхим Г. Шәрык шагыйрьләре. Казан: «Корылтай» ширкәте, 1919. Б. 2–5.

Рәхим Г. Урта мәктәпләрдә әдәбият укыту турында // Мәгариф. 1924. № 5.

Рәхим Гали. Биш ел эчендә татар әдәбияты // Биш ел эчендә. Казан, 1925. Б. 153–195.

Рәхим Г. Халык әдәбиятымызга бер караш // Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз. Раиф Мәрдәнов, Ирек Һадиев. Казан: Җыен, 2008. Б. 76.

Салахов И. Тайгак кичү. Роман-хроника // Казан утлары. 1988. № 4. Б. 16–74; № 5. Б. 3–58; № 6. Б. 3–52.

Салахов И. Колыма хикәяләре. Фажига-хроника. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 256 б.

Салахов И. Тарих үзе олы сабак ул // Татарстан яшьләре. 1988. 18 декабрь. 9 б.

Салахов И. Правда нужна живым // Советская Татария. 1988. 20 декабря. С. 4.

Салахов И. Колыма хикәяләре турында // Социалистик Татарстан. 1989. 27 август. 3 б.

Салахов И. Йөрәктәге яралар // Социалистик Татарстан. 1989. 16, 18, 20 июль.

Салахов И. Это мой долг перед жертвами // Ленинская правда. 1990. 21 март. С. 3.

Сәгъди Г. Әдәбиятыбыз // Мөгаллим, 1913. №2. Б. 25.

Сәхәпов Ә. Кырыс чынбарлык. Казан: Мирас, 1995. Б. 26.

Сәгъди Г. Бездә әдәби тәнкыйд. Үктәбернең ун еллыгына. Казан: Безнең юл, 1927. 22 б.

Сәгъди Г. Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты. Казан: Татгиздат, 1930. Б. 71.

Такташ Һ. Автобиография // Такташ Һ. Әсәрләр. 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Т. 3. 360–363 б.

Такташ Һ. Татарстан Советлар Җөмһүрияте Башкарма комитетына үтенеч, 1929 ел, 17 апрель // Такташ Һ. Әсәрләр. 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Т. 3. 364–366 б.

Такташ Һ. Татарстан пролетариат язучылары оешмасына гариза, 1930 ел, 19 май // Такташ Һ. Әсәрләр. 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Т. 3. Б. 366–369.

Татарстан китап нәшрияты директоры иң күп сатылган китапларны атады // Наш Черемшан. 2017. 28 сентября.

Тинчурин К. Югары сыйфат өчен // Совет әдәбияты. 1936. № 4.

Толымбай Г. «Галимҗан Ибраһимов» җыентыгындагы ялгыш һәм дошман карашлар // Яңалиф. 1930. №5. Б. 70–73.

Толымбайский Г. Китапларны ничек нәшер итмәскә? // Татарстан. 1923. № 205.

Туйкә Ф. Халык әдәбиятын тикшерү юлында // Безнең юл. 1927. №18. Б. 33–37.

Тукай Г. Тәнкыйть – кирәкле шәйдер // Тукай Г. Әсәрләр: 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. Т. 3. Б. 245.

Укмасый М. Интикад // Йолдыз. 1911. 7 июль.

Укмаси М. Интикад // Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән – тәгъзияләргә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 231–233.

Фәттах Н. Шигырьме, әллә башваткычмы? // Татарстан яшьләре. 1965. 17 июнь.

Фәйзи Ә. Иҗат кыюлыгына – юл! // Коммунист. 1933. № 90.

Фәйзи Ә. Әдипнең эрудициясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. Б. 126, 271–274.

Фәйзуллин Р. Шомлы еллар, канлы җиңүләр (1934–1945) // Татарстан язучылар берлеге: публицистик уйланулар, тарихи фактлар, хатирә-күзәтүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. Б. 23.

Фәхретдин Р. Тәкъриз вә интикад // Шура. 1908. № 1. 24–26 б.

Фәхретдин Р. Интикад вә тагын… // Шура. 1916. № 17. Б. 410–412; № 18. Б. 433–435.

Халикова З.А. XX йөз башы – татар әдәби тәнкыйте формалашу чоры // Милли мәдәният. 2003. № 3. Б. 21–26.

Халит Г. Әдәби тәнкыйтебез киң колачлы һәм кыю булырга тиеш // Совет әдәбияты. 1963. №4. Б.147.

Халит Г.М. Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 375 б.

Халит Г.М. Яңа гасыр поэзиясе: XX йөз башы (1905–1917) еллар) татар поэзиясендә иҗат методы, лирик герой, традиция һәм новаторлык мәсьәләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 166 б.

Халит Г.М. Поэзия дерзаний: творчество Хади Такташа и вопросы метода, героя и стиля в татарской поэзии 20-х годов. Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. 258 с.

Халит Г.М. Портреты и проблемы. Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. 344 с.

Харис Р. Әйтәсе сүзебез соңармасын // Казан утлары. 1989. №11. Б. 133–135.

Харрасова Р.Ф. Иҗат лабораториясе: дәреслек-кулланма. Казан: РПФ ГАРТ, 2004. Беренче кисәк. 136 б.

Харрасова Р.Ф. Иҗат лабораториясе. Казан: КДУ, 2004. Икенче кисәк: поэтик иҗат. 228 б.

Харрасова Р.Ф. Уйлар Тукайга илтә. Казан, 2016. 248 с.
Харрасова Р.Ф. Тәнкыйть – кирәксез шәйдер. Казан: Бриг, 2016. 76 б.
Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе. Казан: Мәгариф, 2000. 351 б.
Хәлим А. Туксанынчы еллар әдәбияты // Казан утлары. 1999. № 4. Б. 137–140.
Хәлим А. Сез беләмсез кая барганны? // Казан утлары. 2005. № 1. Б. 109–136; № 2. Б. 96–120.
Хәсәнов М.Х., Мөхәммәдиев Р.С. Әдәби тәнкыйть һәм эстетик фикер мәсьәләләре // Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Т. 3: XX гасыр башы. 490–505 б.
Ходаяров Г. Матур әдәбият турында // Таң. 1929. 25 ноябрь.
Хөсни Ф. Кешегә мәхәббәт турында // Совет әдәбияты. 1954. №8. Б. 88.
Шакирова Ф., Мөсәллимов Р. Хатлардан юллар // Казан утлары. 1966. №2. Б. 154–155.
Шәрәфиев Р. К. Уйлы күңел: тәнкыйть мәкаләләре, әдэби-публицистик язмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 141 б.
Шәрәфиев Р. Киләме, күрәбезме? // Казан утлары. 2004. № 1. Б. 161–163.
Шәрәфиев Р. Безнең дә әниләр бар иде...// Казан утлары. 2002. № 3. Б. 171–175.
Шәрәфиев Р. Ак казлар чакыруы // Казан утлары. 2002. № 12. Б. 151–155.
Шәрәфиев Р. Хакны әйтүчеләр илдә бар // Казан утлары. 2003. № 8. Б. 153–159.
Шәрәфиев Р. Бәндәләр хатасы – бәндәгә сабак // Казан утлары. 2004. № 9. Б. 178–181.
Юзиев Н.Г. Традицияләр яңарганда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. 171 б.
Юзиев Н.Г. Әхмәт Фәйзи – тәнкыйтьче // Әдипнең эрудициясе. Әхмәт Фәйзи. Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. 5, 8 б.
Юзиев Н.Г. Шигърият дөньясы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.312 6.
Юсуф Хос Хожиб. Кутадгу билиг (татарча текстның тәрҗ. күрсәтелмәгән). Тошкент: Фан, 1971. Б. 666–667. URL: http://kitap.net.ru

*Чит телләрдәге әдәбият*

Abdolhossein Zarrinkoub. Naqde adabi. Tehran, 1947. S. 374–379.
Turk Ansiklopedisi. Cilt XXXII. Ankara, Devlet kitaplari, Milli Icitim Basimavi,1983. S. 512.

*Электрон чыганаклар исемлеге:*

Википедия. URL: www.ru.wikipedia.org
Живая литература. URL: www.litlive.ru
Пандия. URL: http://pandia.ru/

Русская литературная критика. URL: www.rl-critic.ru
Студенческая библиотека онлайн. URL: studbooks.net
Сужа СОШ. URL: suzha-school. ru/
Татарская электронная библиотека. URL: http://kitap.net.ru/
Фундаментальная электронная библиотека. URL:www.feb-web.ru
Халкым минем. URL: http://khalkym-minem.ucoz.ru/index/kor_n/0-46
Энциклопедический словарь СМ. URL: smi.academic.ru
Яндекс. URL: Словари slovari.yandex.ru

ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
1. ФӘН БУЛАРАК ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ
ҺӘМ АНЫҢ ТӨП НИГЕЗЛӘРЕ . . . . . . . . . . . . . 6
1.1. Әдәби тәнкыйтьнең предметы һәм бурычлары . . . . . 6
1.2. Әдәби тәнкыйть – иҗтимагый күренеш . . . . . . . . 10
1.3. Әдәби тәнкыйтьнең фәнни нигезе . . . . . . . . . . . 17
1.4. Әдәби тәнкыйтьнең публицистик нигезе . . . . . . . 23
1.5. Әдәби тәнкыйтьтә объективлык
һәм субъективлык мөнәсәбәте . . . . . . . . . . . 38
1.6. Әдәби тәнкыйтьнең объектлары . . . . . . . . . . 58
2. ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬНЕҢ ҮЗАҢЫ
ҺӘМ ҮСЕШ ЭТАПЛАРЫ . . . . . . . . . . . . . 68
2.1. Әдәби тәнкыйтьнең үзаңы формалашу . . . . . . . . . 68
2.2. Дөнья һәм рус әдәби-тәнкыйди фикер тарихы . . . . 89
2.3. Татар әдәби тәнкыйтен чорларга бүлү
мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 95
2.4. Татар әдәби тәнкыйтенең 1917 елгы инкыйлабтан
соңгы үсеш-үзгәреш баскычлары . . . . . . . . . . 101
2.4.1. Тоталитаризм дәвере әдәби тәнкыйте . . . . . . 103
2.4.2. Тоталитаризмнан соң әдәби тәнкыйть . . . . . . 160
3. ТӘНКЫЙТЬЧЕ ОСТАЛЫГЫ . . . . . . . . . . . . . 177
3.1. Тәнкыйди анализ принциплары . . . . . . . . . . . 179
3.2. Тәнкыйди осталык алымнары һәм сәнгатьлелек
мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
3.3. Бөтенлек категориясе . . . . . . . . . . . . . . . . 188
3.4. Эчтәлек һәм форма мөнәсәбәте . . . . . . . . . . 191

4. ИНФОРМАЦИЯ-ПРОПАГАНДА ЧАРАЛАРЫ
ҺӘМ ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ . . . . . . . . . . . . . . . 195
4.1. Пропаганда, агитация чарасы буларак
әдәби тәнкыйть . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 196
4.2. Тәнкыйтьченең һөнәри әхлагы . . . . . . . . . . . 202
4.3. Тәнкыйтьченең әхлакый позициясе . . . . . . . . . 206
5. ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ ЖАНРЛАРЫ . . . . . . . . . . . 211
5.1. Әдәби тәнкыйть жанрларын төркемләү . . . . . . . 212
5.2. Иноформатив төр . . . . . . . . . . . . . . . . . 226
5.3. Аналитик төрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 245
5.4. Әдәби-публицистик төр . . . . . . . . . . . . . . 271
ЙОМГАК . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 291
Белемнәрне исәпкә алу өчен сораулык . . . . . . . . . . 292
Әдәбият . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 294

Научное издание

***Харрасова Рифа Фатхрахмановна***

**ТЕОРИЯ ЛИТЕРАТУРНОЙ КРИТИКИ**

На татарском языке

Компьютерная верстка *Л.Ш. Давлетшиной*
Дизайн обложки *А.В. Булатова*

Подписано в печать 20.10.2017 г.
Формат 60×84 1/16. Бумага офсетная. Гарнитура Times.
Печать офсетная. Усл. печ. л. 18,1. Уч.-изд.л. 16,2. Тираж 200. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

ООО "ТКС Контакт"
420021, Казань, ул. Г. Тукая, 91